КАЗАН (ИДЕЛ БУЕ) ФЕДЕРАЛЬ УНИВЕРСИТЕТЫ

**Ф.Ш. Нуриева, Г.С. Нуриев, Ф.Г. Миңнуллин**

# Дини риторика

*Уку ярдәмлеге*

**КАЗАН УНИВЕРСИТЕТЫ**
**2013**

**УДК 80:2(075)**
**ББК 83.7:86.3я7**
**Н 90**

**Рецензентлар:**

Харисов Фираз Фахраз улы, Казан (Идел буе) федераль университеты Филология һәм сәнгать институтының хәзерге татар теле һәм аны укыту методикасы кафедрасы мөдире, педагогика фәннәре докторы, профессор;

Сафиуллина Резеда Риф кызы, Россия ислам институтының гуманитар фәннәр кафедрасы мөдире, филология фәннәре кандидаты, доцент

**Авторлар:**
филология фәннәре докторы, профессор Ф.Ш. Нуриева;
филология фәннәре докторы Г.С. Нуриев;
филология фәннәре кандидаты Ф.Г. Миңнуллин;
Н.Н. Сабирҗанов;
Н.Р. Сабиров

**Нуриева Ф.Ш.**
**Н 90** Дини риторика: уку ярдәмлеге / Ф.Ш. Нуриева, Г.С. Нуриев, Ф.Г. Миңнуллин һ. б. – Казан: Казан университеты, 2013. – 420 б.

**ISBN 978-5-00019-057-9**

“Дини риторика” уку ярдәмлеге булачак дин әһелләренең, мөгаллимнәрнең аралашу, чыгыш ясау осталыкларын – фикерне анык яңгырату, инануларын башкалар белән уртаклашу, кирәкле мәгълүматны, урынына һәм җаена карап, аңлата-төшендерә белү күнекмәләрен – теоретик һәм гамәли яктан камилләштерү мәсьәләләрен яктырта. Уку ярдәмлеге 033400 – “Теология” белгечлеге өчен, Дәүләт белем стандарты таләпләренә туры китерелеп, югары һәм махсус урта белем бирә торган дини уку йортлары студентлары өчен төзелде.

**УДК 80:2(075)**
**ББК 83.7:86.3я7**

**ISBN 978-5-00019-057-9**

© Казан (Идел буе) федераль университеты, 2013

# Кереш сүз

## Халык белән аралашуның асылы

**«(Ий, Мөхәммәд), син Раббың юлына хикмәтләр һәм матур үгетләр белән чакыр, алар белән бик тә гүзәл рәвештә бәхәсләш. Аллаһ тугры юлдан язганнарны бик яхшы белеп тора, Ул тугры юлга басканнарны да бик яхшы белә»**

**(«Нәхел (Бал корты)» сүрәсенең 125 нче аяте)**

Безнең тормыш аралашудан гыйбарәт, аның нигезен сөйләм тәшкил итә. Сөйләм үзе эчке һәм тышкы, көнкүрештә һәм халык арасында үтә торган аралашу да, вербаль (тел чаралары ярдәмендә) һәм вербаль булмаган (сүзсез, ым-ишарәләр ярдәмендә) аралашу да, табигый яки символик, мәгънәсез яки яшәеш өчен мөһим була ала. Ничек кенә булмасын, кешеләр аралашудан башка яши алмыйлар.

Сөйләмне һәр яклап күзәтсәк, аны аңлау һәм аның төрләре эчтәлегенең бер-берсеннән нык кына аерылып торуын күрәбез. Мәсәлән, сөйләмне үзара мәгълүмат алышу, шулай ук кешеләрне оештыру һәм җитәкчелек итү ысулы, җәмгыятьне тәртип, яшәү рәвеше һәм алымнары белән тәэмин итү дип тә карый алабыз. Сөйләмне тагын символлар һәм уйлап чыгарылган чынбарлыкны оештыру төре, күзалланган дөньяны барлыкка китерү һәм идарә итүнең универсаль юлы, җиһанның югары дәрәҗәдәге асыл үзенчәлеге дип тә аңлатырга мөмкин. Сөйләмне кайсы яктан аңлатсак та, без ялгышмабыз, чөнки сөйләм, тел – икесе дә иксез-чиксез җиһанның барлыкка килү серенә бәйләнгән, чиксез мөмкинлекләргә һәм бай эчтәлеккә ия.

Без үзебез гадәтләнгән дөньяда яшибез һәм туган көнебездән алып сөйләшәбез. Кеше өчен сөйләм гадәти һәм табигый күренеш. Әмма, кайвакыт, күп кеше сөйләшкәндә кыенсына, дулкынлана, кызара ук башлый. Бу хәл сөйләмеңә башкаларның игътибарын сизгәндә туа. Шул чак табигый сөйләм тиз арада авырая, кыенлаша. Без бу очракта бернинди чикләүләрсез узган көндәлек сөйләмнең иҗтимагый – халыкка ирештерү өчен оештырылган – сөйләмгә әверелүен күзәтәбез.

Тышкы яктан көндәлек сөйләмне халык өчен оештырылган сөйләмнән аеру кыен. Ни өчен барлык кеше дә халык алдында

сөйли башлагач, киеренкелек кичерә? Моның җавабы җиңел. Без халык белән аралашканда җаваплылык сизәбез һәм үз-үзебезне нindидер чикләүләрдә тотабыз, үз теләгебез белән кабул ителгән таләпләр йогынтысына эләгәбез.

Тирәнрәк уйлап карасак, аралашу кануннары бик күптәннән барлыкка килгәннәр һәм алар иҗтимагый берләшмәнең язмышын хәл итүче кешеләрнең төрле бәяләренә исәпләнә. Мөгаен, аңсыз дәрәҗәдә узганда, сөйләм төркем оештыру һәм тиз арада нинди дә булса карарга килүдә кирәк булгандыр. Бу яктан караганда, халык алдындагы чыгышларда киеренкелекнең барлыкка килүе аңлашыла. Ул җитәкченең идарә итү мөмкинлекләрен һәм дәрәҗәсен саклау чарасы булып торган. Халык каршында чыгыш ясаучы үзенең һәрбер чыгышы дәвамында җитәкче ролендә була.

Без халык алдындагы чыгыш (аралашу рәвеше) дип, билгеле бер төркем, берләшмә өчен әһәмиятле эчтәлекле сөйләм рәвешенә әйтәбез.

Халык алдындагы чыгыш тыңлаучыларга һәм сөйләүчеләргә бүленә. Сөйләүчеләр аралашу барышында игътибарга лаек була, тыңлаучылардан аерылып тора, аралашуның нәтиҗәлелеген арттыру өчен билгеле бер тәртипкә буйсына. Сөйләүчеләр берләшмә язмышы өчен әһәмиятле сорауларга җавап бирә, ә тыңлаучылар исә аларның карашларын кабул итәргә яки кире кагарга мөмкин. Халык алдындагы чыгышның нәтиҗәсе булып берләшмәне ныгыта торган, барлык кешенең дә мәнфәгатен истә тоткан карар тора.

Халык белән аралашуның эчтәлеге хәзер төрле төркемнәрнең карашларын аңлатуга, ә чыгышлар шул төркемнәр, берләшмәләр җитәкчеләренең бәхәсе, аралашуына әверелә.

Шуның өчен хәзерге заман риторикасында халык алдында чыгыш дип билгеле бер тәртип һәм йола, гадәт сакланган хәлдә, төркемнәрнең үз карашлары белән күмәк алмашу рәвешенә әйтергә була.

Димәк, аралашуның төп рәвеше – халык алдында ясалган чыгышлар – мәгълүмат тапшыру белән чикләнмичә, иҗтимагый аралашуда зур урын билиләр. Чыгышлар сөйләмдә чагылыш тапкан карашлар, фикерләр белән алмашу рәвеше генә түгел, ә иҗтимагый мөнәсәбәтләрне тудыра торган чарага да әйләнәләр.

# I. АРАЛАШУ ЭЧТӘЛЕГЕ

## Аралашу даирәсе

XIX гасырның ахырында төрле танып белү объектын аңлатып бирүнең мөһимлеге анықланды. Аңлату (интерпретация) барышында предмет сөйләм ярдәмендә тәкъдим һәм тәкъдир ителә, аерым бер мәгънә белән башкаларыннан аерып күрсәтелә. Өстәвенә аңлатулар чикләнмәгән, күпсанлы була һәм аларның һәркайсы теге яки бу максатны тормышка ашырырга мөмкинлек бирә.

Мәсәлән, тыңлаучыларны сүз сөйләүче үз ихтыярына буйсындырырга тиешле абстракт кешеләр төркеме һәм нәрсәгә дә булса инандырырга кирәкле кешеләр итеп аңларга мөмкин. Тыңлаучыларны сөйләүче “хезмәт итәргә тиешле ” эш кушучылар һәм аралашу ысулларын файдаланучылар, яисә чыгыш ясаучының киләчәген хәл итәрлек кешеләр төркеме итеп аңлатырга була. Мөмкин булган аңлатуларның саны күп һәм һәр аңлату чыгышның максатларын, стратегиясен, тактикасын һ.б. аралашу чикләрен булдыруга этәргеч ясаячак.

Шунысы билгеле, тыңлаучыларны гына түгел, шулай ук сөйләүче шәхесен, мәдәни дәрәҗәне һәм төркемнең, мохитнең аралашу максатларын һәм шартларын, аралашу нәтиҗәсенә мөнәсәбәтне, аралашуга ирешү юлларын һ.б. да аңлатып бирергә мөмкин. Иҗтимагый (халык белән) аралашуга бу яктан карасаң, ул чиксез күп санлы үзгәрешләргә ия булган катлаулы һәм күп тармаклы системага әверелә. Хәзерге көндә аралашуда өч төрле нәтиҗәле фикер сөреше күзәтелә:

1) Монистик модель бербөтен, бердәнбер нигезне тәшкил иткән асыл (субстанциональ) башлангычны аңлатуга нигезләнгән, мәсәлән, аралашуны чыгыш ясаучы шәхесенә бәйле дип раслау.

2) Дуализм ике башлангычтан барлыкка килгән бербөтен буларак сыйфатлана. Мәсәлән, аралашу сөйләүче шәхесенә һәм тыңлаучылар составына бәйле дигән фикер.

3) Плюрализм, үз чиратында, күп шартларга бәйле күзаллауга нигезләнә: предметны күп кисәкләрдән торган система итеп аңлата. Элементларның бәйләнеше һәм үзенчәлеге бербөтенлек тәшкил итә, ә бөтенлек, үзләренең гадәти торышларыннан аерылган элементлар бәйләнешен һәм үзенчәлекләрен билгели. Мәсәлән,

аралашуның нәтиҗәлелеген сөйләм һәм аралашу чараларын оештырудагы үзара бәйләнеш билгели.

Күпфикерле аралашу рәвешен аралашу даирәсе яки аралашуда бәйләнешләр киңлеге дип атарга мөмкин. Аралашу даирәсе төрле багланышлар оештыра торган кисәкләрдән берләшә, алар сөйләүченең максатчанлыгы, сөйләм сәбәпләре нигезендә һәм тыңлаучылар мөмкинлеге белән бербөтенгә әйләнәләр.

Аралашу киңлеге – катнашучыларның төрле карашларын ныгыта, берләштерә, фикер алышуларына мөмкинлек бирә торган аралашу эшчәнлеге ул.

Аралашу төре никадәр уйланылган булса, иҗтимагый мәсьәләләрне сөйләмдә хәл итү һәм тормышка ашыру шулкадәр җиңелрәк. Аралашу системасы берләшмәләрдә иҗтимагый, дини, сәяси мәсьәләләрне анализлау, ирешелгәннәргә нәтиҗә ясау, хаталарны төзәтү һәм үсеш юлларын үзгәртү программасын аңлау, тормышка ашыру мөмкинлеген бирә.

## Аралашуда катнашучылар

Аралашу мохите, читтән караганда, үзара аралашучы кешеләрдән һәм аларның әйткән сүзеннән, сөйләмнәрендә белдерелгән фикерләрдән гыйбарәт. Алда әйтеп узылганча, аралашу мохитендә берәүләр – сөйләүче, икенчеләр исә – тыңлаучы. Аралашу нәтиҗәле булсын өчен, сөйләүчеләргә дә, тыңлаучыларга да билгеле бер ныклы калыпларга нигезләнеп эшләү мөһим. Аралашу максатыннан һәм ысулыннан чыгып, әңгәмәдәшләрне төрлечә аңларга мөмкин: сөйләүчене – оратор, хөтбәче, вәгазьче, аралашу субъекты, автор, сүз остасы, дәлилләүче, аралашуны тудыручы, аралашу мохитен тудыручы, ниндидер гамәл кылырга өндәүче, чыгыш ясаучы һ.б. төрле атарга мөмкин. Билгеле бер очракта бу атамалар синоним булып та, бер-берсен алыштырып та килә алалар. Сөйләм үзенчәлекләрен үз эченә алганда һ. б. күп кенә очракларда бу синонимнар билгеләмәләргә әвереләләр. Алар сөйләүчене сыйфатлый торган махсус эчтәлекне белдерә башлый. Димәк, оратор дип үз карашларын яклаучы теләсә кемне – дин эшлеклесен, укытучы, язучы, рекламачы һ. б. әйтергә була. Шул ук вакытта оратор дип, үзенең ораторлык карашларын урнаштыручыны, аралашу оештыручыны да әйтеп була.

Дәлилләүче дип, сөйләм вазифаларын тудыручы һәм фикерләрен раслап ассызыклаучыны әйтергә була. Фикерләрне гамәл (акт) аша да дәлилләп була.

«Актор» – сөйләм вакытында нык активлык күрсәтүче һәм үз сүзләрен тормышка ашыручы оратор. Сөйләм субъекты да шул мәгънәдә килергә мөмкин. Бу вакытта сөйләмдә катнашучының нәтиҗәле эшчәнлеге ассызыклана. Без төрле төшенчәләр кулланачакбыз, күп очракта – оратор, чыгыш ясаучы, вәгазьче, хөтбәче.

Әңгәмәдә катнашучы аралашу субъекты буларак чыгыш ясаганда, кабул ителгән кануннарга нигезләнеп эшләве мөһим. Аралашуны оештыручы буларак, шәхес, оратор ролендә чыгыш ясый: ул үз карашларын тыңлаучылар аңларлык дәрәҗәгә житкерүдә сөйләменең максатын билгели. Чыгыш ясауның формасы һәм максаты билгеле бер кагыйдәләргә нигезләнеп, берләшмәдә катнашучыларның таләпләренә җавап бирергә тиеш. Тыңлаучылар да билгеле бер вазифа үтиләр. Алар актив рәвештә әңгәмәгә катнашалар. Аларның да актив рәвештә катнашуы һәм җаваплы булуы мөһим. Чөнки бу әңгәмә оештыруга принципиаль рәвештә йогынты ясый. Хәзерге заман аралашу даирәсендә тыңлаучыларга сөйләмне кулланучылар, адресатлар, реципиентлар, корреспондентлар, оппонентлар һ. б. күптөрле билгеләмәләр бирәләр.

«Реципиент» дип дәлилләр, раслаулар юнәлтелгән тыңлаучыларга әйтәләр.

«Корреспондент» – ул оратор белән кара-каршы әңгәмә урнаштыручы, чыгыш турында фикерләрен житкерүче.

«Оппонент» дип оратор карашларына бәя бирүче һәм тәнкыйть итүче тыңлаучыга әйтәләр.

Ораторның карашларын аңлау һәм тыңлау, соңыннан шуны кабул итү яисә кире кагу – тыңлаучының төп бурычы. Мәсәлән, иң гади мәгълүмати характерда булган сөйләмне хөтбәче тыңлаучыга аңлашылырлык дәрәҗәдә житкерә. Тыңлаучылар үз чиратында бу мәгълүматны кабул итә, эшкәртә, аңлый. Тыңлаучының карашлары хөтбәче ярдәмендә барлыкка килгән кебек, тик тыңлаучының үзенең дә монда роле зур.

## Сөйләм мөнәсәбәтләренең төзелеше

Аралашу вакытында ораторлар нинди генә ысуллар кулланмасыннар, системалылык үрнәге дини, мәдәни, сәяси,

башка иҗтимагый шартларда да шул ук кала. Кайбер иҗтимагый хәлләрдә мәдәнилеккә капма-каршы аралашу да очрарга мөмкин. Мәдәни һәм мәдәни булмаган аралашу асылын аңлау яхшылык һәм яманлык мәсьәләсе кебек үк гади түгел. Әйтергә кирәк, аралашуның мәдәни булмаган төзелеше берләшүгә комачауларга мөмкин. Мәдәни һәм мәдәни булмаган аралашу рәвешләрен билгеләүдә ораторның үзен аралашу эчтәлеге белән тиңләштереп карарга була.

Сөйләм җирлегендә оратор (мәсәлән, вәгазьче) үз карашы өчен җаваплылык тоя, язмышын сөйләм максаты һәм кыйммәте белән берләштерә, чөнки бу – мәдәни аралашу барышы. Оратор үз карашларыннан ераклаштырылган җирлектә чыгыш ясаганда, үзе өчен түгел, ә тыңлаучылар өчен аралаша, эшчәнлек нәтиҗәсе өчен җаваплылык тоймый. Бу аралашу төре мәдәни булмаган аралашу була.

Һәр очракта да аралашуны оештыру ораторддан да, тыңлаучылардан да төгәллек, тәңгәллекне, тик ияреп баруны һәм нәзәкатьлелекне таләп итә.

Охшаш ситуацияләрне күп кенә фикер ияләре фәлсәфи планда да караган, бигрәк тә Э.Кант. Аның теоретик һәм практик аң, шулай ук иҗтимагый мөнәсәбәт этикасын тәнкыйтьләве тикшерелә торган ситуацияне шактый ачыклап бирә ала. Катгый боерык (категорик императив) максатларын аңлаган хәлдә берләшмәнең кызыксыну даирәсенә туры килгән отышлы юлдан барырга киңәш итә Кант. Проблемалы ситуация теоретик аңны чикли, бу фикерләү рәвеше кешенең тәҗрибәдән тыш проблемаларны чишә алмавы сәбәпле, каршылыкка очрый. Хәзерге чорда акыл эшчәнлегенә бәйле бу проблема мәдәни яңарышлар белән бәйләнгән, чөнки халык мәгълүмати алгарыш, үсеш турында инанып фикер йөртә алмый.

Берләшмәнең кабул ителгән үрнәкләр чигеннән тайпылуы кеше алдына шәхес характеры мәсьәләсен куя: җәмгыятькә зыян китермәс өчен нишләргә? Кант кешенең фикерләве һәм иреге башка кешеләр ихтыяҗына юнәлтелгән булсын, нигездә, берләшмә әгъзалары өчен үрнәккә әверелә алсын дигән тәкъдим әйтә. Тикшерелә торган бәйләнештә оратор үзе дә берләшмә әгъзасы, ул берләшмәнең яңарышына, үзгәрүенә һәм үсешенә ярдәм итә. Сөйләм сүзләр җыелмасы гына түгел, ә тормышны үзгәртү турында тәкъдимнәр дә. Россия язмышы шуны күрсәтә: идеолог һәм политиклар керткән “яңалык”лар һәрвакытта да көтелгән һәм уңай

нәтиҗәләрне бирми. Яңалык тарафдарлары сөйли торган сүзләр, еш кына, берәү дә уйламаган хәлләргә әверелә; уйланган һәм сөйләнгән очракларда да, аларның сүзләренә колак салмаган булганнар. Хәзерге сөйләм колакларны матур риторик фигуралар белән бик үк "ләззәтләндерми", ә көчле технологияләр, ысулларга ия миллионнарның аңын киләчәк бурычларга юнәлтә.

Әлеге шартларга бәйле рәвештә хәзерге көн сөйләм мөнәсәбәтләренең иң кимендә, өч төрен аерып күрсәтергә мөмкин. Аларга – фикерләү, сүз куллану һәм әхлакый үрнәкләр яки сөйләм белән берләшмәнең бөтенлегенә, иминлегенә аңлы мөнәсәбәт тәрбияләү кирә.

### *Хәзерге сөйләм төзелеше үзенчәлекләре*

Ораторга – бүгенге җәмгыятьтә берләшмә яңарышын билгеләүчегә – акыл эшчәнлеге белән бәйле мөстәкыйльлек кирәк. Оратор “башка кеше акылы белән” яши алмый, аның, чыгышы эчтәлеге сыйфатында, тыңлаучыларга алынма һәм тәнкыйди карашсыз фикерләр тәкъдим итәргә хакы юк, чөнки алар берләшмә язмышын хәл итәргә мөмкин. Ораторларның, бигрәк тә дин эшлеклеләренең битараф чыгышлар ясау вакыты үтте. Шуңа да хәзерге җәмгыяттә сөйләмне акыл эшчәнлеге нәтиҗәсендә үзгамәлгә ашыру дип аңларга кирәк. Ә оратор тәрбияләү барышында, аның чыгышына тәңгәл яңгыраячак акыл эшчәнлеген камилләштерми мөмкин түгел.

Ораторларның чыгыш үрнәкләре системасы күбрәк аралашуның формаль ягына карый, шуңа күрә риторика иҗтимагый үсешкә дә, аңга да, чыгыш ясаучы кеше буларак оратор белән дә бәйле түгел. Дөресен генә әйткәндә, оратор сөйләме төзелеше берләшмәнең акыллы әгъзасы тәкъдим иткән фикерләрне гамәлгә ашыру омтылышы булып тора. Чын ораторның йөзен акыл һәм әхлак кушылмасыннан торган чыгышыннан ачыклап була.

Әхлакый үрнәкләргә җавап бирерлек чыгыш ясаган ораторның сөйләме берләшмәне ныгытуга юнәлтелгән. Әзерлекле оратор әхлакый темага сөйләмендә дә акыл һәм танып белү мөмкинлекләрен берләшмәнең кызыксыну даирәсенә әйләндерә, тыңлаучы исә бу фикерләрне үз мәнфәгатьләре кебек кабул итә.

Шул рәвешчә, сөйләмнең тулы төзелешен шәхеснең яңача фикерләү үрнәкләре белән берләшмә мәнфәгатьләрен истә тоткан карашлары кушылмасы тәшкил итә. Сөйләмнең мондый идеаль

рәвеше тыңлаучыларга нык тәэсир итә. Сөйләмнең тулы һәм төгәл төзелеше оратор сөйләменең тәңгәл кабул ителүенә, тыңлаучыларның фикеренә әйләнүне исәптә тота. Камил аралашу – ораторның тыңлаучылардан хуплану, йогынты ясау, алар тарафыннан кабул ителү мөмкинлеге булган очрак. Нәтиҗәдә, оратор карашларының тыңлаучыларга күчүе ярдәмендә, гомуми фикер барлыкка килә. Оратор карашларының берләшмә фикеренә әйләнүе өчен ул кулланган үрнәкләр белән туры килгән шартлар кирәк. Шуңа күрә, әгәр берләшмә үз эшчәнлегенә төзәтмә кертү белән кызыксынса, аралашу даирәсендә тыңлаучыларын да әлеге карашны кабул итәргә әзерләп куярга мәҗбүр була. Оратор карашларын тормышка ашыручы тыңлаучыларның дәрәҗәсе берләшмәнең ихтыяҗы һәм ораторның мөмкинлекләре белән билгеләнә. Тулаем алганда сөйләмнең һәрьяклап уйланылган төзелеше (универсаль структурасы) оратор чыгышының эчтәлеген барлыкка китерә. Ул тыңлаучылар тарафыннан тиешенчә кабул ителә һәм берләшмә системасын үзгәртү һәм камилләштерү максатында файдаланыла.

## Максатлы аралашуны оештыру

Аралашуның һәрбер төре максатка буйсына. Максат алдан уйланылган яки очраклы булырга мөмкин. Максат алдан билгеләнмәгән очракларда тыңлаучының бәясе еш кына каршылыклы була. Мәсәлән, әгәр тыңлаучылар чыгышны югары бәяләсәләр, бу чыгыш ясаучының һәм тыңлаучыларның максатлары туры килүен аңлата. Әгәр дә, киресенчә, тыңлаучылар чыгыш ясаучыны кабул итмиләр икән, димәк, чыгыш максатлары тыңлаучыларның ышанычын акламый. Бу очракта карашлары кабул ителмәгән аралашуда катнашучы, һичшиксез, әлеге ризасызлыкның сәбәпләренә төшенергә һәм алга таба бу хәлне булдырмас өчен тырышырга тиеш. Кызганыч ки, тормышта кешеләр ялгышларының сәбәпләренә җитди карамыйлар, күп очракта, уйлап эш итмиләр.

Халык алдында чыгыш максатны аңлы рәвештә оештыруны таләп итә, бу турыда исә күп кенә чыгыш ясаучылар онытып җибәрәләр. Ораторлык осталыгының мөһим бер таләбе булып, конкрет очракта, аралашу шартларын максатка тәңгәл оештыру санала. Шуны да истә тотарга кирәк, иң гади аралашу ситуацияләрендә дә, катлаулыларында да, чыгыш максатлары күп бу-

лырга мөмкин. Халык алдында чыгыш ясауның иң гади максаты булып ораторның аңа билгеләнгән вакыт аралыгында аудитория тарафыннан аралашу субъекты булып танылуы тора. Аралашуның иң катлаулы максатлары булып, үз чиратында, тыңлаучыларны эшчәнлеккә этәрүне, ораторның үз мәдәни дәрәҗәсен танытуны, профессионал һәм остазлык авторитетын булдыруны санарга мөмкин. Оратор тарафыннан тормышка ашырылган максатлар катлаулырак булган саен, аның аралашу дәрәҗәсе һәм статусы югарырык була. Үз чыгышының максатларын тормышка ашырган оратор гына, нәтиҗәле аралашу осталыгына ия дип исәпләнә. Тыңлаучыларга аралашу барышында гына түгел, ә бәлки аннан тыш та, үзенең мәдәни абруе исәбенә йогынты ясый торган ораторны гына оста оештыручы дип әйтергә мөмкин.

Максат куюны аралашуның эчке эшчәнлек барышы итеп тә, чыгыш оештыруның структурасы итеп тә карарга мөмкин. Әлеге структура төп максатка буйсына. Бу эш максатны тормышка ашыручының куелган бурычлары белән чыгыш эчтәлегенең туры килү исәбенә үтәлә. Төп максат катлаулырак булган саен, нәтиҗәле аралашу оештыру өчен кирәк булган ярдәмчел максатларның саны күбрәк була. Аралашуда эшлекле максат куя белү сыйфаты оратор осталыгының мөһим күрсәткече.

Чыгыш ясаучының гади максатлары түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

1) дәлилле килешү булдыру (конкрет аралашуның кагыйдәләре турында килешү);

2) тыңлаучыларга мәгълүмат ирештерү;

3) белем бирү һәм тәрбия чараларын үтәү;

4) булган белемнәрне тирәнәйтү;

5) билгеле хис-тойгы халәте булдыру (мәхәббәт, курку, кызгану, шәфкатьлелек, мәнфәгатьләреңнән баш тарту һ.б.);

6) аралашу эчтәлегенең мөһимлегенә ышану һәм аралашу сәбәпләрен дәлилләүне булдыру;

7) билгеле бер рәвешле эш итү теләген һәм халәтен булдыру;

8) карашлар, күнекмәләр һәм рухи кыйммәтләр оештыру.

Бу исемлектән шунысы аңлашыла – катлаулы максатларга гади максатлар аша гына ирешеп була. Максатларны тормышка ашыру – нәтиҗәле аралашу мөмкинлегенең мөһим чыганагы.

## Көнкүреш сөйләменең максаты

Аралашуны төрле яклап күзәтеп була. Кешеләр мәгълүмат алышу, үз мәнфәгатьләрен, үзләренең бу төркемдәгеләрчә уйлауларын хәбәр итү, иҗтимагый берләшмәләрдә үзара мөнәсәбәтләрен тормышка ашыру, үз халәтләрен оештыру, үз теләкләренә ирешү өчен аралашалар.

Аралашу барышында кабул ителгән үрнәкләр кулланыла, аралашу даирәсендә яңа оешкан үрнәкләр үзләштерелә. Без нигез үрнәкләрне тәрбия һәм уку барышында үзләштерәбез. Бергә аралашуда бу нигез үрнәкләр максатлар, төрле мөнәсәбәтләр, иҗтимагый мөмкинлекләр нәтиҗәсендә үзгәрәләр.

Көндәлек тормышта аралашканда үз алдыбызга нинди максат куюыбызны уйлап карасак, төрле җаваплар табарга мөмкин. Мисал өчен, берләшмә булып оешуны тәэмин итү өчен без тотрыклы, алдан әзерләнеп куелган аралашуны билгелибез. Исәнләшеп һәм саубуллашып, бер-беребезгә сораулар бирешеп, котлап һәм нәрсә дә булса теләп, елмаеп яки чырай сытып берәр оешма вәкилләре үз мәнфәгатьләрен алга сөрәләр, шәхси һәм уртак кәеф халәте оештыралар. Шунлыктан коллективта шат күңелле һәм ягымлы кешеләрне яраталар, ләкин караңгы чырайлы, астыртыннарны күрә алмыйлар. Шат күңелле кешеләр аралашканда үзләре башкаларга күңел күтәренкелеге, көч бирәләр, ә пессимистлар әлеге рухи көчтән файдаланалар.

Моннан тыш, көндәлек сөйләм үзенең төзелеше белән билгеле бер оешу-оештыру максатын күзаллый. Без, аралашу барышында, үзебезнең теләкне, ниятне, максатка ирешү юлларын, ысулларын хәбәр итәбез. Кешеләр үзләренең күңел көчләрен хисләре, кайгы-шатлыклары, өмет-теләкләре, истәлекләре турында сөйләүгә багышлыйлар.

Аралашу, һичшиксез, берләшмә әгъзаларының үзара мәгълүмат алышуында нык әһәмияткә ия. Көндәлек тормышта һәм кечкенә төркемнәрдә аралашуны күзәтү түбәндәге нәтиҗәгә алып килә: көнкүрештә аралашуның төп максаты булып катнашучыларның аралашуны оештыра алуы һәм кабатлап торуы, ягъни кечкенә төркемдә аерым әгъзаны берләшмә карашларына туры китереп тәрбияләве. Көндәлек сөйләмнең төп эчтәлеге аралашучының бу төркемдә үз урынын табуга, карашларын урнаштыруга юнәлдерелгән. Аралашу максаты белеп һәм белмичә дә

урнаша. Әлеге максат бөтен сөйләмне үзенә буйсындыра, гадәти сөйләмне дә катлауландырып, борчылуга кадәр үзгәртә ала.

Сөйләмне, бу очракта, кешенең үз урыны (статусы) өчен көрәше дип атап була. Статус өчен көрәштә: сүз мәгънәсе, интонация, сөйләмнең эчтәлеге, төрле бәяләр, гәүдә торышы, ишарә, күңел халәте, йөз чагылышы катнаша. Статус өчен көрәштә мәгълүмат алмашканда үзеңне тоту гадәте, макияж, имидж, элекке уңышлар һәм дәрәҗәләр, аралашу даирәсе, таныш-белешлек тә ярдәм итә. Мөнәсәбәт төренә: ым-ишарә, алдан-алы кисәтүләр, вәгъдәләр, күз яшьләре, истерика, янау һәм хәтта гамәл кылу – сүздән эшкә күчү дә керә. Алар аралашуда үз урыныңны билгеләргә булыша.

Көнкүреш һәм кечкенә төркем эчендә аралашуда иң мөһиме – максатның статус оештыруга юнәлдерелгән булуы. Аны оештыруда акыл һәм аңлашылып бетмәгән тоемлаулар, сүз белән бәйле (вербаль) һәм сөйләмнән тыш чаралар (караш, кул хәрәкәте, гәүдә торышы һ. б.) катнаша; килеп туган(ситуатив) яки күптәннән таныш (архитипик) хәлләр, гадәтләнгән эш-гамәл яки яңалыклар файдаланыла. Аралашуда катнашучылар бу мәдәни гамәлләрне аңлап кулланcалар, башка кешеләр белән бертигез дәрәҗәдә аралаша, үзләрен уңай хис итә, кечкенә генә төркемнәрдә дә үзләренең максатларына ирешә алачаклар.

## Халык белән аралашуның максаты

Халык алдында аралашу, инде билгеле булганча, күпмедер дәрәҗәдә, иҗтимагый-мәдәни яңарышны тәэмин итә. Ул үтә шәхси (трансперсональ) үзенчәлеккә ия һәм үзенең максатчан оешуында тар аралык чикләреннән үтеп китә. Җәмгыятьнең сәяси һәм төп кыймматләре эчтәлегенә бәйле рәвештә, аралашу ике стратегик юнәлеш ала: гражданлык һәм буйсынучанлык.

Буйсынучанлык юнәлешенең авторитар аралашу кануннары белән туры килүе инде билгеләнде. Буйсынучанлык тибы өстенлек иткән аралашуда кабул ителгән үрнәкләрнең оештырылуы, үтәлү рәвеше җитәкчелектән тора, берләшмәнең әгъзалары тарафыннан көчәйтелгән аралашу барлыкка килә. Халык алдында аралашу барышында оешкан мөнәсәбәтләр эчтәлеге бу очракта читтә кала. Әлеге аралашу шартларында югары җитәкчеләр (элита) ихтыяры төп фикергә әверелә, ә бу фикернең эчтәлеге тормышка ашырылырга тиеш максатка әйләнә, ә тыңлаучыларга файдасы

игътибарга алынмый. Буйсынучанлык рәвешендәге аралашуда оратор берләшмә җитәкчелегенең теләкләрен үти, аның максатлары җитәкчелек бурычлары белән тәңгәлләшә.

Аралашуның демократик рәвешенә гражданлык юнәлеше хас. Аның асылы – мәдәни-аралашу даирәсенең кагыйдәләрен төп үрнәк итеп кабул иткән субъектның ихтыярын һәм теләген тормышка ашырудан гыйбарәт. Гражданлык юнәлеше ярыш шартларында шәхси мөмкинлекләрне нәтиҗәле үзгәртеп коруга юнәлтелгән. Шуңа күрә аралашу барышында сөйләм эчтәлеге әһәмиятле булып тора, ә элита карашы тәкъдим ителгән эчтәлек белән туры килүенә бәйле рәвештә кабул ителә яки кире кагыла.

Шул рәвешле, буйсынучанлык стереотибы оратор карашларының элита фикерләрен яки элита фикере белән туры килгән күпчелек фикерен тәңгәлләштереп карый. Буйсынучанлык стратегиясе белән чыгыш ясаучы оратор берләшмә җитәкчелегенә “ләббәйкә” мөнәсәбәтендә булуын танытырга омтыла.

Халык алдында чыгыш ясауның гражданлык стереотибы капма-каршы максатны күз алдында тота. Әлеге капма-каршылыкның асылы үзара ярышта шәхси фикер үтәлүдә түгел, ә ярашуның эчтәлеге белән билгеләнгән максатта җиңү яулау ихтыяҗыннан гыйбарәт. Гражданлык тибындагы аралашуда ораторның төп максаты тыңлаучыларны үз карашларына ияртүгә кайтып кала.

Оешу рәвеше ягыннан гражданлык халәте буйсынучан аралашу системасындагы җитәкчелек халәте белән тәңгәл килә. Аерма шунда: элита тыңлаучыны үзенә ияртүдә нигез итеп чыгыш эчтәлеген еш кына икенчел, өлешчә эчтәлек итеп, ә эчтәлекле нигез сыйфатында берләшмә җитәкчелеге ихтыяҗын һәм ихтыярын файдалана.

Оратор-гражданинга тыңлаучыны үз карашларына ияртү өчен ул карашларның дәлилләнгән булуы мәҗбүри. Тыңлаучыларны үз фикереңә ияртү төрлечә тормышка ашырылырга мөмкин.

## Аралашу нәтиҗәләрен тикшерү, үзгәртү мәсьәләсе

Аралашуның күп мәсьәләләре аның эчке һәм тышкы чагылышы үзенчәлекләренә бәйле. Аралашучы, тыңлап кына торучылардан аермалы буларак, үзенең гел аралашып яшәвен танып-белүнең башка ысуллары аша аңлый. Мәсәлән, эчке тавышыңны тоемлау ми эшчәнлеге аша башкарыла. Аралашучылар тавышны һава

дулкыннары ярдәмендә ишетәләр. Техник җиһазлар сөйләмне шулай ук һава дулкынлануы аша яздыра.

Бу яңгырау мохитләрендәге дулкыннар ешлыгы аермасына бәйле рәвештә һәрбер кеше ике төрле тавышка ия. Берсе – шәхси, кеше үзе генә ишетә торганы, эчке тавышы. Икенче тавышны барлык кеше дә ишетә һәм ул техник чаралар ярдәмендә язма рәвештә «яши». Моңарчы тавышын ишетмәгән, ләкин бөтен кешегә таныш булган үз тавышын ишеткәч, кагыйдә буларак, кеше югалып кала. Ул тышкы тавышын үзе теләгән рәвешкә яраклаштырырга омтыла, ләкин бу мөмкин эш түгел. Күп кешеләр, башкаларның алар белән генә таныш булуларын, аларны гына ишеткәннәрен аңласалар да, үзләренең тышкы тавышларын “тыңлый алмыйлар”.

Шул ук хәл кешенең күрмә образларны кабул итүенә дә хас. Күп кеше, үзенең тышкы образын танып белүдә үрнәк итеп, көзгедәге кыяфәтен сайлый. Үзенең яңа киемен бәяләүче яшь ханымга игътибар итсәк, ул, ир-атларга бик үк табигый кебек тоелмаган, төрле гәүдә торышын ала. Ир-ат, күпчелек очракта, туры басып бер-ике тапкыр көзгегә карап алу белән канәгатьләнә.

Шул ук вакытта бу ясалма образ тышкы кыяфәтебезгә бәя бирүдә камиллек үлчәме булып кына калмый, хәтта кеше образын тулысынча тудыра. Әгәр дә фотосурәтләрне һәм видео-язмаларны кабул итүгә игътибар итсәгез, кешеләрнең үзбарлыклары белән күзалланган сурәтләрен чагыштырганда төрле образлар тудыруларына ышанырсыз. Үзләрен күреп, танып белүдән куркып калган кайбер кешеләрне дә очратырга мөмкин.

Халык белән аралашу – ораторның тыңлаучыларга үз йөзен танытуы. Чыннан да, чыгыш ясаганда без үзебезнең тавышны, тышкы кыяфәтне, фикерли һәм сөйли белүебезне күрсәтәбез. Без уй-фикерләребезне сөйләп, күңелебезнең сер пәрдәсен ачабыз, тыңлаучыларны үзебезнең хыялларыбызга, рухи кыйммәтләребезгә, күзаллауларыбызга багышлыйбыз, ихласлыгыбыз белән уртаклашабыз. Аралашу технологиясенә караган барлык шартлар турында уйлаганда тормышчан аралашуда күзалланган сурәти һәм камил үрнәкләр чагыштырылганда күп кыенлыклар туа. Бу кыенлыкларга мөнәсәбәт төрлечә була: бөтен мәсьәләләрне инкяр итүдән алып, халык алдында аралашудан тулаем баш тартуга кадәр. Шул ук вакытта аралашу бик мөһим эшчәнлек, аның четерекле мәсьәләләрен мәдәни һәм берләшмә таләпләре кысаларында да, аерым кешеләр арасында да чишәргә туры килә.

## Үзләштерелгән белемнәрне мөстәкыйль тикшерү өчен сораулар

1. Нинди һөнәри даирәләрдә кешенең сөйләм эшчәнлеге иң әһәмиятлеләрдән санала? Ни өчен әлеге даирәләр “югары сөйләм җаваплылыгы” һөнәрләре дип әйтелә?
2. Кешеләрнең үзара мөнәсәбәтләре һөнәри аралашу даирәсенең үзенчәлекләреннән чыгып билгеләнә дигән бәяләмә дөресме? Аңлатып үтегез.
3. Мөгаллимнең сөйләм оештыру үзенчәлекләре нидән гыйбарәт?
4. Аралашу вазыйфасын аңлата торган «коммуникатив» һәм «гностик» терминнарының синоним булып килә алуын аңлатыгыз.
5. Аралашуның башлангыч элемтә урнаштыру өлешен “коммуникатив атака” дип әйтәләр. Ни өчен?
6. Визуаль багланыш нәрсә аңлата? Мөгаллимнең аралашу барышында күз карашының әһәмиятен фаразлагыз.
7. Төркемдә аралашуның уңай һәм кыен яклары ниндиләр?
8. Күп кеше белән аралашуда сөйләм тәртибе нәрсәсе белән үзенчәлекле?
9. Халык белән аралаша белү сәләте нәрсә дигән сүз?
10. Уңай аралашу стиленең күрсәткечләре ниндиләр? Нинди киңәшләрегез бар?
11. Аралашуда (чыгыш, әңгәмә, дәрес барышында) интонация ярдәмендә кабатлау алымы нидән гыйбарәт?
12. Укытуда сөйләм эшчәнлегенең гомумсөйләм халәтеннән аермасы нәрсәдә?

# II. РИТОРИКА. ДИНИ РИТОРИКА: ТАРИХИ КҮЗӘТҮ

## Риторика төшенчәсе

Риторика – ораторлык сәнгате, уй-фикер һәм аны яңгыратуның үзара мөнәсәбәте һәм исбатлау чаралары турындагы фән.

Гадәттә, риторика төшенчәсен фикернең сүзгә мөнәсәбәтен белдерә торган филологик дисциплина дип аңлыйлар. Кагыйдә буларак, риторика җирлегендә аерым бер тел үз системасыннан тыш күзаллана. Фәнни тикшеренү җирлеге булып чыгыш ясаучы (оратор яки аралашучы) һәм тыңлаучы (реципиент) сөйләменең структурасы тора. Моннан тыш риторикада исбатлауның сөйләм технологиясе, максатчан сөйләм оештыру чаралары тикшерелә.

Хәзерге җәмгыятьтә сөйләмнең кешегә йогынтысы көчәя бара. Мәгълүмат чаралары теге яки бу дәрәҗәдә сәяси чикләүләрне алыштырып, күпчелек халыкның аңына тәэсир итә. Бу сөйләм аралашу барышында кешеләрнең аңына, үз-үзләрен тотышына нәтиҗәле йогынты ясауга исәпләнә. Хәзерге лингвопрагматикада һәм гамәли риторикада фәннең предметы булып, тел билгеләренең кешегә булган йогынтысын өйрәнү тора. Риториканы киңәйтелгән мәгънәдә, мәдәният җирлегендә аралашу тәгълиматын оештыра-берләштерә торган фән итеп карарга кирәк.

Риторика, гамәли фән буларак, төрле җирлектә туган лингвистик фәннәрнең, философия, логика, психология, семантиканың теоретик белемнәрен туплый. Риторика, кабул ителгән карашларны тәкъдим итеп һәм халыкка тәэсирен исәпләп, чыгыш хәзерләүне һәм яңгыратуның технологиясен, аларны берләштерү кагыйдәләре җыелмасын туплый. Риториканың теоретик нигезләре сөйләмне оештыруда мөстәкыйль һәм иҗади шөгыльләнергә мөмкинлек бирә. Практик технологияләр сөйләүченең максатына туры килә торган нәтиҗәле аралашу оештыруда ярдәм итәләр. Риториканың теоретик һәм гамәли ягы бер-берсен тулыландырып тора һәм аларның кушылуы гына йогынтылы сөйләм күренешенә мөмкинлек бирә.

Фикерләүнең башка төрләре кебек үк, риторика да иҗтимагый тормышта билгеле вазифалар үти. Аларга гадәттә:

• ораторларның формалашуы – мәдәниятне үстерүгә йогынты ясаучы, риторик белемнәрне, күнекмәләрне һәм алымнарны

профессиональ дәрәҗәдә башкара алучы интеллигентлар тәрбияләү;

- иҗтимагый әһәмиятле мәдәни мәсьәләләрне хәл итәрлек аралашу оештыру, чыгышларда риторик дәлилләрне булдыру кагыйдәләрен төзү;
- җәмгыятьнең төрле сфераларында мәдәни казанышлар алмашу кырын оештыруга йогынты ясау;
- яңа берләшмәләр, аларның төрле структурасын оештыруга этәргеч бирү;
- җәмгыятьнең лаеклы әгъзаларын мәдәниятне җитәкләүчеләр дәрәҗәсенә җиткерүдә җәмәгать эшлеклеләренең гамәлләрен бәяләү критерийларын билгеләү.

Риториканы үзләштерү башлап чыгыш ясаучыга сөйләмен мөстәкыйль рәвештә һәм нәтиҗәле итеп оештырырга мөмкинлек бирә. Риторика телнең дөньяви-мәдәни тәҗрибәсен һәм аның аралашуда кулланылуын өйрәнеп, әзерлексез уза торган сөйләмнең чикләрен киңәйтә һәм һәрбер чыгыш ясаучыга тагын да тәэсирле сөйләм үрнәкләрен үзләштерергә мөмкинлек бирә. Тәэсирле сөйләмгә ия булу тормышта уңышка ирешүдә һәм профессиональ статусыбызга зур йогынты ясый.

## Риторик эшчәнлекнең төп кагыйдәләре

Тулы эчтәлекле аралашу берләшмә өчен мөһим карарларны күмәкләшеп кабул итү вазифасын башкара. Сөйләм шушы ук карарларны тормышка ашыруда терәк булып тора. Бу очракта халык белән аралашу кануннарын үтәү яки технологик җайланмаларга таяну, ягъни алгоритмга иярү уңышка алып килә. Риторик алгоритмның гомум кабул ителгән төзелеше түбәндәгечә була ала:

- Кешеләр аралашканда нинди дә булса мәгълүмат үзләштерәләр. Бу мәгълүматны сайлап алып, эчтәлеген аралашу максатына яраклаштырып, билгеле бер тәртиптә урнаштыралар. Яхшырак аңлашылсын өчен аны җыйнак фикер – тезис рәвешендә чагылдырырга кирәк. Риторикада бу эшчәнлек уйлап табу яки **концепция – ният төзү** дип атала.
- Тыңлучыларга йогынты ясауның нигезен тәшкил итә, шуңа күрә чыгышка әзерләнү **аудиторияне билгеле бер тәртиптә оештыруны** таләп итә. Һәрбер оратор нәтиҗәле аралашуда

тыңлаучыларның ихтималланган теләкләрен, мөмкинлекләрен исәпкә алып, сөйләменең үзләштерелү нигезләрен булдыра.

- Сөйләмнең эчтәлеге һәм тыңлаучының күңел байлыгы ораторга **чыгышы белән отышлы тәэсир итү юнәлешен** (стратегия) билгеләргә булыша. Чыгыш отышлылыгы билгеле бер максатны, сөйләмдә бәхәсле мәсьәләләр даирәсен, төп тезисны һәм оратор карашларын берләштерә. Аралашуның алдан билгеләнгән юнәлешенә тәңгәллеге, чыгышның, гомумән аралашуның, нәтиҗәлелеген нык арттыра.

- Алдан билгеләнгән юнәлеш аралашуның **үтәлү рәвешен (тактик оешуын)** билгели. Үтәлү рәвеше аралашу сәбәпләрен нигезләргә, тыңлаучыларга эчтәлекне, оратор карашларын кабул итәргә булыша.

- Оратор максатларына тыңлаучылары белән **нәтиҗәле аралашу** барышында гына ирешә ала. Мондый аралашу үзара итагатьле, яхшы мөнәсәбәтләр урнашканда мөмкин. Уңайлы, нәтиҗәле аралашу – югары мәдәни байлыклар исәбендә.

- Тотрыклы, нәтиҗәле аралашуны тәэмин итү өчен оратор тыңлаучылары белән үзара элемтә халәтен тикшереп тора. Реаль вакытта **аралашуны контрольдә тотуы һәм кирәксә, төзәтмәләр кертә алуы** ораторның профессиональ дәрәҗәсен билгели.

- Тәҗрибә туплап, оратор үзенең **осталыгын камилләштерә.**

Тәкъдим ителгән алгоритм теләсә нинди аралашуның нәтиҗәлеген арттыра. Нәтиҗәлелек, бу очракта, аралашу максатына ирешү, тыңлаучыларның мәгълүмати ихтыяҗларын канәгатьләндерү, чыгыш ясаучының да максатына ирешеп канәгатьләнү хисе кичерүе дигән сүз. Аралашуда әлеге кагыйдәләрнең тотрыклы күнекмәләргә әверелү мөмкинлеге ораторның киң күләмле танып белү һәм гамәли эшчәнлеген җәелдерүенә бәйле.

### Риторика һәм хөтбә-вәгазьчелек багланышлары

Озак дәверләр яшәешендә риторикага мөнәсәбәт тә үзгәреп торган. Уку-укыту эшчәнлеге белән бәйле замандашларыбыз телендә төрле эчтәлеккә яраклаштырылган риторика сүзе соңгы вакытта бигрәк тә еш кабатлана башлады. Тормышыбызның башка өлкәләрендә дә риторика, бер үк мәгънәдә, бер үк эчтәлектә аңлашылмаса да, киң кулланышта. Бүгенге көндә дә ул төрле

яссылыкта яши, күбәеп тә китте, кайвакыт риторика дип тә аталмый. Шул сәбәпле хәзерге җәмгыятьтә аралашу мәсьәләләрен тикшергән башка фәннәр чолганышында, риторикага, фән буларак үзенең йөзен саклап калырга туры килә.

Сүзебезне риторика белән бик якын мөнәсәбәттә булган дини риторика – хөтбә-вәгазьчелек (башка телләрдәге гомилетика төшенчәсенә якын; гомилетика – грекчадан ὁμιλία "әңгәмә, сөйләшү". Хәзерге риторикада гомилетика төшенчәсе уку-укыту һәм өндәмә сөйләм әзерләү теориясе мәгънәсендә дә йөри) тәгълиматы турында дәвам итик. Риторика белән хөтбә-вәгазьчелекнең үзара бәйләнеш мәсьәләләрен тикшерү берничә сәбәп белән аңлатыла.

Хәзерге риторика, аралашуга бәйле башка фәннәр рәтендә, күп кенә табигый һәм гуманитар фәннәр белән хезмәттәшлектә. Шулай булуга да карамастан, риторика һәм дин белеме (теология) багланышлары турында фикерләр аз яңгырый. Ислам мәдәниятендә хөтбәчелек, вәгазь сөйләү алым-ысулларында нәтиҗәле аралашу асылына кагылышлы күпме кыйммәтле мәгълүмат һәм тәҗрибә тупланган. Риторика буенча дәреслек-уку әсбапларында дини-рухани сөйләм үзенчәлекләре турында бүлек-бүлекчәләр урын алса да, алар риториканың гомумтеоретик кысаларыннан читләтелгән рәвештә язылган. Дөньяви басмаларда, дини күзлектән үткәргәндә, төгәлсезлекләр очрап тора. Әлеге җитешсезлекләр бүгенге фән юнәлешендә дини тәгълимат һәм тәҗрибәнең тиешенчә өйрәнелеп бетмәвеннән, аларның гуманитар белемнәрнең җитди чыганагы дип кабул ителмәвеннән килә.

Шул ук вакытта хәзерге сәяси шартлар ислам дине белеменең тәгълимати һәм кешеләрнең үзара аңлашу барышына (когнитив яссылык) иҗтимагый әһәмияткә ия максатчан йогынты ясарлык гамәли өлешләренә уңай мөнәсәбәт мөмкинчелегенә юл ачалар. Җәмгыятебездә мөселман өммәте көннән-көн ишәя, массакүләм мәгълүмат чаралары тарафыннан дини тормышның үрнәк яклары да күбрәк яктыртыла.

Ислам диненең көчәюе, атеистик юнәлештәге гадәти гуманитар белемнәргә ия булган кешеләрдән үзгә фикер йөртүче, башка рухи кыйммәтләр белән шөгыль-фигыль кылучы, аралашуда милли гореф-гадәтне торгызучылар даирәсенең киңәюенә алып килде. Әлеге күренеш хәзерге җәмгыятьтә мәгълүмати-аралашу

даирәсенең яңа эчтәлеген һәм аның нинди нәтиҗәләргә китерәчәген тәфсилле өйрәнү ихтыяҗын алга куйды.

Риторика кысаларында хөтбәчелек, вәгазьгә игътибар артуның икенче бер сәбәбе: әлеге аралашу рәвешенең риторика тарихында һәм, гомумән, иҗтимагый тормыштагы әһәмиятенә бәйле. Һичсүзсез, хөтбәчелек, үгет-нәсыйхәт кылу мөселман дөньясында риториканың билгеле бер чордагы үсешенә дә зур йогынты ясаган. Хөтбәчелекнең асылын тәшкил иткән вәгазь сөйләү ислам тәгълиматы киң таралганчы ук билгеле булган, шулай ук, дөньяда ислам дине көчәюдә дә бик әһәмиятле урын биләгән.

Искәртеп үтик, “Тел-сөйләм һәм дин” темасы соңгы елларда татар тел гыйлемендә дә ныклап өйрәнелә башлады. Лингвистик тикшерүләргә “Коръәни-Кәрим тексты, пәйгамбәрләр тарихы, рухани әдәбият ядкярләре, догалар җәлеп ителә башлады. Күп очракларда дини текстлар белән мәгънәви, грамматик, стилистик һәм башка лингвистик тикшеренүләр үткәрелә, дини текстларны тәрҗемә итү мәсьәләләре карала, дини лексиканың мәдәни һәм көндәлек тормышта кулланылышы өйрәнелә, вәгазь җыентыклары дөнья күрә. Кайбер очракларда вәгазь сөйләү турында кызыклы күзәтүләр ясала, тик вәгазьнең дини аралашу чарасы буларак үзенчәлекләре аңлатылып бетмәгән әле.

Вәгазь, үзе сәяси һәм хөкем чыгышлары кебек үк, ораторлык сәнгате үрнәгеме, я булмаса, аның асылы грек-рим классик риторикасына бөтенләй туры килмиме? Дөрес, вәгазь сөйләү чыгыш ясаудан үзгә, бөтенләй башка халәттә уза, оештыру рәвешләре дә төрле. Бер-ике аерымлыкка карап тел-сөйләм һәм үзара аралашу мәсьәләләрендә ашыгыч нәтиҗәләр ясау килешми. Бүгенге көн дөньяны танып белү фәненә (онтология) нигезләнеп лингвистик тикшеренү берәмлекләре буларак сөйләм – дискурс (вакыйгалар узышына бәйле рәвештә текстны эзлекле, ритмик, мәгънәви яктан оештыру; хисси бәяләү, тыңлаучыга йогынты ясау (иллокуция); куелган максатка ирешү, төп фикерне ныгыту чараларын да кертеп), иҗтимагый-мәдәни, күңел-фигыль мөмкинлекләре белән, кеше үзе дә карала. Ә шәхесне яки төрле төркемнәргә берләшкән кешеләрне теленә (сөйләменә), милләтенә һәм диненә карап сыйфатлыйлар. Кешенең тоткан динен аның асыл сыйфаты дип таныган хәлдә, аралашу даирәсен дини фикерләренең тормышта кулланылуы дип күзаллаганда, вәгазь һәм хөтбәчелекне лингвистика яссылыгында тикшерү бик мөһим.

Хөтбәчелекнең вәгазь барышында тормышка ашырыла торган (ашырылырга тиеш) төп кагыйдәләре кабатланмас риторик гамәл барлыкка китерә. Әлеге гамәлнең аерылып торган бер билгесе булып, аның ислам тәгълиматы һәм дини фикерләүгә нигезләнгән, аермачык белдерелгән яки фаразланган максатның үтәлүенә юнәлтелгән төзелеше (типик хәлләрдә текст эчтәлеген дөрес аңлату максатыннан сөйләм оештыру чараларын билгеле бер рәвештә урнаштыру (сценарий төзү) тора. Икенче бер күрсәткече – хөтбәченең (вәгазь сөйләүченең) үзара аралашу барышына максатчан йогынты ясарлык аралашу даирәсе оештыруыннан гыйбарәт.

Хөтбәчелекне ислам тәгълиматы һәм гомум риторика кушылмасы дип, вәгазь кысаларында узган аерым бер төре дип карый алабыз. Риторикадан аермалы буларак хөтбә-вәгазьчелекнең үзенчәлеге – Аллаһ юлында нәтиҗәле аралашу ысулларын эзләү, тыңлаучыларга Аллаһның ризалыгына, мәрхәмәтенә, рәхмәтенә өмет-ышаныч уята алырлык сөйләм чараларын куллана белүдә. Нәтиҗә ясап, шуны әйтә алабыз:

– филология һәм иҗтимагый аралашуны өйрәнә торган фәннәр чолганышында хөтбә-вәгазьчелек мөселманча фикерләү һәм дини әдәпне аралашуның беренче максаты итеп куя;

– вәгазьне риторик кысаларда оештыручы буларак, вәгазьче шәхесенең асыл сыйфаты – ислам тәгълиматына инануы. Аның сөйләменең нияти даирәсе (танып белү (гносеологик), әдәп, зәвык концепциясе) дә һәм аралашу тәртибе дә ислам дине кануннарына нигезләнә;

– дин эшлеклесе һәм мәхәлләдәшләренең аралашуы тел-сөйләм (лингвистик) һәм сөйләмнән тыш – экстралингвистик (гәүдә торышы, ым-ишарә, тавыш тоны, көче, тизлеге, тембры үзгәрү һ. б.) чаралар җыелмасы гына түгел. Ул сөйләмнең билгеләнеп куелган (институциональ) һәм тел-сөйләм чараларыннан үзгә төзелешеннән аерылып торган гадәти аралашуы гына да түгел. Тормышта вәгазь, гыйбадәт кылу һәм дини йола үтәү кысаларыннан чыгып, сөйләмнән тыш мәгънәле чаралар белән дә тулыландырыла. Вәгазь дини эчтәлектә генә дә булмаска мөмкин: мәсәлән, гомумкешелек кыйммәтләре, башка дин тотучыларга карата түземлек; көндәлек тәртип, эшчәнлек эчтәлегенә төшендерүдә дә үгет-нәсыйхәт кулланыла;

– аралашу барышының вәгазь дәрәҗәсенә җитүен без вәгазьченең үзгә бер әһәмияткә ия йогынты ясый алуында күрәбез. Вәгазьченең үзгә аралашу ниятенә ирешүдә тыңлаучыларына максатчан йогынты ясарлык, әлеге йогынтының нәтиҗәсен ныгытып куярлык психологик халәт оештыра алуын без төп күрсәткеч итеп саныйбыз;

– вәгазьнең нияти эчтәлеге ислам тәгълиматында гөнаһ вә савап саналган төшенчә-гамәлләрне тәгаенли торган типик сөйләм ситуациясендә оештырыла.

## Борынгы Грециядә риторика фәне

Моннан ике мең ярым ел элек антик Грециядә, элегрәк булганнарның берсенә дә охшамаган, мәдәни байлыклар оеша. Аларның төп үзенчәлекләре – җәмәгатьчелекне оештыру һәм кешенең җәмгыятьтә үз урынын табу ысулларын аңлату була. Антик Греция кешесе закон тарафыннан төгәл билгеләнгән ирек һәм җаваплылык ала. Законнар билгеле бер авторлар тарафыннан тудырылган (Ликург, Дракон, Солон). Алар халык җыелышларында тикшерелеп һәм тавыш бирү нәтиҗәсендә кабул ителгәннәр. Хокук саклау рәвешен халык алдында тикшерүнең катлаулы һәм катгый тәртибе булган.

Борынгы Грециядә демократия элементлары булган мөнәсәбәтләр системасы оеша. Шәһәр-полисларның сәяси тормышында тулы хокукка ия булган яшәүчеләр дә катнашканнар (алар бик күп булмаган), алар барысы да халык алдында аралашу өчен кирәк булган нинди дә булса иҗтимагый вазифа башкарганнар. Һәр гражданин, бигрәк тә Афина кешесе, суд тикшерүләрендә бер генә тапкыр да катнашмаган, ул үзе анда я гаепләүче, я үз файдасына җавап бирүче булып чыгыш ясаган. Күренгәнчә, кешенең гражданлык статусы һәм язмышы халык алдында аралашу осталыгыннан оешкан. Грециядә хокук саклау оешмалары бик катгый кагыйдәләргә буйсынган. Афинада хокук нормаларын үзгәртергә теләгән оратор «муенында элмәк» белән чыгыш ясарга тиеш булган. Һичшиксез, мондый шартларда һәрбер гражданинга да оста чыгыш ясау мөһим булган.

Күп кенә мәшһүр грек ораторларының исемнәре халык арасында танылган була. Аларның даны безнең көннәргә кадәр килеп җиткән. Без, гәрчә, аларны уйлап табучыларының кемнәр икәнен белмәсәк тә, борынгы ораторларның күп кенә принцип һәм

технологияләрен, риторик кануннарын һәм кагыйдәләрен сөйләмебездә кулланабыз. Безнең эрага кадәр II гасырның иң яхшы ун аттик ораторы тарафыннан риторик канун төзелә. Канун төзүчеләр арасында: Андокид, Лисий, Исократ, Исей, Ликург, Демосфен, Гиперид, һ. б. ораторлар бар. Бу канунның нигезе булып, атаклы “биш кисәкле” оештыру системасы тора. Төгәлләнгән яхшы чыгыш ясау өчен канун-кагыйдәләр билгеләнгән:

- фикерләп, сөйләү эчтәлеген уйлап табу;
- уйлап тапканны эзлекле урнаштыру;
- тупланган мәгълүматны сүзләр белән әйтеп бирү;
- текстны истә калдыру;
- сөйләм рәвешендә фикер-карашларны тыңлаучыларга җиткерү.

Күрсәтелгән кагыйдәләр хәзерге заман кешесенә гади һәм анык булып күренә. Шул ук вакытта алар теләсә кайсы ораторны, үз теләкләрен һәм аудитория ихтыяҗларын күздә тотып, аңлы чыгыш ясарга юнәлдерәләр. Аттик канун кагыйдәләре хәзерге көндә дә әһәмиятле һәм аларны халык алдында чыгыш ясаучы теләсә кемгә эшчәнлеген оештыруда иң кыска һәм нәтиҗәле схема дип санарга була.

Демосфен (б. э. 384-322 еллар) – Афинада иң атаклы ораторларның берсе. Аның турында истәлекләр тарихка кереп калган. Демосфенга табигатьтән ораторлык сәләте бирелмәсә дә, ул күренекле оратор образын тудырган. Оратор сөйләм сәләтен үстерү өчен, чыгыш ясаучыларның элекке тәҗрибәсен кулланган.

Шаһитләр әйтүенчә, Демосфен ым-ишарәләргә таянып, риторик фигуралар кулланган, дәлилләр китерү сәләтенә ия булган. Ул көчле теләк, аныклык, кыскалык, сәнгатьлелек һәм сөйләменең чисталыгы белән инандырган. Демосфен чыгышларының иң мөһим чыганагы – үз шәһәренә мәхәббәте, бер нәрсәгә дә карамастан, аның иреген саклау теләге була. Дүрт гасырдан соң Дионисий Галикарнасский: «Демосфенның чыгышларын уку күңелдә көчле хисләр дулкыны уята... инану, үзеңә ышаныч югалту, шүрләү, курку, ләззәт һәм нәфрәт», – дип яза.

Демосфен һәм башка антик ораторларның һөнәри осталыкка ирешү тарихы чын оратор булып җитлегүнең нинди катлаулы эшчәнлек икәненә теләсә кемне инандыра ала.

Хәзерге заманның иҗтимагый тормышында матур сөйләм үсеше үзгәрешләр кичергән. Бары киң карашлы профессионаллар гына үз тормышларының билгеле бер өлешен образлы, кабатланмас (уникаль) сөйләм рәвеше булдыруга багышлыйлар.

Хәзерге җәмгыятьтә, элеккегә караганда, сөйләмне сәнгатьле образ дәрәҗәсенә күтәрү мөмкинлекләре күбрәк.

Шуның өчен, хәзерге мәдәни дәрәҗәсе югары кешеләргә, антик геройларга, көтүчеләргә, балыкчыларга караганда, сөйләм осталыгы һәм технологияләренә ия булу җиңелрәк. Аның өчен билгеле бер дәрәҗәдә тырышлык кына сорала. Хәзерге җәмгыятьтә халык алдында чыгыш ясауда бары надан һәм ялкау кеше генә кыенлык кичерә.

## ***Софистлар***

Безнең эрага кадәр I гасыр Эллада шәһәр-дәүләтләрендә, йогынтылы сүзнең дәрәҗәсе, зарурилыгы үсә, түләүле укытучылар – софистлар (sophistes – оста вәсвәсәче, акыл иясе, коткы салучы мәгънәләре дә бар) барлыкка килә.

Софист укытучылар бик дәрәҗәле, халыкның киң катлавына таныш булганнар. Алар чыгыш ясарга өйрәтү һәм гражданнарга чыгыш текстлары да әзерләп бирү белән шөгыльләнгәннәр. Күбесе – мәгърифәтче-фәлсәфәчеләр, “сүз культын” – сүзнең мәгънәви, йогынтылык көчен – югары дәрәҗәгә күтәргәннәр. Алар сөйләмнең төрле рәвешеннән, антик логика кануннарыннан, бәхәсләшү сәнгате, аудиториягә йогынты ясый алу күнекмәләреннән оста файдаланганнар. Софистлар сөйләм осталыгының практик ягына гына түгел, теоретик гомумиләштерелүенә дә игътибар итәләр.

«Еленага дан» чыгышында атаклы софист Горгий (б. э. к. 485-380 еллар) болай дип язган: «Сүз – бөек хаким ул, кечкенә микъдар һәм сизелмәслек тышчага гына ия булса да, могҗизалы эшләр кыла. Ул куркуга да сала ала, кайгыны да юкка чыгара, шатлык хисе дә, миһербанлык та, кызгану да уятырга мөмкин».

Фән буларак риториканың башлангыч нигезләрен софистлар төзиләр. Аларның фикерләре буенча ораторның максаты хакыйкатьне ачыклау түгел, ә инандыру, ышандыру көчендә. Инандыру, Горгий фикеренчә (дөреслеккә туры киләме, юкмы), оста оештырылган сөйләм нәтиҗәсе. Софистларның максаты – йомшак, көчсез фикерләрне нигезле яңгыратырга өйрәтү. Димәк, софизм сүзенең мәгънәсе – алдан белеп эшләнгән ялган нәтиҗәгә

ирешү. Үз сүзенең көченә таянып, оста софист-оратор, әһәмиятсез әйберне мөһим, мәгънәле күренешне игътибарсыз калдырырга, яңалыкны – элекке, иске фикерне – яңа төшенчәдәй кабул итәрлек итеп сөйләргә тиеш була. Сөйләме белән ул тыңлаучыларын ихтыярсызлап түгел, ә үз теләкләре белән коллары булырлык дәрәҗәгә җиткерә алырга тиеш дип санаганнар софистлар. Дошманының нәтиҗәле дәлилләрен мәсхәрәле көлүләре белән юкка чыгара, ә мыскыллы сүзгә яхшылык белән җавап кайтарырга чакырганнар алар. Горгий фикеренчә, чын оратор бер үк әйберне күккә чөеп мактый һәм чүп дәрәҗәсендә хурлый да алган. Үтемле сөйләмгә ирешү алымнары да билгеләнеп куелган була.

Бу адымнар билгеле бер вакыт аралыгына сыешуны, фикерләрнең тыгызлыгына һәм төгәллегенә, сөйләм ритмыннан, сүз байлыгыннан оста файдалануны, сөйләмнең хис халәтенә йогынтылыгына ирешү ысулларын да берләштергән.

Горгий сөйләмне бизәкли торган, алар горгий фигуралары дип аталалар, стиль чараларын уйлап таба. Алар – антитеза (текст өлешендәге мәгънәви төшенчәләрнең капма-каршылыгы), оксюморон (каршы төшенчәләрнең ярашуы), җөмлә кисәкләренең үзара ярашуы, җөмлә ахырын рифмалаштыру, аллитерация (тартык авазлар тудырган аһәңлелек), ассонанс (сузык авазлар тупланышы аһәңлелеге).

Шул чорларда сөйләм оештыруда кушма җөмләләрнең кулланылышы, тавыш тонын, төсмерен үзгәртү һәм паузаларны чиратлаштыруның әһәмияте, сөйләм җайланмалары буларак, боерык, үтенеч, сорау һәм җавап төрләре, аларны итагатьле оештыру һәм файдалану шартлары (Фразимах, Протогор) тикшерелә.

Софистларның тырышлыгы сөйләмнең тәэсир көчен шундый югарылыкка җиткерә, алар тыңлаучыларын дәлилләрсез дә ышандыра башлыйлар. Тыңлаучыларның сөйләмне аңлау дәрәҗәсе оратор-софистларның фикерләү мөмкинлекләреннән нык түбән булу сәбәпле, аралашу даирәсендә субъективлык өстен чыга. Хакыйкатьнең чагыштырмача (бер үк чыгышта төп фикер һәм аңа каршы фикер дә исбатлана) булуын тәкърарлаган софистлар гомуммәдәни үсешкә куркыныч тудыралар. Борынгының бөек акыл иясе Сократ, аның атаклы дәвамчылары Платон һәм Аристотель үтемле сөйләм ярдәмендә халыкны теләсә нәрсәгә ышандырган, алдау-йолдау алымнары белән дә уңышка омтылган софистларга каршы чыгалар.

### *Риторика үсешендә Сократ һәм Платонның эшчәнлеге*

Софистларның тел белеме өлкәсендәге, сөйләм һәм аралашуда ирешкән казанышлары, эчтәлеккә игътибар бирмәүләре нәтиҗәсендә, җиңелүләренә китерә. Алар өчен хакыйкать югалып, сөйләм эшчәнлеге чыгыш ясаучының тыңлаучыдан өстенлек итү коралына әверелә. Безнең замандашлар алдашу алымнары белән ялганны чын дөреслек итеп күрсәтергә мөмкин булган фикерләү даирәсе – софистиканы беләләр һәм хәтерлиләр.

Аралашуда хакыйкатьнең өстенлеге өчен көрәшкә дөньякүләм мәшһүр фәлсәфәчеләрдән Сократ керешә (б. э. к. 470-390 еллар). Ул катгый рәвештә язма эшчәнлекне кире кага һәм мәдәният тарихында гомергә оратор – телдән чыгыш ясаучы булып кала. Антик Грециядә, аралашуда бер ораторның нәтиҗәле эшчәнлегенә исәпләнгән монолог (нотык) сөйләү рәвеше өстенлек ала. Сократ аралашуның төп принципларын, бурыч-максатларын тәгаенли һәм оратор белән тыңлаучының үзара мөнәсәбәтләрен ачыклый.

Сократ монологик традициядән читләшә һәм гомере буе диалог – әңгәмә рәвешендә генә аралаша. Сократ фикеренчә, аралашуның төп бурычы – хакыйкатьне ачыклау, табу. Диалог – бер-береңә сорау биреп, дөрес җавап табарга ярдәм итә. Хакыйкатьне ачыклау эристика (грек. eristikos – бәхәсләшү сәнгате) атамасын ала. Мәшһүр оратор майевтиканы (хакыйкатькә ирешүдә сорау һәм җавапны максатка яраклы итеп чиратлаштыру осталыгы) һәм иронияне бик еш куллана. Ирония барлык тезисларны шик астына алырга булыша, ә әңгәмәдә бер җаваптан икенчесенә күчү хакыйкатькә алып килә. Сократ барлык эчтәлекнең үсешен дәлилләүгә, тезисны исбатлауга юнәлдергән. Ул аралашуда хакыйкатьне һәр нәрсәдән әһәмиятлерәк дип саный, чөнки хак фикерләр генә дөрес гамәлләргә юл ача.

Сократның укучысы Платон (б. э. к. 427-347 еллар), хакыйкатьнең өстенлегенә нигезләнеп, ораторлык тәгълиматын киңәйтә, үстерә. Платон ораторны үз эшчәнлегендә иҗади фикерләүче мөстәкыйль субъект итеп күзаллый.

Без аралашуны күңел дәрәҗәсенә күтәргән очракта гына инандыру көченә ирешәбез. Шуңа күрә хакыйкатькә ирешү ике яклы фикерләү, диалог ярдәмендә мөмкин, ә әңгәмәдәшнең күңеленә үтеп аралашуны психология фәнен тирән үзләштерү тәэмин итә.

Платон аралашу даирәсен оештыруда файда, аң, психологик белемне берләштерү карашларында торган дип раслап була.

Максатчанлык хакыйкать тануны һәм сөйләмнең дәлилләнү тәртибен тәэмин итә, ә психологик белем хисчән, инандырырлык аралашу шартларын (аралашу сәнгатен) барлыкка китерә.

Софистика һәм диалектика тәгълиматын төзүчеләр бүгенге көндә нык әһәмиятле риторика үсешенә нигез салалар.

Заманча аралашуда бу ике юнәлеш үсешен дәвам итә. Хәзерге мәгълүмати җәмгыятьтә үзенчәлек тә бар: тел, сөйләм иҗат нигезенә, яңа иҗтимагый кыйммәтләр оештыру җирлегенә әверелде. Хәзерге риторика белемнең катлаулырак рәвешенә әйләнде, ул мәгълүмати җәмгыятьтә дә әһәмиятен җуймый.

### *Аристотельнең аралашу тәгълиматы*

Аристотель (б. э. к. 384-322 еллар) антик риторика тәҗрибәсен гамәли һәм фәнни яктан гомумиләштерә, үзенең "Поэтика" һәм «Риторика» хезмәтләрендә Европа ораторлык сәнгате традицияләрен тудыра. «Риторика» дип аталган хезмәте өч китаптан тора. Беренчесендә риториканың инандыру сәнгате буларак асылы, сөйләм төрләре, төрле сөйләм эшчәнлегенең уртаклыклары (топика) анализлана. Икенче китапта риторик дәлилләү нигезе тикшерелә. Өченчесендә, стиль, троплар, риторик фигура элементлары, шулай ук сөйләм төзелеше сурәтләнә.

Аристотель ораторлык эшчәнлеген өйрәнүдә сөйләмнең төп өлешләрен һәм аларның чагыштырма өлешләрен билгеләгән:

- сөйләмнең нияте һәм эчтәлеге;
- оратор образы;
- эмоция;
- композиция;
- стиль.

Аристотель риториканы дедуктив алымга нигезләнгән мантыйк белән бәйли, аерым өлешләргә таркатып, җентекләп өйрәнә.

Бөек акыл иясе фикерләүдә фаразлау алымын һәм гамәли кулланып була торган чара – оратор карашы төшенчәсен кертүе белән риториканы фәнгә әверелдерә, ораторлар кебек үк, тыңлаучылар да сөйләмне тикшерү һәм максатчан бәяләү мөмкинлеге алалар. Сөйләмнең силлогистикага (дедуктив фикерләү рәвеше) нигезләнгән сөйләм тезисларын дәлилләү алымнары, чын

тезисларны таләпләргә туры китереп сайлап алу күрсәткечләре (критерийлары) барлыкка килә.

Моннан тыш, Аристотель аралашу оештыруда сөйләмне кабул итү өлешләренең әһәмиятлеген аныклый, тыңлаучылар өчен кагыйдәләр яза. Аристотель риторикасы бүгенге көнгә кадәр фәнни риториканың нигезе булып кала.

Аристотель, тыңлаучыларның үзенчәлекләренә нигезләнеп, оешу сәбәпләре һәм күрсәткечләре буенча, сөйләмнең өч төрен тикшерә. Ул сөйләмнең оратор, предмет, күренеш эчтәлеге һәм, кемгә юнәлтелүе, ягъни тыңлаучы булганда гына оешуын раслый. Аристотель риторикасында тыңлаучы төп катнашучы, чөнки аралашу аның өчен оештырыла. Тыңлаучыларның узганны, бүгенге һәм киләчәкне фикерли алуларына бәйле рәвештә Аристотель өч төрле сөйләм рәвешен барлый. Алар киңәшле, хөкем итү һәм гамәл кылу (акт башкару) яки эпидейктик сөйләм.

Киңәшле аралашуда катнашучылар тәкъдим ителгән фикерләр белән килешәләр яки аларны кире кагалар, ул киләчәктә булачак мәсьәләләргә кагыла. Хөкем чыгышлары аңлашылып бетмәгән мөнәсәбәттәге билгеле бер карашларны һәм кешеләрне гаепләү, яклау, аклау буларак оешалар. Эпидейктик сөйләм – узганны һәм киләчәкне тикшерү максатында оеша, аның бурычлары – мактау яки кисәтеп кую.

Аристотель, борынгы Грециядәге сөйләм тәҗрибәсеннән чыгып, сөйләм төрләрен вакыт төшенчәсенә бәйләп анлаткан. Уйлап карасак, ул үз чорының чынбарлык тәҗрибәсенә таянып, фәнни риториканың төп төшенчәләрен – нигезен оештырган.

Аның логика һәм риторика өлкәсендәге тикшеренү нәтиҗәләре бүгенге көндә дә әһәмиятен жуймый. Безнең сөйләм эшчәнлегендә борынгының бөек фикер ияләреннән үзләштерелгән бик күп отышлы үрнәкләр бар.

## Борынгы Римда ораторлык сәнгате

Барлык Рим мәдәнияте кебек үк, бөек империянең риторик кыры да греклар тәҗрибәсенә нигезләнгән. Греклардан аермалы буларак, Рим ораторлары аралашуның гамәли ягына күбрәк игътибар биргәннәр. Римда ораторлык юнәлешенең төп кыйммәте булып шәхси һәм дәүләт хокукы, сәяси көрәш каршылыклары һәм башка шуңа охшаш сюжетлар торган. Күп халык җыелган урында

аралашуның әһәмияте б. э. к. II-I гасырларда, гражданнар сугышы белән тәмамланган сәяси бәрелешләр көчәйгән вакытта арта.

Римда аралашу кагыйдәләре камилләшкән, аларда күп кенә яңалыклар тупланган. Язучы һәм дәүләт эшлеклесе Катонның яшь ораторга төбәп әйтелгән афоризмы билгеле: «Гамәлнең асылына якын кил, сүзләр табылыр». Чыгыш ясауның композициясе тәгаенләнә, ул алты буынлыга әйләнә: кереш; сөйләү; аерып, таркатып аңлату; нигезләү; кире кагу һәм йомгаклау. Сөйләм техникасына таләпләр оеша: оратор көчле һәм үзгәрүчән тавышка ия булырга, ягъни тавыш тонын сөйләү ситуациясенә туры китерә белергә тиеш була. Рим ораторлары риторик фигураларга нык игътибар биргәннәр. Хәтерне яхшырту һәм текстны нәтиҗәле истә калдыру өчен күзаллап образ тудыру чаралары кулланылган. Фикерне сүз ярдәмендә (вербаль) белдерүгә дә таләпләр формалаша. Алар: дөреслек, ачыклык, чама һәм матурлык.

Иң билгеле ораторлар арасында беренчесе булып Марк Туллий Цицерон – алдынгы сәяси эшлекле, оратор һәм язучы – саналган (б. э. к. 106-43 еллар). Цицеронның казанышлары ораторлык сәнгатенә бәйле дип санала. Цицерон дәүләтнең республика булып оешуын теләгән. Аның Катилина фетнәсен ачыклавын һәм сенатта аңа каршы сөйләнгән гаепләү чыгышын бүгенге көнгә кадәр хәтерлиләр. Бу авторның төрле хезмәтләрендә риторика оешуда фәлсәфәнең мөһимлеге хакында тезислар, шулай ук уйлап чыгару, кешене үзеңә карату, сүз ярдәмендә фикер җиткерү, хәтер, сөйләм яңгырату мәсьәләләре һәм гәүдә хәрәкәте белән сөйләмнең барлык нечкәлекләренә кадәр башкару осталыгы күзәтелә. Антик автор, беркем, беркайчан да уңышлы һәм кабатланмас чыгышка сөйләм фәне һәм һәр өлкәдә ныклы белемгә ия булмыйча ирешә алмаган, дип яза. Римда ораторлык сәнгатенә уку иң югары дәрәҗәдәге белем булып саналган, ул сигез ел дәвам иткән. Цицерон һәм Рим гореф-гадәте һәрьяклы белемне һәм ораторның тәртибен ассызыклый. Сөйләм, предметны белгәндә генә тулысынча аңлашыла дип санаган оратор. Әгәр ул чыгышның эчтәлеге оратор тарафыннан өйрәнелмәгән һәм үзләштерелмәгән булса, аның сүз ярдәмендә җиткерелүе нәтиҗәсез була.

Риторика сәнгатенең теоретигы Цицеронны югары бәяләүче, аның дәвамчысы Марк Фабий Квинтилиан була (36-96 еллар). Ул "Оратор белеме" хезмәтен калдыра. Анда бүгенге көндә дә актуаль булган кагыйдәләр җыелмасы тупланган. Цицероннан аермалы

буларак, ул ораторны фикерләүче санамаган, ә аралашу стилистикасы белгече итеп таныган. Оратор өчен төп кирәкле әйбер – стилистик чама хисе, аны максатчан дәресләр дәвамында һәм риторика мәктәпләрендә үзләштереп була ди ул. Цицерон һәм Квинтилиан үзләренең теоретик эшчәнлекләрендә ораторлык сәнгатенең ике төп юнәлешен – фикерләү барышы һәм технологияне (чыгыш ясау алым-чараларын) – үстергәннәр.

## Ораторика һәм гомилетика

Аристотель аерып күрсәткән сөйләм төрләрен, вакытлар үткәч ораторика дип атый башлаганнар. Ораторикага, алда әйтелгәнчә, сөйләмнең киңәшле хөкем һәм гамәл үтәү формалары керә. Бу формаларда сөйләм үткән, киләчәк һәм бүгенге хәлләр, үткәннең һәм киләчәкнең бәйләнеше буларак карала. Ораторика хөкем кануннарына, хаклыгына һәм тәҗрибәдә табылган төгәллеккә таяна. Ул аңлы рәвештә, дедуктив логикада һәм исбатланган төпле мәгънәдә төзелә. Ораторикада багланышлар тәҗрибәдә бер генә тапкыр тормышка ашырыла. Чыгыш ясаучыга гына кагылышлы берьяклы кагыйдәләр һәм аралашу рәвеше ораторның үзенчәлекле образын билгели. Ораторның бу үзенчәлеге чыганакларны бер аралашу дәвамында ачып бирү мәҗбүриятеннән гыйбарәт. Шуңа күрә Грециянең антик риторикасы – «ышанычлы сөйлә», ә Борынгы Римныкы – “ышанычлы, матур сөйлә” принцибында төзелгән.

Көнбатышта яңача ел исәбе башлануыннан сөйләм формасы буларак, гомилетика үсеш ала. Гомилетика дини тәгълимат һәм белем үзләштерүне һәм шуларга нигезләнеп гамәл кылуны күзаллый.

Гомилетиканың нигезенә дини рухият салына. Сөйләм дингә мәхәббәт мөнәсәбәтләре урнаштыру буларак тормышка ашырыла. Сөйләмнең терәге булып дини карашлар һәм гаилә кыйммәтләре, ә дөньяга тулаем караш булып дини фәлсәфә тора.

## Россиядә аралашу гадәте һәм риторика

Икенче меңьеллык башыннан Киев Русендә аралашу гадәтенә Византия мәдәнияте һәм дин зур йогынты ясый. Язма чыганаклардан күренгәнчә, борынгы Русь ораторлары белемле булган дип нәтиҗә ясарга була.

Риторика өлкәсендә тикшеренүчеләр, Россиядә Аурупача сөйләм-аралашу үзләштерүне – XVII гасырга мөнәсәбәттә дип раслый. Риторика фәненең беренче китаплары аралашуның югары дәрәҗәсен чагылдыра, аларда сөйләм стиле өйрәнелә.

Рус риториклары, антик риторика кануны нигезендә, әлеге эшчәнлекнең 5 төре буенча юнәлеш алганнар:

1) сөйләнәчәк текстның эчтәлеген уйлап табу;
2) барлыкка килгән эчтәлекне билгеле бер эзлеклелеккә салу;
3) тупланган уй-фикернең мәгънәсен, ниятен тиешле сүзләр белән аңлату (текстны сөйләм рәвешенә китерү);
4) текстны хәтердә калдыру;
5) сөйләп бирү;

Алар сөйләмнең 4 төрен аерып күзәткәннәр:

1) өйрәтү белән бәйле (уку-укыту) сөйләм;
2) хөкем кылганда кулланыла торган сөйләм;
3) киңәш, үгет-нәсихәт сөйләме;
4) тантаналы сөйләм;

Риторикада сөйләмнең бу төрләре бүгенге көндә дә әһәмиятле һәм Россиядә Пётр I реформаларына кадәр кулланыла. Риторика фәненең асылын рус ораторлары түбәндәгечә күзаллаганнар:

1) матур сөйләм теленә өйрәтү;
2) хикәяләү, матур сөйләм алымнарына өйрәнү, эчтәлекне төзәтүдә билгеле бер кагыйдәләрне үзләштерү;
3) аралашу сәнгате казанышларын тормышта файдалана белү (чөнки кагыйдәләргә нигезләнмәгән сөйләм тыңлаучыларны ялыктыра).

Билгеле, риторика укытуда әлеге юнәлеш Квинтилиан фикерен куәтли, ә Цицерондагыча, аралашу барышында фикерләргә өйрәтүне максат итеп куймавы белән аксый.

Петр I идарә иткән чорда риторика фәненең иң күренекле мөгаллиме булып язучы, җәмәгать һәм дин эшлеклесе Феофан Прокопович (1681-1736) саналган. Ул Киев-Могилян дини академиясендә риторика курсларын латин телендә укыган. Бу курс кулъязма рәвешендә нык кулланылган, анда сөйләм теориясе, аның ораторлык һәм шигъри җанрлары, тел чаралары ярдәмендә эчтәлек чагылышы күзәтелгән. Лекцияләр курсында текстларны төрле аралашу очракларында төрлечә куллануга, ораторның дәлилләр сайлап алуына, сөйләм композициясенә, телдән сөйләм жанрларын төрлечә «бизәү»гә таләпләр китерелә.

Рус телендәге беренче риторика дәреслеген Михаил Ломоносов (1711-1765) язган. Ломоносов риториканы телдән һәм язма сөйләм оештыру фәне буларак бәяли. Риторика идарә-хөкемгә кагылышлы, иҗтимагый һәм фәлсәфи-дини темаларга сөйләшкәндә кулланыла торган кагыйдәләрне үз эченә ала. Рус акыл иясе, антик авторлар традициясен күзәтеп, сөйләмнең барлыкка килүен, төзелешен һәм бизәлешен өйрәнә. Ул үз эшчәнлегендә Европа культурасының иң яхшы үрнәкләренә таяна. Хәзерге көндә дә, риторика өлкәсендә эшләүче белгечләр Ломоносов традициясен дәвам итәләр.

Россия мәдәнияте икенче меңьеллык дәвамында дини оешмаларның көчле йогынтысын тоеп яшәгән һәм яши. Россиянең сөйләм киңлеге тезисның эчтәлегенә һәм аның дәлилләнүенә түгел, ә хөкем сөргән идеологиянең төп төшенчәләрен саклауга юнәлтелгән. Һичшиксез, сөйләмдәге үрнәкләрнең һәм хөкем сөргән идеологиянең тәңгәл килүе, билгеле бер рәвештә, сүз белән йогынтының үзенчәлекле асылын тәшкил итә.

Риторикада Россия үзенчәлекләрен исәпкә алган сөйләм үрнәкләрен Н.Кошанский мисалында күрергә була. Аның риторикасының асылы – сөйләмне һәрьяктан матурлап күрсәтүдә.

Рус риторы "йөрәкне чолгап ала торган" күзаллаулар оештыруны, акыл белән инануны тәэмин итәрлек фикерләү фигураларын аерып күрсәтә.

Беренче төр фигураларга ул кисәтүне, җавап кайтаруны, юл куюны, аерып күрсәтүне, фикердә эзлеклелекне, тапкыр сүзлелекне, фикергә әйләнеп кайтуны, фикерне үстерүне һәм төзәтүне кертә. Белгеч карашы буенча, сөйләмдәге мондый күчеш, үзгәреш фикерләүгә йогынты ясарга булыша, чөнки сөйләмне инануга әйләндерә.

Икенчедән, сурәтләү, җанландыру, башка фикерләр белән аралаштыру, капма-каршылык, чагыштыру, риторик сорау, өндәү, эндәш; киеренкелек тудыру, арттырып җибәрү, үтенү һәм булалмастайлыкны раслау фигуралары күзаллауга нык тәэсир итә.

Өченчедән, күңелне ышанычлылык, икеләнү, күттереп тору, мөрәҗәгать итү, эндәш, махсус дәшми тору, сөйләмне кискен рәвештә туктату, йола, ырымнар үтәү, теләкләр теләү, сораулар кую, өндәмәләр белән яулап була.

Күргәнебезчә, XIX гасыр риторикасы сөйләмнең көчен арттыруда күп төрле алымнарны берләштерә.

Әйтергә кирәк, риторика фәне совет власте вакытында зур үсешкә ирешә. Рәсми-сәяси карашлар риторик дәлилләүләр нигезенә салына. Бөтен аралашу барышы, дәлилләүләрнең төп үзенчәлеге, сәяси ихтыяҗларга бәйле булуы сәбәпле, хакимият белән килешүчәнлеккә әйләнә.

Һәрнәрсә белән ризалашу стиле, аралашуны дәүләт эшчәнлегенең бер өлеше итеп аңлату, аралашу кырының бөтен элементларына үтеп керә. Сөйләмнең барлык төрләре дә сәясиләштерелә. Сөйләм сәяси тәрбия һәм халык фикере белән уйнау чарасына әверелә. Россия җитәкчелеге аралашу даирәсенә, бигрәк тә агитация-пропаганда өлкәсенә, зур игътибар бирә. Тоталитар хакимият, халык аңына йогынты ясый торган мөмкинлек буларак, җәмгыятьтәге гомумхалык аралашу чараларын нык тикшереп торган.

Демократик яңарыш бурычларын үтәү шактый дәрәҗәдә хәзерге риториканың һәм халык алдында аралашу үзенчәлекләре күрсәткечләренең үзгәрүенә бәйле. Дәлилләүләр җыелмасының оешу рәвеше мәдәният һәм сәясәт өлкәсенә хәлиткеч тәэсир ясый. Хакимияткә бәйле, килешүчәнлеккә нигезләнгән дәлилләүләр яңа идеяләр һәм гамәлләргә алып килә торган аралашуны тәэмин итә алмый.

## Татар халкында хөтбә-вәгазьләр тарихыннан

Инсаниятә тел гаять тылсымлы, кодрәтле көчкә ия. Элеккеге заманнарда ук акыл ияләре, олуг әдипләр бу көчнең бөеклегенә, нәфислегенә сокланганнар, аның җәмгыятьтә тоткан урынына олы бәһа биргәннәр.

Телнең гаҗәеп хикмәтлелеген, күзгә күренми торган көчкуәтен Коръән Кәримдәге түбәндәге аятьтән дә күрергә мөмкин. Анда: “Синең телең – синең арысланыңдыр, җибәрсәң – ул сине үтерер, сакласаң – ул сине саклар”, – диелгән.

XI йөзнең атаклы шагыйре Йосыф Баласагунлы үзенең “Котадгу белек” (“Бәхет турында белем”) поэмасында да: “Барлык нәрсә телдән: ул кешене күтәрә дә, аның башына да җитә”, – дип, Изге Китаптагы фикерне куәтли. “Котадгу белек”тәге:

Күңел, телеңне дөрес (ихлас) тот, холкың да бөтен булыр,

Һәм синә килер бәхет (байлык), дөньяң да бөтен булыр”, – кебек юллар да телнең, сүз сөйләүнең мөһимлеге хакында сөйлиләр.

Борынгы һәм Урта гасырларның күп кенә әдипләре кебек, XV йөзнең урталарында иҗат иткән татарның бөек шагыйре Мөхәммәдъяр да телнең кешелек дөньясында тоткан ролен түбәндәгечә билгели:

Адәм углының вөҗүде (барлыгы – Ф.М.) эчрә бел,

Бер тылсым, бер әл-гаҗиб ирер бу тел!

Халык арасында да элек-электән тел турында тирән мәгънәле, гыйбрәтле мәкаль-әйтемнәр иҗат ителгән: “Дөньяда сүздән көчле нәрсә юк”, “Сүз сөйләү һөнәр, сөйли белмәгән үләр”, “Сүзне сөйләсәң, уйлап сөйлә”, “Тел күрке – сүз”, “Туры сүз – телнең бизәге”, “Тел – белемнең ачкычы, акылның баскычы” һ.б.

Телнең кешелек җәмгыятендәге тоткан мөһим роленә тукталып, күренекле тел галиме Р.Г.Әхмәтьянов болай ди: “Төрле халыкларның киемнәре, орнамент-бизәкләре, аларның көй-музыка ядкәрләре кешенең тынгысыз иҗади эзләнү җимешләре буларак кыйммәтлеләр. Әмма халыкларның күп гасырлар дәвамындагы иҗади фикер нәтиҗәләрен үзендә туплаган иң зур рухи бина – тел” [Әхмәтьянов, 2003:39].

Әйе, тел – фани дөньяны, чынбарлыкны танып белү, аралашу-фикерләшү, инсаният тудырган матди һәм мәдәни кыйммәтләрне алдагы буыннарга тапшыру чарасы гына түгел, ул – куәтле ышандыру һәм инандыру коралы да.

Телнең тылсымлы тәэсир итү көче, барыннан да бигрәк, аның кешеләрнең аңына, хис-тойгыларына, эчке кичерешләренә зур йогынты ясавында. Ә бу исә, үз нәүбәтендә, күп төрле алымнар, тел-стиль чаралары аша тормышка ашырыла.

Җ.Абызгилдин үзенең “Хитабәт ысуллары” дигән китабында хитабәтнең (хөтбә сөйләүнең) аерым фән, һөнәр булуын ассызыклап үтә: “Хөтбә вә нотык сөйләү һөнәре бик борынгыдан килә. Коръән Кәримдә без Нух галәйһиссәләмнең үз кавеменә нинди күркәм вәгазь сөйләвен күрәбез. Шулай ук Ибраһим г.с.м., Исмәгыйль г.с.м., Йосыф г.с.м., Муса г.с.м., Гайсә г.с.м., Мөхәммәд галәйһимүс-саләтү үәссәламнең вәгазь-нәсыйхәтләренә дә сокланмаска мөмкин түгел”.

Ул хитабәт фәненең борынгыдан килгән һөнәр буларак, юнанилардан (греклардан) башланып, руманиларга (римлеләрдән)

күчүен һәм, Гайсә г.с.м. туганнан соң, руманиларда хитабәт ысулының сөйләү рәвеше үзгәреп, дини төс алуын әйтә [Абызгилдин, 1998:7-8].

Бик күптәнге дәверләрдә, әле борынгы төрки бабаларыбыз табигатьнең илаһи көчләренә ышанган мәҗүсилек һәм тәңречелек чорында ук, төрле бәйрәмнәрне һәм дини йолаларны үткәргәндә, йола – дин башлыклары – шаманнар (камнар) – ыругдашларының, кабиләдәшләренең хис-тойгыларына көчле йогынты ясый белгәннәр, ышандыру-инандыруның күптөрле тел-стиль чараларыннан оста файдаланганнар. Гади халык кына түгел, хәтта кабилә башлыклары – биләр дә алардан куркып торганнар. Телебездә кулланыла торган камчы сүзенең тамырында да борынгы төрки телдән кергән кам фигыле ята. Ул "сугу, сыдыру" мәгънәсендә йөргән. Тува телендәге камчы "шаман чыбыркысы" дигәнне аңлата. Бу да әлеге сүзнең гомумтөрки телдәге камчы "шаман" сүзе белән тыгыз бәйләнештә булуына ишарәли [Әхмәтьянов, 2001:89]. Халкыбызның теләк-алкышларындагы, сынамышларындагы "Әрвахлар рухы шат булсын", "Тәңре ярдәм итсен", "Утка төкерсәң, авыз кутырлый", "Күз тимәсен өчен, бала кулына миләш агачы бәйлиләр", "Утын сызгырса, көн суытыр" һ.б. гыйбарәләр бик күптәннән килеп кергәннәр [Мәхмүтов, 2002:143]. Борынгы бабаларыбызның дөнья, яшәеш турындагы уй-фикерләре мифологик хикәятләрдә, риваять-легендаларда да чагылыш тапкан [Риваятьләр һәм легендалар, 2001:111; Татар мифлары..., 1999:132]. Мәсәлән, "Җир ничек яралган?" дигән риваятьтә борынгыларның күзаллавы болай тасвирлана: "Элекке заманнарда дөнья тоташ судан гына торган. Кешеләр әле булмаган. Суда балыклар һәм су кошлары гына яшәгәннәр. Шунда бер үрдәк су төбенә чумып, борыны белән бер кисәк балчык алып чыккан. Бу зурайган һәм шуннан җир хасил булган ди. [Риваятьләр һәм легендалар, 2001: 27].

X йөз башларында, Идел Болгары дәүләтендә Ислам дине рәсми рәвештә кабул ителгәннән соң, халкыбызның рухи-мәдәни тормышында яңа дәвер башлана. Бераллалыкка нигезләнгән Ислам дине төрле кавемнәрне берләштереп, дәүләтчелекне ныгытып кына калмый, Идел буе болгарларының тормыш-көнкүрешенә, гореф-гадәтләренә, мәдәниятенә тирән йогынты ясый. Болгарда Исламны кабул иткәннән соң, әле халык арасында борынгыдан килгән, инде Ислам кануннарына туры килмәгән мәҗүсилек гореф-гадәтләренә, йолаларына каршы буларак, Бер

Аллаһ идеясе үткәрелә. Бу гасырлар дәвамында укылып киленгән “Бәдәвам китабы”нда да ачык күренә. Аның һәрбер дүртьюллыгы “Алла дигел бәдәвам” гыйбарәсе белән тәмамлана, ягъни дәвамлы рәвештә Аллаһ сүзен кабатларга өнди:

Һәркем җенгә табынса,
Йә суга нәрсә салса,
Агачка нәрсә чалса,
Аллаһ дигел бәдәвам.

Йә зөннарый багъласа,
Йә ул кләү күтәрсә,
Хәрамны хәләл белсә, –
Аллаһ дигел бәдәвам.

Пәйгамбәр билә, диде,
Кяфердер анлар, диде,
Тәмугъда җаны диде, –
Аллаһ дигел бәдәвам. [Бәдәвам китабы, 2005:7].

Исламның асылы булган Коръән Кәримне, Мөхәммәд пәйгамбәр (с.г.в.) сөннәт-хәдисләрен кабул иткән болгарларда җәмгыять тормышының әхлакый нигезләренә карашлар үзгәрә, алар яңа әхлакый кыйммәтләр белән баетыла. Шулай итеп, Ислам гаделлек, шәфкатьлелек, кешелеклелек, рухи-әхлакый сафлык, хезмәт белән гадел көн күрү идеалларын яклый һәм аларны шәхесне формалаштыруда төп кыйммәтләр итеп таный, нәтиҗәдә, инсаннарны яман адымнар, хәрам эшләр кылудан саклап килә [Җәләлиев, 2003:9].

Ислам дине кабул ителгәч, болгарлар файдалана торган чөй (рун) язуы гарәп алфавиты белән алышына. Шул рәвешле, язма мәдәниятә нигез салына. Шуның нәтиҗәсендә безнең ата-бабаларыбызда фәнни-фәлсәфи фикерләр, әдәбият, мәдәният һәм мәгърифәт үсүгә зур этәргеч ясала. Мәчетләр салына, алар каршында мәктәп-мәдрәсәләр ачыла. Болгар һәм Суар шәһәрләрендәге Җамигъ мәчетләр дин һәм мәгърифәт үзәкләренә әвереләләр.

Элек-электән мәктәп-мәдрәсәләрдә Исламият кануннарын ныклап үзләштерү белән берлектә, сүз сәнгатенә, сөйләшү әдәбенә дә өйрәткәннәр, нотыклык сәнгатен үзләштергән һәм Аллаһ сүзен, Мөхәммәд пәйгамбәр (с.г.в.) сөннәтләрен җәмәгатькә фәһемле, оста

җиткерә белүче имам-хатыйблар хәзерләүгә дә зур урын биргәннәр, Сөйләшә белү, сүз сәнгатенә ия булу иң мәртәбәле һәм иң кирәкле гамәлләрнең берсе итеп саналган. Шунлыктан дини уку йортларында төп фәннәр булган Коръән, Тәҗвид (Коръәнне дөрес итеп уку турындагы кагыйдәләр), Коръән тәфсире (аңлатмалары), Гакаид (Иман), Фикъһе (Ислам дине мәсьәләләре турындагы гыйлемнәр), Ислам һәм пәйгамбәрләр тарихы, шәригать гыйлемнәре, гарәп телен өйрәтүдән тыш, әхлак, риторика, фәлсәфә, мантыйк (логика), психология, педагогика кебек гакылият фәннәре дә укытылган, дөньяви белемнәр дә бирелгән.

Дөрес, ул вакытларда барлык Ислам йолалары гарәп телендә башкарылганга күрә, укыту-тәгълим системасында да гарәп теленә өстенлек бирелгән. Әмма төрки-татарча уку һәм төрки текстларны өйрәнү, фикерне үстерү, телне шома, уйны йөгерек итеп әйтеп бирә белү, ирекле әңгәмәгә һәм моназарага (бәхәскә) әзерләү буенча да дәресләр , гамәли шөгыльләр үткәрелгән. Шул максаттан “Бәдәвам”, Кол Галинең “Кыйссаи Йосыф”, Борһанетдин Рабгузиның “Кыйссасел Әнбия”, Сөләйман Бакырганиның “Ахырзаман китабы”, Таҗетдин Ялчыголның “Рисаләи Газизә”, Мөхәммәд Чәләбинең “Мөхәммәдия”, Суфи Аллаһиярның “Сөбател-гаҗизин” һ.б. китаплар файдаланылган. Мәхмүд Болгариның “Нәһҗел фәрадис”, Мәҗлисинең “Кыйссаи Сәйфелмөлек”, Сәйф Сараиның “Гөлстан бит төрки” һ.б. әсәрләрнең дә кулланылганлыклары мәгълүм [Әмирхан, 1997:187-190; Заһидуллина, 2000:20-25].

Исламга мөнәсәбәтле рәвештә халык авыз иҗатының гаҗәеп әсәрләре – илаһи бәетләр, мөнәҗәтләр барлыкка килгән, Аллаһ белән бәйләнешле теләк-алкышлар әйтелгән. Мәсәлән, “Иманыбыздан аерма!” дигән мөнәҗәттә мондый дүртьюллыклар бар:

Газраил якаң тотканчы,
Әҗәл угын кадаганчы,
Кулың, телең тотылганчы,
Укыйк Коръән илә намаз.

Илаһым, син ки шат әйлә,
Бәнем газиз бу җанымны,
Ахырда да насыйп әйлә,
Шәрәфәтле иманымны.

Илаһи, сорыймын синдин
Шул дүрт нәрсәне бирмәгә:
Бере тәүфыйк, бере гамәл,
Бере дәүләт, бере җәннәт.

Дәхи дә эстимен синдин,
Шул дүрт нәрсәне күрмәгә:
Бере дидар, бере вилдан,
Бере хуры, бере гыйлман.

Дүрт нәрсәне кыйлчы асан
Үзең шәфәгатең берлән:
Бере азан, бере сөаль,
Бере сират, бере мизан.

Аерма безне, Илаһым,
Шул изге дүрт китабыңнан:
Бере Инҗил, бере Зәбур,
Бере Тәүрат, бере Коръән.

Шул дүрт нәрсәне күрсәтмә,
Безгә дөньяда, Ярабби:
Бере фәкыйрь, бере ачлык,
Бере бурыч, бере зиндан.

Калдырма миңа, и Раббым,
Дүрт нәрсәнең явызлыгын:
Бере азгын, бере динсез,
Бере шымчы, бере шайтан. <...> [Хөснуллин, 2001:118]

“Алла куәт бирсен, җаныңа саулык бирсен”, “Ходай ак тормышлар бирсен”, “Фәрештәләрнең “амин” дигән чагына туры килсен”, “Ходай тел ачкычлары бирсен”, “Алланың каһәре төшсен”, “Валлаһи газыйм”, “Коръән орсын” кебек халык телендә киң таралган алкышлар, каргышлар һәм антлар да Ислам дине белән багланышлы.

Шулай ук Йосыф Баласагунлы, Әхмәд Йүгнәки, Әхмәд Ясәви, Шәмсетдин Гасый, Сөләйман Бакыргани, Кол Гали кебек атаклы шагыйрьләр дини рухтагы әсәрләр иҗат иткәннәр, адәм балаларын

әдәп-әхлакка өндәгәннәр. Мәсәлән, үзенең бер шигырендә Сөләйман Бакыргани болай ди:

Намаз, руза, тәүбә берлә барганнарга,
Хак юлына кереп, кадәм куйганнарга,
Ошбу юлда җанын фида кылганнарга
Ярлыканмыш коллар берлә сөхбәте бар.

Намаз, руза, тәүбә сәне уттан йолар,
Галәм халкы, сәне сорап, Хакдин теләр,
Кыямәт көн күреп сәне, алар таңлар,
Ни кол ирмеш, бу сәгадәт носраты бар.

Оҗмах эчрә түрт арыктыр, белгел аны,
Монда тәүбә кылганнарга эчрер аны,
Тәүбәсезләр ул арыкдин эчмәс вәли,
Аңа эчрер зәһәр заккум ширбәте бар <...> [Бакырган китабы, 2000:30]

Язма әдәбиятта XII йөзләрдән үк килеп кергән дини мотивлар: Аллаһыны зурлау, Аңа сыгыну, фани дөньяда кылган гөнаһлары өчен ярлыкавын сорау, Аның каршында үзен колбәндә итеп сурәтләү, еллар-гасырлар аша үтеп, XX йөз башы поэзиясенә кадәр килеп җитә. Моны без халкыбызның бөек шагыйре Г.Тукай шигырьләреннән дә күрә алабыз. Мәсәлән, “Туган тел” шигырендә еллар дәвамында мәктәп дәреслекләренә кертелмәгән мондый юллар бар:

И, туган тел! Синдә булган, иң элек кыйлган догам:
Ярлыкагыл, дип, үзем һәм әткәм-әнкәмне, Ходам! [Тукай, 1985:65]

Гаетләрдә, җомга намазларында, мөбарәк кичәләрне, истәлекле көннәрне уздырганда, имам-хатыйблар үзләренең илаһи һәм гыйбрәтле вәгазьләре, үгет-нәсыйхәтләре белән Аллаһ сүзен, изге Коръән аятьләрен, Мөхәммәд галәйһиссәләм хәдисләрен җәмәгатькә өйрәтүдә тырышлык күрсәткәннәр.

Алтын Урда һәм Казан ханлыгы дәверләрендә дә инсаннарга гыйлем-мәгърифәт аша, вәгазьләү аша иман нурын иңдерү дәвам иткән. Имам-хатыйблар, шәйхләр, Кол Шәриф кебек мәшһүр сәедләр үзләренең хөтбә-вәгазьләре, күркәм эш-гамәлләре белән халыкка Ислам гыйлеме һәм тәрбиясе биргәннәр. Бу вакытларда гает һәм җомга хөтбәләре, нигездә, гарәп телендә башкарылса да,

аларның вәгазь өлеше халыкның төп аралашу-сөйләшү теле булган төрки-татар телендә укылгандыр диясе килә. Бәлки, ул вакытларда ук оста вагыйзларның (әхлакка өйрәтүчеләрнең, имам-хатыйбларның) кульязма вәгазьләре дә булгандыр. Шулай булгач, вәгазь, үгет-нәсыйхәт өслүбенең әүвәлге башлангычлары шул чорларда ук формалаша башлаган дияргә мөмкин. Күренекле тел галиме В.Х.Хаков та: “Болгар дәүләте чорында ук үз чорына хас язма әдәби тел һәм стиль үзенчәлекләре үсеп чыга”, – ди. [1999:7]

XVI йөз урталарында, ягъни Явыз Иван баскыннарыннан соң, Казан ханлыгы җимерелеп, илгә зур афәтләр килгәч тә, рәхимсез ирексезләү, көчләп чукындыру, матди һәм мәдәни байлыкларыбызны талау һәм юк итү вәзгыяте башлангач та, мәчет, мәктәп-мәдрәсәләр җимерелеп, күпләгән дин әһелләребез һәлак ителсә дә, мөселман татарларның иң зур күпчелеге исламнан – хак диннән ваз кичмәгән, иманына тугры булып калган. Хәзер инде җәмәгать намазларын, дини бәйрәмнәрне бергәләп үтәү мөмкинлеге калмаса да, аларны гаиләләрендә башкарганнар, Изге Коръәнне күз карасыдай саклаганнар, балаларына шәригать кануннарын өйрәткәннәр, илаһи үгет-нәсыйхәт биргәннәр.

Екатерина II патшалык иткән елларда, мөселманнарга карата кайбер ташламалар ясалса да, Рәсәй империясендә аларны җәберләү, диненнән һәм теленнән биздерү, күркәм гореф-гадәтләрен юкка чыгару сәясәте беркайчан да туктамаган. Бары тик XIX йөз ахыры – XX йөз башларында гына бу вәзгыять берникадәр үзгәрә башлый. Ул татар халкының милләт булып формалашу, милли әдәби тел барлыкка килү, милли үзаң үсү, тәгълим-тәрбия системасында җәдиди үзгәрешләр башлану белән бәйләнгән. Мөселман татарларга Ислам кануннарын, дини йолаларны яшәеш өчен файдалы булырлык итеп үз ана телендә, халык сөйләмә теленә якын булган аңлаешлы телдә өйрәтү, аңлату мөһим мәсьәләләрнең берсенә әверелгән.

Кайбер мәгълүматлардан бәян булганча, хөтбә-вәгазьләрне татарча укый башлау XX йөз башларына туры килә. Шакирҗан Хәмиди [Ш.Х.] үзенең “Голяма тарихы” дигән китабында Казан мәчетләре имамнарының эшчәнлекләренә бәя биреп, Дары заводы каршындагы икенче мәхәллә мәчете мулласы Әхмәтҗан Мөэминовның, беренчеләрдән булып, җомга һәм гает хөтбәләрен татар телендә укый башлавы һәм бүгенгә кадәр дәвам итүе турында яза. Кызганыч, автор моның кайчан башлануын күрсәтми, әмма

китапның 1907 елда нәшер ителүенә карап, бу гамәлнең 1905-1907 елларда башлануын фаразларга мөмкин [Ш.Х., 1907:40; Гимазова, 2004:67].

Татарча хөтбә укуны куәтләп, шулай булырга тиешлеген раслап, бу яңалыкны күтәреп алучылар рәтендә “Иж-Бубый” мәдрәсәсенең имам-хатыйбы һәм мөдәррисе Габдулла Нигъмәтуллин-Бубый да бар. 1902 елда басылып чыккан “Тәрәкъкы фәнүн вә мәгариф динсезлеке мүҗибме?” дигән хезмәтендә үк, ул, Ислам динен фән аша аңлатып бирүнең мөһимлеген күрсәтә. “Җомга һәм гает намазлары, анда укыла торган гыйбадәтләр җәмәгатьне дин нигезләрен аңлауга, аларны үтәүгә өйрәтергә тиеш. Шуның өчен укыла торган хөтбәләр ялвару һәм данлаудан тыш, татар телендә сөйләнергә тиешләр”, – дип ассызыклый [Бубый, 1902:40; Гимазова, 2004:63].

1906 елның мартында хаҗ сәфәреннән әйләнеп кайткан Габдулла Нигъмәтуллин җомга хөтбәсен татарча укый. Бу – бөтенләй башка килмәслек вакыйга була. Күптөрле шау-шулар, каршылыклар, аңлашылмаучылыклар булуга карамастан, абруйлы, уй-ниятләренә инанган тәвәккәл кеше буларак, ул башлаган эш-гамәлләреннән чигенми: җомга һәм гает хөтбәләрен ана телебездә укуын дәвам иттерә. 1908 елда аның “Татарча хөтбә уку дөрестме?” дигән китабы нәшер ителә. Ул анда Коръәнгә, Мөхәммәд пәйгамбәр (с.г.в.) хәдисләренә, күренекле дин галимнәренең хезмәтләренә нигезләнеп, бу гамәлнең дөреслеген дәлилли. “Вәгазь, – ди ул, – җыелган халык Ислам һәм милли рух белән сугарылсын, киләчәктә һәм мәңгелек яшәештә үзләренә файда китерерлек нәрсәләрне аңласыннар өчен кирәкледер. Татарларның күпчелеге гарәп телен аңламый, атна саен бер үк нәрсәне сөйләүче имамнар да, мәгънәсенә төшенмиләр. Әгәр кешеләр нәрсә турында сүз баруын аңламыйлар икән, моны хөтбә дип исәпләргә мөмкинме?” [Бубый, 1908:35]

Шулай итеп, Г.Бубый татарлар арасында Ислам тәгълиматын вәгазьләүгә, пропагандалауга зур өлеш кертә. Җәдитчелек тарафдары буларак, ул ислам динен киң халык массаларына аңлаешлы булган татар телендә аңлатуны яклап чыга, шулай эшләгәндә генә, кеше аңына әйбәтрәк йогынты ясау мөмкинлеген күрсәтә һәм татарча хөтбә укуны нәзари яктан дәлилләп бирә. “Замана иҗтиһад мөнкарыйзмы, дәгелме?” (“Иҗтиһад заманы юкка

чыкканмы әллә түгелме?”) дигән хезмәтендә дә Г.Бубый әлеге реформаторлык фикерләрен дәвам иттерә [Бубый, 1909:69].

Татар телендә хөтбә укуга нык каршы торучылар булса да, бу яңалыкны куәтләүчеләр дә ишәя. Шул уңайдан “Йолдыз” газетасында татарча хөтбә укуны хуплаган мәкалә дә дөнья күрә. Анда Г.Бубыйның “Татарча хөтбә уку дөрестме?” китабы чыгуы турында хәбәр ителә һәм автор да татарча хөтбә укуны хуплап: “Гадәти әңгәмәдә ике сүзне куша алмаган мулланың авыз эчендә ботка пешерүеннән файда юк, аның сөйләмен дә хөтбә дип әйтеп булмый. Бу вакытта җомга намазының катгый башкарылырга тиешле таләпләре үтәлми. Әгәр дә имам үзенең вәгазе белән тыңлаучыларның күңелләренә үтеп кереп, тәэсирле сөйли икән, моны татар телендә аңлатуның бернинди начарлыгы юк”, –дип яза [Йолдыз. – 1909. – 4 февраль].

Г.Бубый һәм башкалар тарафыннан башланган бу яңалыклар, җәдиди үзгәртеп корулар көчәя барган саен, татар мөселманнары тормышына активрак үтеп керә башлый. Җомга һәм гает намазларында, башка дини йолаларны үткәргәндә, хөтбә-вәгазьләрне татарча укуга игътибар арта. Шул ук вакытта татар телендә Коръән тәрҗемәләре, тәфсирләре, Мөхәммәд пәйгамбәр (с.г.в.) хәдисләре, дини китаплар басылып чыга, хөтбә-вәгазь мәҗмугалары дөнья күрә. Шулай итеп, милли татар әдәби теленең стилистик системасында шактый үзенчәлекле булган тагын бер социаль-функциональ стиль – илаһият стиле (өслүбе) формалаша.

Тел гыйлеменең мөһим бер тармагы булган стилистика – тел һәм сөйләм стильләре турындагы тәгълимат дип, аның нигезендә яткан стиль сүзенә нисбәтән (грекча stulos “язу таякчыгы”), гадәттә, иҗади эшчәнлектә нинди дә булса идея-эстетик максаттан чыгып, сәнгатьле тасвирлау чараларын куллану рәвешенә карата әйтелә. Ул “Тел, сөйләм чараларыннан, мөмкинлекләреннән файдалану, алымнарның теге яки бу төре һәм шуңа хас билгеләр”, – дип тә аңлатыла [ТТАС, II, 1979:672]. Бу атамага карата тел галиме Х.Р.Курбатов: “Стиль – билгеле бер фикер яки тойгыны урынына, вакытына һәм максатына ярашлы итеп әйтеп бирү рәвеше”, – дигән төшенчәне сала һәм әйтеп бирүдәге охшашлыклар сөйләм типларын һәм стильләрен китереп чыгаруын, ә сөйләм стильләренең үз нәүбәтендә функциональ яктан, жанр ягыннан һәм индивидуаль үзенчәлек ягыннан аерым төркемнәргә бүленүен күрсәтә [Курбатов, 2002:3].

Стилистика – татар лингвистикасында чагыштырмача яңарак тармак. Шулай булса да, сөйләм төрләре турындагы башлангыч мәгълүматлар XVIII йөз татар мәгърифәтчеләре Сәгыйть һәм Ибраһим Хәлфиннәр тарафыннан әйтелә. XIX йөзнең икенче яртысында татар телендәге стильләр хакындагы кайбер фикерләр М.Иванов, С.Күкләшев, К.Насыйри, Н.Ф.Катанов һ.б. хезмәтләрендә чагылыш таба. Мәсәлән,

М.Иванов татар телен сөйләү теле һәм язма тел дигән төрләргә бүлә. Алар арасындагы аерымлыкларны күрсәтү өчен сөйләмә һәм язма тел үрнәкләрен бирә [1842:311].

С.Күкләшев, М.В.Ломоносовның рус әдәби теле үсешендәге стиль теориясенә нигезләнеп, татар телендә, ягъни сөйләмендә дә югары, урта һәм түбән стильләр булуын әйтә. Автор фән телен, эш телен, гади сөйләү телен аерып чыгара. Күптөрле гарәп сүзләре һәм тәгъбирләре белән чуарланган язма хатирәләрне фәнни телгә, ягъни югары стильгә кертә. Эш теле дип, ул гади сөйләм белән фәнни сөйләм арасында торган, татар сүзләре белән беррәттән гарәп-фарсы сүзләре дә шактый урын алган урта стильне атый. Ә гади телнең әдәби сөйләмә телгә якын һәм татар кешесенә аңлаешлы булуын күрсәтә [Күкләшев, 1869:103-105].

Татар халкының күренекле мәгърифәтчесе К.Насыйри үзенең “Кыскача татар нәхүе” (1860), “Кавагыйде китабәт” (1892) һ.б. хезмәтләрендә өч стиль системасының үсеше белән бәйле булган язма һәм сөйләү теле арасындагы аерымлыкларны билгели һәм язма әдәби телнең халык сөйләмә теленнән шактый ераклашкан булуын, анда башка телләрдән кергән сүзләрнең һәм гыйбарәләрнең күп кулланылуын күрсәтә.

Өч стиль мәсьәләсенә Н.Ф.Катанов та туктала. “Материалы к изучению казанско-татарского наречия” (1898) китабында татар телендә язылган әсәрләрне аерым стильләргә бүлеп карый. Галим ул чордагы гарәп-фарсы сүзләре белән чуарланган язма китап телен югары стильгә, андый сүзләр азрак булган язма әдәбиятны урта стильгә, ә халыкның җанлы сөйләменә якын һәм һәр татар кешесенә аңлаешлы булган халык авыз иҗаты әсәрләрен түбән стильгә кертә. Ул телдәге стильләрне аерымлауда жанр принцибыннан һәм лексик-семантик билгеләр нигезендә лингвистик принциптан чыгып эш итә.

XX гасыр башында, аеруча Октябрь инкыйлабыннан соң, стилистика мәсьәләләре күбрәк галимнәрнең игътибарын җәлеп

итә. Татар стилистикасына караган материаллар теге яки бу дәрәҗәдә шул вакытларда нәшер ителгән грамматикаларда, әдәбият буенча уку әсбапларында, вакытлы матбугатта басылган фәнни язмаларда яктыртылалар. (Г.Сәгъди, Г.Ибраһимов, Г.Нигъмәти, Г.Исхакый, Җ.Вәлиди, Х.Бәдигый, А.Шамов һ.б.)

Стилистика өлкәсендәге күпкырлы һәм максатчан эзләнү-тикшеренүләр XX йөзнең икенче яртысыннан башлана. Лингвистик стилистиканың яңа юнәлешләре барлыкка килә, функциональ стильләрне, әдәби телне тарихи аспектта өйрәнү, газета-журнал теленең үзенчәлекләре, татар язучылары әсәрләренең теле, мәктәп стилистикасы мәсьәләләре аерым китапларда, монографик тикшеренүләрдә, фәнни мәкаләләрдә чагылыш таба. Стилистикага кагылышлы күзәтүләр, фикерләр грамматика һәм лексикология буенча булган хезмәтләрдә, уку ярдәмлекләрендә һәм программаларында урын ала. Стилистика тел гыйлеменең автоном бер тармагы буларак өйрәнелә башлый. Нәзари яктан лексик стилистика, грамматик стилистика, фонетик стилистика, жанр стилистикасы кебек фәнни юнәлешләр барлыкка килә. Шулай итеп, әгәр XIX йөздә һәм XX йөз башларында татар теле стилистикасы яралгы рәвешендә тел белеме яки әдәбият теориясе буенча булган хезмәтләрдә генә чагылып китсә, соңгы дистә елларда ул махсус өйрәнү объектына әверелә.

Бу өлкәдә иң нәтиҗәле эшләүче галимнәребезнең берсе, һичшиксез, В.Х.Хаков булды. Аның иң беренче җитди тикшеренүе публицистика стиленә багышланган [1961:312]. Аннан соңгы хезмәтләрендә ул функциональ стильләрне, лексик һәм грамматик стилистиканы өйрәнүгә җитди игътибар бирде [1961:160; 1963:168; 1972:224; 1979:158; 1985:150; 1993:324; 1999:302; 2003:265].

Татар теле стилистикасын нәзари яктан өйрәнүгә икенче күренекле галимебез Х.Р.Курбатов зур көч куйды [1956:176; 1971:193]. Аның “Сүз сәнгате: Татар теленең лингвистик стилистикасы һәм поэтикасы” дигән хезмәтендә татар теленең лингвистик стилистикасы һәм поэтикасы турында тәфсилле төшенчәләр бирелә, сөйләм стильләренең төп төрләре күрсәтелә, телдәге сүзләр һәм фразеологик әйләнмәләрнең, грамматиканың стилистик һәм поэтик мөмкинлекләре яктыртыла, сөйләшү стиленең фонетик үзенчәлекләре бәян ителә [Курбатов, 2003:199].

Шулай ук татар теле стилистикасын нәзари һәм гамәли яктан өйрәнү С.Ибраһимов [1989:150]; Ф.Сафиуллина [1974:151;

2000:116], Ф.Хисамова [1981:161; 1998:408], И.Бәширова [1999:576; 2000:12-15; 2006:192], С.Поварисов [1974:164; 2002:187], Г.Нуриев [1998:187; 1999:213], Р.Абдуллина [1999:400], А.Тимерханов [2005:312] һ.б. хезмәтләрендә чагылыш таба.

Тел-стиль мәсьәләләрен сөйләм культурасы (әдәбе) белән тыгыз бәйләнештә өйрәнүгә дә җитди игътибар бирелә. Бу яктан Г.Ф.Саттаров [1965:151], Р.А.Юсупов [2003:223; 2007:103; 2007:300], С.Ш.Поварисов [1997:223], Г.С.Нуриев [2001:156; 2005:194], Р.С.Абдуллина [1997:126] һ.б. хезмәтләрен күрсәтергә мөмкин.

Гамәли стилистиканың татар тел белемендә шактый үсеш алган тагын бер юнәлеш – мәктәп стилистикасы бар. Бу өлкәдә эшләүче галимнәр методист укытучылар мәктәп укучылары һәм югары уку йорты студентлары, укытучылар өчен дәреслекләр, программалар, уку ярдәмлекләре төзеделәр. Без монда бигрәк тә В.Х.Хаков [1970:128], С.М.Ибраһимов [1968:128; 1978:143; 1989:150], Р.А.Юсупов [1978:214; 1983:136], Г.С.Нуриев [2006:45; 2006:188; 2008:199], И.Б.Бәширова [2005:25], С.Ш.Поварисов [2002:187] һ.б. хезмәтләрен күрсәтер идек.

В.Х.Хаков стилистиканы: “Матурлык фәне, матур сөйләм сәнгате”, – дип бәяли. Тел гыйлеменең әһәмиятле бер өлкәсе буларак, ул күптөрле тел күренешләрен үз эченә ала. Анда телдәге стильләр, аларга хас закончалыклар тикшерелә, телнең сүзлек байлыгы, фразеологиясе, морфологиясе һәм синтаксисы белән бәйләнешле стилистик- семантик үзенчәлекләр, сөйләмнең поэтик яңгырашын, эмоциональлеген барлыкка китерә торган сәнгатьле сурәтләү алымнары, фонетик, стилистик чаралар киң күләмдә һәм җентекле рәвештә өйрәнелә [Хаков, 1999:3].

Стилистика фәненең өйрәнү объекты турында Х.Р.Курбатов та: “Сөйләм типларының һәм стиль төрлелекләренең төзелешен, аларны барлыкка китерүдә сүзнең, грамматик форма яки фонетиканың ни рәвештә кулланылуын тикшерү эше тел белеменең бер тармагы булган стилистика өстенә төшә”, – дип ассызыклый [Курбатов, 2002:3].

Шулай итеп, фәндә лингвистик стилистиканың ике зур тармагы аерып күрсәтелә: тел стилистикасы һәм сөйләм стилистикасы. Сөйләм стилистикасы үз нәүбәтендә ике төрдә була: сөйләшү стиле һәм язма сөйләм стиле. Аларның һәркайсына фонетик, лексик һәм грамматик үзенчәлекләр хас. Х.Курбатов күрсәткәнчә: “<...> алар

арасында аерма әллә ни зур булмаска мөмкин, чөнки һәркайсы бер үк чыганактан, бер үк милли телне файдаланудан төзелә, ләкин болай карауга аз тоелган шул аермалыклар да стиль барлыкка китерүдә хәлиткеч роль уйный” [Курбатов, 2002: 11].

Сөйләгән яки язган вакытта сүзләр һәм грамматик формалар (кайбер очракта – фонетик яңгыраш та) билгеле бер фикернең кайда, кайчан һәм нинди максат белән әйтелүенә, ул сүзләрнең кемгә төбәлгән булуына карап сайлап кулланыла. Тел чараларының шул рәвешчә билгеле бер максат белән кулланылышы һәм әдәби телнең үсә, камилләшә баруы нәтиҗәсендә, тора-бара сөйләмнең аерым үзенчәлекле сөйләм төрләре – сөйләм стильләре барлыкка килә.

Сөйләм стильләре, үз чиратында, функциональ сөйләм, экспрессив сөйләм һәм сәнгатьле сөйләм дигән өч төрдә була, һәм алар барысы бергә милли әдәби тел стилистик системасының нигезен тәшкил итәләр.

Кешеләрнең үзара аралашу, сөйләшү һәм язышуларындагы билгеле бер практик эшчәнлеккә бәйле булган, күп дәверләр кулланып, шул эшчәнлекне чагылдыруга җайлашкан һәм нәтиҗәдә үзенчәлекле бер рәвешкә кергән үзенә хас сүз һәм әйтемнәре булган, әйтәсе фикерне аерым бер төр белән башлап китүне һәм тәмамлау төсен алып, теге яки бу дәрәҗәдә калыплашкан һ.б. сөйләм типлары функциональ сөйләм стильләре дип атала [Курбатов, 2002:24].

Хәзерге татар әдәби телендә функциональ стильнең язма сөйләм төрләре берничә төргә аерыла. В.Х.Хаков аларның түбәндәге төрләрен күрсәтә: иҗтимагый публицистика стиле, фәнни яки фәнни-популяр әдәбият стиле, рәсми-канцелярия яки эш кәгазьләре стиле, хатлар (эпистоляр) стиле. Галим матур әдәбият стилен аерым билгели [Хаков, 1963:14], Х.Р.Курбатов исә язма сөйләмнең өч төрен аерып чыгара: эш кәгазьләре стиле, фәнни иншалау стиле һәм публицистика стиле [Курбатов, 2002:24]. Функциональ стильнең әлеге төрләре фәнни әдәбиятта шактый тулы өйрәнелгән. (Югарыда күрсәтелгән В.Х.Хаков, Х.Р.Курбатов, Ф.М.Хисамова, И.Б.Бәширова, А.А.Тимерханов һ.б. хезмәтләре).

Х.Р.Курбатов күрсәткәнчә, функциональ стильнең һәркайсы үзенә бер төрле максаттан килеп чыккан.Р.А.Будагов сүзләре белән әйткәндә, “<...> кешеләрнең үзара аралашу сферасындагы бүленешкә чик юк. Шуңа күрә сөйләм стильләре бүленешендә дә

чик юк. Ул бүленеш санап бетергесез күп булырга мөмкин”. Шунлыктан Х.Р.Курбатов та астөшермәдә булса да: “Тарихи яктан караганда, функциональ сөйләмгә тагын йола стиле дә керә”, – дип өстәп куя [Курбатов, 2002:22].

И.Б.Бәширова да җанлы сөйләмнең үзенчәлекле бер төре булган үгет-нәсыйхәт сөйләме булуын һәм аның формасы буенча монологик, әдәби нормага нигезләнгән, гарәп-фарсы алынмалары иркен кулланыла торган сөйләм икәнлеген күрсәтеп уза [Бәширова, 2006:73-74].

Әмма югарыда карап кителгән функциональ стильләр арасында күрсәтелмәгән, бүгенге көнгә кадәр бөтенләй диярлек өйрәнелмәгән, фәнни кулланылышка кертелмәгән тагын бер стильне – илаһият стилен атарга кирәк.

Матурлык фәненең, нәфис сөйләү сәнгатенең шактый үзенчәлекле бер төре булган илаһият стиле инсаннарның аңнарына, хис-тойгыларына, эчке кичерешләренә аеруча нык тәэсир итә торган куәтле ышандыру һәм инандыру чараларының төзек бер системасын тәшкил итә. Бу бөтенлектә хөтбә-вәгазьләр өслүбе аерым бер урынны алып тора.

Еш кына хөтбә һәм вәгазьләрне бер синонимик ояда бирәләр, ягъни мәгънәдәш сүзләр итеп карыйлар. Аларны аерым-аерым карап үтик. Бу чыннан да шулаймы икән?

Хөтбә (гар. хотбә – речь, нотык) – җомга һәм дини бәйрәмнәрдә укыла торган намазларда, дин тотучыларга мөрәҗәгать итеп, имам тарафыннан сөйләнә торган вәгазь. Урта гасырларда ул, нигездә, Алладан хәлифә һәм патшаларга, ханнарга сәламәтлек сорап укыла торган дога булган. Гаскәргә җиңү, халыкны корылык, ачлык кебек афәтләрдән имин итүне сорап та хөтбә укыганнар [ИБС, 1993:152]. “Гарәпчә-татарча-русча алынмалар сүзлеге”ндә хөтбә (хотбә) сүзенең ике мәгънәсе теркәлгән: 1) Речь, нотык, сөйләнгән сүз. 2) Вәгазь [ГТРАС, II, 1993:665].

Вакытлар узу белән, хөтбәләрнең максат-ниятләре дә, эчтәлекләре дә, сөйләү тәртипләре һәм рәвешләре дә үзгәрә, аларның яңадан-яңа үзенчәлекле төрләре барлыкка килә. Шулардан чыгып, хөтбәләрне, нигездә, дүрт зур төркемгә берләштерергә мөмкин: 1. Дини хөтбәләр; 2. Сәяси хөтбәләр. 3. Мәхкәмә хөтбәләре. 4. Тормыш-көнкүрешкә караган хөтбәләр.

Мәчет-мәдрәсәләрдә, җомга һәм гает намазларында, дини бәйрәмнәрдә һәм мәрсияләрдә укыла торган дини хөтбәләрнең төп

максаты – тыңлаучыларда илаһи хис уяту, халыкка дини тәрбия бирү, аларны рухландыру [Мөбарәк, 2002:14].

Гадәттә, хөтбә 5 өлештән тора: 1) Аллаһны мактау; 2) Пәйгамбәр һәм хәлифәләр рухына дога кылу; 3) Аллаһының берлеген раслау; 4) Вәгазь уку; 5) Мөселманнар исәнлегенә дога кылу [ИБС, 1993:152].

Гарәп теленнән алынган вәгаз сүзе "Вәгазь, үгетләп, димләп, өндәп сөйләнгән сүз" дип шәрехләнә [ГТРАС, I, 1993:54]. "Аңлатмалы сүзлек"тә ул ике мәгънәдә бирелә: "1. Үгет, нәсыйхәт, яхшылыкка өндәү. 2. Мәчеттә гыйбрәтләр китереп, дини нәсихәт бирү төсендәге чыгыш" [ТТАС, I, 1977:245].

Хөтбәнең мөһим состав өлеше булган вәгазь җомга һәм гает намазларында гына түгел, бәлки башка дини бәйрәмнәрне һәм мәҗлесләрне, мөбарәк көннәрне, төрле йолаларны (никахлашу, балага исем кушу, сөннәтләү, Коръән укыту, җеназа уку, мәрхүмне искә алу һ.б.) үткәргәндә дә, дөньяви истәлекле көннәр һәм вакыйгалар (Хәтер көне, Әниләр бәйрәме, Өлкәннәр көне, мәчет ачылу, Белем бәйрәме һ.б.) уңаеннан да укыла. Дини һәм дөньяви вәгазьләрнең киң тематикасын һәм матур үрнәкләрен без Җәлил хәзрәт Фазлыевның "Йөз дә бер вәгазь" китабында аеруча ачык күрәбез [Фазлыев, 2005:544].

Шулай итеп, хөтбәнең вәгазьгә караганда киңрәк төшенчә булуы күренә. Әмма шунысы ачык аңлашыла: хөтбәдән башка җомга һәм гает намазлары, ә вәгазьдән гайре хөтбә була алмый. Шуңа күрә Габделхак хәзрәт Саматов билгеләп үткәнчә: "Хөтбә шул ук вәгазь инде. Шуңа күрә әйтеләсе сүзләр, вәгазьләр шул хөтбәгә керергә тиеш <...>. Хөтбә ул – кешеләрнең күңелләренә тәэсир итә торган һәм иманы артуга сәбәп була торган бер вәгазь" [Саматов, 2005:303].

Хөтбә-вәгазьләрнең төп эчтәлеген Коръән-Кәримгә, Мөхәммәд пәйгамбәр (с.г.в.) хәдис-сөннәтләренә нигеләнеп, Аллаһының берлегенә, Пәйгамбәребезнең Аның җирдәге илчесе икәнлегенә инандыру, гөнаһлардан сакланып, үзеңне ахирәт тормышына хәзерләү һәм күркәм холык, әдәп-әхлак белән яшәү мәсьәләләре тәшкил итә. Шуларны җәмәгатькә үз телебездә дөрес итеп, тәэсирле итеп, аңлаешлы итеп җиткерүче дин әһелләренә, имам-хатыйбларга зур җаваплылык, олуг вазыйфа йөкләнә. Коръән Кәримдәге "Нәхел" сүрәсенең 125 нче аятендә Аллаһ Тәгалә әйтә: "Хикмәт белән, гыйлем белән, күркәм вәгазьләрегез белән

бәндәләрне Исламга чакырыгыз. Шулай ук “Минем сүземне әдәм балаларына җиткерүчедән дә сөйкемлерәк кеше юк”, – ди [41:33]. Пәйгамбәребез Мөхәммәд (с.г.в.) тә үзенең бер хәдисендә: “Хәерлегез шул кешедер, кем Аллаһ кануннарын, Коръәнне өйрәнеп, шуны кешеләргә җиткерсә, шуннан да саваплы эш юк”, – дип әйтә. Шуларга нигезләнеп, Җәлил хәзрәт Фазлыев та: “Син күркәм сүз, яхшы вәгазь белән кешедә хакыйкатьне тану теләге уятырга тиешсең”, – дип ассызыклый [Фазлыев, 2005:416].

Күренекле имам-хатыйб һәм галим Җиһангир Абызгилдин хөтбә сөйләүнең әһәмияте турында болай ди: “Хитабәтнең (хөтбә сөйләүнең) кыйммәте вә әһәмияте искиткеч зур. Оста һәм гүзәл итеп сөйләнгән вәгазь, халыклар йөрәгенә гайрәт кертә, аларны шатландыра, елата, үкендерә, дәртләндерә, яшен-картын, баен-фәкыйрен, ир вә хатынын берләштерә. Бер фикергә хезмәт итәргә, бер максатка юнәлергә өнди. Аларга бертөрле хис, бертөрле юнәлеш бирә. Хөтбәләрнең кыйммәтен вә әһәмиятен бер сүз белән генә әйтеп бетерерлек түгел. Шуңа күрә дә инсаннарның барча тереклекләрендә рухларына алган һәртөрле мәгълүматларны, гүзәл хатипларның нотык вә хөтбәләреннән хасил булган рух дисәк тә хата булмас [Абызгилдин, 1998:3-4].

Хөтбә-вәгазь сөйләүнең дә үз хасиятьләре, үз тәртибе бар. Җ.Абызгилдин, мәсәлән, хөтбә-вәгазь сөйләүгә карата булган төп шартларны һәм таләпләрне түбәндәгечә билгели:

1. Хөтбәнең төп мөндәриҗәсе (эчтәлеге) тәгаенләнгән, ягъни алдан хәзерләнеп, кулдан язылган кыскача эчтәлеге булырга тиеш.

2. Хөтбәне изах вә шәрех итеп (төшендереп, ачыклап), мөмкин кадәр гомум халыкның ихтыяҗына карап сөйләргә кирәк.

3. Хөтбәдә гомум халыкка нык тәэсир итәрлек, тыңлаучыларның йөрәк вә рухани хисләрен уятырлык булган бер кыйсем (өлеш, бүлем) булырга тиеш.

4. Хөтбәне тәмамлар алдыннан, тавышны аз гына түбәнәйтеп, Аллаһы Тәгаләгә һәм пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салаллаһу галәйһи вә сәлләмгә хәмед вә сәнә укып дога кылыныр.

5. Хөтбәләр урынына карап, бик үткен гыйбарәләр белән булып, бәгъзән (кайчакта) кызганычлык хисе китерә торган, кайчакта шагыйранә тасвирлар китереп, ә кайчакта барчасын дустанә итеп, менә шул урыннарны белеп, дөрес файдалана белү һәрбер хатипка ляземдер.

6. Хөтбәнең ана телендә сөйләнә торган өлешен һәр милләт кызыгырлык дәрәҗәдә, сөйләм осталыгыңны, төзек сөйләм куәтеңне җигеп, ачык итеп сөйләү тиеш.

7. Хөтбәнең үзен башламактан әүвәл, ул хөтбәнең максаты бәян ителгән бер кыйсем булырга тиеш. Бу кыйсемне ишетү белән, һәркемнең дәрте вә хисе кузгалып, сөйләнәчәк хөтбәгә игътибарлары артыр. Табигый ки, һәрбер хөтбә бер мәсьәләне ачыкларга тиеш [Абызгилдин, 1998:18-19].

Һәр имам-хатыйб аны үз белдегенчә сөйләсә дә, билгеле бер калыпларга ярашырга, шуларны үтәргә тиеш. Оста вәгазьчеләр моны бик белеп эш итәләр. Гадәттә, вәгазь, үгет-нәсыйхәт өч өлештән тора: башлам (кереш сүз), төп өлеш һәм нәтиҗә – йомгак ясау.

Күпчелек очракта вәгазьләр "Бисмилләһир-рахмәнир-рахим" ("Мәрхәмәтлеләрнең иң мәрхәмәтлесе булган Аллаһыбыз" яки "Мәрхәмәтле һәм рәхимле Аллаһ исеме белән башлыймын") дигән Аллаһы Тәгаләгә мактау һәм олылау сүзләрен ирештерүдән башланып китә. Югарыда күрсәтеп үткәнебезчә, вәгазьләрдә теге яки бу фикерне раслау-дәлилләү өчен, Коръәни-Кәримнән сүрәләр, аятьләр, Мөхәммәд галәйһиссәләм хәдисләре китерелә. "Тәүбә" сүрәсеннән кала барлык сүрәләрне: "Бисмилләһир-рахмәнир-рахим" дип, ә аятьне яки аятьтән өзекне "Әгүзү билләһи минәш-шәйтанир-раҗим") ("Аллаһы Тәгаләгә шайтан зарарыннан сыгынамын") дип башлау мәҗбүри. Гает, җомга хөтбәләрендә башламның киңрәк вариантлары да күзәтелә. Мәсәлән, Татарстан Диния нәзарәтенең баш казые Җәлил хәзрәт Фазлыев үзенең һәр җомга вәгазен шушы тәгъбир белән башлап җибәрә: "Әгүзү билләһи минәш шәйтанир-раҗим. Бисмилләһир-рахмәнир-рахим. Әлхәмдүлилләһи раббил галәмин вәссаләтү вәссәләмү гәлә расүлинә Мүхәммәдиү вә гәләлиһи вә сахбиһи әҗемәгин" ("Аллаһы Тәгаләгә шәйтан коткысыннан сыгынамын. Мәрхәмәтле һәм рәхимле Аллаһ исеме белән башлыймын. Галәмнәрнең хуҗасы (тәрбиячесе) Аллаһы Тәгаләгә барча мактаулар булсын. Аллаһ илчесе Мөхәммәд галәйһиссәлламгә һәм аның әһленә (халкына), һәм сәхабәләренең барчасына сәламнәребезне һәм рәхмәтләребезне ирештерәсәң иде" [Фазлыев, 2005].

Һиҗри ел исәбе белән кайсы ай, аның ничәнче җомгасы икәнен әйтә. Вәгазьнең ни хакта булачагын кыскача гына аңлаткач: "Аллаһ Тәгалә тел ачкычлары биреп, хәерле вәгазьләр сөйләргә насыйп

кылса иде, тыңлаган кешеләргә дә, сөйләгән кешеләргә дә шушы вәгазьләр белән вәгазьләнеп, изге гамәлләрне күбрәк кылып, Хак Тәгалә кушканнарны үтәп, тыйганнарыннан тыелып яшәүләрне Аллаһ Раббыбыз барчабызга да насыйп итсә иде...” дип, кереш сүзен җиткерә һәм вәгазен дәвам иттерә.

Җәлил хәзрәт вәгазьдән гыйбрәт алынырга тиешле нәтиҗәне чыгарып, якынча болайрак йомгак ясый: “Инде Аллаһ Раббыбыз барчабызның акылларына камиллек бирсен, хәерле сәламәтлекләр дә насыйп итсен. Хәерле гомерләр дә насыйп итсен. Аллаһтан безгә бүләк итеп бирелгән шушы гомеребезнең калган өлешен туры юлны табучылардан булып үткәрик. Чөнки туры юлның ахыры шатлык, җәннәт белән бетә. Менә шушылай яшәүләребезне Аллаһ Раббыбыз барчабызга да насыйп кылса иде. Һәм актыккы сулышларыбызда: “Ләәә иләәһә илләллааһу Мүхәммәдүр Расүүллааааһ”, (Аллаһ Бер генәдер, Мөхәммәд пәйгамбәр Аның илчеседер – Ф.М.) дип, иман белән Аллаһ хозурына күчсәк иде. Шушы дөньяда тырышып укыткан Коръән, кылган догалар, биргән сәдакалар да безгә ирешерләр иде. Менә шушындый гомерләрне, шушындый үлемнәрне Аллаһ Тәгалә барчабызга да насыйп кылса иде. Шушындый матур иттереп сөйләшеп утырган шикелле, җәннәттә дә очрашуларыбызны Аллаһ Раббыбыз насыйп кылса иде”.

Шундый теләкләрдән соң, вәгазь: “Әссәләәмүгәләйкүм үә рахмәтүллааһи үә бәракәәтүһ” (“Сезгә Аллаһы Тәгаләнең сәламе, рәхмәт һәм бәрәкәте булсын” – Ф.М.) яки “Амин” (“Әмин”) (“Шулай булсын! Дөрес, Хак булсын!”) сүзләре белән тәмамлап куела [Фазлыев, 2005:8-10].

Вәгазьләрдә “Мөхтәрәм дин кардәшләрем!, “Газиз дин кардәшләрем!”, “ Мөэмин кардәшләр!”, “Мөхтәрәм кардәшләрем!”, “Кадерле милләттәшләрем!”, “Мөхтәрәм җәмәгать!”, дигән мөрәҗәгать-эндәшү сүзләре кулланылып, гает-җомга намазларын укырга һәм вәгазь тыңларга җыелучыларга ихтирам белдерелә, үзара якынлык мөнәсәбәтләре, психологик халәт урнаштырыла.

Исламда дингә ихтыярсыз буйсындыру юк, дингә өндәү, вәгазьләү генә бар. Шунлыктан, вәгазьче имам-хатыйбның һәр гамәле, һәр әйткән сүзе зур мәгънәгә ия. Чөнки халкыбызның мәкаль-әйтемнәрендә дә бит: “Сүз сөйләсәң, уйлап сөйлә”, “Кыскалыкта – осталык”, “Белгәнеңне сөйләмә, ни сөйләгәнеңне бел”, “Телгә чичән телнең маен тамызып, сүзнең балын агызып

сөйләр”, “Булган оратор мең авызны каратыр, булмаган оратор болгатыр да таратыр”, – дигән хикмәтле гыйбарәләр гаять күп.

Алда күрсәтелгәнчә, хөтбә-вәгазьләрнең нигезен Коръән сүрәләре һәм Мөхәммәд пәйгамбәр (с.г.в.) хәдисләре (сөннәтләре) тәшкил итә.

Коръән (гар. – яттан уку, яттан сөйләү) – Ислам фәлсәфәсендә Изге Китап. Илаһият фәнендә аның 55 атамасы бар дип күрсәтелә: Коръән-Кәрим яки Коръәни-Кәрим (кәрим – хөрмәтле, кадерле, бөек, газиз), Коръән-Мәҗид (мәҗид – данлы, мактаулы), Коръән-Газим (газим – алдан уйлап куючы, исәпләүче, ниятләүче; батырчылык, кыюлык итүче; баручы, юл күрсәтүче), Китабуль зикер (зикер – искә алучы, искә төшерүче), Китабуль хикмәт, Китабуль-мөбин (мөбин – дөреслек белән ялганны аеручы), Өммелкитаб (Китаплар анасы), Форкан (Коръән), Кәлямулла (Аллаһ сүзе, Коръән), Мосхәф шәриф (кадерле Коръән) һ.б.

Коръәннең үзәгендә бер Аллаһка ышану-инану идеясе ята. Ул – барысын да яратучы, тиңсез, кодрәтле. Изге Китапта Ислам диненең асылы, шәригать кануннары, Адәм (р.г.) балаларының яшәү рәвешләре аңлатыла. Алар арасында иң мөһимнәре түбәндәгеләр: Аллаһы Тәгаләнең берлегенә һәм барлыгына, Мөхәммәд пәйгамбәрнең (с.г.в.) Аның илчесе икәнлегенә ышану (“Лә иләһа илләллаһу Мөхәммәдүр Рәсүлүллаһу”), биш вакыт намаз (ас-салат), Рамазан аенда ураза тоту (ас-саум), мохтаҗларга өлеш чыгару (зәкят) һәм хаҗга бару.

Коръән-Кәримдә Ислам кануннары һәм фазыйләтләре кешенең фикерләве, рухи халәте, үз-үзен тотышы белән тыгыз бердәмлектә бирелә.

Шәрекъ голямалары Коръәнне, эчтәлегенә карап, 10-20 өлешкә аерып тикшерәләр: Аллаһы Тәгалә һәм Аның асыл сыйфатлары; инандыргыч дәлилләр; мөэмин-мөселманнар һәм мөселман булмаганнар; пәйгамбәрләр һәм халыклар; җиһан турындагы фикерләр; җәмгыять төзелеше; туу, яшәү һәм үлем; гаилә; әдәп-әхлак мәсьәләләре; гыйбрәтләр; хәерле һәм бозык эш-гамәлләр; гыйлем һәм фикер йөртү һ.б. Анда инсанны бизәүче әхлакый сыйфатларга аеруча зур урын бирелә: тугрылык, гаделлек, ихласлылык, юмартлык, шәфкатьлелек, сабырлык, ата-ананы хөрмәтләү, сүз һәм эш-гамәл берлеге һ.б. мактала, ә аларның тискәреләре төрлечә хөкем ителә. Бигрәк тә ялганлау, кеше канын

түгү, фетнә тарату, икейөзлелек, эчүчелек, зина кылу, хәрам мал туплау, гайбәт сөйләү һ.б. гаепләнә, алар зур гөнаһлардан санала.

Коръән-Кәрим конкрет тарихи җирлектә, билгеле бер иҗтимагый-сәяси шартларда барлыкка килгән. Изге Китапта шул дәвер кешеләренең гореф-гадәтләре, мифологик күзаллаулары, фикерләү үзенчәлекләре дә гәүдәләнеш тапкан. Әмма Коръәндә вакытлы, тарихи күренешләрне тасвирлау аша, гомумән, инсаният, җәмгыять, яшәеш хакында фәлсәфи уйланулар бәян ителә. Болар Аның эчтәлегендә дә, тел-стилендә дә ачык сиземләнә.

23 ел дәвамында Җәбраил фәрештә арадашчылыгында Аллаһы Тәгаләдән Мөхәммәд пәйгамбәргә (с.г.в.) иңдерелгән Коръән-Кәрим 114 сүрәдән (бүлектән) гыйбарәт. Анда алар үзләренең күләмнәренә карап урнаштырылганнар: әүвәл (беренче сүрәдән кала) иң озыны, аннан соң кечерәкләре. Сүрәләрнең һәрберсе исемләнгән: 1) “Фатыйха” сүрәсе; 2) “Бакара” сүрәсе; 3) “Гыймран” сүрәсе; 22) “Хаҗ” сүрәсе; 30) “Рум” сүрәсе; 62) “Җомга” сүрәсе; 114) “Нәс” (Кешеләр) сүрәсе. Сүрәләргә атамалар, кагыйдә буларак, эчтәлекләренә һәм нигез мәгънәләренә нисбәттән бирелгән.

Һәр сүрә аятьләрдән (тәгъбирләрдән) тора. Аларның да күләмнәре төрлечә. Мәсәлән, 118 нче “Кәүсәр” сүрәсе 3 аятьтән, ә иң озыны булган “Бакара” сүрәсе 286 аятьтән тора. Коръән-Кәримнең төрле басмаларында 6204 тән алып 6239га кадәр аять урын алган. Бер аять берничә хәрефтән дә, сүз яки сүзләр тезмәсеннән, җөмләдән яисә берничә җөмләдән дә торырга мөмкин. Коръән гыйлеме галимнәре күрсәткәнчә, бу аятьләрдә 77934-79934 лексик берәмлек бар.

Коръән башта кульязма рәвешендә генә таралган. Бөек хәлифә Госман әмере белән төзелгән “Мөсхәф” барлык кульязмалар өчен нигез чыганак буларак хезмәт иткән. Аннан күчерелгән иң борынгы кульязмаларның дүртесе безнең көннәргә кадәр килеп җиткән. Алар Мәккә, Каһирә, Вена, Ташкент калаларының иң мәртәбәле урыннарында саклана.

Элек-электән Изге Китапны күчереп язу гаять җаваплы һәм саваплы хезмәтләрдән саналган. Моны гыйлемгә, матур язуга (каллиграфиягә) маһир булган осталар-хаттатлар башкарган. Коръәнне күчереп язуның төрки халыкларда, шул исәптән, татарларда, ифрат бай тәҗрибәсе булган.

Китап басу эше җайга салынгач та, Шәрекъ илләрендә Коръән-Кәримне басма рәвештә тарату тыелып киленгән. Аллаһы Тәгалә сүзләрен басма хәрефләр белән бирү гөнаһ саналган, Аны бары тик кулъязма рәвешендә генә тарату мәгъкуль күрелгән. Әмма бу Изге Китапка булган ихтыяҗны аз санлы кулъязмалар гына канәгатьләндерә алмаган. Акрынлап Аны бастырып чыгара башлыйлар. Мөхтәрәм галимебез Ризаэтдин Фәхретдинов билгеләп үткәнчә, аның гарәпчә басма нөсхәләре 1881 елда Истанбул шәһәрендә нәшер ителә.

Русиядә Коръәннең заманында күренекле галимнәрдән саналган Петр Посников тарафыннан башкарылган рус телендәге тулы тәрҗемәсе 1716 елда басылып чыга. 1783 елда галим Савари тәрҗемәсе бастырыла. 1790 елда Казанның Беренче ирләр гимназиясе директоры булып эшләгән һәм шәрекъ телләрен укытуның ялкынлы тарафдары булган академик М.М.Веревкин тәрҗемәсе нәшер ителә. 1792 елда мәшһүр тәрҗемәче А.Колмаков Коръән Кәримнең рус телендәге дүртенче тәрҗемәсен бастыра. 1854 елда А.Казимирский, 1864 елда К.Николаев тәрҗемәләре дөнья күрә. Моңа кадәр Коръәннең рус телендәге тәрҗемәләре француз, инглиз телләрендәге басмаларга нигезләнеп башкарылса, XIX йөзнең соңгы чирегеннән турыдан-туры гарәп теленнән тәрҗемә ителгәннәре дөнья күрә башлый. Рус телендәге шундый тәрҗемә авторларының берсе шәрекъ һәм гарәп телләре белгече Г.С.Саблуков була. 1877 елда аның тәрҗемәсендә Коръәннең яңа басмасы Казанда нәшер ителә. 1894 һәм 1907 елларда ул кабаттан бастырып чыгарыла. Гомере буе Коръәнне рус теленә тәрҗемә итү белән шөгыльләнгән һәм “Коръән тәрҗемәсенә кушымталар”, “Коръән турында мәгълүматлар”, “Мөхәммәд динендәгеләрнең кыйбла турындагы фикерләре” кебек хезмәтләр язып калдырган Г.С.Саблуков тәрҗемәсе тулы бер гасыр буена бу өлкәдә рус фәне һәм җәмгыяте ихтыяҗларын тулысынча канәгатьләндергән мөһим чыганакка әверелә. Коръәннең рус телендәге чираттагы басмасы бары тик 1963 елда гына дөнья күрә. Аның авторы – бөтен гомерен Коръәнне өйрәнүгә багышлаган, югары уку йортларында лекцияләр укыган атаклы галим, академик И.Ю.Крачковский. Бу тәрҗемә үзенең төгәллеге, текстларның аныклыгы-камиллеге һәм тулылыгы

белән аерылып тора. Аның яңа басмалары 1986 һәм 1990 елларда нәшер ителә.

Ислам дөньясында Корънне мөселман халыклары телләренә тәрҗемә кылу катгый тыелган булса да, төрле дәверләрдә уйгур, фарсы, урду, төрек телләренә тәрҗемә ителгәнлекләре мәгълүм. 1960 елда күренекле төрек галимнәре Хөсәен Атай һәм Ятар Котлыай тарафыннан төрекчәгә яңа тәрҗемәсе дөнья күрде, аннан соң да аның яңадан-яңа басмалары нәшер ителде. 1991 елда Бакуда Корънәнең азәрбәйҗан теленә яңа тәрҗемәсе (тәрҗемәчеләр: З. Бониятов, В.Мәмәдалиев, А.Пашазадә) басылып чыкты.

1911 елда мәшһүр дин галиме Муса Бигиев Корънне татар теленә тәрҗемә итә. Әмма ул тәрҗемә нәшер ителмичә кала. Зыяэтдин Кәмалиның “Корън-Кәрим тәрҗемәсе” дә шундый язмышка дучар була. 1914 елда Камил Мотыйгый-Төхвәтуллин тәрҗемәсенең аерым өлешләре дөнья күрә. Корън-Кәримнең татар телендәге башка тәрҗемәләре билгеле түгел.

1936 елда Каһирәдә (Әл-Әзһәрдәге Ислам университеты) күренекле дин галимнәреннән махсус һәйәт төзелә һәм Корънне башка телләргә тәрҗемә кылу мәсьәләсе уңай хәл ителә.

Тәфсир, гыйльме тәфсир (гар. – аңлатып бирү) – Корънәнең фәлсәфи аңлатмасы. Корънәнең үзе кебек үк, Аның тәфсирләре дә Исламият тарихын, аның гасырлар дәвамындагы эволюциясен өйрәнү өчен әһәмиятле чыганак булып тора. Борынгы тәфсирләр, нигездә, гарәп телендә язылган. Тәфсир эшләүне беренче булып Мөхәммәд саллаллаһу галәйһис-сәламнең (с.г.в.) туганнан-туган кардәше Габдулла бине Габбас башлап җибәргән. Башка тәфсирчеләр аны үзләренең остазы итеп кабул иткәннәр. Сөнниләрдән тәфсир язучы – атаклы голямаларның берсе, күренекле тарихчы һәм дин галиме Әт-Тәбари. Аның “Тәфсире әл-Корън” дигән хезмәте бу өлкәдә аңа кадәр эшләнгәннәрнең бөтенесен үзенә туплаган. Бу хезмәтнең тулы басмасы 1906 елда Каһирәдә 30 җилдтә басылган. Шулай ук Зәмәхшәри Бәйдави, Фәхретдин Рази, Хөсәйни, Җәләлетдин Суюти тәфсирләре бөтен дөнья күләмендә шөһрәт казанган һәм киң таралган.

Мөхәммәд (с.г.в.) өммәтендәге мөселман татарлар өчен дә Корън-Кәримнең татарча тәфсирләренә ихтыяҗ артканнан-арта бара, чөнки дин тотучыларның иң зур күпчелеге гарәп телен аңламыйлар. Димәк, Изге Китаптаниләр язылганын да белмиләр. Ә Корънгә киңәйтелгән мәгънәви аңлатма-тәфсир кылганда

гына, аның бөеклегенә, инсаннарның яшәү рәвешенә тугры юл күрсәткән Изге Китап икәнлегенә ышанырга-инанырга мөмкин.

Мәгълүм булганча, Коръәнне башка телләрдә аңлату-шәрехләү беркайчан да тыелмаган. Моның шулай икәнлеген дәлилләп, атаклы гыйлем иясе Шиһабетдин Мәрҗани да үзенең “Нәзурәтүлхак” (“Хаклыкка бер караш”) дигән хезмәтендә Коръән һәр чорда яңача тәфсир ителергә тиеш, ягъни Коръән сурәләрендәге аятьләрне заман сулышын тоеп тәфсир итү яхшырак дигән фикерне әйтә.

Элегрәк кульязма рәвешендә таралган Коръәннең татарча тәфсирләре XIX йөзнең икенче яртысында басма хәрефләр белән нәшер ителә башлый. Шул дәвернең 80 нче елларында Хөсәен һәм Мөхәммәтзариф Әмирханнар тарафыннан эшләнгән 2 җилдлек “Тәфсире фәваид” (“Файдаларның тәфсире”) Казанда басылып чыга. XX гасыр башларында, гарәп шрифтлары белән эш итүче матбагалар ачылгач, Коръән тәфсирләре күбрәк нәшер ителә башлый. Бу елларда Шакирҗан Хәмидинең “Һәфтияк-Шәриф тәфсире” (Казан, 1906), Шәйхелислам Хәмидинең “Әл-Иткан фи тәрҗемәтуль-Коръән” (Казан, 1907), Габденнасыйр Курсави һәм Ногман әс-Самани тарафыннан шәрехләнгән “Тәфсире Ногмани” (Оренбург, 1907), Мөхәммәтсадыйк Иманколыйның “Тәһсилел бәян фи тәфсире Коръән” (Казан, 1911), Камил Мотыйгый-Төхфәтуллинның “Татарча Коръәни тәфсир” (Казан, 1914) һ.б. басмалар дөнья күрә.

Октябрь инкыйлабыннан соң, Коръән Кәримне нәшер итү, нигездә, туктатыла. 1917-1990 елларда Ул бары тик 8 мәртәбә генә басылып чыга. Узган гасырның 90 нчы елларыннан соң гына, бу изге гамәлият яңадан тормышка ашырыла башлады. Менә соңгы елларда нәшер ителгән Коръән тәфсирләренең кайберләре: Коръән тәфсире – Казан: Татар.кит.нәшр., 1992. – 683 б.; Коръән тәфсире (Ногмани). – Казан, 1992. – 684 б.; Коръәни-Кәрим / төз. Ф.Сәлман . – Казан: Раннур, 1999. – 574 б. Коръән тәфсире / Кереш сүз язучы К.Бикчәнтәев. – Казан: РИЦ “Дом печати”, 2000. – 519 б,; Коръән сүрәләре / Җәгъфәр хәзрәт Мөбарәк. – Казан: Раннур, 2000. – 208 б. ; Коръән аяттләренең татарча мәгънәләре һәм аңлатмалары // Төз. Р.Батулла. – Казан: Татар.газета-журналлар нәшр., 2000. – 600 б. 2011 елда Р.Батулла тарафыннан эшләнгән Коръән тәфсиренең яңа басмасы дөнья күрде.

Бу басмаларда аерым төгәлсезлекләр, җитешсезлекләр булса да, имам-хатыйблар кулында хөтбә-вәгазьләрдә файдаланырлык Коръән Кәрим хәдисләре бар. Алардагы аятьләрне кирәкле урында дөрес тулы һәм аңлаешлы итеп файдалана белергә генә кирәк. Ә алардан башка бер генә дини хөтбә-вәгазь дә була алмый.

## Мөхәммәд галәйһиссәлам хәдисләре

Хөтбә-вәгазьләрдә, Коръән-Кәримнән кала, иң мөһим чыганакларның берсе булып, хәдисләр тора. Алар Мөхәммәд пәйгамбәрнең (с.г.в.) тормышы, эшчәнлеге, кылган гамәлләре, васыятьләре хакындагы риваятьләрне тәшкил итә. Коръән мөселманнар җәмгыятенең барлык хокукый һәм әхлакый мәсьәләләрен үз эченә сыйдырып бетерә алмаганлыктан, VII гасырның азагы – VIII гасыр башларында хәдисләр барлыкка килгән.

Хәдисләр башта телдән-телгә сөйләнеп таралганнар. Дәверләр үтү белән, алар мөхәддисләр (хәдисләрне махсус өйрәнүче галимнәр) тарафыннан тупланып һәм билгеле бер эзлеклелектә тәртипкә салынып, аерым мәҗмугалар рәвешендә эшләнә башлаганнар. Шәрекъ дөньясында шундый җыентыкларның иң билгелесе – “Әл-җәмигъ әс-сахих” (“Ышанычлы җыентык”). Аны төзүче имам Исмәгыйль әл-Бохари 600 меңләп хәдис туплап, шулар арасыннан 7250сен генә иң ышанычлы һәм лаеклы дип санап, үзенең җыентыгына керткән. Бу мәҗмуга гарәп илләрендә күп мәртәбәләр нәшер ителгән. 1974 елда, әл-Бохариның тууына 1200 ел тулу уңаеннан, мөхтәрәм акыл иясенең бу китабы Сәмәркандта басылып чыкты. Сөнни мөселманнар арасында Мөслим Нишапуриның 12 мең хәдисне үз эченә алган “Әл-мәснәд әс-сахих”ы, (“Ышанычлы таяныч”) да шөһрәт казанган.

Октябрь инкыйлабына кадәр татарча хәдис китаплары төрек телендәге мәҗмугалардан тәрҗемә ителгән. Шундый җыентыкларның берсе төрек галиме Мөхәммәдгариф бәк төзегән “Мең дә бер хәдис” Шакирҗан Хәмиди тарафыннан тәрҗемә ителеп, 1906 елда Казанда басылып чыккан. Бу хезмәтнең мөһимлеген автор болай дип бәяли: “Берәүләрнең кыяматкә кадәр башларымызга киләчәк нәрсәләрнең һәркайсыннан шул кыска егерме өч ел эчендә гыйлем калдырган Пәйгамбәребез (с.г.в.)нең хәдис шәрифләрен укып кына түгел, шулар белән гамәл кылмак ляземдер”.

“Мең дә бер хәдис”нең тагын бер басмасы 1907 елда Санкт-Петербургта дөнья күрә. “Мең дә бер хәдис шәриф-шәрхе” исемле хезмәтнең авторы – Габдерәшит казый Ибраһимов. 1909 елда Казанның “Үрнәк” типографиясендә Мөхәммәдгариф хәзрәт Әмирханның (Ф.Әмирханның әтисе) “Әхадисе Коддусия” (“Иң кадерле хәдисләр”) исемле җыентыгы нәшер ителә. Галимҗан Баруди мөхәррирлегендә чыккан “Әд-Дин вә әл-Адәб” журналында да (1906-1908, 1913-1917) эзлекле рәвештә хәдис гыйлеме нигезләре белән таныштырып барылган.

Мөгаллим Габдрахман Кәбиров 1915 елда Казанның “Милләт” матбагасында “Мең дә бер хәдис шәриф тәрҗемәсе”н бастырган. Анда гыйлем, күркәм холык, адәмнәр арасында кардәшлек, мөселманнар, сәүдә кәсебе, бердәмлек, ятимнәргә мәрхәмәт, каберләргә зиярәт, саранлык-юмартлык, олыларны хөрмәтләү, хезмәт кешеләренә мөнәсәбәт, балаларга тәрбия бирү, сүздә осталык һ.б. хакындагы хәдисләр тупланган.

1916 елда Оренбургта күренекле дин галиме Ризаэтдин Фәхретдиновның “Җәвамигуль-кәлим шәрхе” китабы нәшер ителә. Анда әхлакый һәм иҗтимагый эчтәлектәге 344 хәдис тупланган. Автор гарәпчәдәге хәдисләрне татар теленә тәрҗемә итеп, аларга тәфсилле аңлатмалар бирә, хәдисләргә багышлап иҗат ителгән гарәп чыганакларыннан өзекләр китерә, көндәлек тормышта очрый торган гыйбрәтле хәлләрдән мисаллар бирә. Бу китапның яңа басмасы 1989 елда дөнья күрде. Болардан тыш халкыбыз тарафыннан яратылып укыла торган “Кырык хәдис”, “Әхдийсү мөнтәхибә” (“Сайланма хәдисләр”) һ.б. китаплар да киң таралыш алган. Шулай ук мәктәп-мәдрәсә укучылары өчен әзерләнгәннәре дә бар [МБС, 1993:152-156; Мөбарәк, 2002:220-224].

Шунысын да искәртеп узарга кирәк: хәдис гыйлеме һәм аны өйрәтү ысуллары мәктәп-мәдрәсәләрдә аерым фәннәр буларак укытылган, махсус дәреслекләр язылган, аларны өйрәтүче мөхтәрәм галим-мөгаллимнәр булган. Мәсәлән, шундыйларның берсе -Уфадагы “Галия” мәдрәсәсенең мөдәррисе, күренекле дин галиме Зыяэтдин Камали.

Коръән тәфсирләре, хәдис китапларыннан кала, дини әдәбиятның халык арасында киң таралган төре булып, күпсанлы хөтбә-вәгазь, үгет-нәсыйхәт китаплары, дини тәрбия һәм дин гамәлләрен аңлатуга юнәлдерелгән һәртөрле мәҗмугалар тора.

Халык арасында кульъязма һәм басма рәвешендә аеруча киң таралган һәм яратып укылган шундый дини дидактик китапларга "Нәсихәте-с-салихин" ("Изгеләрнең нәсыйхәтләре"), "Кисекбаш китабы", Мөхәммәд Чәләбинең "Мөхәммәдия", Мәхмүд Болгариның "Нәһҗел-Фәрадис" ("Оҗмахлар бакчасына ачык юл"), Борһанетдин Рабгузиның "Кыйссаи Рабгузи" ("Кыйссасел Әнбия"), "Бәдәвам" Мөхәммәд Чокрызадәнең "Алты бармак", Сөләйман Баркырганиның "Бакырган" ("Ахырзаман китабы",) Таҗетдин Ялчыголның "Рисаләи Газизә" һ.б. керә. XIX йөзнең урталарыннан башлап, алар кабат-кабат нәшер ителгәннәр. Шулай ук "Әнвәрүл-гашикыйн" (төрек теленә тәрҗемә итүчесе Әхмәд Биҗан), Әбү Ләис әс-Сәмәркандиның "Тәнбийһүл-гафилийн" (тәрҗемәчесе – Нургали Алкин) , Имам Газәлинең "Нәсыйхатнамә", "Тарикаи Мөхәммәдия", Әбүлхөсәен әл-Багдадиның "Мөхтасар әл-Кодури" (тәрҗемәчесе – Шәйхелислам Хәмиди), "Гайнел-гыйлем" ("Гыйлемнәр чишмәсе) һ.б. китаплар да булган [ИБС, 1993:40-44; Мөбарәк, 2002:228-233].

Бу әсәрләрдә, Коръән аятьләре һәм хәдисләр генә тәфсир ителеп калмыйча, пәйгамбәрләр, изгеләр тормышыннан алынган күп кенә риваятьләр, гыйбрәтле хикәятләр, тәрбияви үгет-нәсыйхәтләр бирелгән. Аларның күбесе мәктәп-мәдрәсәләрдә уку китаплары булып та кулланылганнар. Вәгазьчеләр дә мондый китаплардан оста файдалана белгәннәр.

XX йөз башларыннан татарча хөтбә-вәгазьләр тупланган аерым мәҗмугалар да нәшер ителә башлый. Шундый китапларга Габдрахман Ниязиның "Хөтбәләр мәҗмугасы"н (1908), Нияз Мөхәммәд Сөләйманиның "Төрки хөтбәләр"ен, "Вәгазь намәрисаләсе"н (1909), Габдулла Сөләйманиның "Вәгазьләр"ен (1912), Шакирҗан Хәмидинең "Җомга хөтбәләре"н һ.б. кертергә мөмкин.

1917 елгы Октябрь инкыйлабына кадәр басылып чыккан китаплар арасында Җиһангир Абызгилдиннең "Хитабәт ысуллары" (Уфа, 1917) хезмәте аерым игътибарга лаеклы. Ул хөтбә-вәгазь укучыларга, имам-хатыйбларга, мәктәп-мәдрәсә мөгаллимнәренә хатыйблык (ораторлык) осталыгын камилләштерү буенча методик кулланма булып та хезмәт иткән. Автор, Ислам өйрәтмәләренә нигезләнеп, хөтбә-вәгазь сөйләү ысулларына һәм үзенчәлекләренә туктала, хатыйб-нотыкчыларга сәнгатьле сөйләмне яхшырту буенча киңәш-тәкъдимнәрен җиткерә. Әлеге китапта хитабәт

(ораторлык, сүз сөйләүчелек) сәнгатендә сөйләү теленең, тавышның әһәмиятенә, сөйләмнең максатына карап интонация үзгәрешләренә, интонация белән идарә итү мәсьәләләренә зур урын бирелә. Хатыйблык эшчәнлегендә тавыш-интонация проблемаларына ул психологик күзлектән чыгып якын килә [Абдуллина, 1999:17-22].

Һичшиксез, мәшһүр татар галиме, күренекле дин эшлеклесе һәм Шәрекъ белгече, әдип Ризаэтдин Фәхретдиневнең "Әхлак гыйлеме" сериясендә 1898-1919 елларда күп тапкырлар нәшер ителгән "Гаилә", "Нәсыйхәт", "Тәрбияле хатын", "Тәрбияле ата", "Тәрбияле бала", "Тәрбияле ана", "Шәкертлек әдәпләре", "Адәбе тәгълим" һ.б. китапларын, Ислам фәлсәфәсенә караган хезмәтләрен онытырга ярамый. Чөнки алар мөселман мәктәп-мәдрәсәләрендә әдәп, әхлак, нәфасәт, педагогика дәресләрендә дәреслек яки кулланма итеп файдаланылган, һәр татар гаиләсенең өстәл китабы булып торган [Фәхретдин, 2005:184].

Барыбызга да мәгълүм сәбәпләр аркасында, Октябрьдән соңгы еллар дәвамында дини эчтәлектәге китаплар бастырылмады. Бары тик узган гасырның 90 нчы елларында, дингә карата сәяси вәзгыятьтәге үзгәрешләр нәтиҗәсендә генә, бу эш яңадан тернәкләнеп китте. Илаһият фәненә игътибар артты. Әйе, мондый басмаларга мөэмин-мөселманнар, шәригать юлына басучылар сусаган, ихтыяҗлар гаять зур иде. Шөкер, бер-бер артлы андый китаплар күпләп басыла башлады. Менә соңгы елларда гына нәшер ителгәннәрнең кайберләре: Пәйгамбәрләр тарихы / төз. Ф.Яхин: Казан: Татар.кит.нәшр., 1992. – 144 б.; Иман / төз. Ф.Яхин. – Казан: Татар.кит.нәшр., 1993. – 208 б.; Ислам әхлагы һәм гадәтләре / төз. М.-И. әл-Кайси. – Казан: Иман, 1994. – 120 б.; Корбан гайде. Вәгазьләр һәм хөтбәләр / төз. В.Ягъкуб. – Казан: Татар.кит.нәшр., 1995; Олуг пәйгамбәр / төз. Ф.Яхин. – 1 кит. – Казан: Татар. кит.нәшр., 1994. – 192 б.; Вәгазьләр һәм хөтбәләр / төз. Җ.Мөбарәк. – Казан: Иман, 1995. – 32 б.; Хөтбәләр, вәгазьләр / төз. И.Лотфуллин. – Казан: Югары мәдрәсә нәшр., 1995. – 57 б.; Ислам динендә йола һәм әдәп / төз. Ф.Яхин. – Казан: Джайб, 1996. – 83 б.; Ислам дине нигезләре / төз. Ф.Яхин. – Казан: Раннур, 1997. – 288 б.; Исхакый Р. Җан азыгы. Шигъри вәгазьләр. – Казан: Кыйбла, 1998. – 304 б.; Олуг пәйгамбәр / төз. Ф.Яхин. - 2 кит. – Казан: Татар.кит.нәшр., 1998. – 160 б.; Ислам гореф-гадәтләре / төз. Я.Исхаков. – Казан: Матбугат йорты, 1999. - 128 б.; Пәйгамбәрләр,

фәрештәләр, ахирәт / төз. Ф.Яхин. – Казан: Раннур, 1999. – 368 б.; Пәйгамбәребез Мөхәммәд: Трилогия / төз. Ф.Яхин. – Казан: Раннур, 1999. – 575 б.; Җәлил хәзрәт вәгазьләре. – 2 китапта. – 1 кит. – Казан: Мәдәни җомга, 1998. – 222 б.; 2 кит. – Казан: Мәдәни җомга, 1999. – 256 б.; Исхакый Г. Динсез яшәп булмый. - Казан: Иман, 2000. – 320 б.; Исхакый Г. Ислам әхлагы. – Казан, 2002. – 269 б.; Илле ике вәгазь / төз. Н.Сөләймани. – Казан: Иман, 2001. - 252 б.; Вәгазьләр, әдәп-әхлак китабы / төз. Г.Мөхәммәтшин. – Казан: Идел-Пресс, 2004. – 270 б.; Фазлыев Җ. Йөз дә бер вәгазь. – Казан, 2005. – 544 б. һ.б. Күргәнебезчә, имам-хатыйблар, дин тотучылар өчен дә файдаланырлык әдәбият җитәрлек. Моның өстенә, вакытлы матбугатта, радио-телевидение тапшыруларында да шактый материаллар бирелеп киленә, аудиоязмалар, буклетлар да бар. Дини календарларда, интернет челтәрендә дә илаһияткә, үгет-нәсыйхәтләргә, вәгазьләргә зур урын бирелә.

Алда әйткәнебезчә, хөтбә-вәгазьләрнең үзәгендә Коръән-Кәрим аятьләре һәм Мөхәммәд галәйһис-сәллам (с.г.в.) хәдисләре тора. Шулар нигезендә дини һәм дөньяви вәгазьләр корыла. Дини бәйрәмнәрдә сөйләнә торган вәгазьләрдә Коръән аятьләре һәм хәдисләр күбрәк урын ала. Шунлыктан Коръәннән китерелгән аятьләрне тәҗвид белән, дөрес мәкам белән уку, аларны кимчелексез, тулы аңлатып-шәрехләп бирү аеруча җитди игътибарны сорый. Әмма гыйлемсез, хәзерлексез бу гамәлгә тотынырга ярамый, хаталанудан, гөнаһлы булудан сакланырга, ә булганнарыннан нәтиҗәле файдалана белергә кирәк.

Изге Коръәннән һәм пәйгамбәребез сөннәтләреннән китерелгән өземтәләр (цитаталар) вәгазьнең эчтәлек-төзелешен билгеләүдә, теге яки бу фикерне раслау-дәлилләүдә мөһим роль уйныйлар. Алар, гадәттә, туры сөйләм рәвешендә бирeләләр һәм өземтәне башлауга ишарә итүче, туры сөйләмне вәгазьче сөйләменә бәйләүче сүзләр, ярдәмче чаралар, төрле тыныш билгеләре ярдәмендә килеп керәләр.

Аллаһы Тәгалә сүзләре иңдерелгән Коръән-Кәримнән өземтәләр биргәндә, текст башында яки ахырында аның чыганаклары (сүрәнең атамасы яисә тәртип номеры һәм аятьләрнең гамәлдәге саны) күрсәтелә. Аллаһының сүзләре автор тарафыннан әйтә / әйтәдер / әйтте / әйткән; ди / диде / дигән / диелә / дип; боера / боерды / боерган кебек хикәя фигыльләрнең төрле заман формалары белән бирелә. Мәсәлән: “<...> “Әл-Мүлек” сүрәсендә

(3 нче аять) Аллаһ Раббыбыз әйтә: “Фәрҗигил-бәсара һәл тәраа миң фүтуур” (орфоэпиядә – Ф.М.) – “Минем яратканымда һичбер кимчелек табылмас”, – ди [Фазлыев, 2005:12]. Бу турыда Аллаһы Тәгалә Коръәннең 39 нчы “Әл-Зүмәр” сүрәсенең 10 нчы аятендә болай ди: “Иманлы кешеләр Раббыбыздан куркыгыз. Бу дөньяда игелек кылсыннар өчен җәннәттә нигъмәтләр бар. Бары тик сабыр иткәннәргә генә бихисап әҗерләр булачак” [ТМК, 2008:143]. Җәнабел Хак “Кәүсәр” сүрәсендә: “Раббың өчен намаз укы вә корбан чал”, – дип боера [ТК, 1996:29 апрель].

Коръән аятьләренә аңлатмалар биргәндә дә, югарыда күрсәтелгән фигыль формаларының актив кулланылышы күзәтелә. Мәсәлән, Җәлил хәзрәт Фазлыев үзенең бер вәгазендә өземтәне болай дип бирә: Коръәни Кәримдә Аллаһ Раббыбыз әйтә: “Үә мән әхсәнү кауләм-миммән дәгәәәә иләәллааһи үә гәмилә-саалихәү-үә каалә иннәнии минәл-мүслимииин” (41:33). – Минем сүземне адәм балаларына җиткерүчедән дә сөйкемлерәк кеше юк, – диде [Фазлыев, 2005:12].

Имам хатыйбларның хөтбә-вәгазьләрендә (сөйләмә телдә һәм язмаларда) аятьләрнең иң әүвәл гарәпчә текстлар белән бирелүе, безнеңчә, кирәкле гамәл. Болай эшләгәндә, беренчедән, җәмәгатьнең игътибары көчәйтелә, икенчедән, аның ана телендә аңлатмасын ишеткәч, инсанның күңеле сөенә, мәгънәсенә төшенүенә шатланып утыра.

Мөхәммәд пәйгамбәр (с.г.в.) хәдисләреннән файдаланганда, чыганаклар төгәл күрсәтелми, “хәдисендә”, “бер хәдисендә”, “хәдис шәрифендә”, “сөннәтләрендә” кебек тәгъбирләр белән шул ук *“әйт”, “ди”* фигыльләренең төрле заман формалары кулланыла. Вәгазьнамәләрдә Пәйгамбәребез сөннәтләренең, нигездә, татарча тәфсирләре генә бирелә.

Дөрес, Коръән-Кәрим аятьләреннән, Мөхәммәд пәйгамбәр (с.г.в.) хәдисләреннән кирәкле өземтәләр алу, аларга тулы һәм төзек аңлатмалар бирү имам-хатыйбның гыйлеменә, тел һәм сөйләү осталыгына бәйле. Әмма бер нәрсә ачык булырга тиешле: өземтәләр сүзгә-сүз, курсивлары-чыганаклары һәм башка үзенчәлекләре белән анык китерелергә һәм, барыннан да бигрәк, цитата итеп алынган өзекнең эчтәлеге бозып күрсәтелмәскә тиеш. Чөнки контексттан өзеп алынган җөмлә яки аның кисәге үзе генә аерып алынганда, Коръән аятендәге фикер-мәгънәгә караганда үзгә мәгънә алып куярга мөмкин. Моннан саклану өчен төп нөсхәне

һичбер үзгәртүсез алырга кирәк, шулай ук һәртөрле кирәкмәгән кыскартуларга юл куярга ярамый [Курбатов, 1956:35].

Аларның тәфсирләре тулы, анык һәм аңлаешлы булсын. Кайвакытта татар әдәби теленең грамматик кагыйдәләре җирлегендә, киңрәк аңлатмалар бирү дә комачаулык итми, чөнки хөтбә-вәгазь тыңлаучылар арасында төрле яшьтәге, гыйлем дәрәҗәләре дә, һөнәрләре дә төрле булган кешеләр бар. Төрле хөтбә-вәгазь мәҗмугаларыннан андый үрнәкләрне күпләп китерергә мөмкин. Мәсәлән, Җәлил хәзрәт Фазлыев вәгазендәге Мөхәммәд пәйгамбәр (с.г.в.) хәдисеннән китерелгән бер җөмлә мондый аңлатмалар белән бирелә: "Әллааһүммә иннәкә гәфүү үүн түхиббүль-гәфүә фәгфү гәнни". (укылышта – Ф.М.). – Әй, Аллаһ! Син – гафу итүче, гафу итәргә яратасың. Гафу ит мине, гөнаһларымны ярлыка <...>. Татарча: "Йа, Раббым, ярлыка мине. әлбәттә, Син зур ярлыкаучыдыр", – дигән мәгънә бирә. Һәм Аллаһтан ярлыкау сорап, татарча тагын: "Йа, Раббым, барлык гөнаһларымнан ярлыка, гөнаһларыбыздан ярлыка", – дип йөрсәк тә әйбәт. "Фәгфүгәннә" дисәк, "безне ярлыка" була; "Фәгфүгәнни" дисәк, "мине ярлыка" була. Менә шулай итеп, "безне ярлыка, балаларымны ярлыка" дип әйтсәк, әлбәттә, без саваплырак булырбыз... Чөнки Пәйгамбәребез Мөхәммәд (с.г.в.)нең бер хәдисе бар: "Мөселман мөселман булмас шуңа кадәр, үзенә теләгәнне башкаларга да теләгәнгә кадәр". Без үзебезнең генә ярлыкавыбызны түгел, барлык мөселманнар өчен дә ярлыкауны сорарга тиешбез. Шуңа күрә, "фәгфүгәннә" дип укысак, дөресрәк буладыр" [ТМК, 2010:252-253].

Әйе, вагыйз тарафыннан ирештерелгән һәр сүз, һәр тәгъбир тыңлаучыны уйландырырга, зиһеннәрен яктыртырга, холык-әхлагын күркәмләндерергә, бу гарасатлы заманда адәм рәтле яшәргә көч-куәт бирергә тиеш. Җәмәгатькә аңлаешлы, тирән эчтәлекле, мәгънәле һәм тәэсирле вәгазьләр генә тыңлаучыларның күңелләренә үтеп кереп, мөэминнәргә фани дөньяга һәм ахирәткә өмет биреп, аларны Исламияткә, һидәят юлына өнди алалар.

## Үзләштерелгән белемнәрне мөстәкыйль тикшерү өчен сораулар һәм биремнәр

Аңлатып үтегез: Риторика:

- «инандыру фәне һәм сәнгате» (Аристотель);
- «ораторлык тәҗрибәсен системалаштыру» (Цицерон );
- «нәфис сөйләм сәнгате, яхшы сөйләү сәнгате турындагы фән» (Квинтилиан);
- «белем тапшыру сәнгате» (Ф. Бэкон);
- «инандыру сәнгате һәм инандыру тәэсирен арттыруда сөйләмнең нәфислеге» (М.Ломоносов, А.Лосев, П.Пороховщиков);
- «сөйләм ярдәмендә йогынтылы аралашу шартлары һәм төрләре турындагы фән» (XXI гасыр башы төшенчәсе);

2. Дини риторика турында төшенчә бирегез.
3. Классик риторик эшчәнлекнең биш төп өлеше турында сөйләгез.

**Классик риторикада сөйләмне оештыруның төп буыннары**

| | |
|---|---|
| *Фикер чаткысы кабыну (инвенция)* | Тема, төшенчәләр системасын тәгаенләү. |
| *Фикерне оештыру тәртипкә китерү (диспозиция)* | Теманы үстерү: кереш, төп мәсьәлә, аңлату, раслау, кире кагу, нәтиҗә ясау өлешләрен эзлекле урнаштыру. |
| *Сөйләп карау (элокуцио)* | Сөйләм ситуация-сенә яракла-шып, фраза төзелешен тәгаенләү. Сөйләм тизлеге, ритмын билгеләү, риторик алымнар, троплар, сөйләмнең стилистик чараларын сайлап алу. |
| *Хәтергә сеңдерү (меморио)* | Тулысынча кабатлау (ятлау); эчтәлекнең кыскача язмасын әзерләү; төп мәгънәви өлешләрнең планын хәтергә сеңдерү: төп мәгънәви өлешләрне әһәмиятле сүзләр буенча аерымлау. |
| *Чыгыш ясау (акцио гипокризис)* | Чыгыш ясаучының рухи халәте, шәхси үзенчәлекләре белән бәйле гәүдә торышы, йөз хәрәкәте, ым, ишарәсе, сөйләм техникасы бердәмлеге. |

4. Риториканың максатлары һәм бурычлары хакында кыскача мәгълүмат бирегез.

5. Риториканың фән һәм уку төре буларак аерымлыгы, уртаклыгы нәрсәдә?

6. Антик риторика үсешенә кыскача күзәтү үткәрегез.

7. Рус дәүләтендә һәм Россиядәге риторика сәнгате турында сөйләгез.

8. Татар халкында хөтбә-вәгазьчелек, аралашу тәгълиматының үсеше турында мәгълүмат бирегез.

9. Бер предмет, күренешнең 10 уңай, 10 җитешмәгән ягын атарга.

10. Уңай раслаулардан капма-каршы нәтиҗәгә (А=Б, Б=В, А=В схемасы буенча).

11. Уңай раслаулардан, тиңләштереп, чагыштырып караулардан торган фикерләү чылбырының ахырында, баштагы раслауга капма-каршы нәтиҗәгә килергә (А=В, В тигез түгел С ка, А=С, С=Д, А=С=Д, Д тигез түгел К, ләкин А якынча тигез К га, димәк А тигез түгел икән В га; якынча алдагы схемага охшатып).

12. Г.Хәйям, Хафиз, Дәрдемәнд, Х.Туфан, Р.Фәйзуллин, Г.Мөхәммәтшин, Н.Арсланов, Р. Гаташ, М.Мирза иҗатыннан бер робагый ятлап, эчтәлегенә 6-7 җөмләлек комментарий бирергә.

13. Дөньяви эчтәлекле, дин мәсьәләләренә кагылышлы берәр хәдисне шәрехләп бирергә.

14. Бер мәкальнең эчтәлегенә туры килгән алдагы тарихын яки ахырда булырга мөмкин дәвамын сөйләргә (5-6 җөмлә белән).

15. Г.Тукайның Коръәни-Кәрим тәэсирендә иҗат ителгән шигырен ятларга, эчтәлеге буенча күзаллау хикәясен дәвам итеп сөйләргә.

16. А.Пушкин, М.Лермонтовның дини эчтәлектәге шигырьләрен укып күрсәтергә.

# III. ЧЫГЫШ ЯСАУЧЫНЫҢ ШӘХЕСЕ, ОБРАЗЫ

## Аралашучы образы һәм мәдәният

Меңьеллыклар дәвамында дөнья мәдәнияте, риторикасы үсешендә аралашуның күптән кабул ителгән үрнәкләре бар-лыкка килә. Аралашу күп кенә башка нык иҗтимагый оешмалар кебек гомуми системага яраша. Бу җәмгыятьнең сәяси оешуы һәм аның сәяси режимы, икътисади һәм башка эшчәнлек таләпләре, мәдәният традицияләре һәм таләпләре – барлык шартлар берләшмә эчендә аралашу оештыруга тәэсир итәләр.

Нәтиҗәдә, билгеле бер шартларда оратор сугышчы формасы киеп, дөнья һәм үз иленең куркыныч астында булу-булмавы хакында сөйли һәм халыкны бөтен көченә илне сакларга чакыра. Икенче очракта чапан киеп Аллаһка һәм якыннарына мәхәббәт хакында сөйли һәм халыкны дини тәгълиматка кушылырга өнди. Ораторлар төрле кыяфәткә керә, төрле тавыш белән сөйләшә, төрле кыймммәтләр куллана. Барлык очракта да аларның сөйләү омтылышлары мәдәниятнең теге яки бу аспектына корыла, ә сөйләм нәтиҗәсе берләшмәнең бөтенлеген ныгытуга яки җимерүгә юнәлтелә.

Европача аралашу җирлегендә чыгышларда үз-үзеңне тоту рәвеше табыла, ул гражданлык таләпләренә туры килә һәм ораторның күзалланган кыяфәте белән кушыла. Антик мәдәнияттә барлыкка килгән һәм безнең көнгә килеп җиткән классик кануннарга бәйле рәвештә, оратор үзен кирәкле шәхес итеп күрсәтергә, үзенә ышаныч яуларга һәм тыңлаучының хөрмәтен казанырга тырыша.

Мондый оратор “камил” кеше кыяфәтенә ия: ул физик яктан нык булырга, ашау-эчүдә чама белергә, дәрәҗәле күренергә, чиста, модалы киенергә, көчле һәм матур тавышка ия булырга тиеш... Башка сүзләр белән әйткәндә, әңгәмәне оештыручының күптән кабул ителгән образы, ораторга ышанырга әзер тыңлаучыларның гадәтләнгән мөнәсәбәтен барлыкка китерә: ул “алдый алмый” чөнки ул “хаклы”. Күп кенә замана имиджмейкерлары (оратор, сәясәтче, артистларның кыяфәтен “тудыручы” профессионаллар) оратор образын оештыруда әлеге стереотипны кулланалар. Шулай да ораторның классик образын файдалану һәм берләшмәдә бәйсез аралашу оештыру кире пропорциональ бәйлелектә тора дип әйтергә

була. Эшчәнлек никадәр уңышлы булса, стандарт булмаган кыяфәт шул дәрәҗәдә тәэсирле, берләшмә никадәр көчсез булса, ораторның классик образы шул кадәр тәэсирле була.

Оратор тулысынча үрнәк образдан файдалана, конкрет җирлектә аларны төрләндереп тора. Төрле хәлләрдә оратор бөтен кабул ителгән үрнәкләрне – символик инкяр итүче, битараф яки бөтенесен бутаучы, югалып калмаучы образы белән яраклаштыра. Образ рәвешен табуда сыгылмалылык һәрвакыт тыңлаучыларның ихтирамын яулауда ярдәм итә.

Билгеле булганча, конкрет образ күп кенә җайлашулар яки тәңгәлләштерүләргә ия була. Образга дини, ватанпәрвәрлек, сәяси, мәдәни, һөнәри һәм башка эчтәлекләр өстәп җибәрергә мөмкин. Җәмәгатьчелек мөмкинчелекләрен аралашу мөмкинлекләренә әйләндереп, оратор үз образын бик катлаулы формада оештырганда, башка үрнәкләрне дә өстәргә омтыла.

Ораторның универсал яки мәдәни йөзе аралашу барышында шәхесне бөтен берләшмә мәнфәгатен чагылдыручы, мәдәни мәсьәләләрне чишү дәрәҗәсенә күтәрә. Образның иң югары дәрәҗәсе мәдәният даирәсе белән оратор образын берләштерә һәм шул сәбәпле тыңлаучыларга көчле тәэсир итә.

Аралашу даирәсен болай оештыру җәмгыятьнең абсолют лидерларына – пәйгамбәрләргә, юлбашчыларга – хас. Әлеге образ үзенчәлекләре аралашуның моңа охшаш максатларын тормышка ашыруны таләп итүдә чагыла. Шуның өчен югары дәрәҗәдә аралашучылар шәхси мөмкинлекләр сыйфатында мәдәни казанышларга мөрәҗәгать итәләр һәм үз йөзләрен сакларга телиләр. Ник дигәндә, аралашуның һәр мизгелендә чыгыш ясаучы үз образының тәэсир көчен тыңлаучыларын кызыксындыру, игътибарын туплау чарасы, гомумән, аралашуны нигезләү рәвешендә кулланырга омтыла.

## Сөйләм кырын оештыру өлешләре: этос, пафос һәм логос

Сөйләме аша тәэсир итеп, оратор, алдына куйган максатын үтәү йөзеннән фикер-карашларын тыңлаучыларга җиткерергә тырыша, ягъни оратор үзенең чыгышында сөйләмне тудыручы белән кулланучының сөйләмен бер максатка юнәлтә. Аристотель, махсус, сөйләм төзелешен (структурасын) тикшерә. Сөйләмдә ул

төп өч элементны аерып карый. Әлеге элементларны Аристотель этос, пафос һәм логос дип атый.

Этос дип риторикада кулланучының сөйләмне барлыкка китерүчегә куйган шартын атыйлар. Сөйләүче белән сөйләмне кабул итүче арасында булырга мөмкин яки тәкъдим ителгән таләпләр шактый күп төрле. Рәсми рәвештә таләпләр чыгышны үткәрү вакытына, аудиториягә, сөйләүченең темасына, аның сөйләм даирәсенә, эчтәлегенә һәм башкаларга куела.

Этос, кулланучы теләге буларак, башкаручыга юнәлтелгән: этос тыңлаучылар күз алдында торткан (теләгән) аралашу нәтиҗәләре җыелмасы; аудитория һәм аның тарафыннан сөйләм эчтәлеген кабул итү; чыгыш ясаучы ихтыярына буйсындырылырга тиеш, аудитория булып оешып җитмәгән тыңлаучылар төркеме; аралашу тәэсирчәнлеген арттыруда тыңлаучыларның үз мөмкинлекләреннән файдалану; тыңлаучыларның төрле раслаулары; аларның аралашу нәтиҗәлеген үстерү алымнары һәм башкалар. Барлык мөмкин булган аңлатмаларны да этосның күрсәткечләре дип исәпләп була. Берничә күрсәткечне берсүзсез кабул итеп була, калганнарын кире кагалар. Этосның моделе аралашу барышында чыгыш ясаучы һәм тыңлаучыларның таләпләре берләшү нәтиҗәсендә оеша.

Хәзерге аралашу этосы катнашучыларның үзара мөнәсәбәтендә тигезсезлекне тормышка ашыра. Аралашу вакытында оратор тарафыннан тыңлаучының мөмкинлекләрен үзгәртү, аудитория теләкләрен күз уңаенда тоту да карала. Чынлыкта исә, бу халәт аралашу көчен тигезләү һәм оратор карашларын тыңлаучылар егәренә әвереллдерү белән тәмамланырга тиеш.

Димәк, хәзерге риторикада этос дип ораторның аудиториягә тәэсирен арттыру максатыннан куллана алырдай мөмкинлекләр, чыганаклар җыелмасын атыйлар.

Пафос бу очракта ораторның барлык мөмкинлекләре җыелмасы булып тора. Ул тыңлаучыларның да төрле мөмкинлекләреннән файдаланып аралашканда җитәрлек дәрәҗәдә була дип фаразлана.

Ораторның максатына яраклаштырып, тыңлаучыларның карашларын үзгәртүгә юнәлдерелгән һәм билгеле бер тема буенча эчтәлек тапшыру һәм тәэсир итү нияте (теләге) риторикада пафос дип атала. Пафос дип шулай ук ораторның чыгыштан тыш билгеле бер шәхси үзенчәлекләрен атап була. Оратор этос мөмкинлекләрен

истә тотып, вакытка һәм аралашу урынына туры килгән теманы оештыра, чыгыш төзи һәм оратор буларак үз-үзен әзерли, чыгышның эчтәлеген сайлый һәм билгеле бер сөйләм төрендә тормышка ашыра.

Хәзерге заман пафосын ике яклы дип әйтеп була. Бер яктан, либерализм идеаллары аралашу үсешенә сәбәп була, ул үзара йогынтыга һәм билгеле бер фикергә килү принципларына нигезләнә. Аралашуда катнашучыларның эшчәнлеге: югары дәрәҗәдә сүз иреге, альтернатив позицияләрне хуплау, каршы әйтелгән сүзләргә сабыр булу, мәгълүмат табу мөмкинлеге, ораторлан үзенең пафосын мәдәни дәрәҗәдә оештыруын таләп итә. Оратор яңача аралашу даирәсендә берләшмә әгъзасы буларак катнаша. Аның пафосы шәхсиләшкән этос.

Хәзерге заман аралашуы тыңлаучылар һәм сөйләүчеләрнең үзара ярдәм принцибына нигезләнә. Аралашу чаралары фән һәм мәгълүмат технологияләре ярдәмендә гел үсештә. Күп кенә аралашу, керем алу максаты белән, тамаша-бизнес рәвешен сайлый. Мәгълүмат чаралары, беренче чиратта телевидение, тыңлаучыларның һәм караучыларның этосын программалаштыра, күпьяклы образлар кабул итүгә әзерли. Психологиядә кеше аңын биләп алуда күп чаралар эшләнгән. Хакимият, үз чиратында, ихтыярсызлауга нигезләнгән идарә итү чараларын югалта, нәтиҗәдә ул рөхсәт ителгән алымнар ярдәмендә кешеләргә йогынтысын арттыруны кирәксенә.

Билгеле бер чыгышта сүз ярдәмендә пафосны оештыру логос дип атала.

Логос – этос һәм пафос чыганаклары һәм мөмкинлекләренең кушылуы, берләшүе исәбенә, оратор фикерләренең тыңлаучы карашларына әверелү чарасы да. Логосны шулай ук берләшү нигезе һәм аралашуда катнашучыларның карашлары белән алмашу, аларның күчерелүе дип атап була; логос, шулай ук берләшмә вәкилләренең аралашуда яңа даирәсен булдыру чарасы да.

Хәзерге вакытта логос сүз рәвешендә генә бәяләнми. Аралашу вакытында образлы һәм вербаль булмаган аралашу чаралары актив кулланыла башлады. Алар мәгълүмат тапшыручы һәм реципиентларның (тыңлаучыларның) фикер-карашларын берләштерү мөмкинлекләрен арттыра.

Ирекле аралашуда пафосны, этосны, логосны оештыру законнарын белү, барлык заман ораторларына һәм халкына,

тыңлаучыларга тәэсир итүдә һәм үзләренең максатларын тормышка ашыруда ярдәм иткән. Әйтергә кирәк, шушы кануннар, технологияләр белән эш итә белүче оратор аралашу белән идарә итә ала, һәм үз карашларының кабул ителүенә ирешә.

Башлап чыгыш ясаучылар, пафос һәм логос пропорцияләренә ия булгач, пафосның сөйләмгә тәңгәл рәвешен – образын тудырырга өйрәнәләр: чыгышлары кабул ителерлек, хупланырлык, карашлары белән килешерлек аралашу мөмкинлегенә ия булалар.

## Тыңлаучыларны чыгыш ясаучы карашларына җәлеп итү

Иң заманча онтология (дөньяга караш) аңлатуынча, аралашу безне чолгап алган әйләнә-тирәнең бер өлеше булган сөйләүче һәм тыңлаучыларның үзара йогынтысы ул. Бу тирәлекне төрлечә аңлатырга була. Мисал өчен, куллар һәм йөз хәрәкәте яки караш белән, ягъни вербаль булмаган тәэсир итүдән аермалы буларак, халык белән аралашуны вербаль – билге-тамгалар, сүз белән мәгълүмат алмашуы итеп аңларга була. Шул ук аралашуны, дискурслы җәмгыять оешмасы төзү алымы булдыру дип тә аңларга мөмкин. Аралашуны мәдәни-сәяси тәэсир итешүнең нык әһәмиятле өлеше, берләшмә җитәкчеләренең түбәндәгеләр белән үзләренчә идарә итү рәвеше, тәэсир итешүнең субъект-объект бәйләнеше һ.б. аңлатырга була. Тел чаралары, сөйләм үрнәкләре күзлегеннән караганда, халык белән аралашу, телнең тамгалы үрнәкләрен кулланып, тормыш чынбарлыгын оештыру ул. Югары дәрәҗәдәге шәхси кичерешләр күзлегеннән чыгып бәяләгәндә, аралашу – “психик” егәрлек туплау, хисләр тапшыру һәм үзләштерү, ә тулаем караганда, аралашу – сөйләүче һәм тыңлаучыларны да чолгап алган тәэсирчәнлек кыры (рухи тирбәнешләр кыры) булдыру ул.

Теләсә кайсы очракта гражданлык төрендә чыгыш ясаучының төп максаты (буйсынучанлык үрнәген “җиңеләйтелгән” аерым очрак дип аңлап, киләчәктә максатны тормышка ашыруның буйсынучанлык эчтәлегенә мөрәҗәгать иткәндә махсус тукталырбыз) аралашуның “рухи тирбәнешле” – тәэсирле киңлеген булдырудан гыйбарәт. Тәэсирле, йогынтылы киңлек системадагы барлык элементлар омтылышы туры килүгә нигезләнә һәм аерым шәхесләрнең рухи егәре берләшүе хисабына, үзара тәэсир итешү көчәнешенең артуына китерә. Буйсынучанлыкка корылган аралашуда тыңлаучылар энергиясенең бер өлешен киметү күзәтелә.

Шул рәвешле, чыгыш ясаучының тыңлаучыларын үз карашларына күндерү максаты төрлечә хәл ителергә мөмкин, ләкин теләсә нинди очракта хәл ителергә тиеш. Сөйләүченең тыңлаучыларга тәэсир итәрлек һәм теге яки бу халык алдында ясалган чыгышларны аңлату-төшендерүгә бәйле рәвештә гамәли көч тудырырлык мөмкинлекләре турында сүз йөртергә була. Мисал өчен, аралашуның мәгълүмат алмашу икәнен аңлап, сөйләүче игътибарын чыгышы сыйфатына һәм күләменә юнәлдерә. “Тыңлаучыларның, үз карашларыгызга кушылуына ирешү өчен, нәрсә эшләргә кирәк?” – дигән сораугa, бер генә җавап бар: ”Кызыксындырырга,” – дибез.

Мондый җавап түбәндәге нәтиҗә ясарга мөмкинлек бирә: безнең белем бирү һәм тәрбияләү традицияләре, яшьләрдә, аралашуның буйсынучан үрнәген формалаштыра, ә дөресрәге формалаштырырга тырыша.

Әлеге очракта ачыктан-ачык аралашу мөмкинлеге булып мәгълүмат алмашу тора, ә ул бик түбән дәрәҗәдә аралашу. Андый аралашу мөмкинчелеге аерым очракларда гына карашлар берләшүне тәэмин итә ала. Калган барлык чыганаклар, андый аралашу вакытында я яшерен, я гамьсез рәвештә, өстән-өстән генә атала. Шуңа күрә Россия аралашу тәҗрибәсендә, бигрәк тә ул рәсми аралашу булганда, халык алдындагы чыгышларда шундый мөмкинлекләрдән файдаланыла: тәртип урнаштыру, буйсындыру, кабул ителгәнчә фикерләү, алдашу чаралары һ. б. Мөмкинлекләрне исәпләгәндә, иң әйбәт аралашу чарасы – харизматик (пәйгамбәрләр, юлбашчылар, әйдәп баручылар) аралашуы. Әйдәп баручанлык атаклы кешеләрнең генә көченнән килә, ул сөйләүченең көчле рухи энергиясенә нигезләнгән осталыгында чагыла. Харизмалы чыгыш ясаучы күп төрле аралашу мөмкинлекләрен кулланып, тыңлаучыларын югары киеренкелеккә җиткерә: игътибарларын яулап, ихтыярларын да үзенә буйсындырырга мөмкин. Харизмалы аралашу тәэсирен бер тапкыр гына булса да тойган кеше, бу хакта гомере буе онытмаска мөмкин.

Без нәтиҗә ясап шуны әйтә алабыз: тыңлаучыларның ораторлар белән берләшүендә төп шарт булып ораторның рухи егәрлегенә тәңгәл дәрәҗәдә тыңлаучыларның да мөмкинлекләре кушылу тора.

## Аралашуның нигезе буларак оратор фикере, карашлары

Оратор фикерен, карашларын мәдәни аралашу барышының мөһим өлеше дип санарга мөмкин. Чыгыш ясаучы фикере, карашлары гомуми мәдәни кагыйдәләргә буйсына, билгеле бер югарылыктагы нәтиҗәле аралашуны булдыра. Чыгышны әзерләү барышында һәм оратор образын тагын да киңрәк яссылыкта күзәткәндә ораторның үз карашын булдыруы алга куелган максатларын тормышка ашыруда төп мәсьәлә булып тора.

Оратор фикере дигәндә, бер яктан караганда, ул билгеле бер аралашу рәвешенең кирәкле калыбы һәм нигезе булып тора дияргә мөмкин. Икенче яктан, карашның аныклыгын билгеләп үтәргә кирәк, чөнки ул оратор кулланган чыганакларның җитәрлек булуына һәм әлеге карашны оештыру ысулына бәйле. Аралашу катлаулырак булган саен, караш та төгәлрәк; берләшмә мәгънәле максат һәм катнашучылар үз теләкләре белән оешкан очракта, чыгыштагы фикерләр дә аныграк була. Чыгыштагы фикер дигәндә, ораторның, тыңлаучылары теләкләрен үтәү йөзеннән, мәгънәви-мәгълүмати чыганаклар җыелмасы ярдәмендә белдерелгән иҗтимагый-мәдәни тәкъдиме дип аңларга кирәк.

Шул рәвешчә, фикер-караш мәгънәви-мәгълүмати чыганаклар җыелмасы, аралашу барышында чыгышның төп фикерләрен чагылдырган өлешләр җыелмасы була. Оратор фикере әйтелгәннәрнең соңгы сөземтәсе рәвешендә белдерелергә мөмкин. Шул ук вакытта оратор фикерен сөйләм чаралары белән генә чагылдырып бетерә алмый, аның эчтәлеге вербаль булмаган (тәэсир итү көченә бәйле рәвештә) ысуллар белән дә белдерелә. Фикерне соңгы нәтиҗә рәвешендә сурәтләп, әйтеп бетереп тә булмый, чөнки ул шәхси абруй көче рәвешендә кешеләр арасындагы үзара мөнәсәбәтләрнең югарырак баскычларына күтәрелә, күптөрле максатларга ярашкан аралашу кыры оештыра. Шуңа күрә камиллеккә ирешкән ораторлар “сихергә ия”, “гипнозлый алучы”, “гадәттән тыш” дигән тасвирламалар ала. Моннан чыгып, ораторның рухи үсеше – катлаулы, вакыт белән чикләнмәгән күренеш. Ул үз эченә тыңлаучыларга нәтиҗәлерәк тәэсир итәргә мөмкинлек бирә торган гадиләштерелгән махсус алымнарны берләштерә ала. Шул ук вакытта, ораторның киләчәк хезмәте аңа үзенең сәләтен, шәхси абруен үстерергә мөмкинлек бирә.

Уртакул оратор фикеренең төзелешен карыйк. Фикер-караш өлешләренә түбәндәгеләрне кертергә мөмкин:

- чыгышның төп фикерләрен бәян итү;
- чыгыш эчтәлеге кысаларында төп фикерләрнең шәхсән һәм берләшмә өчен әһәмиятен аңлату;
- төп фикерләргә шәхси бәя;
- тәкъдим ителгән эчтәлекнең мәгънәлелеге;
- төп фикерләрне тормышка ашыру өчен (ашыру барышында) дәлилләнгән оештыру алымнарын тәкъдим итүе;
- тыңлаучылар фикерен оештыруда, дәлилле нигез рәвешендә, үз фикерен тәкъдим итүе өчен җаваплылыгы.

Оратор фикеренең мондый рәвеше, берләшмә мәнфәгатьләреннән чыгып, тезисны нәтиҗәле оештыруы дигән сүз. Оратор фикеренең абруй дәрәҗәсендә оешкан рәвеше аралашу эчтәлегенең тыңлаучылар фикеренә шәхси йогынтысы белән билгеләнә. Фикернең тәэсире көчәю ораторның тыңлаучыларга йогынтысы һәм берләшмә язмышы өчен җаваплылыгын арттыра.

Алда әйтелгәнчә, оратор фикере сөйләмдә һәм аның нәтиҗәсендә турыдан-туры һәм, шулай ук, читләтеп тормышка ашырыла. Ярылып яткан анык фикер текстта яки чыгыш эчтәлегендә эзлекле мәгънәви-гамәли фикерләү белән белдерелгән теләктәшлек яки каршылык булырга мөмкин. Чыгышка читләтелгән тәэсир сөйләм яки сүзсез үтә торган чыганаклар аша тормышка ашырыла.

Ораторның гражданлык яки килешүчәнлек карашлары авторитар, ягъни буйсынучан аралашу үрнәген барлыкка китерә ала.

Авторитар үрнәк эчтәлекне хәбәр итүгә нигезләнгән. Чыгышының эчтәлеген оратор үз фикерен берләшмә җитәкчелеге фикеренә иярү юлы белән барлыкка китерә. Аралашуның авторитар үрнәген оештыру ысулы – бер фикердә булу, ул оратор һәм берләшмә әгъзаларның җаваплылыгын җитәкче фикере белән бергәлектә булдыра.

Килешүчән үрнәк аралашу алымнарын оештыру нигезе буларак, өстенлеген күрсәтә. Оратор килешүчән, плюралистик аралашу барышында үзен иркенрәк хис итә, үз карашының эчтәлеге өчен шәхсән җавап бирә.

Аралашу оештыру алымы буларак – плюрализм, бу вакытта үзара яраклаша торган күптөрле карашлар белдерү алымы. Әлеге тип аралашуны оештыру күп хезмәт, рухи егәрлек таләп итә.

## Чыгышның кыскача чагылышы

Текстның һәм чыгышның иң мөһим кисәге – тезис. Анда тыңлаучыларга җиткерәсе төп фикер чагыла. Бөтен яктан да эшкәртелгән тезис сөйләүче белән тыңлаучылар арасында аралашуны оештыруда бик әһәмиятле.

Гадәттә, тезис дип дәлилләнгән, тыңлаучыларның килешүенә ирешү максатына яраклаштырылган төп фикерне чагылдырган текст (сөйләм) кисәген атыйлар. Элек, антик чорда, риториканы "риторик дәлилләү" фәне дип тә караганнар. Хәзерге вакытта, аны, сирәк кенә булса да, "дәлилләр төзелеше турындагы" фән дип карыйлар, ягъни аның хәзерге мәгънәсендә тезисның оешуы һәм эшкәртелүе ята. Тыңлаучыларга билгеле нәрсәләр турында хәбәр иткәндә фикерне гадәти сөйләм чаралары белән әйтеп китү дә җитә. Белем бирү өлкәсендә тезисларны сөйләүче тыңлаучыларга җиткерергә тиешле төп фикерләр җыелмасы итеп тә карыйлар. Ораторлык сәнгате белән шөгыльләнә башлаганда, тезис төзелешен тикшерү, ягъни түбәндәге сорауларга җавап биреп карау да файдалы: мин тыңлаучыларга нәрсә әйтергә телим? Нәрсәгә инандырырга омтылам? Тезистан шушы сорауларга төгәл җавап таба алу, чыгышларның максатчанлыгын, эчтәлекле һәм мәгънәле икәнен таныта. Әгәр дә ышанычлы җаваплар булмаса, я алар күп булса, тезисның оратор карашларын өлешчә чагылдыруын, я тезисның төп карашларга туры килмәвен күрсәтә. Тезиска нәрсә булса да җитмәсә яки артыгы белән тулыландырып җибәрсәк, чыгышның төп мәгънәсе, акыллы фикерләре сөйләм барышында югалып калырга мөмкин. Тыңлаучыларның оратор сөйләме эчтәлеген һәм аның карашларын аңламаулары да бар.

Мәгънәви яктан караганда, тезис ниндидер бер фикер әйтү. Чын һәм ялган фикер булырга мөмкин. Шуңа күрә тезис дәлилләүгә мохтаҗ. Тезисның дөреслеген раслау төрле исбатланган мисаллар, дәлилләр китерү нигезендә барлыкка килә. Хәзерге фәндә тезисның дөреслеген исбатлауны "Дәлилләр теориясе" өйрәнә. Чыгыш ясаучының төп бурычы: тыңлаучыга дөрес фикер җиткерү. Әгәр тезис дәлилләнгән булса, аның хаклыгына шик калмый.

Тезиска таләпләр:

- мәгънәви ачыкланган булу;
- сөйләм эчтәлеге һәм оратор фикер-карашларының дәлилләү барышында тезис эчтәлегенә тәңгәл булуы;
- сөйләүче һәм тыңлаучы тарафыннан тезисның аңланырлык булуы.

Тезисларны кара-каршы сөйләшү рәвешендә тикшергәндә дәлилләүчеләр күбрәк тә булырга мөмкин. Бу очракта ул билгеле бер килешүгә алып килә.

Аралашу авыррак очракта тезислар шарт һәм нәтиҗә канунына нигезләнеп төзелә. Мисаллар чыгыш эчтәлеген генә ачыклап калмыйча, тулаем аралашуның мәгънәсенә төгәллек тә өстиләр. Мәгънәсе ягыннан тезис – турыдан-туры текстта яки чыгышта чагылыш тапкан мөстәкыйль бер фикер. Ул чыгышның бөтен эчтәлеген чагылдырырга һәм ачыктан-ачык яки сиздермичә генә ораторның карашларын һәм сөйләмен ныгытырга тиеш.

## Танып белүне оештыруда оратор карашларының әһәмияте

Күп тыңлаучыларга без оештырган тезис ябык һәм яшерен кодлы символ рәвешендә булырга мөмкин. Эчтәлек белән тулыландырылмаган очракта символ ябык була, тыңлаучылар аның эчтәлеген кабул итә алмыйлар, тезис аудиторияне кызыксындырмый, җанландырмый. Әлеге хәл сораулар тудыра: “Бездән тыңлаучылар ни телиләр? Болар барысы безгә (тыңлаучыларга) нигә кирәк?” Бу аралашуда төп карашлар үзләренә хуплау тапмый, аларга кушылучы булмый. Тыңлаучыларны теләктәшлеккә әзерләү максатында, тезисны символик яктан төрле алымнар, чаралар ярдәмендә аңлаешлы итәргә кирәк. Танып белү өчен әһәмиятле мөмкинлекләрне карап үтик. Аларның төп юнәлеше – тыңлаучылар өчен чыганаклар белән тезис эчтәлеген туры китерү. Алдагы сүзебездә без ораторның карашларын, мөнәсәбәтләрен, оештыру өлешләрен тикшереп уздык. Аларга технология мәсьәләләрен кертеп карыйлар. Алар тезисларны аңлатып бирә торган мөмкинлекләр:

- ораторның шәхсән һәм берләшмә күзлегеннән тезиска мөнәсәбәте;
- ораторның тезисның эчтәлеген аңлавы;
- оратор аңлатуында эчтәлекнең тыңлаучыларга тәэсире.

Танып белү барышында теләсә нинди тезис аңлатылырга тиеш. Буйсынучан даирәдә аңлату башкалар исеменнән алдан әзерләнгәнчә башкарыла. Моңа дини эчтәлектәге чыгышлар, түрәләр ихтыяры да, фәнни ачышлар, басма чыганаклар да керә. Гражданлык рухындагы аралашу мөмкин булган барлык чыганакларга нигезләнә, ахырдан фикерләр үзгәрергә дә мөмкин. Үзенең карашларын билгеләү өчен, ораторга тезис эчтәлеген конкретлаштырырга туры килә. Әлеге күрсәтмә берничә гамәл нигезендә тормышка ашырыла. Тезисның берләшмә исеменнән тәкъдим ителгән эчтәлеге ораторның үз фикерен дә берләштерә. Бу очракта ул тыңлаучыларының танып белү максатын да истә тота, танып белү халәте тезис һәм чыгыш ясаучының үз фикере дәрәҗәсендә яңгырый.

Күп кенә башлап чыгыш ясаучылар тезисны һәм карашларын эшкәртелеп бетмәгән эчтәлек ярдәмендә барлыкка китерергә тырышалар. Алар читтән алынган тезисны үзләренеке итеп күрсәтә һәм аның дөреслегенә шик белдерми: бу карашлар өчен җаваплылыкны үз өстенә алмый, чөнки күңеленнән аларга ышанмый.

Тезиста оратор эчтәлеккә шәхсән мөнәсәбәтен белдерә. Оратор эчтәлекне үз тәҗрибәсенә тәңгәлләштерә, эчке күзаллавы һәм мәдәни карашлары белән туры китерә. Бу аспектның риторик әһәмияте шунда, оратор чыгыш вакытында эчтәлек белән үзен тәңгәлләштереп карый һәм үз карашларында нык торуын тыңлаучыларга ачык күрсәтә.

Тыңлаучыларга тезис эчтәлегенең мәгънәсен ачыклау, алда күрсәтелгән үрнәк нигезендә үтәлсә, ораторның тәэсир дәрәҗәсе тагын да көчәя. Тезисны болай ачыклап бирү гамәл үтәүгә әзерлек булып тора. Оратор белән тыңлаучылар арасында ихтирам, итагатьлелек сакланганда гына әлеге алым карашларның оешуына китерә. Бу таләпләр үтәлмәгәндә, тезисны аңлату үз карашларыңны көчләп тагу алымына әйләнә, тыңлаучыларда ризасызлык тууга сәбәп була.

Тезисны эшкәртүнең шәхсән тәңгәлләштерү алымы оратор карашларының йогынтылыгын көчәйтә. Төгәл һәм аңлаешлы тезис аралашуда ораторның үзенә һәм карашларына ышанычны арттыра.

### ***Оратор карашының шәхси-гамәли өлешләре***

Бик яхшы әзерлекле, әмма аралашуда бары танып белүне, белем бирүне генә максат итеп куйган оратор, тыңлаучыларында үз карашларына хуплау тудыра алмый. Үз карашлары тәэсирен көчәйтергә теләгән ораторның вазифасы аерым фикерләрне ассызыклаудан, тезиска үзенең мөнәсәбәтен аерып билгеләүдән һәм тыңлаучыларга билгеле бер карашын үзләштерергә тәкъдим итүдән гыйбарәт. Бу яктан караганда аралашу оратор карашларының тыңлаучыларга күчүен аңлата. Өстәвенә бу очрак сүздән эшчәнлеккә күчү рәвешендә, ул мәгълүмат алмашу чикләреннән чыга һәм көнкүрештә гамәлләшү рәвешен үзләштерә. Тезис оештыруда сүз белән гамәлне кушу, иң кимендә, ике аспекттан тора: теләк уяту-оештыру мизгеленнән һәм ораторның тәкъдимнәре өчен җаваплылыгын сиздереп куюдан. Күргәнебезчә, оратор әлеге очракта, алым-ысуллар тәкъдим итеп чыгыш ясый, сөйләм эчтәлеге танып белү эшчәнлеге белән туры килә. Тоталитаризм һәм псевдодемократия шартларындагы буйсынучан аралашуда чыгыш ясаучы үз исеменнән түгел, җәмгыять, берләшмә исеменнән сөйләгән кебек тәэсир тудыра. Бу аралашу рәвешендә халык алдында үткән чыгыш гомуми зарурият булып кабул ителә, аерым шәхес, кешеләр сәяси-иҗтимагый система белән тәңгәлләштереләләр. Димәк, тыңлаучылар ораторның карашларын кире кагып, буйсынучанлык тибындагы аралашуда кабул ителгән үрнәкләр буенча фикер йөртәчәкләр. Аларның чыгыш эчтәлегенә булган мөнәсәбәтләрен, кабул ителгән гомуми бәяләрне оратор шәхесенә "күчереп" куюлары бик ихтимал.

Гражданлык тибындагы аралашуда чыгыш ясаучы эчтәлекне шәхси яссылыкта, үзенеке итеп тәкъдим итә. Бу очракта чыгыш ясаучы үз фикерләре, үзенең берләшмәсе карашлары белән тәңгәлләштерелә. Иҗтимагый дәрәҗәсенә карап, чыгыш ясаучының карашларында шәхсәнлек төрлечә була, университет укытучысы карашы кафедра мөдире карашыннан, ректорныкы декан фикереннән аерылган кебек. Фаразлап карасак, бер үк темага чыгыш ясаучы төрле шәхесләрнең карашлары төрлечә бәяләнә дә. Икенчерәк итеп әйтсәк, гражданлык аралашуында оратор нәтиҗәдә үзе булдырырдай, үзе тормышка ашырырдай гамәл тәкъдим итә. Оратор карашлары аның шәхсән компетенциясе белән туры килергә тиеш. Ул тыңлаучыларына юнәлтелгән өндәмәсендә үзенең гражданлык мөстәкыйльлегенә таянып эш итә.

Үз карашларының, мәнфәгатьләренең өстенлегенә омтылганда оратор нигезсез вәгъдәләр, алдау-йолдау алымнары белән эш итә, фикер-карашларының эчтәлегенә үзенең һәм тыңлаучыларының шәхсән мөнәсәбәтен, фаразларын белдермәскә, белдертмәскә тырыша. Бу уңайдан депутатлыкка кандидатларның күпчелек чыгышларын мисал итеп китерергә мөмкин һәм, әйтергә кирәк, буйсынучанлыкка корылган аралашуда карашларны бу рәвешле оештыру уңышка алып килә, тик тәнкыйтьтән башкага лаек була алмый.

## Оештыруның гражданлык тибында оратор карашына кушылу

Тыңлаучылар алдында чыгышның төп максатын ачыклауга нәтиҗә ясап, шуны әйтергә була. Мәгълүмати кыр оештыруның гражданлык тибы кануннары белән оештырылган чыгыш ораторның үз карашларын тормышка ашыруы була һәм тыңлаучыларның аралашу ихтыяҗларын канәгатьләндерә. Оратор үзенең мөмкинлекләре һәм тыңлаучыларның таләпләренә җавап бирерлек халәт булдыра. Аралашу барышында ул үзенең фикерләрен аралашу оешырлык һәм тыңлаучылар үзләштерерлек итеп төзи. Ораторның үз карашларын тормышка ашырырга омтылуы һәм тыңлаучыларның аралашудагы фикерләрне үзләштерүләре берьюлы уза. Оратор үзенең фикерләрен ачып бирә, ә тыңлаучылар ул карашларны үзләренекенә әверелдерә, аны аралашу даирәсе фикерләренә тиңләштерә.

Шул рәвешчә, аралашуның төп максаты – тыңлаучыларны оратор карашларына якынайту – ике халәтне (пафос һәм этос) тиңләштерү мөмкинлегеннән килеп чыга. Ораторның карашлары, әгәр дә аларга мөнәсәбәте (пафос) исбатланган, җаенке тезиска нигезләнгән, һәм шәхси фикерләренә туры килгәндә генә, тиешле дәрәҗәдә дип исәпләнә. Бу карашлар тыңлаучылар кабул итәрлек итеп уйланылган вакытта гына, аларның аралашуга кушылып китү һәм оратор тарафыннан танып белүгә карата тудырылган омтылышны (этос) тормышка ашыру мөмкинлеген бирә.

Нәтиҗәдә без аралашу даирәсендә бер үк дәрәҗәдә, тигез хокуклы аңлашуга ирешәбез. Ораторның үз фикеренә ияртүе сөйләм аша тыңлаучыларның танып белүләрен һәм теләк-омтылышларын рухи байлыкка әйләндерү дигән сүз. Үзләштерелгән мөмкинчелекләр, үз чиратында, тыңлаучыларны

әлеге берләшмәдә мөстәкыйль оештыручыларга әверелдерү шарты да булып тора.

Югарыда әйтелгәнчә, плюрализм гражданлык рухындагы аралашу даирәсен оештыруда төп принцип. Бу ысул аралашуның теләсә кайсы мизгелендә күп төрле карашлар булуны күз алдында тота; шунлыктан аралашу нәтиҗәсенең бердәмлеге мәсьәләсен хәл итәргә кирәк була.

Чынлыкта, плюрализм, аралашуның соңгы вариантында да җыелма фикерләр булуны кире какмый. Шул ук вакытта, тыңлаучыларны оратор карашларына күндерү ихтыяҗы, киңрәк планда алсак, эшчәнлекне оештыруда фикерләр бердәмлеге – плюрализмга каршы килә. Ни хәл итмәк, бу мәсьәлә, әлегә, дөньякүләм аралашу практикасында чишелмәгән килеш кала.

Аралашуның әлеге этабында плюрализм каршылыгы авторитар (берләшмә җитәкчесе теге яки бу карашларга кушылуны тәэмин итә); демократик юл (берләшмәдә тәкъдим ителгән фикергә күпчелекнең ризалыгы белән кушылу) яки консенсус (килешү барлык аралашучыларның ризалыгы белән башкарыла) белән тормышка ашырыла.

Хәзерге геополитик яки башка берәр берләшмәнең оешу рәвеше әлеге аралашуның принципиаль хәл ителүенә бәйле.

## Оратор образы

Оратор үзенең эшчәнлегендә, гадәттә, бер генә түгел, ә берничә караш, фикер тәкъдим итә. Ораторның карашлары арту аның үз шәхесен «рольләре» белән якынлаштыруга яки билгеле бер чыгыш ясау стиле һәм шәхси манерасы барлыкка килүгә сәбәп була. Аралашу стиле дигәндә без мөмкинчелекләр җыелмасын күздә тотабыз. Алар төрле тыңлаучыларның ораторның күптөрле фикер-карашларына кушылуын тәэмин итә. Ораторның карашлар җыелмасы күбәйгән саен, аның образы да күпкырлы һәм югары һөнәри дәрәҗәдә була бара.

Оештыру мөнәсәбәтләреннән чыгып караганда, оратор образының мөмкинлекләре төрле ысул һәм чаралардан төзелә, шулар ярдәмендә образ иясе үз аралашу халәтен барлыкка китереп, тыңлаучыларга да тәкъдим итә. Аралашуда алым-ысуллар бер-берсенә шактый якын. Күп очракта аларны аеру бик кыен. Аралашу барышын тулаем эшчәнлек итеп карасак, алар бер-берсенә күчәләр, бер-берсенә әвереләләр. Шуңа күрә дә сөйләм мөмкинлекләренең

оештыру чарасы һәм аралашу төрләренә аерылуын истә тотарга кирәк. Аларның төп аермасы шунда: оештыру мөмкинчелекләре гомуми, ә аралашу төре – ситуациягә бәйле һәм конкрет була. Шуңа күрә оратор образында аралашу шартларын барлыкка китерә торган мөмкинлекләр җыелмасы күз уңаенда тотыла.

Оратор образы нинди кыйммәтләрдән оеша соң? Тыңлаучылар оратор фикеренә кушылсын өчен аңа нәрсә эшләргә кирәк? Аралашу кешеләр эшчәнлегендә иң авыр, кушылма эшчәнлек, шуңа күрә аралашу киңлеге мөмкинлекләренә кешенең барлык казанышларын да кертергә мөмкин. Кеше сыйфатларының кайберләре аралашуда җитәрлек дәрәҗәдә аерымлана һәм турыдан-туры ярдәм итә, башкалары аңсыз рәвештә тәэсир итә. Аралашу шартларының һәм мөмкинлекләр-нең бер төрләре кешенең эшчәнлегендә һәм алымысуларында тупланган, ә икенчеләре кирәге чыккач кына кулланыла. Уңышлы аралашу шартларының күп өлеше кешеләрнең табигый рәвештә оешканлыкларыннан, ә тагы да тупланган өлеше дөньяга карашыннан һәм мәдәни үрнәкләр, кыйммәтләр эчтәлегеннән тора. Аралашу даирәсе элементларының күптөрлелеге аралашу мөмкинлекләрен киңәйтә, шул ук вакытта, бик күп кыенлыклар тудыра, чөнки күптөрле мөмкинлекләр арасыннан кирәклесен сайлап алу җиңел түгел. Аралашу мөмкинлекләрен төркемләү (классификацияләү) тагын да катлаулырак, чөнки әлеге төшенчәнең бүленү нигезен табуы авыр.

Мәсьәләне җиңеләйтер өчен без мөмкинлекләрне ике төркемгә: табигый һәм технология мөмкинлекләренә бүләбез. Табигый мөмкинлекләргә кешенең махсус күнектерелмәгән сыйфатларын, нәтиҗәле аралашырга ярдәм итә торган мөмкинлекләрен кертәбез. Махсус әзерлек һәм эшчәнлек барышында үстерелгән нәтиҗәле аралашу алымнары, бу очракта, технология мөмкинлекләрен тәшкил итә.

Әгәр дә оратор образын без аның карашларын һәм чыгыш ясау барышында тыңлаучыларын үз фикеренә ияртүне тәэмин итә торган алымнарга тәңгәлләштереп карасак, ул вакытта алымчаралар үзләштерүне, технологиядә камилләшүне дә образ барлыкка китерү дип аңлатырга мөмкин. Ораторлар әзерләүне ике этапка бүлү уңышлы булыр иде: башлангыч һәм югары һөнәри этап. Башлангыч этап минималь күнекмәләр булдырудан гыйбарәт. Алар җәмәгатьчелек белән аралашуны тормышка ашыруда ярдәм итә, һәм билгеле бер шартларда тыңлаучыларның оратор карашларына

кушылуын тормышка ашыра. Үз чиратында, һөнәри югарылыктагы оратор образы аралашучының карашларын тәртипкә салырлык һәм, шул карашларга карата билгеле бер ихтыяҗ буенча берләшкән тыңлаучыларны тәэмин итәрлек мөмкинлекләрдән оеша.

Оратор һөнәри үсеш дәрәҗәсенең иң югары баскычы булып аның рухи җитәкче дәрәҗәсенә күтәрелүе тора. Ул теләсә нинди аудиторияне оештыру мөмкинлеген бирә һәм, моннан тыш, тыңлаучыларын мәдәни кыйммәтләр иҗат итү сәләтенә күтәрә ала.

Әлегә кадәр кешеләрнең бер-берсенә рухи тәэсиренең табигате ачыкланмаган. Кайбер авторлар харизматик сәләтне суггестия үсеше (сүзсез тәэсир итү сәләте), икенчеләре – рухи көч субъектларының мәдәни өстенлеге, өченчеләре – тәэсирчәнлек (энергетизм) дәрәҗәсенең артуы, дүртенчеләре – аңнан өстен үсеш сыйфатлары һәм башка нәрсәләр белән бәйлиләр.

Риторик максатлардан әлеге мәсьәләне түбәндәгечә ачыклап була: ораторның башкаларны әйдәп барырлык рухи көче тумыштан килгән сыйфатмы, әллә инде ул тәрбия һәм белем алу нәтиҗәсендә барлыкка киләме?

Хәзерге заман белгечләренең кайберләре рухи көч сәләтен үстерергә мөмкин дип уйлыйлар. Шул сәбәпле үз образының тыңлаучыга ныклы тәэсире турында кызыксынучы ораторларны өйрәтә торган алым, чаралар барлыкка килә.

Сәяси лидерлар, зур берләшмә җитәкчеләре төрле эшчәнлекне оештыручылар, хокук һәм мәгариф өлкәләре вәкилләренә һ.б ораторларның көчле рух − юлбашчы дәрәҗәсендә аралашу мөмкинлекләренә мохтаҗ булуларын исбатлап торырга кирәкми.

## Ораторның чыгышка әзерлеге

Ораторның алдан әзерләнү максаты булып, яхшы аралаша алу сәләтенә − аралашуның нәтиҗәлегенә − тыңлаучыларны үзенең фикеренә инандыра, ияртә алу − ирешү тора. Яшь кешедә аралашу дәрәҗәсе түбән була. Тыңлаучыларны үз фикеренә ияртү өчен, ул чыгышына яхшы әзерләнергә, үзен уңай хис итәргә, илһамланып сөйләргә, үзенә “яхшылык теләүче” кешеләр алдында чыгыш ясарга тиеш. Шушы ук таләпләрне нык оешкан, көчле аудитория алдында чыгыш ясаганда тәҗрибәле ораторга куярга була. Универсаль, җитәкче дәрәҗәсенә ирешкән оратор гына тыңлаучылар алдында нәтиҗәле чыгыш ясый ала.

Хәзер ораторның әзерләнүендә беренчел үзенчәлекләрне карап үтәрбез. Бу әзерлек ике төп юнәлештән тора: сөйләнергә тиешле материалның әзер булуы һәм сөйләм рәвеше. Беренче карашка ике юнәлеш бер-берсенә кушылып киткән кебек. Тик оратор текстта тәгаенләнгән үз чыгышын тәңгәлләштерергә һәм максатына ирешергә тиеш.

Чыгыш уңышлы, аңлы рәвештә узсын өчен, оратор үз-үзенә төрле сорау биреп карый: “Нәрсә һәм ни өчен сөйләргә?”, “Ничек тормышка ашырырга?”. Беренче сорау аралашу даирәсен максатчан оештыруга, икенчесе – әзерлеккә, сөйләм үзенчәлеген тормышка ашыру ысулына бәйле.

Кыскача тагы шуны әйтергә кирәк, ораторның халык алдында әйтәсе һәрбер сүзе аның мәдәни дәрәҗәсеннән оеша, чыгыш эчтәлегенә ул бик игътибарлы булырга, халык арасында таралган гомум карашка мөнәсәбәт юнәлтергә тиеш. Чыгыш ясаганда ул тыңлаучыларына карата бертигез мөгамәләдә була. Ни өчен шулай? Чөнки аралашу вакытында, сөйләүче һәм тыңлаучылар арасында аңлашу максаты өстенлек итә.

Аралашуда катнашучыларның һәрберсенең үз фикере аралашу даирәсе белән генә чикләнми, әлеге фикер шәхеснең гражданлык халәтенә бәйле була. Шул сәбәпле, чыгышка әзерләнгән кешене (ораторны да) сөйләм, аралашу сәнгатенә өйрәтеп булмый. Бу кешене үзе белмәгән чит телдә, өстәвенә, тыңлаучылар аның чит милләт кешесе икәнен аңламаслык дәрәҗәдә чыгыш ясарга өйрәтү белән бер булыр иде. Бу ни дигән сүз соң? Эш шунда ки, аңлатасы фикеренә кеше иң элек үзе төшенергә тиеш һәм соңыннан, карашларын тәртипкә салып, аларны башкаларга аңлату юлларын, чараларын, мөмкинлекләрен барлап, аларны тормышка ашыра.

Үз карашларыңны тормышка ашыру нияте түбәндәге тәртиптә башкарылырга мөмкин: чыгыш текстын иҗат итү, чыгышка әзерләнү, чыгыш үзе. Бу алгоритмда фикерләрне яңгырату мәсьәләсе катлаулырак. Башлап чыгыш ясаучыга, әзерлек барышында мәдәни үсеш дәрәҗәсен, белем тапшыру мөмкин-лекләрен, аралашу ысул-алымнарын берләштерү сорала. Оратор чыгышында бөтен кешегә таныш мәгълүматны (китап материалын) гына сөйләмичә, үз мөмкинлекләреннән чыгып, фикерен аерымачык яктыртырга тиеш. Ораторның тел һәм сөйләм культурасы югарырак булган саен, аның сөйләме дә шул кадәр аңлаешлы була. Кешенең укымышлылыгы сөйләмендә дә чагыла.

Сөйләүгә караганда аралашу, фикер алмашу авыррак. Аралашу мөмкинлекләренә, күнекмәләренә белем һәм мәдәни байлыкларга ия булмый торып ирешү мөмкин түгел. Шул чакта гына ораторлык сәләте турында сөйләргә була. Ораторга әзерләнү һәм халык алдында ясаган чыгышы турында яхшы фикер калдыру өчен, иң элек үз мөмкинлекләрен дә истән чыгармаска кирәк. Билгеле нәселдән килгән сыйфатлар, тәрбия, мохит, укытучылар, шәхси тырышлык, аралашу тәҗрибәсе чын оратор образын хасил итә. Ныклы, күпъяклы белемле, аралашу алым-ысулларын үзләштергән оратор гына үзен иркен тота. Үзен иркен тойган ораторга аудитория белән сөйләм мөнәсәбәтенә кереп китү җайлы. Аралашу осталыгын камилләштерүдә һәм шәхси йөзеңне булдыруда берничә шарт бар. Беренчедән, аңлы рәвештә аралашырга кирәк. Моның өчен үзеңә сорау биреп карыйсың: «Әлеге сөйләшүдән мин нәрсәгә ирешәм?», «Аралашуда катнашучылар һәм башка тыңлаучылар мине ничек кабул итәр?», «Ни өчен мин аралашу нәтиҗәләреннән канәгать түгел?»

Бу сорауларга җавап эзләгәндә, үзеңне читтән күргән кебек буласың, үзеңнең сөйләмеңә теге яки бу дәрәҗәдә бәя бирә аласың. Үзеңнең аралашу рәвешен тикшергәндә кимчелекләреңне табу, аларны чишү юлларын билгеләү дә ансатрак. Ахырдан яңа сораулар барлыкка киләчәк: «Мин үз аралашуымның нәтиҗәсен яхшырту өчен нинди мөмкинлекләрдән файдалана алам?», «Шәхсән образымны ничек үзгәртергә?», «Фикерләремне аудитория хупласын өчен нәрсә эшләргә була?» Табылган җавапларны махсус алым-ысуллар белән ныгытырга, күнекмә дәрәҗәсенә җиткерергә кирәк. Тырышып чыгышлар ясап тәҗрибә туплау – көтелгән нәтиҗәләрне соңартмый.

## Оялчанлыкны җиңү мәсьәләсе һәм аралашуның нәтиҗәлеген арттыру

Башлап чыгыш ясаучының аралашуына комачаулый торган җитди сәбәпләрнең берсе булып, тыңлаучылар алдында каушау, яки халык белән аралашудан бөтенләй курку тора. Бик күп кешеләрне бу ялган оялчанлык шул дәрәҗәгә җиткерә ки, алар үз мөмкинлекләрен тулысынча кулланмыйлар һәм сүзләр ярдәмендә тыңлаучылардан “читләшергә” тырышып аралашалар. Әлбәттә, мондый аралашу юнәлешендә чыгыш ясаучының карашы ачылу урынына яшерелә, ә тыңлаучылар анык фикерләргә кушылу

урынына әлеге фикерләрне тапшыручының оялчанлыгын «кичерү» гамәлен үтиләр. Әлеге иҗтимагый-психологик халәтне тикшерү өчен башта аны буйсынучанлык яки гражданлык күзлегеннән аныклап бирергә кирәк. Аралашуның буйсынучанлык төре «оялчанлык» үрнәгенең субъект-объект мөнәсәбәтен оештыру нигезе булып тора: оештыручы-активистлар сөйли, ә калганнар аны тыңлый. Җитәкче сорау биргәч, «сорау алыну»чылар җавап бирергә мәҗбүрләр. Әлеге аралашу стереотибы теләсә нинди авторитар мөнәсәбәтләргә хас. Мондый аралашу рәвешендә булганда оялчанлык калган катнашучылар белән идарә итәргә мөмкинлек бирә торган табигый сәбәп булып тора. Мәсәлән, безнең илдә яшәүче халыкның күбесенә мөстәкыйль һәм билгеләнеп куелган аралашу төрләренең аермасы яхшы таныш: тиешле иҗтимагый рольләрне үтәү таләп ителгән очракларда алар шактый табигый аралашалар һәм иң гади хәлләрдә, хәтта үз ихтыяҗлары, теләкләре буенча аралашканда да, нык каушап калалар.

Д.Карнеги бу проблеманы тикшереп, көнбатыш мәдәнияте вәкилләрен, күбесенчә, эшчәнлекләренең нинди нәтиҗәгә китерүе борчый дигән фикергә килә. Мөгаен, бөтен кешеләр дә тыңлаучылары алдында каушыйдыр. Гражданлык карашларыннан чыгып аралашучы үз статусын аңлы рәвештә ныгыта һәм үз карашларына оптимистик мөнәсәбәт оештыра.

Әгәр без буйсынучанлык үрнәгендә булсак, тыңлаучылар белән идарә итә алмаслык оялчанлык стереотибына буйсынганбыз икән, әлеге үрнәктән гражданлык калыбына күчү оялчанлыкны җиңү исәбенә үтәлергә мөмкин. Гражданлык үрнәге Россия шартларындагы демократик реформа чорында теләсә кайсы ораторга аңлаешлы. Аның буйсынучанлык тибыннан тышкы аермасы халык алдында чыгыш ясаучы кешенең үз статусын үзгәртүдән гыйбарәт. Буйсынучанлык юнәлешендәге оратор үзен берләшмәдән аермый, аның карашларының эчтәлеге берләшмә әгъзаларының карашлары белән тәңгәл килергә тиеш дип уйлый. Ораторның барлык берләшмә фикере белән тәңгәл килгән шәхсән караш оештыру ихтыяҗы барлыкка килә. Әлеге ихтыяҗ җитди каршылыклар китереп чыгара һәм алар тартыну-каушауның төп чыганагына әвереләләр.

Әлбәттә, мондый аралашу стратегиясендә оратор үзенең карашларын ачу урынына, аларны яшерә. Ә тыңлаучылар оратор

карашларына кушылу урынына, аралашу рәвешеннән оялып утыралар.

Ораторның үз дәрәҗәсен үстерергә омтылышы аңа берләшмәдән аермалы шәхсән караш барлыкка китерергә һәм аның эчтәлеге өчен генә җавап бирергә мөмкинлек тудыра. Тулаем берләшмә карашларыннан читләшү, үз статусыңның әһәмиятенә ышану белән тәңгәл килгән очракта, оялчанлык, каушау дәрәҗәсе шактый кими.

Оялчанлыкны җиңү мәсьәләсендә төп фикерләр:

- Оялчанлыкның асылына төшенү;
- Оялчан кешенең холкын үзгәртү максатларын оештыру;
- Куелган максатка ирешү өчен өстәмә кызыксындыру чаралары куллану;
- Үзара аралашуда тиңдәшлек культурасына өйрәтү;
- Төрле вакыйгалар барышында аралашуда «маска» куллану, рольле уен, «сүз уйнату» алымнары белән тыңлаучыларның игътибарын җәлеп итүгә күнектерү;
- Чыгышта уңышка ирешү һәм кыенсынуны җиңү өчен иң отышлы сөйләм рәвешен күнектерү;
- Кыенсынуга сарыф ителәсе егәрлекне чыгышның эмоциональ дәрәҗәсен күтәрү өчен файдалану;
- Һәр ике якны кызыксындырган мәсьәләләр турында сөйләшкәндә, карашлар тапшыруда тырышлык кую;
- Уңайлы аралашуга омтылып, тыңлаучыларның теләкләрен исәпкә алу һәм үзара фикер алмашуда үз иҗади мөмкинлекләреңнән файдалану.

Чыгыш вакытында аудитория белән аралашудан канәгатьләнү һәм рухи көч аласыз икән, үзегезнең максатыгызга ирештегез дигән сүз.

Чыгыш ясаучы тыңлаучыларның карашларын дөрес бәяләмәсә, әңгәмә уңышсыз була. Тыңлаучы белән үзеңне артык иркен тоту да чыгыш ясаучы файдасына түгел. Аралашудагы бу кимчелекне бетерү өчен сөйләүчегә “артык тырышуын” чикләргә кирәк. Тыңлаучыларның чыгыш ясаучыга карашын үзгәртү өчен аларның барысын да кызыксындырган мәсьәләләргә – берләшмә мәнфәгатьләренә тукталырга, тыңлаучы фикерен дә хөрмәт итәргә кирәк.

Дини эчтәлекле аралашуда сөйләм йогынтылыгын арттыру өчен дин әһелләре кешеләрнең белем дәрәҗәсен, мавыгучанлыгын һәм тормыш хәлен исәпкә ала.

## Аралашу мөмкинлекләре сыйфатында шәхес холык-фигылен (темпераментын) файдалану

Халык белән аралашу мөмкинчелекләренә шәхес үзенчәлекләрен турыдан-туры күчереп булмый. Аралашу эчтәлеген тәэмин итү гомуммәдәни һәм һөнәри юнәлешләрдә күзаллана.

Төрле темпераментлы кешегә тасвирланган вакыйгалар төрлечә тәэсир итә. Бу аерымлыкларны халык белән аралашу мөмкинлекләренә әверелдерергә тырышып карыйк.

Билгеле булганча, психик темперамент асылын антик чорда ук белгәннәр. Гадәт буенча, меланхолик, холерик, сангвиник һәм флегматик темпераментларны аерып чыгаралар.

Темпераментны аралашу мөмкинлекләренә әверелдерүдә меланхоликлар белән эш кыенрак. Меланхолик темпераментлы кешеләрнең төп уңай ягы — аларның нечкә күңеллеге, көчле фантазиясе, эчтәлекне образлар ярдәмендә кабул итү сәләте, эмпатиянең (кеше өчен дә кайгыра белү, миһербанлык) иң югары баскычта булуы. Оратор тыңлаучы-меланхоликның эчке дөньясы мәсьәләләрен аңларга, аралашу киңлегендә мөмкинлек итеп куллану рәвешен табарга тиеш. Меланхоликлар кечкенә аудиторияләрдә зәукый эчтәлекле аралашуны җиңел кабул итәләр. Карашларны тапшыру юнәлешендә толерантлык (түземлелек һәм ризалашу) үрнәген куллану уңайрак.

Меланхоликлар өчен аралашуда төп авырлык шуннан гыйбарәт: алар үз шәхесләрен һәм аларга кагылышлы вакыйгаларны депрессив рәвештә аңлатуга һәвәс. Меланхоликларның тотрыксыз, яралана һәм тиз рәнҗи торган психикасы тәртипкә салынган аралашу барышына янау тудыра. Тыңлаучыларның, көтелмәгәндә, агрессив бәя белдерүләре нәтиҗәсендә, меланхолик-ораторларның аралашу ситуациясеннән читләшүе мөмкин. Аралашу мөмкинлеген югалту фаразланганда, оратор тыңлаучыларның тискәре егәрен киметергә һәм үзенең аралашу даирәсен сакларга тиеш. Ахыр чиктә, аралашу эчтәлегенә һәм структурасына куркыныч сиземләнгәндә, меланхоликка аралашуны гадәти тыныч-салмак рәвешкә китереп, чыгышын

дәвам итәргә кирәк. Шулай да меланхолик өчен аралашуның өзелүе бик мөмкин хәл.

### *Ныклы холык-фигыль мөмкинлекләре*

Холериклар белән аралашу гаять катлаулы. Алар – хисчән, кыю, елгыр; артык көчкә, дәрткә ия; фикерләве, сөйләм темпы тиз. Оратор буларак, холерик үзенең мөмкинлеге итеп югары дәрәҗәдәге көчен, дәртен, фикерләү һәм гамәл кылу тизлеген, аудиториянең бәяләренә бирешмәвен, инанганлыгын, гамәл кылуда тәвәккәллеген файдаланырга мөмкин. Оратор-холерик тыңлаучыларның тормышта булган хәлләрен уртаклашырга, шул сәбәптән борчылырга һәм аларга ярдәм итәргә әзер. Ул яхшы күңелле, ихлас, ачык йөзле, әйләнә-тирә йогынтысына буйсынмый. Кеше буларак, холерик бик елгыр, һәрвакыт эшкә керешергә әзер тора.

Бу сыйфатлар фикер-караш булдыруда һәм аларны тыңлаучыларга тапшыруда җиңеллек тудыралар. Холерик-оратор агитатор һәм пропагандалаучы буларак та уңышлы эшләр алып бара. Аның көч-куәтенә каршы килү авыр. Әгәр холерик үз карашларында нык торса һәм үзенең хаклыгына инанган булса, бик көчле һәм нәтиҗәле оратор була.

Холерикның кимчелекләре: сөйләменең тиз булуы, ым-ишарәләрнең ешлыгы, көчле дәртләнүнең тиз сүнүе. Бу күренешләр нәтиҗәле аралашуга комачаулый һәм аралашуның сүлпәнләнүенә китерә. Беренче чиратта холерикка кинәттән кабынып китүен, дәртләнүен һәм бик тиз салмаклануын тигезләргә өйрәнергә кирәк. Холерик үзенең сөйләм тизлеген тикшереп торырга һәм аңлы рәвештә акрынайтырга тиеш, чөнки сөйләм тизлеге һәм тавыш көче белән идарә итә алмавы сәбәпле, тыңлаучылар холерикны аңламаска, икенче төрле кабул итәргә мөмкиннәр. Аңа артык хәрәкәтләр ясаудан да үзен тыеп торырга кирәк, чөнки тыңлаучының бөтен игътибары хәрәкәтләргә күчә һәм сөйләм эчтәлегенә игътибары кими. Холерикларга ачу саклау халәте хас. Аларга дәвамлы аралашу кыен (мәсәлән, укыту). Аларның кызып китүчәнлеге, аралашу халәтен үзгәртүгә омтылуы, энергетик хәле һәм кәефе үзгәрү контрольгә һәм риторик алым-күнекмәләргә мохтаҗ. Тик холериклар үз җитешсезлекләрен танып, үз мөмкинлекләрен үстерү белән шөгыльләнергә яратмыйлар.

Нәтиҗәле аралашуда кулайрак холык-фигыль сангвиникларда, бигрәк тә алар холерик тибына якын булса. Сангвиник темперамент ораторга куәтле булырга, аралашуның күп кенә җитешсезлекләрен киметергә ярдәм итә. Сангвиник үзенең холык сыйфатларын нәтиҗәле аралашу мөмкинлекләре рәвешендә куллана ала, алардан теге яки бу рәвештә үзләренә җәлеп итәрлек үзенчәлекләр булдыру таләп ителә.

Флегматиклар карашларында нык торулары һәм артык пошынмас булулары белән аерылып торалар. Флегматик аралашу вакытында төрледән-төрле мөмкинлекләр куллана, ләкин алар түбән дәрәҗәдә булмасыннар өчен, фикерләвендә салмаклану халәтен бетерү кирәк. Флегматикка үзенең сөйләмен тизләтсә, хәрәкәтләрен арттырса, яшереп торган көч-куәтен аралашуда файдаланса һәм аңлы рәвештә кулланса яхшы була. Флегматик аралашуны акрын, сузып алып баруы белән тыңлаучыларын ялыктыра. Флегматик бу кимчелекләрен көч-куәтен өлешләп-өлешләп файдаланып җиңә ала. Игътибар яулау өчен сөйләм темпын, тавыш көчен арттырып, күтәреп торуларны аралашуның әһәмиятен үстерү өчен кулланырга мөмкин. Флегматик холыклы оратор үзе генә белгәннәрне сөйләп, таныш яки бер дәрәҗәдәге аудиториядә аралашу оештырганда уңышка ирешә.

Холык-фигыльнең төрлелеге аралашуның табигый җирлеге. Кешеләрдәге төрле холык-фигыль гадәти күренеш. Һәртөрле холык иясе дә нәтиҗәле чыгыш ясарга, ораторлык эшчәнлеге белән шөгыльләнергә сәләтле була. Кешенең төрлелеге үзе үк иҗади эшчәнлектә бер-берсен тулыландыра торган мөстәкыйль үзкыйммәт. Һәр оратор үз холкы сыйфатларын чыгыш ясауның, аралашу оештыруның мөмкинекләре итеп файдалана ала. Холык-фигыль сыйфатларының тискәре ягын гына бәяләп, үз мөмкинлекләреңне йомып калганда, аралашуның нәтиҗәлелеген генә киметергә мөмкин.

### *Үтә шәхсән психологик эчтәлекле мөмкинлекләр*

Без халык алдында чыгыш ясауның төп максаты – тыңлаучыларның оратор караш-мөнәсәбәтләренә кушылуы – турында бер генә кабатламадык. Киң таралган караш безне бер-беребезгә охшамаганлыкка ышандыра. Шул ук вакытта, көнчыгыш культурасының, россиялеләрне дә кертеп, эгоистлык асылы («мин»гә юнәлтелгән) аңсыз ышануларга нигезләнгән: мин

нормаль, ә калганнар төрле-төрле. Шулай да без барыбыз да бер үк үрнәкләргә иярүчеләр. Тик трансперсональ (үтә шәхсән) психологиягә нигез салган Юнгның тикшеренүләре тыңлаучыларны башка фикерләргә ияртү бик үк җиңелләрдән түгеллекне күрсәтте.

Үтә шәхсән бүленеш буенча, барлык кешеләр дә холык-фигыльләре үзенчәлекләре белән аерылалар. Бу үзенчәлекләр кешенең дөньяга карашларын билгели. Кайбер кешеләр экстравертларга керә, алар үзләренең психик энергияләрен бер үк эшчәнлектә булган объектларга юнәлдерәләр. Капма-каршы кешеләр үзләренең энергияләрен бу объектларга шәхсән бәя белдерүгә юнәлдерәләр һәм алар интровертларга керә. Күпчелек кешеләр, гадәттә, катнаш группага карый. Бу группа вәкилләренең артык ачык беленеп торган психологик үзенчәлекләре юк.

Халык алдында чыгыш ясау кешеләрнең үзара фикер-караш алмашу халәтендә уза. Аларның үтә шәхсән психологик үзенчәлекләре бер-берсеннән нык аерыла. Бу очракта ораторга тезисны исбатлауда әлеге өч психологик төзелешле төркемне күзаллап, чыгышында үз карашларын төрлечә өстәү бурычы йөкләнә.

Бу мәсьәләдә ораторга, беренче чиратта, кешенең интровертмы, экстравертмы яки нейтраль группа вәкилеме булуына төшенергә кирәк.

Оратор, сөйләме эчтәлегенә ярашып, чыгышында билгеле бер алым-ысуллар җыелмасын күздә тота. Бу алымнар аның карашларын капма-каршы фикер вәкилләре дә аңларлык, кабул итәрлек дәрәҗәдә оештырырга булышалар.

Тыңлаучыларның төрле психологик үзенчәлеге аралашу уңайлыгын арттыра, аларны җәлеп итүне җиңеләйтә торган өстәмә мөмкинлекләр барлыкка китерә. Шунысы кызганыч, безнең аралашу даирәсендә үтә шәхсән һ. б. холык-фигыль үзенчәлекләренә исәпләнгән технологияләрне түбән дәрәҗәдә кулланалар.

Хәзерге заман кешесе уңайлы әйләнә-тирәлектә яши һәм көчле, гадәти булмаган иҗтимагый-мәдәни багланышлар басымын тоя. Аралашу барышында алар төрле яктан, кайвакытта, көтелмәгәнчә каршылыкта тәэсир итә.

### ***Психологик җайланмаларның аралашуда әһәмияте***

Гадәти аралашу һәм Россия шартларында аңлашу (башка мәдәниятләрдә аралашу-аңлашу бөтенләй башка төрле булырга мөмкин), имеш, бер-берсенең караш, мөнәсәбәтләрен аңлауга нигезләнгән (урынлы-урынсыз да «мине дөрес аңлагыз» дип әйтергә яратабыз). Бу тәгъбир башкалар фикеренә кушылу өчен җитәрлек нигез кебек кабул ителә. Тик интроверт һәм экстраверт шәхесләрнең бер-берсен аңламавы, капма-каршы карашларны кабул итмәүләре һәм үзара кире кагулары күзәтелә.

Ник дигәндә, экстравертлар һәм интровертлар бер үк предметны күзалласалар да, аңлатмаларның аермасын тоймыйча, төрле әйберләр турында сөйләшәләр: беренчеләре – объект турында, ә икенчеләре объект белән субъектның үзара мөнәсәбәтен шәхсән күзлектән бәялиләр

Мәсәлән, экстраверт фильмны әйбәт дип раслый, чөнки аның әллә ничә премиясе бар, ә интроверт фильмны ошатмый, чөнки ул аның күңеленә начар тәэсир итә. Билгеле, экстраверт фильмның зәүкый дәрәҗәсен сәнгать белгечләре бәяли дип ышана һәм әңгәмәдәшенең бу бәягә бернинди дә катнашы юклыгын искәртеп үтә. Интровертлар үз чиратында, экстравертларны үз фикерләре түгел, ә чит кешеләр фикере кызыксындыра дип санаячак һәм мондый мөнәсәбәтнең үзенә бернинди дә йогынты ясый алмавын әйтәчәк. Димәк, оратор үз карашын, үзенчәлекле психологик халәтләрен истә тотып, өч төрле тыңлаучыга аңлаешлы итеп оештырырга тиеш. Алдан-алы шәхсән холык-фигыль үзенчәлекләрен исәптә тоткан җайланмалар эшләнмәсә, фикерләр, никадәр дөрес, төгәл, инандырырлык булуларына карамастан, катгый кире кагылырга мөмкин.

Мәсәлән, мондый очраклар мәгариф системасында диплом проектларын яклаганда һәм рәсми дәрәҗәдәге имтиханнарда булырга мөмкин.

Моннан тыш, хезмәткәрләрне технологик программалауга нигезләнгән сәнәгать җитештерүчәнлеге экстраверт җайланмага туры килүен истә тотарга кирәк. Инроверт буларак оешкан кешеләр тәрбия, белем үзләштерүдә, безнең чынбарлыкта экстраверт үрнәкләренең өстенлек итүе сәбәпле, кыенлыклар кичерәләр. Бу хәл тумыштан килгән холык-фигыль үзенчәлекләрен белми торып, интроверт кешеләрнең автоматик рәвештә яңадан программалаштырылуына китерә. Тумыштан килгән психик җайланма саклана, ул теге яки бу яңа экстраверт үрнәкләрнең

структуралары белән мөнәсәбәткә керә, уйламаган уңайсызлыклар китереп чыгара һәм табигый психиканы җимерә. Хәзерге иҗтимагый мөнәсәбәтләр мондый «юк-бар нәрсәгә игътибар итми», ләкин күп кенә кешеләр гарипләнгән холык белән яшәргә мәҗбүрләр. Бу феномен күп кенә интровертларны психик күңелсезлекләргә, күңел төшенкелегенә, хәтта авыруга кадәр җиткерә, күп очракта «кыргый» гамәлләрнең һәм җинаятьләрнең сәбәбе булып тора.

Нәтиҗәдә интровертлар безнең җәмгыятьтә юк кебек, ә экстравертлар дөньяда күп кенә башкача уйлый һәм җайлаша торган кешеләрнең барлыгы турында «башларына да китермиләр». Аралашу мөнәсәбәтләрендә әлеге психологик тирәлек түбәндәге хәлләрне барлыкка китерә:

- кешеләр үзләренең психологик аерымлыкларын аңламыйлар, шул рәвешле башкаларның мөнәсәбәт җайланмалары искергән, шәхси характерда (шәхси карашларын кабул ителгән үрнәк, табигый хәл дип аңлыйлар) дип уйлыйлар;
- фикерләр тәкъдим итүче интровертлар, аралашу тирәлегендәге җайланмаларның үз карашларына кире, катнаш бәйләнешенә нигезләнәләр;
- үзләренең карашларын экстравертлар катгый тезислар һәм аралашуда нык кысалы структуралар ярдәмендә тәкъдим итәләр;
- экстравертлар карашын тыңлаган интровертлар алар белән килешмиләр, тәкъдимнәрен әдәпсезлек дип аңлыйлар;
- тыңлаучы-экстравертлар интровертларның карашларын, артык субъектив кабул итәләр;
- аралашуда катнаш типтагы кешеләр күп кенә мөнәсәбәт типларын кабул итәргә мөмкиннәр, тик интровертлар яки экстравертлар кебек чиктән-чиккә ташланулардан гына сакланырга кирәк.

Димәк, психологик җайланмаларның шәхсилеген аңлау, үзенчәлекләрен истә тоту, гомуми мәдәни кыйммәтләргә таяну ораторга фикерләре белән алмашу мөминлекләрен арттыра. Капма-каршы психик җайланмалы вәкилләрнең психологик үзенчәлекләрен исәпкә алмыйча нәтиҗәле аралашуны күз алдына китерергә дә мөмкин түгел. Бу капма-каршылык көчле психологик җайланмалы кешеләрнең бер-берсен кабул итмәүләре, аңсыз рәвештә, дөрес түгел дип уйланган психотип мөнәсәбәтләренә бәйле. Психологик каршылыкларны юкка чыгару профессиональ

ораторның бурычы. Аеруча бу бурыч конкрет кешеләрнең һәм берләшмәләрнең язмышына тәэсир итәрлек җаваплы чыгыш оештыручы оратор өчен мөһим.

## Чыгыш текстын язуда акыл эшчәнлегенең әһәмияте

Сөйләм ниятен һәм караш-фикерләр каршылыгын этоска һәм пафоска берләштерү тәмамланганнан соң, оратор сөйләм тексты язуга күчә ала. Текст язу максаты булып, күтәрелгән мәсьәләне тыңлаучыларның карашларына, ораторның үз мөнәсәбәтенә (пафосына) тәңгәлләштерүе тора.

Ораторның текстта карашларын, зирәклеген, акыл эшчәнлеге белән бәйле (менталь) башка сыйфатларын файдалануы мәҗбүри. Чыгыш ясаучының текст язуда уңышлы эшчәнлеге, аның тумыштан килгән һәм күнектерелгән сәләтенә бәйле. Шуңа күрә аның төп өлешләренә тукталыйк:

- Чыгыш тексты әзерләүче, үзенең акыл мөмкинлекләрен тулысынча файдаланып, язмача вариантта пафосына, этосына һәм карашларына җавап бирерлек язма сөйләм рәвешен оештырырга омтыла. Билгеле, язма текст төзелеше белән җанлы сөйләм төзелеше аерыла. Аларың аермасы анык: күреп үзләштерү нигезендә барлыкка килгән сурәтләр, ишетеп үзләштерелгән сурәтләргә караганда икенче төрле оешалар. Уку өчен язылган текст, ишетеп үзләштерү мөмкинлекләренә якынайтуга мохтаҗ. Кайвакыт мәгълүмат тапшыруда, башлап чыгыш ясаучылар әзер язма үрнәкләрдән файдаланырга тырышалар. Болай эшләү җитди хаталану, чөнки язма текстның төзелеше сөйләү өчен бөтенләй яраксыз була.
- Чыгыш текстында риторик алымнарны истә тоту мәҗбүри. Риторик алымнарга фикер-карашларны оештыру һәм тәкъдим итү, сәламләү һәм мөрәҗәгать ысуллары; аңлатмалар бирү; чигенешләр, кабатлаулар һәм эчтәлекле паузалар оештыру; махсус нәтиҗәле алымнар: чыгыш ясаучы һәм тыңлаучылар тәҗрибәсенә мөрәҗәгать итү; серләр сөйләү һәм шәхси сыйфатларны җентекләүләр; ачышлар һәм шаккаттыргыч хәбәрләр һәм башка чаралар керә. Ораторның абруен көчәйтә, хокук, мәдәни кагыйдәләргә каршы килми торган барлык элементлар да текст эчтәлегенә кертелергә мөмкин.
- Чыгыш язучының сәләте оратор һәм тыңлаучыларны берләштерүдә ярдәм итә. Текстка йөкләнгән сөйләм рәвеше үтә

шәхсиләштерүгә дә мохтаҗ. Язылган текстта тормышчан аралашуның мөмкин булган башка темалары да чагылса, аның сыйфаты тагы да югарырак була.

Гомумән, чыгышка әзерләнгәндә без колакка ятышлы, үзенчәлекле характерда булган текст булдырырга омтылабыз. Әгәр дә текстның эчтәлеге ораторның караш-мөнәсәбәте итеп бирелсә һәм аның структурасында, тыңлаучыга, әңгәмәдәшләрнең күзаллаган күренеш-вакыйга белән үзләрен тоту рәвешләре чагыштырмача якынайтылса, чыгышның нәтиҗәлеге ышанычлы була.

Димәк, язмача текстның, чыгышның менталь байлыгына без башкаларның әзер хезмәтен күчерүне түгел, ә тыңлаучыларның фикерләү дәрәҗәсенә якын аралашу оештыруны кертәбез.

Гадәттә, оратор текстны компиляция методы белән − башка тексттан, башка кеше уйларыннан җыеп – төзи. Бу юнәлеш экстраверт җайланмалы кешеләргә һәм хәзерге технологияләргә туры килә. Интровертларга капма-каршы эшчәнлек ысулы хас. Алар табигый рәвештә үзләренең карашларын булдырырга тырышалар, хәтта чит текстлар нигезендә дә (тик кагыйдә буларак, текстлар язмыйлар).

Башлап чыгыш ясаучы, беренче этапта кыенлыклар кичерә, тик текстлар язуда үз алымын яки стилен булдырса, бурычын җиңеләйтә. Эшнең башлангыч этабында компиляция методын куллану отышлы була. Эчтәлекнең өлешләрен риторик алымнарга җайлаштыру һәм максатлар белән берләштерә алу − компиляция язучының бурычы. Бу бурыч та җиңелләрдән түгел, чөнки безнең мәдәнияттә язма чыгыш жанры үсеш алмаган һәм шул сәбәпле популяр булып саналмый.

Әйтергә кирәк, яхшы сыйфатлы һәм риторик кагыйдәләр буенча оешкан текстсыз нәтиҗәле чыгыш ясап булмый. Шул сәбәпле профессиональ оратор фикер-карашларын язып аңлату осталыгын камилләштерергә, акрын гына компиляциядән үз текстларын оештыру күнекмәләрен дә үзләштерергә тиеш.

Үзенчәлекле чыгыш текстын төзү өчен, эчтәлеген үз тәҗрибәңнән алырга, аны аңларга һәм аңлатырлык дәрәҗәдә риторик алымнар уйлап табып, язып куярга мөмкин.

## Чыгыш оештыруда акыл эшчәнлегенә бәйле мөмкинлекләр

Гомуми ният, фикер-карашларны әзерләү, текст язу, сөйләп карау − аралашу эшчәнлеген тормышка ашыру алгоритмының мәҗбүри һәм әһәмиятле өлешләре. Шулай да аралашу сөйләмсез мөмкин түгел. Ул мөстәкыйль эшчәнлек буларак карала ала. Сөйләмне яңгырату әзерлек белән бәйле, ләкин чыгыш нәтиҗәсе әзерлектән генә тормый. Аралашу һәрвакыт чынбарлыкның шушы мизгелендә, «монда һәм хәзер». Чыгыш ясаганда тәҗрибәле оратор үткәннәрне онытып тора һәм кабатланмас аралашу оештыра. Халык алдындагы чыгышны иҗади мизгелгә тиңләргә мөмкин.

Халык алдындагы чыгыш − иҗтимагый, мәдәни казаныш. Камил чыгышта шәхеснең сәләте, барлык өлкәдәге зирәклеге чагыла. Психофизиологлар әйтүенчә, чыгыш ясаганда кеше күп күләмдә энергия сарыф итә. Әлеге хәл ораторның берьюлы берничә вазифа башкаруы белән аңлатыла. Вазифаларның күбесе аңлау-төшенү өлкәсенә кагыла. Алар арасында иң әһәмиятлеләре: ораторның үзен тоемлау халәтен оештыруы, сөйләмен эчтәлекле итәрлек фикерләр туплавы, аларны сөйләм рәвешенә китерүе, аваз әйтүне, тавыш төсмерен ишетеп-тикшереп торуы, тыңлаучылар белән аралашуны оештыруы һәм аның барышын тикшерүе, төзәтмәләр кертә алуы.

Аңлашылганча, чыгыш вакытында киң кырлы акыл эшчәнлеге күзәтелә. Барысын да берьюлы эшләргә туры килгәнгә кыенлыклар туа. Белгәнебезчә, аң егәре кешенең бөтен гамәлләрендә, һәрбер эшчәнлегендә катнашмый. Кеше эшчәнлегенең күп кенә яклары, күнегелгән рәвештә, аңсыз үтә. Кешенең күнегелгән үрнәкләре булмау сәбәпле, ул аны аңлы рәвештә башкарырга мәҗбүр. Күп микъдарда аң егәре сарыф ителүгә карамастан, күнекмәләр булмау сәбәпле, гамәлләр башкару дәрәҗәсе бик түбән була. Белемле һәм аралашуда төрле үрнәкләргә ия кешеләр, тәҗрибәле оратор кебек, кыенсынмыйча аралашалар, ә тәҗрибәсе булмаганнар һәрвакыт текстка ябышалар һәм тизрәк бу уңайсыз вазифадан − аралашканда фикер алышудан − котылырга телиләр.

Югарыда күрсәтелгәннәр аралашу максатын ике юнәлештә оештырырга ярдәм итә: оратор эшчәнлегендә үзенең акыл мөмкинлекләрен файдалана яки, үзенә яраклаштырып, әзер риторик алгоритм куллана. Һәрьяклы аралашу оештыра алырлык булып өлгерү өчен акыл эшчәнлеге дәрәҗәсен – фикерләү

культурасын – үстерергә кирәк. Әлеге дәрәҗәгә ирешү җиңелләрдән түгел.

Риторикада әзер фикерләү рәвешен тормышка ашыру җиңелрәк. Мондый очракта чыгыш текстын өйрәнү, сөйләм культурасын үстерү, аудиториядә эшли һәм тыңлаучыларның холык-фигыль үзенчәлекләрен белү, алар белән идарә итә алу, шәхсән һәм гомуми фикерне нигезле дәлилли белү җитә. Күргәнебезчә, акыл байлыгы ораторга риторик алым-чараларга таянып, үз-үзен оештыру режимында эшләргә һәм аралашу оештыруда үзенчә эшләүдә ярдәм итә. Чынлыкта исә, акыл мөмкинлекләрен үстереп һәм риторик алымнар җыелмасын тулыландырып, шушы ике юл белән бару кулай.

Билгеле булганча, риторика, башка гамәли белемнәр кебек үк, үзендә ике төрле үрнәкне берләштерә: исбат ителгән белем һәм алым-күнекмәләрне. Алым-күнекмәләр үзенчәлеге аларның бер билгеләнгән мәгънәлелегендә чагыла. Нәтиҗәле аралашу максатын тормышка ашыру өчен әзер чаралардан тулырак файдалану отышлы. Алардан тиешле дәрәҗәдә файдалану өчен ныклы күнекмә булдыру (автоматизга ирешү) зарур.

Искә төшерик, автоматизм билгеле бер эшчәнлектә, акыл көчен урынлы файдаланырга һәм аралашу вакытында иҗади максатларга, уңышларга ирешергә ярдәм итә. Бу фикер сөйләм образын һәм ораторның үз йөзен булдыруда әзер үрнәкләрне үзләштерү әһәмиятен искәртә.

### *Ораторның үз йөзен булдыруда акыл мөмкинлекләре*

Нәтиҗәле һәм профессиональ дәрәҗәдә аралашу өчен анда катнашучы (бигрәк тә оештыручы) билгеле бер образ – үз йөзен булдыруга мохтаҗ икәнен тагын бер кат искә төшереп үтик. Оратор образын без, автор (оратор) карашларын нәзәкатьле оештыруга юл ача торган фикерләр тапшыру һәм тыңлаучыларны ияртә алу мөмкинлекләре җыелмасы итеп аңлыйбыз. Халык белән аралашу максатына ирешүдә, әзер күнекмәләрне белеп, урынлы куллануга ярдәм итә торган мөмкинлекләр ораторның акыл үзенчәлекләре буларак карала.

Оратор образы анык сөйләмендә чагыла, алай гына да түгел, тәҗрибәдән чыгып фикерләү, аны аңлап җиткерү (төшенү), аңлатырлык итеп эшкәртү аның образын тулыландыра. Без аңлы рәвештә риторик белемнәр үрнәге белән тәңгәл килгән шәхси

тәҗрибәне берләштерәбез һәм, шушы яңалыкларны кулланып, образны баетабыз. Шул чакта үз йөзебез, үз алымнарыбыз турында сөйләргә мөмкин.

Куелган мәсьәләне хәл итү өчен, түбәндәге таләпләрне үтәү мөһим:

- һәр чыгыш барышында аралашу халәтен бербөтен буларак төшенү, тикшереп тору;
- һәрбер чыгыштан соң аны анализлау һәм, җитешсезлекләре булганда да, алга адым буларак аңлау;
- килеп туган мәсьәләләрне хәл итү ысулларын башка ораторлар кулланган әдәбият һәм аларның тәҗрибәсе нигезендә табу;
- гамәли һәм фикерләү ысулларын берләштереп, проблемаларны чишүдә үз образыңа күчерү – үз йөзеңне булдыру.

Акыл эшчәнлеге мөмкинлекләрен, аралашу барышындагы хаталардан котылу, кыенлыкларны бетерү һәм чыгышларның нәтиҗәлелеген өзлексез арттыру, үз йөзеңне булдыру өчен файдаланырга кирәк.

Аралашу нигезен акыл эшчәнлегенә бәйләү, ораторның фикерләрен аңлауга омтылышны һәм тагын да нәтиҗәлерәк, камилләштерелгән аралашу рәвешен – яңа аралашу үрнәкләрен – эзләүне өзлексез дәвам итәргә җирлек тудыра. Риторикада беркайчан да үз мәгънәсен югалтмый торган әйтем бар – “Үзеңне өйрән”. Аралашу киңлеген оештыруда риторик алым-чараларны алдан күрү сәләтен ораторның шәхсән акыл культурасының әһәмиятле казанышы дип санарга була.

Ораторның холык һәм акыл эшчәнлеге мөмкинлекләре аңа төрле холык-фигыльгә ия булучылар белән тәңгәл һәм уңышлы аралашырга, шулай ук аңлы рәвештә үз карашын оештырырга, тыңлаучыларының үз фикеренә кушылуына ирешергә һәм аралашуда шәхси тәҗрибәсен файдаланып, үзенең ораторлык образын үстерергә мөмкинлек бирә.

## Аралашу рәвешен оештыру мөмкинлекләре

Мөмкинлекләрнең өченче төренә аралашу рәвешен тудыра, чагылдыра алырлык элементлар керә. Алар аралашуда турыдан-туры, алдан әзерләнмәгән гомум мәдәни дәрәҗә, мәдәни кыйммәтләр буларак катнашалар. Бу мөмкинлекләр, нигездә, аралашуның тәэсирен көчәйтү өчен мәдәни сыйфатлары югары теге

яки бу катнашучы осталыгыннан файдалана белү дигән сүз. Билгеле бер мәдәни кыйммәтләр төрле кешедә бар һәм аларны куллану нәтиҗәле булганлыктан, аның мөһим сыйфатларын ачыклау, тәртипкә салу һәм аралашу рәвешенә әверелдерү риторик хәзерлекнең башлангычы була.

Аралашу рәвешен оештыру мөмкинлекләренә кешеләрнең нинди сыйфатлары нигез булып тора соң? Алар бихисап күп. Мәдәни дәрәҗәсе югары һәр кеше чыгыш оештыруга әзер булырга мөмкин. Аралашу мөмкинлекләре сыйфатында куллану өчен бу үзенчәлекләрне ачыкларга, аңларга һәм шәхеснең ныклы күнекмәләренә әйләндерергә генә кирәк.

Кешенең үзенчәлекле сыйфатын аңлау һәм аралашу кыйммәтенә күчерү өчен, остаз җитәкчелегендә аерым эшчәнлек оештыру кулай. Әмма безнең мәдәни даирәдә мондый мөмкинчелек сирәк очрый.

Бу эштән кала тагын үзанализны да кулланырга була. Моңа тыңлаучылар, дуслар һәм башкаларның бәяләре, җиңелчә тәнкыйтьләп кисәтүләре керә. Бу очракта бер шартны истә тотарга кирәк: профессионаллар ярдәмендә уңай образлар үстерелә һәм тискәреләре киметелә. Дилетантлар ярдәме һәм мөстәкыйль эш, кагыйдә буларак, уңай якны үстерергә мөмкинлек тудыра, әмма, бөтенләй диярлек, тискәре үрнәкләрне уңай якка үзгәртүдә ярдәм итми. Ләкин үзанализ һәм төрле ярдәм нәтиҗәле образ тудыру өчен бик әһәмиятле.

Аралашу киңлегендә чыгыш ясаучының үз-үзен тотышы, ягъни тәртибе бик мөһим. Аның образының нәтиҗәле күрсәткече – хәерхаклык, сабырлык. Чыгыш ясаучы тыңлаучыларына, булдыра алганча, файда китерергә тырыша.

Ул үзенең ачыклыгы, гаделлеге, тынгысызлыгы, дөреслеккә омтылышы һ. б. белән табигый рәвештә тыңлаучыларга тәэсир итә. Ораторның мондый оешканлыгы, кайбер кимчелекләре булса да, аралашуга уңай йогынты ясый.

Аралашуда рухи күтәренкелек тә бик көчле тәэсир итә. Ул чыгыш ясаучыда да, тыңлаучыда да куәтле дәлилләү җирлеге. Югары энергияле аралашу тыңлаучыны үзенә буйсындыра, ә бу чыгыш ясаучы ихтыяры дигән сүз.

Аралашу рәвешенең бу төрендә кимчелекле як – максат, эчтәлек сыйфаты һәм карашларның уйланып бетмәве. Әмма сокландыргыч күтәренкелектән тайпылу бик үк җиңел түгел. Шуңа

күрә, тыңлаучыларның чыгыш ясаучы фикерендә берләшүе шиксез. Мәсәлән, һәр харизматик шәхес тә рухи күтәренкелек үрнәгендә аралаша.

Чыгыш ясауда иң үтемсез алым – белемсезлек, дорфалык. Бу очракта чыгыш ясаучы тыңлаучыны үз максатын тормышка ашыру җирлеге мөнәсәбәтендә куллана. Төрле рәвештә булырга мөмкин бу аралашу. Мәсәлән, оратор чын карашларын яшереп, тыңлаучыларны алдап, илтифатлылык, игътибарлылык мөнәсәбәте урнаштыра. Мондый җайланманың капма-каршысы – тыңлаучыларны куркыту. Бу тыңлаучыларны үз ихтыярларыннан башка берләштерү теләге белән эшләнә. Чыгыш ясау рәвешен табигый оештыру юлы булып хәерхаклык, мәрхәмәтлелек җайланмаларына иярү тора. Ул, үз чиратында, игелеклелек, тыйнаклык, киң күңеллелек дигән сүз.

Отышлы аралашу рәвеше турыдан-туры оратор образының камиллегенә бәйле. Оратор образының (үз йөзенең) тәэсире үз шәхесе үзенчәлекләре исәбенә көчәергә мөмкин. Аралашу кыйммәтләренә әверелдерергә мөмкин булган шәхес үзенчәлекләренә риторик алымнарда, үрнәкләрдә билгеле булган сыйфатларны өстәргә кирәк. Мәсәлән, махсус тикшеренүләр нәтиҗәсе буенча, телевидение дикторының тамашачыга тәэсире, ничек кенә сәер тоелмасын, 80 % күрмә образ тәэсире исәбенә һәм якынча 20 % – тел чаралары ярдәмендә оеша икән.

Күрмә образның тәэсир көче нәрсәләрдән оеша? Мөгаен, аңа ораторның тышкы кыяфәтен, прическасын, гәүдәсен дөрес тота белү осталыгын, ым-ишарәләре ярдәмендә сөйләмнең эчтәлеген чагылдыруын һәм елмаю рәвешен, мимика һәм гәүдә хәрәкәтләре белән тыңлаучыга үзенең карашларын белдерүне кертергә мөмкин. Моннан тыш, макияж, образ аксессуарлары (күзлек, портмоне, визитка, ачкыч, портфель, кулъяулык) психологик тәэсирлелек, үз-үзен тоту гадәтен һ. б. өстәргә кирәк. Кеше хыяллану куәсе, зәвыгы булганда тыңлаучыга тәэсир итәрлек үз имиджын − кабатланмас үз йөзен булдыра ала.

## Аудиториянең оратор шәхесенә, образына мөнәсәбәте

Оратор өчен беренче тәэсир проблемасы бигрәк тә әһәмиятле. Бу күренеш һәр кеше өчен дә мөһим, тик чыгыш ясаучыга икеләтә, өчләтә игътибарлы булырга туры килә. Ник?! Чөнки ораторның

тыңлаучылары белән очрашуы дәвамлы түгел, соңыннан үзе турындагы фикерне – беренче тәэсирне – ул берничек тә үз файдасына үзгәртә, тыңлаучылар күңелен яулый алмаячак. «Киеменә карап каршы алалар, акылына карап озаталар» дигән мәкальне бөтенебез дә беләбез. Тик әлеге сүзләр һәр очракка да туры килеп бетсә икән...

Дәвамлы аралашу барышында гына акыл турында ниндидер нәтиҗәгә килергә мөмкин , ә аудитория белән очрашуны озакка сузылган аралашу дип булмый. Лекторны, ораторны күп очракта “тышкы кыяфәтенә, тышкы билгеләренә, киеменә” карап озатканнарын истә тотарга кирәк .

Чыгыш ясаучыны аудитория иҗтимагый һ.б. хәленә (кем ул – галим, депутат, ир-ат, хатын-кыз, язучы, комментатор, журналист, укытучы һ. б.), шулай ук, шәхсән үзенчәлекләренә (тышкы кыяфәте, аралашу осталыгы, тәртибе, рухи сыйфатлары һ. б.) карап бәяли. Тыңлаучылар аның шәхсән сыйфатларын, иҗтимагый роленә караганда, өч тапкыр югарырак бәялиләр икән.

Аудитория ораторның шәхси үзенчәлекләренә, башкалардан аерылып торуына нык игътибар итә. Ул чираттагы ораторның, билгеле бер мәсьәләгә карашын аерымлап куярга, аңа ышаныч күрсәтергәме-юкмы дип алдан хәл итәргә тели. Шулай булса да, табигыйлек, ихласлыкны башкалардан аерымлыкны аудитория гел тоеп, күреп торырга тиеш. Кемгәдер охшарга тырышмыйча, үз йөзеңне сакларга, уңай сыйфатларны гадәткә әверелдерергә кирәк.

Ораторның үзен үзенчәлекле тотышы, үз йөзе булуы тыңлаучыларның ышанычын ныгытып, аның фикерен хәтерләп, үзләштереп утыруларына сәбәп була. Иң элек ораторның шәхес сыйфатлары хәтердә кала – аннан соң аның карашлары аңга сеңә.

### ***Сөйләмнең күзгә ташланып торган элементлары***

Күп ораторлар турында тыңлаучыларның фикере аларның чыгышлары вакытында оеша. Сөйләм мәгънәсенә игътибарлы булып, үзен уңайлы шартларга куеп, оратор, тыңлаучыларның фикерләренә йогынты ясау мөмкинлегенә ия.

Ораторның тышкы кыяфәте, билгеле бер кысалар эчендә, үзенә җәлеп итеп торырга тиеш. Артык мөлаемлык, дөресрәге кыяфәтең белән артык игътибар җәлеп итү, эчтәлектән читләшүгә алып килә һәм чыгышка ышанычны киметә.

Ир-атка уртача модалы, күзгә ятышлы костюм кияргә омтылсалар яхшы була. Мода артыннан куучы хатын-кызны аудитория тискәре бәяли.

Хатын-кызга бизәнү әйберләрсез, сумка-перчаткасыз, эшләпәсез чыгыш ясау уңышлы була.

Ир-ат чыгышка килгәндә кесәсеннән бөтен әйберләрен алып куйса, ручка-карандашлар, газета тотмыйча чыгыш ясаса, уңай тәэсир калдыра.

Лекторның киеме үз яшенә туры килергә тиеш, теге яки бу якка тайпылулар аудиториянең кәефен җибәрә.

***Ораторга ышаныч арттыра торган шартлар:***

- караңгы тондагы гадәти кием (куе зәңгәр, коңгырт, кара, куе яшел, соры төсләр)
- киемнең сыйфатлы материалдан булуы;
- киемнең күзгә «ташланып» торуы;
- бигрәк тә хатын-кыз киеме өчен эшлекле стиль мөһим.

Озын җиңле күлмәк бөтен таләпләргә дә җавап бирә. Иң абруйлы төсләр – соры, яисә куе зәңгәр, коңгырт, “кычкырып” тормаган төсләрнең аксыл вариантлары;

- күзлек кысасының карасу төстәгеләре;
- турыпочмаклыкка якын силуэт;

***Ораторның дәрәҗәсен киметә торган күрсәткечләр:***

- артык ачык, кычкырып торган төсләрдән киенү;
- киемнең артык модалы булуы;
- бизәнү әйберләренең күплеге, купшылык;
- хатын кыз киемендә кыланчыклык (кокетство);
- шарга охшаш силуэт;

Аудитория тышкы кыяфәте белән үзенә яраклашырга тырышуын сизсә, ораторга ышанычын арттыра. Мәсәлән, үзенең тулылыгын яшерергә омтылган ораторны аудитория җылы каршылый. Үз яшенә хас модадан калышмаучы хатын-кызны аудитория үз итә.

***Чыгыш манерасы***

Чыгышта ораторның тәртибе, гадәтләре тыңлаучылар хәтеренә нык сеңеп калучан, аудиториянең ышанычын арттыру яки киметүдә бик әһәмиятле.

П.Сопер фикеренчә, чыгышта үз-үзеңне тоту гадәте ораторның тышкы кыяфәтенә караганда да мөһимрәк – «Чир китә, гадәт кала» диләр бит, дөрестән дә, ул хаклы, тышкы кыяфәт гадәткә караганда тизрәк онытыла.

Иң элек чыгыш ясау гадәтенә – манерасына – нәрсәләр килешеп бетмәгәнне барлап чыгыйк:

- Ораторның үз-үзен тотышында арыганлык; кабалану; ризасызлык (бүлмә, зал, урнашу, чыгыш башлауның кичегүе, тыңлаучыларның саны, соңга калулар һ. б. кагылышлы) чагылмаска тиеш.
- Артык кызып китү дә чыгыш ясаучыны бизәми (тыңлаучылар оратор өчен оялып, аска карап утырмасыннар).
- Оратор үзенең кыюсызлыгын сиздермәскә тиеш.
- Үзенең турыдан-туры вазифасын үтәү өчен оратор беркайчан да гафу үтенергә тиеш түгел.

***Чыгыш ясауның иң отышлы манерасы***

Ул түбәндәге таләпләрне канәгатьләндерә:

- Дәртләнеп сөйләргә.

Ораторның рухи көче тыңлаучыларга да тапшырыла, алар рухи киеренкелектә торып, сөйләнгән мәгълүматка ныграк ышаналар.

- Физик ныклык, житезлек.
- Ышанычлы тышкы кыяфәт.

Ораторның үзенә ышанычы бик тиз аудиториягә күчә һәм ул чыгыш ясаучының сүзен тәнкыйтьләмичә, ышанып кабул итә. «Ышанычлы тышкы кыяфәт булдырыгыз, ул тынлаучыларга уңай тәэсир итә», – дип язган П.Сопер. Ышанычлы кыяфәткә ирешү бик авыр түгел – иң элек иякне бераз күтәрергә киңәш ителә. Сөйләгәндә бераз югарырак карап сөйләргә була. Югарылыкны ансат кына билгеләргә мөмкин: кагыйдәсе – арткы стена белән түшәм тоташкан сызыкка тигезләнергә мөмкин (аудиториясенә карап), яки утырган тыңлаучыларның башларыннан өскәрәк. Туры басып торырга киңәш ителә; бер якка да янтаймаска; тыңлаучыларның йөзенә, күзенә карап алырга кирәк.

- Дустанә, ихлас тавыш.

Аудитория ораторның ихласлыгына өметләнә. Аудитория белән бер кеше белән сөйләшкән кебек, иркен, дусларча аралашырга кирәк.

Аудиториягә үзегезнең аларга якын булуыгызны искәртеп торырга кирәк. Үзенеке итеп исәпләгән ораторның сөйләмен аудитория бик ышанып кабул итә. Кызыксыну даирәсенең, карашларның, проблема, кыенлыкларның уртаклыгын аудиториягә хәбәр итеп, бүлешеп торырга кирәк. Чыгыш беткәч тә аудиториядән ашыгып чыгып китмәскә, ә тыңлаучыларның берәрсе белән фикер, сүз алышырга, сорау бирергә, чыгышка мөнәсәбәтләрне уртаклашырга була. Бу чаралар да соңгы «уңай ямь», канәгатьләнү хисенә ия.

- Игътибарны эчтәлеккә юнәлдерү.

Чыгышта сезнең төп максатыгыз – сөйләнгән сүзләр белән бик әһәмиятле мәгълүмат тапшыру, үзегезнең аңлавыгызча, хәл ителәсе мәсьәләләрне хәбәр итү, ягъни үз мөнәсәбәтегезне аңлатып бирү. Чыгышның формасы икенчел булып, тыңлаучылар төп уйфикерне аңлап барырга тиешләр. П.Сопер «үзегезнең кыяфәтегез турында борчылмагыз, шәхси хисләрегез турында онытып торыгыз, тыңлаучыларга үз фикерләрегезне җиткерү мәсьәләсендә игътибарлы булыгыз», – дип киңәш итә.

### *Ораторның аудиториядә урнашуы һәм хәрәкәтләнүе*

Әйткәнебезчә, ораторга аудиториядә басып тору нәтиҗәлерәк. Ул һәркемгә дә күренеп торырга, аудиториядән алда, аерылып торырга тиеш. Басып торучы оратор аудиториягә:

- ихтирамын күрсәтә;
- үзе өчен даими дикъкатькә (рухи киеренкелеккә) ирешә;
- вакытны яхшырак сизә;
- дәртләнебрәк сөйли.

Чыгыш барышында хәрәкәтләнү мәҗбүри. Кымшанмаган да ораторга аудитория иске карашлар тарафдары дип, ышанмыйчарак карый.

### *Караш*

Безгә гел карап торсалар да уңайсыз була. Без, бәлки, очраклы гына булган карашларны үзебезне бәхәскә чакыралар (ораторга каршы фикердә торсак, билгеле) дип кабул итүебез бар; үзебезгә карата мөлаем мөгамәлә яисә аерым игътибар дип ялгышуыбыз да ихтимал.

Түбәндәге киңәшләрне үтәргә була:

- Чыгыш ясаучы бер-бер артлы һәрбер кешегә карап алырга тиеш, кемне дә булса шәхсән аерып кую, башкаларның кәефен җибәрүе бар.
- Кайбер фикерләрне оештырган мизгелдә генә аудитория белән бәйләнешне өзеп торырга мөмкин. Соңыннан карашның яңадан кемгә дә булса әйләнеп кайтуы уңайлы.
- Бушлыкка, яисә икенче яссылыкка күчү аудиториянең ышаныч дәрәҗәсен киметә һәм ул тынычсызлана башлый.
- Чыгыш барышында, идән, аяк (дошман аякка карар), тәрәзә, түшәм, башка чит предметларны күзәтмәсәк тә ярый. Бу гадәт аудитория белән араны өзә.
- Аудиториядә карашны акрынлап, салмак темпта күчерергә кирәк.
- Сөйләмнең башынан-ахырына кадәр карашны аудиториядән аермаска тырышырга кирәк.
- Дусларыгызны очраткандагы кебек, аудиториягә мөлаем караш ташлагыз. Һәркемне күрүегезгә шат, һәркемгә карарга омтыласыз кебек булсын.
- Тыңлаучыларга караш ташлаганда, күзенә карагыз. Күзгә карау тиз узарга тиеш, чөнки ул кызыксыну һәм күңелгә ятышлылыкны белдерә. Озак һәм текәлеп карап тору тыңлаучыны борчуга сала яки аның ихтыярына басым ясау дип кабул ителә.
- Зур аудиториядә барлык тыңлаучыларны да аерым-аерым төркемнәргә бүлеп, карашны бер төркемнән икенчесенә юнәлтергә, бер төркемне дә игътибардан читтә калдырмаска кирәк.

### *Поза*

Басып торган ораторның аяклары җиңелчә аерылган, аяк башы ян-якта, тик гәүдә авырлыгы икесенә дә бер үк түгел, иң әһәмиятле, тәэсирле өлешләрдә авырлыкны үкчәгә түгел, аяк очына күчерү уңай тәэсир тудыра.

Күкрәк бераз алда, эчнең аскы өлеше җыелган. Ияк һичничек түбән төшми, куллар бераз җәелгән, хәрәкәтсез катып калмыйлар. «Ябык» позадан сакланыгыз – аудитория үзенең ораторга ышанычын киметә, яки «борынын чөя» дип кабул итә.

Утыруга караганда басып тору тәэсирлерәк. Чыгыш ясаучы аудиториядән никадәр югарырак, аның аралашу позасы шул кадәр

көчле. Монда югарылык буенча өстенлек кагыйдәсе (вертикаль доминанта) тәэсире оеша.

### *Ораторның ым-ишарәләре*

Ишарә – кул бармаклар торышы гына түгел, ул кеше гәүдәсенең һәртөрле хәрәкәте, ым-ишарәсе. Ым-ишарәне аяклар, җилкәләр, бөтен гәүдә белән эшләргә мөмкин. Ишарәләрне күрсәтү, тасвирлау, ияртү һәм мәгънәле төрләргә аерып күзәтәләр.

Соңгы төр ишарә-ымнарны чыгыш барышында кулланырга тәкъдим итмиләр.

"Ишарә-ымнарсыз чыгыш тыңлаучыларны сагайта, «күңелдә тискәре мөнәсәбәт, ышанмаучанлык юшкыны калдыра» (П.Сопер).

Ым-ишарәләргә таләпләр:

1. Ишарәләрнең табигыйлегенә омтылырга;

2. Алдан уйланып куелган ишарәләр ясамаска кирәк. Алар кылану буларак кабул ителәләр һәм ризасызлык тудыралар;

3. Ым артыннан бертуктаусыз ым булмый;

4. Ым-ишарәләрне төрләндереп торырга;

5. Киемне, бизәнү әйберләрен, сәгатьне бертуктаусыз тоткалап тормаска;

6. Куллар инандыру тактына бәйле рәвештә тоташырга һәм салмак кына аерылырга тиешләр.

- кул хәрәкәтләренең күбесе билдән югары үтсен, аста булса (кулы салынган, хәлсезләнгән) дип уйлыйлар – югалып калу, уңышсызлыкны чагылдыра;
- терсәкләрне кысып тотмагыз – абруегызны түбәнәйтеп күрсәтә;
- учларыгыз кысылган хәлдә булу сезнең көчсезлегегез һәм аудиторияне үзегезгә ияртә алмавыгыз буларак кабул ителәчәк;
- ике кул белән дә ишарәләр ясарга кирәк.

### *Ораторның аудиторияне тоемлавы*

Оратор аудиториянең халәте турында һәрвакыт мәгълүмат алып тора, үзенә һәм сөйләнгән сүзенә аның мөнәсәбәтен сизә. Оратор бу мәгълүматны һәрчак «туплап» торырга, очрагына карап, чыгышына үзгәрешләр, төзәтмәләр кертергә тиеш. Аудиторияне тою өчен күзәтүчәнлек һәм тәҗрибә сорала. Башлап чыгыш

ясаучыга берничә киңәш. Ораторны игътибар белән тыңлаучыларны әлеге күрсәткечләр чагылдыра:

- ораторга юнәлгән карашлар;
- тыңлаучының гәүдәсе ораторга таба янтайган, ул якынрак булу максатыннан урындыкның читенә утыра;
- башының бер якка авышуы да тыңлаучының кызыксынуын чагылдыра.

### *Ораторның тавышы һәм интонациясе*

Чыгыш ясаучының тавышы көчәнмичә, гайрәтле яңгырарга тиеш, бу очракта чакыру, өндәү чагыла.

Тавышның көче дәрәҗәсе – аудиториянең күләменә карап үзгәрә. Көчсез тавыш чыгыш ясаучының үзенә ышанмавы, артык көчле тавыш – ярсучанлыгы дип кабул ителергә мөмкин.

Халык алдындагы чыгышларда интонация түбәндәге таләпләргә җавап бирә:

- чыгыш барышында тавыш тоны гел үзгәреп тора, монотоннан сакланырга кирәк;
- табигый тавыш чыгышның эчтәлеген ачарга ярдәм итә. Эчтәлеккә туры килмәгән тавыш канәгатьсезлек тудыра, комик хәлдә калдыра.

Темп – уртача, тынып торулар дәвамлы түгел. Зур паузалар – аудиториянең ачуын китерә.

Әһәмиятле сүз алдыннан тавыш күтәрелә һәм пауза ясала (тавыш түбәнәю дә күзәтелә). Әһәмиятле сүздән соң, гадәттә, пауза булмый. Булган очракта ул уйлануны, яңа фикер туплауны белдерә.

Рәсми әйтелеш стиле өчен текстның, гадәттә, салмак яңгыравы хас, сүзләрдәге, сәнгатьле әйтелешнең кайбер очракларындагы кебек, авазларның озынайтылуы күзәтелми.

Рәсми әйтелеш стилендә алты просодик күрсәткечне аерып куярга була.

1. Югары тонда һәм көчле тавыш белән башланган сөйләм тыңлаучыларның игътибарын туплый. Ахыргы синтагмаларда күтәрелә торган тоннардан тавышның түбәнәя баруы сөйләүченең үзенә нык ышанычы буларак яңгырый.

2. Бер төрле интонация бизәгеннән икенчесенә күчү абзацларда, төп фикердән аны ачыклаган сүзләргә күчкәндә, автор сөйләме эчендәге башка кеше фикерләрен аерымлап куюда ( цитата китергәндә ) кулланылырга мөмкин. Төп логик басымлы синтагма

фраза уртасында килгәндә тавыш югарыдан түбәнгә төшә һәм фраза ахырына кадәр шулай түбән дәвам итә. Капма-каршы куелган синтагмаларда тавыш югарыдан түбәнгә төшеп, яңадан күтәрелеп кала.

3. Рәсми әйтелеш стилендә мелодик диапазон – даими, нормадан читләшү күзәтелми диярлек, ягъни тавышның югарыдан түбәнгә һәм киресенчә тирбәлүе билгеле югарылык арасында гына уза.

4. Сөйләм темпы – уртача тизлектә, төп фикерне хәбәр итүдә бераз салмаклану була.

5. Тавыш көче дә артык үзгәрешсез. Төп фикерне аерымлау өчен генә тавыш көчәеп ала.

6. Рәсми әйтелеш стилендә дә паузалар мәгънәви характерда, шулай ук каушап яки онытып җибәрү, икеләнү-шикләнү паузалары да очрый. Соңгылары тыңлаучыны лектор сөйләменә кушылып китәргә өндәгән кебек яңгырыйлар. Рәсми сөйләм стилендә игътибарны туплау яисә юнәлтү паузалары да була.

Рәсми әйтелеш стилендә үзенә генә хас тотрыклы күрсәткечләр җыелмасы бар, аларның төре сәнгатьле әйтелеш стилендәгедән азрак. Рәсми әйтелеш стиленең төп максаты булып тыңлаучыга хәбәрнең эстетик ягын түгел, ә эчтәлеген – ниятен җиткерү тора. Просодик күрсәткечләр җыелмасы шушы бурычларны: үз-үзеңә ышанычны, катгыйлыкны, фикер эзлеклелеген, инанганлыкны, капма-каршылыкны яки төп мәгънәне аерымлауны белдерү өчен кирәк.

Рәсми әйтелеш стиленнән үзгәрәк вәгазь, үгет-нәсыйхәт (публицистик чыгышлар) әйтелеш стилендә аерым просодик күрсәткечләр бар:

1. Халык алдындагы чыгышларда түбән төшә торган, “ноктага килгән” тавыш ешрак яңгырый. Фраза башындагы һәм уртадагы тактларда тавышның күтәрелүе-төшүе (катнаш контурлар) күзәтелә.

2. Диапазонның югарыга таба киңәюе, ягъни тавышның югарырак яңгыравы, әйтелештә тантаналыкны тудыра. Аудиториянең зурлыгы да мелодик диапозонның киңәюенә алып килә.

3. Күп очракта, әйтелеш тизлеге – салмак. Аудитория зуррак һәм чыгыш тантаналырак булган саен сөйләм тизлеге акрыная. Вәгазьче сөйләме тизлеге, еш кына эчтәлегенә һәм кабул ителүенә карап үзгәрә. Фикер үсеше, дәлилләү барышында сөйләм тизлеге дә, тавышның тон диапазоны һәм көче дә үзгәрә. Вәгазь стилендә

әйтелеш тизлегенең кискен капма-каршы куелуы сөйләм кисәкләренең нык аерымлануына алып килә.

4. Вәгазьче әйтелеш стилендә сөйләмнең мәгънәви кисәкләрен генә түгел, сөйләмнең йогынтылылыгын көчәйтү максатыннан, иң әһәмиятле берәмлекләрне (аерым сүз, иҗек булуы да ихтимал) дә махсус пауза белән билгеләргә мөмкин. Төп мәгълүмат алдыннан пауза озаграк була. Чыгышлар вакытында каушау паузалары да очрый. Чыгыш ясаучы артык борчылса, аларның саны күпкә арта.

Вәгазьче сөйләме лекторлар чыгышыннан «нәрсә» турында сүз баруы белән генә түгел, ә «кем»тарафыннан һәм «ничек» хәбәр ителүе белән аерылып тора.

Шунысын да искәртик, вәгазь, үгет-нәсыйхәт сөйләменең просодик күрсәткечләре сәнгатьле әйтелеш стилендәгеләрдән нык үзгә. Вәгазь сөйләменең максаты тыңлаучыга турыдан-туры тәэсир итү, ниндидер гамәлгә өндәү рәвешендә, ә сәнгатьле әйтелештә просодик күрсәткечләр җыелмасы, күзаллап, җанлы образ тудыру өчен хезмәт итә. Оста вәгазьчеләр сәнгатьле әйтелеш стилен дә камил дәрәҗәдә үзләштерергә тиешләр.

### Үзләштерелгән белемнәрне мөстәкыйль тикшерү өчен сораулар һәм биремнәр

1. Чыгыш ясаучының үз-үзен ничек тотарга тиешлеген тасвирлап бирергә.

2. Киемдәге (кемнеңдер) кыланчыклык чагылышын 5-6 пункттан тасвирлап бирергә (рәсемен ясарга).

3. Киенүдә эшлекле стиль һәм беренче тәэсир, бүгенге көн модасы турында мәгълүмат бирергә (рәсемен ясарга).

4. Сүзсез генә үзеңнең арыганлыгыңны, кабалануыңны, ризасызлыгыңны уйнап күрсәтергә.

5. Кыюсызлыктан ышанычлы кыяфәткә күчү җайланмаларын уйнап күрсәтергә.

6. Шәкертләр тудырырга мөмкин комачаулык ситуацияләрен уйнап күрсәтергә, анализ ясарга.

7. Аудитория алдына басып, 10 секунд тыңлаучыларны күзәтергә («Әйе», «юк» җавабы бирерлек гади сорау әзерләргә).

8. 1) Дин әһелен, яраткан җырчыңны, хөрмәт иткән берәр шәхесне нинди киемдә күрергә теләр идең? (Төсле карандашлар белән кием рәсемен ясарга, материалларын тәкъдим итәргә).

9. Вәгазь текстларыннан мәгънәви басым кагыйдәләренә мисаллар табарга һәм яңгыратып карарга (һәр канун, кагыйдәгә икешәр мисал).

10. **“Минем холкым”** тестына җаваплар бирегез.

Кешенең холкы, иң элек, җәмгыять, башка кешеләр алдындагы һәм үзенең бурычларына мөнәсәбәтендә чагыла. Һәр сорауга “әйе” яки “юк” дип җавап бирегез.

1) Күп кенә танышларыгызның холыкларын яман дип исәплисезме?
2) Көндәлек вак-төяк бурычлар сезнең кәефегезне җибәрәме?
3) Сез дусларыгызның үзегезгә тугрылыклы булуларына ышанасызмы?
4) Таныш түгел кеше сезгә “син” дип эндәшсә, сезгә уңайлымы?
5) Эткә яки мәчегә суга аласызмы?

6) Әйбер сатып алуда сез кибетләрне еш алмаштырасызмы?
7) Җәмәгать эшләрен теләп башкарасызмы?
8) Ялгышканыгызны аңлап алгач та, сез үз фикерегезне куәтләргә сәләтлеме?
9) Даруларны еш кулланасызмы?
10) Сезнең белән очрашуга килергә тиешле кешене, түземсезләнмичә, биш минуттан артыграк көтә аласызмы?
11) Уңыш сезне әйләнеп уза дигән фикер еш борчыймы?
12) Дусларыгызның шаяртуларын сез елмаеп кына үткәреп җибәрә аласызмы?
13) Сез ачу саклаучанмы?
14) Сезнең якның климаты бозылган һәм елның һәр фасылында һава торышы гадәттәгедән үзгә тоелмыймы?
15) Иртә таңнан кәефегез бозылганы буламы?
16) Хәзерге заман музыкасы сезне үртәлдермиме?
17) Өегездә чит кешеләрнең булуы туйдырмыймы?

Холкыгызның нинди икәнлегенә ышанасыгыз килсә, тискәре җавапларны санарга кирәк.

Әгәр алар 11 һәм күбрәк булса, сез күндәм, аралашучан, тугрылылы; дуслыкка, кешеләргә мәрхәмәтле. Сезнең белән уртак тел табу җиңел.

Тискәре җаваплар 7 дән 10 га кадәр булганда, сезнең холкыгызга артык ярсучанлык, кешеләргә ышанмау, үпкәчеллек хас дип уйларга җирлек бар.

Әгәр тискәре җаваплар 7 дән аз булса, үзегезнең тар холыклы булуыгызда шикләнмәскә кирәк. Сезгә тормышка һәм башка кешеләр белән аралашуга булган карашларыгызны үзгәртү юлларын эзләргә кирәк.

11. **“Тыңлый белү сәләтегез ни дәрәҗәдә?”** икәнен тикшерегез.

Әлеге тест сорауларына җавап 9 балл белән бәяләнә: 9 балл – сезгә хас булган сыйфатның югары дәрәҗәсе; 1 балл – иң түбән дәрәҗәдәге сыйфат күрсәткече; 5 балл – әлеге сыйфатның уртача чагылышы.

Җавап биргәндә ихласлык төгәл нәтиҗәләрнең җирлеге булып тора.

1) Тыңлаган булып күренергә тырышып, башка нәрсә турында уйлануларыгыз еш буламы?
2) Әңгәмәдәшегез сезгә кызыксыз булса, сөйләшүне йомгаклап куюыгыз еш кабатланамы?
3) Әңгәмәдәшегезнең сөйләм рәвеше һәм үз-үзен тотышы сезнең кәефегезне еш җибәрәме?
4) Аралашканда конфликтлы хәлләргә еш юлыгасызмы?
5) Игътибарын тикшерелә торган мәсьәләнең асылына юнәлә торган репликалар белән әңгәмәдәшегезнең сүзен еш бүлдерәсезме?
6) Терминнар һәм басымнарны дөрес кулланмаганда әңгәмәдәшегезнең сөйләмен еш төзәтеп торасызмы?
7) Әңгәмә, аралашу барышында сезне тавыш күтәрү, дорфа сүзгә дорфалык белән җавап дәрәҗәсенә китереп җиткерү очраклары еш буламы?
8) Әңгәмәдәшегезне еш туктатасызмы һәм бу сезнең гадәтегезгә әйләнмәдеме?
9) Әңгәмә барышында үгет-нәсихәткә күп вакыт сарыф итәсезме?
10) Сезгә ошамаган тема, мәсьәләләр буенча сүз чыкканда, әңгәмәдән читләшүегез еш күзәтеләме?

Балларның санына карап, тыңлый белү сәләтегезне билгеләгез:
79-90 – бик түбән;
71-78 – түбән;
63-70 – уртачадан түбән;
55-62 – уртачадан бераз түбән;
47-54 – уртача;
39-46 – уртачадан бераз артык;

31-38 – уртачадан югары;

23-30 – югары;

10-22 – бик югары.

Тыңлый белү, тыңлый алу дәрәҗәгезне билгеләгәч, үзегезгә җитешмәгән якларны төзәтергә тырышыгыз.

# IV. АРАЛАШУ ДАИРӘСЕН ОЕШТЫРУНЫҢ АЛЫМ-ЧАРАЛАРЫ

## Аралашу оештыруда технологияләрнең әһәмияте

Технологияләр тиешле шартларны һәм алшартларны, мөмкинчелекләрне, нинди дә булса эшчәнлектә файдаланып, нәтиҗәләргә ирешүдә ярдәм итә торган кагыйдәләр, алым-чаралар булып торалар. Вәгазьчеләр әзер алым-чараларны тормышка ашыра, аларны уйланылган рәвештә куллана, берләшмәдәге дәрәҗәләренә карап, үзләре төзи алалар.

Технологияләр аралашу нәтиҗәсендә үзләштерелгән һәм күпмедер дәрәҗәдә үсешкә ирешкән дин әһелләре тарафыннан мәдәни өлге рәвешендә уйланып сайланган тәҗрибә ул. Риторик эшчәнлек, аерым алганда, чыгышларны әзерләү, оештыру, яңача һәм күнегелгән эшчәнлек төрләреннән тора. Бер яктан караганда, технологияләр, кагыйдә буларак, тулаем кабул ителгәнчә тормышка ашырылырга тиеш. Икенче яктан караганда, һәрбер риторик эшчәнлек конкрет характерда һәм һәрвакыт уникаль (кабатланмас) була. Шуңа күрә вәгазьче үзенә кирәкле технологияләрне аерып ала, аралашуның барлык якларын – пафос , этос, логосны – мәҗбүри рәвештә истә тотып куллана.

Кешелек җәмгыяте аралашуны оештыруда зур тәҗрибә, күпсанлы үрнәкләр, технологияләр һәм принциплар туплады. Аларны белү вәгазь сөйләү осталыгын арттыра, ә тиешенчә куллану нәтиҗәле һәм югары мәдәни аралашу мөмкинлеге бирә. Риторика дәресләре һәм махсус шартларда чыгышлар ясау тәҗрибәсе вәгазьче сәләтен барлыкка китерә. Бүгенге көндә әһәмиятле мәдәни үрнәкләргә якынайтылган аралашу оештыра алуын дин әһеленең осталыгы дип санап була.

Һөнәри осталыкка ирешкән зәвыклы оратор (имам-хатыйб) аралашу төрләрен һәм дәрәҗәләрен дөрес бәяләргә сәләтле. Гражданлык һәм менталитет үрнәкләре белән берләштерелгән аралашуның гамәли күнекмәләр җыелмасы һәм имамның шәхси стиле (чыгыш культурасы) булу югары дәрәҗәдә кабатланмас аралашу оештыруга этәргеч булып тора. Югары дәрәҗәдәге вәгазь культурасы дип, аралашу ярдәмендә мәхәлләнең дини ихтыяҗларын тулысынча чынбарлыкка әйләндерү осталыгын атыйлар.

Башлап хөтбә язучылар риторика дәресләре барышында аралашу технологияләрен үзләштерәләр һәм вәгазьче образын тудырып, аларны кулланырга дә өйрәнәләр. Алар үзенчәлекле сәләтнең нигезенә төшенәләр һәм югары мәдәни дәрәҗәдәге профессионалга әйләнүнең кирәклеген дә аңлыйлар. Мондый үсеш теоретик һәм гамәли әзерлекне, шулай ук кабул ителгән һәм гамәли, һәм теоретик тәҗрибәне аерым стильгә әйләндерә баруны, алым-чараларны тормышта тикшереп карауны, мөстәкыйль эшчәнлекне таләп итә.

Бу юнәлештә, күп кенә илләрдә, мәсәлән, АКШ һәм Көнбатыш Европаның кайбер илләрендә белем бирүнең төрле системаларында остаз укытучылар тарафыннан өзлексез дәресләр үткәрелә.

Безнең чынбарлыкта андый дәресләр, кагыйдә буларак, актерлар һәм сәясәтчеләр әзерләүдә тормышка ашырыла. Кайбер гуманитар, хокук һәм башка аралашу осталыгын үстерү кирәк булган күп кешеләр остазлар ярдәменнән башка мөстәкыйль рәвештә дә шөгыльләнәләр.

## Чыгыш темасын сайлау

Профессиональ чыгыш ясаучылар, мәсәлән, укытучылар, имам-хатыйблар, гадәттә, үзләренең мөмкинлекләренә һәм тыңлаучыларның ихтыяҗларына туры килгән темага чыгыш ясыйлар. Яңа гына эшчәнлеген башлаган дин әһеле, мөгаллим һәрвакытта да тыңлаучылар – мәхәлләдәшләре, шәкертләре, теләгенә, ихтыяҗына туры килерлек чыгыш ясый алмый. Теманы ачып бетерә алмау яшь имамның эчке киеренкелеге белән бәйле. Тулы күләмле чыгыш аның зур тәҗрибәсе булганда гына мөмкин. Аңлату юллары исәпсез күп булган мәсьәләләрне тикшерү, тиз төшендерү авыр бирелә. “Йөз кат ишеткәнче, бер кат күрү хәерлерәк” тәгъбирен искә төшерсәк, сәхнәдә актер бик оста сөйли.

Актерлык эше режиссёрлар һәм сценаристлар ярдәмендә барлыкка килә. Актерның төп эше булып “образ”га керү, үзе белән персонаж образын бер итеп тоемлаудан тора. Профессионаллар бу эшне тулаем башкарып булмаганны беләләр һәм бу тамаша сәнгатенең бер сере булып тора. Ә яшь имамның үзенә актер да, сценарист та, үз-үзенә режиссёр да булырга туры килә.

Универсаль оратор үз сөйләмен, предметны күз алдына китерүдән башлап, тыңлаучының аның фикеренә кушылуына кадәр үзе оештыра. Чыгышны яхшы башкару өчен ораторның билгеле

бер язмасы булырга, сөйләмнең образын булдырырга һәм тыңлаучыны шушы образга берләштерергә кирәк. Әлеге эшчәнлекнең төп чыганагы булып компетентлык һәм аралашу куәсе тора. Алар тыңлаучыларны сөйләм даирәсенә күчерергә ярдәм итәләр. Әлеге шартлар булганда, чыгыш ясаучының тоткан урыны шушы чыганакларны берләштерү осталыгына һәм нәтиҗәле кулланыуына бәйле.

Яңа гына эшчәнлеген башлаган дин әһеленә әлеге өстенлекләр, кагыйдә буларак, җитми, шуның өчен аларга үзләренең эчке мөмкинлекләрен куллану мөһим. Әлеге чыганакның төп төре булып, имамның предметны яхшы белүе һәм аңа кызыксынулы караштa булуы тора. Шәхеснең әлеге үзенчәлекләре компетентлы һәм дулкынландыргыч чыгыш оештырырга ярдәм итә.

Тагын бер кат шуны кабатлап үтәсе килә: һәрбер вәгазь (чыгыш) эчке теләк, әзерлек, хисси көч таләп итә. Әлеге мөмкинлекләр тыңлаучыга тәэсир итү өчен кирәк. Шуның өчен дә вәгазь темасын дөрес сайлау бик мөһим.

## Сөйләм эчтәлеген төзүнең билгеле алымнары

Сөйләм эчтәлеге – тематик кыр − оештыруда беренче адым булып сөйләм концепциясен (ниятен) тудыру тора. Сөйләмнең концепциясе итеп аның мәгънәсен исәпләргә кирәк. Сөйләмне мәгънәви яктан эшкәртүне товарны әйләнешкә кертүгә әзерлек белән чагыштырып була. Технологик яктан караганда, концепция оратор образы белән туры килгән пафос, этос, логос һәм сөйләм эчтәлеген берләштерүне күздә тота. Икенче төрле әйткәндә, сөйләмнең нияте түбәндәге сорауларга җавап табарга ярдәм итә: нәрсә әйтергә? Ни өчен әйтергә? Ничек әйтергә? Кемгә әйтергә? Тыңлаучыларны үз карашларыңа ничек күндерергә?

Тулы концепцияне төзү бик җиңел эш түгел. Концепцияне эшләү чыгышка әзерләнүдән башлана, аның бөтен барышында дәвам итә, чыгыш яссылыгында чагыла һәм чыгыш беткәч тә тәгаенләнә. Концептуаль эшчәнлек − ораторның акыл байлыгы, зирәклеге. Кагыйдә буларак, тәҗрибәле чыгыш ясаучылар зур осталыкка ирешкән фикер ияләре булып торалар.

Тәңгәл туры килгән ният һәм эчтәлек, хәтта, бик кыска чыгышны да нәтиҗәле итәргә ярдәм итә. Үз чиратында, ниятенә туры килмәгән, уңышлы исәпләнерлек чыгыш та “һавада эленеп калырга”, аны үтемлелектән мәхрүм итәргә мөмкин.

Концептуаль эшчәнлекне (ниятне тәгаенләүне) чыгышның максатын аңлау һәм оештыру белән бәйләп карыйлар. Концептуаль эшчәнлекнең башлангыч стадиясенә сөйләм предметын, темасын, төп проблемаларын кертеп тикшерәләр. Предмет сөйләмгә эчтәлекнең чыганагы буларак карый, ул материаль да, идеаль да була ала. Сөйләмнең эчтәлеге белән предметы арасындагы бәйләнеш аралашу максатыннан чыгып билгеләнә. Аралашу белән предмет арасында бәйләнеш төрлечә булырга мөмкин, шул исәптән символик та, ирекле дә. Сөйләмнең темасын үзгәртү максатыннан аралашу предмет эчтәлегенең һәм сөйләм эчтәлегенең туры килүен таләп итә.

Сөйләмнең темасы фикерләү нәтиҗәсен тәшкил итә, предметны күзалланган яки идея дәрәҗәсендә ачыклый. Пост-модерн үрнәгендә сөйләм темасы ачык системаны һәм плюрализм законнарына буйсына торган аңлатуны күздә тота. Ә бу исә үз чиратында сөйләм темасының чиктән тыш субъектив булуын һәм аны сөйләм тудыручының иҗаты икәнлеген күрсәтә.

Классик традиция сөйләмнең темасын кабул ителгән үрнәк кагыйдәләр буенча оештыруны таләп итә. Мәсәлән, вернисаж оратордан яңалык һәм үз иҗатын чагылдыруны таләп итсә, диплом эшен яклау – квалификация нормаларын үтәүне күз алдында тота.

Чыгышның хәл ителәсе төп соравы – тыңлаучы өчен әһәмияте булган каршылыклар җыелмасы. Чыгыш барышында каршылыклар туа, тикшерелә һәм хәл ителә. Чыгышларны болай оештыру аудиториянең кызыксынуы һәм игътибары артуга ярдәм итә. Иң нәтиҗәле чыгыш булып, исбатланасы, хәл ителәсе әлеге мәсьәләләрне тыңлаучылар ярдәме белән чишү тора (Сократ диалоглары).

Димәк, сөйләм кырын тематик яктан оештыру фикерләү дәрәҗәсе белән бәйле билгеле бер алым-чараларны тормышка ашыру дигән сүз. Һәрбер чыгыш ясаучы боларны белергә тиеш. Хәл ителәсе мәсьәләләр чагылышы булып берләшмәнең үзгәртүләр таләп ителгән эшчәнлеге була ала. Бу очракта чыгышның темасы булып, берләшмәнең нинди дә булса хәл ителәсе каршылыгы тора. Чыгыш структурасын төзү өчен эчтәлекләре буенча туры килгән мөмкинлекләрне һәм берләшмәнең кабул ителгән казанышларын кулланырга кирәк.

Бу очракта аралашу, берләшмә мәнфәгатьләре һәм проблемалы танып белү элементларыннан торган эшчәнлекнең катлаулы

рәвешенә әверелә. Эшчәнлекнең болай оешуы риторик элементларны тормышка ашыруны күздә тота. Аларның асылы булып тыңлаучыларны бүгенге әһәмиятле мәсьәләләр яссылыгына күчерү һәм берләшмәдәге билгеле бер яңа карашлар белән таныштыру тора.

Гадәттә, аерым чыгышлар гадиерәк төзеләләр. Аларны тормышка ашыру өчен яңалык түгел, ә таныш мәгълүмат, гадәти мөмкинлекләр кулай.

## Сөйләм ниятен тәгаенләү

Ниятне (концепцияне) рәсмиләштерү өчен эчтәлекне тезис жанрында таркату уңышлы алым дип санала. Тезис рәвешендәге эчтәлек кыскача оештырылган төп кагыйдәләр системасы буларак бәян ителә. Тезислар композициясе кыскача керешне, тупланган эчтәлекне, йомгаклау тезисын берләштерә. Ораторның анык сөйләме, чыгыштагы карашларны аныклый һәм үзенең образын күркәмли.

Яңа гына вәгазь сөйли башлаучылар өчен концепция төзү, фикер эзлеклелегенә ирешү авырлыклар тудыра. Бу хәл концепцияне бары тик автор буларак кына төзи алу, аны башка автордан үзләштерү кыенлыгы белән аңлатыла. Чит концепция аз нәтиҗәле, чөнки ул бөтенләй башка сөйләм халәтен чагылдыра.

Ният эшкәртү алгоритмы түбәндәге рәвештә булырга мөмкин:

- предметны һәм сөйләм темасын шәхси аңлауга ирешү;
- сөйләм темасын хәл ителәсе мәсьәләләр рәвешендә чагылдыру;
- шәхси һәм берләшмә тәҗрибәсе, шулай ук әдәбиятта тупланган белем нигезендә мәсьәләне тикшерү;
- үз сөйләм эчтәлегендә берләшмәдә кабул ителгән үрнәкләрне эшкәртү һәм ораторның шәхси карашларын оештыру.

Әлеге алгоритмның эчтәлеге югары акыл эшчәнлегенә һәм тикшеренү мөмкинлекләренә ия булуны таләп итә. Мәсәлән, шәхси сөйләм темасын тормышка ашыру өчен, белем һәм мөстәкыйль фикер йөртү сорала. Теманың хәл ителәсе мәсьәләләр рәвешендә чагылышы сөйләүченең фәлсәфи фикер йөртергә әзер булуына бәйле, ул берләшмә тәҗрибәсе үрнәкләренә, дәлилләү, танып белү, текст төзү культурасына ия булганда гына мөмкин.

Ният оешуның башлангыч этабы психиканың интроверт төзелешкә туры килүе белән катлаулана, әйтеп киткәнебезчә,

җитештерү культурасы экстраверт характерда. Шул сәбәпле безнең сөйләм кырыбызда калыплашкан үрнәкләр хакимлек итә.

Аралашу даирәсендә килеп туган хәлләрне үзгәртү бик авыр. Кешеләр берләшмә эшчәнлегендә җаваплылык тойсыннар өчен үзләре бу эшчәнлекне актив оештыручылар булырга тиешләр.

***Сөйләм оештыруда уйлап табуның әһәмияте***

Сөйләм ниятен төзү аралашу даирәсен оештыруда мөстәкыйль жанр булып тора. Ният сөйләм текстына гына түгел, барлык аралашу өлкәсенә карый. Хәзерге заман риторикасындагы аралашу ниятен оештыру, үзенең "уйлап табу" һәм "урнаштыру" өлешләре белән борынгы ораторларның классик кануннарына туры килә. Аралашуны әзерләүнең башлангыч этабында төп таләп булып сөйләмнең ниятенә туры килүе тора. Башлап вәгазь сөйләүчеләр фикерне урынлы куллану мәсьәләсен әлеге сорауларга җавап биреп аңларга мөмкиннәр:

- Вәгазьче кем ул, аудиториядә аның әһәмияте?
- Аралашу узачак аудиториянең составы нинди?
- Дин әһеле (оратор) һәм аудитория мөнәсәбәтләрендә вәгазьнең (чыгышның) предметын һәм темасын нәрсә тәшкил итә?
- Тыңлаучыларның мөмкинлекләренә таянып, теманы ничек аңлатырга?
- Аралашуны вәгазьнең нинди жанрында тормышка ашырырга?

Аралашуны шулай оештыру сөйләмне әзерләгәндә аеруча мөһим, ләкин безнең аралашу даирәсендә бик авыр кабул ителә, чөнки без, күп очракта, буйсынучанлык мөнәсәбәтендә. Бу мөнәсәбәт аралашуны әзерләгәндә югарыда китерелгән сорауларга җавап бирүне күздә тотмый.

Сөйләмнең урынлы булуы яки ниятенә туры килүе аралашуның идеал үрнәкләренә һәм күрсәткечләренә туры килүе ул.

Сөйләм ниятен уйлап табуны түбәндәге принциплар җыелмасы ярдәмендә күрсәтергә мөмкин:

- мәгънәви яңалыкларга ия булганда гына сөйләм үтемле була;
- конкрет чыгыштагы яңалыклар һәрчак аралашу күрсәткечләренә туры килә, алар килеп туган хәлләргә бәйле рәвештә оештырылалар;
- мәгънәви яңалыклар куллану вәгазьче һәм тыңлаучылар карашларына яңалыкны күчерә торган гомуми алымнарга бәйле;

- сөйләм стиль таләпләренә туры килергә тиеш.

Сөйләмнең семантик һәм стилистик туры килүен оештыру принципларына тукталыйк. Аристотель риторикасында сөйләмдә **гомуми урыннар** яки **топослар** куллану җентекләп тикшерелә. Аларга аралашу процессында бердәм мәгънә кыры барлыкка китерә торган мәгънәле (семантик) үрнәкләрне кертәләр. Топослар үзләре – таныла, аңлашыла, гомуми кыйммәтләргә туры килә һәм сөйләмнең йогынтысын үстерергә булыша торган мәгънәви фигуралар. Метафорик яктан топосларны файдалану вәгазьчегә тыңлаучылар белән «бер телдә» аралашырга мөмкинлек бирә. Тәҗрибәле имам топосларны кулланып, аралашуны күпкә җиңеләйтә, аңлаешлы итә, мәгънәви һәм карашлар тәңгәллегенә шартлар тудыра.

Стилистик туры килү эчтәлекнең һәм текстның мәгънәви уйланылган булуы ул. Шулай ук, вәгазь ниятендә аларның аерым жанр үрнәкләренә, замана шаукымы үрнәкләренә иярүне; шәхси стиль элементларын тормышка ашыруны күзәтергә мөмкин. Стиль сүзләр сайланышын, сөйләм фигураларын, сөйләм тропларын һәм сөйләм ритмын билгели. Стильне сөйләмнең нинди дә булса башка чагылышы аша бирелгән үзенчәлегенә кертергә мөмкин. Ул бары тик кешенең мәдәни дәрәҗәсе ярдәмендә генә аңлашыла. Сөйләм стилен камилләштерә торган технологияләр куллану да уңайсыз, чөнки стильнең туры килүчәнлеген бары тик мәдәни үсеш һәм зәвык аша гына аңлый алабыз.

Вәгазьләүне яңа башлаучылар ниятне читтән алуга омтылып, нинди дә булса эшчәнлектә танылу мөмкинлекләрен һәм иҗади сәләтләрен юкка чыгаралар. Ә мондый очракта нәрсә эшләргә? Дин әһеленең дәрәҗәсе, тәҗрибәсе кимрәк булганда, ул үзенең эчке мөмкинлекләренә ныграк таянырга тиеш. Моннан тыш, абруйлы имамнарның хупланган үрнәкләренә мөрәҗәгать итәргә һәм остазлар белән ешрак киңәшергә кирәк. Сөйләм ниятен оештыру һәм аны уйлап табу иҗади эшчәнлек төре булып тора, һәм ул мәдәни-риторик хезмәт нәтиҗәсендә генә камилләшергә мөмкин.

## Сөйләмдә дәлилләрнең урнашуы яки композиция

Сөйләмнең төп нияте аның күп кенә кисәкләренең урнашуын ачыклый, чыгышның нәтиҗәлелеген күтәрү максатында гомуми төзелешен тәгаенли. Башка сүз белән әйткәндә, төп фикерләрне туплау, әйтелмәләр җыелмасы төзергә ярдәм итә, алар үз чиратында дәлилләр дә булып киләләр, тезисның дөреслеген исбатлыйлар һәм оратор карашларын яклыйлар.

Уй-ниятләрдән оратор технологияләр этабына күчә, башкача аны "урнаштыру" дип йөртәләр. Риторикада **урнаштыру** – ул сөйләм уеның сүз белән белдерелгән рәвешен табу яки төрле фикерләр җыелмасы булдыру, композиция барлыкка китерү. Композиция – система буларак, борынгы риторикаларда эшләнелә, шуннан бирле бернинди үзгәрешләр дә кичермәгән дияргә була.

Классик композиция кануны дәлилләүнең 8 төп өлешен берләштерә, тыңлаучыларга оратор (вәгазьче) карашларын кабул итүдә ярдәм итә. Композиция, нык тәэсир көченә исәпләнеп, сөйләм өлешләренә бүленгән эчтәлекне урнаштыруда булышлык күрсәтә. Композиция элементларына: мөрәҗәгать, тема атамасы, хикәяләү, тасвирлау, раслау, кире кагу, өндәмә һәм йомгаклауны кертәләр.

Сөйләмнең тәэсирен арттыру өчен иң көчле дәлилне чыгышның ахырына – ягъни өндәмә өлешенә куялар. Кайвакыт сөйләм өлешләре урыннары белән алмашалар. Андый композиция **инверсияле** дип атала. Мәсәлән, иң көчле дәлил чыгышның башында да булырга мөмкин.

**Мөрәҗәгать** үзенең урнашу урыны белән кереш өлешкә туры килә, аның вазифасы аралашу даирәсенең башлангыч өлешен төзүдән гыйбарәт. Мөрәҗәгать озак вакытлар ритуал рәвешендә була. Аның эчтәлегенә ораторны тәкъдим итү; ораторның теләкләрен тыңлаучыларга анлатуы, аларны аралашуга чакыруы һәм, кереш сүз итеп, максатларын әйтүе керә. Билгеле кысалардагы мөрәҗәгать (мәсәлән: Хөрмәтле тамашачы!) әдәбият кичәләренә, театр һәм шәһәр мәйданнарына күчә, ә оратор мөрәҗәгате үзе сайлаган гадәти этикетка әйләнә һәм ирекле рәвештә яңгырый башлый.

**Теманың атамасын**, сөйләм өлеше буларак, болай башлау тәкъдим ителә: тыңлаучылар ораторның кем булуын, максатын, чыгышы темасын, һәм тыңлаучыларга, темага мөнәсәбәтен

аңларлык булсын. Мәгълүмат аңлаешлы итеп әйтелә һәм бөтен тыңлаучыларга юнәлдерелә. Мондый сөйләм өлешләренең максаты – тыңлаучыларның игътибарын аралашуга юнәлдерү һәм оратор белән публика арасында ныклы элемтә булдыру. Уңышлы башлам – чыгышның нәтиҗәлелегендә чагыла.

**Хикәяләү –** тынлаучыларны сөйләм предметы белән таныштыру һәм теманың тарихи чагылышын күрсәтү вазифаларын үти. Хикәяләү теманың төп мәсьәләләрен ачыклый. Аралашу предметының аңлатмасын дөрес күрсәтү бик әһәмиятле. Хикәяләү төп дәлилләрнең нигезен һәм теманың **тасвирлама** өлешен тәшкил итә.

Тасвирлау чыгышның эчтәлекле өлеше һәм, өлешчә, үзәге булып тора. Тасвирлау сөйләм темасын, максатчанлыгын ачыкларга, сөйләүчегә һәм тыңлаучыга чыгышның әһәмиятен аңларга ярдәм итә. Чыгышта тасвирлау ярдәмендә тезисның тормышка ашырылуы күзәтелә. Тезисның әһәмиятле фикерләре төзелгән, система буларак каралган, аралашу җирлегенә күчерелгән һәм хәл ителгән булырга тиеш. Тасвирлауның югары үрнәге булып, анык, төгәл, тикшерелгән тезис тора, тик ул дәлилләүгә мохтаҗ.

**Дәлилләү** – мәгънәви раслау өлешенә карый, ул тезисның хаклыгын белү өчен билгеләнгән. Тезис дәлилләр ярдәмендә исбатлана, ә ул үз чиратында чыгышның дәлилләр җыелмасында урнашкан була. Дәлилләү – мәгънә ягыннан оештырылган әйтемнәр һәм фикергә нәтиҗә ясауда чагыла. Моннан башка дәлилләү мисаллар, тәҗрибә нәтиҗәләре ярдәмендә башкарыла.

Мәгънәви дәлилләү индуктив һәм дедуктив фикерләр чылбыры ярдәмендә башкарыла. Дәлилләүгә катгый охшашлык кирә, ләкин онытмаска кирәк, охшашлык белән генә дәлилләүдә дөрес нәтиҗә ясап булмый. Хакыйки (чын дөрес) дәлилләргә дедуктив фикерләү алып килә. Шулай ук, индуктив фикерләү дә дөрес булырга мөмкин. Катгый рәвештә дәлилләү булып дедуктив фикерләр чылбыры тезү, тулырак йомгак булып, тиңләштерүгә нигезләнгән сөйләм тезисы тора.

**Кире кагу** – дәлилләүнең киресе. Кире кагуның максаты каршы як яңгыраткан тезисның асылын ачыклаудан гыйбарәт. Кире кагу, тезисның ялганга (бәлки) корылган сөйләм икәнен күрсәтүгә нигезләнгән.

Кире кагу, сөйләм өлеше буларак, тезис дәлилләүне көчәйтә һәм чыгыш ясаучының карашларын ныгыта.

**Өндәмә** чыгыш ясаучының фикерен тагын да көчәйтеп җибәрә,

чөнки тезисны тойгылы рәвештә ирештерә, чыгышның эчтәлеген кичерешләр өлкәсенә алып керә. Кичерешләр тезис буенча күзаллаулар бәйләнешенә, тыңлаучылар, оратор яки тулаем берләшмәнең рухи халәтенә бәйле була. Кичерешләр билгеле бер вакыйгалар үсешендә барлыкка киләләр, алар тезисның эчтәлеге яки аралашуда катнашучы төрле кешеләрнең хисләренә бәйле. Кичерешләр тезисның гореф-гадәткә мөнәсәбәтенә дә, кабул ителгән үрнәкләргә яки төркем эшчәнлегенә, әдәбият яки көнкүреш кыйммәтләренә бәйле рәвештә оешырга мөмкин.

Аристотель аралашуга тәэсир итә торган иң көчле кичерешләр дип, мәхәббәт һәм нәфрәт тойгыларын санаган. Тәэсире көчле булганнарга: курку, хәлгә керү, мәрхәмәтлелек, кыен хәлне гамәли уртаклашу, ышануны һәм өмет тойгыларын китерергә мөмкин.

Тәэсирле өндәмә аралашуны зәвыклырак итәргә, аны тамаша сәнгате дәрәҗәсенә күтәрергә мөмкин.

Әгәр чыгыш уңышлы булса, **йомгаклау** өлешендә оратор бөтен сөйләгәннәрен кыскача кабатлый һәм тыңлаучыларга нык тәэсир иткән хис халәтен тагын бер кат кичерергә ярдәм итә. Йомгаклау өлешендә төп фикерләрне мәгънәви басым белән аерып кабатлау эчтәлекне ныгытуга алып килә.

Текст төзүдә, төп фикерләре дә яхшы әзерләнгән булса, композиция мөмкинлекләрен куллану – сөйләмнең тәэсирен күп тапкырлар көчәйтә.

Күргәнебезчә, классик композиция эчтәлекне оештыруда тармакланган төзелеш тәкъдим итә. Күптөрле композиция чаралары тыңлаучыларның игътибарын сөйләүчегә һәм чыгышның эчтәлегенә юнәлдерергә; чыгышның башламында кузгатылган мәсьәләдә тарихи үсешен хикәяләргә, аның эчтәлеген тасвирлау рәвешендә чагылдырырга һәм актуальлеген күрсәтергә, аны тезис рәвешендә чишәргә булыша.

Классик композиция безгә тезисны турыдан-туры һәм читләтеп раслауда, күптән кабул ителгән көчле дәлилләр кулланууны, шулай ук, өндәмә рәвешендә сөйләп, чыгышның тәэсирчәнлеген арттыруны тәкъдим итә.

Тулаем алганда, җыйнак, уңышлы композиция ораторның дәлилләрен көчәйтеп, тыңлаучыларның үз карашларын булдыруда да ярдәм итә.

## Чыгыш текстын әзерләү,
## алдан кабатлау

Чыгыш оештыруның төп өлеше – текст төзү. Әзерләнүнең бу төре башлап чыгыш ясаучылар (яшь имамнар) өчен мөһим, чөнки аларның сөйләмнәре автоматлаштырылмаган, һәм чыгыш ясауны җиңеләйтүдә күп кенә өстәмәләргә мохтаҗ. Чыгышта алар өчен киң таралган чыганак – алдан әзерләнгән текст. Текстны язмача әзерләгәндә сөйләп аңлатуны гына игътибарларга түгел, ә чыгыш ясаганда әһәмиятле булган ярдәмче гамәлләрне дә исәптә тотарга кирәк.

Сөйләм һәр кешенең үзенә генә хас сыйфаты булып тора һәм аралашу вакытында кешенең образын (йөзен) ачып сала. Сөйләм бу мәгънәдә, төп-төгәл итеп, кешенең эчке дөньясын, рухи яшәешен күрсәтә. Риторика – сөйләмнең үзенә генә хас билгеләрен законнар һәм кагыйдәләр рәвешендә гомумиләштерә, ә алар үзләре төрле мәдәни үзенчәлекләргә ия. Риторика кагыйдәләрен куллану тыңлаучыларның чыгыштагы фикерләргә, оратор күз алдында торган мәгънәгә юнәлдерергә, карашларын үзгәртергә, аралашу барышын яңадан төзергә булыша.

Һәрбер аралашу төп максатчан мизгелләрне генә түгел, ә үзенчәлекле аерым кисәкләрне дә берләштерә. Дөресен әйткәндә, сөйләм үзенчәлекле күренеш, билгеле күләмдә бертөрле кагыйдәләрдән генә түгел, ә күпсанлы яңалыклардан тора. Текст, бер карасаң, гел бертөрле мәгънәгә ия кебек, тик чыгыш ясауда күптөрле мөмкинлекләр чыганагы булып тора, чыгыш оештыручының сөйләм һәм рухи үзенчәлекләрен чагылдыра. Бу хәлне аңламау нәтиҗәсендә, башлап чыгыш ясаучыларның күпчелеге, текстны башыннан ахырына кадәр укып кына чыгалар. Текст башка автор тарафыннан язылган булса да, күпчелек чыгыш ясаучыларны бу хәл куркытмый, хәтта табигый очрак кебек кабул итеәә. Ләкин башка автор язган текст белән чыгыш ясау, күз бәйләп, качышлы уйнауга тиң.

Кайбер ораторларга текстның чыгыш вакытында кирәк булмавы, ә башкаларның текстан башка сөйли алмавы аны әзерләүгә төп караш булып тора. Хәзерге риторикада текстсыз чыгыш ясау кире кагылган һәм онытылган. Бу хәл тоталитаризм чорында аралашу эчтәлеге белән идарә итү өчен барлыкка килә. Чыгышның тулы текстын язу аралашу практикасын, сәяси мәсьәләләрне игътибар үзәгендә тотуны җиңеләйтә.

Һәрбер башлап чыгыш ясаучы үз үзенчәлекләрен истә тотарга һәм сөйләмендә, ихтыяҗына карап, язма чыганаклардан файдалана белергә тиеш. Чыгыш вакытында, “текст” булып кулланылачак язма ораторның күзаллавына туры килгән сөйләм рәвешенең төп язмасы хәленә җиткерелергә тиеш.

Онытмаска кирәк, тыңлаучылар белән чыгыш вакытында аралашу, аларны гипноз хәленә кертә һәм вәгазьченең мәхәлләдәшләренә, мәсәлән, вәгазь вакытында, булган йогынтысын көчәйтә. Үз чиратында текстны аңлаешлы, сәнгатьле генә уку, вәгазьченең тыңлаучыларга йогынтысын тиз киметә һәм аны сөйләм эчтәлеге, сөйләүченең тышкы образы белән генә чикли. Шуңа күрә, махсус әзерләнгән вәгазь тексты, эчтәлеге һәм сөйләм рәвеше белән вәгазьченең ихтыяҗларына туры килеп, аның мөмкинлекләрен күпкә арттыра һәм аралашу даирәсен киңәйтә.

Текстның мөмкинлеген арттыруда, икенче хәлиткеч мизгел – аның эчтәлеге төзелеше. Текстның төп вазифасын түбәндәге сораулар ачыклый: “Нәрсә әйтергә?”, “Ничек, ни рәвештә? Нинди вербаль чаралар белән?” Язма текст әдәби эшләнмә генә түгел, ә чыгыш жанрының җирлеге дә булырга тиеш. Чыгыш жанрының үзенчәлеген аңлар өчен, “Мин нәрсә сөйлим?” соравына, “Бу эчтәлек тыңлаучыларга ничек тәэсир итәр икән?”– дигән сорауны да өстәргә кирәк. Бу сораулар бөтен текстка кагыла: һәрбер өлештә, текстны үзе төзеп чыгыш ясаучы, нәрсә сөйләвенә, аның тыңлаучыларга тәэсиренә игътибарлы булырга, язма текст һәм чыгыш тексты “Оратор карашына якынайтамы?” дигән сорауга җавап бирергә тиеш.

Текстның үзенчәлегенә тәэсир итә торган өченче шарт – текст төзүченең психологик халәте. Әйтеп киткәнебезчә, кабатланмас шәхес интроверт яки экстраверт юнәлешкә омтыла. Интровертлар дөньяны табигый рәвештә кабул итәләр һәм тышкы дөнья объектлары белән мөнәсәбәтне шәхси яссылыкта оештыралар. Экстравертлар, үз чиратында, кешегә бәйсез булган объектларга, аларның эчтәлегенә, асылына юнәлгәннәр. Кешеләр төрле психик үзенчәлекләргә ия булулары сәбәпле, бу җайланмаларны йөртүчеләр, үзләре дә белмичә, бер-берсен аңламыйлар.

Үзләренә нык ышанган интровертлар һәм экстравертлар чыгыш эчтәлегенең, үз карашларының капма-каршы җайланмалы кешеләр тарафыннан кабул ителү мөмкинлегенә, ысулларына юнәлдерергә тиешләр. Бу аралашу аңлаша алмаучы кешеләр өчен мөһим, алар

башкалар белән аралашканда, үзләренең карашлары белән санашмыйлар дип уйлап, тискәре тойгылар кичерәләр. Хәзерге заманда экстраверт җайланмалар өстен торуын онытмаска кирәк, шуңа күрә бу кагыйдәне интровертларга кулланырга кирәк, чөнки алар югарырак мәдәни фикерләүчеләр үзләрен аңламыйлар дип кыенсыналар.

Чыгыш вакытында текст тыңлаучылар белән төпле аралашу урнаштыру максатыннан кулланыла. Ул оратор ихтыяҗларына туры килгән сөйләм рәвеше, ә сөйләмнең эчтәлеге – тыңлаучылар мөмкинлегенә исәпләнгән булырга тиеш.

Һәрбер башлап чыгыш ясаучының сөйләме ике төрдә: беренчесе, язма әдәби сөйләм төрендә чыгышның тулы тексты. Сөйләмнең бу төре әдәби эшчәнлек нормаларына туры килергә һәм аның мәдәни казанышына әверелергә мөмкин.

Икенче төр текстлар һәрбер ораторның аралашу рәвешенә якынайган булырга тиеш.

Тыңлаучылар алдындагы вәгазь һәм аның язмача тексты бер-берсеннән аерылалар. Вәгазь текстында аралашуның риторик мизгелләре чагылыш табарга тиеш. Яшь дин әһелләренең риторик алым-чаралардан файдалана белмәүләре яки кулланмаулары зур ялгыш.

Вәгазь тексты канунлашкан, классик текстларга (Коръәни-Кәрим, тәфсирләр, хәдисләр, ислам дөньясында танылган дин белгечләренең) таянып язылса, имамның үз холык-фигыленә, аның образына туры килсә, бигрәк уңышлы була.

## ***Вәгазь тексты язу***

Вәгазь текстының кереш өлешен язганда, иң элек, аның сөйләү өчен кулай рәвешен билгеләргә кирәк. Кабул ителгән таләпләрдән тайпылмаска тырышу, вәгазь текстын һәрвакыт күз алдында тотуны кагыйдә дәрәҗәсенә җиткерде. Бу кагыйдә вәгазьчегә ярдәм түгел, ә контроль функциясен үти.

Чынлыкта исә, дин әһелләренең текстка карата мөнәсәбәтләре төрле: вәгазьдә текстны кирәк дип санаучылар, көтелмәгән очракларда гына файдаланучылар һәм вәгазьне тексттан башка сөйли алмаучылар бар.

Технологиясе ягыннан караганда вәгазь текстлары оешуның ике төре бар: хәзерләнгән һәм яраклаштырылган. Хәзерләнә торган текстлар хөтбә эчтәлеген тулыландыра, ә яраклаштырылганнары –

вәгазь вакытында ярдәм итә. Текстлар, чынлыкта, һәр вәгазьченең осталыгына, әдәби мөмкинлекләренә, ихтыяҗына туры китерелеп, шәхси рәвештә төзелә.

Хәзерләнә торган текстның технологиясен карап үтик, икенче төрле аны конспект дип тә йөртәләр. Мондый текст хәзерләү сөйләмнең ниятенә бәйле. Интроверт өчен текст план-конспект рәвешендә ниятне язу. Экстраверт өчен, конспект тулы эчтәлеге язылган һәм нәтиҗә өлешендә төп карашлар чагылыш тапкан язма. Хәзерләнә торган текстның авыр төре – билгесез аудитория өчен универсаль сөйләм вариантын язу.

Төзелеше ягыннан хәзерләнгән текст шәхсән белгәннәрдән һәм үзләштерелгән эчтәлекнең берләшүеннән оеша. Башлап вәгазь сөйләүчеләргә текстагы үзенең һәм читтән алынган эчтәлекне аерып куярга, чыганакларны күрсәтеп барырга кирәк. Үз карашларыңны, бәяңне белдерү мәҗбүри эш, тик башкалар фикерен үзеңнеке итеп танытырга тырышу килешми. Нәтиҗәдә, конспект нияткә туры килгән эчтәлекле мәгълүматны берләштерә. Аның төзелеше вәгазьченең хәтер үзенчәлегенә бәйле. Конспектның план, тезислар җыелмасы яки тулы текст ук булуы мөмкин.

Яраклаштырылган текст аралашуда ярдәм итәрлек мәгълүмат тупланган язманы күз алдында тота. Вәгазьнең нәтиҗәлеген арттыру өчен махсус эшкәртелгән текстлар да була, чөнки мәгълүмати технологияләр төрле алымнар кулланырга мөмкинлек бирә. Төрле алымнар рәтенә шрифт рәвеше, таблица, интерваллар зурлыгы, төсләр белән аерымлау, рәсем керә. Бу чаралар текстны образлы күзаллауга әйләндерү өчен кирәк.

Текстсыз вәгазь сөйләүчеләргә яраклаштырылган текст рәвешен хәтердә калдыру шарт. Һәрбер язма текстта вәгазьнең якынча планы, тезис рәвешендә булса да, эчтәлек бирелсә, бигрәк тә әйбәт була.

Текстта истә калдыруы читен төшенчәләр булырга мөмкин. Алар рәтенә алынмалар, терминнар, цитаталар, саннар керә. Бу кыенлыкларны яшь имамнар, сөйләгәннәре аңлаешлы булсын өчен, төрле җиһаз, плакат, компьютер кулланып җиңәләр, төп төшенчәләрне әйтеп яздыралар, балалар укытканда дидактик карточкалардан файдаланалар.

Текст сөйләм вакытында бары ярдәмче рольне генә үти: һәрбер хөтбәче текст төзүдә үз алымнарын, шәхси стилен булдыра.

### *Вәгазьне алдан кабатлау*

Вәгазьче риторик осталык һәм мөмкинчелекләргә ия булса да, аудиториягә яраклаштырылган текст һәм аралашуга алдан әзерлек – уңышка ирешү чыганаклары. Әйтеп киткәннәрдән күренгәнчә, дин әһеле вәгазь вакытында, күп микъдарда көч сарыф итә; бер үк вакытта, чикләнмәгән күләмдә, төрле вазифа башкара. Вәгазьче остарган саен күптөрле гамәлләрне автоматик рәвештә башкара. Мондый мөмкинлекләрне риторикада профессиональ, сәнгати аралашу дип йөртәләр.

Алдан кабатлауның вазифа-бурычлары түбәндәгеләр:

- чыгыш эчтәлеген үзләштерү;
- яраклаштырылган текстны тикшереп, эшкәртеп чыгу;
- тыңлаучылар белән аралашуны алдан уйлап кую, кара-каршы сөйләшүгә әзерләнү;
- үз-үзеңә ышаныч тудыру, хәзерләгән текстка һәм булачак сөйләмеңә карата уңай хисләр, яхшы фикер булдыру;
- нәтиҗәле хәзерлек һәм чыгыш ясау өчен көч туплау.

Чыгышның эчтәлеген уку барышында, хәтергә сеңдергәндә тупланган тәҗрибә нәтиҗәләрен һәм шәхсән тикшерелгән алым-чараларны үтәргә кирәк. Истә калдыру чаралары күп: уйланудан (медитациядән) алып ятлауга кадәр. Истә калдыруны җиңеләйтү өчен, иң беренче эчтәлекнең конспектын төзергә яки үзеңдәге барлык белемнәрне хәтердә яңартырга кирәк. Текст эчтәлеге никадәр тулырак язылса, булачак вәгазь эчтәлеген бербөтен итеп истә калдыру шулкадәр җайлырак. Эчтәлекне шәхси тәҗрибә белән бәйләү бик файдалы. Медитация белән эш итүче вәгазьчеләргә, эчтәлекне уйлар чылбыры итеп тезү өчен, билгеләнгән вакыт чикләрен исәптә тотарга туры килә.

Эчтәлекне хәтерләүдә иң нәтиҗәле ысул – мәсәлән, вәгазьгә әзерләнү максаты белән эчтәлекне кабатлауда төп фикерләр чылбырын хәтергә беркетү. Хәтер ныгытуны язмача да үтәргә була. Мәсәлән, структур схемалар, график һәм рәсем, фразалар язып кую рәвешендә, техник чаралар кулланып абзацлар башламын, аңлаешлы символлар, шартлы билгеләр рәвешендә. Яхшы ысул булып, текстны кат-кат уку һәм телдән сөйләү санала. Истә калдыруны төрләндерә торган саен, яхшырак нәтиҗәгә ирешелә. Хәзерләнгәндә иң куркынычы – вәгазьләүдән курку хисенә бирелү.

Тискәре хисләрне контрольдә тотарга һәм юк-бар уйларны читкә кагарга кирәк.

Вәгазьдә, уңышсызлыктан саклану чарасы буларак, аудитория мөмкинлекләренә яраклаштырылган текст куллану зарур. Алдан әзерләнү вакытында текстны нык үзләштерергә кирәк, чөнки белгәнне кулланганда тыңлаучылар белән үтемле аралашып була.

Дөньяви эчтәлекле текстны чикләнгән күләмдә кулланганда тыңлаучылар белән аралашу һәм фикер эзлеклелеген сиздереп бару авыр. Кирәк урында паузасыз сөйләү өчен текстка ияреп барырга туры килә. Әгәр дә дин әһеле текстка озак вакыт игътибар бирми икән, ул аның белән элемтәсен югалта. Образлы кабул итүне күзаллап, махсус алымнары билгеләнгән текст булганда мәсьәлә җиңел хәл ителә.

Чыгыш өчен яраклаштырылган текстта таяныч "маяк"лар булдыру мөһим, чөнки, аларга нигезләнеп, текстка ияреп барырга һәм шул ук вакытта тыңлаучылар белән иркен аралашырга була, бу исә – алдан-алы кабатлаулар нәтиҗәсе. Имам әзер текст белән таныша, образлы ориентирлар системасын үзләштерә һәм аралашканда текст белән элемтәсен югалтмый. Болай хәзерләнү яшь имамнар өчен үз йөзен булдыру чарасы.

Тыңлаучылар белән аралашуны җайлау вәгазьдә төп күрсәткеч. Тәҗрибәле вәгазьченең аралашу сәләтен – килеп туган хәлләрне контрольдә тотуын, аудиториягә көчле йогынты ясавын – тыңлаучылар сизеп тора. Дин әһеленең үз-үзенә ышанмавы тыңлаучыларда да тискәре халәт тудыра. Этосны исәпкә алу таләпчәнлек һәм алдан җайлашу күрсәткечләрен: тыңлаучыларның имамга булган мөнәсәбәтен, вәгазь темасына һәм анда чагылыш тапкан фикерләргә кушылуны, танып белү һәм аралашу мөмкинлекләрен берләштерә.

Яңа гына вәгазьгә керешүчеләрнең күпчелеге бирелгән сораулардан куркалар. Абруйлы вәгазьче тыңлаучыларның үзләрен сораулар белән хәйран калдыралар. Аралашуга, әңгәмәгә әзерлек мондый таркау аралашуны туплауда булыша. Сораулардан курыкмаска кирәк, чөнки алар дин әһелен уңайсыз хәлдә калдыру өчен, бик сирәк биреләләр. Үзең теләп, ихтирамлы сөйләшү һәрвакытта да уңайлы, билгеле. Шул сәбәпле вәгазьгә керешүче тарафыннан алдан төзелгән диалог бик күп проблемаларны юкка чыгара.

Һәм соңгысы, кабатлау вакытында вәгазьче үзенең холык-

фигыле (психик) һәм акыл эшчәнлегенә (менталь) карата булачак уңай бәягә исәп тотарга тиеш, бу барлык катнашучылар өчен дә нәтиҗәле аралашу шарты. Моны тормышка ашыру өчен, үзеңдә, вәгазьгә әзерләнү белән беррәттән, кирәкле дәлилләр һәм егәрлек булдыру мөһим. Бу этапта төшенкелек хупланмый.

Аңлашулы аралашуга исәп тотып, вәгазьче, шикләнмичә, үзенең белеме һәм тәҗрибәсе белән уртаклашырга, теләсә кайсы аудиториягә керә ала. Аралашуны оештыручы, тыңлаучыларны борчыган мәсьәләләрне белүче һәм тормыштагы көнүзәк каршылыкларны чишүдә ярдәм итүче, киңәш бирүче кешене көтеп алалар.

Нәтиҗәле аралашу турыдан-туры алдан кабатлауларның саны белән бәйләнгән. Алдан кабатлауда дин әһеленең сөйләме генә түгел, ә ым-ишарәләре һәм йөз хәрәкәте дә катнаша һәм тиешле рәвешен ала.

Тыңлаучыларга вәгазьченең сүзләреннән тыш, аның тышкы кыяфәте дә тәэсир итә. Шуңа күрә, әзерлек вакытында аерым элементларны гына түгел, ә гомумиләштерелгән сөйләм образын да кабатларга кирәк, чөнки ул вәгазьченең үз образы – үз йөзе белән бәйле.

## Нотык сөйләү

Сөйләм яңгыраганда дин әһеленең үзен тоту стиле, үз йөзе чагыла. Нотык нияткә яраклаштырып әзерләнгән эчтәлекле һәм язмача булырга тиеш. Тик тәҗрибәле имам, бервакытта да, алдан әзерләнгән нотыкны кулланмый. Сөйләүнең иҗади төре илһамга нигезләнә һәм аралашуның килеп туган төгәл рәвеше белән билгеләнә. Көчсез вәгазьче өйрәнгәнен һәм язганын көчкә исенә төшереп, я текстның эчтәлеген, я әзерләнгән текстның кисәкләрен генә сөйли. Чынлыкта, нотык яңгыратуның бөтен төре дә аралашуның алшарты, мөмкинлеге булып тора, ләкин бу аралашу үзе түгел. Оста вәгазьче билгеләнгән вакытка исәпләп, тыңлаучылары белән бер тиңдәй аралашырлык итеп, нотыгын, һәрвакыт, яңадан әзерли.

Өстәвенә, һәр вәгазьченең яңгыраган нотыгы шул ук булса да, аларны ике төркемгә аерып карарга мөмкин. Беренчеләре алдан әзерләгән нотыкларын кабатларга мөмкиннәр, икенчеләре шул ук сүзне кабатларга оялалар. Тыңлаучыларның этосын һәм аралашуның нәтиҗәлеген истә тотып, һәркем төрлечә аралашырга мөмкин.

Нотык сөйләүдә дин әһеле тыңлаучыларны аралашуга катнаштырырга, аларның игътибарын җәлеп итәргә һәм бу игътибарны нотыкның ахырына кадәр югары дәрәҗәдә тотып, эчтәлекне үзләштерүләренә ирешергә тиеш. Сөйләм төзелешен истә тотып аралашучы тыңлаучылары белән фикерләрен алмашырга тырыша. Төп максатны тормышка ашыруда, аралашу мөмкинлекләрен карашлар белән ирекле алмашырлык дәрәҗәдә үзгәртергә кирәк. Бу мөмкинлекләргә эчтәлек, сөйләм стиле, дәлилләү, фикерләр төрлелеге, карашлар белән алмашу, психологик тәэсир һ. б. керә. Без вәгазьгә әзерләнүдә, эчтәлек мөмкинлекләрен карадык. Хәзер, кыскача, стиль мөмкинлекләренә тукталыйк.

Сөйләм стиле чаралары имам һәм тыңлаучы арасында барган аралашуны – карашлар алмашуны – аңлаешлы, килешүчән, бердәй тәэсирле итә. Пафос һәм этоска бәйле рәвештә телнең табигый һәм өлешчә табигый чаралары кулланыла.

Тыңлаучыларны җанландыру, аңлау сәләтләрен арттыру өчен ритмлы итеп, сәнгатьле сөйләргә кирәк. Телдән әйтелгән сөйләмдә ритм, пауза һәм сөйләм типлары чиратлашу нигезендә барлыкка килә. Риторикада кабул ителгән фикер: сөйләм вакытында тыңлаучылар аваз һәм сүзләрне танып беләләр, ә пауза вакытында эчтәлегенә төшенәләр. Уйлап карасаң, мәгълүмат кабул итү тулаем тормышка ашырыла, ләкин әлеге эшчәнлекнең механизмы фәнни рәвештә нигезләнмәгән. Теге яки бу очракта да сөйләм авазлар алмашыну һәм паузалар чиратлашу берлегеннән барлыкка килә.

Сөйләмнең гармоник ритмына ия кешеләр паузаның 3 төрен кулланалар. Озын пауза сөйләмне периодларга бүлә. Периодлар төгәлләнгән фикерне белдергән берничә җөмләдән гыйбарәт. Периодны кыска паузалар белән аерылган җөмләләр чылбыры барлыкка китерә. Һәр җөмләнең ритмы бар, ә ул ритмны тагы да кыска паузалы синтагмалар барлыкка китерә.

Карашлар алмашу өчен эчтәлек һәм аны яңгырату гына җитми. Эчтәлек – мәгълүмати аралашуның предметы, яңгырату – аралашуны булдыру чарасы. Һәр аспект аралашуга төрлечә йогынты ясый. Вәгазьчегә ныклы тәэсиргә ирешүдә, очрагына туры килгән, дәлилләүләр дә кирәк. Дәлилләү эчтәлекнең логик (мәгънәви) эшкәртелүеннән тора. Төпле дәлилләүгә ия булу логиканың нигезләрен белү дигән сүз. Моның өчен төшенчәләр белән сак эш итәргә, фикер йөртүдә, нәтиҗә чыгаруда ашыкмаска, нәзәкатьлелеккә ирешергә кирәк.

## Дәлилләү, дәлилләү төрләре, алымнары

Дәлил һәм аның ысулы белән, ягъни белем яки тезисның хаклыгын раслау алымнары белән, риторика һәм логика һәрвакыт кызыксына. Дәлилнең дөрес яки ялган булуын ачыклау, табу мөмкинлеге логика фәненә нигез булган дигән фикер яшәп килә. Хәзерге вакытта дәлилләүне иҗтимагый аралашу төре буларак кабул итәләр, ә ул үзе аралашу чарасының мәгънәви төзелешен аңлаудан барлыкка килә.

Дәлилнең җирлеге – хәбәр итү, ул аңлатма бирү яки тезистан, хәбәр авторы, хәбәр кабул итүче һәм автор белән кабул итүченең кире бәйләнешыннан оеша.

Әгәр вәгазьчене автор дип алсак, ә тыңлаучыларны кабул итүче дип әйтсәк, әлеге тәгълимат мөмкинлекләрен дин әһеленә сөйләүче карашларын ныгытуда кулланырга була.

Дәлилләү теориясендә карашларны кире кагу үрнәкләре дә төзелә, алар әңгәмә коручыларның каршы як фикерләрен тәнкыйтьләү җирлеге буларак кулланыла. Дәлилне сөйләгәндә яки аңлатканда "кире кагуны" көчәйтү, яки тыңлаучының катгый фикерен йомшарту ораторның (дин әһеленең) каршылыкка үз карашын белдерүе булып тора. Капма-каршы фикерләр яңгыратучыны өч төрле ысул белән кире кагып була:

- аңлатманы кире кагу;
- күренешнең ялган булуын исбатлау (үз тезисыңның хаклыгын дәлилләп);
- дәлилләрнең ялган булуын ачыклау.

Аңлатуның дөреслеген тикшерүчеләр үзләре дә күренешләрнең капма-каршылыгыннан яки дәлилне аңлатуда хакыйкатьтән ераклашмаска тиешләр.

Оратор дәлилләүне арттыру кагыйдәләрен дә белергә тиеш. Монда исә берничә төркем формалаша: тезиска, дәлилнең үзенә һәм дәлилләү барышына карата.

Тезиска карата мондый кагыйдәләр бар:

- тезис мәгънәви ачыкланган, аңлаешлы һәм төгәл бәян ителә;
- тезис бөтен дәлилләү системасында бер мәгънәле булып кала, үзгәрми.

Дәлилләү кагыйдәләре түбәндәгеләр:

- дәлилләр хак фикерләр яки дәлилләү барышында фикерләр чылбыры белән исбатланырга тиешләр;

• дәлилләр үзара каршылыклы булмыйлар.

Дәлилләү барышына карата да кагыйдәләр эшләнгән:

• дәлилләү – аңлатмага юнәлеш бирүдә ярдәм итә торган өлеш, ә тезис – нәтиҗә өлеше булган фикерләү рәвеше;

• дәлилләүдә логиканың барлык канун-кагыйдәләренә карата фикернең урынлы, әдәпле кулланылышы;

• тезисларның хаклыгын билгеләүдә, нәтиҗәләр хакында фикер йөртүдә ихтималлык карашларына мөмкинлек бирү.

## *Дәлилләү төрләре*

Белгәнебезчә, дәлилләү – аралашуда нинди дә булса фикерне исбатлау өчен раслау, аңлату, тәртипкә китерү рәвеше.

Дәлилләү – раслау системасы, димәк раслый-раслана торган фикерләр бер-берсе белән бәйле.

Дәлилләү – эш, гамәл барышы, димәк раслауларны эзлекле рәвештә урнаштырырга туры килә.

Дәлилләрнең система һәм эшчәнлек барышы булуын оратор гына түгел, тыңлаучылар да аңларга тиеш.

Ораторга ниндидер максатларны үтәр өчен китерелгән дәлилләр системасы тәкъдим итү генә җитми, ә ул системаның тыңлаучылар аңларлык һәм аудиториянең кабул итү мөмкинлекләрен истә тотуы хәерле.

Уңай һәм тискәре дәлилләр була:

1.Уңай дәлилләр: хакыйкать; абруйлы чыганаклар; гади, аңлаешлы, кабул ителерлек фикерләр; аудиториянең дөреслек, намус, иҗтимагый идеал турындагы карашларына якын, тормыш чынбарлыгына, аек акылга туры килерлек, җавап бирерлек дәлилләр.

2.Тискәре дәлилләр: фикернең аталган максатларга якын да тормавын бернинди дәлилләрсез расларга тиеш булалар.

Күп кенә аудиторияләрдә көчле дип саналган типик дәлилләрне атап үтик:

- дәрәҗәле чыганаклардан өземтәләр (цитаталар);
- фәнни аксиома;
- рәсми документлар, законнар;
- табигать кануннарын;
- эзләнү, тикшеренү нәтиҗәләре;
- экспертларның йомгак сүзе;
- абруйларга сылтама;

- вакыйгада үзе катнашкан, бу хәлләрне үз күзләре белән күргән кешеләрнең күрсәтмәләре;
- статистик мәгълүмат.

### *Дәлилләү алымнары*

Кими барган дәлилләр – алдан көчле дәлилләр; соңыннан хисси халәт: үтенеч, теләк (гариза язу, үтенеч белдерү) яки нәтиҗә ясау. Уңай ягы:

- беренче раслаулар хәтергә ныграк сеңәләр;
- игътибарны туплау һәм дәвамлы тотып торуда ярдәм итәләр;
- иң элек фикерләү: акыл алдан, аннан хис.

Арта барган дәлилләр – дәлилләү һәм хисси халәт чыгыш ахырына көчәя бара.

Бу төр дәлилләүләр – акыл һәм рухи халәтнең тантанасы. Өстенлеге – кызыксыну даирәсе урнашкан, хәзерлекле аудиториядә куллану нәтиҗәле була.

Бу төр дәлилләрнең нәтиҗәлек шартлары:

- аудитория ораторны бирелеп тыңласа;
- расланырга тиеш фикер артык катлаулы булса;
- сөйләнгән мәсьәлә аудитория өчен хәл ителеп бетерелмәгәндә;
- аудитория мөстәкыйль рәвештә нәтиҗә ясый алса.

Берьяклы, ике яклы дәлилләүләр була. Берьяклы дәлилләүләрдә: я гел "уңай", я гел "тискәре" фикерләр яңгырый.

Ике яклы дәлилләүләрдә: фикерләр чагыштырыла, каршы фикерләр белән тикшерелә, яңа нәтиҗәләр ясала.

Ике яклы дәлилләрдә "оппонент", “фараз кылыну” алымы кулланылырга мөмкин.

Берьяклы дәлилләрнең нәтиҗәлеге:

- ниндидер күренешкә карашны нығыту өчен кулланыла;
- аз белемле кешеләргә тәэсире көчле;
- нык ук булмаган инану җирлеге;
- әзер фикерләрне үзләштерүгә ярдәм итә.

Ике яклы, каршылыклы дәлилләрнең нәтиҗәлелеге:

- хәбәр ителгән хәлләргә тискәре мөнәсәбәттә булган кешеләргә нык тәэсир ясый;
- фикерләр белән "уйнау" га каршы хәзерли;

- нык инануларга алып килә;
- анализга өйрәтә, мөстәкыйль нәтиҗәләр ясауны күнектерә.

### *Индуктив һәм дедуктив дәлилләү*

Индуктив дәлилләү – мисаллардан (факттан) – нәтиҗәгә килеп дәлилләү төре. Хатын-кызлар, 18-23 яшьтәге аудиториядә куллану нәтиҗәле була.

Дедуктив дәлилләү – гомуми кагыйдәдән аерым фактлар (мисаллар, очраклар) ярдәмендә аңлату, раслау рәвеше. Ир-ат, фәнни аудитория, 23 яшьтән югары аудиториядә уңышлы кулланыла.

Дәлилләрне кабул итүгә комачаулый торган мизгелләр:

- элекке мәгълүматны кире кага торган фактларны аудитория кабул итә алмый. Соңыннан чыгыш ясау отышлы, бу очракта алдагы фикерләрне туплап, нәтиҗә ясаган кебек тәэсир кала;
- аудитория бер фикернең күп тапкыр кабатлануын өнәми;
- чит тел терминнарын куллану аудиторияне борчый;
- сөйләм кагыйдәләрен бозу һәм алардан читләшү, хаталы яңгырау – ораторга ышанычны киметә, аның компетентлыгы шиккә алына.
- вак-төяк детальләрнең, дәлилләрнең күплеге кабул итүне авырайта. Цицерон: "Публика алдында кирәклесен генә әйтеп, кирәкмәгәнен әйтмәскә" киңәш иткән.
- чыгышта мәгълүмат чыганагының таныш булуы, танылуы. Кечәге газета материалын сөйләп, бик урынлы булса да, аудитория игътибарын яулап булмый. Информация чыганагын я танымаслык дәрәҗәгә җиткерергә, я турыдан-туры чыганакны атап үтәргә кирәк.

### *Кире кагулы һәм булышлык итә торган дәлилләр*

Кире кагуда гел тискәре дәлилләр кулланыла.

Булышлык итә торган дәлилләрдә гел уңай фактлар китерелә. Бу очракта оппонентыннан алда чыгыш ясаган оратор үз тезисларын күтәрә һәм каршы якны гаепли ала.

Оппонентыннан соң сүз алса, оратор оппонентның чыгышын тикшерә һәм булышлык итә торган дәлилләр китереп, үз файдасына нәтиҗә ясый ала.

## Дәлилләрнең эчтәлегенә бер караш

Тел һәм сөйләм мәдәниятнең күпкырлы күренеше буларак, өлешчә кагыйдәләр җирлегендә урнаша, ә берникадәр өлеше аларның чигеннән дә чыга. Дәлилләү – логика һәм риториканың бер өлеше буларак, кагыйдәләргә буйсына һәм бу җирлектә тулы аңлатма бирә. Дәлилләү –ышандыру чарасы буларак, билгеле бер кагыйдәләрдән өстенрәк тора. Шулай ук, аралашу вакытында дәлилләүче, үзе белеп, дөрес булмаган дәлилләрне аңлы һәм аңсыз рәвештә куллана ала. Шуңа күрә, оратор дәлилләрне аера белергә тиеш һәм кирәк чакта аларны кире кагарга һәм үзе дә капма-каршы дәлилләрдән сакланырга тиеш. Шулай да әдәпсез, ялган дәлилләр, дөрес дәлилләрне танырга ярдәм итә, чөнки алар арасындагы аерымлыкларны күрсәтә.

Бик итагатьле, ихтирамлы булган, логик кагыйдәләргә туры килүе белән инандыру тудыра торган тезислар ярдәмендә исбатланган дәлилләү – дөрес дәлилләү дип атала.

Ялгыш яки исбатланмаган тезислар ярдәмендәге ышандырулар – дөрес булмаган дәлилләүне хасил итәләр. Әдәпсез (корректлы булмаган), урынсыз кулланылган дәлилләрнең максаты: ышаныч тудыру, оратор фикерләренә иярту, ә аларның нигезенә бик үк дөрес булмаган тезис салына. Дәлилләү теориясендә киң кырлы, күп төрле алымнар теркәлгән:

- гомумиләштерелеп дәлилләү;
- абруйга нигезләнеп дәлилләү;
- шәхескә сылтаулап дәлилләү;
- аерым кеше фикерен китереп дәлилләү;
- киң катлау хезмәт ияләре фикеренә таянган булып дәлилләү;
- дәрәҗәгә, масаючанлыкка дәлилләр;
- көчне ассызыклап дәлилләү.

Дөрес булмаган дәлилләү софистикага якын тора. Заманында софистика ялган тезисларны исбатлау нигезендә барлыкка килә. Гадәттә, софистика логикага каршы куела. Нигезле карашларны һәм объектив дөреслекне – хакыйкатьне яклаучы ораторлар, дөрес булмаган дәлилләр кулланучыларның хәйләләренә каршы тора белергә тиеш.

Дәлилләрне гомумиләштерү оппонентның фикерен кире кагуда кулланыла, тыңлаучылар фикеренә каршы куелуы сәбәпле, әлеге фикернең тикшерелүенә китерә.

Тыңлаучыларның шәхси фикерләрен оратор каршы тезисның тотрыксызлыгын арттыруда файдалана.

Шәхескә булган дәлилләрне куллануда оппонентның максаты – тезисның хаклыгын тикшергәндә тыңлаучылар игътибарын әлеге тезисны күтәргән шәхеснең берәр үзенчәлекле сыйфатына күчерү.

Киң катлам халык фикеренә таянып дәлилләү тыңлаучыларның төркемгә әверелүенә нигезләнгән. Кешеләр төркеме белән (оешкан аудитория төшенчәсе белән бутамаска) түбән мәдәни дәрәҗәле инстинкт һәм аңсызлык идарә итә. Бу төр дәлил – халык фикеренә сылтама – гадәттә, төрле катлам халык җыелган аудиторияләрдә кулланыла. Рациональ дәлилләр демагогия белән алыштырыла, аларның кулланылуы милли, дини, патриотик һ.б. төрле хис-тәләкләр кабынуга җирлек була.

Аерым кешегә дәлил – гомумкешелек тарафыннан кабул ителгән кыйммәтләрне алыштыруга нигезләнгән. Ул җыелган халык фикеренә сылтама ясап дәлилләүгә якын тора. Кешелеклелек турында сөйләп, рухи кыйммәтләргә мөнәсәбәтле фикер йөрткән булып, игътибарны төп максаттан читкә җибәрү “уены” аерым кешегә карата дәлилләрнең эчтәлеген тәшкил итә.

Абруйга, дәрәҗәгә дәлил шуннан гыйбарәт – тыңлаучыларның игътибарын дәрәҗәле шәхескә юнәлтеп, тезисның хаклыгы тикшерелми кала. Бу дәлилнең тагын бер исеме – "кыюсызлык", чөнки тезисны исбатлау дәрәҗәле кеше карашына алыштырыла һәм ул оппонент ягыннан тәнкыйтьләүгә дучар булмый. Дәрәҗәгә дәлил килешүчән аудиториядә нәтиҗәле, бигрәк тә ул башлыкка яки хакимият даирәләренә юнәлтелгән булса.

"Шөһрәт ярату, масаючанлыкка дәлил "шәхескә дәлил"нең яшерен төре. Бу хәйлә эчтәлеге тыңлаучыларның игътибарын тезистан оппонентның уңай үзенчәлекләренә күчерүдән оеша. Оппонентка карата ялагайлык барлыкка килә, ә тыңлаучыга карата – уңай, гуманистик кыйммәтләр кулланыла.

Физик көчкә яки җәзага дәлил иң таралган һәм үтемле, итагатьле булмаган дәлил. Итагатьле булмаган тезис тыңлаучыларга ачыктан-ачык яки астыртын янау белән юнәлтелә һәм алар әңгәмәнең нәтиҗәсенә тәэсир итә. Физик көчкә дәлил төрле дәрәҗәдәге аралашуда кулланыла – югары даирәләрдә дә, шәхесара мөнәсәбәтләрдә дә.

Күрсәтелгән дәлилләрдән тыш наданлыкка, кызгануга, террорга һ.б. юнәлтелгән дәлилләр дә бар. Гадәти аралашуда

тыңлаучыларны ышандыру, оратор карашларына күндерү өчен бөтен рөхсәт ителгән мөмкинлекләр дәлил итеп кулланыла. Ышандыру барышында көчсезләнгән һәм ялган тезис мөмкинлекләре итагатьле булмаган дәлилгә әйләнәләр, ә алар белән ризалашмаска кирәк.

## Коръәни-Кәримдәге риторик дәлилләр

Мәгълүм булганча, Коръән теленең стиле илаһи сүзнең тулаем максатыннан – иманның хаклыгына инандыру һәм аның таләпләренә күндерүдән чыгып билгеләнә. Коръән, милләтенә, тән төсенә, тумышына, белем дәрәҗәсенә карамастан, һәммә инсанга өндәмә рәвешендә яңгырый. Кешеләрнең мәгълүматны төрлечә кабул итүләренә дә карамастан, әлеге мәгълүмат аларның үз тәҗрибәләренә таянып үзләштерелмәгән очракта да, изге текстның хаклыгына ышандыра торган дәлилләре бик күп. Белгәнебезчә, тезисның дөреслеген чагылдырган сөйләм кисәген (фрагментын) без риторик дәлил дибез.

Коръән текстында риторик дәлилләрнең электән үк билгеле булган төрләре (архитиплары) очрый дигән мәгълүмат бар. Әлеге карашны куәтләп, галим әз-Зәркани Коръәндәге дәлилләрнең катлаулы фәлсәфи раслауларга, калыплашкан һәм мантыйк кагыйдәләренә генә нигезләнмәвен дә искәртә. Галим бу фикерен ике сәбәп белән аңлата. Беренчедән, Коръән иңдерелгән заманда гарәпләр үзара аралашуда бу төр дәлилләрне кулланмаганнар, чынлыкта, Коръән аларның сөйләм үзенчәлекләренә нигезләнә: «*(Аллаһның әмерләрен)* Ана телендә яхшылап аңлатсыннар дип, *(үз араларыннан)* пәйгамбәрләр күндердек. Аллаһ *(мөселман булырга)* теләмәгәнне адаштырыр, теләгәнен тугры юлга чыгарыр. Аллаһ көч һәм хикмәт иясе» («Ибраһим» сүрәсенең 4 нче аяте). Икенчедән, катлаулы фәлсәфи раслаулар күп кешегә тиз генә аңлашылмый, аларга нигезләнү үзеңнең хаклыгыңны башкача аңлата алмаганда гына максатчан була.

Коръән текстын өйрәнү барышында күпчелек дәлилләрнең максатлы, төпле раслауларга (логик) яки мәгънәви дәлилләргә) нигезләнгәнлеге күренә. Алар, беренче чиратта, акыл көченә инанган фикерләрнең мәгънәсен ачык сиземли торган, аларның хаклыгы ышанырлык дәлил булуына төшенә алган аудиториягә юнәлтеләләр. Мәгънәви дәлил буларак, Аллаһның җиһанны яралтучы булуын раслаган мисалны күзәтеп үтик. «Әллә алар

үзләреннән-үзләре барлыкка килдеме? Әллә алар үзләре юктан бар итә аламы? Әллә соң күкләр белән Җирне алар юктан бар иттеме? Хәер, алар *(Аллаһның кодрәтенә)* ышанмый» («Тур (Тау)» сүрәсенең 35-36 нчы аятьләре). Мәһабәт сарай, тирә-янындагы гүзәл бакча яныннан үткәндә, акылында булган кеше аларны үзләре барлыкка килгән дип әйтми. Сарай үзен-үзе төзегән, агачлар үзләрен-үзләре үстергән дип әйтү бигрәк тә ахмак фараз. Бу очракта, оста нәкышчылар, төзүчеләр, бакчачылар хезмәт куйганлыгы хакында һичнинди шик-шөбһә булуы мөмкин түгел. Әлеге мантыйкка ярашып, Коръән кешеләрне Аллаһның күк һәм җирне булдыручы икәнлегенә инандыра.

Аятьләрдә Аллаһның бердәнберлеген башка төр мәгънәви дәлилләр белән аңлатылуын да очратабыз: «Аллаһ бернинди дә баланың атасы булмады. Аңа тиң башка бер илаһ та юк. Әгәр булса, һәр илаһ үзе яралткан малны һәм идарәне үз кулына алырга тырышыр иде һәм, мотлак, алар бер-берсен җиңәргә тырышып, сугышырлар иде. Сөбханаллаһ! Аллаһ алар *(мөшрикләр)* табынганнардан өстен» («Мөэминун (Мөэминнәр)» сүрәсенең 91 нче аяте). Бу аятьтә китерелгән тезис киресен әйтү алымы белән раслана. Әйтик, Җиһан берничә тиңдәшсез Аллаһ кодрәте белән оешкан һәм алар үзләренә генә буйсынуны таләп итәләр, ди. Бу очракта алар арасында кискен каршылык башланып, үзара көрәш яки берсенең генә тулаем җиңүе яки Җиһанның җимерелүе белән тәмамланыр иде. Башка сүзләр белән әйткәндә, Коръәндә язылганча, Җирдә һәм галәмдә искиткеч тәртип, ритм саклануы, Аллаһның бердәнберлегенә инандыра торган дәлил. Кабул ителгән карарларның, хәл ителгән мәсьәләләрнең кулайлыгына, файдасына кагылышлы логик дәлилләр дә бик урынлы. Мәсәлән: «Аллаһка вә Ахирәт көненә иман китереп, үзләренә Аллаһ тарафыннан бирелгәнне *(дин юлында)* сарыф итсәләр, ни була иде инде? Аллаһ аларның хәлен бик яхшы белеп тора» («ән-Ниса (Хатыннар)» сүрәсенең 39 нчы аяте).

Һәркем ниндидер карарга үзбелдегенчә килә, ниндидер мәсьәләне үзенчә хәл итәргә хокуклы. Кешеләр инанып, Аллаһның ихтыярына буйсына яки имансызлык чоңгылына тәгәри ала. Бары тик үзләренең язмышыннан ваз кичә яки ниндидер тарафны сайламый кала алмыйлар. Җирдә, иман китереп, лаеклы яшәгән кешеләр, ахирәттәге тормышның юклыгын фаразлаганда, нәрсә югалталар соң? Намуссызлык юлында, гөнаһ кылып, әшәкелек

таратып яшәүчеләр, Аллаһның вәгъдәсе дөрес булган очракта, нәрсәгә ирешәләр? Берәүләр һичнинди югалтуларга дучар ителмиләр, икенчеләре һәрнәрсәдән мәхрүм булачаклар. Аллаһка буйсынуның өстенлеген, Коръән, киресенә каткан имансызларга, шул рәвешчә аңлата.

Кешенең танып белүен камилләштерүгә, аятьләрнең әһәмиятен аңлатуга юнәлдерелгән логик дәлилләр белән беррәттән, Коръәндә тыңлаучыларның рухи халәтенә, кичерешләренә йогынты ясарлык хисси дәлилләр дә очрый. Теге яки бу ышануларга һәм гамәлләргә хисси мөнәсәбәт оештырып, алар аудиториянең аңына сеңдерелергә тиешле фикергә җирлек әзерлиләр. Мәсәлән, Кыямәт көнендә имансызларның нинди очракта котылу мөмкинлекләрен аңлатканда: «Аятьләребезне ялганга чыгарып, үзләрен бөек күрсәтергә теләгәннәр бар, менә шуларга инде Күк капусы ачылмаячак һәм алар, дөя энә күзе аша узганга чаклы, җәннәткә кермәячәк. Гөнаһлыларны менә шулай җәзалаячакбыз», – диелә «Әгъраф (Пәрдә, калкулык)» сүрәсенең 40 нчы аятендә. «Кяферләрнең кулында Җир йөзендәге байлыкларның бөтенесе булса, хәтта икеләтә артык булса да, Кыямәт көнендә җәзадан котылу өчен шул байлыкны бирсәләр дә, кабул ителмәс. Алар өчен әче газап бар» («Маидә (Табын)» сүрәсенең 36 нчы аяте).

Нигездә, хисси дәлилләр чит абруйга яки күпчелек фикеренә таянудан оеша. Мәккә мәҗүсиләре өчен язу таныган кешеләрнең – яһүдләр һәм христианнарның сүзе абруйлы саналган. Алдан күрүчәнлек турындагы кайбер фикерләрнең дөреслеген раслау максатыннан Коръәндә дә аларга сылтама китерелгән: «*(Ий, Мөхәммәд)* сиңа чаклы да Без вәхий тапшырылган кешеләрне генә пәйгамбәр итеп җибәрдек. Әгәр *(бу турыда)* белмисез икән, белгәннәрдән *(китаплы халыктан)* сорагыз *(«Аятьтәге **“әһлүз-зикр”**, ягъни **“белгәннәр”** сүзен, Тәүрат белән Инҗилне яхшы белгән кешеләр, китаплы халык, дип аңларга кирәк.* Мостафа Чагрыҗы тәфсиреннән») («Әнбия (Пәйгамбәрләр)» сүрәсенең 7 нче аяте). Чит абруйларга мөрәҗәгать итү очраклары аз, чөнки бу дәрәҗәдә хәл ителә торган сораулар да бик чикле. Алай гына да түгел, кайбер очракларда, ялган шаһитлек мөмкинчелеген күзаллап, Коръән читтән булган дәлилләрне гаепләп чыга: «Үзләренә Китап иңдерелгәннәрне күрдеңме? Потларга *(таш сыннарга, агач сыннарга)*, шайтанга ышаналар, соңыннан кяферләр өчен:

– Болар Аллаһка иман китерүгә караганда турырак юл, – дип сөйлиләр» («ән-Ниса (Хатыннар)» сүрәсенең 51 нче аяте).

Аудиториягә дәлилләр, күпчелек фикеренә сылтама ясау Коръәндә, еш кына, пәйгамбәребез Мөхәммәднең (сгв) замандашлары күзаллауларына һәм ышануларына юнәлдерелгән. Мәҗүсиләр, Җиһанны бар иткән Аллаһның бердәнберлегенә ышанган хәлдә дә, гозерләрен уйлап чыгарылган аллаларга юнәлткәннәр. Коръәндә Аллаһның бердәнберлеген дәлилләүдә мәҗүсилектәге әлеге каршылыкларга мөрәҗәгать итела: «Хактыр ки, алардан:

– Күкләрне вә Җирне кем юктан бар итте? – дип сорасаң, әлбәттә:

– Аллаһ бар итте, – дип әйтерләр. Әйт син аларга:

– Шулай булгач, әйтегез әле: Аллаһ миңа берәр төрле зарар кылырга теләсә, Аллаһны инкяр итеп, табынганнарыгыз Ул биргән зарарны китерә алачакмы? Яки Аллаһ миңа рәхмәт әйләсә, алар Аның рәхмәтен юкка чыгара аламы? – дип сора. Әйт син аларга:

– Миңа *(ярдәм итәргә, мине сакларга)* Аллаһ җитәр, – диген. Тәвәккәл итүчеләр бары тик Аңа инанып, аркаланалар» («Зүмәра (Халык өере)» сүрәсенең 38 нче аяте).

Бу – мәҗүсиләр Җирдә һәм күкләрдә Аллаһның чикләнмәгән хакимлеген таныган очракта, таш сыннар да ярдәмгә килмәячәген, ялваруларына җавап кайтармаячагын белдерү өчен китерелгәнгә дәлил. Алдагы мисал риторикада шәхескә юнәлтелгән дәлил дип атала. Аерым шәхес абруена сылтама, аудиториянең күпчелеге фикеренә таяну дәлиленең бер төре. Аудитория фикеренә таяну дәлилләре арасыннан гамәли әһәмияте, бурыч үтәүгә өндәү, заруриялык дәлилләрен дә аерып карыйлар.

Гамәли әһәмиятле дәлилләрдә теге яки бу фикерне сайлауның файдалыгына, кулайлыгына игътибар ителә. Мондый дәлилләрдән, Мәккә халкының исламны кабул итүдән нинди файда күрәчәген аңлаткан аятьләрне әйтеп үтәргә кирәк: «Хактыр ки, сезгә шундый мәртәбәле бер Китап иңдердек: анда сезгә үгет-нәсыйхәт тә, шәрәфләр дә тупланган. Һаман шуны аңламыйсызмы?» («Әнбия (Пәйгамбәрләр)» сүрәсенең 10 нчы аяте).

Аудитория хуплаган бурыч төшенчәсенә нигезләнгән дәлилләр бурычка тугрылыкны куәтләргә өндәгән дәлилләр булалар. Мәсәлән, Коръән иңдерелгәнче, мәҗүсиләр, аларга пәйгамбәр җибәрелгән очракта, Аллаһның кануннарын, яһүдләр һәм

христианнарга караганда да, яхшырак үтәргә ант итәләр. Шул сәбәпле дә Мәккә халкын Исламга өндәү үзләренә йөкләгән бурычларын, вәгъдәләрен исләренә төшерү белән үрелеп бара: «*(Мәккә мөшрикләре)* Аллаһ исеме белән ант иттеләр:

– Валлаһи! Безгә дә кисәтүче пәйгамбәр килсә, башка халыкларга *(яһүд белән христианнарга)* караганда да без алданрак тугры юлга баскан булыр идек, – диделәр. Пәйгамбәрнең килүе аларның тугры юлдан ераклашуын арттырды гына» («Фатыр (Яралтучы)» сүрәсенең 42 нче аяте).

Зарурилыкка дәлилләрдә тәкъдим ителгән чишелешнең кире каккысызлыгы аңлатыла. Мәсәлән: «Раббы алдында *(җавап бирергә)* тупланачакларын белгәннәрне шушының белән *(Коръән белән)* үгетлә, кисәт. Аларга ул вакытта Аллаһтан башка яклаучы дус булмас. Бәлки алар акылга килеп) иман китерер, тәкъва булыр» («Әнгам (Мал-туар)» сүрәсенең 51 нче аяте).

Башка яклаучысы һәм ярлыкаучысы булмагач, ничек инде кешеләр Аллаһ юлыннан тайпыла алалар? Шундый дәлилләр ярдәмендә, Коръән, иманның зарурилыгын һәм Аллаһның кушканнарын үтәү тиешлеген исбатлый.

Коръәндә мәгънәви һәм хисси дәлилләр үзара үрелеп баралар. Шул сәбәпле, хис белән өретелеп тәэсирчәнлеге арткан мәгънәви дәлилләрнең исбатлау көче артып китә. Уйлап чыгарылган аллаларга табынуның мәгънәсез бер шөгыль булуы ни дәрәҗәдә үтемле аңлатылганын күзәтеп үтик: «Аллаһ төнне көн белән аралаштырыр, көнне исә төн эченә кертер. Кояш белән Айны үз әмере белән йөртер. Аларның һәрберсе билгеләнгән мөддәткә чаклы шулай йөрер. Боларның бөтенесен дә Аллаһ берүзе майтара. Барча милек – Аныкы, Аны инкяр итеп, сез табынган *(потлар, сын)*нар исә хәтта чикләвек кабыгындагы элпәнең бер җепселенә дә хуҗа була алмыйлар.

Әгәр дә сез аларны *(дога кылып, Илаһка тиңләштергән сыннарыгызны, потларыгызны, һәйкәлләрегезне ярдәм сорап)* чакырсагыз, алар сез чакырганны ишетмәс *(догаларыгызны кабул итмәс)*. *(Чөнки алар җансыз)* ишеткән сурәттә дә, сезгә җавап бирмәсләр *(ярдәм итә алмаслар)*. Кыямәт көнне Аллаһка тиң булудан ваз кичәрләр *(файда да, зыян да эшли алмаслар)*. Бу Хакыйкатьне сиңа барча нәрсәләрдән хәбәрле булган Аллаһтан башка һичкем әйтмәс» («Фатыр (Яралтучы)» сүрәсенең 13-14 нче аятьләре).

Коръән Аллаһның бер үзенә табыну өстенлеген аңлатып кына калмыйча, шул ук вакытта тыңлаучыларда бу мәсьәләгә тиешле мөнәсәбәт тә оештыра. Акылында булган кеше бернинди дә кодрәткә ия булмаган һәм аның ялваруларына колак салмаган кемгәдер ярдәм сорап мөрәҗәгать итәрме икән? Мәгънәви дәлилләрнең үтемлелек чаралары белән хисси дәлилләрнең тәэсирчәнлек мөмкинлеге ярашу Коръән раслауларын анык һәм бәхәстән өстен итә.

Алда китерелгән мисалларда Коръәндәге дәлилләрнең исбатлаулардан тыш аралашу вазифасын үтәүләре дә аңлашыла. Алар ритор (вәгыйзь) белән аудиториянең аралашуын җиңеләйтәләр, карашлар берләшүгә ярдәм итәләр. Шул максатны күзаллап аудитория белән бәйләнеш урнаштыруда төрле сөйләм чаралары кулланыла да: мөрәҗәгатьләр, өндәмәләр, риторик эндәшләр, читләтеп һәм турыдан-туры сораулар, риторик сораулар һ. б. Мәсәлән, Кыямәт көнендә яңадан терелүнең хаклыгын раслаганда, Коръәни-Кәрим безне бәхәс алымына ияртә: «Кеше үзен: һич чикләүләрсез, авызлыксыз, күзәтүчесез яшәргә хаклы, дип саныймы әллә? Ул ана карынына атылган бер тамчыдан хасил икәнен онытамы? Соңра шул тамчы бер оешкан кан кебек (яралгы) булды, аннан соң аны кеше кыяфәтенә кертеп, дөньяга яралттык. Ирле-хатынлы итеп тудырттык. Шушыларны бар итә алган Аллаһ мәетләрне генә терелтә ала торгандыр, шәт?» («Кыямәт» сүрәсенең 36-40 нчы аятьләре).

Әлбәттә, күзгә бәрелеп торган хакыйкать белән килешкәндә, каршы сүз сөйләүчедә дә (оппонентта) таныргa теләмәгән фикерләр белән ризалашу теләге туа.

Гомумиләштереп әйткәндә, Коръәндәге дәлилләр теге яки бу ышануларның, гамәлләрнең һәм әхлакый сыйфатларның дөреслеге яки ялгышлыгына инану чарасы буларак китерелгәннәр. Әлеге дәлилләрнең риторик кыйммәте Коръәни-Кәрим тезисларының хаклыгын нигезләп кенә калмыйча, кешенең рухи дөньясына сүз ярдәмендә уңай йогынты да ясыйлар. Изге Коръәннең аудиториясе Җир шарындагы берничә миллиард халыкны берләштерсә дә, төрледән-төрле карашлы, акыл-белем дәрәҗәсе төрле дәрәҗәдәге кешеләр аның дәлилләренең исбатланган булуын аңлыйлар.

Йомгаклап әйткәндә, тел-сурәт, сөйләм оештыру чараларының һәрьяктан камил җыелмасы Коръәни-Кәримнең тиңдәшсезлегенә тагын бер таныклык, тагын бер дәлил.

**Дәлилләрне нәтиҗәле куллануның кагыйдәләре һәм алымнары**

Һәрбер дәлил билгеле бер аудиторияне, билгеле бер очракны күз алдында тотып әзерләнә. Әлбәттә, фикерләрне эзлекле һәм дөрес сайлау чыгышның темасы, төп мәсъәләләренә кагылышлы рәвештә төзелә.

Шулай да, һәрбер чыгышның максатына ирешүдә ярдәм итәрлек гомум кагыйдәләр дә бар:

- Хисчәнлек (эмоциональлек).

Хисси халәт – халык алдында нәтиҗәле чыгыш ясауның иң төп сыйфаты. Аудиториягә сөйләгән сүзегезнең сезне борчуын сиздерегез һәм үз кичерешләрегезне тыңлаучыга җиткерергә тырышыгыз. Хис халәте аудиториягә нык тәэсир итү чарасы, игътибарны туплауда алыштыргысыз чара. Шуны онытмаска кирәк, хисле сөйләмне балалар, хатын-кызлар, яшүсмер яки әзерлексез кеше тыңлаганда, аның нәтиҗәсе логик дөреслектән көчлерәк була. Шуны да искәртеп үтик, ораторның хис чагылышы билгеле бер чамадан чыкмаска, артык кызып китүгә әверелмәскә тиеш.

Ораторның тойгы-кичерешләрен аудитория күреп-сизеп торса яхшы, тик хисләр сөйләмнең эчтәлегенә зыян итәргә тиеш түгел. Моңа бәйле шундый кагыйдәне истә тотарга кирәк: иң элек хис тудырырлык мисаллар табарга һәм аларны хисле итеп сөйләп бирергә өйрәнергә кирәк.

- Мәгънәви (логик) басымнарны чикләү.

«Хис-логика» берлегендә хәзерге аудиторияләр хисне артыграк тоярга тиеш. Ни өчен? Һәртөрле логик фикерләү, бигрәк тә теләсә нинди дедукция (гомумидән хосусыйга бару юнәлешендә фикер йөртү) үзенчә мәҗбүри акыл өйрәтү, аудиторияне берникадәр рухи ирексезләү булып тора – аны логик дәлилләр белән ниндидер махсус хәзерләнгән тозакка куып кертәләр кебек. Кешеләрнең күпчелеге кемнеңдер аларга “бердәнбер” хакыйкатьне, шик калдырмыйча дәлилләүне яратмый. “Ораторданн төгәл дәлилләр таләп итәргә кирәкми, – дип өйрәткән Аристотель, — нәкъ шулай ук математиктан да хисле фикерләү таләп ителми.”

Дәлилләр китерү мәҗбүри, тик хикәяләүдә мәгънәне рухи күтәренкелек, хис халәтенә алып килерлек күренеш, анык мисаллар, шаяртып алу (юмор) артына “яшерергә” кирәк.

- Тыңлаучылар өчен бик мөһим фактларга мөрәҗәгать итү.

Теләсә нинди аудиториядә чыгыш ясаганда, сез сөйләнгән сүзләрнең мәгънәсен табарга һәм аңлатырга тырышыгыз. Үз җөмләләрегезнең яки мәгълүматыгызның тыңлаучылар өчен чын-чынлап файдалы булуын күрсәтегез.

• Фикерләрне берәр шәхес белән бәйләп аңлату.

Фикерләрне тикшерүне кешеләрне тикшерүгә әйләндерү ысулы бик көчле тәэсир итә. Әлеге ысул фикер иясен, ә соңыннан инде ул яклаган фикерне мактау яки тәнкыйтьләүгә кайтып кала.

Билгеле булганча, мондый дәлилләр "шәхескә юнәлтелгән" яки "публикага юнәлтелгән дәлилләр", әлбәттә, алар югары нәтиҗә бирә. Әлеге шәхесләрнең шөгыльләрен атау аларның сәяси карашларын шиккә калдыра, юкка чыгаруы да мөмкин.

Идея иясенең уңай портретын тудырып, бу вакытта, нәрсә өчендер аны тәнкыйть итеп, тыңлаучының аңына без әлеге идеянең аудиториядән дә хупланмавына ирешәбез. Шуны да әйтеп китәргә кирәк, шәхескә бәйле дәлил еш кына "авыз томалау өчен", демагогик максатларда да кулланыла.

• Сөйләмдә читкә тайпылу.

Һәрвакыт бер темага гына сөйләү килешми. Идеяләрегезне «төреп куеп», тыңлаучыларга бераз ял биреп, төп темадан чит-кәрәк китәргә мөмкин. Тагын бер әһәмиятле алым: аудиториянең игътибарын бераз читкә юнәлдерүдән, ораторның ышандыру көче арта. Мәсәлән, шунысы ачыкланган, акрын музыка фонында сөйләү, табигать күренешләре төшерелгән слайдлар күрсәтү, стена артында очраклы шакулар һ.б., аудиториянең игътибарын, ораторга ышанычын арттыра, мәгълүматны ныграк үзләштерүдә ярдәм итә икән. Шуны искәртеп үтик: аудиториянең төп фикердән читләшүе, әлбәттә, кире нәтиҗә бирә: мәгълүмат кабул ителмичә кала. Комачаулык тудыра торган мизгелләрне бик сайлап тудырырга кирәк. Сүз уңаенда әйтеп узыйк, чыгышының дәлилләнүенә комачаулыкны ораторның үз тавышы да тудырырга мөмкин (бик көчле яисә бик акрын сөйләве, тон диапазоны үзгәрү һ.б., ораторның тышкы кыяфәте, киеме үзенчәлекләре, нинди дә булса, юк кына сәер хәрәкәте, гәүдә торышы, ишарәсе һ.б.). Һәрнәрсәдә уртачалык, уйлап эш итү мөһим.

• Парадокс дәлилләр файдалану.

Күп кенә аудиторияләрдә дәлилләү барышында каршы фикер куллану файдалы. Бу алым бик авыр, аны баштанрак әйләнә-

тирәдән уйлап карарга һәм алдан әзерләргә кирәк, чөнки мондый дәлилләр истә ныграк кала, шуңа күрә файдалы булып чыга.

- Аудиториядән өстенлекне күрсәтү.

Аудиториягә үзегезнең укымышлылыгызны танытыгыз: аңлаешлы чит ил терминнарын, гарәп (латин, инглиз) телендә хикмәти фикерләрне кулланыгыз, чит ил чыганакларын әйтегез. Тик һәр очракта урталыкны сакларга кирәк, ләкин бу «тәрбиясезлеккә дәлил» дип аталган алым оратор сөйләменең инандыру көчен арттыра.

- Аз сүзлелек (тыйнаклык).

Аз сүзле булу таләбе – иң мөһимнәрдән. Кыска, аз сүзле сөйләм, һәрвакыт, төгәл була. Кыска чыгышлар, озыннарга караганда, әйбәт истә кала һәм аудиториягә акыллы һәм дөрес булып тоела, алар еш кына бик нәтиҗәле булалар.

Кыска чыгышларны аудитория дөрес дип таба һәм тиз үзләштерә. Кире кагылырлык фикерләрне алдан сизеп, үзебезнең аңлавыбызны хәбәр итсәк, аларның йомшак өлешләрен күрсәтсәк, яхшырак булыр. Чыгышта башта чит кеше карашын, ә аннан үзеңнекен тәкъдим итәргә була; шул рәвешчә, соңгы сүзне сез әйтәсез. Алдан күреп эшләү кискен каршылыклардан арынырга булыша. Без кире фикерне үзебезгә уңай чишелерлек итеп оештырабыз һәм аудиториягә дә үзебезнең файдага аңлатабыз, үзебезгә кирәкчә аңлатырга тиешбез.

- Авторитетларга таяну.

П.Сопер авторитетларга таянуның өч төрен аерып чыгарган: 1) оратор авторитетына таяну; 2) җәмгыять фикеренә таяну; 3) белемле авторитетларга таяну.

Аудиториягә танылган белгеч буларак билгеле яки халыкның ышанычын казанган булса, ораторның үз авторитеты аеруча үтемле була. Шуңа күрә ораторны иң беренче чиратта белгеч, үз эшенең остасы буларак таныштырырга кирәк, ул үзе турында үзе дә мәгълүмат бирә ала. Тыңлаучылар ораторның абруена ышансалар, алар яхшы гына тыңлап, чыгыш нәтиҗәләрен истә калдыралар һәм сөйләм рәвешенә карамыйлар. Әгәр дә чыгыш ясаучы әлеге аудитория өчен бик үк авторитетлы булмаса, тыңлаучылар хәбәр ителгән нәтиҗәләргә азрак игътибарлы булалар. Димәк, чыгыш ясаучы өйрәтүче ролендә булганда аның абруе уртача була. Өндәмә чыгышларда ораторның абруе бигрәк тә югары булырга тиеш.

Тирән белемле, абруйлы кешеләргә таяну – ул экспертлар, танылган белгечләр, ислам белеменең күренекле галимнәре, сәясәт эшлеклеләре фикеренә нигезләнү дигән сүз. Алар тарафыннан сөйләнгән мәгълүматны кулланганда, чыганакны төгәл күрсәтергә кирәк.

Югары дәрәҗәдәге абруйга сылтама – пәйгамбәребез Мөхәммәд (сгв) хәдисләре вәгазьчегә үз сөйләменең ышандыру тәэсирен көчәйтергә мөмкинлек бирә.

- Аңлаешлы, анык мисаллар куллану.

Мисалларны белеп куллану – олы сәнгать. Әйткәнебезчә, алар бик күп булырга тиеш түгел. Мисаллар аңлаешлы, дөресрәге, бик анык, күз алдына җиңел килеп баса торган, күзаллау сурәте уятучан, кызыксынуны арттыра торган булсалар кулай.

Мисаллар китерүнең 3 кагыйдәсе бар:

1) Бөтен игътибарны төп мәгънә турында хәбәр итә торган мисалга юнәлтергә.

2) Аудиториягә мисалның мәгънәсен көчләп такмаска тырышырга. Аудитория үзе нәтиҗәгә килергә тиеш.

3) Мисал бик яхшы уйланылган, кыскартылган һәм сезнең чыгышыгызга өлешчә кертелгән булырга тиеш.

Мисаллар итеп озын цитаталарны кыска итеп, тыңлаучылар анык күзалларлык рәвештә сөйләргә кирәк.

- Саннарны дөрес куллану кагыйдәләре:

1. Саннар аз булырга тиеш, шул чакта гына алар ышандырырлык була;
2. Китерелгән саннарны чагыштырып яки пропорциядә күрсәтергә кирәк;
3. Саннарны түгәрәкләп күрсәтү әйбәтрәк;
4. Статистик мәгълүматның чыганагын төгәл әйтергә кирәк;
5. Саннарны тезеп бирмәскә киңәш ителә.

- Вәгазь (чыгыш) вакытында күргәзмә әсбаплар куллану:

1) Күргәзмә материал сөйләмгә аныклык, игътибар арттыруга ярдәм итмәсә, аны кулланып тору мәгънәсезлек;

2) Күргәзмә материалны кирәкле мизгелдә генә кулланырга;

3) Таблица һәм графиклардагы язулар бөтен аудиториягә күренерлек булсын;

4) Һәр таблица буйга язылган һәм аның атамасы эре хәрефтән.

5) Статистик таблицаны диаграмма формасында бирү зарур, алар күләмне һәм үсеш юнәлешләрен ачыграк чагылдыра.

Тикшеренүләр күрсәткәнчә, нәтиҗәле графиклар – төсле, төрле размердагы турыпочмаклыклар;

6) Таблица һәм графиктагы мәгълүматны үз фикерләрегез белән бәйләү мәҗбүри;

7) Күргәзмә әсбапка түгел, ә тыңлаучылырга мөрәҗәгать итеп сөйләү мөһим;

8) Тыңлаучыларга бернинди дә әсбаплар һәм сурәтләр таратырга ярамый – бу аудиториянең игътибарын читкә юнәлтә;

9) Әгәр тыңлаучылар элеп куелган күргәзмә әсбапларны күзәтсәләр, пауза ясап, карап бетерергә ирек бирегез;

10) Әгәр сезгә нинди дә булса әйберне кулга тотып күрсәтергә кирәк икән, аны җилкә югарылыгында яки тагын да югарырак тоту отышлы.

## Үзләштерелгән белемнәрне мөстәкыйль тикшерү өчен сораулар һәм биремнәр

1. Инандыру ысуллары: мисал, тезис, дәлил, дәлилләү, раслау, типик дәлилләр, турыдан-туры раслау, читләтеп раслау – бәяләмә бирегез. Фикерләү схемасы: беренче мисал (очрак) икенчесенә бәйле, икенче мисал (очрак) дөрес, димәк шулай ук беренчесе дә, ихтимал, дөрес – мисал китереп аңлатыгыз. Тәҗрибәгә таянып кире кагу – ниндидер карашны тәҗрибә үткәреп тикшерү һәм кире кагу – мисал китереп аңлатыгыз

2. Дәлилләү барышы: исбатланырга тиеш раслау **(тезис);** тезисны нигезләү өчен китерелгән раслаулар **(нигезләү);** логик фикерләү, фикерләү нәтиҗәләре җыелмасы **(дәлилләү ысулы, рәвеше)**; бер яки берничә кабул ителгән дәлилдән яңа дәлил оешу **(фикерләү нәтиҗәсе);** исбатлау ышандырырлык, юнәлтелгән өстәмә мисаллар белән ныгытыла **(юнәлтелгән дәлилләр);** өр-яңа раслау **(йомгак, нәтиҗә)** – мисал китереп аңлатыгыз.

3. Логика кануннарына – охшашлык (тиңдәшлек); каршылык; өченчесе инкяр ителү; җитәрлек дәлилләнү – билгеләмә биреп үтегез.

4. Фикерләү сыйфатлары: ачыклык (аныклык); эзлеклелек, каршылык булмау; нигезле дәлилләнү – билгеләмә бирегез.

5. Нәрсә ул кире кагу ысулы? Үз фикереңне яклауда, оппонент фикеренә мөнәсәбәт белдерүдә бәхәс алымнары:

- юмор, ирония, сарказм;
- мәгънәсезлеккә җиткерү;
- кире “һөҗүм”;
- каршы як репликасын үзләштерү;
- сораулар белән күмү;
- шәхескә юнәлтелгән дәлил;
- җыелган халык фикеренә сылтама – аңлатып үтегез.

6. Инандыруның берьяклы ысуллары: йола, гореф-гадәткә нигезләнү; дөрес сиземләү (интуиция); ышануларга таяну; мәгънәсен, файдасын, максатчанлыгын исәпкә алу; зәвык тойгысына таяну – мисаллар белән аңлатып үтегез.

7. Башкаларның мәнфәгатен кайгырту; киң күңеллелек; хуплаулы мөнәсәбәт; итагатьлелек; килешүчәнлек; хәерхаклык – нинди дәлилләргә таләпләр? Һәрберсен аңлатып үтегез.

8. Әлеге алым-ысулларның кайсысы әдәпле булган, кайсысы әдәпле үк булмаган дәлилләү очракларына карый. Мисаллар белән аңлатып үтегез:

- аудитория фикеренә колак салу;
- шәхескә юнәлтелгән дәлил;
- җыелган халык фикеренә, хис-халәтенә сылтама;
- каршы як фикерләрен үз карашларыңны ныгыту өчен файдалану;
- масаючанлыкка сылтама;
- абруйларга таяну;
- көчкә таяну;
- мәгълүматсызлык, наданлыкка сылтама;
- кызгандыру;
- темадан аңлы рәвештә читләшү;
- хәл ителәсе мәсьәләләргә кагылышы булмаган «сүз боткасы»;
- төп фикернең җеп очын чуалту;

9. Уңай, кире; арта бара, кими торган; бер яклы, ике яклы; каршылыклы; индуктив һәм дедуктив дәлилләүгә мисаллар әзерләргә.
10. Таблицаны файдаланып, халык алдындагы чыгышның төп кисәкләре һәм максатлары турында сөйләгез.

**Халык алдындагы чыгышның төп кисәкләре һәм максатлары**

*Чыгышның төп кисәкләре*




11. Таблицаны файдаланып, чыгышка әзерләнү һәм халык алдында чыгыш ясауның төп өлешләре турында сөйләгез.

**Чыгышка әзерләнү һәм халык алдында чыгыш ясауның төп өлешләре**




12. Таблицаны файдаланып, чыгышларда мантыйк кануннарын файдалану турында сөйләгез.

**Чыгышларда мантыйк кануннарын файдалану**



13. Таблицаны файдаланып, чыгыш ясаучының аудиториягә йогынтысы турында сөйләгез.

**Чыгыш ясаучының аудиториягә йогынтысы**




**14. Таблицаны файдаланып, чыгышлар сөйләменә таләпләр турында сөйләгез.**

**Чыгышлар сөйләменә таләпләр**



# V. СӨЙЛӘМ ТӨРЛӘРЕ ҺӘМ АРАЛАШУ РӘВЕШЕ

## Нотык (монолог) сөйләме, төрләре

Ораторның, тыңлаучылар белән аралашып, үз карашларына күндерүдә берүзенең сөйләме монолог дип атала. Монолог – ачыктан-ачык аралашуның иң гади рәвеше, чөнки аралашуның максатын оратор билгели. Тыңлаучылар оратор сөйләменең эчтәлеген үзләштерә һәм шуның нигезендә оратор фикерләрен кабул итә яисә аның белән килешми.

Антик риторика, аралашуның төп төре санап, монолог өлгесен тикшергән. Аристотель – анализлы риторикага, ә Квинтилиан синтез алымлы риторикага нигез салучы булып исәпләнә. Аристотельнең системасы, нигездә, тыңлаучылар өчен кагыйдәләрне өйрәнсә, Квинтилиан системасында сөйләүчеләр өчен булган кагыйдәләр өйрәнелә.

Аристотель аеруча зур әһәмиятне топикага («топос» грекчадан – урын) – уй-ният оештыруда фикерләү үрнәкләре һәм аларны урынлы куллану ысулларына – акыл эшчәнлегенең гомуми каннунары турындагы тәгълиматка – биргән. Топос сүзен тәрҗемә иткәндә ул “урын” мәгънәсен белдерә. Сөйләмдә һәрбер сүз, фикерләү рәвеше үз урынына, үз мәгънәсенә ия була. Бу өлеш сөйләүчеләр өчен дә, тыңлаучылар өчен дә бер төрле аңлашыла торган булырга тиеш. Риторика фәнендә аерым тикшерүләргә, билгеле бер кагыйдәләргә нигезләнеп, монолог оештыру осталыгына өйрәнергә мөмкин. Бу кагыйдәләрдә монолог (нотык) эчтәлеге ораторның иҗади эшчәнлеге һәм аның тыңлаучыларга аңлаешлы булырга тиешлеге искәртелә.

Квинтилиан монолог оештыруның алым-чараларын тикшерә. Аның алым-чаралар җыелмасында фикер уйлап табу, дәлилне урынлы урнаштыру, сүз белән баету һәм сөйләм башкару өлешләре бар. Хәзерләнүнең иң җаваплы этабы итеп, ул уйлап табуны исәпли. Әйтеп бирү уйлап табу күнекмәләренә ия булу өчен Квинтилиан риторларга идарә хезмәткәре яки юрист һөнәрен үзләштерергә киңәш итә. Ул чорларда чыгыш ясауның эчтәлеген уйлап табу күнекмәләренә өйрәнү, идарә хезмәткәренең укуын тәмамлаган вакытларга туры килгән.

Ораторлык сәләтенә ирешүне Квинтилиан риторика тәгълиматын өйрәнү, уңай күнекмәләр үзләштерү, иң абруйлы

ораторларга охшарга тырышу һәм шәхси образ тудыру дип фаразлаган.

Монолог жанрына доклад, лекция, хөтбә уку-сөйләү, вәгазь сөйләү, хөкем чыгышы, мәйдандагы нотык, хәтта, теләсә нинди аудиториядәге аерым сүз һ. б. керә. Һәрбер жанр үзенә генә хас, махсус үзенчәлекләргә ия.

Аралашуның монолог рәвеше, антик заманнар белән чагыштырганда, хәзерге аралашу киңлегендә үзенең әһәмиятен югалткан. Антик аралашуда гражданлык хисе югары дәрәҗәдә була, хәзер дә әһәмиятле мәсьәләләрне тикшереүдә бөтен кешенең фикерен исәпкә алу зарур.

Сөйләм предметы турында фикер алышуда аралашуның диалог (әңгәмә) төре уңайлы. Шуңа күрә хәзерге риторикада монологны хосусый әңгәмә рәвеше итеп карау юнәлеше үсеш ала. Шулай исәпләгәндә монолог тәмамланмаган әңгәмәгә әверелә һәм аралашуның катлаулырак кануннарына буйсына.

Монолог, әңгәмәгә караганда, аеруча әһәмиятле ихтыяҗларны канәгатьләндерә. Шуның белән беррәттән, хәзерге аралашу даирәсендә монолог кулланылмаса да аралашу өзелми. Монолог яңгыраганда да, барыбер, үзара фикер алышу була һәм берләшмәнең уртак карашлары оеша.

### *Нотык сөйләме төрләре*

Рәсми һәм укыту сөйләмендә нотыкларның иң таралган төре – доклад. Докладның үзен дә ике төргә аерып карыйбыз: доклад һәм белдерү. Ике очракта да әлеге сөйләм төре фәнни, сәяси, яисә башка иҗтимагый мөһим темага багышланган эчтәлек рәвешендә башкарыла. Ораторның докладының эчтәлеге белән яңалык булырга тиеш. Ул аны тыңлаучыларга бәян итә һәм башка карашлардан аерылып торган шәхси фикерен "яклый".

Доклад гомумиләштерүнең фәнни-иҗтимагый даирәгә дә үтеп керүе сәбәпле, аралашуда киң таралган күренеш. Без тыңлый торган докладларда яңалык сирәк яки бик аз күләмдә, чөнки рөхсәт ителгән мәгълүматны гына сөйләү күзәтелә.

Белдерүдә яңалык азрак, шуның өчен күп кенә “докладлар”ны хәбәр тапшыру дип атарга һәм тиешенчә бәяләргә кирәк. Башлап чыгыш ясаучыларга доклад-белдерүләрендә нәзәкатьле булып, кулланылган чыганакларга сылтамалар ясап, тезисларны төгәл һәм аңлаешлы итеп оештырырга һәм табылган фикерләрнең кабул

ителгән кагыйдәләргә тәңгәл килүенә омтылырга кирәк, чөнки чыгыш шуларга нигезләнеп оеша.

Лекция – нотык жанрының иң таралган рәвеше. Аралашуда ул, бертөрлелеге сәбәпле, пафос һәм этосның тәрбия, белем бирү вазифасын үтәүгә нигезләнгән. Лекциянең төп бурычы – тыңлаучыларга мәгълүмат бирү һәм аларның акыл эшчәнлегенә тәэсир итәрлек шартлар булдыру. Монолог төре буларак, лекция, тыңлаучылар белән үткен фикерле аралашуны күзаллый, үзара аңлашу һәм тотрыклы эчтәлекне тәэмин итә. Аеруча бу караш аралашу эчтәлеген шәхси яссылыкка күчерә белүче һәвәс интроверт оратор өчен мөһим.

Нотык сөйләме төрләре – төгәл һәм максатчан оешкан чыгышлар. Мәсәлән, хөтбә, вәгазь, котлау, тантаналы гамәл, ритуал, киңәшмә, хөкем һ. б. нотык-чыгышлар бар. Алар максатчан аралашуны тормышка ашыруда ышанычлы ысуллар – махсус әзерләнгән гомуми гамәлләр яки сайлап алынган урынлы кулланылган алымнардан оешалар. Мондый алым-ысуллар эчтәлегендә мәдәни-тарихи үрнәкләр тупланган була, алар катнашучыларда максатка һәм аралашу темасына тәңгәл аерым бер халәт һәм хисләр чыганагын тәшкил итәләр.

Аерым сүз – монологның бер төре, гомумиләштерелгән үзенчәлеккә ия һәм йолалар үтәгәндә тавыш ярдәмендә тормышка ашырыла. Ул керештә, йомгакта, тантаналы мизгелдә һәм саубуллашканда яңгыраган сүзләр булырга мөмкин. Бу жанрда чыгыш дәвамлы түгел, оратор йола гамәлләрен, кабул ителгән тәртипне тавыш белән белдерә. Ритуал җайланмалар берләшмә әгъзалары эшчәнлегенең ниятенә әйләнә.

Вәгазь – сөйләм төре буларак, тыңлаучыларга таныш эчтәлеккә нигезләнә. Вәгазь сөйләүнең максаты – шушы мизгелдә тыңлаучыларның нинди дә булса әһәмиятле сюжетны төгәл аңлауларын үстерү.

Вәгазь сөйләү, күбесенчә, абруйлы кеше тарафыннан үтәлә. Кагыйдә буларак, ул дини, дөньяга караш һәм әхлакый мәсьәләләр белән бәйле. Вәгазь сөйләүченең төп бурычы – шәхси тәҗрибәсенә нигезләнгән, югары дәрәҗәдәге хисле сөйләм рәвеше оештыру.

Тәҗрибәле вәгазь сөйләүчеләр риторик сораулар, өндәүләр, эндәшләр, кабатлаулар, катлаулы периодлар, образлы ритмика һ. б. технологик ысулларны кулланалар. Доклад укучыдан, лектордан, сөйләм нигезе буларак – аңлаешлылык; ирекле темага чыгыш

ясаучыдан – чамадан артмаган рухи күтәренкелек таләп ителсә, вәгазь сөйләүчедән тыңлаучылар эчкерсез, ышанычлы, хисси аралашу көтәләр.

Хәзерге заман монолог төрләре мәгълүмати технологияләрне куллануга нигезләнгән. Алар урынлы һәм тиешенчә кулланылганда сөйләмнең мөмкинлекләрен шактый югары дәрәҗәгә күтәрәләр. Аудио һәм видео мөмкинлекләрен куллану ораторның оештыру, һәм йогынты куәсен һәм тыңлаучылар санын күп тапкырлар арттыра. Россиядәге һ. б. илләрдәге күп кенә көчле ораторлар мәгълүмати технологияләр мөмкинлеген шәхси аралашу мөмкинлекләре буларак кулланалар. Шуңа күрә, әлеге яңа алым-чаралар бүгенге көндә бик нәтиҗәле.

## Өндәмә (мәйдан) нотыклары

Митинг чыгышларының – мәйдан нотыкларының – максаты – бер тезисны хисси халәттә дәлилләп, эш-гамәлгә теләк уяту. Митинг нотыкларының башкарак төрләре – сәяси өндәмә белән чыгыш ясау, ризасызлык белдерү, сайлау алды чыгышы, бердәм хәрәкәткә, эш-гамәлгә чакыру һ. б.

Мәйданда чыгыш ясаучы җыелган халыкның теләк-омтылышларын нык тоемларга-белергә бурычлы. Митингка җыелган халык төркеме артык үзенчәлекле була:

1. Күпсанлылык. Бу күрсәткеч, үз чиратында, тыңлаучыларда интеллект дәрәҗәсенең кимүенә китерә. Д.Карнеги әйткәнчә, «төркем эчендә кеше, 5-6 кешелек төркемчектә игътибар да ителмәгән нәрсәләрдән мыскыллап көләргә яки кул чабып хупларга мөмкин».

2. Әзерлексез булу. Бу очракта материалны индуктив ысул белән – аерым фактлардан гомумилеккә омтылып – оештырырга туры килә.

3. Тәэсир көченең югары дәрәҗәсе. Төркемдә кеше бик тиз иярүчәнгә әйләнә. Аерым шәхес кичерә торган тойгы төркемдә дүрт-биш тапкыр көчәеп китә.

5. Тойгылы чакыру, өндәмәләрнең тиз үзләштерелүе. Мәйдандагы халык бик тиз һәм зур теләк белән гади, ләкин хисле яңгыраган, җиңел үтәлә торган өндәмәләргә колак салучан.

6. Акыллы, эшлекле (конструктив) тәкъдимнәрне авырлык белән бәяләү, аңлау. Төрле караштагы кешеләр тәкъдимнән,

өндәмәдән мәгънә эзләп тормый. Җыелган халык катлаулы фикерләү рәвешен бөтенләй кабул итми.

7. Тиз ышанучанлык. Халык бер яклы мәгълүматны тиз үзләштерә һәм инана башлый. Мәгълүматны тикшереп тормый. Көчле хисси халәттә яңгыраган ялганны да дөрес дип куәтләп торырга мөмкин.

Әлеге үзенчәлекләр чыгышның эчтәлегенә һәм ораторның үзенә дә зур таләпләр куя. Митингта нәтиҗәле чыгыш ясау өчен түбәндәге таләпләрне онытмаска кирәк:

- сүздә тәвәккәллек (мер-мер килмичә, белеп сөйләү);
- чыгышның кыскалыгы (2-3 минут);
- кыска тәгъбирләр куллану;
- тапкырлык (канатлы сүзләр, афоризмнар куллану);
- бер тезис, бер мәсьәләне тикшерү;
- башка карашларга урынлы (урынсыз) тәнкыйть сүзе;
- үз сүзеңә, башка карашларга бәя биреп бару;
- үзеңнең фикер аныклыгың («мин яклыйм», «мин каршы», өченчесе – юк!);
- сөйләмнең гамәли ягына игътибар: теге яки бу эшкә конкрет чакыру («мин сезне… өндим, «бу теләгемә кушылырга чакырам »);
- үз карашларыңны гомуми фикер дип тәкъдим итү.

## Аралашуда хисси халәткә ирешү алымнары: хуплау, кече күңеллелек, ташлама ясау (хәтер саклау)

Аралашуда – әңгәмә оештыра алуда, адресатның дикъкатен яулап аңлашуга килү, аны фикердәшкә, гамәлдәшкә әверелдерергә омтылуда күңелне канатландыру-үстерү, кече күңелле була белү, күңел саклау, күңел юату, ягъни хисси халәткә ирешү бик мөһим.

Халык алдында чыгыш ясауга әзерләнгән кешегә (шулай ук, үзен күпмедер дәрәҗәдә зыялы әңгәмәдәш итеп күзалларга теләгән һәркемгә дә), үз фикерләренә инандырырга да исәпләгән дин әһеленә, сөйләме белән тыңлаучыларның күңелләрен китү-кайтарудан сакланырга туры килә. Бу урында "Ышандыру максатында тыңлаучыларыңны үпкәләтмә" гыйбәрәсен кагыйдә дәрәҗәсенә күтәрсәк тә урынлы булыр.

Алай гына да түгел, адресатны мактап (берәүне аерып, башкаларны кимсетеп, маңгайга бәреп түгел, ә читләтеп сиздерсәк шәбрәк), аз гына булса да куаныч, үзенә ышаныч хисен үстереп

җибәрсәк; фикерләүдә үзебезгә тиңләштерә алсак, кайбер мәсьәләләрдә өстенрәк тә итеп күрсәтә белсәк, әңгәмәбез, алдыбыздагы һәртөрле бурыч-максатлар ике як өчен дә күңелдә канәгатьләнү уятыр.

Аралашуда канәгатьлек канунын сөйләм рәвешенә әйләндерүдә хуплау, кече күңеллелек, хәтер саклау (ташлама ясау) кебек алымнар һәм сөйләм рәвешләрен күзәтеп үтик.

Күңел үстерү һәм хуплау – тыңлаучыларны турыдан-туры яки читләтеп, ым-ишарә белән мактау, күңелләрендә яхшы кәеф дулкыны кузгату, шатландыру, өмет чаткысы уяту алымы һәм сөйләм рәвеше (мәсәлән, комплимент). Әлеге үтемле алым һәм сөйләм рәвеше чыгышларның кереш һәм йомгак өлешләрендә еш кулланыла. Мәсәлән, “Идегәй” дастанында Туктамыш ханның Субраны җырлатып, Идегәйне сынаганы (IV бүлек):

Аргы угыл да бирге угыл,
Шул читтәге шул угыл –
Кош борынлы Кобогыл,
Бүре пычым шул угыл,
Балтыры җуан, кулы үнән,
Җай татарга охшый шул угыл;
Ирене юка күренә –
Чичән икән Кобогыл,

Яурыны яссы, муйны озын –
Җәй тартамага кулы озын –
Мәргән икән Кобогыл;
Бармагы җиздәй маешкан –
Чибәр икән Кобогыл;
Чәче айдай балкыган –
Асыл икән Кобогыл;
Бите нурдай түгелгән –
Түрә булыр Кобогыл…

Хуплау сүзен куллану кайвакытта урынлы? Аның төрләрен барлап үтик:

• аерым очракларда шәхесне мактау, юбилейларда котлау сүзе, мәҗлесләрдә теләк теләү, шулай ук, дәфенләү чыгышлары да. Шәхескә мәдхия аның кылган гамәлләрен мактау, “күккә чөю” буларак оеша;

• тулы бер берләшмәнең (оешманың) эшчәнлеген, ирешелгән казанышларын хуплау, алдагы уңышларга ышаныч белдерү;

• ниндидер күренеш (фәндәге ачышлар, гомуми максатлар, билгеле бер “очрак” буенча җыелган халык алдында) белән кызыксынуны арттыру, ирешелгән югарылыкларны хуплап, яңа ачышларга, эш-гамәлгә рухландыру.

Хуплау чыгышлары тыңлаучыларда рух күтәренкелеге уятырга, актив хисси халәт булдыруга юнәлдерелә. Адресатның күңел кылларын нечкәртү мәңгелек кыйммәтләрне – әхлак кануннары һәм кагыйдәләрен, мәрхәмәтлек, явызлык, яманлык төшенчәләрен, халык тарихындагы истәлекле вакыйгаларны, аның иманы, гореф-гадәтләрен – искә алудан башлана.

Мактау-хуплау өчен сәбәп табылып кына тора.

Ни өчен мактыйбыз һәм “күккә чөябез”?

Аристотель тарафыннан бирелгән җаваплар, бераз гына үзгәреп, бүгенге көндә дә бик отышлы.

Аристотель фикеренчә[1], игелек кылу, хәерле гамәл һәртөрле чагылышында да мактауга лаек. Игелек кылуның иң югары чагылышлары: батырлык, кыюлык, гаделлек, миһербанлык, киң күңеллелек, эчкерсезлек–риясызлык, юмартлык, шәфкатьлелек, инсафлылык һ. б.

Истәлекле вакыйга, күренеш, атаклы шәхесләр һәртөрле мактауга лаек. Өлкән буыннарның дан-шөһрәтенә тиңләшү, гореф-гадәтенә тугърылык та мактау җирлеге була ала.

Җәмгыять, кешелек өчен файдалы һәрбер эш-гамәл, шулай ук, мактау объекты булып тора.

Мактау кагыйдәләре:

1. Адресат факторын исәпләү. Аристотель аудитория югары бәяләгән кыйммәтләрне мактарга киңәш иткән.

2. Борынгылар, мәдхия җырлаганда, очраклы рәвештә кылынган күркәм эш-гамәлне дә күңел омтылышына бәйләп, “алдан ниятләнгән” итеп күрсәтергә тырышканнар.

3. Хуплау сүзен оештыру, көчәйтү һәм арттырып җибәрү чараларыннан башка мөмкин түгел. Хәерле эш-гамәлне мактаганда бу эшкә шәхеснең керүзе һәм беренчеләрдән ке-решүе, уңайсызлык һәм нык каршылыкларны җиңүдә тиң-дәшсез кыюлык үрнәге күрсәтүе дә арттырылып тасвирлана. Һәм, әйтергә кирәк, әлеге чаралар хуплаулы сөйләм рәвешендә ялган, хакыйкатькә хилафлык булып кабул ителмиләр.

4. Игелекле эш башкарган шәхесне “күккә чөйгәндә” чыгыш ясаучы аны тарихи шәхес, атаклы кешеләр белән тиңләштерә, алар кылган эш гамәлләр дәрәҗәсе белән чагыштырып карый.

[1] К.: Аристотель. Риторика: I книга. 9 // Античные риторики. – М.: МГУ, 1987.

Алай ук мактап булмаса, шәхесне гадәти күренеш-вакыйга, бернениди күренекле эш-гамәл кылмаган кешеләр белән чагыштырып, җәмгыять өчен файдалы хезмәте өчен мактыйлар.

Үзенчәлекле риторик жанр буларак оешкан мактау-хуплау сүзе – комплиментны күзәтеп узыйк. Комплимент – электән үк билгеле чагыштырулар һәм метафораларны, риторик алымнарны (гипербола, антитеза, градация, амплификация (бизәкләү) һ. б.) яңа мәгънә төсмерләре тудыруда оста файдаланып, күңелне хушландыру (үсендерү) өчен кулланылган сөйләм жанры. Комплиментны күңел күрүгә исәпләнгән кыска мактау сүзе; чамасын, урынын, вакытын белеп ясалган мөлаем кисәтү дип тә әйтә алабыз.

Комплимент оештыруның төп кагыйдәләрен барлап үтик:

- чынбарлыкка туры килгән (табигыйлек) һәм күпертелгән (шартлылык), ләкин яратып әйтелгән, ягымлы тонда яңгыраган сүзнең чамадан чыкмый ярашуы, икенче төрле итеп әйтсәк, табигыйлек һәм шартлылык бердәмлеге;
- нәзәкатьле, тапталмаган, итагатьле, эчкерсез эчтәлекнең җыйнаклыгы;
- комплимент – гади хәбәр генә түгел; ул сизелер-сизелмәс күпертелгән бәяләр, серле табышмак, каршылыклы чагыштырулар булганда күркәм яңгырый.

Тыңлаучыларның күңелләрен яулауда иң үтемле чаралардан – адресантның үз ялгышларын тануы, элеккеге хаталары өчен үкенүен белдерүе. Әдәби әсәрдән мисал итеп, “Идегәй” дастаныннан “Идегәйнең улы Норадынга рәнҗеп әйткәнен” китереп үтик:

Идегәй анда рәнҗеде,
Рәнҗегәндә моны әйтте:
– Норадын да булсаң, булсана!
Болытка җиткән Нарс тауны
Җилеп үк тә үтсәң үтсәнә!...
Ханга лаек туды дип,
Ханнан кәбеч алдырдым;...
Күкрәгең яулы үссен дип,
Качкан яуны кудырдым,
Башлап ханны кудырдым,
Аны да синнән үтерттем,
Картайган да көнемдә
Үз башыма көч иттем!...
Син дигәндә җан аткан
Ялгыз атаң мин идем,
Күзем орып чыгардың;
Кайда барып уңарсың?
Кайда бер барсаң, тынарсың?
Язгы белән гөнаһысын
Кайда ла барып йоларсың?

Әлеге чаралар сөйләмдә кече күңеллелек алымының нигезен тәшкил итә. Чыгыш ясаучы хата дип саналырлык гамәлләрен барлап, ихласлыгын таныта, үзен адресат белән бер дәрәҗәгә куя һәм аларны фикердәшенә әверелдерә ала. Адресат чыгыш ясаучының кече күңелле булып кыланганын тойса, киресенчә дә булуы ихтимал.

Бер әңгәмә дәвамында фикердәш-гамәлдәш "тәрбияләүдә" тыңлаучыларның хәтерен саклый алу, ташламалар ясау үтемле алым. Бу алымның асылында каршы якның фикере белән килешкән булып, тыңлаучылар белән берлектә ул фикернең ялгышлыгын исбатларга омтылу ята.

Чыгыш ясаучыга, үз фикерләренә каршы яңгыраган сүзгә каршы "юк, сез хаклы түгел" дип катгый җавап кайтарудан сак булырга киңәш ителә. Әңгәмәдәшнең хәтерен калдырмаска тырышып, бәхәсле мәсьәләләрдә: "Әйе, ләкин..."; "Менә бу фикер белән килешәм, тик..."; "Сез сөйләгән сүзләр дөрес, ә бу очракны ничек аңларга..."; "Дөп-дөрес, шулай да..."; "Сез хаклы, шуңа да карамастан..." кебек лексик калыплардан файдалану, оппонентның фикерләрен фаразлап карау да ташлама ясау алымы буларак бәяләнә.

Әле аталган алымнар тыңлаучының күңеленә сүз белән тәэсир итүдә нәтиҗәле, беренчел адымнардан.

## Котлау сүзе

Котлау – иң гади һәм нык өйрәнелгән нотык төре. Төрле берләшмә-оешманың тулы тормышы өчен кешеләрне берләштерү, эшчәнлек сәбәп-шартларын булдыру, берләшмә мәнфәгатьләре өчен җан ату хисен тәрбияләү һ. б. шундый максатларда котлау сүзе нык тәэсир көченә ия.

Гадәттә, төрле бәйрәмнәр һәм күңел ачу кичәләре котлау сүзләре белән үрелеп бара. Аларның төп максаты – барлык кешеләрне туплау, бәйрәм мохитен тудыру.

Бүләкләү документларын, тантаналы чыгышларны, тәбрикләү сүзләрен, шатлык белән уртаклашу хатларын, бәйрәм телеграммаларын, куанычлы мәгълүматны, котлау адресларын һ. б. котлау сүзенә кертәләр. Бу стиль нигезендә мактау сүзе яки тантаналы сөйләм ята. Күп очракта, башлап чыгыш ясаучылар тантаналы сүзләр таләп ителгән халәттә, кыенсынып, эндәшми калалар. Аларга, мондый җитешсезлекләреннән котылу өчен, нәрсә

эшләргә кирәк соң? Иң гади юл – үз күңеләңне күрү-күтәрү. Әгәр оратор бәйрәм рухын тойса, бернинди дә авырсынулар булмый. Бәйрәм вакытларында тәнкыйть сүзе урынлы түгел, ул тантаналы нотык үзенчәлегенә карамый.

Котлау сүзе ике төп компонентны берләштерә: ритуал – гадәт-йола үтәү һәм шәхси мөнәсәбәт белдерү. Бу компонентларның өлешчә чагыштырмалыгын саклау бик мөһим. Йола үтәү берләшмәнең гадәтенә әверелә. Мактау сүзен әйтү өчен эшчәнлекнең даими үсешен, аерым кешеләрнең уңышларга ирешүен истә тотарга һәм аларны берләшмә фикере итеп һәм шул берләшмә сөйләме рәвешендә яңгырату кирәк. Бу тыңлаучыларга рухландыргыч тәэсир итә.

Шәхси мөнәсәбәт йола белән тәңгәл килергә тиеш. Бу очракта үзара эшчәнлектә җанлану, үсеш күзәтелә, карашлар алмашына. Шәхсилек эчкерсез кичерешләр белән көчәеп китә. Тантаналы сөйләмдә шәхес һәм коллективның мөнәсәбәтен ачыклау зарур.

Тантаналы сөйләм оештыруда үз алымнарының җитешмәвен тойган башлап чыгыш ясаучыга “бәйрәм эчтәлеге” образын тудыруны – “бәйрәм уйнап карауны” тәкъдим итәргә була. Бу “уенга” аның күңеленә якын булган вакыйгалар һәм, очрагына карап, тыңлаучылар өметләнгән төрле жанрдагы сөйләм үрнәкләрен кертергә кирәк.

## Тәкъдим итү чыгышы

Тәкъдим итү чыгышы борынгы чордан билгеле. Ул теләсә нинди оешма эшчәнлегендә кулланыла. Гадәттә, тәкъдим итү чыгышы җитәкчелекнең берләшмә әгъзаларына эшчәнлек юнәлешләрен үзгәртүен хәбәр итүендә оеша. Җитәкчелек алмашынганда, яңа җитәкче тәкъдим итү чыгышына мөрәҗәгать итеп, үзенең борчулары, ниятләре турында сөйли.

Риторик жанрның әлеге төре чыгыш ясаучыдан пафослы сөйләм таләп итә. Бу бурыч җиңелләрдән түгел. Берләшмә стратегиясе алышыну яки җитәкчелекнең үзгәрүе киләчәк өчен зур борчу тудыра. Тыңлап утыручыларның сөйләгәннәргә тәнкыйть күзлегеннән каравы эшне кыенлаштыра. Әгәр дә инде каршы фикерләр әйтелсә, ситуация тагын да катлауланырга мөмкин.

Тәкъдим итү чыгышының түбәндәге күрсәткечләрен аерып чыгарырга мөмкин:

- аралашу өчен уңайлы урынны һәм вакытны сайлый белү зарурлыгы. Сөйләүчеләр чыгышлары белән уңай кичерешләр барлыкка китерергә тырышалар;
- әлеге ситуациядә кереш сүзне берләшмәнең нейтраль позициядә торучы абруйлы әгъзасы әйтсә, уңышлы була;
- чыгыш ясауда төп максат – тыңлаучыларның оратор белән танышуы. Сөйләүче аудиторияне аңлавын таныта белергә тиеш. Берләшмәнең берәр әгъзасына мөрәҗәгать итеп (исеме белән дәшеп), чыгыш ясау борынгы чорда да уңышлы алым булып саналган;
- сөйләшүдә берләшмә өчен әһәмиятле мәсьәләләр тикшерелә. Оратор үзе белгән чишелеш юлларын да өсти ала. Махсус сәбәпләр булмаганда, тыңлаучыларда кызыксыну кузгатмый торган сорауларга мөрәҗәгать итү киңәш ителми;
- оратор әдәплеге белән аерылып торырга, сөйләменең йогынтылыгын игътибар үзәгендә тотарга тиеш;
- ораторга ялыктыргыч сөйләмнән сакланырга кирәк. Вакыт-вакыт ораторның тыңлаучыларны киләчәктә көтелгән хәлләр (перспектива) белән рухландырып алуы уңышлы була;
- чыгышның ахыры оптимистик өндәмәләр, мөрәҗәгатьләргә бай булса яхшы. Соңыннан тантаналы аралашуга күчәргә мөмкин.

## Хөкем чыгышлары

Россия хокук системасындагы 1864 нче елгы реформага кадәр хөкем (суд) сөйләме киң кулланыш тапмаган.

1864 елгы реформа башлану белән, Россиядә дә, күренекле суд ораторлары өлгереп җиткән, мәсәлән: В.Д. Спасович, К.И. Арсентьев, Ф.Н. Плевако, А.Ф. Кони. XX гасыр башындагы революцияләр бу күренешне туктаткан. Хөкем һәм хокук сөйләме, суд әһелләренә тәэсир итүне, суд тикшерүендә катнашучыларның карашларына, бөтен дәүләтнең хокук даирәсенә һәм бер үк профессиядәге кешеләрнең берләшмәсенә йогынты ясауны максат итеп куя.

Танылган рус ораторлары, тирән хис-тойгы халәтен тудырып, гражданлык тибында чыгыш ясаганнар. Алар азатлык, гаделлек һәм хакыйкатьнең рәсми вәкилләре булганнар.

Хөкем кылу сөйләме өч өлешкә бүленә: гаепләүче (прокурор сөйләме), яклаучы (адвокат сөйләме) һәм судьялар сөйләме. Хәзерге вакытта хөкем теленең нигезе – дәлилләү һәм исбатлау.

Хөкем сөйләмендә максатны тормышка ашыру өчен оратор фактлар, мөнәсәбәтләрне ачыкларга, аларны исбатларга һәм тыңлаучыларны сүзенең дөреслегенә инандырырга тиеш. Оратор үзенең эшчәнлегендә – хокук даирәсен үстерүдә – түбәндәге эчтәлекле вазифалар башкара:

- фикер алышу предметын тәшкил иткән юридик фактлар системасын булдыру өчен хокук ситуациясен ачыклап бирү;
- факт (мисаллар) хокук ситуациясе белән берләшкән объектив предмет сыйфатында бирелә. Әлеге риторик буынны башкару өчен, фактка бәйле рәвештә хокук кануннарын ачыклап, кабул ителгән аныклыкны табу;
- хокук нигезләре язма рәвештә төрле мәгълүмати-хокукый инстанцияләрдә (идарә итү органнары системасында үзара бер-беренә буйсынган суд яки административ оешмалар) туплана, аларга закон текстлары, законның актлары, комментарийлар (аңлатма), карарлар, хокук бозу тасвирламалары керә. Дәлилләүдә хокук чыганакларының тикшерелә торган очракка туры килүе сөйләмдә итагатьлелекнең мөһим шарты булып тора;
- сөйләмне хокукый мәсьәләләр тәэсирен көчәйтергә булыша торган сәяси-мәдәни контекстта алып бару таләп ителә. Хокуктан тыш нигезләүләрне сайлау сөйләмнең нәтиҗәлелеге өчен бик мөһим;
- әле күрсәтелгән шартларның җыелмасы, катлаулы мәдәни-хокукый эчтәлекле тезисның сыйфатына тәэсир итә;
- тезисның дөреслеге дәлилләнгән фактлар һәм риториканың гомуми кануннары ярдәмендә исбатлана.

“Хокук нормалары бозылган очракта гына алар үтәлә” дигән әйтем билгеле. Россиядә хокукый дәүләт төзү зарурлыгы, хокукый аралашу даирәсенең җәмгыятькә тәэсиренә һәм аның сыйфатына бәйле. Закон саклау өчен көрәш, халык белән аралашу даирәсендә башлана һәм төгәлләнә. Шуңа күрә хокук даирәсендә хезмәт итүче, әйдәүче шәхесләрдән сөйләмнәрен аңлы рәвештә оештырулары, шуңа өйрәнүләре таләп ителә.

## Нотык сөйләм алымнарына төшенү

Нотыкны сөйләүдә төп шарт – алдан-алы сөйләмне итагатьле максат-бурычларга буйсындыру. Тыңлаучыларның бурычы – оратор сөйләмен игътибарлап тыңлау, аңлы рәвештә үзләштерү, истә калдыру һәм карашларын кабул итү.

Игътибарлы тыңлауның үз кагыйдәләре, алым-ысуллары бар һәм аны үзенә күрә бер осталык дип танып була. Тел өйрәнгәндә без сөйләргә һәм тыңларга күнегәбез. Мәдәниятне үзләштергәндә без телне аңлап, үз фикеребезне оештырабыз.

Гомумән, сөйләмне тыңлаганда, без аңа төшенәбез һәм аралашу рәвешенә әйләндерәбез. Мәдәнияткә тартылу никадәр көчле булса, кешенең аңы да зирәкләнә һәм баш миебез яңа мәгълүматны кабул итәргә әзер була.

Кайбер очракларда, тыңлаучы билгеле бер сөйләм үрнәкләрен, фикерләү рәвешен, үсеш дәрәҗәсе һәм максаты башка булу сәбәпле, аңламый һәм тәңгәл кабул итәрлек мөмкинлеге дә булмый.

Аристотельнең сөйләмне аңларга булыша торган үрнәкләре, күрсәтмәләре, аны кабул итү алгоритмы турында беләбез. Антик философ ялгыз сөйләмне аңлау рәвешенә түбәндәгеләрне керткән:

- оратор образы;
- сөйләм төрләре;
- билгеле бер чыгыш төренең образы;
- чыгышта хиссилек;
- сөйләмнең мәгънәви (логик) эчтәлеге;
- композициясе һәм стиле.

Әлеге тикшерү рәвеше монологны аңлауга этәргеч ясап кына калмый, аны аңлы рәвештә бәяләргә дә булыша.

## Мәгълүматның кабул ителүе буенча тыңлаучылар төре

Аудиториягә тәкъдим ителгән мәгълүматка тыңлаучылар төрле мөнәсәбәттә була.

Тыңлаучыларны берничә төркемгә берләштерәбез:

1. Чыгыш өчен борчылучылар.

Бу тыңлаучылар, чыннан да ораторны яки берәр чыгышны тыңларга махсус киләләр. Аларда темага яки оратор шәхесенә карата кызыксыну көчле. Бу төркемгә үз карашларын киңәйтергә теләгән кешеләр керә, аларның активлыгы югары була. Мәгълүм булганча, әлеге төр тыңлаучылар профессиональ уку аудиторияләренең күпчелеген тәшкил итә.

2. Битараф тыңлаучылар.

Алар мәгълүматка битараф (нейтраль) мөнәсәбәттә торалар, тик аерым фактлар белән кызыксыну булырга мөмкин. Күп очракта

чыгышка алар сүз тыңлап кына киләләр. Аларның игътибарын җәлеп итү мөһим.

3. Гадәттән тыш килешүчән тыңлаучылар.

Гадәттә, алар аз санлы, күп очракта алар кулланучы кешеләр яисә ораторның чыгышы алар өчен күрсәтмә бирүгә тиң. Мәсәлән, туристлар төркеменең күрсәтмәләр (инструктаж) алгандагы очрашуында маршрут, җыелу урыны, нәрсәләр алырга кирәклеге турында сүз барганда тыңлаучыларның бөтенесе дә гаять җанланып китә.

4.Кире беткән тыңлаучылар (каршылыклы төркем).

Бу тыңлаучылар темага, материалга, лекторга һәм бөтенесенә берьюлы тискәре караштa.

Алар дәлил белән риза булмаска тырышалар, иҗтимагый тормышта катнашабыз дип уйлап, кимчелекләрне тәнкыйтьләп канәгатьләнү хисләре кичерәләр яисә уңышсызлыкларын, начар кәефләрен башкаларга сылтарга мөмкиннәр.

Бу төр тыңлаучылар теләсә кайсы аудиториянең 10 % тәшкил итә, әлеге сан үсештә булмый, даими килеш кала.

Аудиториядә мондый тыңлаучыларны аерып буламы? Билгеле, алар чыгышлар алдыннан арткы рәтләргә, ераккарак утырырга тырышалар. Аларга нинди мөнәсәбәттә булырга? Әгәр комачауламасалар, күрмәмешкә салышырга. Аларны кызыксындырырга кирәкми, көтелгән нәтиҗә күзәтелми, ә көч – сарыф ителәчәк.

5.Теләктәшлек күрсәтүчеләр. Алар актив тыңлаучылар, тик исләре китмәгән кебек утыралар. Кайбер тикшерүчеләр күрсәткәнчә, уртача статистик аудиториядә игътибары сөйләүчегә төбәлгән тыңлаучылар – 30 % тәшкил итә; игътибарсызлар – 10 %, ә 60 % тыңлаучыны – «уятырга» туры килә.

Әгәр чыгыш ясаучы аудиториянең активлыгын 50-60 % җиткерә алса, хәбәрне, чыгышны уңышлы дип санарга кирәк. Бөтен кешене кызыксындырып булмый, аның өчен тырышырга да кирәкми.

## Нотыкны бәяләү мәсьәләсе

Аристотель тарафыннан тәкъдим ителгән нотык тикшерү схемасы гомуми күрсәткечләрдән аермалы, сирәк очракларны күз алдында тота. Бирелгән анализ рәвешен даими куллану гадәткә әверелә һәм үзлегеннән тормышка ашырыла башлый. Экспертларның моңа охшаш бәясе тыңлаучыга үзенең шәхси

фикерен тупларга мөмкинлек бирә. Тыңлаучы, соңгы нәтиҗәләрне фаразлап, аңлы рәвештә, оратор карашы белән килешергә дә, кире кагарга да, берләшмә өчен зыянлы булганда, бу фикерләр белән көрәшергә дә мөмкин.

Нотык сөйләмен тикшерүне җиңеләйтү өчен, риторикада кагыйдәләр җыелмасы оешкан:

•чыгышның бөтен эчтәлеген дә игътибар белән кабул итәргә;

•сөйләмдә аңлашылып бетмәгән, куркыныч фикерләр булырга мөмкинлеген, алардан котылу юлын фаразларга;

•ораторның максатларын чыгыш эчтәлегеннән аерып карау урынлы була;

•мәгълүмат бирелгәндә ораторның холкын, шөгылен, шәхес үзенчәлекләрен, кызыксыну даирәсен, ниятен һәм теләкләрен аңларга;

•оратор тезисының, карашларының уңай яки тискәре мәгънәсен аңларга;

•тыңлаучы оратор тезислары һәм карашларының тискәрелеген сизсә, аларны ирексезләп тагуга каршылык күрсәтергә.

Бу кагыйдәләр тыңлаучы образының тәнкыйтьчәнлеген хуплый, үз кызыксынуларын һәм берләшмә мәнфәгатьләрен тормышка ашыруга юнәлтелгән булуын раслый. Тыңлаучы бу кагыйдәләрне үтәп, үзе өчен оештырылган сөйләмнең эчтәлеген кабул итеп кенә калмый, ә чынбарлыкта аны тикшереп, аңлап, шәхси уй-фикерләрен оештыра, оратор карашларына, гомумән, чыгышка мөнәсәбәтен тәгаенли. Тыңлаучының мондый гражданлык мөнәсәбәте демократик һәм килешүчән аралашу нигезе булып тора.

### ***Ораторның үз нотыгын тикшерүе***

Сүзне тиешле дәрәҗәдә аңлау һәм чыгышка (монолог-нотыгына) үз карашларын билгели алу һәркем өчен дә әһәмиятле. Тыңлый белү кагыйдәләрен үзләштергән оратор үз сөйләм эшчәнлеген бәяли ала һәм аны камилләштерү мөмкинлегенә ия була.

Ораторның сөйләмен һәрьяклап тикшерү һәвәслеге, үз рефлекслары аның һәм тыңлаучы карашларын берләштерүдә булышлык итә.

Ораторның үз образын тикшерүе – сөйләм эшчәнлеге турында мәгълүмат туплауда да беренче адым. Нотык барышында,

әйткәнебезчә, оратор образы, аралашу нигезен тәшкил итә. Оратор образы тыңлаучыларга күп кенә алым-чаралар ярдәмендә тәэсир итә. Ораторның тышкы кыяфәтен төп риторик мөмкинлек дип аңларга кирәк. Образ тудырганда, аны уен рәвешендә оештырып, конкрет бер кешенең сөйләмендә кулланылган рольләр җыелмасы итеп карыйлар.

Билгеле бер сөйләм төрендә аерым бер роль башкаруны образ тудыру дип тә, билгеле бер эшчәнлек дип тә карап була. Сөйләмнең төреннән чыгып, без мәгълүматны төрле максатта тапшыра алабыз: шатландыру, төрле хисләр уяту, өметләндерү, тәрбияләү, яңа мәдәни үрнәкләр барлыкка китерү, шәхес структурасын алыштыру һ. б. Сөйләм төп максатына яраклы образны таләп итә. Максат никадәр катлаулы булса, образ да максатчан мөмкинлекләргә шулкадәр бай булырга тиеш.

Һәрбер чыгышны тикшереп барырга кирәк. Бу эш ораторны тыңлаучылары фикереннән хәбәрдарлыкка ирештерә.

Ораторның игътибар үзәгендә тыңлаучының хис халәтенә тәэсире, аның дәрәҗәсенә бәя бирү булырга тиеш. Көлү һәм елау, мәхәббәт һәм үч – барысы да сөйләүченең осталыгы һәм сәнгати мөмкинлекләре белән башкаларга тәэсиренә бәйле.

Әлегә кадәр тикшерелгән һәрбер юнәлеш тә, оратор образы һәм сөйләменең тыңлаучыга тәэсире турында барды. Иң әһәмиятлесе – сөйләмнең эчтәлеге. Сөйләм төзелешенең мәгънәви (логик) анализы һәм дәлилләрнең кыйммәте – сөйләм үтемлегенең кирәкле өлеше. Һәркемгә дә сөйләмнең "мәгънәле" дигән бәяләмәсе мөһим.

Тезис эчтәлеген барлыкка китергән уйлануларның ныклы төзелеше төп фикер һәм карашлар дөреслеген исбатлый, тыңлаучыга көчле дәлил буларак тәэсир итә. Логик үрнәкләр, дөрес карашлар, хак нәтиҗәләр ясауга мөмкинлек бирү сәбәпле аларга иярү, сөйләмнең тәэсир көчен арттыра.

Һәм, ниһаять, композиция төзү һәм стиль оештыру өлкәсендәге осталык сөйләмне төгәл, аңлаешлы, истә калучан һәм үтемле итә.

## Нотыклы аралашуда сораулар

Аралашу мохитендә сорау оештыру фикерләр алмашу бурычын үти. Аралашуда, фикер алмашуның күпчелек өлеше аңламыйча эшләнелә.

Шуңа күрә монологта сорау-җавап халәтенең нидән гыйбарәт булуын карап узыйк. Логика фәнендә сорау бирү танып белүдәге

билгесезлекне бетерү таләбе дип аңлатыла. Тәҗрибәгә нигезләнгән фәннәрдәге барлык фикерләр дә гипотеза дигән караш бар, шуңа күрә дә һәр раслауны сораугa әверелдерергә мөмкин.

Икенче шарт шул, теләсә нинди сорау ике өлештән тора: эчтәлекне аңлатып үтү, ә ул төгәллеккә мохтаҗ һәм сорау өлеше. Сораласы эчтәлекне аңлатып үтү сорауның алшарты була. Сораулар, алшартлары анык булса, әдәпле, ихлас фикер булалар. Нигез алшарты ачыкланмаган сораулар, логик фикерләүдән чыгып, әдәпсез сораулар булалар. Аудиториядә яңгыраган күп сорауларны, тиешле аңлатма бирелмәү сәбәпле, әдәпле дип булмаганлыктан, җавапсыз калдырсаң да ярый. Аларны төзәтелгән рәвештә тәкъдим итеп җавап бирергә була. Мондый хәл чыгыш ясаучының караш-фикерләрен көчәйтә , чөнки ул бәхәс өлкәсендә үз мәдәни дәрәҗәсен чагылдыра, шулай ук сорауның үзенә җайлырак нигезле шартын тудыра ала.

Оратор төгәл сорауны кабул иткәч, аны үзенең фикерләве өчен алшарт буларак аерып алып, карашларын чагылдырган тезисы итеп кулланырга тиеш. Сорауның тезисы үзгәртелгән, киңәйтелгән, оратор карашы белән аваздаш булырга яки туры килмәскә мөмкин. Моннан тыш, оратор аңлы рәвештә җавап бирү рәвешен сайлап ала. Җаваплар көчлегә һәм көчсезгә бүленә. Көчле җавап танып белүдә билгесезлекне, аңлашылмаган төшенчәләрне тулысынча юкка чыгара, көчсезе – өлешчә генә. Җаваплар тагын тулы һәм өлешчә дә була. Тулы җавап катлаулы сорауның барлык кечкенә кисәкләрен дә аңлатып үтә. Ә тулы булмаган җавап сорауны өлешчә генә канәгатьләндерә.

Үзеннән-үзе аңлашыла, чыгыш ясаучы җавапларының сый-фаты аның әзерлегенә, сайланган темасын ни дәрәҗәдә белүенә һәм мәдәни үсешенә бәйле. Әмма, сорауларга җавап бирүдән качу тискәре нәтиҗәләргә генә китерә. Сораулардан курку хисе көннән-көн арта бара, чыгыш ясауны чикләгән көч тагын да арта. Ораторга бу халәтне барыбер җиңәргә һәм бөтенесен дә яңадан башларга туры килә.

Нотыклы аралашуда катнашучыларның сорауларына җаваплар килеп туган хәлне җанландырып җибәрә һәм нотыкны берләшмә оештыру өчен нәтиҗәле, әмма тормышка ашыруы катлаулы булган, фаразланган әңгәмә рәвешенә, ягъни кара-каршы сөйләшүгә якынайта. Үзара аралашуда, гадәтләнгән буенча, сораулар бирмиләр. Шуңа күрә риторика сәнгате өлкәсендәге белгечләрнең

сораулар бирергә, аларны төрләндерергә чакырган өндәмәләре һавада асылынып, буш сүз булып кала. Нигә шулай?

Сәбәпләр берничә: сорау тыңлаучыны аралашу субъектына әйләндерә; аңа игътибар итәләр; тыңлаучы анонимлыкны, ягъни билгесезлекне югалта, ул чыгыш ясаучы һәм аралашу оештыручыларның кызыксыну даирәсенә эләгә. Башлап чыгыш ясаучыларга сораулар белән сак эш итәргә кирәк. Бу проблема һәр ораторның мөмкинлекләренә һәм карашларына бәйләнгән. Аралашуның эчтәлеге һәм рәвешенә карап, сораулар я күп, я бөтенләй булмаска мөмкин. Чыгыш ясаучы бирелергә мөмкин сорауларны алдан уйлап куярга һәм сорау-җавап мизгелләрен даими күзәтеп торырга мәҗбүр.

### *Сорау төрләре*

- Каршы сорау. Бу сорау әңгәмәдәшеңнең соравына җавап рәвешендә бирелә. Әлеге очракта «Бик теләп җавап бирер идем, ләкин килешегез, минем соравым алданрак бирелде, башта сез шуңа җавап бирсәгез иде» дип сүз башлау кулай.
- Юнәлтелгән сорау. Бу сорау ораторның фикерен бер генә юнәлешкә этәрү, ике карашның берсен сайлау мөмкинлеген (альтернатива) калдырмау максаты белән бирелә. Фактик рәвештә, бу – риторик сорау, сорау-фикер, сорау-җавап. Мәсәлән, «Көнбатышның финанс ярдәмен кабул итеп, бәйсез була алырбызмы икән?» Бу сорауларга ике төр мөнәсәбәт күрсәтергә мөмкин: беренчедән, бу сорауны риторик итеп түгел, ә бәлки мәгънәви, ягъни кирәкле сорау дип кабул итәргә мөмкин: «Бик кызык сорау. Соравыгыз аңлашылды. Бу – катлаулы сорау, шулай да аңа җавап бирергә мөмкин…» һ. б. Икенче ысул: сорауда тәкъдим ителгән фикернең дөрес икәнен күрсәтү (сез хаклы, ләкин ул аерым бер шартларда гына дөрес була ала, бездәге шартлар исә бөтенләй үзгә.)
- Четерекле сорау. Бу «тешли» торган сорау, бөтен кешегә ораторның көчсезлеген күрсәтергә тырышу. Четерекле сорауларга да ике төрле җавап булырга мөмкин: я, чынлап, беркатлы, риясыз булу (андый ысул бу төр сорауларны тәмам юкка чыгара), я ирония куллану.
- Ихтыярсызлау соравы. Бу төр сорау оппонентның ораторга басым ясарга, аңа үз фикерен тагарга тырышуы.

Әлеге сораулар, гадәттә: «…, бу фикерләрне һичкем инкяр итә алмас», «…, сез бу хакыйкать белән килешмичә булдыра алмыйсыз,...» – һ. б. шундый сүзләрдән башланып китә.

### *Аудитория сорауларына җавап*

Тәҗрибәсез ораторлар сораулардан куркалар, кайвакытта тыңлаучылар сорау бирмәсәләр, чыгышны уңышлы дип тә саныйлар. Сораулардан куркырга кирәкми, ә бәлки чыгышның тәэсир көчен арттыру максатыннан аудиторияне сорау бирерлек халәткә җиткерү үзен аклый.

Сорауларга җавап бирүнең төп принциплары:

• Барлык сорауларда җавап бирергә кирәк, тик шунда ук җавап бирүнең мәҗбүри түгеллеген дә әйтик.

Җавап бирүне: «Мин сезне аңладым, бу сорауга соңрак җавап бирермен», «Бу – шәхси мәсьәлә, сез, зинһар, тәнәфес вакытында минем яныма килегез, без аны хәл итәрбез» дип кичектереп торырга була.

• Сорау бирүчене тиң күреп җавап кайтарырга кирәк. Бу сорау биргән һәр кешегә ихтирам күрсәтергә, аудиториянең һәр соравын урынлы дип танырга кирәк дигән сүз. Сорауга үзеңнең тискәре мөнәсәбәтеңне сиздерергә, әлеге сорауның җитди булмавын яки мәгънәсез булуын ассызыкларга ярамый – теләсә кайсы сорау җавап бирүне таләп итә. Хәтта, артык җитди булып тоелмаган сорауга да, аның күпмедер дәрәҗәдә мәгънәле асылын табарга тырышып, тапкыр җавап бирергә кирәк.

• Җавап көтүчегә: «Сез мине дөрес аңламагансыз» дип түгел, «Мөгаен, мин үз фикеремне тиешенчә җиткерә алмаганмындыр» дип әйтергә кирәк.

• Җавап кыска булырга тиеш. Җавапны лекциягә әйләндерергә кирәкми. Инде билгеләп үтелгәнчә, бер сорауга җавап минут-минут ярымнан артмаска тиеш.

• Сорауга каршы сорау бирергә була. Бу – җавап-һөҗүмнең класссик алымы. Бу алым сезне, үзегез җиңеләчәк бәхәстән коткарачак.

### **Кара-каршы сөйләшү яки әңгәмә кору**

Нотык (монолог), безнең белгәнебезчә, бөтенләй берьяклы була алмый. Хәтта игътибарлы, нотыкны тикшерү белән шөгыльләнгән тыңлаучы, сөйләмдә катнашучы буларак аңланырга мөмкин.

Искәрмә һәм сораулар, шулай ук, сөйләм төре булып тора. Диалог – әңгәмә – ике кеше аралашуда уртак фикер оештыру сөйләме. Кайбер очракта диалогны ике яклы аралашу дип аңлыйлар, ә полилог, нигездә – күпкырлы, бер мизгелдә өч кешедән артык сөйләүче яки сөйләүче-тыңлаучы сөйләме.

Әңгәмәнең оешу рәвешен истә тотарга кирәк. Аның нигезендә сорау һәм аңа җавап ята. Сораудан һәм җаваптан тыш, әңгәмәдә хикәяләү, боеру, гамәл кылу, игътибарлы тынлык өлешләре бар. Әңгәмәдә катнашучылар сорауларга җавап бирергә тиешләр. Боеру эш-гамәл, хикәяләү яки кыска хәбәр белән җавап бирүне таләп итә. Хикәяләү алымы җавапта да хикәяләп бирүгә яки игътибарлы тыңлауга исәпләнә. Гамәл кылу нигезендә сөйләмнән башка үтә торган күнекмәләр, ә игътибарлы тынлыкта – кабул ителгән һәм аңлашылган эчтәлек хакында сүзсез яки кыскача хәбәр була.

Кешенең яшәеш рәвешен әңгәмә кору, гамәл кылу һәм ял итү өлешләреннән тора дип аңлатырга мөмкин. Аларның һәрберсе чиратлаша, бер-берсен дәвам итә торган эшчәнлек.

Күп кабатланган мәгънәсендә әңгәмә − билгеле бер максатны күздә тоткан репликалар белән алмашу.

Әңгәмә кору − туры мәгънәсендә ике яки берничә нотык берлеге, бу очракта ул алдан-алы уйланып куела.

Аралашу даирәсенә карамаган өзек-өзек хәбәрдән торган сөйләмне дә иң гади әңгәмә дип санарга мөмкин. Чынбарлыкта менә шушы мизгелдә оештырылган әңгәмәне да аерып куярга була. Бу төр әңгәмәне табигый сөйләм рәвеше дип тә исәпләргә ярый. Мәсәлән, җыелыш берничә нотык җыелмасыннан тора, охшаш репликаларны үз эченә алмый. Чынлыкта, әңгәмә аралашучылар нияте сыйфатында тәкъдим ителгән максатка яраклашып оеша. Әңгәмәнең эчтәлеген билгеләүдә бердәм күрсәткечләр юк һәм аның оешу рәвешендә гомуми бәяләрне генә аерып куярга мөмкин. Хәзерге җәмгыятьтә әңгәмә кору нотык сөйләүгә караганда әһәмиятлерәк. Әңгәмәдә катнашучыларның үзләренең мәдәни һәм аралашу мәнфәгатьләре киңрәк канәгатьләндерелә, төрле шәхси фикерләр белән алмашу тормышка ашырыла.

### *Әңгәмә оешу нигезләре*

Әңгәмә күп буынлы аралашу, сөйләм ягъни репликалар белән аралашуны чагылдырган, берничә сөйләм эшлеклесе катнашкан күренеш. Хәзерге аралашу киңлегендә әңгәмәне

уртак эш итү яисә шәхесара аралашу дип атап була. Әгәр дә һәр аралашучының яхшы нотык сөйләүче икәнен дә исәпкә алсак, аларның һәрберсенең үз карашы була. Әңгәмәнең (төгәлрәк полилогның) үзенчәлеге, **нотыктан** аермасы, шуннан гыйбарәт, мондый аралашуның субъекты бер үк вакытта оратор да, тыңлаучы да булып тора. Әңгәмәдә катнашучыларның ораторлык һәм тыңлаучы роле, эчке эшчәнлек буларак, бер үк вакытта тормышка ашырыла. Тышкы күренештә рольләр чиратлаша. Полилогта катнашучылар уртак гамәлдә – тыңлау-сөйләү барышында үзләренең фикерләре белән алмашалар.

Һәр катнашучы күңеленнән фикерләр җыелмасы арасында үз фикерләренең **өстен чыгуына** омтыла, теләгендә, бер максат белән оешкан төркем карашына әверелүен һәм уртак гамәл нәтиҗәсенә әйләнүен тели. Тыңлаучыларга карашлар тәкъдим итүдә оратор рольләрне чиратлаштыра: ул сөйли дә, тыңлый да ала. Аралашу даирәсенә бәйле рәвештә, аралашу төрлечә тормышка ашырыла.

Буйсынучанлык тибында субъекттан, әйдәүче субъект карашлары белән үзара килешенеп, фикерләр алмашу таләп ителә. Чыгыш ешлыгы әлеге аралашу киңлегендә сөйләм эшлеклесенең **үз дәрәҗәсен, үз урынын белүгә** бәйле. **Әйдәүче** субъектлар, буйсынучан тыңлаучыларга караганда, оратор ролендә ешрак чыгыш ясыйлар. Өстәвенә, әңгәмәдә активлык күрсәтү катнашучының карашлары белән түгел, ә аралашудан тыш статусы белән, мәсәлән, профессиональ яисә сәяси дәрәҗәсе белән билгеләнә.

Гражданлык тибында аралашу рәсми кагыйдәләргә, карашлар эчтәлегенең һәм катнашучыларның ирекле аралашу мөмкинлекләренә нигезләнгән. Буйсынучанлык элементлары гражданлык полилогында да бар, ләкин алар **этикет**, **йола элементлары**, **әдәп кагыйдәләре**, остазларга карата **хөрмәт билгесе** һ. б. аша чагыла. Гражданлык аралашу даирәсендә, ораторның рухи егәрлеге һәм бай эчтәлекле мөмкинлекләре ярдәмендә аны әңгәмәнең нәтиҗәле катнашучысыннан абруйлы әңгәмәдәшкә әверелдерә.

Уртак карашлар булдыру ысулы тәкъдим ителгән карашның нигезле булуы, максатлары төгәллеге, әңгәмә оештыру рәвешенә бәйле. Антик риторикада әңгәмәле аралашуның өч төре оеша: **эристика, диалектика** һәм **софистика.**

Бу өч юнәлеш теләсә кайсы әңгәмәле аралашуның уртак өлешләрен чагылдыра. Теләсә нинди аралашу нигезендә каршы

фикер иясен җиңү, хакыйкать һәм белем үзләштерү теләге, аралашуны нәтиҗәле итәрлек шәхси мөмкинлекләр бар. Эчтәлекне максатларның кайсысы тирәсендә генә туплаганда да, алар оештыруның уртак күрсәткечләренә, ә кагыйдәләрне узып киткәндә тыелган аралашу ысулына әвереләләр.

### Әңгәмә оештыру кануннары һәм алымнары

**I канун – Камил диалог (әңгәмә) кануны.** Нәтиҗәле аралашу сөйләм ситуациясендә катнашучыларның ике яктан да йогынтылы фикер уртаклашулары барышында гына мөмкин.

**II канун – Тыңлаучыларны максатка юнәлдерү кануны.** Чыгыш ясаучы, сөйләменең башыннан ахырына кадәр, тыңлаучылары – әңгәмәдәшләре (сөйләм адресаты) игътибарын төп фикеренә, максатына юнәлтә. Әңгәмәдәшләр дә бу омтылышны сизеп-белеп торсалар, аралашу нәтиҗәле уза.

**III канун – Сөйләмнең хисчәнлек кануны.** Сөйләмнең хисчәнлек канунын тормышка ашыруда чыгыш ясаучы, нәрсәдер хәбәр иткәндә яки әңгәмә оештырганда, тыңлаучыларының (әңгәмәдәшләренең) да хис-тойгы халәтен кузгатырлык сәнгатьлелеккә омтыла. Акыл һәм тойгы бердәмлеге нәтиҗәле аралашу өчен бик мөһим.

**IV канун – Канәгатьлек кануны.** Чыгыш тыңлаучыларда (әңгәмәдәшләрдә) канәгатьлек хисе уяту, аларның күңелен күтәрү максатына юнәлдерелсә, аралашу ике як өчен дә илтифатлы мөнәсәбәттә узса, сөйләмнең нәтиҗәлелеге арта төшә.

### Әңгәмә-бәхәс (эристика)

Фикер алмашу барышы субъект белән эчтәлек арасында сүз көрәштерүгә (диспут, дискуссия (моназара) китерә. Антик Грециядә бәхәсләшү сәнгатен эристика дип атаганнар. Төп максаты җиңү булганга, бәхәстә теләсә нинди алым-чаралар рөхсәт ителгән, нәтиҗәгә бик үк нәзәкатьле булмаган юллар белән дә килергә яраган.

Эристик аралашу оппонентны бәхәсләшмәс дәрәҗәгә җиткерү, психологиясен какшату һәм һәртөрле ысуллар белән чит фикерне көчләп тагу нигезендә төзелә. Бәхәс алып баруда төп кагыйдәләр:

- һәр оратор, яшерен рәвештә, үзенең шәхси мәнфәгатьләрен алга чыгарырга тырыша;
- кызыксынуның нигезен барлыкка китерү өчен оппонентларга

тезис һәм карашларның эчтәлеген ныклап тикшерергә ирек бирмәскә кирәк. Бәхәс билгесезлектә алып барылырга тиеш.

• аралашу барышында төп максат – ораторның мәнфәгатьләрен кайгыртуы;

• оппонентның тәэсир дәрәҗәсен, абруен киметергә тырышу һәм төрле ысуллар белән аңа булган ышанычны йомшарту;

• софистика, эклектика, ихтималлык методларын кулланып, дәлилләү кагыйдәләрен ораторның үз максатларына буйсындырырга тырышуы;

• оратор образының тәэсирчәнлек үрнәкләрен, күрсәткечләрен файдалану. Уңышсызлыкларны яшерү һәм бәхәстә җиңү мизгелләрен арттырып күрсәтү;

• һәрвакытта ниндидер гамәл кылуга хокукны һәм соңгы фикерне әйтү мөмкинлеген саклау;

• эристика шәхси тезисларның какшамаслыгына, сөйләмне дәлилләү мәсьәләләренә буйсындыру һәм ораторның үз карашларын, бернәрсәгә дә карамастан, саклауга нигезләнә.

Әңгәмәдә бәхәс юнәлешен оратор үз кагыйдәләренә буйсындыра. Оратор риторик мөмкинлекләрен тулысынча куллана алмый, ул үз уен алдан белдерергә тиеш түгел. Көчле моназарачы, үз мәнфәгатьләрен генә кайгыртучы оппонентның тел төбен аңлап, риторика, логика, сәнгать мөмкинлекләрен кулланып, аның фикерен юк итә белергә тиеш. Бәхәсле ваграк мәсьәләләр дә булырга мөмкин. Берләшмә өчен бик мөһим эшчәнлек турында сүз барганда бәхәсле карашлар бик куркыныч. Нәтиҗәдә, әңгәмә-бәхәстә җиңү шәхси фикерләрне берләшмә эшчәнлеге сәясәтенә әйләндерә ала. Бу хәл берләшмәне, гомумән, таркалуга китереп җиткерергә дә мөмкин.

### Бәхәскә диалектик караш

Бәхәскә диалектик караш аралашуда катнашучыларның бергәләп хакыйкать эзләвен белдерә. Аралашу рәвеше буларак, диалектика, фикерләүдә каршылыкларны җиңүгә, танып белү тәгълиматына нигезләнә һәм максатчанлык кануннарына буйсына.

Карашларны тикшерү барышында каршылыкларны җиңү түбәндәге кагыйдәләргә нигезләнә:

• сөйләмне максатка, фикер эзлеклелегенә һәм риторика кануннарына нигезләргә;

• тезис оешу барышында аның исбатлануын күзалларга һәм төп

фикерләргә кагылышлы карашларны үзгәртмәскә;

- барлык фикер йөртү эшчәнлегендә терминнарның эчтәлеккә һәм мәгънәләренә тәңгәллеген сакларга;
- фактларны бөтен тулылыгында, сөйләмнең тәҗрибәгә нигезләнүе рәвешендә карарга;
- яңа мөмкинлекләр ачыкланганда тезисның эчтәлеген алмаштырырга һәм тәгаенләргә;
- оппонентка карата авторитар һәм психологик басым булдырмаска;
- оппонентка хөрмәт белән карарга, аның ялгыш һәм уңайсыз тоелган карашларына тискәре тәэсир белдермәскә;
- оппонент карашларын хакыйкатьне ачыклау максатында гына кире кагарга, бәхәснең барлык фикерләренә объектив якын килергә, аралашу барышында хәйлә кулланмаска, үзеңчә генә фикерләүгә юл куймаска;
- эзлекле исбатланган, тәҗрибәдә расланган, каршылыклы фикерләре ачыкланып беткән карашларны гына хак дип санарга.

## Аралашуның софистик нигезе

Софистика юнәлеше Сократ тарафдарларына кадәрге риторикада оеша. Аның асылы ораторның тыңлаучыларын карашларына инандыруда тел һәм аралашу чараларының барлык мөмкинлекләрен файдалануга кайтып кала. Софистларга һәм аларның укучыларына фикерне оештыра, тыңлаучыга җиткерә белү осталыгы бәхәсләр вакытында җиңү яуларга ярдәм итә. Хакыйкатьне ачыклаганда ярыш булмау бу сәнгатьнең чәчәк атуына китерә, ләкин ул Сократ һәм аның дәвамчылары тарафыннан тәнкыйтьләнә. Бу тәнкыйтьнең нигезендә – софистларның оратор карашлары дөреслегенә битараф булулары, ә Сократ фикеренчә, оратор карашы берләшмәнең язмышын хәл итә.

Бу юнәлеш уңай булып исәпләнмәсә дә, софистик мөмкинлекләр хәзерге аралашу даирәсендә аерым бер хәйлә ысулы булып кулланыла. Безнең җәмгыятьтә өстенлек алган аралашу рәвеше фаш итү һәм каршы фикерне җиңү максаты белән софистика алымнарын куллана.

Софистиканың тискәре ягы шунда: ул риторика һәм фикерләү мөмкинлекләрен үз мәнфәгатьләреннән чыгып файдалана. Тәҗрибәле софист тыңлаучыларны үз карашларына җәлеп итү өчен, кабул ителгән мөмкинлекләрдән файдаланган кебек була,

ләкин алар берләшмә фикеренә туры килми, оешмага файда китерми. Софистика төрле бәхәсләрдә аңлатмалар, төшенчәләр, фикри нәтиҗәләрне әдәпле булмаган ысуллар белән отышка юнәлдерә. Фикерләү төгәлсезлекләре белгечләргә генә билгеле, ә калган тыңлаучыларда ул ныклы инану уята.

Хәзерге заман аралашу даирәсендә төзелеше ягыннан дөрес күренгән, ә эчтәлеге ялган булган күп төрле софизмнарны очратып була. Мондый софизмның нигез чыганагы булып, мәгънәви эчтәлеге билгесез аңлатма тора. Теләсә нинди мәгънә белдергән, билгесез аңлатмадан томанлы фикерләүләр барлыкка килә.

Сөйләмдә файдаланылган софизмнарны киметү өчен тәҗрибә, осталык кирәк. Әгәр без, аралашуны мәгънәләре аңлашылып бетмәгән, туры мәгънәләренә тәңгәл килмәгән төшенчәләр белән дәвам итсәк, софистика киләчәктә дә нык тамыр җибәрәчәк.

## Әңгәмәнең тәэсирчәнлеген оештыру ысуллары

Җиңүгә яки хакыйкать эзләүгә корылган әнгәмә аралашуның максатлары дөрес оештырылганда гына чынга ашачак.

Әңгәмә кору репликалар алмашу икәнен без беләбез. Репликалар алмашу әңгәмәнең эчтәлегенә һәм сыйфатына берникадәр йогынты ясый. Аларның оешу рәвешеннән аралашуда катнашучыларның әңгәмәдәге урыннары тәгаенләнә.

Әңгәмә төрле як әйткән каршылыклы тезислардан оеша. Әңгәмәдә, гомумән, һәр якның тезисы бер-берсе белән төрле каршылыкта булырга мөмкин. Тезислар аңлаешлы, мәгънәви яктан эшкәртелгән һәм бер-берсенә каршылыклы төркемнәргә туплана. Уртак тезис, аңлы рәвештә, каршылыкларны хәл итүдән соң барлыкка килә. Уртак тезис – үзара аңлатмалар җыелмасы – әңгәмәдәшләрнең бердәм карашы нигезенә салына.

Бердәм тезис барлыкка китерүдә әңгәмәдәшләр берүк мөмкинлеккә ия. Аралашучыларга әңгәмәдә тоткан урыннарын тигезләү өчен әңгәмәне оештыру өлешләре ярдәмгә килә.

Әңгәмәнең таралган төре – каршылыклы әңгәмә. Монда диалогта катнашучыларның репликалары белдерелү рәвеше һәм мәгънә ягыннан аерыла. Каршылыклы әңгәмә аралашучыларның бер-берсенә каршы килүеннән гыйбарәт. Икенче төрле, каршылыклы әңгәмәне – бәхәсләшү диләр. Үзәктә конфликт халәте, репликалар аермалыгы, әңгәмәдә каршылыкның хәл ителмәве тора.

Реплика ияләре бәхәсләшүне – фикер алышуны – оста оештыручылар булып, каршылыклы әңгәмәне ахырына кадәр җиткерергә тиешләр.

Уңай рәвештә кара-каршы сөйләшү – гәпләшү, асыл әңгәмә. Монда репликалар арасында каршылыклар юк, пауза сакларга һәм фикер алышуда кискен мизгелләрне җайларга мөмкин. Чын әңгәмә төрле тезисларны тикшерү белән тәмамлана. Ул оратор тарафыннан тынычландыру чарасы һәм тезислар каршылыгын туктата торган көч буларак кулланылырга, идарә итү чыганагы булып килергә мөмкин. Асыл әңгәмә чаралары белән оратор, җиңү үз ягында дип санаган көндәшенең "уяулыгын" киметә ала. Оста чыгыш ясаучы яшертен дәлилләр табып, үз фикерен урынлы рәвештә исбатлап та куя.

Репликалар белән алмашуның өченче төре булып, әңгәмә-полилог, театрлаштырылган әңгәмә санала. Монда исә фикер алмашучыларга репликалар төрле күләмдә бүленгән. Алар бердәй, яисә капма-каршы булырга мөмкиннәр. Фикер алышучыларның кайберләре репликалар алмашалар, кайберләре тыңлап кына тора һәм ахырдан гына үз фикерен әйтеп куя.

Аралашучылар күп булганда, театрлаштыру, әңгәмә оештыру рәвеше булып килә. Төп фикер тавыш бирү нәтиҗәсендә үтә. Репликалар алмашуда катнашмаучы да игътибарны җәлеп итә, эндәшмәсә дә, вербаль булмаган чаралар ярдәмендә фикер алышуда, шулай ук, катнашучы булып тора.

Тормышта әңгәмәнең "түгәрәк өстәл" дигән төре дә бар. "Түгәрәк өстәл"дә катнашучылар үз карашларын халык алдында әйтә белергә, каршылыкларны җиңү кануннарыннан чыгып фикер йөртергә һәм дискуссиядә (моназара) катнашучыларның бөтенесен дә канәгатьләндерерлек карарлар, нәтиҗәләр таба белергә тиешләр.

Әлеге юнәлештәге сөйләшү җәмгыятьнең һәм гражданнарның аралашу культурасы югары дәрәҗәдә үсеш алганда мөмкин.

## Әңгәмәле аралашуга караш

Хәзерге заманда диалог рәвешендә аралашу нәтиҗәлелеккә, чынбарлыктагы гамәлгә омтыла. Аңа шартлылык, очраклылык, кыскалык, эндәшми калу хас. Моннан тыш диалогка бердәм эшчәнлек рәвеше дә хас. Диалогта – энгәмәдә – катнашучылар бер-берсенең фикерләрен, темаларын дәвам итәләр, пафос һәм этос дәрәҗәсендә берләшәләр.

Нотыкта пафос ораторның нәрсә әйтергә теләве белән билгеләнә. Полилог вакытында пафос бөтен кешегә күчә. Бу аралашу рәвеше нинди максатка юнәлтелгән булса, пафос та шуңа юнәлдерелә. Үзара сөйләшүнең нәтиҗәлелеге сөйләмдә катнашучыларның оратор сүзе белән килешүендә түгел, ә оештыручыларның яки катнашучыларның шушы аралашудан көткән нәтиҗәсендә. Аралашудан я тулаем берләшмә, я аның бер өлеше генә үзенә файда ала. Үз мәнфәгатьләрен генә кайгырткан кешеләр әңгәмәне бәхәс дәрәҗәсенә җиткерәләр.

Репликаларның күп булмавы, диалог формалары белән аны башкару шартлары, аралашу максатларының берләшмә ихтыяҗы белән туры килүе әңгәмәнең тәэсирен арттыра.

Әңгәмә оештыручыдан, катнашучыларның субъектив карашлары һәм теләкләре туры килгәндә, аралашу максатларын тормышка ашыру осталыгы таләп ителә. Әңгәмәне әйдәп баручы эчтәлеккә кагылышлы мәсьәләләрне тикшерүне аз санлы, кыска һәм нәзакатьле чыгышлар белән чикләргә омтыла. Бу вакытта аның бурычы – сөйләм аныклыгын күзәтү. Кара-каршы сөйләшүнең сыйфат мәсьәләләрен тирәнтен күзәтү бер-берсен алыштырырлык карашларны исәпкә алу һәм гомуми нәтиҗәдә мәсьәләнең төрле ягын тиешенчә берләштерүне тәэмин итә. Күп очракта әңгәмәнең нәтиҗәлелеге әйдәп баручы катнашучының осталыгына бәйле.

### *Дискуссия һәм полемика*

Кара-каршы сөйләшү рәвеше күпмәгънәле булу сәбәпле, аларны бутамас өчен, бер-берсенә булган мөнәсәбәтләрен тәгаенләргә кирәк. Полилог һәм диалог бер предмет турында бәхәс. Оратор карашы тезис формасында чагыла һәм билгеле бер сандагы кешеләр аралашуында күренә. Аларның төп максаты – бәхәс нәтиҗәсендә бердәм фикер булдыру. Бәхәсле сүзләр ярышы бер предмет турында берничә кеше белән аралашу һәм, шул ук вакытта, һәрбер якның үз фикерен якларга тырышуын берләштерә.

Бәхәс билгеле бер максатны күз алдында тотмавы, нәтиҗәнең таркаулыгы белән барлык аралашу төрләреннән аерылып тора. Бәхәсне чагылдыруда шулай ук дискуссия, полемика, дебат кебек терминнар да кулланыла.

Дискуссия – иҗтимагый бәхәс, анда төрле каршылыклы фикерләр чагыштырыла һәм ачыклана. Дискуссиянең максаты булып, барлык катнашучыларга уңайлы чишелеш, кайсыдыр

карашның дөреслегенә инандыру, һәрбер катнашучыны канәгатьләндерерлек фикер булдыру тора. Дискуссия үзенең барышы белән әңгәмәгә якын. Хәзерге чорда ул – фән, сәнгать, сәясәт, фәлсәфә өлкәләренә карый, вакыт буенча чикләнмәгән, ниндидер нәтиҗә чыгаруга исәпләнмәгән була. Эчтәлекләре белән дискуссия һәм диспут тәңгәлләшә. Аралашу рәвеше буларак, диспут урта гасыр университетларында, гыйльми дәрәҗә алу өчен, халык алдында язма фәнни эшләрне яклау барышында барлыкка килгән. Хәзерге мәгънәсендә диспут халык алдында уза торган, махсус белгечлек яки уку-укыту барышындагы әһәмиятле фәнни һәм иҗтимагый мәсьәләләрне тикшерү төшенчәсен бирә. Диспутта катнашучыларның саны аз була. Хәзер диспутлар ниндидер риторик нәтиҗә ясау өчен түгел, ә берләшмәне ныгытуда гадәтләнгән эшчәнлек төре, йола буларак узалар.

Аралашу тәэсирчәнлегенә карап “диспут” төшенчәсенә мәгънәләре белән “дебат” һәм “фикер уртаклашу” төшенчәләре синоним.

Дебат – шул ук фикер уртаклашу, тик бәхәсле мәсьәләләр турында сүз барганда. Дебат барышында фикер белдерелеп кенә калынмый, аңлатылып, икенче як та кабул итәрлек “фикер алмашу” барлыкка килә. Дебат һәм фикер уртаклашу кара-каршы сөйләшү рәвешенең бер төре, алардан соң гомуми карарга, уртак фикергә киләләр.

Полемика – аралашу предметы турында бәхәсләшү. Кайбер очракта, аңа һөҗүм һәм дошманлык мәгънәсен дә салалар. Ләкин чынбарлыкта полемикага болар хас түгел. Полемика аралашуга гына түгел, ә кешеләр арасындагы башка мөнәсәбәтләргә дә бәйле. Шуңа күрә кара-каршы сөйләшүгә корылган аралашуда нәзәкатьлелек, дустанә мөнәсәбәт таләп ителә. Кайбер шәхесләргә хас кискенлек хакыйкатьне ачыклауда һәм уртак карашлар оештыруда уңайсызлыклар тудыра.

## Фикер каршылыгын хәл итү ысулы буларак сөйләшүләр оештыру

Кайвакыт, бернигә дә карамыйча, капма-каршы фикерләрне ачыклауга корылган аралашуда да катнашырга туры килә. Бу очракта риторик бәхәстә катнашу өчен гади кагыйдәләрне үтәү дә житә:

- иң беренче чиратта, карашларның төгәл адресын билгеләргә, китерелгән тезисны танытырга һәм аны исбатларга керешергә;

• аралашуда фикерләр уртаклашу чикләреннән чыкмаска, моңарчы яңгырамаган үзгә тезислар һәм аргументлар булганда гына, яңа ораторларның катнашуы белән килешергә;

• ике яклы бәхәс шартларында аның кагыйдәләрен истә тотарга, китерелгән дәлилләрнең дәрәҗәсен төшерергә тырышуны фаш итәргә яки каршылыклы фикер алышуны чамадан тыш бәхәскә әверелдерүдән сакланырга. Әгәр фикерне бәхәскә әверелдерү башланса һәм бу хәлне үзгәртеп булмаса, сөйләшүләр оештыру ысулын кулланырга.

Сөйләшүләр ул – каршылыктан котылу ысулы, оппонентлар тарафыннан конфликтны чишү өчен оештырылган әңгәмә.

Конфликтлы хәлләрдә катнашучылар берьяклы гына эшчәнлек алып барыргамы (бу очракта һәр як бер-берсеннән бәйсез рәвештә үз юлын билгели), яисә оппонент белән бердәм эшчәнлек корыргамы (ягъни конфликтны турыдан-туры сөйләшүләр яки өченче бер чит якның ярдәме белән чишәргә тырышу) дигән сайлану алдында калалар. Шул сайлану нәтиҗәсендә сөйләшүләр алып баруның төре, урыны, вакыт чикләре билгеләнә.

### *Сөйләшүләрнең төрләре һәм вазифалары*

Сөйләшүләрне төрлечә төркемләргә (классификацияләргә) мөмкин:

I. Конфликтта катнашучылар санына карап ике төрне аерып була:

а) ике яклы сөйләшүләр;

б) күпьяклы сөйләшүләр – аларда икедән артык як катнаша;

II. Сөйләшүләр алып барганда өченче битараф якны чакыру яки чакырмауга нисбәтле шулай ук ике төрне билгелиләр:

а) турыдан-туры сөйләшүләр – конфликтта катнашучылар турыдан-туры сөйләшүләр алып баралар;

б) читләтелгән сөйләшүләр, ягъни бу очракта өченче бер як кушылу күзаллана.

III. Сөйләшүләрдә катнашучыларның максатларына бәйле рәвештә түбәндәге төрләрне аералар:

а) булган килешүләрне саклау максатыннан сөйләшүләр алып бару. Мәсәлән, конфликт озак вакытка сузылган һәм катнашучыларга “ял итү” таләп ителә. Соңрак алар тагын да отышлырак аралашуга күчәргә мөмкиннәр;

б) сөйләшүләрне өр-яңадан оештыру, ягъни конфликтта

катнашкан бер як икенчесе хисабына үзе өчен кулай үзгәрешләр кертергә тели;

в) яңа шартлар булдыру турында сөйләшүләр – конфликтта катнашучылар арасында әңгәмәне озайту һәм яңа килешүләр төзү;

г) читтән булган этәргечләргә ирешү буенча сөйләшүләр алып бару, икенчел мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтелгән булалар.

Сөйләшүләрдә катнашучыларның максатларына нисбәтле сөйләшүләр алып баруның төрле вазифаларын билгелиләр. Сөйләшүләрнең *төп вазифасы* ул – хәл ителәсе мәсьәләнең чишелешен бергәләп эзләү.

*Мәгълүмати вазифа*. Мәсьәләне чишү өчен каршы якның мәнфәгатьләре, карашы, чаралары турында мәгълүмат алу һәм, әлбәттә, үзеңнекен белдерү өчен кулланыла. Бу вазифа мөһим санала, чөнки чишеләсе хәлнең асылына төшенми торып, ике якның да фикерен, карашын белмичә уртак нәтиҗәгә килеп булмый.

*Аралашу вазифасы*. Конфликтта катнашучыларның үзара аралашуын көйләү өчен кирәк.

*Өндәү вазифасы*. Конфликтта катнашучылар башкарган эшләрен аклау максатыннан иҗтимагый фикергә тәэсир итәргә тырышалар. Алар үзләре өчен уңай һәм оппонентка карата тискәре фикер уяту максатыннан массакүләм мәгълүмат чараларыннан файдаланалар.

## Сөйләшүләр алып бару стратегияләре

Конфликтка кергән яклар сөйләшүләр алып баруны төрлечә кабул итәргә мөмкин:

- башка чаралар ярдәмендә җиңүгә омтылу;
- ике якның да мәнфәгатьләрен исәпкә алып, конфликтны хәл итү барышы.

Шулардан чыгып, ике төп юнәлеш билгеләнә:

1) сөйләшүләрдә “сатулашу” төре;

2) кызыксыну даирәсен исәпкә алып үткәрелгән сөйләшүләр, ярдәмләшүгә исәпләнгән эшчәнлек.

Теге яки бу юлны сайлау һәрбер як өчен сөйләшүләрдән көтелгән нәтиҗәләр, катнашучыларның сөйләшүләр алып баруның отышлы, уңай ягына исәп тотуы белән бәйле.

### *Сөйләшүләрнең “отыш-югалту” төре*

Конфликтка кергән яклар яки шуларның берсе конфликтны “отыш-югалту” төрендә туктату ягында торырга мөмкин. Бу очракта килеп туган каршылыкны “отышсыз уен” итеп карарга мөмкин, ягъни килешмәгән якларның мәнфәгатьләре тулысынча капма-каршы була һәм бер якның җиңүе икенчесенең җиңелүен белдерәчәк.

Бу төр сөйләшүләрдә ярыш һәм яраклашуга туры килгән стильләр файдаланыла. Әлеге ярыш буйсындыруга юнәлдерелгән була һәм турыдан-туры оппонетның мәнфәгатьләренә каршы булуны аңлата: минем җиңүем өчен, син җиңелергә тиеш. Кайсы да булса бер як, шулай ук, яраклашуга барырга мөмкин. Бу очракта конфликтта катнашкан якларның берсе җиңелүен таный һәм ким дигәндә, үзенең мәнфәгатьләрен бик аз күләмдә генә канәгатьләндерә ала. Конфликтны “отыш-югалту” алымы буенча төгәлләргә омтылу сөйләшүләрнең өзелүенә һәм конфликтның тагын да үсүенә китерергә мөмкин.

Сөйләшүләрнең “җиңелү-җиңелү” һәм “отыш-отыш” төрләрен дә аерып карыйлар. Конфликтка кергән яклар “отышсыз уен”нан качарга теләгән очракта, каршы якның кызыксынуларына илтифат итәргә тиеш була. Нигездә, күпчелек конфликтлар “отышсыз уен”ны белдерәләр, ягъни бу очракта ике як та җиңә яки җиңелә.

“Җиңелү-җиңелү” төрендәге сөйләшүләр шулай ук “сатулашу” алымы белән бәйләнгән һәм нәтиҗәдә бер як та теләгәненә ирешә алмый кала. Бу очракта сөйләшүләрдә катнашучылар хәл ителәсе мәсьәләне компромисс нигезендә чишәргә омтылалар. Компромисс ике якның да үзара юл куюларына исәпләнә: һәрберсе нинди дә булса җиңүгә ирешсен өчен, һәрберсе нидер югалтырга тиеш була. Компромисс ике якның да бер-берсенә юл куюны таләп итсә дә, ул барыбер, аларның капма-каршылыкка корылганлыгын белдерә һәм бу очракта бердәм эшчәнлек мәҗбүри.

Конфликтка кергән яклар сөйләшүләрнең югары дәрәҗәдә уртак нәтиҗәгә китерәчәген күзаллаган очракта, алар “отыш-отыш” төренә мөрәҗәгать итәләр. Һәрберсенең мәнфәгатенә ирешү, бары тик сөйләшүләрне кызыксыну даирәсен истә тотып алып барганда гына мөмкин. Димәк, сөйләшүләрдә катнашучылар хезмәттәшлекне сайлыйлар.  Хезмәттәшлек ул – бер якның кызыксынуы үтәлмәгән очракта, икенчесенеке дә кайгыртылмаячак дигәнне аңлата.

### *Сөйләшүләрдә “сатулашу”*

Сөйләшүләрдә “сатулашу” алымын кулланганда катнашучылар капма-каршылыкта булалар һәм мәнфәгатьләрдән бигрәк аерым карашлар турында сатулашалар.

- караш ул – конфликтта катнашучылар хәл ителәсе мәсьәләне ничек аңлаулары һәм сөйләшүләрдә нәрсәгә ирешергә теләүләрен билгеләү;
- мәнфәгать ул – ни өчен конфликтта катнашучыларның мәсьәләне нәкъ менә шулай аңлауларын, нәрсәгә ирешергә теләүләрен билгеләү.

“Сатулашу” алымының ике төрен аерып карыйлар: йомшак һәм катгый. Катгый стильне кулланганда, аз гына юл куюлар сайланган карашларда нык торырга тырышуны белдерә, ә йомшак стильдә – килешүгә ирешү өчен кара-каршы юл куюлар күзәтелә.

### *Кызыксыну даирәсен исәпкә алып үткәрелгән сөйләшүләр*

Мәнфәгатьләр даирәсен исәпкә алып үткәрелгән сөйләшүләр юлы “сатулашу”га капма-каршы төр булып тора. Бу стратегия “сатулашу”дан аермалы буларак, партнерлык ысулын кулланудан гыйбарәт.

Бу төр сөйләшүләр алып баруларның төп үзенчәлекләрен Р.Фишер һәм У.Юри ачык билгелиләр:

- конфликтта катнашучылар килеп туган хәлне бергә тикшерә һәм бергәләп аннан чыгу юлларын билгели. Бу очракта алар дошманнарча түгел, ә киресенчә, дустанә мөнәсәбәттә аралашалар;
- төп игътибар карашка түгел, ә конфликтка кергән якларның мәнфәгатьләренә юнәлтелгән була;
- сөйләшүләрдә катнашучылар четерекле мәсьәләләрне үзара отышлы чишү юлларын эзләүгә юнәлгән булалар;
- конфликтка кергән яклар объектив чынбарлыкта килеп туган билгеләргә таянырга тырышалар; үзеңне оппонент урынына куеп карау һәм аның фикерен аңларга тырышу сиземләнә;
- ирешелгән килешү, булдыра алганча, күбрәк катнашучыларның мәнфәгатьләрен истә тотарга тиеш.

Кызыксыну даирәсен исәпкә алып үткәрелгән сөйләшүләрдә конфликтта катнашкан бер як та өстен калмый һәм катнашучылар килешүләрне гадел һәм иң кулай чишелеш буларак кабул итәләр.

## Сөйләшүләрне оештыру баскычлары

Сөйләшүләр алып бару ул – катлаулы эшчәнлек, бурычларына бәйле рәвештә, берничә баскычлы. Бу эшчәнлекнең иң гади һәм шул ук вакытта эчтәлекле моделе түбәндәгечә:

- сөйләшүләргә әзерләнү;
- сөйләшүләр алып бару;
- килешүгә ирешү;
- сөйләшүләрнең нәтиҗәләрен тикшерү һәм ирешелгән килешүләрне үтәү.

### *Сөйләшүләр алып баруга хәзерләнү*

Сөйләшүләрнең уңышлы узуы, аларга ничек хәзерләнүгә дә бәйле. Хәзерлек этабы сөйләшүләргә кадәр күпкә алданрак башланырга мөмкин һәм үз эченә ике мөһим үзенчәлекне берләштерә: оештыру һәм эчтәлек.

*Оештыру өлеше.* Булачак сөйләшүләрнең темасына карамастан, катнашучы яклар берничә мәсьәләне хәл итәргә тиешләр. Иң беренче чиратта очрашуның урынын һәм вакытын билгеләргә кирәк.

Сөйләшүләрнең көн тәртибен төзү дә хәзерлекнең мөһим өлеше һәм бер чарасы булып тора. Аны төзегән вакытта очрашуда каралачак сораулар, аларның эзлеклелеге, оппонентлар чыгышларының дәвамлылыгы билгеләнә. Бу шулай ук катлаулы эш, ләкин көн тәртибен дөрес билгеләү оештыру эшчәнлегенә төгәллекләр кертә. Сөйләшүләрне оештыру этабы очрашуда кемнәр катнашачагын, санын, делегация башлыгын билгеләү белән бәйле. Делегациянең составын билгеләгәндә теге яки бу кешенең нәтиҗәдә нинди файда китерә алуын истә тотарга кирәк.

*Эчтәлек мәсьәләсе.* Сөйләшүләр алып баруга хәзерлек барышында конфликтка кергән яклар берничә бурычны үтәргә тиешләр:

- хәл ителәсе мәсьәләләрне һәм катнашучыларның мәнфәгатьләрен тикшерергә;
- килешүгә китерәчәк икенең берсе мөмкин булган чишелешне билгеләргә;

- чишелешнең берничә юлын булдырырга һәм тәкъдимнәрне оештырырга.

Хәл ителәсе мәсьәләләрне һәм мәнфәгатьләрне тикшерү хәзерлек эшенең эчтәлеген билгели. Сөйләшүләрдә катнашасы яклар килеп туган хәлне бөртекләп тикшереп чыгалар һәм, кирәк булган барлык мәгълүматны җыйган очракта гына, сөйләшүләр уңышлы узарга мөмкин. Шул ук вакытта үзеңнең генә мәнфәгатьләреңне түгел, ә оппонентларның кызысынуларын да яхшылап тикшерергә кирәк. Юкса сөйләшүләр «саңгыраулар әңгәмәсе»нә әверелергә мөмкин. Р.Фишер һәм У.Юри чит кешеләрнең мәнфәгатьләрен билгеләү өчен, төп алым буларак, үзеңне оппонент урынына куеп карарга, ни өчен алар теге яки бу караштa торуларын аңларга тырышырга тәкъдим итә.

Сөйләшүләр башланганчы һәрбер як икенең берсен билгеләргә һәм теге яки бу чишелеш төренә сайлау мөмкин-челеген, туры килгән тәкъдимнәрне дә оештырырга тиеш. Бу очракта иң яхшы тәкъдимне генә түгел, ә бәлки икенче һәм өченче төрләр турында да уйларга кирәктер. Шулай ук, хәзерлек барышында конфликтта катнашучылар һәм үзләренең, һәм оппонентларның мәнфәгатьләрен истә тотып, мәсьәләне төрлечә чишү юлларына кирәк булган барлык мәгълүмати материал-ларны һәм документларны әзерлиләр.

Конфликтта катнашучы якларның сөйләшүләр оештыруга максатчан хәзерлек алып баруы конфликтның тагын да катлаулану яки өзелү мөмкинлеген киметә, булачак сөйләшүләрнең нәтиҗәле узачагына өмет уята.

### *Сөйләшүләрне алып бару*

Сөйләшүләр конфликтта булган якларның мәсьәләне хәл итәргә тотынган мизгеленнән башлана. Беренче очрашуда ук хәзерлек барышында билгеләнгән берничә сорауны ачыклап куярга кирәк. Ике якның да килешүен таләп итә торган сорауларга түбәндәгеләр керә:

1) көн тәртибе;
2) очрашуларның вакыт чикләре;
3) оппонентлар чыгышларының чиратлашуы;
4) килешүләргә ирешү алым-ысуллары җыелмасы;
5) сөйләшүләрдә арадашчыларның катнашу-катнашмавы.

Сөйләшүләр алып баруның түбәндәге өлешләрен аерып чыгарырга мөмкин:

1) катнашучыларның мәнфәгатьләрен һәм карашларын тәгаенләү;

2) мәсьәләне чишәргә мөмкин булган төрләрне ачыклау;

3) килешүгә ирешү.

Алдан үткәрелгән хәзерлек эше әле һәрбер якның карашы турында тулы һәм тәңгәл (адекват) күзаллау булдыру дигән сүз түгел. Шуңа күрә, сөйләшүләр оештыруның иң беренче өлешендә оппонентлар арасында төрлечә аңлашылган четерекле мәсьәләләр, фикер каршылыгы, ике якның да тоткан карашлары турында мәгълүмат алмашу уза. Тагын бер мөһим як шунда, әгәр дә оппонентлар уртак эшчәнлек алып баруга көйләнмәсәләр, аларның килешүгә ирешүләре зур шик астына алына. Америка галимнәре Р.Фишер һәм С.Браун сөйләшүләр алып барганда уңай климат тудыруга ярдәм итә торган алты элементны аерып чыгаралар:

*1) уйлап эш итү* – каршы як хис-кичерешләргә бирелсә дә, сабыр булырга кирәк. Үз холкыңны тыеп тора алмау уртак эшчәнлекне җимерергә мөмкин;

*2) аңлау* – оппонентны аңларга тырышыгыз. Аның фикеренә колак салмау килешүгә ирешүне чикли;

*3) аралашу* – турыдан-туры элемтәгә керү конфликтта катнашучылар арасындагы мөнәсәбәтләрне яхшырту өчен кулланыла ала;

*4) тәгаенлек* – тикшерелмәгән мәгълүматны кулланмагыз;

*5) акыл сату, өйрәтү тонының булмавы* – интонация, сөйләм тоны урынлы кулланылырга тиеш;

*6) башка фикерне кабул итүгә әзер булу* – оппонентның фикерләү рәвешен аңларга тырышыгыз. Башка кешенең карашын аңлау – ул әле аның белән килештең дигән сүз түгел. Оппонентларның карашларын кабул итәргә теләмәү сөйләшүләрнең өзелүенә китерәчәк.

Сөйләшүләр алып баруның икенче өлеше – иң җаваплысы һәм авыры. Бу этапта сөйләшүләрдә катнашучылар проблеманың уртак чишелеш мөмкинлекләрен билгеләргә тиеш, ә конфликтлы ситуациядә моңа ирешү җиңел түгел. Теге яки бу чишелешкә туры килгән вариантны тәкъдим иткәндә һәм сөйләшкәндә оппонентлар үзләренең карашларын тагын да көчәйтергә яки киметергә мөмкиннәр. Болар барысы да аларның тыңлый, инандыра һәм сораулар бирә белүләренә бәйле. Мәсьәләнең берничә чишелеш юлын эзләгәндә оппонентлар иҗади уйлый белергә дә тиеш. Бу

сыйфат түбәндәгеләрне күз алдында тота:

- әзер кысалардан баш тарта белү;
- мәсьәләнең бер яссылыгыннан икенчесенә җиңел күчә алу;
- көтелмәгән, уникаль чишелешләрне таба белү.

Әгәр дә конфликтка кергән яклар проблеманы бергәләп, сөйләшүләр алып бару аша хәл итәргә теләсәләр, бу этапның нәтиҗәсе булып, килешүнең төп вариантларын билгеләү тора һәм катнашучылар өченче этапка күчәләр.

***Килешүгә ирешү. Консенсус алымы***

Бу өлеш мәсьәләнең чишелешен эзләүдә озын һәм катлаулы юлны тәгәлли. Конфликтка кергән яклар ахыргы килешүләрне оештыруга күчәләр. Килешү өстендә эшләгәндә сөйләшүләрдә катнашучылар ике як өчен дә яраклы чикләргә сыйган төп чишелешне билгеләргә тиешләр. Килешү төзергә мөмкин булган өлкә сөйләшү тирәлеге дип атала. Һәр килешүгә бары тик шуның кысаларында гына ирешергә була. Бу өлкә зур һәм күпкырлы булырга мөмкин. Килешүгә ирешү төрле чишелешкә нигезләнә ала:

- урта;
- асимметрик;
- өр яңа фикерле чишелеш.

Сөйләшүләрдә типик чишелеш булып урта яки компромисс санала. Бу очракта конфликтка кергән яклар бер-берсенә юл куялар. Асимметрик чишелеш булганда конфликтта катнашкан бер якның юл куюы икенче якныкына караганда зуррак була. Мондый чишелеш төре, мәсәлән, ата-ана белән яшүсмер егет арасында туган конфликтлы ситуациядә кулланыла.

Алдагы чишелеш төре ул – өр яңа фикергә килү. Бу очракта каршылык тулысынча чишелә яки мөһимлеген югалта һәм нәтиҗәдә конфликтта катнашучыларның мөнәсәбәте тулысынча үзгәрергә мөмкин. Мондый төр килешүгә килү иң авырлардан санала һәм сөйләшүләрдә катнашучылардан конфликтны тулаем хәл итәрлек эшчәнлек алып бару таләп ителә.

Өр-яңа фикерле чишелешнең икенче юлы мәнфәгатьләрнең үзгәрүе яки проблеманы яңа күзлектән караган очракка туры килә. Өр-яңа фикерле чишелеш үз чиратында теге яки бу дәрәҗәдә компромисс элементларын да берләштерә.

Килешү төзү ике төрле була:

1) иң элек гомуми планда килешү төзелә, ә аннары һәрбер мәсьәләнең сораулы мизгелләре карала;

2) сөйләшүләр алып баруда катнашучылар килешүгә ирешү өчен һәрбер мәсьәләне бер-бер артлы чишәләр.

Бу очракта аерым чишелешләрнең бергәлеге гомуми нәтиҗәгә алып килә.

Сөйләшүләр алып баруда катнашучыларга мәсьәләнең чишү төрләрен билгеләрлек түбәндәге күрсәткечләрне кулланырга мөмкин:

- гомуми, уртак кыйммәтләр, әхлакый кагыйдәләр;
- ике як тарафыннан да хөрмәт ителгән гореф-гадәтләр;
- кануннар, белешмәләр, профессиональ нормалар;
- эксперт билгеләмәләре;
- охшаш очракларга сылтамалар.

Бу күрсәткечләр гамәли яктан кулай һәм сөйләшүләрдә катнашучыларның барысы өчен дә яраклы булырга тиеш.

### *Консенсус алымы*

Консенсус алымы (лат. consensus – ризалык, бердәмлек) сөйләшүләрдә барлык катнашучыларның төзелгән карар белән килешүенә исәпләнә. Бу алым “башкаларның мәнфәгатьләрен кабул итү, үз кысыксынуларыңны тормышка ашыру өчен шарт булып торуга” нигезләнгән. Консенсус алымына нигезләнгән килешүләр нык булалар, чөнки бу алым оппонентларның кайсысы булса да берсенең каршы карашта булуын кабул итми. Димәк, сөйләшүләр оештырганда консенсус алымын куллану, һәр ике якның да карашлары уртак, ныклы һәм дәвамлы булуын аңлата.

### *Сөйләшүләрнең нәтиҗәлеген тикшерү,ирешелгән килешүне үтәү*

Сөйләшүләрдә катнашучы якларның кара-каршы эшчәнлеге тәмамланса да, соңгы өлеш буларак, сөйләшүләр оештыруның нәтиҗәләрен һәм ирешелгән килешүләрне тикшерү өлеше дәвам итә. Иң элек үткәрелгән сөйләшүләрнең уңай яки тискәре булуына карамастан, һәрбер якка нәтиҗәләр чыгарырга кирәк:

- сөйләшүләргә хәзерлек ничек узды;
- сөйләшүләр алып барганда планлаштырылган программа сакландымы;
- оппонентлар белән үзара эшчәнлек нинди характерда булды;

- оппонентларны нинди дәлилләр инандырды, кайсылары тискәре тәэсир калдырды һәм ни өчен шулай;
- юл куюлар булдымы һәм алар нинди нәтиҗәләр бирәчәк;
- сөйләшүләр алып барганда нинди кыенлыклар туды;
- алда хезмәттәшлек итүнең преспективалары бармы һәм нинди;
- киләчәктә сөйләшүләрдән алган нинди тәҗрибәне кулланырга мөмкин булыр;
- ирешелгән нәтиҗәләрнең төп сәбәпләре нинди.

Сөйләшүләрнең уңышлылыгын билгеләү өчен берничә күрсәткечтән файдаланырга мөмкин: 1) уңышның төп күрсәткече – мәсьәләнең чишелеш дәрәҗәсе. Шулай да, чишелеш нәтиҗәсе төрле була ала:

- конфликтны "отыш-отыш" төре кысаларында төгәлләү мәсьәләне көн тәртибеннән төшереп калдыра;
- конфликтның "отыш-җиңелү" яки "җиңелү-җиңелү" төре буенча тәмамлануы киләчәктә хезмәттәшлекнең конфликтсыз булачагын искәртми.

2) сөйләшүләр оештыру һәм аларның нәтиҗәләренә субъектив карашлар. Әгәр дә ике як та сөйләшүләрнең нәтиҗәләре белән ризалашсалар һәм кабул ителгән килешүне гадел дип санасалар, сөйләшүләр уңышлы узган дияргә була.

3) килешүнең шартларын үтәү дә сөйләшүләрнең уңышлылыгын билгеләүдә бер күрсәткеч булып тора. Бу очракта сөйләшүләрнең нәтиҗәлелеген озайту һәм ныгыту өчен килешүгә аны тормышка ашыру планын да кертергә кирәк. Шулай ук әлеге планның үтәлүен тикшерү системасы да билгеләнергә тиеш.

Нәтиҗә ясап, шуны искәртәсе килә: сөйләшүләр алып баруда катнашучылар үзләренең бурычларын мөмкин кадәр тиз арада башкарырга тиешләр, юкса тоткарлану якларның бер-берсенә карата ышанмавын һәм икеләнүен тудырачак.

### *Сөйләшүләрдә арадашлык итү модельләре*

Каршылыкны үзара гына хәл итү мөмкин булмаган очракта мәсьәләгә карата битараф булган өченче якның ярдәменә таянып сөйләшүләр алып барырга була. "Өченче як" термины бик киң төшенчә. Конфликтны чишкәндә өченче як катнашуның берничә төрен аерып карарга була.

1) суд – ул төгәл билгеләнгән, законлы рәвештә беркетелгән

тикшерү эшчәнлеге алып бара һәм судья кабул иткән чишелешне конфликтта катнашучылар үтәргә тиешләр. Бу очракта өченче як конфликтны чишүдә тулысынча катнаша.

2) арбитр – хәл ителәсе мәсьәлә турында сөйләшү барышын көйли торган төгәл нормаларның булмавы белән үзенчәлекле. Катнашучылар өченче якны үзләре сайлыйлар һәм чит як чыгарган нәтиҗәләр мәҗбүри булалар.

3) арадашлык шулай ук сөйләшүләр алып баруда ярдәм итүнең бер рәвеше. Уңай аралашу һәм мәсьәләне чишү юлларын эзләгәндә ярдәмче, ләкин шул ук вакытта соңгы нәтиҗәне катнашучылар ясый. Шуңа күрә арадашчы алдан ук нәтиҗәләр өчен бары тик конфликтта катнашучылар җавап бирәчәген ассызыкларга тиеш.

***Конфликтны җайга салуда өченче якның катнашу рәвеше***

| **Катнашу рәвеше** | **Өченче якның катнашу үзенчәлекләре** |
|---|---|
| Өченче як, битараф судья (третейский суд) | Мәсьәләне хәл итү төрләрен билгеләүдә иң күп мөмкинлекләргә ия. Проблеманы өйрәнә, ике якны да тыңлый, бәхәсләшүгә урын калдырмаслык карар чыгара. Мисалга аксакалларның конфликтлы хәлләрне җайлавын, утырышчылар суды карарын китерергә була. |
| Арбитр | Шулай ук шактый зур вәкаләткә ия. Ул конфликтны өйрәнә, катнашучылар белән бергә тикшерә. Үтәү мәҗбүр булган соңгы карарны чыгара, әмма яклар аның белән ризалашмыйча, югарырак даирәләргә мөрәҗәгать итә алалар. |
| Арадашчы (медиатр) | Тагын да битарафрак роль. Махсус белемнәрне файдаланып мәсьәләне уңай тикшерүне оештыра. Соңгы нәтиҗәне оппонентлар ясый. Арадашчы алдан ук уңышсызлык өчен бары тик конфликтта катнашучылар җаваплы икәнне ассызыкларга тиеш. |
| Ярдәмче (модератор) | Каршылыклы мәсьәләне хәл итүне тикшерү барышын уңай якка үзгәртү максатыннан катнаша; очрашулар һәм сөйләшүләр оештыра, ләкин проблеманың эчтәлеге турында бәхәскә |

| | |
|---|---|
| | һәм ахыргы карар кабул итүгә йогынты ясамый. |
| Күзәтүче | Конфликттагылар арасында булып, якларны элек кабул ителгән килешүләрне бозуларыннан яки үзара һөҗүмнәреннән тыеп тора. Күзәтүченең булуы бәхәсле мәсьәләләрне сөйләшүләр оештыру юлы белән хәл итү өчен шартлар тудыра. |

Нәтиҗә ясап әйткәндә, конфликт – иҗтимагый бәйләнешләрнең аерылгысыз үзенчәлеге. Димәк, һәрбер кеше теге яки бу конфликтта катнашкан яисә катнашачак. Конфликтларны чишкәндә сөйләшүләр оештыруны иң кулай һәм отышлы ысул дип санарга була. Сөйләшүләр оештыру үз чиратында катлаулы һәм катнашучылардан хәзерлек таләп итә торган эшчәнлек. Шуңа күрә сөйләшүләр оештыруның төрле мәсьәләләрен өйрәнү һәрбер кеше өчен бүген дә әһәмиятле санала. Шулай да сөйләшүләр оештыру турында мәгълүматлы булу, уңышка ирешү дигән сүз түгел. Сөйләшү алып бару өчен белем туплау һәм күнекмәләр булдыру мөһим. Ә моңа бары тик гамәли эшчәнлек алып барганда гына ирешергә мөмкин һәм, әлбәттә, әгәр дә катнашучылар чын күңелдән уртак фикергә ирешергә теләсәләр генә, сөйләшүләр уңай нәтиҗәләргә алып килә.

**Үзләштерелгән белемнәрне мөстәкыйль тикшерү өчен сораулар һәм биремнәр**

1.Таблицаларны файдаланып, теләсә-нинди темага әңгәмә оештырып аралашыгыз.

**а) Әңгәмәдәшләр тибы**

| I. Тәкәббер – чикләнгән “йо-мык” тип | Ихлас – “ачык” тип |
|---|---|
| 1. Беренче планда – “мин үзем”. Минем дөньям – иң кызыклысы | 1. Иң кыйммәтлесе – минем әңгәмәдәшем, аралашу темасы |
| 2. Сүзеңне тыңлата алу – хакимлек билгесе. Шуңа да, ничек кенә булса да, төрле юллар белән үз сүзеңне сөйли алу, кеше сөйләменә сүз кыс-тыру, үз карашыңны аңлату, үз теләгеңә ирешү өчен көрәш. Аралашу ысулы – үзеңә буй-сындыру (авторитар алымнар, өстенлек | 2. Фикер алышуда кем өстен – минме, башка берәүме – барыбер. Өстен чыгарга тырышу бер-береңә сүз белән йогынты ясауда, чын-чынлап аралашуга комачаулый, әңгәмәне кызыксыз итә. Аралашу ысулы – һәр очракта бернинди |

| | |
|---|---|
| итү, буйсындыру). | көрәшсез, тигез теләктәшлек. |
| 3. Әңгәмәдәшем – минем теләкне үтәүче объект. Аралашуда мин – әйдәп баручы, ул – буйсынучы. | 3.Әңгәмәдәшем – миннән бәй-сез, мин идарә итәргә тиеш булмаган, үзенчәлекле мөстә-кыйль рухи дөнья. Аның белән танышу – кызыклы һәм файдалы. |
| 4. Үземне танытасым, үзем белән хозурланасым, үз карашларымны гына бәян итәсем килә. | 4. Башка кешенең рухи дөньясы белән танышасым, аның фикерләрен тыңлыйсым, аңлыйсым килә. |

**ә) Әңгәмәдә сөйләм оештыру тәртибе**

| I.Монологта тәкәбберлек (чик-ләнгән “йомык” тип | II. Монологта ихласлык (“ачык” тип) |
|---|---|
| **1. Иң мөһиме – беркемне тыңла-мыйча, үзең сөйләү. Әңгәмәдәш сөйләгәндә, туктагач аңа нәрсә әйтү яки сүз кыстыру турында уйлап утыру, уңай очрак көтеп, аның сүзен бүлдерү.** | 1.Иң мөһиме – бирелеп тыңлау. Әңгәмәдәш сөйләгәндә игъти-бар белән тыңлап, нәрсә әйтергә теләгәнен аңларга тырышу. Аның фикерен үзеңнеке белән чагыштырып, уңай җавап әзер-ләү. Әңгәмәдәшне бүлдермәү. |
| 2.“Мин-минлек” ысулы фразалары:<br><br>-мине шулар һәм шулар кызыксындыра; -мин теләр идем..; -минем исәпләвемчә; -сезгә бу мәгълүм булмаса да...; -сез, билгеле, бу хакта, турыда хәбәрдар түгел (белмисез әле).<br><br>**Иң элек үз мәнфәгатьеңне, фи-кер-карашларыңны, теләкләре-ңне кайгырту һәм әңгәмәдәшеңә үз теләкләреңне белдереп кую.** | 1.Илтифатлы (сез/син) ысул фразалары:<br><br>-Сезне нәрсә кызыксындыра?; -Мөгаен, сез белергә телисез-дер...; -Сез ... турыда нинди фи-кердә?; -Сезгә бу турыда ишетү кызыклы булыр; -Сез, әлбәттә, бу турыда беләсез; -Сез бу хакта, мөгаен, ишеткәнсездер.<br><br>**Беренче планда әңгәмәдә-шеңнең кызыксыну. Бу хакта махсус ихтирамлы белдерү.** |
| 3.Әңгәмәдәшеңнең кем булуы һәм исеме әһәмиятле түгел. Әңгәмә барышында аңа “сез” яки “син” дип кенә мөрәҗәгать итү. | 1.Әңгәмәдәшеңнең исемен (исе-мен, әтисенең исемен) хәтергә сеңдерү, мөрәҗәгатьтә файдала-ну; аның һөнәре, яшь үзенчәлек-ләре, карашларын истә тоту. |
| 4.Әңгәмәдә үз фикереңне кабат-лап, аларның матур яңгырау-лары белән хозурлану. | 4.Әңгәмәдәшнең төп фикерен, аерым фразаларын ихтирам белән кабатлау |
| 5.Һәр репликаны “мин” яки “юк” сүзе | 5.Бик кыен булса да, сүзне “әйе” дип, |

| | |
|---|---|
| белән башларга: Юк, минем уйлавымча...; Юк, сез хаклы түгел, минем фике-ремчә...; Мин үзем генә дөресен сөйлим. | уңай раслаудан башларга: Әйе, сез хаклы, тик...; Әйе, мин сезнең белән тулаем килешәм, әмма...; Әйе, кайбер сорауларым булса да, сезнең фикерләр дөрес.<br><br>Әгәр әңгәмәдәш хаклы булса, бу турыда шунда ук әйтеп узарга. |
| 6.Әңгәмәдәшкә булачак сорау-ларны, ул ризасызланып, кире җавап бирерлекләрен оештыру. | 6.Сорауларны әңгәмәдәшең ки-лешерлек, дөресрәге, тискәре җавап бирә алмаслык итеп уйларга тырышу. |
| 7.Үз фикерләреңне кискен, катгый рәвештә белдерү. Итагать саклап тормаска! Син иң акыллысы (яхшы белгеч) бит. Һәркем белеп торсын! | 7.Фикерләрне белдерүдә кат-гыйлыктан тайпылырга тыры-шырга: Ә сезгә болай тоелмый-мы?; Мөгаен, алай дип исәпләү дөресрәк булыр.<br><br>Һәркем ялгышырга мөмкин: ул да, мин дә. |
| 8.Сөйләшү барышында кырыс булырга. Әңгәмәдәшеңне мак-тарга ярамый. Ул акыллы дип уйлыйк, ләкин син зирәгрәк бит! Әгәр әңгәмәдәшең ялгы-шып куйса, бу турыда кисәтү ясау мөмкинлеген шатланып файдаланырга. | 8.Һәр мөмкинлекне файдала-нып әңгәмәдәшеңә уңай мөнә-сәбәтеңне, аның фикерен хуп-лавыңны сиздерергә. Әңгәмә – имтихан, ә син – укытучы, бәя биреп утыручы түгел |
| 9.Әңгәмәдәшеңне һәм әйләнә-тирәдәгеләрне никадәр тискәре бәяләсәң – шулкадәр дөресрәк булачак, чөнки барысы да – начар, син берүзең генә яхшы. Менә шул хакта гына сөйләшергә кирәк тә. | 9.Әлбәттә, әйләнә-тирәдә хаксызлык җитәрлек, тик гадел эшләр, яхшылык та күп. Сүзне шул турыда дәвам итү әйбәтрәк булыр. |
| 10.Үзеңә әһәмиятле тоелган мәсьәлә хакында сөйләргә. Би-лгеле, итагатьлелек өчен, гадәт-тә, әңгәмәдәшең фикере белән дә кызыксынырга кирәк. Әңгәмәне телгә килгән теләсә нинди сораудан башларга була: Әти-әниләрең ни хәлдә? Стипендияң күпме? Кәеф шәпме? Машинаң төзекме? Нәрсә эшлисең? (Имтиханнан “өчле” алганын оныткансың: Әйдә, ярамаган тагы, ис китәрлек хәл түгел). | 10.Сүзне икебез өчен дә кызыклы темага башлау кулай. “Шәхсән” сорауларны кәеф җибәрмәслек, үпкәләтмәслек итеп уйларга туры килә. |

**б) Эшлекле әңгәмә оештыру**

***Әзерлек.*** Тема, максат, бурычлар, уңышка ирешү ысулларын һәм алымнарын, алга куелган мәсьәләне уңай хәл итәрлек сораулар уйлап кую.

***Кереш.*** Сорауларны, әңгәмәне уңай раслаулар белән үзең әйдәп барырлык һәм темага кагылышлы мәгълүмат тупларлык итеп оештырыга.

***Әңгәмә башы.*** Сәламләшү: исем, фамилияңне әйтеп исәнләшү; үзеңнең карашларың, кызыксыну даирәң белән таныштыру; хуплау, мактау сүзе, мөлаем караш; үзеңә шәхсән кагылышлы сорау бирү; ярдәмгә өметләнү, үзеңнән ярдәм мөмкинлекләрен атау.

**в) Әңгәмәнең төп өлеше эзлеклеге**:

| Гамәл төре | Ысулы |
|---|---|
| 1. Мәгълүмат туплау. | “Әйе/юк” җавабы белән чикләнмәслек, әңгәмәдәшнең сүз сөрешен сизем-ләрлек сораулар бирү. |
| 2.Чишеләсе мәсьәләне (проблеманы) хәл итү. | Риторик сораулар, “уйлану өчен сораулар”: әңгәмәдәш мәсьәләне хәл итүдә өстәмәләр, төзәтмәләр, яңа дә-лилләр китерерлек сораулар куллану. |
| 3. Күчеш: икенче мәсьәләне хәл итәргә керешү. | Күчеш сораулары: әңгәмәдәшнең яңа күтәрелгән мәсьәләгә мөнәсәбәтен билгеләү өчен аның карашларын, сорауларын тыңлау. |
| 4.Икенче мәсьәләне (проблема №2) хәл итәргә керешү. | Яңа мәгълүмат туплауда “әйе/юк” җавабы алынырлык сорауларга күчү. |

***Әңгәмәне төгәлләү.*** Нәтиҗәләрдә үзара килешүчәнлек; кызыклы әңгәмәдән канәгатьләнү хисе белдерү; әңгәмә башкалар тарафыннан өзелсә, алда да хезмәттәшлеккә ышаныч сиздерү. Искәрмәләр:

1.Әгәр әңгәмәдәш уртак мәсьәләне хәл итүдә каушап, ике-ләнеп калса, итагатьлек саклап, аны “әйе/юк” җавабын әйтерлек халәткә алып килү. Уңай җавапка ирешү өчен, эзлекле рәвештә икенче төрле юллар, алымнар (альтернатива) тәкъдим итү.

2.Сез теләгән уңай җаваптан соң әңгәмәдәшне, аның өчен отышлы чишелеш белән тәбрикләү, нәтиҗәле эшчәнлеккә өмет белдерү. Кире очракта – мәсьәлә уңай хәл ителерлек, алдан әзерләнгән соңгы дәлилне китерергә мөмкин.

3.Әңгәмәне тискәре җавапка төгәлләтмәскә тырышыгыз. Алдагы эшлекле аралашуны күзаллап (теләп) булса да, “әйе” җавабына ирешү.

**г) Каршылыкны әңгәмә ярдәмендә җиңү**

*Әңгәмә өлешләре:*

I. ***Тасвирлама***. Килеп туган хәлне үз күзлегеңнән чыгып, лә-кин объектив рәвештә, кыскача сөйләп бирү. Бәхәс кузгатырлык мәсьәләләр күтәрмичә, сүз куертмаслык, күз алдындагы фактлар китерергә. Әңгәмәдәшнең тәртибенә тукталмыйча, тыныч, паузасыз, тавышка бераз катгыйлык өстәп сөйләргә.

II. ***Бәя***. Бәхәскә тартылмыйча, әлеге мәсьәләгә мөнәсәбәтне хәбәр итү, канәгатьсезлекне ачыктан-ачык сиздерү.

III. ***Тәкъдим***. Ачык һәм төгәл итеп, килеп туган хәлдән чыгу юлларын хәбәр итү.

IV. ***Нәтиҗә***. Әңгәмәдәшкә тәкъдимне кабул иткән очракта – отышын, кире кагылганда – зыянын искә төшерү. Янамыйча, ярсымыйча, үтенмичә, ныклы, дустанә сөйләшеп, сүзне күтәренке, мөлаем тонда тәмамларга.

2.Түбәндәге текстка мисаллар табыгыз.

**Әңгәмәдә тулы һәм өлешчә ризалашу һәм ризасызлык**

Сөйләмнең (әңгәмәнең) эчтәлеге һәрвакыт игътибар үзәгендә. Без аның мәгънәсе белән килешәбез яки ризалашмыйбыз. Килешү мәгънәсен фикер-карашлар, ниятләр, теләкләр һәм хисләрнең тәңгәл килүе белдерә. Уй-фикерләр, сораулар, раслауларның кире кагылуы ризасызлык белдерү була. Үзара фикер алышуда ризалык белдерү яки ризасызлык тулы күләмендә чагылмый да кала, әлеге очракларны күзәтеп үтик. Беренче аралашучының мөнәсәбәтле репликасында чагылган фикере, омтылышы, теләге белән тыңлаучы-аралашучы үз репликасында тулысынча ризалашса (бирелгән сорауны расласа), бу тулы ризалашу күренеше була. Мәсәлән: (мисал китерергә).

Беренче аралашучы үзенең тәкъдимен белдерә, икенче аралашучы җавабында бу мәсьәләдә үзенең дә шул ук фикердә, ягъни фикерләрнең уртаклыгын белдерә – бу очрак тулысынча ризалашу була.

Өлешчә ризалашу – сорау бирүче әңгәмәдәш фикере, нияте, теләге белән җавап бирүче килешә, тик җавапта билгеле бер шарт куела яки җавап тәкъдим-фикергә тулысынча туры килеп бетми һәм еш кына ризасызлык төсмерендә яңгырый (мисал китерергә).

Беренче укучы үтенечен белдерү белән икенче укучы аның теләге белән килешә, фикерләр туры килә, ләкин ул үзенең шарты үтәлсә генә ризалаша. Әлеге шарт, безнең карашка (беренче укучы уйлавынча) ризасызлык күрсәткече булып тора. Димәк, өлешчә ризалашу әңгәмәдәшләрнең билгеле бер шарт үтәлүдән соң теләкләре тәңгәлләшкәндә генә оеша.

Тулы ризасызлык – сүз башлаган әңгәмәдәшнең фикере, нияте, теләге белән икенче әңгәмәдәшнең фикере, нияте, теләге бөтенләй туры килмәгәндә күзәтелә (мисал китерергә).

Әңгәмәдәшләрнең ниятләре туры килмәве ярылып ята, бу очрак – тулы ризасызлыкка мисал.

Өлешчә ризасызлык – беренче башлап фикер әйткән әңгәмә-дәшнең фикере, нияте, теләге белән икенче әңгәмәдәш тулысынча килешеп бетмәгәндә яңгырый. Икенче аралашучы беренчесенең мөнәсәбәтле репликасында яңгыраган фикеренә-карашына шик белдерә яки ачык белдерелгән ризасызлыгын итагатьлерәк яңгырата, яки читләтеп әйтә , яки яшертен сиздерә (мисал китерергә).

Әлеге мисалда әңгәмәдәшләрнең бер мәсьәләгә карата фикер-карашлары төрле. Шулай ук икенче әңгәмәдәш сүз башлаган әңгәмәдәшнең үзенә юнәлтелгән фикеренә мөнәсә-бәтен, үзенең фестивальдә катнашу-катнашмавын төгәл белми, шул сәбәпле, аралашуда ниндидер әйтеп бетермәү тоемлана, ягъни ризасызлык тулы чагылышын тапмый (җавап-фикер белдерүче әңгәмәдәш “икеле”дип тел төбен яшерүне көчәйтә). Шуңа күрә бу очрак өлешчә ризасызлыкка мисал була ала.

Өлешчә ризалашу һәм өлешчә ризасызлык бер үк мәгънәне ачыклыйлар, бары тышкы күрсәткечләре генә аларны төгәл аерымлап куярга мөмкинлек бирә. Аларны шәхсән бәя белдерү буларак күзәтеп үтик:

1. (Мисал китерергә).

2. (Мисал китерергә).

Беренче мисалда беренче аралашучының җавап көткән сора-вы икенче аралашучы тарафыннан өлешчә раслана, сорауның бер өлеше генә уңай бәяләнә – бу өлешчә ризалашу. Икенче мисалда да шул ук сорау куела. Икенче аралашучы сорауның билгеле бер өлешенә каршы килеп, “юк” җавабын бирә, ләкин башка яссылыкта аның җавабы уңай – бу өлешчә ризасызлык.

Ике мисал да эчтәлек мәгънәләре белән бер үк. Аларны без тышкы чагылышларына карап кына аерабыз. Ризалашу һәм ри-засызлык махсус һәм гадәти тел чаралары белән белдереләләр. Әңгәмәдә махсус чаралар (күп очракта, модаль сүзләр) ризала-шу яки ризасызлык күрсәткечләре, гадәти чаралар ризалашуда да, ризасызлыкта да күзәтеләләр. Беренче мисалның ризалашу-ны белдерү репликасында беренче урында махсус сүз: “әйе” ре-лятивы (релятив дип без әңгәмәдәшнең соравына, мөрәҗәгатенә, күренеш-вакыйгага, гомумиләшкән бәя, мөнәсәбәт белдерә тор-ган сүзләргә әйтәбез) кулланыла. Каршы куючы “ләкин” теркә-гечennән соң, бирелгән сорауга кире җавап алына, тулаем алган-да, бу мисал – өлешчә ризалашу. Икенче мисалның мөнәсәбәтле репликасында беренче урында ризасызлыкны белдерә торган махсус чара – “юк” релятивы. Каршы куела торган “ләкин” теркәгечennән соңгы репликада – ризалашу яңгырый. Димәк, икенче мисалны без өлешчә генә ризасызлык төренә кертәбез.

Шул рәвешчә, үзләштерелә торган мәгълүматка икенче аралашучы һәрвакыт ризалашу яки ризасызлык мөнәсәбәтен белдерә. Әлеге мөнәсәбәт тулысынча яки өлешчә оешырга мөмкин, бәхәскә дә үсүе бар.

3.Таблицаны файдаланып, тыңлаучылар төре турында сөйләгез.

**Тыңлаучылар төре**




**4.“Тыңлый һәм тыңлата беләсезме?”** тестына җаваплар бирегез.

Хезмәткәрләр бер-берсен ишетә-тыңлый-аңлый алмаулары сәбәпле, конфликтлы хәлләр барлыкка килә, кискенләшеп китә һәм инцидент дәрәҗәсенә кадәр үсәргә мөмкин. Бу хәлләр аларның бер-берсен тыңларга һәм аңларга теләмәүләреннән, һәрвакыт үз фикерләрен аңлата белмәүләреннән, теге яки бу очракка ачык һәм төгәл караш күнекмәләренә ия булмауларыннан килеп чыга.

Тыңлый алу һәм аралашу мөмкинлекләрегезне сорауларга төгәл генә “әйе” яки “юк” җавапларын биреп, ачыклый аласыз.

1) Үзара аралашканда, нәрсәдер аңлатканда, сез әңгәмәдәшегезнең төшенүенә игътибар итәсезме?
2) Әңгәмәдәшегез аңлый торган сүзләр сайлап сөйлисезме?
3) Башкалар белән уртаклашканчы, сез үз идеяләрегез, караш-тәкъдимнәрегез турында уйланасызмы?
4) Әңгәмәдәшегез яңа фикер яңгырагач, сорау бирмәсә дә, сез аны фикерегезгә төшенгән дип исәплисезме?
5) Сөйләмегезнең аңлаешлырак, кыскарак булуына омтыласызмы?
6) Сөйләмегезнең эзлеклелегенә омтылып, үз караш-тәкъдимнәрегезне бәян итү рәвеше турында алдан алы уйланасызмы?
7) Үзегезгә сорау бирүләрен хуплыйсызмы?
8) Үзегезне тирә-юндәге кешеләрнең уйларыннан хәбәрдармын дип исәплисезме?
9) Әйләнә-тирәгездәге кешеләрнең фикер-карашларын сиземләвегезне тәгаенләү өчен сез аларга сораулар бирәсезме?
10) Сез фактлар (мисаллар) һәм фикерләрне аерып карыйсызмы?
11) Әңгәмәдәшегезнең дәлилләренә каршы яңа фикерләр эзлисезме?
12) Әңгәмәдәшләрегезнең сезнең белән тулысынча килешүләре өчен тырышасызмы?
13) Сез, һәрвакыт, аңлаешлы, төгәл, кыска һәм әдәпле сөйләшәсезме?
14) Үз фикерләрегезне туплау максатыннан, әңгәмәдәшләрегезгә тәкъдимнәрегез турында уйланыр яки сораулар бирер өчен паузалар ясыйсызмы?

Кем дә кем 4, 8, 11, 12 нче сораулардан башкаларына уңай (“әйе”) җавабын бирсә, аларны оста аралашучы, үз фикер-карашларын әңгәмәдәшләренә җиткерә белүче, тыңлый белү сәләтенә ия кешеләр дип әйтеп була. Башкача булганда, тыйлый алу һәм аралашу мөмкинлекләрегезне арттыруда төрле комачаулыклар барлыгы турында уйланырга туры килә.

5. “Студент имтиханда” сериясеннән профессорның таркаулыгыннан җиңелчә генә шаярып алган мәзәкләрне рольгә бүлеп уйнап күрсәтегез.

6. “Студент имтиханда” сериясеннән студентның билге өчен тапкырлыгын, максатчанлыгын тасвирлаган мәзәкне фарс дәрәҗәсендә уйнап күрсәтегез.

7. “Студент көнкүреше” темасына берәр мәзәкне сентимент, фаҗига, җиңелчә көлү, киная төсмерләре белән уйнап күрсәтергә.

8. “Балалар сөйләшә” сериясеннән 3-4 мәзәкне берләштереп,“ике бала”, “әтисе-улы”, “әнисе-улы”, “әнисе-кызы”, “мөгаллим-шәкерт” өчен реприза языгыз, башкарып күрсәтегез.

9. Бәхәс – фикерләр һәм карашлар бәрелеше. Дәлилләү барышында аның төп өлешләре: кире раслау – антитезис куллану – оппонент та, пропонент та үз карашларын яклыйлар – ...

Бәхәснең тагын нинди сыйфатларын әйтер идегез?

10. Бәхәс алып бару рәвешләренә – дискуссия, полемика, эклектика, софистикага – бәяләмә бирегез.

11. Бәхәс алым-ысулларына – башлап җибәрү; “һөҗүм”, каршы якның игътибарын читкә юнәлдерү; дәлилләү йөген күчерү; каршы якны үз дәлиле белән җиңү; көтелмәгәнлек; каршы сүзне кичектереп тору; алдан-алы катгый фикерләр яңгыратмау, соңыннан сүз алу – җәенке аңлатма бирегез.

12. Бәхәстә бик урынлы булмаган ысулларны – каршы якка сүз әйтергә бирмәү; катнашучы-тыңлаучылар «хор»ын оештыру; ихтималланган теләк-омтылышларга сылтама; ялган, дәлилләнмәгән мисаллар китерү; алдан уйлап фикер чуалту; каршы якның күңел тынычлыгын алуны – аңлатыгыз.

13. Эристикага нинди таләпләр куела?
14. Таблицалар буенча сөйләп күрсәтегез.

**а) Конфликтларың төркемнәре**

| № | Төркемләү сыйфатлары | Конфликтларның төрләре |
|---|---|---|
| 1. | Килеп чыгу өлкәсе | Сәнәгать һәм икътисадка бәйле конфликтлар. Идеология һәм сәясәткә бәйле конфликтлар. Иҗтимагый-психологик конфликтлар. Гаилә-көнкүреш конфликты. |
| 2. | Таралу даирәсе, дәвамлылыгы һәм киеренкелеге | Шәхес күңелендәге конфликт. Шәхесара конфликт. Шәхесара-төркем җирлегендәге конфликт. Гомуми һәм аерым мәсьәләгә багышланган конфликтлар. |
| 3. | Конфликтлы мөнәсәбәттә катнашучылар | Төркемара конфликт. Гаугалы, тиз узучан, кыска вакыт аралыгында үткән конфликт. Киеренкелектә узучан, дәвамлы конфликт. Сизелми һәм салмак узучан конфликт. Сизелми һәм тиз узучан конфликт. |
| 4. | Конфликтның асылы | Чынбарлык (предметлы) конфликты. Реаль булмаган (предметсыз) конфликт. |
| 5. | Чыганагы һәм сәбәпләре | Объектив һәм субъектив конфликтлар. Оештыру эшчәнлегенә бәйле конфликт. Хис-тойгылы һәм иҗтимагый-хезмәт конфликтлары. Эшлекле һәм аерым төркем мәнфәгатьләренә караган конфликтлар. |
| 6. | Аралашу халәте | Бер яссылыктагы (горизонталь) конфликт. Буйсыну мөнәсәбәтендәге кешеләр арасынлдагы (вертикаль) конфликт. Катнаш төрдәге конфликт. |
| 7. | Иҗтимагый нәтиҗәлелеге | Уңай һәм тискәре конфликтлар. Оешманың камилләшүенә ярдәм итә торган (конструктив) һәм үсешенә комачаулый торган (деструктив) конфликтлар. Яңарышка юнәлдерелгән һәм урнашкан тәртипләрне җимерүгә, киеренкелекне аттыруга юнәлтелгән конфликтлар. |
| 8. | Узу рәвеше һәм бәрелеш дәрәҗәсе | Ачыктан-ачык һәм астыртын узучан конфликтлар. Уйламаганда килеп чыккан; алдан әзерләнеп оештырылган; вакытын көтеп, махсус оештырылган конфликтлар. |
| 9. | Җайга салу алымнары һәм колачлау дәрәҗәсе | Нык каршылыклы һәм ташлама ясап хәл ителә торган конфликтлар. тулысынча яки өлешчә хәл ителә торган конфликтлар. Килешү һәм хезмәттәшлеккә алып килә торган конфликтлар. |

**ә) Оешмада конфликтның вазифасы**

| Конфликтның вазыйфасы | Конфликтның юнәлеше һәм нәтиҗәләре | |
|---|---|---|
| | уңай | тискәре |
| Хезмәттәшләр нең бердәмлеген арттыру | Шәхесара һәм төркемара киеренкелекне йомшарту; шәхси һәм коллектив мәнфәгатьләрен килештерү; формаль һәм формаль булмаган төркемнәрне берләштерү; гомумкызыксыну даирәсен киңәйтү һәм ныгыту | Коллективның оешканлыгын һәм бердәмлеген какшату; аерым шәхес һәм төркемнәр арасындагы мәнфәгатьләр ярашуын җимерү; уртак эшкә хилафлык кылу, башкалар исәбенә үз файдаңны кайгырту; минминлелеккә, үзсүзлелеккә, тәртипсезлеккә күз йому |
| Иҗтимагый багланышларны көчәйтү | Хезмәттәшләрнең нәтиҗәле һәм җиңел аралашуын тәэмин итү; максатларга ирешүдә, хезмәт вазыйфасын үтәүдә һәм иҗтимагый партнерлыкны арттыруда килешеп эшләү | Уртак эш белән шөгыльләнүчеләрнең гамәлләрендә килешеп бетә алмаулары; уртак уңышка ирешү өчен үзара кызыксынуның кимүе, хезмәттәшлеккә омтылуда комачаулыклар булдыру |
| Иҗтимагый киеренкелек чыганаклары турында кисәтү | Хәл ителмәгән мәсьәләләрне барлау һәм аларны бетерү чараларын эзләү; эшчәнлекне оештыру һәм саклау шартларында коллективның ихтыяҗын, мәнфәгатен һәм кыйммәти күрсәткечләрен тормышка ашыру | Җитәкчелек гамәлләренә карата кискен ризасызлык оештыру; урындагы аерым затларның җитешсезлекләренә протест белдерү; хезмәт шартларыннан канәгатьсезлекнең көчәюе |
| Яңалык, иҗади башлангычларга ярдәм итү | Хезмәт нәтиҗәлеге һәм эшчәнлеккә омтылышның көчәюе; осталык күтәрүдә ярдәм итү һәм хуплау; иҗатта, мәсьәләләрне яңача һәм уңайлы хәл итүдә булышу | Иҗтимагый һәм хезмәт нәтиҗәлеген арттыруда өстәмә комачаулыклар оештыру; эшчәнлеккә омтылышны, дәртләнеп эшләү һәм иҗади башлангычларны булдырмаска тырышу; мәсьәләләрне яңача хәл итүдән качу |
| Эшлекле мөнәсәбәтләрне | Ышанычлы иҗтимагый-психологик климат урнаштыру; | Әхлакый-психологик мохитнең начараюы; эзлекле мөнәсәбәтләр һәм үзара |

| | | |
|---|---|---|
| үзгәртү | хезмәткә һәм эшлекле тәкъдимнәргә ихтирамлы мөнәсәбәт булдыру; үзара ышаныч халәтен үстерү | хезмәттәшлекне оештыруның катлаулануы |
| Оешмада һәм анда эшләүчеләр турында мәгълүмат | Эшче-хезмәткәрләрнең оешмадагы хәл-әхвәлнең торышы хакында хәбәрдарлыклары үсү; “уртак тел” табу | “Кырын караш” халәтенең көчәюе; хезмәттәшлектән читләшү; фикер уртаклашу, диалог оештыруга каршы килү |
| Кара-каршы көрәшне булдырмый калу чаралары | Үзара килешү нигезендә каршылыкларны җайга салу; иҗтимагый мөнәсәбәтләр һәм хезмәт оештыруда капма-каршылыкларны киметү | Киеренкелек һәм дошманлыкны көчәйтү; килешүгә китерә торган чара-алымнардан читләшү |

**б) Конфликтларның үсеш баскычлары һәм этаплары бәйләнеше**

| № | Конфликтларның үсеш баскычлары | Конфликтның үсеш чикләре | Конфликтны хәл итү мөмкинлеге, % |
|---|---|---|---|
| 1. | Конфликтның башлануы | I этап. Конфликтның хасил булуы һәм аны уңай хәл итхгә рухи хәзерлек.<br>II этап. Конфликт килеп чыгуның чын сәбәбен билгеләү. | 90 |
| 2. | Конфликтның үсеше | III этап. Конфликтны хәл итүнең мөмкин булган вариантларын эзләү. | 45 |
| 3. | Конфликт югары ноктасы | IV этап. Конфликтны хәл итү вариантларын табу һәм сайлау. | 5 |
| 4. | Конфликтның кими башлавы | V этап. Конфликтны җайга салуның башлануы. | 20 |
| 5. | Конфликтның туктавы | VI этап. Конфликтны җайга салуның дәвамы. | 50 |
| 6. | Конфликтның тәмамлануы | VII этап. Конфликтның җайга салынып бетүе (хәл ителеп бетүе) | 100 |

**в) Арадашлык итү этаплары**

| Этаплар | Төп бурычлар | Арадашчыга киңәшләр |
|---|---|---|
| I этап<br>Әзерлек. Мәсәләнең эчтәлеге белән танышу. | Сөйләшү өчен мөмкинлекләр тудыру.<br>Алдан килеп туган мәсъәләләрне тикшерү.<br>Конфликтның халәтенә беренчел бәя бирү.<br>Конфликтны хәл итүдә арадашчылык куллану мөмкинлеген бәяләү.<br>Медиация турында мәглумат туплап бирү<br>Катнашучыларның (яки аларның вәкилләренең) ризалыгын алу<br>Арадашчылык оештыру(вакыт, урын, оештыру рәвешен билгеләү).<br>Арадашлык кагыйдәләре белән таныштыру.<br>Арадашчы сыйфатларын аңлату. | Конфликтта катнашучыларны сәләмләп, алда билгеләнгән урыннарга урнашырга тәкъдим итү.<br>Үзегез белән һәм якларны таныштырыгыз.<br>Очрашу максатын аңлатыгыз, якларның катнашу теләеләре булуын ассызлыклагыз.<br>Үзара аралашу кагыйдәләрен, аларның әһәмиятен тагын бер кат искә төшерегез.<br>Конфликтта катнашучылар халәтен бәяләгез. Ике як та катнашуга әзерме? Катнашучыларның берәресе кызып китмәгәнме, борчылмыймы?<br>Тынычлык урнаштыру өчен өстәмә чаралар куллану соралмыймы? |
| II этап<br>Мәгълүмат туплау | Катнашучыларның карашларын ачыклау.<br>Катнашучылар ия булган мәгълүматны бәяләү һәм тигезләү максатыннан аныклык кертү ачыктан ачык хәбәр итү.<br>Һәркем өчен кабул ителгән һәм көн тәртибендә каралачак план һәм карарлар белән таныш булуына ирешү.<br>Ихтирамлык, хәлгә керүчәнлек, ышаныч халәтен тергезү (яңадан оештыру).<br>Соңыннан эшкәртеп бетерү максатыннан барлык әһәмиятле темаларны ачыклау, билгеләү һәм хәтергә ассызыклап, сеңдереп кую.<br>Катнашучылар тәкъдим иткән карашларны тикшерү темаларына әйләндерү. | Конфликтта катнашучыларның берәресеннән беренче булып башлавын сорагыз. Бу аларның теләкләреннән тора. Хәзер сез сюжет бәйләнешендә торуыгызны бәяләп куегыз.<br>Бәлки, конфликтта катнашучылар проблеманы хәл итү халәтендә беренче тапкыр<br>Актив тыңлау алым файдаланыгыз, сезгә ярдәм итсә, кыскача язып куегыз, ясагыз.<br>Нәтиҗә ясалган мизгелләрдә очракларда да актив тыңлау алымын, вербаль булмаган бәяләрне дә файдаланыгыз.<br>Конфликтта катнашучыларның тәртибенең һәм куллары хәрәкәтенә аеруча игътибарлы булыгыз.<br>Кирәк булса, сөйләшүне |

| | | |
|---|---|---|
| | | туктатыгыз, икесен дә тынычландырыгыз яки икенче катнашучыны аның да сөйләп бетерергә шундый ук мөмкинлеге булачагына ышандырыгыз.<br>Сөйләүчегә игътибар күрсәтеп, мәгълумат агышын дәвам иттерегез. Арадашлык халәтен дәвам итегез<br>Беренче катанашучының хәбәрен кыскача гомумиләш-тереп куегыз, Кыскача сөйләгән вакытта арадашчы тискәре бәя һәм ком-ментарийларны төшереп калдырып, киеренкелекне йомшартырга мөмкин. Катнашучылардын аның хәбәрен дөрес аңлавыгыз турында тәгаенләгез. Катнашучыны уртак эшкә өлеш керткәне өчен хуплап алыгыз. Икенче якның сабырлыгын (мөмкин булса) бәлки үбегез.<br>Икенче катнашучы белән дә шул ук гамәлләрне кабатлагыз.Ике якның да үз үзләрен тотышларына аеруча игътибар белән күзәтегез. |
| III этап Кызыксыну даирәсен аныклау | Карашлар һәм темалар артына яшерелгән кызыксыну даирәсен һәм ихтыяҗларын ачыклау. Бернинди чикләүләрсез катнашучыларның халәтенә хис-тойгы халәтенә иркенлек бирү. | Һәр катнашучыдан мәсьәләне хәл итүдә ярдәм сорау.<br>Мәсьәләләне хәл итәрлек яки ризасызлык тудыра алырлык хәбәрләр һәм карашланы аңларга тырышыгыз.<br>Катнашучыларның хәбәрен гомумиләштереп кыскача кабатлаганды төп мәсьәләне, проблеманы аерып куегыз. Кирәк булганда аерым очрашулар үткәрегез. Килешү һәм ризасызлык өлешләрен билгеләгез, конфликтта катнашучыларга мәсьәләләрне һәм таләпләрне мөһимлекләре буенча урнаштырырга ярдәм итегез. |

| | | |
|---|---|---|
| IV этап<br>Идеяны креатив эзләү, хәл итүнең мөмкин булган төрләрен ачыклау. | Сөйләшуләр даирәсен киңәйтү өчен идеялар эзләү .<br>Якларның мәнфәгатен исәпләп чишелешнең яңа төрләрен кулланып мөмкинлекләрен җыйнау(туплау) | Һәрбер катнашучының мәсьәләне хәл итүдә мөмкин булган төрләрне яки чараларны саклап утуен сорагыз.Һәрбер төрнең эчтлеген кыскача сөйләп чыгыгыз.Һәрбер катнашучы белән әлеге төрнең тормышка ашуын кабат-кабат тикшерегез.<br>Әлеге төрнең (мөмкин булса) тормышка ашырыла алмавын билгеләп үтегез. Эш тукталып калганда, гомумиерәк рәвештә башка мөмкин булган төр тәкъдим итегез. Якларны уңышның актималлегенә ныграк ышандырыгыз. Эш тукталып калганда,төнәнфес яки мәсъәләне башка очрашуга күчеруне тәкъдиме белдерегез.<br>Конфликтта катнашучылардаг мөмкин булган чишелешлзрне гамәлдә сынап карауларын сорагыз. |
| V этап<br><br>Чишелеш төрләрен сайлау. | Яңа фикер һәм дәлилләрдән чыгып,мәнъфәгатьләргә нигезләнеп,мөмкин булган чишелешне сайларга һәм бәяләргә. Мәнфәгатьләргә теләктәшлек белдереп,яки ташлама ясап, конфликтны хәл итү яки җайга салуның һәркем өчен мөмкин төрен тормышка ашыру.<br>Килеп чыккан нәтиҗәләрне оештыру, техник,финанслау,социаль,экологик, юридик яктан тормышка ашыру мөмкинлеген тикшерү. | Икесе өчен дә уңай хәл ителеш төрен сайлауларын хуплагыз, тәкъдим ителгән төрләрен,гамәли әһәмиятен билгеләгез. Катнашучыоарга чишелешне тормышка ашыру программасын эшләргә ярдәм итегез. Якларның башлангыч халәтен купкә алга китүләрен бәяләп үтегез. |
| VI этап<br><br>Килешү төзү һәм аны тормышка ашыру | Килешү төзү.Килешүнең арадашлыктан тыш та тормышка ашырыла алуын тикшерү. Килешүнеҗ тормышка ашырылу юлларын ачыклау.<br>Нәтиҗәләрне тикшереп тору һәм алдагы очрашулар турында килешү төзү. | Килешү шартларын кыскача гомумиләштерегез. Якларның нәтиҗәне хуплау-ларын ассызыклагыз. Һәркем-нзн тикшерелергә тиешле берәр сорау калу-калмавын белешегез. Килешүнең сезнеке түгел,ә аларныкы булын ассызыклагыз. Якларны үзлә-рен итәгатъле тотулары өчен |

| | | |
|---|---|---|
| | | мактап алыгыз.Кабул ителгән килешүнең тормышка ашачагына ышануыгызны куәтләгез. |

15. «Мактап торган дуска каршы, дөресен әйткән дошман яхшы». Ничек аңлыйсыз?

16. «Төшендем ялгышыма – төзәлдем язмышымда» тәгъбирен аңлатыгыз.

17. Тәрбия мәсьәләсенә кагылышлы темага, ата-аналар җыелышына 3 минутлык нотык язарга, укып күрсәтергә. Проблемалы сорауны аерып куярга.

18. Берәр дөньяви темага мәкалә укылгач, тозак сорау, каршы сорау, юнәлтелгән сорау, четерекле сорау, сорау-ризасызлык, ихтыярсызлау сораулары төзергә, яңгыратырга.

19. Төрле типтагы сораулар файдаланып, 1 минутлык бәхәсле диалог төзергә, яңгыратырга.

**Өстәмә эш:** 1. Ислам мәдәнияте тарихына кагылышлы, гомуми кешелек кыйммәтенә ия тема сайларга, бәхәсле мәсьәләләрне аерып куярга, кереш сүз язарга һәм йомгак сүзнең якынча эчтәлеген әзерләргә. 2. Әзерләнгән темага диспут үткәрергә.

# VI. СӨЙЛӘМ КУЛЬТУРАСЫҺӘМ АРАЛАШУ СТИЛЕ

## Сөйләм культурасы

Хәзерге дини, сәяси, икътисади җәмгыятьтә мәдәниятне үзенчәлекле яшәеш рәвеше дип аңлыйлар, ул билгеле бер тәртип кагыйдәләре, акыл эшчәнлеген яңарту ысулы буларак бәяләнә. Бу очракта мәдәниятне аңлау яшәеш рәвешләренең һәм җәмгыять нигезенең тәңгәллегеннән гыйбарәт. Икенче тәгълимат мәдәниятне бербөтен система – иҗтимагый берләшмәнең оешу, яңару ысулы итеп карый. Мәдәният җәмгыятьнең бөтен даирәсендә, барлык гамәлләрендә чагылыш таба. Бу очракта тормыш агышы мәдәни үрнәкләргә чагыштырмача тәңгәл килергә тиеш.

Мәдәни дөньяга карашның икесе дә сөйләм культурасын өйрәнүдә бик мөһим. Аларны аера белү өчен, без сөйләм культурасы һәм аралашу культурасы турында сөйләшәчәкбез. Хәзерге әдәби телнең кагыйдәләренә нигезләнгән аралашу рәвешен без сөйләм культурасы дип аңлыйбыз. Сөйләм культурасын «телне мәдәни корал итеп яңарту максатыннан, тел гыйлеменең канунлаштыру мәсьәләләрен өйрәнә торган бүлеге» тикшерә. Югары сөйләм культурасына ия кеше сөйләмен кагыйдәләргә туры китереп оештыра, аралашу даирәсендә мәдәни дәрәҗәсен яңартып яши. Сөйләм культурасы сөйләмнең (чыгышның) эчтәлеге түгел, ләкин сөйләм кимчелекләре чыгышта эчтәлек җитешсезлекләре күрсәткече буларак күзаллана.

Гадәттә, сөйләм культурасына әдәби телнең кагыйдәләр җыелмасын, аралашу кагыйдәләре җыелмасын һәм сөйләм этикетын кертәләр. Оратор сөйләменең аңлаешлылыгын, аның сөйләмне оештыру һәм тыңлаучыны үз ягына үзгәртү сәләтенең бердәмлеген сөйләм культурасы тәэмин итә. Билгеле булганча, телнең яшәеш рәвеше һәрвакыт аның эчтәлеге белән бәйле; моннан чыгып сөйләм культурасын, иҗтимагый эчтәлек белән чагыштырганда, кешенең камиллек үлчәме итеп карарга була.

Тел нормалары дип билгеле бер аралашу даирәсенә хас булган дөрес әйтелеш, сүзләрне урынлы куллану үрнәкләре, стилистик һәм грамматик кагыйдәләр атала. Ясалма телләр киңлегендә сүзлек, синтаксис һәм семантика нормаларын да аерып карыйлар, алар сөйләмне максат белән тәңгәлләштерәләр, аралашу өчен аңлаешлы итәләр.

Табигый, әдәби сөйләм һәм язма телнең нормаларын төрлечә төркемләргә мөмкин. Без бу кагыйдәләрне дөрес әйтелеш (орфоэпик), җөмлә һәм сүзтезмә ясалу (синтаксик), сүз ясалышы (морфологик) һәм сүзне куллану (лексик) нормаларына берләштереп карый алабыз. Катгый һәм җиңелчә (нейтраль) нормалар булуын әйтергә кирәк. Үзенең сөйләм культурасын үстерергә теләгән яшь мөгаллимгә әзерләнүне мәҗбүри рәвештә катгый нормаларны үтәүдән башларга кирәк һәм, акрынлап, сөйләмнең бөтен байлыгын һәм мөмкинлекләрен үзләштерү мәгъкуль.

## Әдәби яңгыраш нормалары

Татар әдәби телендә сөйләм нормалары орфоэпия (дөрес әйтелеш), акцентология (сүз һәм мәгънәви басым кагыйдәләре), дикция (авазның анык әйтелеше) һәм орфофония (тавышның дөрес яңгыравы) кагыйдәләренә нигезләнә. Дөрес яңгыраш кагыйдәләре, билингвизм шартларында, рус теленнән кабул ителгән алынма сүзләрдә басымның куелышы ирекле, күп урынлы һәм эластик характерда булуы белән бераз катлаулана.

Дөрес әйтелеш басымнардан, тавыш төсмере ярашудан һәм конкрет артикуляция шартларына бәйле рәвештә барлыкка килә.

Хаталы әйтелеш сөйләмне кабул итүгә комачаулый, аның мәгънәсен боза, кайвакыт эчтәлеген аңлауда күп ялгышларга китерә, аудиторияне тыңлаудан читләштерә. Дөрес әйтелеш – ораторның сәнгати дәрәҗәсен һәм белемлеген раслау нигезе.

Югары белемле, укымышлы мохиттә тәрбияләнгән һәм тиешле белем алган оратор тел, сөйләм кагыйдәләрен яхшы белә. Ул әйтелештә хата ясамый диярлек. Аңа бары тик аерым җитешсезлекләргә игътибар итәргә һәм аларны киметергә кирәк.

Әдәби тел нормаларын белмәгән һәм аңсыз рәвештә әдәби булмаган әйтелешне кулланган кешеләр аерым ярдәмгә мохтаҗлар. Чөнки әйтелешне үзлектән генә төзәтеп булмый.

Ораторның иҗтимагый дәрәҗәсе күтәрелү орфоэпик хаталарга кире пропорциядә. Чөнки мәсьәлә ораторның үз эшенең остасы булуы, абруе белән бәйле. Дөрес әйтелешне күнектерү эшчәнлеген Х.Х.Сәлимовның “Татар теленең орфоэпик сүзлеге” хезмәте белән танышудан, Г.С.Нуриевның “Татар сөйләм культурасы: орфоэпия, дикция” уку ярдәмлеген үзләштерүдән башларга була.

Күп кенә ораторларга үзләренең әйтелешен әдәби югарылыкка җиткерү бик күп сәбәпләр аркасында мөмкин түгел. Практикада

шундый очраклар булгалый, кешеләр әйтелешне җитәрлек дәрәҗәдә белмәгәнлектән, оялып, эндәшми торырга һәм, хәтта, халык алдында чыгыш ясаудан баш тартырга мәҗбүр булалар. Беренчедән, аралашуда үзеңне чикләү афәтле рәвештә психикага тәэсир итә һәм төрле авыруларга китерергә мөмкин. Икенчедән, күп кенә кешеләр актив аралашу таләп ителгән иҗтимагый вазифалар башкаралар. Сөйләм культурасы өлкәсендәге кимчелекләр профессиональ һәм социаль үсешкә комачаулый. Бу очракта нәрсә эшләргә?

Беренчедән, профессионаллар ярдәмендә үзеңнең табигый мөмкинлекләреңне яхшырак аңлау һәм аларны белеп файдалану уңай нәтиҗәләргә алып килә. Уңай мөмкинлекләрне бар егәренә кулланырга, ә оратор образында күзәтелгән җитешмәгән яклар белән килешергә һәм аларны риторика, сөйләм алымнары ярдәмендә киметергә мөмкин.

Бу очракта чыгышларга җентекле, максатчан һәм даими хәзерләнергә киңәш ителә. Шул ук вакытта үзеңнең аралашу тәҗрибәңне әледән-әле аңлы рәвештә тикшереп торырга кирәк.

Чыгышны мәрхәмәтлелек нигезендә, тыңлаучылар файдасын күзаллап оештыру бик мөһим.

Ораторның тыңлаучыларга карата ихтирамы әйтелештәге кимчелекләрен һәм аралашуның башка җитешсез якларын сиздермәскә ярдәм итә. Һәм шуны да истә тотарга кирәк: тыңлаучылар мәгълүматны аңсыз рәвештә кабул итәләр, шуңа күрә кабул итү җитәрлек дәрәҗәдә булмый.

Ораторның чыгыш оештыруда табигый мөмкинлекләрне файдалануы, аларны дөрес, вакытлы-урынлы куллануы аралашуның нәтиҗәлелеген арттыруга булыша. Шул ук вакытта ораторның образын әдәби әйтелеш яссылыгында камилләштерергә кирәк. Уңайлы аралашу оештыру авыр, ләкин шуңа да карамастан, аның нәтиҗәсе искиткеч булачак.

## Лексика һәм морфология нормалары

Сөйләм нормаларына сүзнең мәгънәсе буенча кулланылуын, мәгънәви басым кануннарын сүз ясалышы ысулларын һәм әйтем, җөмлә барлыкка килү кагыйдәләрен кертергә мөмкин. Шулай ук сөйләмнең мөстәкыйльлеккә ия аерым төрләрен оештыру кагыйдәләрен билгели торган шәхси яки функциональ стильне,

телнең барлык мәдәни даирәсен нормалаштыра һәм үстерә торган гомум әдәби стильне аерып карарга була.

Мәдәни стиль фикернең эчтәлеген күзалларга, аны кирәкле дәрәҗәдә мәгълүмат үзләштерерлек рәвешкә китерергә, тыңлаучыларның игътибарын җәлеп итеп, аларда күңел көрлеге, эстетик ләззәт уятырга һәм тыңлаучыларга оратор карашында берләшергә ярдәм итә.

Лексик нормаларны белү фикер эчтәлеген һәм аның вербаль рәвешен тулыландырырга мөмкинлек бирә. Һәрбер сүз һәм төшенчә, аларның төрле тезмәләре билгеле бер мәдәни мәгънәгә ия. Хәтта туган телне белү төрле дәрәҗәдә булырга мөмкин. Шулай да кешеләр телнең билгеле бер лексик катламнарын беләләр һәм аларны үзләренең шәхси сөйләмнәрендә кулланалар. Тел мәгънәсенә иң югары дәрәҗәдә ия булучылар – шагыйрьләр, язучылар, фәлсәфәчеләр, ягъни югары культуралы кешеләр. Алар телне йогынты чарасы рәвешендә кулланалар. Күпчелеге үз эшенең остасы һәм, әйтергә кирәк, лингвистлар телне универсаль рәвештә беләләр. Лексик төгәллек өчен кагыйдәләр белү генә җитми, телнең тәмен хис дәрәҗәсендә тоемлый белүне күнектерергә кирәк.

Прагматик яктан караганда оратор үзе үзләштергән лексемаларны гына кулланырга тиеш. Ул тел берәмлекләрен нәрсә өчен, нинди максаттан һәм ничек кулланасын белә һәм аларга, йогынты чарасы булганга, җитди карый.

Лексик стереотиплар һәм штамплар кулланырга була, ләкин сүзне ялгыш кулланып, мәгънәви капкынга эләгүең бар.

Сүзне дөрес кулланып сөйләү, телне бик яхшы белү, логика, мәдәни эчтәлек һәм башка күп нәрсәләр белән билгеләнә. Шуңа да сөйләмнең дөреслеген саклау – гомуммәдәни мәсьәлә.

Морфология нормативлары телнең гомуми кагыйдәләренә буйсынып оешкан һәм кагыйдәләр нигезендә үзгәрә торган сүзләрне генә кулланырга өнди. Норманы бозу өчен тел тирәлеген алыштыру җитә. Алга киткән тел тирәлегендә сөйләшүчеләрнең күп сүзләре таныш булмаганлыктан, алар янында без үзебезне чит кешеләр кебек хис итәбез. Тел нормаларына көндәлек аралашуда яки махсус рәвештә кагыйдәләр ятлап өйрәнеп була. Диалекталь яки нормалаштырылмаган тел мохитендә үскән сөйләүче, югары белемле интеллигент булса да, сөйләменең хаталы булырга мөмкинлеген истән чыгармаска тиеш. Хаталы сөйләм төрле морфемаларның аң һәм аңга бәйле булмаган төрле дәрәҗәдә ныклы

урын алуына бәйле. Дөрес сөйләргә өйрәнү өчен башлап чыгыш ясаучыга максатчан эш алып барырга кирәк. Стильнең гомуми нормалары шәхси риторикаларда, сөйләмнең билгеле бер жанрларында, теге яки бу берләшмәләр аралашуында, аеруча танылган чыгыш ясаучыларның сөйләмнәрендә аныкланалар. Стиль ягыннан камиллек сөйләмне нәтиҗәле, үтемле итә. Стиль мөмкинлекләре риторик нормаларга әйләнә, мәдәният эчтәлегенә күчә. Шул рәвешчә, сөйләм практикасы белән бергә риторика да белем төре буларак камилләшә. Һәрбер сөйләүченең стиле гомуми характердагы элементларны һәм гомуми нормалардан тайпылган шәхси стильнең үзенчәлекле билгеләрен эченә ала. Башлап чыгыш ясаучыга яхшы стиль нормаларына нигезләнгән шәхси мөкинлеләрен кулланырга кирәк. Шәхси стиль алымнары, аның камиллеге кинәт кенә барлыкка килми, алар – аралашуда тәҗрибә туплау нәтиҗәсе.

## Синтаксис һәм стиль таләпләре

Синтаксис нормалары итагатьлек таләпләренә туры килгән һәм бер төгәл мәгънә белдергән тел тәгъбирләрен оештыру кагыйдәләрен билгели. Логикада фикер йөртү структурасы чыгыш ясаучыны мәгънәле предикатка (хәбәргә) тиңли. Чыннан да, иң катлаулы синтаксик конструкцияләр дә хәбәрнең тармакланган төрләре булып тора. Синтаксик яктан дөрес һәм анык булмаган “җәзаларга ярамый кичерергә” мисалы сөйләмдә барлыкка килергә мөмкин булган хаталарның оешу рәвешен һәм мәгънәсезлеген ачык күрсәтә.

Синтаксик норманың гамәли ныгып калган яклары бар. Оратор аныграк фикерләгән саен, күбрәк гади җөмләләр белән эш итә. Фикерне һәм сөйләм ысулын катлауландыру күләмле, авыр синтаксик төзелмәләр куллануга алып килә. Билгеле бер дәрәҗәдә белемгә ия ораторга синтаксик мөмкинлекләрнең тәңгәл тәэсирен аңлау һәм аудиториядә шул даирәдә эшләү җитә.

Синтаксик культураның урта дәрәҗәсенә ия булган оратор тел, логика, фәлсәфә һ. б. белемнәрнең кулланыш нормаларын үзләштергән була. Фикер оештыру мәсьәләсендә оратордан катлаулы фикерне тел чаралары рәвешенә тәңгәл күчерә белү сәләте таләп ителә. Әлеге иҗади эшчәнлекнең мәгънәсе – аңлы рәвештә фикерне сүзгә күчерү, әйтелгән сүзнең эчтәлеген һәм оешу рәвешен бәяләп, сайлап алу.

Синтаксик культураның югары дәрәҗәсендә мәдәни контекст даирәсендә яңача фикерләү юлларын һәм тел чаралары ярдәмендә төрле сөйләм структураларын төзеп була. Табигый телләрдә синтаксик кагыйдәләр инде урнашып бетүгә карамастан, бөек язучылар һәм сүз осталары яңа төзелмә, әйтелмәләр иҗат итәләр.

Стилистик нормалар сөйләм оештыруның гомуми үрнәкләрен кабул итәргә чакыра. Стильне теге яки бу мәдәни тирәлектә оешкан сөйләм рәвеше яки чыгыш жанры дип карап була. Әдәби стиль сөйләм культурасының теләсә нинди чагылышына нигез булып тора. Сөйләмнең һәр төре аңа гына хас булган үзенчәлекләре белән аерыла. Бу үзенчәлекләр сөйләм төрләрен урынлы куллану, эчтәлеккә тәңгәл килү кагыйдәләре, стиль һәм аралашу максаты белән билгеләнә.

## Халык алдындагы чыгышта стиль чараларының әһәмияте

Билгеле, һәрбер ораторга үзенең сөйләмен камилләштерергә кирәк, чөнки аның чыгышы һәрвакыт тыңлаучының игътибар үзәгендә. Тыңлаучылар һәр хатаны, сүзнең дөрес кулланылмавын сизәләр. Чыгыш ясаучының ялгышын сизүгә, тыңлаучыларның аңа ышанычлары кими башлый.

Бу җәһәттән, ораторның аралашу осталыгы, чыгыш стиле хакында әйтергә мөмкин. Чыгыш стиле дигәндә халык алдында чыгыш ясаучыга хас фикер, мәгънә тапшыру осталыгы, аерым шартларда, телнең төрле катламын максатлы кулланып, карашлар алмашуда иң уңайлы сөйләм рәвешен оештыру турында сүз бара.

Белгечләр – Е.Юнина белән Г.Сагач чыгышта фикерләрне халыкка җиткерү сыйфатларын аерып карыйлар:

- Дөреслек (әдәби тел нормаларына буйсындырылган сөйләм);
- Сәнгатьлелек (чыгышта фикер үзләштерелү тыңлаучының хисе, эчке кичерешләренә йогынты ярдәмендә тормышка ашырыла);
- Аныклык (сөйләм авазларының аермачык яңгыравы, дөрес әйтелеш, яңгыраш кагыйдәләренең үтәлүе чыгышка ачыклык кертә);
- Төгәллек (чыгышта фикерләү сыйфаты сүзләрнең дөрес мәгънәдә кулланышына бәйле);
- Кыскалык;

• Урынлы кулланылу (теге яки бу аудиториядә әйтем һәм сүзләрнең урынлы һәм максатлы кулланылышы аралашу шартына туры килә).

Әгәр чыгыш ясаучы санап үтелгән аралашу сыйфатларына ия дип табылса, аралашу нәтиҗәле була.

## Сүз төркемнәренең стиль мөмкинлекләре

Халык алдындагы чыгыш стиле турында сөйләгәндә сүз төркемнәренең стилистик мөмкинлекләренә игътибар итәбез. Исем, фигыль, сыйфат, сан, алмашлыкларны урынлы куллану сөйләмнең төгәллеген, тойгылыгын арттыруда чагыштыргысыз әһәмияткә ия.

Исем сүз төркемендә мәгълүмати вазифа беренче урында. Сөйләмнең сәнгатьлелек даирәсендә исемнәр зәүкый йөк тә үтиләр, сурәтнең тәэсирле төгәллеген оештыруда катнашалар. Чыгыш текстларында конкрет исемнәр вакыйга-күренешләрнең күзалланырлык дәрәҗәдә тасвирлануын тәэмин итәләр, ә абстракт исемнәр сөйләмнең үтемлеген, тантаналыгын көчәйтеп, чыгыш ясаучының фикерләү куәсен чагылдыралар.

Сөйләмнең тәэсирен арттыруда ялгызлык исемнәрнең символик мәгънәләре дә ярдәмгә килә. Чыгыш ясаучы вакыйга сөйләгәндә, мисал китергәндә, үзенең хәбәренә яшерен яки туры мөнәсәбәтен, мәсәлән, катнашучы шәхесләргә бирелгән исем аша да белдерә ала (әдәби әсәрләрдә бу очракка мисаллар күп).

Ялгызлык исемнәрдән географик атамалар да стилистик чара (бизәк) буларак еш кулланылалар. Урын-җир атамалары, төрле күзаллаулар нәтиҗәсендә, көтмәгәндә тәэсирле, тирән мәгънәле сурәткә әйләнеп куялар: Болгар, Биләр, X гасыр дисәк, шанлы Болгар дәүләте; Казан, 1552 нче ел дисәк, татар халкының дәүләтчелеген югалтуы күз алдына килеп баса.

Исем сүз төркеме күчерелмә мәгънәдә генә түгел, чыгышларда туры мәгънәсендә кулланылып та, йогынтылы стилистик мөмкинлекләргә ия.

Барлык сүз төркемнәреннән фигыль сүз төркеме гамәл-вакыйгаларны тасвирлауда киң мөмкинлекләргә ия булуы белән аерылып тора. Кешенең рухи дөньясын да фигыль категорияләре ярдәмендә чагылдыра алабыз. Чыгышларда эш-гамәлләр турында эзлекле рәвештә мәгълүмат бирүебез хакыйки дәлил (чөнки чынбарлыкка туры килә) булып кабул ителә. Фигыльләр, күчерелмә мәгънәдә килеп, санап бетергесез зәүкый вазифа да

үтиләр. Булып узган хәлләр турында сөйләгәндә, хәзерге заман фигыльләре, үткән заман фигыльләрен алыштырып, вакыйганы тыңлаучыга якынайталар, “тарихны” хәзер, шушы мизгелдә үтәлә торган итеп, безнең күз алдына көтелмәгәнчә китереп бастыралар (бара, китә, сөйли, тыңлый).

Сөйләмне йогынтылы яңгыратуда хәзерге заман фигыльләре, һичшиксез үтәләчәк гамәлләрне белдерү өчен, билгеле киләчәк заман фигыльләре рәвешендә кулланылалар (барам, сөйлим).

Сөйләмнең үтемлеген, дәлилләү көчен арттыруда үзган заман фигыльләрен куллану киң мөмкинлекләргә ия. Булачак хәлләрне сөйләгәндә категорик үткән заман хикәя фигыльләрен (-ды/-де; -ты/-те) куллану дәвамлылык һәм кабатланып торуны, кире кагу мөнәсәбәтен чагылдыра. Көндәлек сөйләмдә күзәтелгәнчә, чыгышларда категорик үткән заман хикәя фигыль (сөйләде, тыңлады, әйтте, кайтты) һәм нәтиҗәле үткән заман хикәя фигыль (әйткән, тыңлаган) “ди”, “имеш”, “икән” модаль сүзләр белән хәзерге заман, киләчәк заман мәгънәсендә кулланганда, мыскыллау-хурлау төсмерен (әйтте ди, барды ди; биегән имеш, көткән ди, яраткан икән) белдереп, бу вакыйга-гамәлнең беркайчан да үтәлмәвенә ишарә булып яңгырый.

Ымлыклар белән килгән категорик үткән заман хикәя фигыль (Ах-вах килде; әйдә, киттек!) кыска чыгышларда, мәсәлән, өндәмә чыгышларда, отышлы яңгырыйлар, эш-гамәлнең мизгел дәвамлылыгында узуын күз алдына китереп бастырып, сөйләмнең омтылышлы перспективасын тәэмин итәләр.

Киләчәк заман хикәя фигыльләр, күчерелмә мәгънәдә кулланганда башка вакыт аралыгын чагылдырып, йогынтылы яңгырыйлар. Киләчәк-үткән заман хикәя фигыле (барачак иде) киләчәктә буласы эшне хәзерге заманга күчерә, хәзерге мизгелдә, тиз үзгәрә һәм кабатлана торган күренешне тасвирлаганда кулланыла.

Катгый киләчәк заман хикәя фигыле (әйтәчәкмен, тыңлаячаклар) сөйләү мизгеленнән соң үтәләчәк эшне катгыйлык белән белдерә, чыгышларда үз сүзеңә ышанганлык, тыңлаучыларны инандыру чарасы булып яңгырый.

Билгесез киләчәк заман хикәя фигыле (барыр-бармас) йогынтылыгы ягыннан бик көчле түгел, тик хәзерге заман (кирәген әйтә белер, ярсымас) төсмерендә яңгырап (хәзерге киләчәк заман дип тә йөртелә) гомумиләштерү мәгънәсен бирә. Билгесез киләчәк

заман хикәя фигыле төгәл үз мәгънәсендә килеп тә эш-гамәл кылуга әзерлекне, бу гамәлнең үтәләчәгенә ышаныч төсмерен тудыра ала. Чыгышларда II затта берлек һәм күплек санда килгәндә билгесез киләчәк заман хикәя фигыль (җырларсың, кул чабып торырсыз) гамәл кылуга этәргеч, боерык мәгънәсендә дә яңгырый.

Эш-гамәлнең бер тапкыр гына үтәлү рәвешен, нәтиҗәсен уйлаганда килеп туган хәлне, аның чик-чамадан артып китүен, хәзерге мизгелдә әһәмиятен башка кеше сүзләренә сылтаулап сөйләү өчен категорик үткән заман (җырладым, исләре китте) һәм нәтиҗәле үткән заман хикәя фигыльләргә (чыгыш ясаганмын, хуплагансыз, әйткәннәр) мөрәҗәгать итү тыңлаучыларга нык тәэсир итә.

Өндәмә чыгышлардагы мөрәҗәгатьләрнең катгыйлыгын (боеруны) киметү – киңәш, йомшак боеру, сорау, үтенү төсмерендә яңгырату өчен, боерык фигыльгә –чы/-че кушымчасы, әле, инде кисәкчәләрен кушып сөйләргә кирәк. Бу очракта аралашучылар дустанә, ихласлык мөнәсәбәтендә булалар. Боерык фигыльнең үзен генә яңгырату чыгыш ясаучыны тыңлаучыларыннан өстенлеген күрсәтү чарасы булып, илтифатсыз яңгырый. Контекстта -са/-сә кушымчалы шарт фигыльләрне кисәкчәләр белән кулланганда боеруның төрле төсмерләренә ирешәбез, аралашудагы җылылыкны җуймый кала алабыз.

Икенче заттагы боерык фигыльләр (җырла) өченче заттагы боерык фигыльләр (җырласын) иде ярдәмче фигыле белән килеп (җырла идең; җырласын иде) төрле теләк төсмерен белдерәләр.

Икенче зат боерык фигыльләр белән (тыңла, фикерен бел), контекстка бәйле рәвештә, теләмичә үтәлгән эш-гамәлне дә хәбәр итеп була. Өченче зат боерык фигыльләр сөйләмгә бераз тантаналык өстиләр. Дәлилләүдә кире шарт мәгънәсен белдергән өченче зат боерык фигыльне кулланып, оппонентның игътибарын өстәмә мисалларга юнәлтеп, үз фикереңне ачыграк яңгыратырга була (сөйләсен, исбатласын; Яңа дәлилләр китерсә дә, үз фикеремдә калам).

Өндәмәләрдә, лозунгларда, газета мәкаләләре атамасында, төрле мөрәҗәгатьләрдә инфинитивны (татар телендә -ырга /-ергә, -арга/-әргә, -рга/-ргә кушымчасы белән ясала) куллану сөйләмнең үтемлеген арттыра. Стиль таләбенә җавап итеп инфинитивны боеручан тонда катгый теләк, тыю, әмер, эш-гамәлгә өндәү итеп яңгыратырга була. Инфинитив иде ярдәмче фигыле белән килгәндә

шарт фигыль мәгънәсенә ия була, көчле теләкне белдерә: җырларга иде! Шарт фигыльнең (җырласа иде) синонимик рәвешеннән аермалы буларак, инфинитивның әлеге төре (җырларга иде) гамәлнең үтәлешенә ышаныч, ә шарт фигыль төре гамәлнең ихтималлыгына ишарә генә булып кала.

Инфинитив ниндидер эш-гамәл кылуга көчле омтылышны чагылдыруы сәбәпле чыгыш текстында максатчан кулланыла. Сөйләмнең тойгылыгын арттыру максатыннан инфинитивны ымлыклар, модаль сүзләр белән куллану да (Их җырларга да, җырларга әле!) үзен аклый.

Эш-хәрәкәтне башка сүз төркемнәре белән дә тасвирлап була: тиңдәш исемнәр җисемнәрнең, күренешләрнең мизгел эчендә тиз алмашынуын күз алдына китереп бастыра, тасвирламаның тәэсирен арттыра. Исем фигыльләр ярдәмендә гамәлнең шушы мизгелдә көчәюен чагылдырырга, сөйләмдә төгәллеккә һәм сурәтлеккә ирешергә мөмкин. Тик фигыль сүз төркеменең заман, зат, наклонение (мөнәсәбәтлек) категорияләре генә эш-гамәл, хәрәкәтнең, тормыш вакыйгаларының үсеш дәрәҗәсен үтәлү рәвешен, эш-хәлнең чынбарлыкка мөнәсәбәтен төгәл аныклап киләләр, көчле стилистик чара булып торалар.

Шулай ук сыйфат сүз төркеменең стилистик йөген бәяләп бетергесез. Сөйләмнең хиссилеген, йогынты көчен арттыруда аларны урынлы куллану чыгыш ясаучыны үз эшенең остасы итеп таныта. Сыйфат сүз төркеме исемнәрне ачыклап, сәнгатьле текстта каһарманнарның тышкы кыяфәте, холык-фигыле, табигать күренешләре аша авторның (чыгышларда – чыгыш ясаучының) үз мөнәсәбәтен дә билгеләү чарасы. Чыгыш текстларында асыл сыйфатларның дәрәҗә категорияләрен файдалану сөйләмнең хиссилеген, мәгънәсен көчәйтеп җибәрә, тик чама хисен генә онытмаска туры килә. Чыгышларда әдәби калыплашкан билгеләр, тиңдәш аергычлардан саклану мөһим. Алар кирәкмәс яки өстәмә күзаллаулар җирлеге булып, тыңлаучыларны төп фикердән читләштерәләр. Цицерон да, юкка гына, "кирәклесен генә" сөйләргә кушмаган.

Чыгыш осталары да сан сүз төркеменең стилистик мөмкинлекләренә шикләнеп карыйлар, чөнки статистик мәгълүмат тыңлаучыларны ялыктыра. Тик урынлы кулланылган төгәл сан дәлилләү нигезе, хисси халәт җирлеге дә булып килә. Күчерелмә мәгънәдә кулланылып (тропларда: гипербола һәм литоталарда)

саннар сөйләмнең тәэсирлеген арттыралар. Микъдар саннары, төгәл күзалланырлык сурәтләр тудырырлык итеп чагыштырылганда алыштыргысыз мисаллар, бу очракта сөйләмдә үтемле яңгырыйлар. Микъдар саннары, антоним парлар оештырып, антитеза нигезенә салыналар: “Җиде кат үлчә, бер кат кис”.

Чыгыш текстларында рәвешләр, төп мәгънәләрендә кулланылып, эш-хәл билгесен яки билгенең билгесен белдерәләр, ачыктан-ачык белдерелгән яки ихтималланган мәгънәсенә төшендерәләр. Билге рәвешләре (тиз, еш, күп, урталай, искиткеч, җиңелчә, осталарча, дәлилдәй, нотыктай һ. б.) сөйләмнең хиссилеген оештыруда катнашалар, ә хәл рәвешләре (быел, һәрчак, бире, янәшә, юкка, бушка, юри, тиктомалга һ. б.) эш-хәлнең үтәлү вакыты, урыны, сәбәбе, максаты буенча ачыклаулары сәбәпле дәлилләү барышын җиңеләйтә алалар.

Сөйләмдә алмашлык сүз төркеменең стилистик мөмкинлекләре ныграк чагыла. Чыгышның язма текстында төгәллек, аныклык беренче таләпләрдән. Сөйләмдә исә аныклыкка без алдагы хәлләрне сөйләп тә, теманы, кирәкле сүзләрне кабатлап та, ым-ишарәләр ярдәмендә өстәмә мәгълүмат биреп тә ирешәбез. Алмашлыкларсыз бу очракта һич мөмкин түгел. Әлбәттә, сөйләмдә мәгънә төсмере интонациягә бәйле, шул сәбәпле алмашлыклар мәгънәви басым белән әйтеләләр дә. Алмашлыклар үзләре мәгънәви басымга ия булмасалар да, хәбәрнең әһәмиятле өлешен аерымлап, шул өлешне күрсәтеп киләләр. Язма текстта күрсәтү алмашлыклары (андый, мондый, әлеге), сыйфатларны алмаштырган (мондагы, шушындый, түбәндәгечә, алдагы, билгеле, күрсәтелгән, атап үтелгән) алмашлык сүзләр, билгесезлек алмашлыклары (кем дә булса, нәрсә дә булса, кайбер) кулланылса, сөйләмдә күрсәтү алмашлыклары (шундый, тегенди, шушы, алай, болай), билгесезлек алмашлыклары (кемдер, нәрсәдер, әллә нинди) һәм сорау алмашлыклары күбрәк кулланыла. Сәнгатьле текстларда зат алмашлыклары күп кулланыла, ә рәсми-эшлекле стильдә I, II зат берлек һәм күплек алмашлыклары сирәк күренеш. Чыгышларда зат алмашлыкларын куллану, бигрәк тә I заттан сөйләү ышанычлы мәгълүмат, ә аларны кабатлап тору мин-минлек булып кабул ителә. Чыгышта I заттан III затка күчеп сөйләү күренеше читтән күзәтү, читләтеп бәяләү була. Билгесезлек алмашлыкларыннан зат алмашлыкларына күчкәндә сөйләмнең тәэсире көчәя, тыңлаучыларның игътибары

арта. Күрсәтү алмашлыклары, очрагына карап, югары яки түбәнәйтелгән бәя төсмере белдерә алалар. Текст эчтәлегенә туры килгән күрсәтү алмашлыкларын бер-бер артлы куллану сөйләмнең әһәмиятле өлешләренә игътибар туплый.

Риторик сорауларда сорау алмашлыклары мәгънәви йөк үтиләр, юлара мәгънәдән яшерен инкяр сиземләнгәндә сорау җөмләләре бигрәк тә тәэсирле яңгырыйлар. Бу очракта сорау алмашлыклары кире җавапны алдан әзерләгән кебек, көчәйтелеп, икеләнергә урын калдырмыйча яңгырыйлар.

Чыгышларда зат һәм билгеләү алмашлыклары аныклык өстәсәләр, билгесезлек алмашлыклары кире вазифа үтиләр – сөйләнгән күренеш-вакыйгаларга якынчалык төсмере өстәп, хәбәрнең дөреслегенә шик тудыралар – димәк, сөйләмдә бәяләмә (күп вакыт тискәре мөнәсәбәт, илтифатсызлык) мәгънәсендә киләләр. Дәлилләү барышында каршы як фикерен китереп, аны кире кагуда, оппонентның тезисларын (әлбәттә, алар ялган булсалар) тәнкыйтьләгәндә (юкка чыгарганда) билгесезлек алмашлыкларының еш кулланылуы максатка яраклы була.

## Коръән аятьләренең татарча мәгънәләре теленә лингвистик күзәтү

### *Аятьләрнең туры һәм күчерелмә мәгънәләре*

Предметлар һәм күренешләр арасындагы охшашлыкны төгәл күреп ала белү гарәп телендә югары бәяләнә, чөнки бу телнең үткен чагыштырулар һәм тәэсирле метафоралар *(бәлага)* белән тулы 20 миллионлап сүз байлыгын исәпләп башкарыла. Ләкин дин кануннарын эченә алган изге текст өчен, аныклык, тышкы бизәкләр белән хиссилеккә ирешүгә караганда, күпкә әһәмиятлерәк. Шуңа да галим-голамәләр арасында Коръән сүзләрен күчерелмә мәгънәдә тәфсирләү буенча уртак фикер булмаган. Баштагы тәфсирчеләр, үз хезмәтләрендә риваятьләргә һәм сүзләргә лексик-семантик анализ ясауга гына таянып, бу мәсьәләгә артык игътибар итмәгәннәр. Ләкин IX гасырның беренче яртысында ук инде, тәфсирдә сүзләрнең күчерелмә мәгънәсенә мөрәҗәгать итү урынлы куллану юнәлешенә нигез итеп алына башлый.

Аллаһның сыйфатларын антропоморфизм (гади кеше сыйфатлары) аша аңлаудан шикләнеп, мүгтәзилитләр Аллаһның сыйфатлары һәм гамәлләре искә алынган аятьләрнең туры мәгънәләрен танымаганнар. Мәсәлән, “җиңелү белмәс кодрәт иясе,

олуг Аллаһ” тәгъбирен (“Рахмән (Рәхимле)” сүрәсенең 27 нче аяте) һәм “үз кодрәтем белән барлыкка китергәнгә сәҗдә итү” тәгъбирен («Сад (Даут)» сүрәсенең 75 нче аяте), алар Аллаһның илаһи асылы һәм кодрәтенә карый дип аңлатканнар. Мүгтәзилитләрнең төп оппонентлары Аллаһның сыйфатларын рациональ акылга нигезләнеп аңлату мөмкинлеген инкяр итү юнәлеше тарафдарлары *(әһл әл-хәдис)* булган. Нәтиҗәдә, сүзләрнең туры *(хакыйка)* һәм күчерелмә *(мәҗәз)* мәгънәләре дини бәхәсләр җирлегенә әйләнә. Ул бәхәсләрдә һәр як та Аллаһның сыйфатлары изге икәнлеген үзенчә аңлатырга тырыша.

Гарәп телендә *мәҗәзның* булуы күп филологлар, шул исәптән әл-Җурҗани (1078 елда вафат), Ибне Җинни (1002 елда вафат), әс-Саккакый 1338 елда вафат) тарафыннан танылa. *Хакыйка* дип – тулаем текстта нинди дә булса сүзнең кабул ителгән лексик мәгънәсенә туры китереп (шул сәбәпле сүзне ялгыш куллану очраклары һәм сүзнең таралыш алмаган мәгънәләре кулланылмый) файдалануга әйтәләр. *Мәҗәз*ны галим әл-Казвини ике төргә бүлә. Беренчесенә ул сүзләрне бирелгән текстта куллану гадәти булмаган очракларны (мәсәлән, зәкят сүзен дини-хокукый язмаларда «үсеш» мәгънәсендә куллану) кертә. Икенче төре – сүзне туры мәгънәсендә түгел, ә күчерелмә мәгънәдә куллану, мәсәлән, кыю, батыр сугышчыны – «арыслан» дип атау.

‘Абд әл-Җурҗани (гарәп риторикасының атасы) фикеренчә, *хакыйка* – сүзне телдә ныгып калган бер лексик мәгънәсендә куллану, ә *мәҗәз* – бер предметның (күренешнең, сыйфатның, хәрәкәтнең) аталышын алар арасында булган охшашлык аркасында икенчесенә күчерү (икенче төрле әйтсәк: метафора). Лексик мәгънә төшенчәсендә сүзнең контекстка бәйле булмаган үз мәгънә эчтәлеге күзаллана. Әгәр дә тулаем текстта сүзне лексик мәгънәсендә кулланып була икән, аны шул текстта күчерелмә мәгънәдә куллану бары тик контекстуаль алшартлар (*карā’ин*) булганда гына мөмкин.

Сүзләрне күчерелмә мәгънәдә куллану аларның төп мәгънәсен инкяр итә, мәсәлән, “Мин дошманнары белән сугышучы арысланны күрдем. Юк, ул арыслан түгел иде, ул батыр мөселман сугышчысы иде”. Башка сүзләр белән әйткәндә, *мәҗәзны* кире кагарга була, шуңа да кайбер галимнәр *мәҗәз* барлыгын инкяр иткәннәр. Шулар арасында заһиритлар мәзһәбенә нигез салучы Давыд бине ‘Али (883 елны вафат), мүгтәзилит тәфсирчесе Әбу

Мөслим әл-Исфахани (934 елны вафат), шәфигый мәзһәбе белгече Бине әл-Касс ат-Табари (946 елны вафат) һ. б. Алар Коръәндә формаль яктан булса да кире кагылырлык раслауларның булуы мөмкин түгел дип исәпләгәннәр. Нәтиҗәдә, Коръәннең бар мәгънәсе *хакыйка* категориясенә карый, һәм сөйләнгән әйбер турында хәбәрдар кешенең башына иң беренче нинди уй килә, шуннан оеша. Мәсәлән, "гаделсез шәһәр" гыйбарәсендә ("Һуд" сүрәсенең 102 нче аяте) ул шәһәрдә яшәүче кешеләрнең азгынлыгы турында сүз бара. "Аллаһка буйсынып, *(Аның диненә, Аның пәйгамбәре китергән Исламга)* ярдәм итсәгез" гыйбарәсе ("Мөхәммәд" сүрәсенең 7 нче аяте) бернинди дә аңлашылмаучанлык тудырмый, чөнки, Исламны белгән кешегә бу очракта Аллаһның диненә ярдәм бирү турында сүз баруы аермачык чагыла. Мондый фикерләр Коръән мәгънәсе турында уйланган кешенең башына беренчеләрдән булып килә, шуңа күрә дә, монда мәгънә күчеше юк.

Телдәге исемнәрнең алдан билгеләнгәнлеге турында сүз куерту күпләр тарафыннан гарәп телендә *мәҗазның* булуын инкяр итүгә дә китергән. Билгеле филолог Әбу 'Али әл-Фариси (987 елда вафат), дин белгечләре Әбу Исхак әл-Исфарайини (1027 елда вафат), Бине Таймиййа (1327 елда вафат), Бине әл-Каййим (1350 елда вафат) һ. б. шундый фикердә булганнар. Алар һәр сүз яки тәгъбир бирелгән контекст кысаларында аңа ритор тарафыннан нинди мәгънә салынган, шул мәгънәгә ия дип исәпләгәннәр. Нәтиҗәдә, сүзләр һәм тәгъбирләр мәгънәгә аерым-аерым торганда түгел, ә бары тик үзләре кулланылган контекстта гына булып чыга. Тел белгече А.Игнатенко бу идеяне "тәгъбирләр мәгънәсенең шәхси һәм тулаем тексттагы концепциясе» дип атый. Хәзерге философиядә ул (Кембридж университеты профессоры Людвиг Витгенштейн) (1951 елда вафат була) табигый телләрдә мәгънә плюральлеге концепциясенә якын.

Шуңа да карамастан, күп кенә тәфсирчеләр, *мәҗаз* Коръән текстларының аныклыклыгын югалтмый, ә аның аңлаешлылыгын, күркәмлеген, кабатланмаслыгын ассызыклый дип исәплиләр. Бу проблемага Әбу 'Убайда ат-Тайми, әш-Шәриф әр-Ради (1015 елда вафат), Бине 'Абд әс-Сәлам (1262 елда вафат) үзләренең махсус хезмәтләрен багышлыйлар. Әз-Зәркәшинең сүзләренә карагаганда, *мәҗазне* төшереп калдыру тексттагы язмаларның камиллегенең яртысын югалтуга китерер иде. Ул Коръәндә күчерелмә мәгънә

кулланунын ике рәвешен аерып күрсәтә: логик *(мәҗаз ‘акли)* формасын һәм лексик-семантик *(мәҗаз лугави)* формасын.

**Логик күчерелмәләр** – бер зат башкарган гамәлне (предметны, күренешне) икенче затка (предметка, күренешкә) күчерү. Андый *мәҗазга* Коръәндә мисаллар күп: «халкын фиркаларга аерып бетерде; аларның бер өлешен изеп, зәгыйфьләндерде, аларның *(яһүдләрнең)* угылларын суеп, кыз балаларын гына калдыра башлады» (“Касас (Кыйссалар)” сүрәсенең 4 нче аяте), «аларның киемнәрен салдырып» (“Әгъраф (Пәрдә, калкулык)” сүрәсенең 27 нче аяте). Беренче аятьтә сүз Фиргавен турында бара, ул үзе эшләмәгән, ә аның фәрманы буенча аның сугышчылары кылган гамәлләр аңа күчерелеп языла. Моны шулай итеп аңларга кирәк: “Фиргавен фәрманы белән ир балаларын үтертеп, хатын-кызларын исән калдыртып, Исраил халкын көчсезләндерде”. Икенче аятьтә Иблис Адәм һәм аның хатынының киемнәрен салдырды дип хәбәр ителә. Ә чынлыкта ул моңа сәбәп кенә була, гамәлне Аллаһ Үзе башкара.

**Лексик-синтаксик күчерелмәләр** – сүзнең төп мәгънәсен күчерелмә мәгънәдә куллану була. Әз-Зәркәши андый *мәҗазларның* Коръәннән алынган мисаллар белән кырыкка якынын аерып күрсәтә, аларның кайберләренә тукталып үтик:

а) бербөтеннең атамасын аның өлешенә күчерү яки киресенчә. Мәсәлән, “бармаклары белән колакларын томаларлар” аятендә (“Бәкара (Сыер)” сүрәсенең 19 нчы аяте *асāби‘* (бармаклар) сүзе астында бербөтеннең өлеше, ягъни, бармак очлары күз алдында тотыла. “Йөзеңне Мәсҗид-и Харам *(Кәгъбәтулла)* тарафына юнәлт!” аятендә (“Бәкара (Сыер) сүрәсенең 144 нче аяте) *ваджх* (йөз) сүзе астында кешенең тулаем гәүдәсе күзаллана;

б) гомуминең атамасын аның өлешен белдергән кисәгенә күчерү яки киресенчә. Беренче очрак аятендә («[фәрештәләр] җирдәгеләр өчен ярлыкау сорарлар” (“Шура (Киңәш)” сүрәсенең 5 нче аяте) бар. Бу очракта җирдәгеләр дигән вакытта бары тик мөэминнәр генә күз алдында тотыла. Әлеге төр *мәҗазның* кире рәвешендәгесен без «пәйгамбәрләр булабыз» сүзләрендә (“Шөгарә (Шагыйрьләр)” сүрәсенең 16 нчы аяте) очратабыз, анда *рәсүл* (илче) сүзе берничә кешегә карата кулланыла;

в) урын атамасы анда булган әйбергә күчерелүе яки киресенчә. Мәсәлән, “Әл-Гыймран” сүрәсенең 107 нче аятендә – “Йөзләре ак булганнар исә Аллаһның рәхмәтенә юлыгачаклар. Алар шул

рәвешчә анда *(җәннәттә)* дәвамлы калачаклар” – Аллаһ рәхмәтенең төп урыны җәннәт турында сүз бара. “Галәк (Яралгы тамчысы)” сүрәсенең 17 нче аяте: “... үзенең якыннарын ярдәмгә чакырсын”), *нāди* (төркем) сүзендә, анда булган кешеләр, аның ярдәмчеләре күз алдында тотыла;

г) затның яки предметның элекке яки киләчәктә булачак атамасын куллану, мәсәлән: (“Хатынын аергач һәм хатынның гыйддәте үтсә, алга таба хатыны белән кушылып шәригатьчә яшәргә теләсәләр, аларның яңадан никахлашуына комачауламагыз” (“Бәкара (Сыер)” сүрәсенең 232 нче аяте) яки: (“Мин төшемдә шәраб ясаганымны күрдем” (“Йосыф” сүрәсенең 36 нчы аяте). Беренче аятьтә элеккеге ирләре белән никах яңарту турында, ә икенче аятьтә – киләчәктә хәмергә әйләнәчәк йөзем суын сыгу турында сүз бара;

д) предмет (билге, хәрәкәт) атамасын аңа капма-каршы предметка (билгесенә, хәрәкәтенә) күчерү. Мәсәлән, “Иншикак (Ертылу) сүрәсенең 24 нче аятендә – “Син аларны хәтәр җәза бирүче газаплар белән кисәтеп, куркытып тор” – *башшара* (сөендер) фигыле “көендер” мәгънәсендә кулланыла. Ә “Әгъраф (Пәрдә, калкулык)” сүрәсенең 12 нче аятендә – “Мин сиңа кушканнан (сәҗдә итүдән) баш тартырга ни сәбәп булды?”, без “комачаулау” фигыленең гадәти булмаган кулланылу ысулын, аның “этәрде, мәҗбүр итте, тыйды” мәгънәсендә кулланылуын күрәбез.

е) җөмлә өлешләренең, шул исәптән тиңдәш кисәкле өлешләренең дә, үзара урыннарын алыштыру. Мәсәлән, “Барлык нәрсәнең вакыты”, (“Рәгыд (Күк күкрәү)” сүрәсе, 38 нче аять), “аларның ачкычларын күтәрмәк берничә куәт иясенә дә авырлык китергән булыр иде” (“Касас (Хикәя)” сүрәсе, 76 аять, “Мөхәммәд г-мгә якынлашты һәм җиргә төште” (“Нәҗем (Йолдыз)” сүрәсе, 8 нче аять), “[хатыны] көлде, сөенеч хәбәр бирдек” (“Һуд” сүрәсе, 71 аять) сүрәләрендә җөмләнең тиңдәш өлешләренең урыннарын алыштыру кулланылган. Билгеле, фәрештә башта югарыдан җиргә төшкән, аннан соң гына Мөхәммәдкә якынлашкан. Шулай ук, Ибраһимның хатыны да башта сөенечле хәбәр ишеткән, аннан соң гына көлгән.

*Маҗазның* бу төренә бер морфологик конструкция урынына икенчесен куллану очракларын да кертәләр, мәсәлән, төшем юнәлешле сыйфат фигыль (*исм маф‘ул)* урынына үтем юнәлеш

сыйфат фигыль (*исм фā‘ил*) куллану һәм киресенчә. (“ятакка коелган судан”, “Тарыйк (Йолдыз)” сүрәсе, 6нчы аять) тәгъбирендә *дāфик* сүзе *мадфук* мәгънәсендә кулланыла. Ә “кешеләр күзенә күренми торган пәрдә” (“Бәнү Исраил (Ягъкуб балалары)» сүрәсе, 45нче аять) тәгъбирендә *мастур* сүзе *сāтир* мәгънәсендә файдаланыла. Алда әйтеп үтелгәнчә, гарәп грамматикасы өчен андый күчешләр гадәти.

Бер үк сүз яки тәгъбир берьюлы туры һәм күчмә мәгънәләрендә кулланыла алмый дип исәпләнелә. Элеккедә кабул ителгән сөнни тәфсирендә Коръән һәм Сөннәттә ныклы дәлилләр булганда, туры мәгънә куллану мөмкин булмаган вакытта гына, күчерелмә мәгънәгә мөрәҗәгать ителә. *Кәләмнең* төрле мәзһәб тарафдарлары, Аллаһның сыйфатларын төгәл аңлату өчен, *мәҗазны* куллану даирәсен киңәйтәләр. Батинилар тәфсирләрендә мәҗаз иң югары әһәмияткә ия, алар һәрбер сүрәдә дә диярлек ниндидер яшерен мәгънә бар диләр.

### ***Коръәндә лексик чагылдыру чаралары***

Борынгы заманнардан ук башкалар сизә-тоемлый алмаганны күрә белүчеләргә, сөйләмдә гадәти булмаган тасвирлау чараларын уйлап табучыларга кешеләр сокланып караганнар. Аеруча көчле һәм истә кала торган әйтелмәләр, күп очракта, бер сүзнең мәгънәсен икенче сүзгә күчергән вакытта барлыкка килә.

Төрки халыкларның уртак шагыйре бөек Низами үзенең бер әсәрендә кабатланмас тел-сурәт чараларын кулланган (шигъри юлларга салынмаган тәрҗемә):

Мин – төн уртасындагы аймын, ләкин тапларны белми торган.

Мин – энҗемен Аллаһ мине кимчелекләр белән кәһәрләмәгән.

Авырсаң, бальзам эчмә син, минем бәетләрем шифалырак бит,

Минем сүзләр, нәкъ татлы финик кебек, бар мактаулардан да өстенрәк.

Минем күңел капкачларымда васыять уеп язылган:

«Мин әйткәннән соң телмәрләр бүтән яңгырамаячак”.

Минем тыным – океан, андагы су төшү-күтәрелешләре.

Сулыш алды – чумучы төпкә чумды, сулышын чыгарды – диңгез төбеннән тапты энҗе.

Кабартылган беләзекләр кебек шалтырый минем мактануым,

Мин ничек тәүбә итәм, оялам чамасыз мактаулардан мин.

Хәйләкәр фокусчы да түгелмен мин, алдап аллага табынучы да;

Күзләремә суган да сөртмәдем мин, тапламадым зәгъфран белән яңакларымны да.

Ходаем! ярдәм ит миңа, гади кешеләрдән аны көтмәс өчен,

Якла мине үзең, байлардан аны эзләп йөрмәс өчен.

Барыбыз да без – мизгелдәгеләр генә, үлем тамгасы салынган безнең барыбызга да.

Син – зарури барлык син, булачаксың, булгансың. Бар.

Әбу әл-Мәжд Сана’и (1150 еллар тирәсендә вафат), Әүхәд әд-Дин Әнвәри (1189 елны вафат), Фәрид әд-Дин ‘Аттар (1221 елны вафат), Җәләл әд-Дин Руми (1273 елны вафат) – алар барысы да Коръәннән илһам җыйганнар, аларның үлемсез газәлләрендә Коръән аятьләренә күпсанлы аллюзияләр (ниндидер әдәби, тарихи, мифологик фактка анык ишарә яки ачык күрсәтмәләр булган стилистик фигуралар) бар.

Предметлар һәм күренешләр турында образлы күзаллаулар тудыра торган күчерелмә мәгънәдә кулланыла торган сүзләр, сүзтезмәләр, әйтем-әйтелмәләр һәм сүз әйләнмәләре – **риторикада троплар** дип аталалар. Алар сөйләмнең сурәтлелеген, тәэсирлелеген арттыру, аңа аһәңлек һәм хиссилек сыйфатларын бирү өчен кулланылалар. Коръән текстында тропларның берничә төрен күрергә була: эпитетлар, метафоралар, метонимияләр һ. б.

**Эпитет** – ниндидер предметның яки күренешнең яшерен чагыштыруны эченә алган образлы характеристикасы. Тропларның бу төре предметның теге яки бу үзенчәлеген ассызыклый, кешегә нык тәэсир итә торган күрмә образ тудыра. Эпитетларны без, мәсәлән, җәннәт савытларын тасвирлаган вакытта, (“көмешләнгән бәллүрдәндер”, “Инсан (Кеше) сүрәсе, 16 нчы аять) очратабыз. Бу көмеш шулкадәр пакъ һәм үтә күренмәле, чынлап та бәллүр кебек күренә. Башка эпитетта «энҗе йолдыз» (“Нур” сүрәсе, 35 нче аять) йолдызның балкуы энҗе белән чагыштырыла.

**Чагыштыру** – гомуми билгеләре булган ике предметны, төшенчәне, хәл-торышны үзара тәңгәлләштерүгә корылган образлы әйтелмә. Тропларның бу төре Коръәндә предмет яки күренешнең аеруча әһәмиятле үзенчәлеген күрсәтү өчен еш кулланыла. Мисалга, Коръән, гөнаһлыларның үгетләүләрдән качуын арысланнан качучы ишәкләр гамәленә тиңли (“Мүдәссир (Бөркәнүче)” сүрәсе, 49-51 нче аятьләр), ә имансызларның борчылуларын биек тауларга менгәч күкрәк кысылуы белән (“Әнгам (Терлек)” сүрәсе, 125 нче аять). Уйлап чыгарылганнарга,

сыннарга, потларга табынучыларның буш өметләре пәрәвез тотрыксызлыгы белән чагыштырыла (“Ганкәбут (Үрмәкүч)” сүрәсе, 41 нче аять). Соңгы ике мисалда абстракт төшенчәләр чынбарлыктагы образлар белән чагыштырылалар, ә беренче ике мисалда – чынбарлыктагы ике матди образ үзара чагыштырыла.

Чагыштыру үзенең мәгънәсе белән гарәп риторикасындагы *тәшбиһка* якын. Синтаксис конструкциясе үзенчәлекләренә карап бу лексик чара ике төргә бүленә: *мурсал* һәм *му'аккад.* Беренче төренә (мурсал) чагыштыруны аңлаткан сүзләр һәм кисәкчәләр белән оеша торган туры чагыштырулар керә, мәсәлән: «Аның җимешләре гүя шайтан башларыдыр” (“Саффат (сафта торучылар)” сүрәсе, 65 нче аять) Әгәр дә *тәшбиһта* чагыштыруны аңлаткан сүзләр яки кисәкчәләр булмаса, ул *му'аккад* дип атала: “ә аның хатынннары – аларның аналары” (“Әхзаб (Гаскәрләр)” сүрәсе, 6 нчы аять); «сургучы – мускустыр” (“Мүтәффифин (Кимерүчеләр)” сүрәсе, 26 нчы аять). Мондый алымнар күпкә тәэсирлерәк һәм, предмет һәм күренешләрнең күп яклап ошашлыкларын күз алдында тоталар.

**Метафора** — сүзнең ошашлыкка, тиңдәшлеккә (аналогия) яки турыдан-туры әйтелмәгән чагыштыруга нигезләнеп, күчерелмә мәгънәдә кулланылуы. Күпчелек метафораларда сүзнең күчерелмә мәгънәсе алгы планга куела һәм аның төп мәгънәсе гыйбарәгә үзенчәлекле бер хисси халәт төсмере өсти. Мисал өчен: “башым ак чәчләр белән тулды” («Мәрьям» сүрәсе, 4 нче аять) тәгъбирен алыйк. Никадәр тәэсир көче бу кыска метафорада! Тыңлаучыда ул куе чәчләре баш кырыеннан чалара башлаган һәм башын чал чәчләре балкышы каплап алган, зур хөрмәткә лаек карт кеше образын барлыкка китерә. Бу тәгъбир һәм башындагы чалы янып тора иде” гыйбарәләре арасында аерма нинди зур. Моны “өйдә ут яна башлады” һәм “өй уттан яна башлады” тәгъбирләрен чагыштырып аңларга була. Әгәр дә беренче фразаны өй эчендә ут кабызганнар дип күз алдына китереп булса, икенчесе, аңлашылганча, өй тулаем ут белән камап алынган иде – янгын – мәгънәсен бирә.

Мәккә мөшрикләренең хәле тасвирланган башка бер мисалны карыйк: «Аллаһ аларга ачлык һәм курку киеме бирде” (“Нәхел (Умарта кортлары)” сүрәсе, 112 нче аять). Бу метафора нигезендә *либāс* “кием” сүзен куллану күчерелмә мәгънәдә, ул мәккәлеләрнең хәлләре авырлыгын чагылдыра. Ачлык аларга физик газаплар

китерә, ә курку исә, аннан һич тә ким булмаган рухи газапларга дучар итә. Һәм бу аларның тышкы кыяфәтендә дә чагыла. Бу метафораның тәэсирлеге һәм киң мәгънәлеге шулай ук күчерелмә мәгънәдә булган *azāka* (түмен татырга бирергә) фигылен куллану белән тагын да көчәя төшә.

**Җанландыру** – җансыз предметларны кеше хисләре, сөйләме, шөгыль-фигыленә ия кебек итеп тасвирлау. Мәсәлән, «ул тын ала башлагач, таң белән ант итәмен” (“Тәквир (Чорналу)” сүрәсе, 18 нче аять) дигәндә *танаффаса* (“тын алырга”) фигыле кулланылган. Бу сүзләрдә безнең әйләнә-тирә дөньябыз үзгәрә һәм җанлана. Төнлә ул әйтерсең лә, сулыш алуын беразга туктатып тора, ә иртәнге таң нуры белән җанлана башлый. Һәр мизгел саен, кояш нуры җирнең иң ерак почмакларына үтеп кергәнче, күбрәк һәм күкрәк кебегрәк сулый. Тәфсирчеләр еш кына җанландыруны туры мәгънәсендә аңлаталар. Ул җансыз табигатьне башкача, үзенчәлекле күзаллау белән аңлата: «Аллаһны мактап тәсбих әйтмәгән нәрсә юк, ләкин сез аларның тәсбихләрен аңламыйсыз” (“Бәни Исраил (Ягъкуб балалары)» сүрәсе, 44 нче аять). Җанландыруны еш кына метафораның бер төренә кертәләр, һәм гарәп риторикасында бу ике троп уртак – *исти‘āра* исеме астында берләштерелә.

**Метонимия** – мәгънәләре чиктәш булуга бәйле бер сүзне икенчесе белән алыштыру. Бу чара җир-су, вакыт аралыгы һәм сәбәп бәйләнешләренә мөнәсәбәттә билгеләнергә мөмкин. Метонимиянең метафорадан төп аермасы шунда: сүзләрнең лексик һәм күчерелмә мәгънәләренең чынбарлыкта үзара бәйләнештә булмавында. Үзара җир-су аралыгы мөнәсәбәте аша бәйле метонимиягә *kарйа* (“шәһәр”, “Йосыф” сүрәсе, 82 нче аять) сүзенең “шәһәр кешеләре” мәгънәсендә кулланылуы мисал булып тора. (“Без сезгә киемнәр яраттык”, “Әгъраф (Пәрдә, калкулык)” сүрәсе, 26 нчы аять) аятендә яңгыр җибәрү турында сүз бара. Яңгырдан башка тукыма, кием әзерләр өчен кирәк булган үләннәр дә үсми, мал да ишәйми. Бу очракта, чиктәш төшенчәләр сәбәп бәйләнешендә тоташтырылган.

**Синекдоханың** алда әйтелгән троплар белән охшашлыгы зур. Бербөтеннең өлеш яки киресенчә өлешнең бербөтен атамасына нигезләнгән әйтелмә синекдоха дип атала. Мәсәлән, *ракаба* “муен” сүзе“ “кол, әсир” мәгънәсендә кулланыла (“Ниса (Хатыннар)” сүрәсе, 92 нче аять). Икенче бер аятьтә Кәгъбә (“Маидә (Аш

яулыгы)” сүрәсе, 95 нче аять) сүзеннән тулаем әл-Хәрам мәчете күзаллана. Бу мисалларда бербөтен бары тик күзаллана, ә тыңлаучының игътибары аның иң үзенчәлекле, әһәмиятле өлешенә юнәлдерелә. Кайбер очракларда синекдоха тупас, колакка ятышсыз сүзләрне алыштырыр өчен кулланыла. Мәсәлән, җенси якынлык кылу *рафас̱* (“оятсыз сүз”, “Бәкара (Сыер)” сүрәсе, 197 нче аять), *дух̱ул* (“керү”, “Ән-Ниса (Хатыннар)” сүрәсе, 23 нче аять), *мубāшара* (“орыну”, “Бәкара (Сыер)” сүрәсе, 187 нче аять) сүзләрен кулланып әйтелә.

**Перифраза** – сөйләмне бизәкләү һәм предметның үзенчәлекләрен аерып күрсәтү максатыннан, туры атаманы тасвирлама тәгъбир белән алыштыру. Мәсәлән, “бер кешедән” (“Ниса (Хатыннар)” сүрәсе, 1 нче аять), “ирләрегезнең берсе”ннән (“Әхзаб (Гаскәрләр)” сүрәсе, 40 нчы аять) тәгъбирләрендә Адәм галәйһиәссәлам белән сәхабәләрдән Зәйд бине Харис күз алдында тотыла. Мәккәне “шәһәрләр анасы” (“Әнгам (Терлек)” сүрәсе, 92 нче аять) дип атау да перифраза булып тора. Тәфсирчеләр бу атаманы Җир йөзендәге иң борынгы гыйбадәтханә – Кәгъбәнең анда булуы белән дә аңлаталар.

Перифраза, метонимия, һәм синедохаларның югарыда китерелгән мисаллары гарәп риторикасында *кинāйа* төшенчәсе белән берләштерелә.

**Парадокс** – гомум кабул ителгән фикерләү кысаларына туры килмәгән, гадәти булмаган, көтелмәгән чара. Мондый тропта беренче карашка бер-берсенә каршы торган кебек күренгән төшенчәләр берләшәләр, һәм килеп туган капма-каршылык фонында тасвирлана торган күренеш, вакыйганың асылы нык тәэсирчәнлеге белән ачыклана. Мәсәлән, гөнаһлының җәһәннәмдәге хәлен тасвирлап, Коръән: (“ул җәһәннәмдә үлмәс, һәм тере булмас”, “Әгълә (Бөек)” сүрәсе, 13 нче аять). Икенче мисал – яһүдләрнең Мөхәммәд Пәйгамбәргә (аңа Аллаһның хәер догасы һәм сәламе булсын!) мөрәҗәгать иткән сүзләре: («Ишетергә ярамаган сүзләрне ишет”, “Ниса (Хатыннар)” сүрәсе, 46 нчы аять). Фикер йөртүнең гадәти булмавы тропның мәгънәсе турында уйланырга мәҗбүр итә, ә анда яшеренгән үткер фикерләр тәҗрибәле риторларны да таңга калдыра.

Теологик күзлектән караганда, Коръәндә **гипербола** һәм **литоталар** (предметның үзлеген, аңлы рәвештә чамасыз арттыру яки киметүгә нигезләнгән троплар) юк, чөнки Коръәндәге бөтен

чагыштырулар дөрес һәм төгәл. Шул ук вакытта, кайбер бик оста чагыштырулар һәм тәгъбирләр сүз сәнгате әсәрләрендәге гипербола кебек күренәләр: (“атар биналар кеби зур очкыннарны”, “Мүрсиләт (Җибәрелмеш)” сүрәсе, 32 нче аять), (“күкләр ярылырга якын булды вә җир ярылырга һәм таулар җимерелеп төшәргә якын калдылар. Аллаһның баласы бар, дип дәгъвә иткәннәре өчен”, “Мәрьям” сүрәсе, 90-91 нче аятьләр).

Коръәндәге без карап үткән сурәтләү чаралары сүзләрнең мәгънә эчтәлеген үзгәртү юлы белән төзеләләр. Бу очракта көтелмәгәнчә тәэсирле мәгънә эчтәлекләре оешып, аятьләрнең сәнгати кыйммәтен һәм аларның аудиториягә хисси йогынтысын арттыра төшәләр. Гарәп язмаларында андый синтаксик ысуллар өч төркемгә берләштерелә: *ташбих*, *исти‘āра* и *кинāйа*. Аларның мәгънәсенә экспликация эшләү зур катлаулылык тудырмый һәм Коръән текстының да аныклыгын киметми. Киресенчә, метафора һәм чагыштырулар аша тудырылган күрмә образлар абстракт төшенчәләрне чынбарлыкка якынайта һәм теге яки бу күренеш тасвирын тулырак итә. Ә хәзер без фразаны үзенчәлекле оештыруга нигезләнгән сурәтләү чараларын тикшерүгә күчәбез.

***Коръәндә синтаксик чаралар.***

Сүзләр бәйләнешенең гадәти тәртибе сакланмауга нигезләнеп, үзгә бер ысул белән төзелгән синтаксик төзелмәләр **риторик (стилистик) фигуралар** дип аталып йөртеләләр. Фәнни әдәбиятта бу төшенчәне троплар белән тиңләштереп карыйлар. Риторик фигуралар белән троплар арасында анык чикләр куярга кирәк. Әгәр дә тропларның сәнгати кыйммәте сүз мәгънәсен күчерү исәбенә ирешелгән образлылык белән билгеләнсә, риторик фигуралар исә – нигезендә гадәти булмаган, ләкин телдә чагылыш тапкан синтаксик төзелмәдән оеша торган сөйләм оештыру ысулы. Коръәндә очраган риторик фигураларның күп төрле булуына карамастан, аларны төп дүрт төркемгә бүлеп күзәтергә була: өстәү фигуралары, киметү фигуралары, урнаштыру фигуралары, фикри фигуралар.

**Өстәү фигуралары** сүзләрне, сүзтезмәләрне һәм синтаксик төзелмәләрне кабатлау юлы белән төзеләләр. Гарәп риторикасында тәгъбиргә, өстәмә мәгънә йөкләү зарурлыгы булмаганда, сүзләрне кабатлау кабул ителмәгән. Кабатлаулар кабатлана торган өлешнең әһәмиятен арттыралар, аның мөһимлеген тоемларга ярдәм итәләр. Еш кына кабатлана торган

сүз яки тәгъбир төп сүз дә була, мәсәлән: (“Өйләрегезгә арткы яктан керүегез изгелек түгел, ләкин изгелек, Аллаһка гөнаһлы булудан сакланудыр”, “Бакара (Сыер)” сүрәсе, 189 нчы аять. Монда *бирр* “изгелек” сүзе ике тапкыр кабатлана, аять тулаем шул төшенчәне аңлатуга багышланган.

Кабатлануга корылган, еш очрый торган фигураларга репризалар, анафоралар, эпифоралар керә.

**Реприза** – язмада башта килгән сүзнең төгәл яки үзгәртелгән рәвештә ахырга таба да кабатлануы, мәсәлән: (Безләрне туры юлга күндер! Ул юлны Син әүвәлгеләргә ингам итеп бирдең, безләрне Синең ачуың төшкән вә адашкан кешеләрне бидгать һәм заләләт юлыннан башка юлга күндер, ягъни Сине ачуландырмаган һәм хак юлдан адашмаган кешеләр юлына күндер!”, “Фатиха” сүрәсе, 6-7 нче аятьләр).

**Анафора** – берүк сүз, сүзтезмәләрнең, ритмик яки синтаксик төзелмәләрнең чиктәш яки бер-беренә якын урнашкан фразалар алдында кабатлануы, мәсәлән: «Сәдакаларыгызны ачык итеп бирмәгез, яхшы булыр. Сәдакаларыгызны фәкыйрьләргә яшертен бирсәгез, сезнең өчен тагын да хәерлерәк булыр. Шуңа күрә, *(Аллаһ)* гөнаһларыгызның бер өлешен ярлыкар. Сез ни генә эшләсәгез дә, Аллаһ барысыннан да хәбәрдар» («Бәкара (Сыер) сүрәсенең 271 нче аяте»); исем һәм фигыльләр генә түгел, *башка сүз төркемнәре* дә кабатланырга мөмкин: (“Кайчан кояшның нуры китәрелсә, чорналса (караңгылык белән). Кайчан йолдызлар җиргә коелсалар. Кайчан таулар урыннарыннан кузгалсалар”, “Тәквир (Чорналу)” сүрәсе, 1-3 нче аятьләр). Әгәр дә беренче очракта параллель төзелмәләрдә мәгънәви басым кабатланган өлешләрдә булса, соңгысында иярчен җөмләнең мәгънәви үзәген тәшкил иткән сүзгә бирелә. (Тагын к.: «Бәкара (Сыер) сүрәсенең 194 нче аяте».)

Анафора да, эпифора да бергә килә торган очраклар да бар: «Кайсы яктан гына сәфәргә чыксаң да, *(намаз укыганда)* син йөзеңне Мәсҗид-и Харам тарафына тот. Шөбһәсез, бу – Аллаһтан килгән хакыйкый әмер. Аллаһ ни кылганнарыгыздан хәбәрсез калмас. Кайсы яктан гына сәфәр чыксаң да, *(намаз укыганда)* син йөзеңне Мәсҗид-и Харам тарафына тот. Кайда гына булсагыз да йөзегезне шул якка борыгыз, кешеләр сезне хата эшләүдә гаепли алмасын. Алардан курыкмагыз. Бары тик Миннән *(җәзамнан)* куркыгыз. Шулай булганда, Мин мәрхәмәтемне тәмамлап, сезгә

тапшырырмын, бәлки сез тугры юлга басарсыз» («Бәкара (Сыер) сүрәсенең 149-150 нче аятьләре»).

**Эпифора** – берүк сүз яки сүзтезмәләрнең чиктәш яки бер-берсенә якын урнашкан фразалар ахырында кабатлануы, мәсәлән: «Һәй, Исраил угыллары! Сезгә биргәнем нигъмәтләрне исегезгә төшерегез. Миңа биргән антыгызны тотыгыз. Сезгә биргән вәгъдәмне Мин дә үтәрмен вә фәкать Миннән, Миннән генә куркыгыз. Вә яныгыздагы нәрсәне дөресләүче буларак иңдергәнемә инаныгыз, аны беренчеләрдән булып инкяр итүче булмагыз, аятьләребезне арзан бәягә сатмагыз вә фәкать Миннән, Миннән генә куркыгыз *(Минем җәзамнан куркыгыз!)* («Бәкара (Сыер)» сүрәсенең 40-41 нче аятьләре)». (Тагын к.: «Бәкара (Сыер)» сүрәсенең 238-239 нчы аятьләре.) Мондый кабатлауларның мәгънәсе аятьләр азагының бертөрле ритмда ирешүдә түгел, ә кабатлана торган сүзнең яки сүзтезмәләрнең мәгънәсен көчәйтү дә.

Күп очракларда риторик фигуралар тулы бер җөмләләрнең яки аларның өлешләрен кабатлап барлыкка килә. Мәсәлән, кабатлана торган чиктәш аятьләр, гадәттә, хисси көчне арттыруга хезмәт итәләр: (Юк ...тиздән белерләр. Моның соңында тиздән белерләр”, “Нәба (Хәбәр)” сүрәсе, 4-5 нче аятьләр); (“Ий мондый кеше синңа ґәзаб тиеш, ґәзаб тиеш! Дәхи сиңа ґәзаб тиеш, ґәзаб тиеш!”, “Кыямәт” сүрәсе, 34-35 нче аятьләр). Кайбер сүрәләрдә бер үк аять, текстта бертигез диярлек аралыктан соң кабатланып, текстта **рефрен** рәвешендә килә. Мәсәлән: «Раббыгызның кайсы нигъмәтен Аныкы түгел диярсез?” аяте “Әр-Рахман” сүрәсендә утыз бер тапкыр, ә «Хакны ялган диючеләргә кыямәт көнендә үкенеч вә җәһәннәм чокырыдыр!” аяте “Мүрсиләт (Җибәрелмеш)” сүрәсендә ун тапкыр кабатлана.

**Саналмыш рәт** – бер-бер артлы килгән һәм үзара өтер яисә “беренчедән”, “икенчедән” сүзләре белән аерымланып китерелгән фикерләр. Бу алымның йогынтылы риторик чара булуы өчен санап үтелгән синтаксик төзелмәләр дүрт-биш һәм тагы да артыграк булса яхшы. “Күп” дигән төшенчәне аудитория өч тапкыр кабатлагач кына аңлый, мәсәлән: («Ислам динен риза булып тотучы ирләр вә хатыннар, вә ышану лязем булган нәрсәләрнең һәммәсенә дә ышанучы ирләр һәм хатыннар, вә Аллаһуга итагать итүче ирләр һәм хатыннар, вә сүздә һәм гамәлдә туры булган ирләр һәм хатыннар, вә гадел яшәп дин дөрес тотар өчен бөтен авырлыкларны күтәрүче сабыр ирләр һәм сабыр хатыннар, вә

күңелләре белән Аллаһуга түбәнчелекле булып дин эшләренә мәхәббәт итүче ирләр һәм хатыннар, вә Аллаһ күрсәткән урыннарга зәкят вә башка садакаларын бирүче ирләр һәм хатыннар, вә рузә тотучы ирләр һәм хатыннар, вә зинадан сакланучы ирләр һәм хатыннар, вә Аллаһуны күп зекер итүче ирләр һәм хатыннар, бу әйтелгән эшләрне эшләүчеләргә Аллаһ вак гөнаһларына ярлыкауны хәзерләде вә изге гамәлләренә олугъ әҗерләр хәзерләде», 33 нчы "Әхзаб (Гаскәрләр)" сүрәсе, 35 нче аять). Шулай да, саналмыш рәтнең тәэсир көче төзелмәләрнең саны белән генә дә билгеләнми, ә җөмләнең кисәкләрен санау җөмләнең баш кисәкләре алдыннан килүе белән дә. Мондый кабатлауларның риторик нәтиҗәсе тыңлаучыны киеренке көттереп торуга корылган.

**Градация** — чагыштыру, образлар һәм сөйләмнең башка тәэсирле чаралары көчен бер-бер артлы арттыру яки киметүгә нигезләнгән синтаксик чара. Мәсәлән: «Мин сезгә биргән байлыктан Аллаһ юлына һәм мохтаҗларга садака бирегез, кыямәт көне килмәс борын, ул көндә үзегезне ут газабыннан сатып алу сәүдәсе булмас һәм ул көндә дуслык һәм шәфәгать итү эшләре булмас" ("Бәкара (Сыер)" сүрәсе, 254 нче аять). Аятьтә гөнаһлылар соңгы тормышта өмет иткәннәрнең барсы да бер-бер артлы инкяр ителә. Алар җәзадан акча биреп тә котылып кала алмаячаклар, аларны газаплардан коткаручы дуслары да булмас аларның, аларны аралап алып калыр өчен яклап йөрүчеләре дә булмас.

Коръәндә очрый торган градацияләр үсеп бара торган һәм кимеп бара торган булалар. Үсеп бара торган градацияләрдә сүзләр һәм тәгъбирләр тавыш төсмере һәм мәгънә көче белән арта барган тәртиптә урнашалар, ә кимеп бара торганында киресенчә. Мәсәлән: «Безгә сабырлык, батырлык бир һәм аякларыбызны нык беркет һәм кяфер кавемен җиңәргә ярдәм бир", "Бакара (Сыер)" сүрәсе, 250 нче аять). Соңрак килгән һәр ялвару алда бирелгән теләкнең әһәмиятен арттыра. Ә "Сынар өчен күңел сөйгән нәрсәләрдән: хатыннар, балалар, сыер, кәҗә кеби дүрт аяклы хайваннар, җыйган алтын, көмешләр һәм зиннәтләнгән йөгерек атлар һәм иген кеби нәрсәләр Аллаһдан кешеләргә сөекле ителде" ("Әл-Гыймран" сүрәсе, 14 нче аять) аятендә кызыктыра, азындыра торган мал-мөлкәт әйберләр ахырдан бирелеп, мәгънәләре көч киму тәртибендә урнаштырылган.

**Мәгънә көче кимеп бара торган фигуралар исәбенә** эллипсис и апосиопеза да керә. **Эллипсис** — җөмләнең контекстыннан аңлашылган бер яки берничә сүзне төшереп калдыру. Андый ысул, гадәттә, әйтелмәнең гомуми мәгънәсен чагылдыру өчен кулланыла, мәсәлән: («сез дә [алар кебек] батыл гамәлләргә чумдыгыз (“Тәүбә” сүрәсе, 69 нчы аять). “Кичүне үтү” фигыле, еш кына, “нигә дә булса тотынырга” мәгънәсендә йөри. Биредә, Коръәннең башка урыннарындагы кебек, ул төрле начар гамәлләр кылуга ишарә итә, чөнки, аннан соң тәмамлык төшереп калдырылган.

**Апосиопеза** – башланган сөйләм өзелүне белдерә торган стилистик фигура. Әйтми калу синтаксиста җөмлә өлешен төшереп калдыру булып күренә һәм ул, гадәттә, тулаем текстның тәэсир көчен арттыра. Андый алым куллануны без тәкъваларның җәннәткә баруын тасвирлаганда күрәбез: («алар барган төшкә җәннәт ишекләре ачылып торыр”, 39 нчы “Зүмәра (Халык төркеме) сүрәсе, 73 нче аять). Баш җөмләне төшереп калдыру Коръәндәге фикерне үтемлерәк итә, күзаллауга киң мөмкинлекләр ача.

**Урнашу фигураларына** антитеза, гипербатон һәм өстәмә керә.

**Гипербатон** – мәгънәсе буенча бәйле сүзләрнең синтаксик эзлеклелеген үзгәртү. Мәсәлән, “Кәһаф (Тау тишеге)”сүрәсенең беренче ике аятен «Аллаһга шөкер, үзенең колына дөрес язулар иңдерде һәм анда ялганны урнаштырмады” дип аңларга кирәк. Ләкин гарәп телендәге *kайййм* “дөрес” сүзе артка этәрелгән, шуның аркасында, тыңлаучының игътибары язуның шул үзенчәлеген ассызыклый. Коръәндә сүзләрнең алда (препозиция) яки ахырда (постпозиция) килү мәсьәләләре Бине ас-Са’иганың (1375 елда вафат) *ал-Мукаддима фи-л-алфāз ал-мукаддама* (Алга этәрелгән сүзләргә кереш) трактатында бөртекләп өйрәнелгән.

**Антитеза** – төшенчә, хәл-халәтнең, күренеш-вакыйганың, сурәтләрнең катгый каршылыгыннан оешкан стилистик фигура. Кайбер очракларда капма-каршы кую гыйбарәнең тулаем мәгънәсен аңлата, мәсәлән: («Аллаһ – бай, ә сез – ярлы”, Кыйтал (Мөхәммәд) сүрәсе, 38 нче аять); («Алар аны ерак дип уйлыйлар, ә без якын дип исәплибез”, Мәгариҗ сүрәсе, 6-7 нче аятьләр); («Аллаһ Тәгалә кемне туры юлга салса, ул кеше, әлбәттә, туры юлдадыр. Ул кемне адаштырса, Ул адаштырган кешеләр һәлак булучылар”, “Әгъраф (Пәрдә)» сүрәсе, 178 нче аять). Болар – төгәл антитезага мисаллар. Башка очракларда капма-каршы кую

гыйбарәнең бары тик бер өлешен генә тәшкил итә, мәсәлән: (“Дөреслектә файдалы булган җиңеллек авырлыктан соң. Дөреслектә авырлыктан соң гына файдалы җиңеллек табыла”, “Инширах (Ачмак)” сүрәсе, 5-6 нчы аятьләр).

**Өстәлмә** – грамматик яктан җөмләнең башка кисәкләре белән бәйле булмаган кереш сүз, кереш сүзтезмә, кереш җөмлә. Мәсәлән: (“ул ант бик олуг анттыр, әгәр белсәгез”, “Вакыйга (Хәл)” сүрәсе, 76 нчы аять); ("Ий Раббым, кыз бала тудырдым, ир бала булса дин хезмәтенә яхшы булыр иде", – диде. Аллаһ белүчерәктер, нинди бала тудырганыңны. Хөннә әйтте: "Ир бала, әлбәттә, кыз бала кеби түгел”, “Әл-Гыймран” сүрәсе, 36 нчы аять). Өстәлмә – сөйләм теленә хисси яки тәэсирле мәгънә өсти һәм күпкә түбән (яки югары) тон һәм сөйләмдә тизләтелгән темп белән аерылып тора.

Коръәндәге **фикри фигураларга** риторик сораулар, риторик өндәүләр, риторик мөрәҗәгатьләр карый.

**Риторик сорау** – җавап таләп ителмәгән сорау рәвешендә раслау яки инкяр. Риторик сорауларны иң көчле һәм нәтиҗәле чара дип саныйлар. Ул текст өлешләрен сиздерми генә бәйләп куя. Риторик сорау көтелмәгәндә аудиториянең игътибарын кузгата.

Риторик сорауны О.С. Ахманова «Көчәйтелгән игътибар җәлеп итү, хисси тонны арттыру өчен, раслау яки инкярны сорау рәвешендә оештыра торган сөйләм фигурасы», – дип бәяли.

Риторик сораугa, сөйләмнең билгеле бер төре буларак, аерым бер үзенчәлекләр хас.

Беренчедән, сорау жөмлә рәвешендә һәм сорау жөмләнең барлык күрсәткечләренә ия (интонацияне дә кертеп) булса да, риторик сораугa каршы әңгәмәдәш-тыңлаучының җавабы мәҗбүри түгел, чөнки ул үзе раслау яки инкяр рәвешендәге хәбәр яки теләк, ният, нindидер гамәл кылуга этәргеч буларак төзелә.

Икенчедән, инкяр рәвешендәге риторик сорау һәрвакыт уңай бәяләнә, ә сорауда кире кагу (каршы кую) булмаса, ул кире раслаулы, тискәре бәяле була. Шулай ук, риторик сорауның төп максатларыннан берсе – сорау эчтәлегенә сорау бирүче (адресант) теләгән мөнәсәбәт оештыру.

Риторик сорау тема яки фикерләрне аңлату, тыңлаучылар карашын оештыруның бер мизгеле. Шул сәбәпле ул кинаяләп, читләтеп әйтүгә бик якын. Нindидер фикерләү эзлеклелеге, дәлилләү, тасвирлау, анык җавапларга исәпләнми риторик сорау.

Ул сөйләмнең әһәмиятле төп фикеренә дикъкать туплау вазифасын үти.

Сорау-сорау берлегендә риторик сорауның максатчанлыгы һәм фаразланган тәэсир мөмкинлекләре артып китә. Алар әңгәмәдәшләрнең уңай яки тискәре мөнәсәбәтләрен чагылдыра алалар, хисси һәм шәхси бәя төсмерләре гаҗәпләнүдән ачулануга кадәр һ. б. төрләнә ала.

Мәсәлән: ("Әллә Без Раббиларына карышып көфран нигъмәт кылучы кешеләрдән башкаларны ґәзаб белән җәзалыйбызмы?", "Сәба" сүрәсе, 17 нче аять); ("Коръән белән гамәл кылмаучы фасыйклардан башкалар һәлак булырлармы?", "Әхкаф (Комлык)" сүрәсе, 35 нче аять). Әлеге аятьләрдә тискәре җавап аңлашыла. Бирелгән сораугa җавап уңай булган башка очраклар да бар, мәсәлән: ("Әллә кәферләргә җәһәннәмдә урын юкмы?", "Гәнкәбут (Үрмәкүч)" сүрәсе, 68 нче аять); ("Үзенең колы Мухәммәд г-мне сакларга һәм ярдәм бирергә Аллаһ үзе җитмиме?", "Зүмәра (Халык төркеме)" сүрәсе, 36 нчы аять). Галимнәр фикеренчә, мондый очракларда сорау кисәкчәсе "әллә" кулланылмый.

Сөйләмдә риторик сораулар, гадәттә, түбәндә әйтеп үтелгән хәл-халәтне аңлатып, өстәмә хисси вазифа башкаралар.

а) тәкәбберлек чагылышы: (Мысыр патшалыгы минем кулымда түгелме, вә Нил дәрьясе һәм башка елгалар минем хөкемем астында агалар түгелме? "Зүхъруф (Зиннәтләнү)"сүрәсе, 51 нче аять);

б) шелтә белдерү: ("Әя Аллаһ җире сезгә киң иде түгелме? Сезгә дин иркен урынга күчеп китү лязем иде, ни өчен күчмәдегез?", "Ниса (Хатыннар)" сүрәсе, 97 нче аять);

в) үпкәле шелтә яңгырату: ("Аллаһудан куркучы итәргә, дәхи хаклык белән иңгән Коръән белән вәгазьләнеп ихласлыкны, тәкъвәлекне камилләштереп иманнарын куәтләргә вакыт җитмәдеме?", "Хәдид (Тимер)" сүрәсе, 16 нчы аять);

г) хөрмәт белдерү: ("Аның рөхсәтеннән башка кем яклый ала?", "Бакара (Сыер)" сүрәсе, 255 нче аять);

д) курку хисе уяту: "Иман китермәүче тәкәбберләргә әллә җәһәннәмдә урын юкмы?" ("Зүмәра (Халык төркеме)" сүрәсе, 60 нчы аять);

е) гаҗәпләнүне чагылдыру: ("Нинди китап бу?", "Кәһаф (Тау тишеге)" сүрәсе, 49 нчы аять).

**Риторик өндәү** – сөйләмдә фикерне, хисләр чагылышын, катлаулы кичерешләрне сүзләр белән генә аңлатып бетерә алмаслык иң югары киеренке мизгелдә тавыш төсмерләре белән дә белдерүгә исәпләнгән сурәтләү чарасы. Аның төп вазифасы – сөйләмнең әһәмиятле өлешенә игътибар юнәлтү. Мәсәлән: (“Моның соңында да Минем аңа мал арттырмагымны өмет итәдер”, “Мүдәссир (Бөркәнүче)” сүрәсе, 15 нче аять), ягъни, мондый бозык бәндәгә үлгәннән соң хөрмәт күрсәтү – беркайчан да булмаячак.

**Риторик мөрәҗәгать** яки **риторик эндәш** – раслау яки сорау рәвешендә боерык яки башка мөнәсәбәт белдерү. Уңай яки тискәре тон төсмерендә яңгырый, мәсәлән: (“Аналар балаларын тулы ике ел имезсеннәр!”, “Бакара (Сыер)” сүрәсе, 233 нче аять), ягъни, әни кешеләр балаларын ике ел буе күкрәк белән туендырырга тиешләр.

Без Коръәндәге тел-сурәт, фикри чараларның кайберләрен генә барлап үттек. Бу проблема гарәп риторикасына (*‘илм ал-байāн*) һәм сөйләм фигураларына (*‘илм ал-бади‘*) багышланган хезмәтләрдә җентекләп тикшерелгән. Коръәннең риторик чараларын өйрәнүгә атаклы стилистлар әл-Бакиллани һәм әл-Җурҗани, тәфсирчеләрдән – Фәхр-ад-Дин әр-Рази һәм аз-Замахшари зур өлеш керткәннәр. Кайбер авторлар Коръән риторикасының нәфислеген *иҗазәт* тәгълиматы белән бәйлиләр. Бине әл-Мөхтәз (909 елда вафат) һәм әс-Сүюти изге текстта риторик чараларның барлык архитибын да табарга була, дип барганнар. Бу күренешне алар Коръәннең кабатланмаслыгын дәлилләү дип исәпләгәннәр. Шул ук вакытта әл-Бакилани риторик чараларның кабатланмас була алмауларын искәрткән. Ничек кенә булмасын, Коръән стиле үзенчәлекләрен белү һәр тәфсирче һәм *мөҗтәһидләр* өчен мәҗбүри булып тора.

## Вәгазьләрнең лексик составы

Функциональ стильләрне (өслүбләрне), аерым алганда, хөтбә-вәгазьләр өслүбен һәръяклап һәм тирәнтен өйрәнү, хәзерге этапта аның тулы хокуклы кулланылышын һәм үсешен тәэмин итүдә иң кирәкле шартларның берсе булып тора. Вәгазь сөйләүче имам-хатыйб өчен дә ул зур әһәмияткә ия, чөнки аның авызыннан чыккан һәрбер сүз ачык һәм аңлаешлы булырга тиешле. Шуңа күрә борынгы дәвернең иң бөек фикер иясе Аристотель дә үзенең

безнең эрага кадәр 335 елда язылган “Риторика” дигән хезмәтендә: “Сөйләмнең төп кыйммәте – аның анык булуында. Әгәр сөйләм анык түгел икән, ул үзенең максатына ирешә алмый”, – дип язып калдырган [Аристотель, 1958:17];

Халкыбызның: “Тел күрке – сүз”, “Сүзең булсын аңларлык, өзелсә дә ялгарлык”, “Таныксыз сүз – иярсез ат кебек”, “Аз сүз белән күпне әйт”, “Белмәгәнне сөйләмә, ни сөйләгәнеңне бел” кебек мәкаль-әйтемнәрендә сөйләмдә сүзнең тоткан роленә, аның әһәмиятенә олы бәя бирелә.

Теләсә кайсы телнең, шул исәптән, татар теленең дә гасырлар дәвамында тупланган бай сүзлек хәзинәсе бар. Аны, грек телендәге “lexikos” сүз, тәгъбир, әйләнмә дигән төшенчәләр нигезендә, телнең лексикасы дип атап йөртәләр. Ә бу өлкәне өйрәнә торган фән тармагы лексикология дип атала.

Татар теленең сүзлек составын өйрәнә башлау үткән гасырларга ук карый. Әмма нигезле һәм күпкырлы фәнни өйрәнүләр XX гасырда бигрәк тә, соңгы дистә елларда, алып барыла. Сугыштан соңгы периодта татар теленең лексик системасын төрле аспектта өйрәнү-тикшерү эше аеруча җанланып китә. Бу юнәлештәге өйрәнүләр гомуми грамматикаларда һәм Ш.Рамазанов, Л.Җәләй, З.Вәлиуллина, Ф.Фәсиев, Ә.Ахунҗанов, Г.Саттаров, В.Хаков, Ф.Ганиев, М.Зәкиев, Ф.Хисамова, Р.Әхмәтьянов, Ф.Сафиуллина, И.Низамов, Ф.Гарипова, Ф.Баязитова һ. б. галимнәрнең монографияләрендә, махсус мәкаләләрендә чагылыш таба.

Башка функциональ стильләрнең сүзлек составы, лексик-семантик үзенчәлекләре шактый өйрәнелсә дә (В.Х. Хаков, Х.Р. Курбатов, Ф.М. Хисамова, И.М. Низамов, И.Б. Бәширова, А.А. Тимерханов һ. б.), хөтбә-вәгазь сөйләмиятендә кулланыла торган тел байлыгы бөтенләй тикшерелмәгән, фәнни яктан бәһа бирелмәгән.

Хөтбә-вәгазь өслүбендә кулланыла торган лексик берәмлекләрне үзләренең килеп чыгышлары буенча, асылда, өч зур төркемгә берләштерергә мөмкин:

1. Төрки-татар сүзләре.
2. Гарәп-фарсы алынмалары.
3. Рус һәм рус теле аша Көнбатыш Европа телләреннән кергән сүзләр.

1.Телебезнең сүзлек составы – зур тарихи үсеш нәтиҗәсе ул. Телдәге сүзләр үзләренең барлыкка килүләре, килеп чыгышлары ягыннан төрле чорларга карыйлар.

Хәзерге татар әдәби теленең сүзлек составы бик борынгы дәвергә – төрки халыкларының барысы өчен дә уртак булган борынгы төрки телгә барып тоташа. Бу телдәге сүзләрнең күпчелеге җәмгыятьтә, кешенең тормыш-көнкүрешендә иң мөһим, иң кирәкле төшенчәләрне белдерә. Алар үзләренең тамыр составы буенча, ягъни телнең хәзерге төп сүзлек фондына кергән, ләкин әдәби телдәге сүз ясау ысуллары һәм чаралары белән ясалмаган нигезләрдән гыйбарәт. Тамыр нигезләр рәтендә шулай ук кучкар, болгар, толмач, оста, керәш, арыслан, бәйрәм, каргыш, кызган-, ялвар-, интек- кебек сузъясагыч кушымчалар ярдәмендә ясалган, ләкин шәкли тамырлары телдә инде бөтенләй кулланылмый торган сүзләр дә карала.

Һәрбер телнең тамыр составында генетик яктан үзтамырлар һәм алынма тамырлар аерымлана. Үзтамырларга телнең үзендә борын-борыннан билгеле булган һәм каян да булса читтән кергәнлек билгеләре булмаган тамыр сүзләр керә. Төп тамыр сүзләр гомумтөрки һәм борынгы төрки сүзләрдән яки шулардан үзгәреп килеп чыккан “яңа” сүзләрдән тора [Әхмәтъянов, 2003:13]. Гомумтөрки катламга кергән сүзләр әйтелешләре һәм язылышлары белән берникадәр аерылып торсалар да, уртак лексик байлыкны тәшкил итәләр. Алар кешенең тән төзелешенә караган сүзләр (*баш, аяк, кул, авыз, күз* һ.б.), кардәшлек атамалары (*ата, ана, бала, ир, хатын, кыз, олан* һ.б.), алмашлыклар (*мин, син, ул, без, сез, алар, бу, үз* һ.б.), урын-вакыт төшенчәсен белдерә торган сүзләр (*көн, төн, ел, ара, ал, як* һ.б.), табигать күренешләре атамалары (*җир, су, ай, яңгыр, күк* һ.б.), зоологиягә караган сүзләр (*ат, тәкә, куй, арыслан, бөркет* һ.б.), үсемлек исемнәре (*ут, агач, каен, җиләк, сарана* һ.б.), саннар (*бер, ике, өч, ун, йөз, мең* һ.б.), эш-хәрәкәтне белдерә торган сүзләр (*ал-, бир-, бел-, бул-, кыл-, ит-* һ.б.), асыл сыйфатларның күпчелеге (*ак, кара, яшел, яшь, тере* һ.б.), көнкүрештә кулланыла торган лексика (*тимер, аш, ил, азык, алтын* һ.б.) һәм башкалар керә. Бу лексик берәмлекләр, бик борынгы заманнарда ук барлыкка килеп, телнең төп сүзлек фондын тәшкил итәләр, шулар нигезендә бик күп яңа сүзләр ясала һәм телнең сүзлек составы үсә, үзгәрә, камилләшә бара.

Болар иҗтимагый тормышның барлык өлкәләрендә дә актив кулланылышта йөриләр, алар үз телен белгән һәр кешегә дә аңлаешлы. Хөтбә-вәгазьләрдә алар иң зур күпчелекне тәшкил итәләр.

Дөрес, вакытлар узу белән, төрки-татар сүзләренең дә кайберләре киң кулланылыштан төшеп калалар, телнең архаик катламына күчәләр. Алар арасында мәгънәви үзгәрешләр кичергәннәре дә шактый. Телнең пассив сүзлек составына күчсәләр дә, аерым стильләрдә аларның шактый еш кулланылганлыклары күзәтелә.

Шуларның кайберләренә тукталып үтик. Хөтбә-вәгазьләрдә *күк, тәңре, ыру (ыруг), нәсел-ыру, ил, илче, йорт, кардәш, угыл (ул), кеше, кол, кемсә, каргыш, кичә (кич), иңү, ярлыкау, ярату (яралту), әйләү (әйдәү), күндерү, тыелу, кубарылу, сыгыну, ою, кылу (кыйлу), чалу (сую, бугазлау), ошбу, олуг, тугры, илә (илән), кеби* һ.б. сүз-гыйбарәләр актив кулланылышта йөриләр.

**<u>Күк</u>** сүзе хәзерге татар әдәби телендә берничә мәгънәдә кулланыла. Исем буларак, ул: “1. Җирдән югарыга караганда гөмбәз сыман булып күренә торган һава пространствосы. 2. Җирне чолгап алган дөнья (галәм) пространствосы. 3. күч. Дини карашлар буенча: алла, фәрештәләр һ.б.ш. рухлар яши торган урын. 4. күч. шигъ. Билгеле культура һәм социаль-тарихи үзенчәлекләр белән характерлана торган кеше лек җәмгыяте. 5. с.мәгъ. Астрономиядә кулланыла торган астрономик. 6. рәв.мәгъ. күккә. Югарыга, югарыга табан” мәгънәләрен белдерә. *Күк бите, күк йөзе, күк гөмбәзе, күк чите, күк чатыры, күк җисеме* кебек сүзтезмәләрдә һәм *күк капугы ачылу, күк (күкләр) күкрәтү, күк (күкләргә) ашу, күккә күтәрелү, күктән иңү, күктән сөрелү, күктән төшү* һ.б.ш. фразеологик әйтелмәләрдә төрле мәгънә төсмерләре салына.

Сыйфат буларак аның “1. Спектрның иң төп төсләрнең берсе: зәңгәр белән шәмәхә арасындагы төс, шул төстә булган. 2. Ат төсе турында: аксыл соры төстәге (кайбер диалектларда соры төстәге тимер күк атны да күк ат дип йөртәләр)” дигән мәгънәләре дә күрсәтелә.

Сөйләмдә ул *кебек, шикелле* бәйлекләре урынында да кулланыла [ТТАС, 1979, II:291-292].

Гомуми һәм борынгы төрки телдә кӧк, кӧку рәвешендә, “күк (небо)” һәм “зәңгәр, шәмәхә” мәгънәләрен алып, башка бик күп сүзләр ясауда продуктив нигез булган [Әхмәтъянов, 2001:127].

"Күк сүзендә башка мәгънә төсмерләре булса да, – ди В.Х.Хаков, – төс мәгънәсендә ул борынгы телдә тәңре, зәңгәр сүзләре белән синоним булып йөргән. Тәңре сүзе дә зәңгәр сүзе кебек үк, төс мәгънәсен белдергән. Соңга таба ул табигатьтән өстен көч, күктәге Алла төшенчәсен белдерә башлаган" [Хаков, 2003:106]. Мәсәлән: Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәләм Җәбраил фәрештә белән күккә менәләр. Мөхәммәд галәйһиссәләм җиде кат күк аша үткәндә, аның һәр капусында үзенә кадәр Җир йөзенә килеп киткән пәйгамбәрләр: Адәм, Идрис, Муса, Гайсә һәм Ибраһим (аларга Аллаһының сәламе ирешсә иде) белән очраша [Сабиров, 2012:59].

**Тәңре.** Вакытлар узу белән, моңа кадәр табигатьнең илаһи көчләренә табынган төрки бабаларыбыз да күп илаһлыкка нигезләнгән мәҗүсилектән бераллалыкка, ягъни тәңречелек диненә күчәләр. Борынгы төркиләрнең инануларынча, илаһи көчләр 17 илаһтан торган һәм алар арасында иң куәтлесе Тәңре дип аталган Баш илаһ булган. Тәңре җир йөзен һәм күкне, җирдәге һәм күктәге барлык нәрсәләрне, галәмне, яшәешне барлыкка китергән көч булып саналган. Ул – игелек Алласы, кешеләрне яратучы һәм аларны яклаучы да. Тәңре күктә булганга, аны Күк Тәңресе дип йөрткәннәр һәм галәмдәге иң зур рухи көч булуына ышанганнар. Төркиләр үзләрен исә "Күк уллары", "Тәңре уллары" дип исәпләгәннәр.

Гомуми төрки телдә тәңри, тәңири, көнчыгыш төркиләрдә тәңәрә, теңәри рәвешендә йөргән әлеге лексик берәмлекләр "тәңре", "күк императоры" дигән мәгънәне белдергәннәр [Әхмәтьянов, 2001:196]. Ислам дине кабул ителгәннән соң, төрки халыкларда, шул исәптән, болгарларда да, "Аллаһ" төшенчәсен белдерү өчен борынгы төрки телдә "Күк Аллаһы" мәгънәсендә йөргән "Хода (Ходай)" сүзе дә, "Бөтен дөнья белән идарә итүче" мәгънәсендә Тәңре атамасы да кулланыла башлаган [ИБС, 1993:151-152]. Сирәгрәк булса да, Тәңре сүзе "Галәмнәр хуҗасы, илаһи зат, кодрәт иясе Аллаһ мәгънәсендә вәгазьләр телендә дә кулланыла һәм "Тәңрем", "Тәңре Аллам" гыйбарәләре белән бирелә. Шул ук вакытта Коръән-Кәрим аятьләрендә: "Аллаһтан башка тәңре юк", – дип күрсәтелә.

Дин әһелләре арасында әлеге атаманы куллануга карата төрле фикерләр бар. Мәсәлән, Габделхак хәзрәт Саматов болай дип язган иде: "<...> Тәңре дигән сүз дә безнең Идел буенда һәм башка төрки

халыкларда шушы илаһи затны билгели торган сүз булуга карамастан, Коръәни Кәримдә булмаган һәм хәдисләрдә очрамаган исемнәр белән Аллаһ Тәгаләнең затын атамасак иде” [ТМК, 2010:39]. Ә Җәлил хәзрәт Фазлыев исә: “Ышануның мәгънәсе – исемдә түгел, җисемдә. Дога кылганда, кем генә дип мөрәҗәгать итсәң дә, күңелеңдә “Аллаһ Тәгалә” дигән бөек зат торса, әлбәттә, догаң ирешә”, - ди [Фазлыев, 1999:75].

**Ыру (ыруг)** сүзе гомуми төрки һәм борынгы төрки телдә уруг ыру, нәсел, орлык,, борынгы төркидә үр, ор “орлык, нәсел тамыры” сүзеннән килеп чыккан [Әхмәтьянов, 2001:254]. “Татар теленең аңлатмалы сүзлеге”ндә ул болай дип бирелә: “1. Нәсел, кан кардәшлеге булган берничә буын”. Ә ыруг сүзе исә: “Борынгы җәмгыятьтә төп җитештерүче оешма-борынгы уртак баба, кан кардәшлеге нигезендә берләшкән һәм коллектив хезмәт белән яши торган кешеләр төркеме” дип тәгъбир ителә [ТТАС, III, 1981:548].

**Нәсел-ыру** гыйбарәсендә гарәп теленнән алынган нәсел (“токым, бер ата-бабадан таралган токым”) [ГТРАС, 1993:459] һәм борынгы төрки телдәге ыру сүзләре ята. Ул нәсел-нәсәп кебек үк “туганнар, туган-тумача, кардәшләр” мәгънәсендәге сүзләргә җыелмалык төсмере өсти [ТТАС, 1979, II:453], шул мәгънәдә вәгазь өслүбендә дә кулланыла.

**Ил.** Гомуми төрки телдә “ил, халык; тынычлык, солых” мәгънәләрендә йөргән әл, эл берәмлекләренең фонетик варианты [Әхмәтьянов, 2001:77]. “Аңлатмалы сүзлек”тә аның берничә мәгънәсе теркәлгән: “1. Билгеле бер хөкүмәте булган дәүләт мәмләкәт. 2. Туып үскән җир, ватан; 3. диал. Авыл. 4. Халык һ.б.” [ТТАС, 1977, I:377]. Татар халкының “Ил әче – алтын бишек”, “Ил иргә, ир илгә таяна”, “Илгә таянган Идел кичәр”, “Илнең күрке – тынычлык”, “Иле барның теле бар”, “Илен белмәгәннән, игелек көтмә” һ.б. мәкаль-әйтемнәрендә ил сүзе белдергән мәгънәләр тагын да аныграк төсмерләнә. Хәзерге телебездә кулланыла торган *ил-ана, ил-ата, илбасар, илгизәр, илгәзәк* (ачык йөзле, киң күңелле, ягымлы, түбәнчелекле, кечелекле), *илдәш, ил-йорт, ил-көн* (ил һәм аның халкы), *ил-күз* (халык, авыл халкы), *илкүләм, илсөяр, илче* һ.б. лексик берәмлекләрнең нигезендә дә ил сүзе һәм ул белдергән төп мәгънәләр ята. *Ил авызы, ил агачы, ил белән, ил гизү, ил йомышы, ил-күз алдында, ил-су тарту* һ.б. фразеологик әйтелмәләрдә дә нигез мәгънәләр сакланып кала [Сафиуллина, 2001:105].

“Аңлатмалы сүзлек”тә шул тамырдан ясалган илче сүзенең “Пәйгамбәр, рәсүл” дигән мәгънәсе дә күрсәтелә [ТТАС, I, 1977:385]. *Аллаһ илчесе* дигән сүзтезмәдә дә шул мәгънә шәрехләнә. Мәсәлән: Аллаһ илчесе, галәйһиссәләм бик тыйнак булган [Сабиров, 2012:26]. Аллаһ сөбханә вә тәгалә аны халыкларны агарту, бәхетле итү өчен илче итеп җибәргән [ТК, 1996:29 июль]. Аллаһының Илчесе салләллаһу галәйһи вә сәлләм: “Ходай биргән нигъмәт адәм баласы өстендә күренеп торырга тиеш”, – диде [ДК, 2013:148].

**Йорт.** Гомуми төрки телдәге “йорт, төп биләмә, кышлау” мәгънәсендәге йурт сүзе йуры – “кайтып йөрү” фигыленнән дип фаразлана [Әхмәтъянов, 1981:132]. “1. Тору өчен, төрле учреждениеләр, предприятиеләр өчен билгеләнгән корылма, бина; өй. 2. Бер хуҗалык булып яшәүче кешеләр, семья. 3. Ишек алды. 4. Культура-агарту, фән эшләренә, көнкүреш хезмәтләре күрсәтүгә һ.б.ш. мөнәсәбәтле дәүләт учреждениесе, шул учреждение урнашкан бина. 5. Ил, туган җир. 6. иск. Династия, нәсел-нәсәп” һ.б. мәгънәләрдә кулланыла [ТТАС, I, 1977, :461]. “Идегәй” дастанында Идел-йорт тәгъбире билгеле бер халыкның яшәү урынын, туган җир төшенчәсен чагылдыра.

И Идел-йорт, Идел-йорт,
Идел эче имин йорт,
Атам кияү булган йорт –
Иелеп тәзем кылган (олылаган) йорт;
Анам килен булган йорт –
Иелеп сәлам әйткән йорт;
Кендегемне кискән йорт,
Керем-коным юган йорт;
Бия сауган сөтле йорт,
Кымыз эчкән котлы йорт [Идегәй, 1888:132].

Хөтбә-вәгазьләрдә бу лексема җәмәгать җыела торган урынны, ягъни мәчетне белдерә. Мәсәлән: Кешеләр Аллаһ йортында җыелып, Аның изге китабын укыганда, мөселманнарның җаннарына тынычлык иңәр, бәрәкәтле булырлар һәм фәрештәләр алар өстендә канатларын җәеп торырлар [Сабиров, 2012:93]. Мәчет ул – мөселманнарның барысы өчен дә уртак йорт, ул – Аллаһ йорты [ДК, 2013:113].

Йорт сүзенең акрынлап тар мәгънәдә йөри башлавы төрки халыкларның утрак тормышка күчү процессы белән дә тыгыз

бәйләнештә карала. Йорт сүзе этимологик яктан күчү урынын белдергән йөр (йөр-ет) фигыленә барып тоташа. *Йорт* һәм *юрта* сүзләренең дә тамыры бер үк. Аларның синонимы булган өй сүзе дә ерак тарихтан килә. Кыпчак язмаларындагы *үв, үв иясе* формалары шуны күрсәтәләр [Хаков, 2003:103].

**<u>Кардәш-карындаш</u>** ("бер карыннан туган") сүзеннән үзгәреп килеп чыкан [Әхмәтъянов, 2001:93]. "Аңлатмалы сүзлек"тә ул: "1. Уртак ата-ана, яки әби-баба буенча нәсел, туган кешеләр, иптәш, дус, тугандаш. 2. Аерым тезмәләр составында: уртак сыйфатлар, интереслар буенча "якын, үз кеше" мәгънәсендә бирелә [ТТАС, II, 1979: 59]. Хәзерге татар әдәби телендәге *кардәш-кабилә, кардәшлек, кардәш-ыру, карендәш, карендәшлек* кебек исемнәрнең нигезендә дә *кардәш* сүзе тора. Вәгазьләрдә ул аерым да, *дин, мөселман* сүзләре тезмәсендә дә эндәшү, мөрәҗәгать итү гыйбарәләре булып хезмәт итә. Шулай ук, алар олылау, хөрмәтләү сыйфатлары белән дә кулланылалар. Мәсәлән: мөхтәрәм кардәшләрем, хөрмәтле дин кардәшләрем, газиз мөселман кардәшләрем һ.б.

**<u>Угыл (ул)</u>** сүзе этимологиясе ягыннан ике элементтан тора: 1. <u>Уг (улг)</u> ана нәсел дигәнне аңлата; - ыл – кечерәйтү кушымчасы [Хаков, 2003:115]. Борынгы төрки телдәге *оглан, углан, олан, огыл "угыл"* сүзеннән килеп чыккан [Әхмәтъянов, 2001:153]. "Аңлатмалы сүзлек"тә әлеге атама ул сүзенә кайтарыла һәм түбәндәге мәгънәләр белән шәрехләнә: "1. Ата-ананың ир баласы. 2. Ир затындагы яшь буын. 3. Кайда да булса туган, торучы яки нинди дә булса милләт вәкиле булган уңай характерлы, танылган кеше" [ТТАС, III, 1981:306]. Хөтбә-вәгазьләрдәге *ул* 1 нче мәгънәдә кулланыла. Аның фонетик варианты булган *угыл* – искергән, китап сүзе. Шулай да хөтбә-вәгазьләрдә аның актив кулланылышы күзәтелә.

Хәзерге татар әдәби телендә **<u>кеше</u>** сүзе киң кулланылышка ия. Ул берничә мәгънәдә йөри: "1. Фикерләү, сөйләшү, корал җитештерү һәм анан хезмәттә файдалана алу сәләтенә ия булган зат, җан иясе, шәхес // Югары мораль һәм рухи үзлекләр гәүдәләнеше буларак шәхес. 2. күч. Санау берәмлеге мәгънәсендә кулланыла. 3. Кем дә булса берәрсе; беркем. 4. Икенче берәү, чит, ят адәм (билгесез затны белдерү өчен кулланыла). 5. сөйл. Күч. Сөйгән яр, ир буласы яки дус егет [ТТАС, II, 1979: 89-90]. *Кеше арасына керү* (җәмгыятьтә, тормышта үз урыныңны булдыру),

*кеше булу* (1. Югары мораль һәм рухи үзлекләргә ия булу; 2. тормышка яраклы булу, тормыш итәрлек кеше булу; 3. Каты авырудан терелү, өметсез булып саналган авырудан терелү, аякка басу), *кеше итү* (1) кемгә дә булса тормышта, җәмгытьтә үзенә урын табарга ярдәм итү, тәрбияләү; 2) каты авырудан терелтү, аякка бастыру, *кеше итеп карау* (санлау, исәпләшү, хөрмәт итү), *кеше кулына калу* (1) авыру, гарип булу) яки картлык аркасында башкалар ярдәменә мохтаҗ булу; 2) кемгә дә булса буйсынып яши башлау, үз иркен югалту, *кеше рәтенә керү* (1) үсеп, мөстәкыйль яши башлау; 2) кеше арасына керү; 3) авырудан терелү, кеше сүзе (гайбәт) һ.б. төрле фразеологик тәгъбирләрдә яңа мәгънәви төсмерләр ала. Ул яңа лексик берәмлекләр ясауда да актив катнаша. Мәсәлән, *кешелек, кешелекле, кешелексез, кешеләрчә, кеше-мазар, кеше-фәлән* һ.б.

Вәгазь өслүбендә *кеше* лексемасы, нигездә, 1 нче мәгънәсендә кулланыла. Мәсәлән: Аллаһ Раббыбыз мөселманнарга, иман китергән кешеләргә: "Әй, сез, иман китергән кешеләр! " – дип мөрәҗәгать итә ("Гыймран" сүрәсенең 160 нчы аятеннән башлап). Пәйгамбәребез (с.г.в.) әйтте: "Сезнең хәерлегез шул кешедер, кем Аллаһ кануннарын, Коръәнне өйрәнеп, шуны кешекләргә җиткерсә" [Фазлыев, 2005:14]. Кешедә булырга тиешле иң зур байлык – тәрбия һәм әхлак гүзәллеге [Мөхәммәтшин, 2004:96]. Җиһанның шәрәфе (кадере – Ф.М.) кеше белән, кешенең кыйммәте акыл вә иман беләндер [ТМК, 2008:178].

**Кол** сүзе вәгазьнамәләрдә, аерым алганда, Коръән Кәримнән китерелгән аять тәфсирләрендә, шактый еш кулланыла. Мәсәлән: Ислам асылы – Аллаһ колы булу, хәрамнан сакланып, Аллаһы кушканча хәләл тормыш кичерү [ТМК, 2010:93]. Мин фәкать дин өчен, милләт өчен борчылучы, Аллаһының бер колы [ТМК, 2008:291]. Бу кичәдә Аллаһы сөбханә вә Тәгаләнең гафу вә рәхмәтләрен колларына күбрәк итеп бирүе турында сөйләнә [Мирас, 2008, № 8:58].

Әлеге лексема үзенең килеп чыгышы буенча гомуми төрки телдәге кул сүзеннән [Әхмәтъянов, 2001:110]. "Аңлатмалы сүзлек"тә аның берничә мәгънәсе күрсәтелгән: 1. Барлык хокуклардан һәм җитештерү средстволарыннан мәхрүм ителгән, үз хуҗасы – колбиләүченең милке саналган кеше; колбиләүчелек җәмгыятендә изелүче сыйныф вәкиле // Иске Россиядә крепостной крестьян. 2. күч. Тулысынча (экономик, политик һ.б.ш.) бәйле,

ирексез, хокуксыз кеше турында. 3. дини. Аллага буйсынган кеше, бәндә. 4. күч. Үзенең иреген, эшләрен тулысынча кемгәдер, нәрсәгәдер буйсындырган, шуңа бик нык бирелгән кеше [ТТАС, II, 1979:130]. Хөтбә-вәгазьләр өслүбендә ул 3 нче мәгънәдә кулланыла һәм гарәп теленнән алынган бәндә, мәхлук сүзләренең синоним төрдәше булып тора.

**Кемсә**. Хәзерге телебез өчен архаик катламга күчкән бу сүз, борынгы әдәби телдәге “кем ирсә, кем әрсә кем булса (шул)” гыйбарәсеннән кыскарып, кемсә рәвешендә кулланыла һәм “кемдер берәү” мәгънәсендә йөри [Әхмәтьянов, 2004:131]. “Аңлатмалы сүзлек”тә дә ул “кем” һәм “кеше” мәгънәләрендә бирелә [ТТАС, II, 1979:84]. Хөтбә-вәгазьләр телендә әлеге сүз “кеше” мәгънәсендә кулланыла. Мәсәлән: Әгәр бер мән Шәгъбан ае беткәнче руза тотса, Аллаһы Тәгалә ул кемсәгә оҗмах вәҗеб кылыр <...>” [Мирас, 2003, № 10:105].

**Каргыш.** Р.Әхмәтьянов фикеренчә, бу сүз карга-ш сүзеннән үзгәреп килеп чыккан яки башка төрки телләрдән алынган. Ә *карга* – нигезен борынгы төрки телдәге *“карыг”,* “җавап карау” сүзенә дә баглап була. Татар сөйләшләрендә *карган-у* “ант итү”, ягъни “әгәр фәлән эшне эшләсәм, миңа фәлән явызлык булсын” дип, үз-үзеңне каргау [2001:92]. “Аңлатмалы сүзлек”тә ул “Бик ачулы, үчле теләк; ләгънәт, каргау сүзе дип тәгъбир ителә. Каргау сүзендә “Берәрсенә яки берәр нәрсәгә карата начар теләк теләү; ачынып рәнҗү” мәгънәсе ята [ТТАС, II, 1979:59]. Телебездәге *каргану, каргаулы, каргышлы, каргыш алу, каргыш төшү* кебек гыйбарәләрдә дә шул мәгънәләр саклана. Халкыбыз иҗатында “Алланың каһәре төшсен”, “Алланың ләгънәтләре яусын”, “Йөзең кара булгыры”, “Каһәр суксын”, “Мур кыргыры” һ.б.ш. каргышлар (яман теләкләр) булса да, каргау хупланмаган, аның ахыр нәтиҗәсеннән курку булган. Без моны барыбызга да мәгълүм булган “Сак-Сок” бәетеннән дә беләбез: <...> Җәй көннәрендә сайрый сандугач,

Әнкәй елама, үзең каргагач.

Якты дөньяны күрми калабыз,

Каргады безне газиз анабыз.

Әткәй калдыргач өйдә калдык без,

Әнкәй каргагач Сак-Сок булдык без. [Татар халык иҗаты, Бәетләр, 1983:206].

**Кичә (кич).** Мөселманнар җәмәгате өчен истәлекле вакыйгалар белән бәйләнешле кичәләр (кичләр) бар. Мәсәлән: *Рәгаиб кичәсе*

(Рәҗәб аеның беренче җомгасына каршы кичкә туры килә. Шушы кичтә Мөхәммәд галәйһиссәләмнең атасы хәзрәте Габдулла белән анасы хәзрәти Әминә никахлашканнар һәм беренче тапкыр күрешкәннәр), *Мигъраҗ кичәсе* (Мөхәммәд пәйгамбәрнең Аллаһы Тәгалә белән сөйләшү өчен күккә ашкан киче. Ул Рәҗәб аеның 27 сендә үткәрелә), *Бәраәт кичәсе* (Шәгъбан аеның 15 нче көненә туры килә. Риваятьләргә караганда, бу кичтә инсаннарның бер еллык язмышы билгеләнә), *Кадер кичәсе* (Рамазан аеның 26 нчы кичендә бәйрәм ителә. Бу кичтә Мөхәммәд галәйһиссәләмгә Аллаһы Тәгаләдән Коръән аятьләре иңдерелә башлаган). Бу кичләрдә гамәл кылынган гыйбадәтләр, укылган вәгазьләр фазыйләтле һәм саваплы санала. Шуңа күрә кичә (кич) сүзләренең хөтбә-вәгазь өслүбендә дә еш кулланылышы күзәтелә. Мәсәлән: “<...> Кадер кичәсеннән соң иң мөбарәк кичә – ул Бәраәт кичәседер [Сабиров, 2012:69]. Бу кичәдә хәлебездән килгәнчә гыйбадәтләребезне үтәргә, догалар кылырга, тәүбә итәргә, начар эшләрдән тыелырга тиешбез [Мирас, 2005, № 8:58]. Бу кич – догалар вә теләкләр кабул була торган кич [Мирас, 1998, № 12:84].

**<u>Кичә сүзе</u>** гомуми төрки телдә качә, кәчә рәвешендә “кичен, соң, төнлә” мәгънәләрендә йөргән [Әхмәтъянов, 2001:108]. “Аңлатмалы сүзлек”тә аның ике мәгънәсе теркәлгән: “1. иск. шигъ. Кич. (тәүлекнең көн бетеп, төн башлануга кадәр булган вакыт арасы; 2. Кунаклар белән үткәрелә торган кичке мәҗлес // нәрсәгә дә булса багышланган кичке җәмәгать җыены” [ТТАС, I, 1977:116].

**<u>Иңү.</u>** Хәзерге татар әдәби телендә бу сүз 9 мәгънәдә кулланыла: “1. Югарыдан түбән таба төшү // дини, с.ф. форм. Иңгән. Күктән боерылган. 2. диал. Бату, баю (кояш турында). 3. Җиргә батып керү, сеңү. 4. Чокырланып батып керү. 5. Берәр нәрсәнең эченә керү. 6. Белән алу. 7. рәв. Мәгънә. Күч. диал. Иңеп. Бик тирән (йокы турында). 8. диал. Бер нәрсәдән икенче нәрсәгә йогу. 9. күч. Ишетелү, барып җитү [ТТАС, I, 1977: 448]. Әлеге фигыльнең “йөкләтү” юнәлешендәге иңдерү формасы да бар. Хөтбә-вәгазь телендә *иңү*, *иңдерү* лексемалары Аллаһы Тәгалә тарафыннан Коръән Кәрим аятьләренең Җәбраил фәрештә аша Мөхәммәд галәйһиссәләмгә җиткерелү вакыйгасы һәм кадер кичәсе бәйрәме уңаеннан файдаланыла. Мәсәлән: Коръән – Аллаһының меңнәрчә галәмнәргә иңдерелгән иң соңгы һәм иң камил мәңгелек сүзе [ТМК, 2008:265]. Кадер кичәсе көнне Җәбраил фәрештә бөтен фәрештәләр белән Җир йөзенә иңәр дигән [ТМК, 2010:253]. Кадер

кичәсендә мөһим бер вакыйга бар: Коръән Кәрим беренче тапкыр шул кичтә иңдерелә башлый [Мирас, 2000, № 1:71]. Изге Рамазан Аллаһның китабы, Коръән Кәрим иңдерелгән ай <...> [Сабиров, 2012:92]. Безгә Мөхәммәд Мостафа (с.г.в.) иңдерелгән [ТМК, 2008:3]. Шуннан соң Аллаһы Тәгаләдән тагын бер аять иңгән [Фазлыев, 2005:27]. Әлеге мисаллардан күренгәнчә, иңдерелү сүзе "төшерелү, боерылу, җибәрелү" мәгънәләрендә кулланыла. Шулай ук аның "күмү, җирләү" мәгънәсендәге кулланылышы да бар.

**<u>Ярлыкау.</u>** Дини сөйләмдә бу сүз "Гафу итү, аклау, кичерү, гөнаһларын йолу" мәгънәсендә йөри [ТТАС, III, 1981:648]. Шул мәгънәдә ул хөтбә-вәгазь өслүбендә дә актив кулланыла. Мәсәлән: Аллаһтан ярлыкау сорап, татарча тагын "Йа, Раббым, барлык гөнаһларымнан ярлыка, гөнаһларыбыздан ярлыка", – дип йөрсәк тә әйбәт. Без үзебезнең генә ярлыкауны түгел, барлык мөселманнар өчен ярлыкауны сорарга тиешбез [ТМК, 2010:252-253]. Аллаһ Тәгаләдән Аның үземне һәм сезне ярлыкавын сорыйм [Сөләймани, 2001:102]. Әгәр үлгән булсалар, аларның каберләренә барып, кулларыбызны күтәреп: "Йә Раббым, ата-анамның гөнаһларын ярлыкап, аларга рәхмәтеңне ирештерсәң иде", дип догалар кылыйк [Сабиров, 2012:177].

**<u>Ярату (яралту).</u>** Хөтбә-вәгазьләр телендә *"ярату"* һәм *"яралту"* лексик берәмлекләре мәгънәдәш сүзләр буларак кулланыла. Мәсәлән: Пәйгамбәребез үзе балаларны бик ярата, башка әти-әниләргә дә балаларын сөяргә, яратырга киңәш итә иде [Мөхәммәтшин, 2004:95]. Дөнья яралтылганнан соң, җаннар яралтылганнан соң, Аллаһ Тәгалә әдәм баласын балчыктан яралтты, фәрештәләрне нурдан, җеннәрне уттан яралтты [Фазлыев, 2005:23]. Безне ир һәм хатын-кыз итеп яралткан, арабызга бәхет чыганагы булган ихлас мәхәббәт урнаштырган Аллаһы Тәбарәкә вә Тәгаләгә иксез-чиксез мактауларыбыз һәм олуглауларыбыз булса иде [Сабиров, 2012:115]. Җир вә күкләрне Хак Сөбханә вә Тәгалә Гашурә көнне яраткан [Мирас, 2000, № 4:106]. Адәм баласы, кайсы гына милләт һәм нинди төстә булсын, һәркайсы яратылышы белән кадерле, чөнки ул барлык мәхлукатның иң кадерлеге һәм юктан бар итеп яратучы Раббуль Гыйззә каршында иң хөрмәтлесе [Мирас, 2000, № 3: 97].

Татар теленең хәзерге сүзлек составында *яралту* сүзе юк һәм ул "Аңлатмалы сүзлек"тә дә теркәлмәгән. Ә андагы *ярату* сүзенең *"барлыкка китерү, бар итү, тудыру"* һәм *"яралу, яратылу"*

фигыльләрендәге *“Туу, барлыкка килү”* мәгънәләре Аллаһы Тәгалә тарафыннан җиһандагы барлык тере һәм тере булмаган нәрсәләрнең барлыкка китерелүе, тудырылуы төшенчәсенә туры килә [ТТАС, III, 1981:645]. Хөтбә-вәгазь телендә *ярату* һәм *яралту* параллель кулланылышта йөрсә дә, телебездә актив файдалануда булган *ярату* лексик берәмлеген куллану, безнеңчә, күпкә уңышлырак.

*Әйләү*. Хөтбә-вәгазьләрдә, аеруча, аларның йомгаклау өлешендә, әйләү фигыле еш файдаланыла. Ул күбрәк гарәп теленнән кергән *насыйп, гафу, муафикъ, кабул* кебек сүзләр тезмәсендә кулланыла. Мәсәлән: Барыбызны бәла-казалардан имин кылып, хәвеф-хәтәрсез, кайгы-хәсрәтсез тулысынча коллыктан арынырга насыйп әйлә [ТК, 1996:15 октябрь]. Вә киләчәк заманнарыбызда бөтен җир шары мөэмин-мөселман кардәшләр белән аралашып, куанычлы вә шатлыклы гыйбадәтләр муафикъ әйлә [ТК, 1996: 15 октябрь]. Тәүбә вә истигъфарда (гафу итүне, ярлыкауны сораууда – Ф.М.) бары тик гөнаһларны гафу әйләү турында гына була [Мирас, 1998, № 12:86]. Ий, Раббым, Аллаһ! Ошбу Рәгаиб кичәсендә кылган гыйбадәтләребезне, теләгән теләкләребезне фазлы кәрәмең илә (бөтен юмартлыгың белән – Ф.М.) кабул әйлә [Мирас, 2003, № 8:58].

Хөтбә-вәгазь телендә шактый актив кулланыла торган әйләү сүзе хәзерге телебез өчен архаик катламга күчкән, ул ит – ярдәмче фигыленә туры килә [ТТАС, III, 1981:677]. Бу лексик берәмлек борынгы төрки телдәге “*эйб, ай яхшы, яхшылык*” сүзеннән ясалган) булырга тиеш [Әхмәтъянов, 2001:27]. Хөтбә-вәгазьләр өслүбендә шул ук тамырдан ясалган әйдәү сүзе дә кулланыла. Мәсәлән: Йә, Раббы, үзебезгә дә, балаларыбызга да тәүфикъ вә һидаять биреп, хәерле истикамәт (туры юл) насыйп әйдә [ТК, 1996:15 октябрь]. Хак Сөбханә вә Тәгалә безне сабырлар җөмләсеннән әйдәсә иде [Мирас, 2003, № 7:99]. Күргәнебезчә, фигыль тезмәсендәге әйдә сүзе дә ит-, кыл- ярдәмче фигыльләре функциясен башкара.

**Күндерү.** Хәзерге татар әдәби телендә нигезендә төрки телдәге күн – “тураю, төзәю” [Әхмәтъянов, 2001:29] сүзе яткан бик күп лексик берәмлекләр бар. Мәсәлән: *күндерү, күндәм, күнегү, күнекмә, күнектерү* һ.б. Гомумкулланылышта файдаланыла торган күн- лексемасы “1. Ризалык бирү, риза булу. 2. Гадәтләнү (иярләшү, күнегү //өйрәнү, нинди дә булса күнекмәләргә ия булу. //Җайлашу,

өйрәнеп китү (“сизү, күрү, ишетү органнары турында” мәгънәләрен белдерә [ТТАС, II, 1979:300].

**Күндерү** фигыленең мәгънәләре төрлечә. Омонимнар буларак алар сүзлектә аерымланып, мөстәкыйль мәкаләләр итеп бирелә: *Күндерү* “I. Үтенеп, сорап, нәрсәне дә булса эшләргә ризалату. 2. сөйл. Өйрәтү, күнектерү // буйсындыру; күндерү II. кит. иск. 1. Нинди дә булса максат белән берәр кая җибәрү. 2. Сүзләр белән үзеңнең мөнәсәбәтеңне белдерү, сәлам җибәрү. 3. Күч. диал. Ашау” [ТТАС, II, 1979: 299].

Хөтбә-вәгазь телендә күндерү сүзе “өйрәтү, күнектерү, гадәтләндерү, җибәрелү” мәгънәләрендә кулланыла. Мәсәлән: Җир йөзендә булган барлык милләт, барлык җан ияләрен һидаять юлына күндерү өчен Аллаһы Тәбарәкә вә Тәгалә дүрт пәйгамбәргә дүрт китап җибәргән [ТК, 1996: 14 октябрь]. Әй, иман китергән адәмнәр, сез дә аңа салават әйтегез һәм сәламнәр күндерегез [Сабиров, 2012:53]. Пәйгамбәрләрнең һәрберсе гүзәл әхлак өйрәтү нияте белән күндерелгән булсалар да, Расүлуллаһ (с.г.в.) исә шуны тәмам итеп, өйрәтү һәм камиллеккә ирештерү өчен җибәрелгән [ТМК, 2008:23].

**Тыелу.** Хөтбә-вәгазь телендә шактый еш кулланылучы әлеге гыйбарә “1. Рөхсәт ителмәү, нәрсәне дә булса эшләмәскә кушылу. 2. Берәр эш эшләүдән, сүз әйтүдән үзен-үзе тыю” мәгънәләрен белдерә [ТТАС, III, 1981:184]. Шул мәгънәләрдә һәм фигыльләрнең төрле грамматик категорияләрендә ул имам-хатыйб сөйләмендә дә кулланыла. Мәсәлән: <...> Раббыбыз кушканнарын җиренә җиткереп үтәргә, тыйган гамәлләрдән тыелып яшәргә насыйп итсә иде [Сабиров, 2012:159]. Барчабыз да хәрамнардан тыелып, Аллаһ Тәгалә кушканнарны үтәп яшәсәк иде [Фазлыев, 2005:27]. Аның тыйган нәрсәләреннән тыелмак тиешледер [Мирас, 2003, № 10:107]. Ураза сүзе “тыелу” дигәнне аңлата [Сабиров, 2012:75].

**Кубарылу.** Кубару фигыленең төшем юнәлешендәге кубарылу формасы дини төшенчәне белдергәндә, “үлгән кешеләрнең кыямәт көнендә яңадан терелүе” дип тәгъбир ителә [ТТАС, II, 1979:179]. Шул мәгънәдә ул вәгазьнамәләрдә дә кулланыла. Мәсәлән: Пәйгамбәребез: “Кайсы кавемгә охшарга тиешсез, шулар белән кубарылырсыз”, – ди [ТМК, 2008:3]. Ул көндә кешеләр, каберләреннән кубарылып, хисап җиренә <...> барырлар [Мирас, 2001, № 4:119]. Бервакытны Пәйгамбәребез саләллаһу галәйһи вә

сәлләмнән сорыйлар: “Шәһидләр белән берәр кеше кубарылырмы?” [ТМК, 2008:154].

**Сыгыну.** Р.Әхмәтъянов күрсәткәнчә, татар телендә борынгы кулланылыштагы *сыгын* (*сыг-* ның кайтым юнәлеше), ике сүз биргән: *сыгын-у* (Аллага сыгыну) һәм *сыен-у* [Әхмәтъянов, 2001:184]. “Аңлатмалы сүзлек”тә сыгыну сүзе сыену лексемасына кайтарыла [ТТАС, II, 1979:691]. Ә сыену фигыленең түбәндәге мәгънәләре билгеләнә: “1. Яклау эзләп яки иркәләнеп, берәүнең янына килү, аны кочаклау, кочагына керү һ.б.ш. // Берәр җиргә яшеренү, посу, ышыклану. 2. Ярдәм итәрдәй берәр кеше янына, иминлекне тәэмин итәрдәй берәр җиргә урнашу [ТТАС, II, 1979:693].

Хөтбә-вәгазь телендә *сыгыну* һәм *сыену* сүзләре “Аллаһыдан яклау, ярдәм сорап, “Аның булышлыгына өмет итү” мәгънәсендә кулланыла. Мәсәлән: Шәһәрдән чыккач, Пәйгамбәребез галәйһиссәләм болай дип дога кылды: “Йә, Раббым, мин үземнең көчсезлегемнән, гаҗизлегемнән Синңа сыенам. Йә, Раббым, миңа золымлык кылган кешеләрнең зарарыннан сиңа сыенам [Сабиров, 2012:134]. Һәр вәгазьдә еш файдаланыла торган “Әгүзү билләһи минәш-шәйтанир-раҗим” гыйбарәсе дә: “Аллаһы Тәгаләгә шайтан коткысыннан сыгынамын”, – дип шәрехләнә.

**Ою.** “Бу тамырда, – ди Р.Әхмәтъянов, – бер яисә ике сүзме икәнлеген әйтү кыен, гомуми төрки телдәге уйы – “ою, оешу, охшашлану, беришле булып китү” борынгы төрки телдә -уйу – удү- “йоклау” мәгънә җәһәтеннән дә, фонетик яктан да бер. Борынгы ойы-у “бергә берләшү” мәгънәсенә дә ия булган. Бу нәтиҗә *оерша* (ойорша) “укмашкан нәрсә, төер һәм *оеш-у* (ойош-у) сүзләреннән чыга. Төрек, чыгтай, казакъ телләрендәге уй – ярашу” сүзе дә шул нигездән булса кирәк. [Әхмәтъянов, 2001:153]. “Аңлатмалы сүзлек”тә ою сүзенең берничә мәгънәсе бирелә: “1. Изрәү, йокымсырау; йоклау хәленә җитү. 2. Тып-тын булу, бөтенләй хәрәкәтсез калу // күч. йомылып яшәү, бернинди акыл эшчәнлеге күрсәтмәү турында. 3. Берәр нәрсәгә бирелеп, үз-үзеңне оныту; онытылу. 4. Сиземлеген югалту, хәрәкәтсезләнү (тән әгъзалары турында). 5. иск. Намазда имамга, муллага ияру турында // күч. Эштә, хәрәкәттә кемгә яки нәрсәгә булса да ияру, буйсыну, бәйле булу. Хөтбә-вәгазьләрдә аның төрле мәгънәләрдә кулланылуы күренә. Мәсәлән: Галәм-җиһанны яралткан вә төрле нигъмәтләре белән тутырган Раббуль галәмин хәзрәтләрен белмәү, Аның

хөкеменә, кануннарына, дәрман-боерыкларына оемау, буйсынмау, адәм баласына утлы газапларның килүенә сәбәпчедер [ТМК, 2008:178]. Динебез ялкаулыкны, оеганлыкны, пессимизмны мәкруһ күрә, ягъни яратмый [ТМК, 2008:53].

**Кылу (кыйлу)** – хөтбә-вәгазьләрдә иң еш кулланыла торган лексик берәмлекләрнең берсе. Ул “1. Кит. Нәрсә дә булса эшләү, нинди дә булса эш башкару. //Нәрсәне дә булса оештыру, үткәрү; ясау. 2. Ярдәмче фигыль функциясендә. 1) Китү; 2) дини ритаулны белдергән исемнәр белән килгәндә “шул ритаулны башкару” мәгънәсен аңлата” [ТТАС, II, 1979: 221]. Аның күптөрле лексик-грамматик мәгънәләрдә кулланылышын без түбәндәге мисаллардан күрәбез: <...> намаз соңында вәҗиб булган сәһү сәҗдәсе кылабыз [ТМК, 2008: 54]. Яшьләрне балаларыгыздай күреп, аларга мәрхәмәтлек һәм шәфкатьлелек кылыгыз [Сөләймани, 2001:102]. Яралтылышның иң бөеге итеп, Аллаһ Раббыбыз кешене бар кылды [Фазлыев, 1999:8]. Аллаһы Тәгаләгә хезмәт кылу – ул бөтен шәригать боерыкларын үтәү: намаз уку, ураза тоту, Коръән уку, зекер әйтү, шулай ук хәрамнардан тыелу [Сабиров, 2012: 7-8]. Үзебезгә дә остаз булып, дога кылучылар калдырырлык хәерле гомерләр насыйп булса иде [Фазлыев, 2005: 15]. Иң күп шөкрана кылучылар – Аллаһ нигъмәтләренең кадерен белүчеләр [Сабиров, 2012: 10].

Кайбер вәгазь-нәсыйхәтләрдә, электән килгән китап теленең дәвамы буларак, кыйл сүзен куллану да очрый. Мәсәлән: Динебез тарафыннан тыелган тагын бер кәсеп – фәхешлек кыйлу [ТК, 1996: 23 март].

**Ошбу.** Хәзерге телебез өчен искергән сүз буларак, бу лексик берәмлек “Аңлатмалы сүзлек”тә *бу, шушы* күрсәтү алмашлыкларына кайтарыла [ТТАС, II, 1979:490]. Ә *бу* алмашлыгы исә ике мәгънәдә шәрехләнә: “1. Пространство яки вакытның үзеңә якынрак өлешендә булган нәрсәне яисә кешене күрсәтү өчен кулланыла; киресе: теге. 2. Әле генә искә алып үтелгән нәрсәгә ишарә ясау өчен кулланыла [ТТАС, I, 1977: 185]. Р.Әхмәтьянов фикеренчә, *ошбу* – борынгы төрки телдәге *ушбу, ушабу* – борынгы *уш, уша* сүзләреннән килә [Әхмәтьянов, 2001: 157].

Хөтбә-вәгазьләрдә ошбу сүзе, югарыда күрсәтелгән мәгънәләрдә киң кулланылышка ия. Мәсәлән: Ислам дине вә Ислам шәригатенең төп чишмәсе ошбу Коръәндер [ТК, 1996: 30 ноябрь]. Мөхтәрәм мөселман кардәшләрем, әйдәгез, ошбу бөек Рамазан

көннәребездә күңел шәрифләребезне, гакылыбызны имтихан кылыйк [Мирас, 1998, № 1: 125]. Ошбу сыйфатлар Раббыбызга хезмәт кылуда чагылырга тиеш [Сабиров, 2012:7].

**Олуг.** Хөтбә-вәгазьләрдә күптәннән килгән төрки катламның кулланылышы олуг сүзендә дә чагылыш таба. Гомум кыпчак телендәге *улу, уллу,* гомум төркидәге *улуг, уллуг* “олы, зур” сүзе борынгы төрки һәм борынгы монгол телләрендәге ул “дәрәҗәле кешеләр утырган махсус ястык” сүзеннән килә”, – дип яза Р.Әхмәтьянов әлеге сүзнең этимологиясе һәм мәгънәләре турында [2001:154]. “Аңлатмалы сүзлек”тә ул “бөек, олы” мәгънәләрендә тәгъбирләнә [ТТАС, II, 1979:467]. Шул мәгънәви җирлектә *олугла,* (ихтирам итү, хөрмәтләү, зурлау), *олуглык* (зурлык, мәртәбәлек; олуг булу хәле), *олуглыклы,* (мәһабәт, тантаналы) сүзләре дә ясалган. Вәгазьнамәләрдә бу лексик берәмлекләр актив кулланылалар. Мәсәлән: Алласызлык – бер афәт, олуг хәсрәт, караңгылык, игелексезлектер [ТМК, 2008:178]. “Олугларыбызны, могтәбәр галимнәребезне ихтирам кылып дога кылыйк” [Мирас, 1998, № 12:86]. Борынгы олугълыкларыгыз, дәрел-дөнья горурлыгыгыз бетте – хәзер һәр җирдә һәркем һәр яктан тигез [Мирас, 2000, № 2:73]. <...> бу кичә (Мигъраҗ кичәсе – Ф.М.) Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәләм хәзрәтләренең тормышында олуг могъҗиза булып санала [Сабиров, 2012:58].

**Тугры**. Ә Р.Әхмәтьянов билгеләвенчә, әдәби телдәге *тугры* сүзе “туры, турылыклы” борынгы төрки телдәге *тогыр* – “аркылы килеп ату” сүзеннән килеп чыккан [2001:213]. “Аңлатмалы сүзлек”тә ул туры күзенә кайтарыла һәм түбәндәге күчерелмә мәгънәләрдә тәгаенләнә: 8. Уендагын яшермичә, ачыктан-ачык, дөресен әйтүче; саф күңелле // Яшермичә, ачык-тан-ачык әйтелгән (уй-фикерләр, сүзләр турында). 9. рәв. Мәгъ. Чын, дөрес, рас // и. мәгъ. *турысы*. Берәр нәрсәнең дөресе, чыны. 10. Гадел, хатасыз. 11. хыянәтсез, ышанычлы, турылыклы [ТТАС, III, 1981:173].

Шул мәгънәләрдә хөтбә-вәгазьләрдә дә шактый киң кулланыла. Мәсәлән: Икенче бер хәдистә болай дип әйтелгән: “Тугрылыкны нык саклагыз, тотыгыз, чөнки тугрылык кешене яхшылыкка, яхшылык җәннәткә илтер. Кеше һәрвакыт тугры сөйләсә, Аллаһ янында бик тугры кеше дип язылыр [Сабиров, 2012:20]. Тугрылык – бәхет-сәгадәткә юнәлүдер, юлның тугрысын сайлаудыр [ТМК, 2008:180].

**Чалу, сую, бугазлау.** Бу сүзләр синонимнар буларак, Корбан гаете уңаеннан сөйләнә торган вәгазьләрдә кулланылалар.

“Татар теленең аңлатмалы сүзлеге”ндә *чалу* фигыленең бик күп мәгънәләре күрсәтелә. Шуның “сую (күбрәк корбанга суела торган хайваннар турында әйтелә)” дигән мәгънәсе белән хөтбә-вәгазьләрдә дә кулланыла [ТТАС, III, 1981:405].

Р.Әхмәтьянов аның гомумтөрки телдәге *чал* – җилкенеп сугу, селтәнү, ташлау, мал тоту, әләктерү, карык ыргыту, арканлау, урату, урау, скрипкада уйнау (сызма белән селтәнү)”, борынгы төркидәге *чал-іо* сүзеннән килеп чыкканлыгын һәм *чал* – лексемасы белән мәгънәви тамырдашлыгын күрсәтә [2001:228]. Хөтбә-вәгазь телендә ул “сую” мәгънәсендә кулланыла. Мәсәлән: Корбан чалу безгә Ибраһим галәйһиссәләмнән мирас булып калган [ТК, 1996: 30 апрель]. Иң яхшы гыйбадәт – Корбан чалудыр [Сөләймани, 2001:101]. Ибраһим галәйһиссәләм улын азат кылу һәм Җәбраил фәрештә алып килгән куйны чала [Сабиров, 2012:158].

“Аңлатмалы сүзлек”тә *сую* сүзенең берничә мәгънәсе теркәлгән: “1. Бугаз кисеп, канны агызып үтерү. 2. Кан чыгар дәрәҗәдә ышкытып кырдыру, җәрәхәтләү, чиләндерү (тәнне). 3. күч. сөйл. Иң җаваплы, хәлиткеч берәр вакытта тоткарлык һ.б. ясап, бик уңайсыз хәлгә кую. //Нык җәфалау, газаплау. 4. диал. Тунау; тирене аерып җәрәхәтләү. 5. диал. Каезлап, кәүсәсеннән аеру, куптару (агач кабыгын)” [ТТАС, I, 1979:689]. Р.Әхмәтьянов аның килеп чыгышын гомуми төрки телдәге сай – “кыйнату, сугу, сую, кабык (тире) сую” сүзеннән дип күрсәтә һәм мәгънә үсешен түбәндәгечә билгели: “Сугу, сугып үтерү > пычак белән сугу > сую > суелган малны тунау > һәртөрле тире, кабык кебек нәрсәләрне сую” [Әхмәтьянов, 2001:181]. Хөтбә-вәгазь телендә ул “Аңлатмалы сүзлек”тә шәрехләнгән беренче мәгънәдә кулланыла. Мәсәлән: Корбанга бер яше тулган куй, сарык һәм кәҗә - бер кеше өчен, ике яше тулган сыер яисә биш яше тулган дөя – җиде кеше өчен суюдыр [Сөләймани, 2001:101]. Фикыһ гыйлемендә: “Корбан ул – махсус бер хайванны, билгеле бер вакытта Аллаһы Тәгаләгә якынаю ниятеннән чыгып суюны аңлата”, – дигән [Мирас, 2000, № 3:96].

Шул ук мәгънәләрдә бугазлау сүзе дә кулланыла. Гомуми төрки телдәге бугаз, богаз, бугаз, тамак” нигезендә ясалган бу лексик берәмлек “Аңлатмалы сүзлек”тә: “1. Сую. 2. Бугазны чәйнәп, ертып үтерү (ерткычлар турында) // күч. Үтерү, юк итү,

бетерү" мәгънәләрендә бирелгән [ТТАС, I, 1977:186]. Аның 1 нче мәгънәсендәге кулланылышын түбәндәге мисаллардан күрергә мөмкин: Корбан гаете (нәзер – бугазлау) көне – Ибраһим галәйһиссәләмнең нәзере буенча углы Исмәгыйльне Корбан итеп бугазларга әзерләнгән көнедер [ТМК, 2010:322]. Ибраһим галәйһиссәләм углы Исмәгыйльне бугазлыйм дип торган заманда, Җәбраил фәрештә килеп, бугазлатмаган, Аллаһы Тәгаләнең әмере белән углы урынына бер куй китереп, шуны Корбан кылырга кушкан [ТМК, 2010:323].

Болардан тыш, хөтбә-вәгазь телендә хәзерге телебез өчен искергән, актив кулланылыштан төшеп калган *илә, илән, кеби, берлә* кебек ярдәмлек сүз төркеменә кергән лексемаларны да еш очратабыз. Алар, бигрәк тә, хәзерге вәгазьчеләрдән Җәгъфәр хәзрәт Мөбарәк нотыкларында еш очрыйлар. Мәсәлән: Бәндәнең Аллаһы Тәгалә каршындагы дәрәҗәсе савап эшләү илә арта [Мирас, 1998, № 12:85]. Һәм әгәр бер кеше бу Рамазан аенда ахшам, ястү вә тәравих намазын җәмәгать илән һич калдырмый укыса, ул кешегә Кадер кичәсенең савабы бирелергә мөмкин [Мирас, 2000, № 1:71]. Кинәт бөтен дөнья икегә ярылган кеби бер гаять тә каты улау тавышлары ишетелер [Мирас, 2001, № 4:119].

Әлбәттә, хөтбә-вәгазьләрдә актив кулланылышта булган башка бик күп төрки-татар сүзләре бар. Аларның күбесенә күпмәгънәлелек хас. Шунлыктан сөйләмдәге мәгънәви үзенчәлекләрен белергә һәм дөрес файдаланырга кирәк.

2. Кулланылыш сферасы һәм ешлыгы буенча гарәп-фарсы сүзләре телебездә бик зур урын алып тора.

Татар теленең сүзлек хәзинәсен баетуда мөһим роль уйнаган бу алынма сүзләр төрле заманнарда һәм төрле юллар белән телебезгә үтеп кергәннәр. X гасырга чаклы ук Идел Болгары дәүләтенә гарәп сәүдәгәрләре, сәяхәтчеләре килә башлаган. Сәүдә итү белән бергә, алар монда Ислам динен таратканнар, мәчет-мәдрәсәләр ачканнар, гарәп язуына һәм теленә өйрәткәннәр. X йөз башында Ислам дине кабул ителгәннән соң, Якын Көнчыгыш белән багланышлар тагын да көчәйгән, телебезгә аеруча дини төшенчәләрне белдергән бик күп сүзләр, гыйбарәләр кабул ителгән.

XIII-XIV гасырларда Алтын Урда белән гарәп илләре, аерым алганда, Мисыр арасында сәүдә, мәдәният һәм илчелек мөнәсәбәтләре тагын да көчәеп киткән. Сарайда һәм Алтын

Урданың башка мәдәни үзәкләрендә бик күп галимнәр, шагыйрьләр, әдипләр яшәгән. Бу дәверләрдә әдәбият үскән, төрле фәнни китаплар язылган. Гарәпчә укып белем алган галимнәр һәм шагыйрьләр шул замандагы төрки телгә күп кенә гарәп сүзләре кертkәннәр, гарәп һәм фарсы әдәбиятының иң гүзәл үрнәкләрен иске татар теленә тәрҗемә иткәннәр.

Менә шул чорларда һәм бигрәк тә XVIII-XIX гасырларда татар теленә үтеп кергән бик күп гарәп-фарсы сүзләре һәм гыйбарәләре башта язма телдә, соңга таба халык сөйләмә телендә дә кулланыла башлаган. Әмма бу алынмаларның билгеле бер өлеше сөйләү теленә үтеп керсә дә, язма әсәрләрдә киңрәк файдаланылган. Шуның нәтиҗәсендә халык сөйләмә теленнән шактый аерылып торган югары стильдәге китап теле барлыкка килгән. Тәгълим-тәрбия системасында гарәп теленә өстенлек бирелү, гарәп грамматикалары үрнәгендә дәреслекләр төзелү, татар теленә Коръәнне, Мөхәммәд пәйгамбәр (с.г.в.) хәдисләрен, башка дини китапларны тәрҗемә итү һәм шәрехләү нәтиҗәсендә дә, телебезгә күпләгән гарәп сүзләре һәм тәгъбирләре үтеп кергән.

XIX йөзнең соңгы чирегендә милли әдәби телне формалаштыру, гарәп-фарсы сүзләре белән тәмам чуарланган, аңлаешсызга әверелгән китап телен халык сөйләмә теленә якынайту буенча киңкырлы эшчәнлек башлана. Габделҗаббар Кандалый, Каюм Насыйри, Муса Акъегет, Заһир Бигиев, Фатих Халиди, Габдрахман Ильяси, Ризаэтдин Фәхретдинов, Габдулла Тукай, Фатих Әмирхан, Гаяз Исхакый, Галимҗан Ибраһимов һәм башка күренекле мәгърифәтче галимнәребез, әдипләребез бу юнәлештә шактый иҗтиһадлык күрсәтәләр. Октябрь инкыйлабыннан соң, бигрәк тә узган гасырның 20-30 нчы елларында мондый эш-гамәлләр тагын да көчәя. Гарәп язуын башта латин графикасына, аннан соң кириллицага алмаштыру процессында да элек-электән актив кулланылышта булган гарәп-фарсы сүзләре телебездән кысрыклап чыгарыла, аларның функциональ мөмкинлекләре чикләнә. Татар теле өчен "кирәксезгә әверелгән" байтак гарәп-фарсы сүзләре, башлыча, китап сүзләре сөйләм телендә генә түгел, матур әдәбиятта, матбугатта да кулланылмый башлый.

Татар әдәби телен гарәп-фарсы алынмаларыннан "чистартканда", түбәндәге принциплардан чыгып эш итеlә:

1. Теге яки бу төшенчәне аңлату өчен гарәп телендәге сүз урынына, шул ук мәгънәне белдерүче татар сүзе алына. Мәсәлән: *сәнә - ел, важҗиб – тиеш, дәрья – елга, карья – авыл, җәһаләт – наданлык, мәхбүс – тоткын, сөаль – сорау, мәдәд – ярдәм, зольмәт – караңгылык, икъбал – киләчәк* һ.б.

2. Әдәбиятта, фәнни хезмәтләрдә кулланыла торган гарәп-фарсы сүз ләрен татар, рус яки халыкара атамалар белән алмаштыру. Мәсәлән: *мөхәррир – редактор, истыйлях – термин, һәндәсә - геометрия, хәят – тормыш, мәшрикъ – көнбатыш, мөндәриҗә - эчтәлек, сарыф – морфология, нәхү – синтаксис* һ.б.

3. Дини төшенчәләрне белдерә торган сүзләрнең күпчелеген әдәби телдән алып ташларга яки күчерелмә мәгънәдә генә кулланырга. Мәсәлән: *тәкбир, зәкят, гошер, савап, җәһәннәм, җәннәт, оҗмах, гыйбадәт, Алла* һ.б. Кызганычка каршы, дини атамаларга каршы шушындый тел вәзгыяте озак еллар дәвам итә. Нәтиҗәдә, узган гасырның 80 нче еллар башында чыккан “Татар теленең аңлатмалы сүзлеге”ндә дә андый эчтәлектәге күп кенә сүзләр кертелми, яки “уйдырмаларда”, “мифик”, “имештер”, “кимсетеп әйтү”, “ироник мәгънәдә” кебек искәртмә-аңлатмалар белән бирелә. Мәсәлән, *бәндә, мәхлук* лексемаларына да шундый мәгънәләр салына, ә илаһият телендә ул “кеше”, “Аллаһ колы” (кимсетү белән түгел) мәгънәләрендә кулланыла.

Дөрес, гасырлар дәвамында кулланылышта булган, халык сөйләмә телендә дә ныклап урнашып калган барлык гарәп-фарсы сүзләреннән һәм гыйбарәләреннән бөтенләй ваз кичү коточкыч зур югалту, телебезне тәмам зәгыйфьләндерү булыр иде. Шуңа күрә әлеге алынмаларга карата кайбер ташламалар да ясала. Әйтик, 1924 елда Мәскәүдә Татар-башкорт мәгариф эшчеләре корылтаеның киңәш мәҗлесендә кабул ителгән тезисларда гарәп-фарсы сүзләрен куллануга карата болай дип языла.

1. Гарәпчәдән кереп тә, халык эчендә үз теле кебек үзәкләшкән сүзләр (*каләм, һава, китап, дөнья, шәфкать, мәрхәмәт, рәхмәт, мәктәп* һ.б.) элеккедәй үз урыннарын саклыйлар.

2. Әдәбиятыбызда киң таралып, гражданлык алып, үз телебез дәрәҗәсендә үзләшкән атамалар, сүзләр гарәпчәдән булсалар да, һаман да матбугатыбызда кулланылалар (*әсәр, шигырь, әдәбият, мәгариф, дәүләт, җәмәгать, милләт, тарих, гыйлем, хезмәт, әхлак* һ.б.).

3. Исламның үзендә генә булып, татарча да, башка телләрдә дә сүзе булмаган мәгънәләрнең атамалары шул гарәпчә яки фарсыча рәвешендә йөртеләләр (*иман, гаид, хаҗ, хәлифә, хәрам, хәләл, фарыз, пәйгамбәр, сәхабә, намаз* һ.б.) [Хаков, 2003:244].

Әмма тиздән бу "чистарту"ның ахыр нәтиҗәләре дә күренә башлый: телебездәге гарәп-фарсы алынмалары гына түгел, күпләгән төрки-татар сүзләре дә рус, Көнбатыш Европа телләреннән кергән алынмалар исәбенә кысрыклап чыгарыла: ***сәясәт*** – политика, ***икътисад*** – экономика, ***мәдәният*** – культура, ***сәнәгать*** – промышленность, ***җөмһүрият*** – республика, ***корылтай*** – съезд, ***фирка*** – партия, ***ватанпәрвәр*** – патриот, ***әхлак*** – мораль, ***сыйныф*** – класс, ***тәрәккыять*** – прогресс, ***рәис*** – председатель, ***кунакханә*** - гостиница, ***нотык*** – лекция, ***шигар*** – лозунг һ.б. Шөкер, XX йөзнең 90 нчы елларыннан соң, элеккеге кулланылыштагы гарәп-фарсы сүзләренең шактые телебезгә яңадан әйләнеп кайта башлады.

Гомумән, телебездә гасырлар буе яшәп килгән, аның сүзлек составында мөһим роль уйнаган мондый гарәп-фарсы сүзләрен кирәксезгә алмаштырып, алар урынына башка сүзләр эзләп маташу телнең үсешен чикләү, аны ярлыландыру булыр иде. Шуңа күрә *шагыйрь, әдип, фикер, хәтер, азат, җәмгыять, гомер, вакыт, рәхәт, шат, нәфис* һ.б. күпләгән сүзләрне татар теленең сүзлек хәзинәсеннән чыгарып ташласак, телебез җитәрлек дәрәҗәдә үскән милли әдәби тел сыйфатын югалтыр, аның тулылыгына һәм камиллегенә зыян килер иде. Шуңа күрә теге яки бу төшенчәне төгәл чагылдыру өчен яраклы күпчелек өчен аңлаешлы булган гарәп-фарсы сүзләрен һәм гыйбарәләрен актив куллану телебезнең сүзлек хәзинәсен баета, аның функциональ мөмкинлекләрен үстерә.

Татар әдәби телендә нормалашкан гарәп-фарсы алынмаларын лексик-семантик яктан берничә төркемгә бүлеп карарга мөмкин:

1. Дини төшенчәләрне белдерүче сүзләр: *Аллаһ, Коръән, дин, Ислам, иман, гает, гыйбадәт, дога, шәригать, савап, хөтбә, тәсбих, ураза, ахирәт, хаҗ, хәзрәт, пәйгамбәр, диндар, азан, мулла, тәмуг, бидгать, ваҗиб, мәүлә, ширек, ясин, фидия, тәкбир* һ.б.
2. Фән һәм мәгариф өлкәсенә караган сүзләр: *гыйлем, җәдит, әлифба, сабак, китап, мәдрәсә, шәкерт, мөгаллим, имтихан, сарыф, имла, талиб, шивә, өслүб* һ.б.

3. Әдәбият һәм мәдәният өлкәсенә караган сүзләр: *әдип, шагыйрь, шигырь, иҗат, мәдәни, дастан, сәнгать, мәкалә, сурәт, мәрсия, матбугат, мәҗмуга* һ.б.
4. Иҗтимагый-сәяси төшенчәләрне белдерә торган сүзләр: *җәмгыять, мәмләкәт, сәясәт, дәүләт, ватан, халык, хөррият, кабилә, әмер, даирә, фәрман, сыйныф, хөр, икътисади, милләт, хокук* һ.б.
5. Тормыш-көнкүрешкә караган сүзләр: *әсбап, пәрдә, бина, җиһаз, никах, гаилә, васыять, һөнәр, бәрәкәт, ният, әманәт, нәсел, мәҗлес, шәраб* һ.б.
6. Кеше, аның тормышы, төрле сыйфатлары һәм кичерешләре белән мөнәсәбәтле сүзләр: *зат, инсан, адәм, гомер, корбан, вафат, каһарман, вөҗдан, гадәт, шәфкать, шөһрәт, ихлас, гакыл, гадел, сабыр, әдәп, инсаф* һ.б.
7. Көн, ай исемнәре; урын-вакыт белән бәйләнешле сүзләр: *дүшәмбе, сишәмбе, чәршәмбе, пәнҗешәмбе, җомга, шимбә, якшәмбе, рамазан, гасыр, дәвер, заман, сәнә, сәгать, хәзер, вакыт, миляди, һиҗри, офык, рәҗәб, сәфәр, җөмәдел-әүвәл, җөмәдел ахыр, шәүвәл, зөлкагдә, мөхәррәм* һ.б.
8. Сәүдә һәм юл йөрү төшенчәләрен белдергән сүзләр: *милек, хисап, кыйммәт, файда, ришвәт, мал, зарар, сәфәр, сәяхәт, кәрван, мосафир, мосафирханә, гер, мизан* һ.б.
9. Медицина өлкәсенә караган сүзләр: *сәламәт, шифа, дару, табиб, дәва, дәрман, даруханә, шифаханә* һ.б.
10. Хәрби төшенчәләрне белдергән сүзләр: *хәрби, гаскәр, хәнҗәр, солых, һөҗүм, әсир, һәлакәт, дошман, афәт* һ.б.
11. Хакимият, идарә, хөкем эшләре белән бәйләнешле сүзләр: *хаким, идарә, әмир, шаһ, падишаһ, патша, задә, тәхет, мөһер, мөдир, вәзир, вәкил, хөкем, гаеп, шаһит, җинаять, маддә, җәза, җәллад, зиндан, казый, канун, карар, нотык, мәхбүс, хокук* һ.б.
12. Кыйммәтле ташларны, казылма байлыкларны белдерүче сүзләр: *алмаз, ахак, җәүһәр, якут, гәрәбә, гәүһәр, зөбәрҗәт, фирүзә, мәгъдән* һ.б.
13. Аралашуның төрле өлкәләренә караган, абстракт һәм башка сүзләр: *ахыр, аһәң, бәрәкәт, дәрәҗә, дәлил, даими, зарур, зиннәт, зикер, золым, җавап, җиһан, җәдвәл, җәмәгать, инсан, ихтыяр, иҗтиһад, кабилә, кагыйдә, катгый, ләззәт,*

*маһир, мескен, мәслихәт, мөһим, наз, намус, нур, нәзарәт, пот, пәри, пөхтә, риза, рөхсәт, сәлам, сәбәп, тәкъдим, тәбрик, тәҗрибә, фани, фирка, хәзинә, хәбәр, хәләл, хөрмәт, чара, шарт, шөһрәт, ядкарь, яр, әманәт, әҗер, өмет, җенес, җенси, җефет, җисем, һәйкәл* һ.б.

14. Табигать күренешләре, тереклек ияләре белән бәйләнешле сүзләр: *дәрья, зилзилә, шәфәкъ, туфан, һава, табигать, җанвар, хайван, былбыл, тутый, багбостан* һ.б.
15. Уртаклык исемнәреннән, сыйфатлардан һәм сыйфат фигыльләрдән ясалган кеше исемнәре: *Адилә, Бибинур, Вафирә, Гадилә, Газизә, Галия, Гөлназ, Динә, Зилә, Кадрия, Ләйлә, Миләүшә, Надия, Нурия, Равия, Рәдинә, Сәгыйдә, Тәэминә, Фәридә, Фәүзия, Халисә, Шәрифә, Ясминә, Әминә, Өммегөлсем, Җәмилә, Һаҗәр, Бакый, Габдулла, Данис, Закир, Инсаф, Кәрим, Мансур, Мөхәммәт, Ногман, Равил, Сабир, Тәфкил, Фарук, Хәбир, Хөсәен, Шаһинур, Әгъзам, Өлфәт, Җәгъфәр, Һади* һ.б.
16. Затларны, предметларны ачыклап килүче сыйфатлау сүзләре: *зирәк, пакъ, саф, газиз, мөхтәрәм, фидакарь, гадел, тәкәббер, залим, гаҗәеп, мөлаем, маһир, фәкыйрь, хөр, шәхси, җәдит* һ.б.
17. Алмашлыклар, ярдәмлекләр, грамматик яктан мәгънә бәйләнешенә катнашмаган сүзләр: *әлбәттә, әмма, хәтта, шаять, ихтимал, ифрат, гомумән, кадәр, гайре, фәкать, ләкин, вә, мәсәлән, ниһаять, ягъни, һич, һәммә* һ.б.
18. Ярдәмче фигыльләр белән килә торган сүзләр: *кабул, дәвам, сарыф, фаш, һәлак, хасил, насыйп, гафу, ваз, исраф, мәҗбүр, бәян, инкяр (инкяр)* һ.б.

Хөтбә-вәгазьләр лексикасында гарәп-фарсы сүзләре актив кулланылышка ия, ягъни алар бу өслүбнең шактый бай сүзлек составын тәшкил итәләр. Аларның киң кулланылышы, аеруча, дини вәгазьләрдә күренә. Бу аңлашыла да, чөнки Коръән аятьләренә, Мөхәммәд галәйһиссәләм сөннәтләренә, дини риваятьләргә нигезләнгән вәгазьләрдә башкача була да алмый. Шулай итеп, Коръән Кәрим сүрәләренең тәфсирләрендә, Мөхәммәд пәйгамбәр хәдисләренең шәрехнамәләрендә дини төшенчәләрне белдерә торган бик күп гарәп-фарсы сүзләре сакланып кала. Шулай ук кайчандыр телебездә актив кулланылышта булып, хәзер инде архаик катламга күчкәннәре дә

байтак. Югарыда инде, без хәзерге татар әдәби телендә киң кулланылышта булган бик күп гарәп-фарсы алынмаларының тематик төркемчәләрен биргән идек. Һичшиксез, алар хөтбә-вәгазь өслүбендә дә саклананалар, чөнки Коръәндә инсан яшәешенең барлык өлкәләре тулы һәм ачык күрсәтелгән. Шуңа күрә хөтбә-вәгазьләрдә файдаланыла торган барлык гарәп-фарсы сүзләрен һәм гыйбарәләрен ике зур төркемдә бирәбез.

1. Дини төшенчәләрне белдерә торган лексика: *Аллаһ, Ходай, Коръән, пәйгамбәр, фәрештә, иман, мөэмин, мөселман, шәригать, дин, ислам, дога, намаз, ахирәт, гөнаһ, җәннәт, тәмуг, гает, гыйбадәт, әҗәл, имам, хәзрәт, кыямәт, рәсүл, җеназа, гүр, әүлия, хаҗ, шайтан, тәсбих, рамазан, зякят, таһарәт, бәддога, сәҗдә, гошер, садака, амин, госел, хөтбә, мәүлә* һ.б.

2. Иҗтимагый тормышның төрле өлкәләренә караган сүзләр: *фән, гыйлем, мәктәп, мәдрәсә, шәкерт, мөгаллим, тәгълимат, гамәл, мәҗмуга, мәдхия, мәрсия, риваять, җәмгыять, җәмәгать, инсан, бәндә, мәхлук, адәм, зат, мән (кеше, зат, шәхес), дәгъва, гаилә, никах, васыять, нигъмәт, ният, нәзер, җәбер, хөрмәт, шәфкать, хакыйкать, гакыл, әдәп, әхлак, сабыр, бичара, шәһит, җәза, дөнья, рухият, гадәт, гайбәт, сәгадәт, насыйп, бәрәкәт, мәхшәр, каһәр, сүрә, аять, тәҗвид, нәсыйхәт, тәгъбир, вәгазь, хәдис, хәләл, җәфа, һидая* һ.б.

Кайбер вәгазьнамәләрдә бүгенге көн укучысы өчен аңлашылмаган аерым сүзләргә шәрехләүләр бирелсә дә, шактый гына гыйбарәләр аңлаешсыз кала. Гарәпчәләре камил, исламияттән гыйлемнәре җитәрлек булмаган кешеләргә, һичшиксез, аларның мәгънәләренә төшенеү авыррак. Мәсәлән: *бидгать* (яңалык; диннең кагыйдәләренә, дини хакыйкатькә туры килми торган фикер-гамәлләр, гадәт-йолалар), *вәҗиб* (тиешле, зарури, кылынганы өчен савап, үтәлмәгән очракта гөнаһ дип санала торган эш-гамәл), *вәкыф* (дин һәм хәйрия максатларына күчерелгән салымсыз милек), *гадәләт* (гаделлек), *газават* ( дин өчен изге сугыш), *гаиб* (яшерен, билгесез), *гафләт* (игътибарсызлык, саксызлык, ваемсызлык, гамьсезлек), *гашура* (мөхәррәм аеның унынчы көне), *дәгъват* (Иманга чакыру, дингә өндәү), *дәҗҗал* (ахырзаман алдыннан килеп чыгарга тиешле ялган пәйгамбәр), *истигъфар* (Аллаһы Тәгаләдән гафу үтенү, ярлыкавын сорау: "əстәгъфирулла" дип әйтү), *истикамәт* (турылык, намуслылык, дөрес юнәлеш, туры юл; Аллаһ кушканнарын тайпылышсыз үтәү, тыелган гамәлләрне кылмау),

*ифтар* (ураза тоткан кешенең авыз ачканнан соң, кичке ашы), кабих (начар, яман, бозык), *кадир* (һәрнәрсәгә көче җитүче, көче чикләнмәгән), *кальб //калеб* (әверелдерү, әйләндерү, үзгәртү, алмаштыру, йөрәк, күңел, эчке кичерешләр), *мәгъфирәт* (ярлыкау, кичерү, гафу итү), *монафикъ* (икейөзле, эчкерле, ышанмаучы кеше), *мөхәддис* (хәдисләр өйрәнүче), *рәкәгать* (намаз вакытында укыла торган догаларның һәм башкарыла торган хәрәкәтләрнең һәрбер циклы: аягүрә тору, иелү, тез чүгү, башны җиргә кую һ.б.), *рәсүл (пәйгамбәр), рия* (икейөзлелек, монафыйклык), *салават* (мактаулы догалар, намазлар), *салат* (Ислам динендәге шәригать кануннары буенча билгеләнгән биш фарыз (мәҗбүри үтәлергә тиешле) гамәләрнең берсе – намаз), *сәхабә* (Мөхәммәд галәйһиссәләмнең көрәштәшләре, аны үзе исән чакта күргән кешеләр), *саум* (фарыз гамәлләрнең берсе – ураза), *сыйхәт* (сәламәтлек, саулык), *тәҗвид* (Коръәнне дөрес итеп уку турындагы кагыйдәләр), *тәкъдир* (язмыш); берәүнең эшләгән эшен тану, бәя бирү; очрак, ихтимал, бәя бирү, бәя билгеләү), *тәкълид* (иярү, башкалар эшләгәнне эшләү, охшатып эшләү, гореф-гадәт, традиция), *тәркиб* (төзелү, барлыкка килү, туплану), *фәләк* (күк гөмбәзе), *фәтва* (Коръән белән сөннәткә нигезләнгән шәригать хөкеме), *фидия* (йолым, үлгән кешенең гөнаһсын йолып калу өчен бирелгән мал, садака), *фирка* (төркем, җәмгыять, оешма), *хиҗаз* (Согуд Гарәбстаны урнашкан ярымутрауның Көнбатыш яр буе, Мәккә һәм Мәдинә шәһәрләре урнашкан урын), *хилаф* (ярамаган эш, мәкер, хыянәт, алдау), *химая* (яклау, саклау, берәүнең кул астында булып саклану, ярдәм, терәк, спонсорлык), хитаб (эндәшү, сүзне берәүгә юнәлтеп сөйләү, сүз, мөрәҗәгать), хитабәт (ораторлык, сүз сөйләүчелек), *һиҗрәт* (күченү, күчү, качып китү), *шәйх* (карт, карт кеше, башлык, юлбашчы, аксакал, дин эшләрен карап торучы, дин башлыгы, ишан), *шәрәф* (дан, дәрәҗә, абруй), *шәрех* (аңлатма), *шәүвәл* (мөселман, календаренең урынлы ае), *шәһадәт* (таныклык, шаһид булу, күрсәтү Аллаһыны тану), *шөкер* (яхшылыкка каршы үзенең шатлыгын белдерү; ризалык-канәгатьләнгәнлек күрсәтү), *шөкрана* (күргән яхшылыкка каршы шатлык белдерү билгесе), *ярабби* (“И, Аллам” гыйбарәсе), *әда* (үтәү; бурычны түләү), *әрвах* (рух), *әссәламе галәйкем* (“Сезгә тынычлык булсын” дигән исәнләшү гыйбарәсе), *җаһил* (надан, белемсез, укымаган) һ.б.

Әлбәттә, хөтбә-вәгазьләр телендә кулланылган барлык гарәп-фарсы сүзләренә аңлатмалар биреп бетерү мөмкин түгел.

Дини төшенчәләрне белдергән барлык атамаларның татар телендәге бердәйлекләрен дә табу читенрәк. Әмма телебездә андый мөмкинлекләр дә җитәрлек, бигрәк тә, архаик катламда булган алынмаларны шәрехләгәндә. Шуңа күрә гарәпчәдән һәм татарчадан шактый гыйлеме булган имам-хатыйб хәзерге татар әдәби теленең мондый лексик җегәрлеген дә истән чыгармаска тиешле. Мәсәлән: телебез өчен искергән, хәзерге актив кулланылышыннан төшеп калган бик күп гарәп-фарсы гыйбарәләрен татар теленең һәркемгә аңлаешлы тел берәмлекләре белән алмаштырып була. Әйтик, ***әтраф*** – тараф; ***бакый*** – мәңгелек; ***зикер*** (итү) – искә алу, искә төшерү; ***истигъфар*** (кылу) – гафу үтенү, ярлыкауны сорау; ***һәфтә*** – атна; ***сәнә*** – ел; ***важиб*** – тиеш; ***җәһаләт*** – наданлык; ***мәдәд*** – ярдәм; ***тәкъва*** – изге; ***икъбал*** – киләчәк; ***зольмәт*** – караңгылык; ***җәнүб*** – көньяк; ***шәриф*** – кадерле; ***хөҗҗәт*** – дәлил; ***хилаф*** – начар, тискәре; ***тәшәккер*** – рәхмәт; ***сыйххәт*** (сихәт) – исәнлек, саулык; ***рия*** – икейөзлелек, ***һәдия*** – бүләк һ.б.

Шулай ук кайбер сүзлекләргә дә мөрәҗәгать итәргә мөмкин. Мәсәлән: М.И. Мәхмүтов, К.З. Хәмзин, Г.Ш. Сәйфуллин тарафыннан төзелгәлн “Гарәпчә-татарча-русча алынмалар сүзлеге” (Казан, 1965), аның 2 томнан торган икенче басмасы 1993 елда дөнья күрде. Х.К.Баранов төзегән “Арабско-русский словарь” (М., 1956. – 1186 с.), Р.Р.Сафиуллинаның “Мөселман терминологиясе сүзлеге” (Казан, 2006. – 118 б.; татар һәм рус телләрендә). “Татар теленең аңлатмалы сүзлеге”ндә дә (3 томда – Казан, 1977, 1979, 1981) архаиклашкан күп кенә гарәп-фарсы сүзләре теркәлгән.

Билгеле булганча, телебезнең сүзлек хәзинәсендә ныклы урын алган гарәп-фарсы сүзләренең иң зур күпчелеге гасырлар дәвамында кулланылып килү нәтиҗәсендә бөтенләй диярлек “татарлашып” беткәннәр, һәм гарәп телен белмәүчеләр аларны ана теле сүзләре дип тә уйлыйлар.

Аларның татар әдәби теле кануннарынча үзләштерелүендә түбәндәге күренешләрне күрсәтеп була:

1. Гарәп-фарсы сүзләре, татар телендәге сингармонизм законына (рәт гармониясе) буйсынып, калын яки нечкә әйтелешкә күчкәннәр. Мәсәлән: *мумкин – мөмкин, мухбир – мөхбир, мөнаҗат – мөнәҗәт, наләт – нәләт, хукумәт – хөкүмәт, мәрхум – мәрхүм, хабәр – хәбәр, сахнә – сәхнә* һ.б.

2 Гарәп теленең үзендә сингармонизм законы юк, шуңа күрә бер үк сүздә алгы рәт (нечкә) һәм арткы рәт (калын)

сузыклары да килә ала. Мәсәлән: *китап, дәвам, гадәт, галим, галәмәт, ихтимал, тасвир, сәлам, бәла, һәлак* һ.б.

Шактый гына гарәп-фарсы сүзләре татар орфографиясендә үзләренең язылышларын саклап калсалар да, әйтелештә барыбер татар теленең сингармонизм законына буйсыналар, күбрәк нечкәртеләләр. Мәсәлән: *бәла – бәлә, гадәт – [гәдәт], гозер – [гозер], каләм – [кәләм], кадер – [кәдер], мәгариф – [мәгәриф], сәнгать – [сәнгәт], газиз – [гәзиз], канәгать – [кәнәгәт]* һ.б.

2. Гарәп телендә 6 сузык аваз бар. Шуларның өчесе озын [а], [у], [и]. Озын сузык авазларны язуда билгеләү өчен, гарәп әлифбасында, өч аерым хәреф бар: (әлиф)', (wау), (йа). Кыска сузыклар [а], [у], [и] аерым хәрефләр түгел, бәлки юлның өстенә яки астына куела торган өстәмә билгеләр, хәрәкәләр, (фәтхә: – [а, ә], кәсрә: – [и], замма: – [о, ө] ярдәмендә күрсәтелә. Озын һәм кыска сузыклар аерым фонемалар булып торалар һәм сүзләрнең мәгънәләрен үзгәртәләр. Мәсәлән: кыска сузык [а] урынына озын сузык [а] яки, киресенчә, озын сузык [а] урынына кыска сузык [а] әйтелсә, сүзнең мәгънәләре төрлечә була: ***галәм*** (дөнья, җир йөзе) – галәм (әләм, байрак), ***кабил*** – кабул итүче; булдыклы, сәләтле; булачак, киләчәк; ***кабил*** – Адәм балаларының берсенең исеме – кабил (төр, төркем), ***гаммә*** (халык, масса; гади халык; җәмгыятьтәге билгеле бер катлау, халык катлавы) – гаммә (ата-ана белән бертуган кыз кардәш, олы апа) һ.б.

[а, а] сузыкларының нечкә варианты булып, [ә, ә] авазы йөри, әмма ул фонема түгел, чөнки [а] яки [ә] әйтелүдән сүзнең мәгънәсе үзгәрми, шуңа күрә, мөгаен, кайбер вәгазьчеләр әлеге авазларның калын һәм нечкә төрләрен дә үзбелдекләренчә кулланалар. Мәсәлән: *адәм – әдәм, амин – әмин, садака – сәдака, расул – рәсүл, савап – сәвап, сәхабә – сәхәбә, харам – хәрам (хәрәм), шайтан – шәйтан, шөкрана – шөкранә, сәлам – сәләм, таһарәт – тәһарәт, руза – рүзә, важҗиб – вәҗиб* һ.б. Әмма татар орфографиясендәге тарихи-традицион принцип (сүзләрнең элеккеге язылышларын саклау) нигезендә, югарыда санап кителгән лексик берәмлекләр *адәм, амин, садака, рәсүл, савап, сәхабә, хәрам, шайтан, шөкрана, сәлам, тәһарәт, руза, важҗиб* язылышында кабул ителгәннәр, яки телнең үсеш-үзгәреш процессында шул рәвешне алганнар. Татар теленең аңлатмалы (1977-1981) һәм орфографик (1983) сүзлекләрендә дә шулай теркәлгәннәр. Шуңа күрә аларны шул язылышта файдалану дөресрәк булачак.

3. Гарәп теленнән алынган сүзләрдәге башка озын һәм кыска сузык авазлар да татар телендә кайбер үзгәрешләр кичерәләр. Мәсәлән: *хотбә – хөтбә, сабун – сабын, виҗдан – вөҗдан, минбәр (трибуна, кафедра, мәчеттә вәгазь сөйләү, намаз уку, дога кылу, җәмәгатькә мөрәҗәгать итү өчен имамга көйләнгән урын) – мөнбәр (менбәр), фитнә – фетнә, сирр – сер, җинн – җен, мәҗлис – мәҗлес, мухбир (хәбәрче) – мөхбир, мумкин – мөмкин, муэмин – мөэмин* һ.б.

Гарәп телендә 25 тартык аваз бар. Сүзнең калын яки нечкә әйтелеше татар телендә сузыкның калын яки нечкә булуына бәйле. Гарәп тартыкларының күбесе яки калын гына, я нечкә генә була, тартыклар язуда аерым хәрефләр белән билгеләнә, һәм сүзнең калын яки нечкә әйтелеше татар телендәге кебек сузык авазга түгел, бәлки тартыкка бәйле була.

Татар теленә кергән гарәп сүзләрендә тартык авазлар аерым үзгәрешләргә дучар булалар.

1. Рус язуына (кириллицага) нигезләнгән татар алфавиты, гарәп тартыкларын язуда, белдерү өчен хәрефләр җитмәү сәбәпле, төрлечә әйтелә торган фонемаларны бер хәреф белән генә күрсәтергә мәҗбүр итә. Мәсәлән, гарәп сүзләрендәге калын һәм нечкә әйтелешле [х, х], [т, т], [г, г], [к, к] орфографиядә “х”, “т”, “г” һәм “к” хәрефләре белән генә күрсәтелә. Гарәптәге калын әйтелешле [д], [з], сакау [з] һәм нечкә әйтелешле [з] тартыклары бары тик “з” хәрефе белән белдерелә. Мәсәлән, [рамадан] – рамазан, [дарар] – зарар, [зат] – зат, [зәхмәт] – зәхмәт һ.б. Шулай ук калын әйтелешле [с], сакау [с] һәм нечкә [с] өчен дә бер үк “с” хәрефе генә кулланыла: [сахнә] – сәхнә, [мәсәлән] – мәсәлән, [хисаб] – хисап һ.б.

2. Гарәп теленә генә хас булган тавышсыз тартык [һәмзә] татар телендә сүзнең башында һәм азагында бөтенләй укылмый, сүз уртасында килгәндә, хәзерге татар орфрграфиясендә ул “э” хәрефе белән билгеләнә. Мәсәлән: [тәэмин] – тәэмин, [муэмин] – мөэмин, [бәлаэ] – бәла һ.б.

3. Гарәп телендә сүз азагында яңгырау әйтелә торган тартыклар татар телендә саңгырау парлары белән алмашына: *гайд – гает, өмид - өмет, гайб – гаеп, шад – шат, мәктәб (әл мәктәбе) – мәктәп, китабун – китап* һ.б.

4. Гарәп телендәге куш тартыкларның берәрсе төшеп тә калырга мөмкин: *сиррун – сер, хассун – хас, хөрр - хөр, әһәммият - әһәмият* һ.б.

5. Кайбер алынмаларның аваз составы кыскара. Мәсәлән: *гакыл – акыл, гамәл - әмәл, хаҗәт - әҗәт, һәйбәт - әйбәт, һәвәс - әвәс, хәрам - әрәм, нәгъләт – нәләт, гыйбарәт – гыйбрәт, хафиз – абыз, хәлвә - әлбә, тәгам – тәм.* Бу кыскару нәтиҗәсендә кайбер мәгънәви үзгәрешләр дә килеп чыккан.

Шулай ук татар телендә кулланыла торган гарәп сүзләрендәге кайбер сүз алды артикльләре һәм сүз ахырындагы кушымчалар да төшереп калдырыла: *әл-ислах – ислах, әл мәктәбе – мәктәп, әл-зат – зат, китабун – китап, сиррун – сер* һ.б.

Гарәп сүзләрен сөйләмдә дөрес куллану өчен басым мәсьәләсенә игътибарлы булу мөһим: Мәгълүм булганча, татар телендә басым сүзнең соңгы иҗегенә төшә, ә гарәп телендә басым үзгәрүчән, ул сүздәге озын сузыкларга һәм иҗекләргә бәйле. Татар теленә кергән гарәп сүзләрендә басым үзгәрә, ул татар фонетикасы закончалыгына буйсынып, сүзнең соңгы иҗегенә күчә. Мәсәлән, *мәдрәсә – мәдрәсә, мәктәб – мәктәп, дәрс – дәрес, шагир – шагыйрь* һ.б.

Тел галимнәре күрсәтүенчә, гарәп сүзләре формасы һәм мәгънәсе буенча бербөтенлек үзенчәлегенә ия. Берсен икенчесеннән аерып карасаң, бу бөтенлек югала. Күренекле гарәп галиме, телче Ибне Җинни дә: “Гарәпләрдә сүз-максат һәм ниятләрне җиткерү алымы. Яңгырашы мәгънәсенә туры килсен өчен, алар сүзләрне игътибар белән сайлыйлар. Сүз белән эш итү алар өчен, иң беренче чиратта, мәгънә белән эш итү ул”, – ди [Сафиуллина, 2006:4].

Димәк, хөтбә-вәгазь телендә кулланыла торган һәр сүз, һәр гыйбарә үзенең дөрес әйтелеше, язылышы һәм мәгънәсе белән дә игътибар үзәгендә булырга тиешле. Юкса, вәгазьләрдә дә очрый торган “гает бәйрәме” килеп чыгарга мөмкин. Ә бит гарәп телендәге гайд (гает) шул ук “бәйрәм” дигәнне аңлата [ГТРАС, I, 1993:68].

3. Хәзерге татар әдәби телендә рус һәм рус теле аша Көнбатыш Европа телләреннән кергән сүзләр шактый зур урын били.

Борынгы төрки-татар бабаларыбыз элек-электән үк славян кабиләләре белән тыгыз бәйләнештә, ут-күрше булып яшәгәннәр. Күпьяклы багланышлар нәтиҗәсендә, төрки-татар теленә байтак

кына славян-рус сүзләре үтеп кергән. Мәсәлән, шулар арасында иң борынгылары, ягъни Казан ханлыгы яулап алынганчы ук кабул ителгәннәре: *арыш, сука, мүк, салам, буразна, уҗым, әвен, эскерт, кәбестә, борыч, ызба, бүрәнә, мич, матча, кәҗә, гөрәнкә, чиркәү* һ.б. [Ахунзянов, 1968:57-86].

Казан ханлыгы буйсындырылганнан соң, рус сүзләренең татар теленә үтеп керүе бик нык арта. Аннан соңгы чорда *бояр, указ, команда, округ, уезд, пошлина, почта, печать, манифест, генерал, рапорт, завод, чайник, сохари* һ.б. сүзләр алына [Ахунзянов, 1968:89-101]. Пугачев яулары заманында рус алынмалары аеруча күп керә. Россиядә капитализмның үсеше, уртак икътисади һәм сәяси тормыш, халык массаларында революцион аң үсү, рус пролетариаты, әдәбияты һәм мәдәниятенең тәэсире бу алынмаларның тагын да артуына китерә. Октябрь инкыйлабы татар халкының бөтен язмышын, беренче нәүбәттә, рус халкының яшәеше белән бәйләп куйды. Шуңа күрә алдагы дистә елларда рус алынмалары (һинд-Европа һәм интернациональ сүзләр белән бергә) кулланылмаган бер генә өлкә яки тармак та калмады. Мәсәлән: *анализ, автономия, адрес, атеизм, банк, вирус, ветеран, вокзал, герб, гигиена, демократия, закон, идея, институт, комиссия, конфликт, партия, олимпиада, радио, химия, грамматика, чек, теория, характер* һ. б. Алар моңа кадәр гасырлар дәвамында киң кулланылышта булган төрки-татар, гарәп-фарсы сүзләрен рәхимсез кысрыклап чыгардылар. Хәтта рус – Көнбатыш Европа алынмаларының кирәгеннән артык кулланылуы сизелә башлады. Сөйләм һәм тел культурасының соңгы дистә елларда рус алынмалары исәбенә нык артуы, гомумән, татар теленең яшәешенә зур куркыныч тудырды. Дөрес, бер телдә үз эчендә генә бикләнеп, аерымланып яши алмый. Әмма телнең дәверләр аша килгән бай сүзлек хәзинәсенә, аның гаять зур потенциалына зыян салып, телне кирәгеннән артык башка тел сүзләре белән чуарлау файдага китерми. Шуңа күрә дә, соңгы елларда мондый алынма сүзләрнең кайберләре яңадан татар әдәби теленең лексикасында тотрыклы урынын алган "элеккеге сүзләр" белән алыштырыла башлады. Мәсәлән, *республика – җөмһүрият, автономия – мохтарият, партия – фирка, съезд – корылтай, прогресс – тәрәккъыять (алгарыш), экономик – икътисади, интеллигент – зыялы (укымышлы), класс – сыйныф, редактор – мөхәррир,*

*промышленность – сәнәгать, власть – хакимият, закон – канун, врач – табиб, больница – хастаханә, санаторий – шифаханә* һ. б.

Һичшиксез, алынмаларга мөнәсәбәт мәсьәләсе һәр очракта конкрет хәл ителергә тиеш. Әмма бер нәрсә бәхәссез булып кала: телнең үзендә кирәкле сүз була торып та, аның урынына алынма сүз куллану урынсыз. Хәзерге икетеллелек шартларында тел, сөйләм әдәбе, милли телнең чисталыгы аеруча үзәк мәсьәләләрнең берсе булып тора. Ә кирәксезгә рус сүзләре кулланып сөйләшү әдәпсезлек, наданлык, үз ана теленә карата ихтирамсызлык икәнен бервакытта да истән чыгарырга ярамый.

Рус һәм һинд-европа телләреннән алынган сүзләрнең кулланылышы татар әдәби теле стильләрендә төрлечә. Хөтбә-вәгазьләр өслүбендә, аерым алганда, дини үгет-нәсыйхәтләрдә алар азрак кулланыла. Һичшиксез, кешелек яшәешенең барлык өлкәләрен дә колачлап алган Коръән аятьләренә, Мөхәммәд галәйһиссәләм хәдисләренә, башка шәригать кануннарына нигезләнеп, хөтбә-вәгазьләр сөйләгәндә, имам-хатыйбларга кайбер рус сүзләреннән һәм гыйбарәләреннән файдаланырга туры килә. Мәсәлән, вәгазь сәламәтлекне саклау, гыйлем-һөнәр алу, әхлакый тәрбия бирү, яман гадәтләрдән котылу турында бара икән, һичшиксез, аерым алынмалар да файдаланыла. Шундыйлардан хөтбә-вәгазь телендә түбәндәге алынма сүзләрне күрсәтергә мөмкин: *наркотик, организм, биология, поезд, машина, гашиш, героин, реклама, пиво, вич, диагноз, проблема, актив, директор, ксерокс, конституция, принцип, пессимизм, ветеран, лидер, республика, президент, класс, гимназия, университет, бизнес, пенсия, закон, миллион, эстафета, репрессия, фактор, компьютер, телевизор, интернет, группа, политика* һ.б.

Кайберләрен язма сөйләм үрнәкләрендә дә карап китик: Бүген бөтен дөньяда бер зур фаҗига бар, ул – *наркоманиянең* киң таралуы [Мирас, 2003, № 1:103]., Мөселман *лидерларының* һәм *теоретикларының* игътибарыннан базар икътисадының кайсы якка үсүе дә читтә калмый [ТК, 1996:22 август]. *Физика, химия, биология, математика* яки бүтән фәннәр – алар барысы да Аллаһының Җир йөзенә урнаштырган кагыйдәләрен өйрәтәләр [Фазлыев, 2005:11]. Хәмер арыганлыкны бетерми, көч тә өстәми, киресенчә, кеше *организмы* эшчәнлегенең сыйфатын киметә [Сабиров, 2012:101]. <...> бүген өч *миллионга* кадәр мөселман кешесе хаҗ кыла [ДК, 2013:285].

Шулай итеп, хөтбә-вәгазьләр теленең сүзлек составы гаять бай һәм үзенчәлекле. Дини эчтәлектәге нәсыйхәтләрдә гарәп-фарсы сүзләренә өстенлек бирелсә, дөньяви вәгазьләрдә, нигездә, төрки-татар сүзләре аерым очракларда, рус алынмалары да кулланыла.

Хөтбә-вәгазьләрдә дини төшенчәләрне белдергән, әмма актив кулланылыштан төшеп калган кайбер гарәп сүзләренең, гыйбарәләренең аңлатмалары яки бүгенге телебездә кулланыла торган башка мәгънәдәш төрләре бирелә. Мәсәлән, <...> Рәсүл Әкрәм өммәте өчен хак Тәгаләдән шәфәгать (яклау, химая) сораган [Мирас, 1998, № 12:85]. Аллаһ тарафыннан кичерелми торган иң зур гөнаһлар – көферлек (Аллаһка ышанмау) һәм ширек (күпаллалык) [Сабиров, 2012:66]. <...> бу рамазан шәриф Мөхәммәд өммәтенең фәлахи (рәхәт) мәңгелек белән кавышуы өчен сәбәптер [ДК, 2013:192].

***

Татар теленең лексик системасын үстерүдә һәм арттыруда билгеле булганча, берничә әһәмиятле юнәлеш бар: 1) телнең үз потенциалыннан файдаланып, сүз ясау чараларын нәтиҗәле куллану; 2) кайчандыр актив кулланылышта булган лексикадан файдалану; 3) башка телләрдән сүзләр алу.

Телебезнең сүзлек составы һәрвакытта, барыннан да элек, үзенең сүз ясау чаралары нигезендә үскән һәм үсә бара. Яңа мәгънәләргә ия булган сүзләр ясау телнең сүзъясалыш системасын тәшкил итә. Аның нәзари һәм гамәли нигезләре төрле грамматикаларда, махсус хезмәтләрдә, аерым фәнни мәкаләләрдә күпкырлы һәм тәфсилле өйрәнелгән, аның алымнары һәм методлары күрсәтелгән.

Татар телендә сүзъясалышының түбәндәге ысуллары бар: 1) фонетик ысул; 2) кушымчалау ысулы; 3) сүзләр кушылу; 4) сүзтезмәнең кушма сүзгә күчүе; 5) Сүзтезмәнең кушымча алып кушма сүзгә күчүе; 6) конверсия (лексик-грамматик ысул); 7) лексик-семантик ысул; 8) аббревиация (кыскартылмалар ясалышы). Шулар арасында кушымчалау, сүзләр кушылу, сүзтезмәләрнең кушма сүзгә күчү ысуллары иң киң кулланылучы ысуллардан санала [Ганиев, 2000:14].

Хөтбә-вәгазьләрнең лексикасында да кушымчалау, конверсия, сүзләрне кушу, сүзтезмәләрнең кушымчалар алып кушма сүзгә күчүе һәм лексик-семантик ысуллар аеруча нәтиҗәле. Бу өслүбнең

этрафлы сүзләр хәзинәсендә төрле структураларга караган йөзләрчә, меңнәрчә лексик берәмлекләр тупланган.

Аларның бик төрле модельләрен без, бигрәк тә, күпсанлы исемнәр, фигыльләр, сыйфатлар һәм башка мөстәкыйль сүз төркемнәре ясалышында күрәбез. Мәсәлән: тереклек, сәламәтлек, кешелек, миһербанлылык, ризалык, монафикълык, илче, вәгазьче, риячы, бәла-каза, вәгазь-нәсыйхәт, әҗер-савап, Аллаһ бәндәсе, нәфес колы, җан иясе, тәүфикъ, һидаять; пакъләү, буйсыну, чумдыру, ярлыкау, танып белү, гыйлем алу, гайбәт сату, шөкрана кылу, яхшылык кылу, ярдәм итү, фарыз кылу, риваять итү, кәсеп итү, җавап бирү, бәхиллек бирү, тәһарәт алу, иңә башлау, исраф булу, васыять әйтү, мәкруһ күрү, насыйп әйләү; сөекле, мәрхәмәтле, бәрәкәтле, гөнаһлы, имансыз, кимчелексез, хатасыз, ачлы-туклы, мөкатдәс, илаһи, фани, дөньяви һ.б.

Исемнәр дөньясында аеруча киң кулланылышта булганнары: Аллаһ, Коръән, Пәйгамбәр.

Коръән Кәримдә Аллаһы Тәгаләнең 99 исеме һәм асыл сыйфатлары булуы турында әйтелә. Аллаһ – шулар арасында иң беренчесе. Аллаһы Тәгаләнең бүтән исемнәре аерым-аерым бер мәгънәне аңлатуда дәлил булып торалар. Ә бу исем Аның бөтен сыйфатларын берләштерә. Мәсәлән, Аллаһы Тәгаләнең “әл-Мәҗид” сыйфаты аның бары тик “данлы” сыйфатын белдерә. “Аллаһ” исеме исә Аның 99 исеме белдергән барлык мәгънәләрне үз эченә алган [Мирас, 2003, № 3:106].

Хөтбә-вәгазьләр өслүбендә иң күп кулланылучы Аллаһ атамасыннан тыш Аллаһы Тәгалә, Раббы, Аллаһ Раббы, Хак Тәгалә, Аллаһы сүбехәнә вә Тәгалә, Гаршел-Газыйм Раббысы, җиде күк раббысы, Раббулгаләмин хәзрәтләре, Бөек хуҗа һ.б. аталышлары бар. Мәсәлән, акылның нуры – Аллаһыдан килер [ТМК, 2008: 178]. Һәрнәрсәдән элек Аллаһы Тәгаләнең үзен бәндәнең көче җитәрлек рәвештә белү – һәрбер бәндәгә фарыз [Мирас, 2003, № 3:106]. Ислам галимнәре әйтүенчә, балигъ яшенә җиткән һәрбер мөселман Аллаһы Тәбарәкә вә Тәгаләнең 14 сыйфатын белергә тиеш, аларны белү Аллаһы Тәгалә һәм Аның сыйфатлары турындагы ялгыш фикерләрдән, дөрес булмаган карашлардан саклый [Сабиров, 2012:84].

Коръән (гар. – яттан уку, яттан сөйләү) – Ислам фәлсәфәсендә Изге Китап. Илаһият фәнендә аның 55 атамасы бар дип күрсәтелә: Коръән-Кәрим яки Коръәни-Кәрим (кәрим – хөрмәтле, кадерле,

бөек, газиз), Коръән-Мәҗид (мәҗид – данлы, мактаулы), Коръән-Газим (газим – алдан уйлап куючы, исәпләүче, ниятләүче; батырчылык, кыюлык итүче; баручы, юл күрсәтүче), Китабуль зикер (зикер – искә алучы, искә төшерүче), Китабуль хикмәт, Китабуль-мөбин (мөбин – дөреслек белән ялганны аеручы), Өммелкитаб (Китаплар анасы), Форкан (Коръән), Кәлямулла (Аллаһ сүзе, Коръән), Мосхәф шәриф (кадерле Коръән) һ.б.

Хөтбә-вәгазьләрдә пәйгамбәребезнең төрле атамалары, шулай ук алар аерым сүзләр, сүзтезмәләр, эпитетлар белән күрсәтелә. Мәсәлән: Пәйгамбәр, Мөхәммәд Расүлуллаһ пәйгамбәр, Мөхәммәд галәйһиссәлам, Расүл (Рәсүл), Расүсуллаһ, Аллаһ илчесе, Пәйгамбәрләр пәйгамбәре, Ислам пәйгамбәре, Хәзрәте Мөхәммәд, Мөхәммәд Мостафа (мостафа – сайланган, сайлап алынган), Расүл Әкрам (бик хөрмәтле илче; бик затлы пәйгамбәр) һ.б. Бигрәк тә Мөхәммәд пәйгамбәр, Расүл атамаларының киң кулланылышын күрсәтергә мөмкин. Кайбер вәгазьләрдә Расүлуллаһны (Аллаһ илчесе) әфәнде сүзтезмәсендә бирү дә күзәтелә: "Янә бер көн Расүлуллаһ (с.а.г.в.) әфәндебезгә Тәмил кабиләсенең элегрәк килгәләгән берәү керде" [Мөхәммәтшин, 2004:99]. Әлеге сүзтезмәдә әфәнде сүзенең "госманлы төрек телендәге "әфәнди"дән алынып, "галим, дини укымышлы" мәгънәләрендә хөрмәтләү, олылау өчен кулланылган булуын әйтергә кирәк [Әхмәтьянов, 2001:30-31]. <...> Раббыбызның әүвәлге изге китапларының беренче нөсхәләре барлык әдәмнәргә ахырзаман пәйгамбәре булып Аллаһының расуле Мөхәммәд Мостафа галәйһиссәлләм икәнен дәлил итәләр [ТМК, 2008:83]. Юлларның иң хәерлесе Хәзрәте Мөхәммәд (с.г.в.) әфәндебезнең юлыдыр [ТМК, 2008:180]. Мөхәммәд пәйгамбәр атамаларыннан соң салләллаһү гәләйһи вә сәллам гыйбарәсе кулланыла, язмаларда ул беренче хәрефләре белән (с.а.г.в.), (с.г.в.с.), (с.г.в.) дип кыскартылып бирелә.

Гомумән, морфологиягә кагылышлы күптөрле стиль үзенчәлекләре сүз төркемнәрендәге категорияләр һәм аларның ясалышы белән тыгыз бәйләнештә тора.

Исемнәрнең, фигыльләрнең, сыйфатларның, рәвешләрнең, алмашлыкларның һ.б. сүз төркемнәренең ясалышы, андагы мәгънәләр белән бәйләнешле тел-стиль күренешләре грамматик стилистикада үзенә бер урынны алып торалар. Алардан дөрес һәм урынлы файдалану хөтбә-вәгазьләрне бай эчтәлекле, тулы һәм мәгънәле итә.

## Көнкүреш сөйләм стиле

Көнкүреш сөйләме – иң катлаулы жанрларның берсе. Аның катлаулылыгы шуннан гыйбарәт: ул башка сөйләм төрләренә карағанда, аңсыз рәвештә кулланугa нигезләнгән. Бу аралашу киң күләмле. Көнкүреш сөйләме этикетның күп төрен һәм төрле катлам сүзләрен үз эченә ала. Шулай ук көнкүреш сөйләме гадәти, артык иркен, кабатлаучан шартларда тормышка ашырыла.

Көнкүреш сөйләме берләшмәнең тормыш дәрәҗәсенә, гореф-гадәтләренә, йолаларына һәм тотрыклы үрнәкләренә бәйле. Ул киң кырлы көнкүреш чынбарлыгының эчтәлегенә туры килә.

Бер яктан, көндәлек тормышта без күнегелгән рәвештә аралашабыз. Түбән хисле һәм психикасы үсеш алмаган кешеләр өчен көндәлек тормыш аралашу даирәсе түгел, чөнки аның көнкүрешендә үзгәрешләр күзәтелми. Ә психикасы тотрыклы һәм югары дәрәҗәдә хисле кешеләр, киресенчә, көндәлек тормышта аралашырга телиләр һәм моның өчен күп сәбәп табалар. Кечкенә төркемнәрнең көч-егәренә бәрабәр билгеле бер аралашу җирлеге барлыкка килә. Көнкүрештәге төркем яки гаилә башлыкларының риторик һәм оештыру осталыгына бәйле рәвештә, аралашу уңайлы яки конфликтлы булырга мөмкин.

Башка яктан караганда, көнкүреш сөйләмгә, башка сөйләм төрләре белән чагыштырганда, иҗтимагый мөнәсәбәтләр дә аз йөкләтелмәгән. Әйтеп үтелгәнчә, бу аралашуда төп максат булып, кешенең берләшмәдәге хокуклары һәм аларга яраклашуы тора. Аралашып, кешеләр бер-берсен таныргa омтылалар. Һәрбер кеше дә билгеле бер дәрәҗәгә омтылып яши һәм ул шул берләшмәдән хуплау, җөпләү сүзен көтә.

Барысына да тирә яктагылардан игътибар, мактау сорала. Дәрәҗәнең какшавы бик авыр кабул ителә һәм кеше үзенә булган ихтирамны кире кайтару өчен көрәшә башлый. Әгәр дә әйләнә-тирәдәгеләр бу аралашуның эчтәлеген аңламасалар, көнкүрештә каршылыклар туа.

Көнкүреш аралашуының ничек уңайлы узуын беркем дә белеп бетерми. Шулай да, көнкүреш сөйләм телен яхшырта алырлык берничә фикерне ачыклап үтик:

- әдәплелек, дин һәм миһербанлык карашларына нигезләнеп, үзеңә ничек карауларын теләсәң, әйләнә-тирәдәге кешеләргә дә шундый караштa булу;

• киң кулланылыштагы көнкүреш сөйләменә аңлы мөнәсәбәт булдырырга, берләшмә әгъзаларының шәхси тормышлары сөйләмнәрендә чагылуын аңларга, чөнки сүзләр эчке халәтне куәтлиләр, аңа йогынты ясыйлар;

• көнкүрештә аралашуга иң яхшы күрсәтмә: игелеклелек – барлык кешеләрнең дә бәхете өчен тырышу. Шул ук вакытта артык ярату, мактау да куркыныч. Шундый әйтемнәр дә бар: "Мәхәббәттән нәфрәткә – бер адым", "Кешене мактап хур итәләр";

• һәрбер кеше аерым бер шәхес буларак катлаулы, башкаларга рухи дөньясын кинәт кенә ачып салмый. Ул хөрмәтләүгә, аңлауга лаек;

• көнкүреш сөйләме ярарга тырышып, уйнап сөйләшү түгел, ә хисле, ихлас, ихтирамлы сөйләшү булырга тиеш;

• башкаларга нәрсә әйтсәң һәм нинди гамәл кылсаң, үзеңә дә шуның әйләнеп кайтасын һәрвакыт истә тоту файдалы.

## Уку-укыту сөйләменең үзенчәлекләре

Уку-укыту сөйләме – аралашуның киң таралган рәвеше. Бездә барысы да өйрәтә һәм бөтен ил укый. Уку-укыту сөйләменең максаты – белем бирү, күнекмәләр булдыру һәм осталыкка омтылыш тәрбияләү. Билгеле булганча, белем бирү тикшерүдән аерылгысыз. Шуңа күрә белем бирү даирәсендә белемнең эчтәлеге күп тапкырлар тапшырыла. Әлеге белем иҗтимагый тормышта кабул ителгән карашлар оештыруга юнәлдерелгән, аннан соң ул фикерләр, гамәлгә кадәр үсеп, инануга әверелеп, кеше белән идарә итәчәкләр.

Укыту-өйрәтүдә үрнәк фикер (динамик стереотип), булдыру гомуммәдәни кыйммәткә ия. Укытуның эчтәлеге һәм стиле белем бирү концепцияләре һәм программалары белән билгеләнә, аларның нигезен дәреслекләр тәшкил итә. Укыту ярдәмлекләре текстлы нигез булып торалар. Алар җирлегендә аралашу тормышка ашырыла.

Уку-укыту стиле, халык белән аралашу кебек үк, буйсынучан һәм гражданлык халәтендә була. Теләсә нинди аңлау рәвеше ике компонентны берләштерә:

1. Эш-гамәлнең гомуми чагылышы һәм эшчәнлек максаты юнәлдерелгән шәхеснең белем үзләштерүдәге урыны.

2. Максатны тормышка ашыру ысулларын белеп куллану.

Гражданлык аңы кешенең белем даирәсендә дөрес юнәлеш табуын күз алдында тота. Бу очракта кеше белем эчтәлеген ачыклаган (үзенә нәрсә кирәген үзе белә) максатын билгели, дөрес карар кабул итә, үз теләге һәм хокук нормаларына туры китереп, билгеле бер алым-чаралар ярдәмендә белем үзләштерүне тормышка ашыра.

Буйсынучан стереотип читтән тагылган шартларга һәм программалаштыруга нигезләнә. Кешегә әмер бирелә. Максатны, нинди генә юл белән булса да, тормышка ашыру өчен, аңа белем кирәк.

Гражданлык халәтендә укытуның стиле укучыга мәдәни белем бирүне тәэмин итә, билгеле бер илнең гражданы булуны, ватанпәрвәрлекне аңлата.

Әлеге типта белем үзләштерү юлларын аңлау укыту барышының төп мәсьәләләрен хәл итә:

- укытучыга үзенең образын ничек гәүдәләндерергә;
- укучы моделе нинди, укытучының аңа мөнәсәбәте нинди булырга тиеш;
- укытуның эчтәлеге нәрсәләрне берләштерә, укыту сөйләмендә нинди максатлар куела;
- белем бирүне һәм аның сыйфатын исәпкә алуны ничек оештырырга;
- сөйләмнең хисси төзелеше нинди кыйммәтләр белән билгеләнә;
- уку-укыту сөйләме ничек оештырыла.

Уку-укыту сөйләме, ораторикадан аермалы булган, гомилетика дигән сөйләм төренә керә. Гомилетика бер үк ораторның бер үк аудиториядә күп тапкырлар эшләве белән үзенчәлекле. Шуңа күрә укыту даирәсендә эшләүче оратор (укытучы) тотрыклы абруйга (авторитетка) мохтаҗ. Абруй, дәрәҗәсенә карап, аралашу нәтиҗәсенә – уңай яки тискәре – йогынты ясый.

Гражданлык тибындагы аралашуда укытучы белем бирүченең тотрыклы образы булып тора. Буйсынучан аралашуда укытучы – белем бирүче һәм дәүләт вәкиле сыйфатында. Аралашу халәте аның образына да тәэсир итә. Укыту сөйләмендә оратор образы, белем бирүче үрнәгенә нигезләнгәндә, аралашу чикләрен киңәйтә. Безнең илдә укучыларның тәртип кагыйдәләренә буйсынырга (яки буйсынмаска) дигән ныклы карашлары белем бирүдә аралашуны кыенлаштыра.

Укытучының идарә итү үрнәкләрен берләштергән абруе, тәртипкә салынган мөнәсәбәт булганда, аралашу максатын тормышка ашыруны җиңеләйтә, ләкин эчтәлек ягыннан аралашуны чикли. Кагыйдә буларак, ораторның конкрет образы укыту сөйләме кысаларында бик күп күрсәткечләр нигезендә оеша.

## *Уку-укыту эшчәнлегендә укытучының аралашу манерасы (стиле)*

Укытучы (оратор) образына (үз йөзен оештыруга) белем бирү мохите (җәмгыять), эчке дөньясы һәм шәхси карашлары тәэсир итә. Укытучы холкының әһәмиятле иҗтимагый якларын тышкы шартлар барлыкка китерә. Ә эчке таләпләр тышкы мөмкинлекләрне үзгәртә, аларның кушылуы нигезендә образ эчтәлеге оеша.

Укытучының гомумиләштерелгән образы (үз-үзен тоту стиле) түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

- уку-укыту барышында укытучы үз ихтыярын тормышка ашыра. Бу укучыларның да, укытучының да эш-гамәлләрен программалаштыра;
- укытучы укучыларның игътибарын туплый, максатчан биремнәр оештыра, билгеле бер хисси атмосфера тудыра;
- җәмгыятьтә һәм уку-укыту эшчәнлегендә укытучы, интеллигентлар берләшмәсе исеменнән чыгыш ясаганлыктан, үзен тыныч һәм гади тота;
- укытучы үз-үзенә ышанычы булганда гына укучыларга тәэсир итә һәм аларда да шул сыйфатны булдыра ала;
- уку-укыту эшчәнлегендә, куелган максатларны тормышка ашыру өчен, укытучы оста аралаша, тәвәкәллек үрнәге күрсәтә, сорауларга җавап биргәндә югалып калмый;
- аралашуның нәтиҗәлелеге укытучының укучылар белемен билгели белүе һәм аудиториядә барлык кирәкле мөмкинлекләрне оештыра алуы белән бәйле;
- укытучы аудиториядә үз-үзен тоту кагыйдәләрен һәм сөйләм культурасын саклый. Аның абруе сыйныф эшчәнлегенә нык тәэсир итә.

## *Укыту барышында – аудитория*

Укыту сөйләменең үтемлеге күп кенә укытучылар өчен мөһим мәсьәлә. Алар сөйләм телен гомер буе камилләштерәләр, чөнки укучылар коллективының белем дәрәҗәсе өчен укытучы җавап бирә.

Укытучының гражданлык хисе аудитория белән белем нигезендә берләшүен таләп итә. Укытучыдан укыткан фәненә, дәресләренә ихлас мөнәсәбәтне көтәләр. Аның төп бурычы булып мондый аудиториядә белемгә мохтаҗ булганнарга ярдәм итү тора. Укыту-аралашу, аудиториядә гражданлык тибы булса, үзара ярдәмләшү мөнәсәбәтләрен күздә тота. Аннан башка тиешле аралашу барып чыкмаячак.

Буйсынучан аудиториядә укытучы гомуми белем тапшыручы булып тора. Андый аудитория укытучыдан эчкерсезлек көтми, ул үзара ярдәмләшү турында уйламый. Аудитория үзе өчен куркыныч булмаган мөнәсәбәткә омтыла. Аудиториянең буйсынучан тибы укыту тәртипләрен нык саклауга нигезләнгән. Аның нигезе аңга да, аңсызлыкка да барып тоташа.

Аудиториянең танып белү теләге мөмкин булган ихтыяр-сызлаулардан котылу теләге белән алышына. Безнең илебездә яхшы укучыларның күбесе белемгә түгел, ә төрле конфликтлардан котылырга, нейтраль урында булырга омтыла. Нәтиҗәдә, аралашу барышында бер-берсенә каршы куелган уен барлыкка килә: тәртип һәм белем. Ләкин алар бер-берсенә тәңгәл түгел.

Буйсынучан халәттәге структурадан гражданлык тибына күчү күпкә катлаулы. Моның өчен укытучыларның образын гына түгел, ә укучы образын үзгәртергә кирәк. Күренеп тора, бу эшчәнлек бик озакка сузылачак. Ул шәхеснең аңлы һәм аңсыз рәвештә оешкан асылы белән бәйле. Шуның өстенә, яңа мәдәни һәм аралашу типларының барлыкка килүе, иҗтимагый тормышны яңача оештыруны таләп итә. Гражданлык тибы, яңа таләпләр җирлегендә, фикерләүдә һәм гамәл кылуда да яңалык таләп итә.

Укыту аудиториясен оештыруда идеология ярдәменә генә исәп тотып булмый. Үз-үзеңне тоту, мәгълүмат кабул итү үрнәкләре авыр оеша, бу рухи һәм акыл эшчәнлеге фәндә әле аз өйрәнелгән. Шуны әйтергә мөмкин, үрнәк эчтәлек оешуның үзенчәлекле өлеше аңсыз гамәлләргә бәйле.

Тыңлаучыларның – укучыларның – үзгәрүе өчен безнең тормышыбызда һәм укытуда бирелгән эчтәлеккә табигый рәвештә

тәэсир итәрлек уңай үзгәрешләр кирәк. Бу өлкәдә бәхәскә, киңәшкә генә корылган педагогик технологияләр белән үзгәрешләргә ирешү мөмкин түгел.

## Рәсми-эшлекле аралашу стиле

Соңгы вакытта, базар икътисады үсешенә бәйле рәвештә, рәсми-эшлекле сөйләм төре киң аралашу рәвешенә әйләнде.

Хәзерге вакытта Россиядә рәсми сөйләшүләр күп алып барыла, тик аларның стиле сөйләм культурасы нормаларыннан ерак тора. Эшлекле аралашу сөйләме − иң максатчан оештырылган сөйләм. Эшлекле сөйләмдә катнашучыларның әңгәмәсе, иң беренче чиратта, соңгы нәтиҗәгә юнәлгән. Бу төр сөйләшүләрнең ахыры матди байлыклар күчеше белән бәйле чишелеш булганлыктан, сөйләм нәтиҗәсе киләчәктә булачак матди уңышларны әзерли.

Эшлекле сөйләм, аралашу төре буларак, иң каршылыклысы да. Аның каршылыгы тормыш-көнкүреш, аның матди байлык җитештерү, үзләштерү законнары һәм кешеләрнең бер-берсенә йогынтыларын идеаль оештыра алу-алмаулары белән бәйле.

Үзара ярышның катгый законнары эшлекле аралашуга ихтыяҗ тудыра. Карар кабул итүче кешенең нәтиҗә сүзе һәрвакыт субъектив була, чөнки эшлекле стиль шәхсән кызыксынуны таләп итә. Ә ул, үз чиратында, сөйләшүләрдәге аралашуны тамырдан үзгәртергә мөмкин.

Рәсми дәрәҗәдә дә эшлекле сөйләшүләр алып бару осталыгы өстәмә табыш чыганагы булып тора, ә өстәмә табыш заманча технологияләрнең үсешен тәэмин итә.

Эшлекле сөйләшү табыш китерә торган киңлекне, шәхси абруйга ирешүне берләштерә һәм бу эшчәнлекне билгеле бер системага сала торган идарә итү җирлеге. Эшлекле аралашуда сөйләм предметы булып кешеләрнең үзара мөнәсәбәте тора.

Эшлекле сөйләмнең охшаш өлешләре түбәндәгеләр:

- сөйләмдә катнашучыларның һөнәри белемлеге. Эшлекле кеше беренче сүзләрдән үк кем белән аралашуын аңлый;
- аралашучылар арасында һәрвакыт аныклык, тормышчан фикер һәм ачыклык булу;
- дәрәҗәңне, урыныңны һәм иптәшләрең (бизнес партнерлары) арасында барган сөйләшүне аңлау, бәяләү;

• синең белән сөйләшүче кешенең иҗтимагый һәм рухи дәрәҗәсенә, сөйләменең эчтәлекле юнәлешенә туры килерлек аралашу тирәлеге оештыру;

• сөйләшүдә үзара ышаныч мохите булдыру;

• сөйләшүчене аңларга тырышу, аның аралашудан көткән уңай фикерләрен сизү, начар уйларын юкка чыгару яки йомшарту;

• сөйләмне рухланып, дәлилләр китереп алып бару, эшлекле тәмамлау күнекмәләрен булдыру.

## Рәсми-сәяси аралашу стиле

Рәсми-сәяси аралашу иҗтимагый өлкәгә хас. Ул төрле темаларда була: хакимият оешу, сугыш һәм тынычлык, террорчылык белән көрәш, экономик үсеш һәм башкалар. Демократик сайлау шартларында сайлау мәсьәләләренә багышланган темаларга аралашуны да рәсми-сәяси аралашу дип аерып күрсәтергә була. Мөһим иҗтимагый-сәяси мәсьәләләрне хәл итү сәяси аралашу дәрәҗәсендә барганлыктан, ул, кагыйдә буларак, җаваплы һәм гражданлык рәвешендә була. Сәяси аралашу өчен радио һәм телевидениедә дә аерым вакыт каралган; иң яхшы күп урынлы заллар файдаланыла; үзара тәэсир итешүнең, йогынтының эчтәлекле рәвеше буларак, пропаганда, агитация, реклама киң җәелдерелә, киң масса халык туплана-оештырыла. Икенче яктан караганда, дөньяның күпчелек илләрендә, рәсми-сәяси аралашу эчтәлексез һәм әһәмияте дә шулкадәр генә дигән фикер яши. Бу капма-каршылык сәяси аралашу стиленең идеология белән сугарылуыннан килә. Идеология ул − аерым мәнфәгатьне күпсанлы тыңлаучыларга таратуга нигезләнгән аралашу эчтәлеге. Рәсми-сәяси аралашуны барлыкка китерүдә фикер-карашларның авторлары, һәрвакыт, бу фикерләр иҗтимагый һәм хәтта гомуми кызыксыну тудыралар дип күрсәтергә тырышалар. Сәяси җитәкчелек вәкилләре үз карашларын партия тарафдарларының барысының кызыксынуы дип исбат итәләр. Хакимият гамәлләренең оешмаганлыгын каршы як партия вәкилләре исбатларга омтыла һәм башка юл тәкъдим итә. Бу яки теге партия вәкилләре нык ышаныч белән үз җитәкчеләренең генә хаклыгын белдерәләр. Әйткәнебезчә, хәзерге җәмгыятьтәге аралашу стилен ике төргә бүлеп карарга була: гражданлык һәм буйсынучанлык.

Гражданлык стиле демократик сәяси система барлыкка килгәндә үсеш алган. Гражданлык диалогы киңлегендә барлыкка

килгән карашлар һәрдаим ныклап урнашкан политик символ да була ала. Бүгенге җәмгыятьтә аралашу таләбенә сәяси җитәкчеләрнең ихтыяҗына буйсыну стиле җавап бирә. Аның максаты – оратор карашларын кабул итүдә сәяси җитәкчелекне кызыксындырган демократик, гражданлык формалары булдыру. Буйсынып аралашу рәвеше, гадәттә, бәхәсле характерда.

Кагыйдә буларак, буйсынучан аралашуда әңгәмә рәвеше симметрияле түгел. Дәлилләнгән килешү җитәкчелек тарафыннан тудырыла. Тотрыклы сәяси режим аны гомум кабул ителгән аралашу кагыйдәләренә әверелдерә. Җитәкчеләр бәхәс кануннары буенча аралаша, оппонентларын да аралашканда бертөрлелек, түземлелек үрнәкләренә буйсындыра.

Бүгенге көндә сәяси аралашу үрнәкләренең һәм иҗтимагый максатларның үзара нинди мөнәсәбәттә булуларын төгәл генә әйтеп тә булмый.

Бер яктан, аралашу оештыруда килешүчәнлеккә омтылыш беркемдә дә шик тудырмый. Әлеге карашлар һәм үрнәкләр иҗтимагый аңда урын алдылар. Икенче яктан, җәмгытьтә гражданлык үрнәкләрен үстерә торган формаль нигез булуга да карамастан, сәяси чынбарлык халык белән аралашу төрләренә каршылыклы мөнәсәбәттә.

## Өндәмә сөйләме стиле

Аңлату, төшендереп бирү (пропагандалау) һәм өндәү (агитацияләү) халык алдындагы сөйләмнең төп вазифалары булып тора.

Тәрбия һәм укыту барышында кешедә мәдәниятнең билгеле бер рәвешен яңарта торган, иҗтимагый үрнәкләр җыелмасы туплана. Аңлату һәм өндәмә ярдәмендә чынбарлыктагы үрнәкләр үзгәрә һәм күпмедер вакыттан соң иҗади егәрлеккә, көчкә әверелә.

Төшендерү яңа ысулларның элеккеләренә караганда мөһимрәк икәнлеген аңларга ярдәм итә. Өндәмә яңалыкка каршы эшчәнлекләрне үзгәртергә әзер булган омтылыш, теләк барлыкка китерүгә юнәлтелә. Буйсынучан аралашуда өндәмә сөйләмне сәяси-дини максатта кулланалар, ә ирекле аралашуда – реклама нигезендә. Өндәмә сөйләме һәрбер тыңлаучыга һәм бербөтен берләшмәгә юнәлтелгән була. Реклама адрессыз, абстракт эндәшкә нигезләнә, теләгән кеше үзе сайлап алыр дип фаразлана.

Уку-укыту барышында укучыларның игътибарын билгеле бер эшчәнлеккә юнәлтү омтылышы әлеге сөйләмнең төп максаты булып тора. Өндәмә сөйләмнең нәтиҗәлелегенә ирешү өчен түбәндәге кагыйдәләрне үтәргә кирәк:

- сөйләмнең кереш өлеше аерылып торуга мохтаҗ, башыннан ук өндәмә ачык, аңлаешлы, билгеле булырга тиеш. Кереш өлешнең структурасына кереш кисәтүләр, ораторның максатларын әйтүе, аңлатмалар, кыскача эчтәлек керә;
- өндәмә сөйләме халык (кечкенә аудитория) үзенчәлекләрен җентекле рәвештә исәпкә алуны таләп итә. Аудиториянең составы, аның мөмкинлекләре, кәефе, хисси халәте, сөйләм эчтәлегенә һәм чыгыш ясаучыга булган мөнәсәбәте – болар барысы да аралашуның шартлары;
- өндәмә рәвешендәге аралашуда әңгәмә элементлары булу мөһим. Өндәмә сөйләменә күбесенчә, театрлаштырылган әңгәмә туры килә. Тыңлаучыларның репликалары ораторга тотрыклы бәйләнеш һәм хисси бердәмлек халәте булдыруда ярдәм итә;
- тыңлаучыларга йогынты нәтиҗәле булсын өчен чыгышның башында үзара аңлашу халәте булдыру шарт. Бу халәт сөйләм тезисын уңай бәяләүне тәэмин итә;
- үзара аңлашу булдыру өчен түбәндәгеләрне истә тоталар: эчтәлеккә карата уңай мөнәсәбәт оештыру, тыңлаучыларны оратор тәҗрибәсен үзләштерүгә җәлеп итү; тыңлаучылар өндәмәгә каршы мөнәсәбәттә булган очракта, ораторга һәм сөйләмгә карата килешүчәнлек булдыру, хезмәттәшлеккә теләк уяту. Бу максатны тормышка ашыруның иң яхшы чарасы − шаяртып алу;
- көлкеле шелтәләүләр (искәрмәләр) куллану аларның урынлы булуын таләп итә. Оратор теге яки бу тойгылы мисалларның итагатьле булуларын катгый тикшереп торырга тиеш;
- тискәре мәгълүмат куллану соралмый, әмма кирәк очракта, тыңлаучыларның өндәмәне ни рәвешле бәяләүләренә һәм хис халәтләренә игътибарны көчәйтү мөһим;
- өндәмә чыгышында ораторның образын (йөзен) хаклыгына инанганлыгы, эчкерсезлеге, эш-гамәлгә шәхси әзерлеге, төгәллеге һәм тәвәккәллеге билгели.

## Үзләштерелгән белемнәрне мөстәкыйль тикшерү өчен сораулар һәм биремнәр

1. Педагогик риторика – уку-укыту барышында мөгаллимнең аралашу сәнгате һәм, тәҗрибә тапшыруны камилләштерү максатыннан, һөнәри аралашу фәне. Бу очракта риторика өйрәнү объектымы, әллә өйрәтү чарасымы?

2. Укучының белемгә омтылышын үстерү, уку эшчәнлеген иҗади оештыру нинди максатны күзаллый?

3. Мөгаллим-шәкерт аралашуында сөйләм осталыгына ирешү, сөйләм сәләтен үстерү юллары:

1) тәҗрибә һәм сиземләүгә таяну;

2) һөнәри аралашу алымнарын үзләштерү (төгәллек, аныклык, кыскалык, аралашу компетенциясе, адресатны тоемлау);

3) аралашу кагыйдәләрен үтәү;

4) аралашуга алдан әзерләнү (дидактик материал сайлау, сөйләм структурасын уйлап кую, конспект булдыру) – җөенке рәвештә аңлатыгыз.

4. Уку-укыту сөйләменең мәгълүматлыгына һәм өндәмәлегенә кагылышлы таләпләрне санагыз, аңлатып үтегез.

5. Аралашуда әйдәүче буларак, мөгаллим:

- тапкыр һәм мавыктыргыч сөйләме ярдәмендә аудиториянең кызыксыну даирәсен билгели-тәрбияли. Тик укытуда кызыклы мәсьәләне сайлап алу мөмкинлеге чикләнгән, чөнки тема – уку планында, эчтәлеге – программада билгеләнеп куелган. Үтелгән теманы ничек кызыклы итеп үстерергә, яңа теманы ничек кызыклы итеп аңлатырга?
- бергәләп фикерләү, иҗатташлык мөнәсәбәтләре урнаштыра. Бу очракта, өйрәтү нәтиҗәлелеге нәрсәгә бәйле?
- әһәмиятлесен кабатлап тора. Хәрефен-хәрефкә кабатлаумы, әллә лексик-грамматик синонимнарга таянып кабатлау нәтиҗәлерәкме?
- мәгълүматның төп фикерен, әһәмиятле өлешен аерып куюда ярдәм итә. Калыплашкан лексик чаралар ярдәмендә төп фикерне ассызыклауга мисаллар китерегез.
- тәңгәлләштерү алымын куллана. Тәңгәлләштерү алымын куллануда мөгаллим фикер эзлеклеген җуймаска тиеш. Шул хакта җәенкерәк итеп сөйләгез.
- мәгълүматны өлешләп тапшыра: «Сөйләм сегментлыгы» алымының отышлыгын аңлатыгыз.

6. Дини белемнәрнең аңлаешлыгына ирешү алымнарының – риторик сорау; риторик өндәү; фаразланган, ихтималланган сөйләм; өземтәләр китерү; төрле тел-сурәт чаралары; кабатлауларның – әһәмиятен кыскача аңлатып үтегез.

7. Риторик сорауга, риторик өндәүгә, вәгазьләрдән мисаллар табарга, укып күрсәтергә.

8. Коръәни-Кәримнән, хәдисләрдән, вәгазьләрдән кабатлауларга (анафора, эпифора, акромонограмма, кабатланучы сүзләр) мисаллар табарга.

9. Дин белгечләренең хезмәтләреннән градация, антитеза очракларына мисаллар табарга.

10. Коръәни-Кәрим, хәдисләрдән, дин белгечләренең хезмәтләреннән гипербола, литота, метафора, охшашландыру очракларына мисаллар табып аңлатырга.

11. Саналмыш рәт очрагына төрле темага мисаллар төзергә.

12. Рәсми-эшлекле аралашу жанрының үзенчәлекләре турында сөйләгез.

13. Рәсми-сәяси аралашуга нинди таләпләр куела?

14. Телефоннан рәсми сөйләшү, шатлыклы хәбәр ирештерү үзенчәлекләре турында сөйләгез.

15. Тәкъдим итү чыгышларының төрләрен, аларның үзенчәлекләрен ачыклап үтегез.

16. Мәхәллә җыелышын ачып җибәрү сүзе әзерләргә, укып күрсәтергә.

17. Рәсми аралашу диалогы төзергә, укып күрсәтергә.

18. Туган көн, юбилей, берәр тантаналы вакыйга белән котлау тексты язарга.

19. Вәгазьләр әзерләргә, укып (сөйләп), башкарып күрсәтергә.

20. Бер үк фразаны төрле темпта яңгыратып карарга.

21. Төрле типтагы сөйләм өзекләренең эчтәлегенә хас булмаган интонация белән укырга.

22. Алдагы фикерне, соңыннан килгәне белән бәйләп, көчлерәк яңгыратып, мәгнәви перспективага омтылу интонациясен күнектерергә.

# ӘДӘБИЯТ ИСЕМЛЕГЕ


1. Абдуллина Р.С. Риторика һәм интонация / Р.С. Абдуллина. – Яр Чаллы: КамАЗ, 1999. – 400 б.

2. Абдуллина Р.С. Стилистика һәм сөйләм культурасы мәсьәләләре. – Яр Чаллы: КАМАЗ, 1997. – 128 б.

3. Андреев В.И. Деловая риторика: Практический курс для творческого мастерства / В.И. Андреев. – Изд-во КГУ, 1993. – 252 с.

4. Аристотель. Риторика // Античные риторики / Аристотель. – М.: Изд-во МГУ, 1978. – 352 с.

5. Аристотель. Риторика. Поэтика / Аристотель. – М.: Лабиринт, 2000. – 221 с.

6. Арутюнова Н.Д. Язык и мир человека / Н.Д. Арутюнова. – М., 1995. – 895 с.

7. Әмирхан Р. Иманга тугрылык. – Казан: Татар.кит.нәшр., 1997. – 384 б.

8. Әхмәтьянов Р.Г. Татар терминологиясенең тарихи чыганаклары. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2003. – 174 б.

9. Бахтин М.М. Проблемы речевых жанров // Собрание сочинений. Т. V. / М.М. Бахтин – М.: Русские словари, 1997. – С. 159.

10. Бәширова И.Б. Хәзерге татар әдәби теле. Семасиология: Татар лексикасында системалы бәйләнеш-мөнәсәбәтләр. – Казан: Алма-Лит, 2006. – 192 б.

11. Бройниг Г. Руководство по ведению переговоров / Г.Бройниг. – М., 1996.

12. Бубый Г. Татарча хөтбә уку дәрестме? – Казан: “Үрнәк” электротип., 1908. – 35 б.

13. Вәгазьләр, әдәп-әхлак китабы / төз. Г.Мөхәммәтшин. – Казан: Идел-Пресс, 2004. – 270 б.

14. Виноградов В.В. О теории художественной речи / В.В. Виноградов. – М.: Высшая школа. 1971. – 240 с.

15. Ворожейкин И.Е., Кибанов А.Я., Захаров Д.К. Конфликтология: Учебник / И.Е. Ворожейкин, А.Я. Кибанов, Д.К. Захаров. – М.: ИНФРА-М, 2000. – 224 с.

16. Галиулла З. Өмет белән яшик. – Казан, ТаРИХ, 2011. – 116 б.

17. Гимазова Р.А. Просветительская деятельность Нигматуллиных-Буби. – Казань: Печатный двор, 2004. – 220 с.

18. Ганиев Ф.Ә. Хәзерге татар әдәби теле: Сүзъясалышы. – Казан: Мәгариф, 2000. – 271 б.

19. Җәлил хәзрәт вәгазьләре. – 2 кит. – 1 кит. – Казан: Мәдәни җомга, 1998. – 222 б.; 2 кит. – Казан: Мәдәни җомга, 1999. – 256 б.

20. Җәлил хәзрәт Фазлыев. Йөз дә бер вәгазь. – Казан, 2005. – 544 б.

21. Заһидуллина Д.Ф. Урта мәктәптә татар әдәбиятын укыту методикасы: Методик кулланма. – Казан: Мәгариф, 2000. – 335 б.

22. Зәкиев М.З. Хәзерге татар әдәби теле: Синтаксис / М.З. Зәкиев. – Казан: Тат. кит. нәшр., 1966. – 288 б.

23. Ибраһим әл-Кайси М. Ислам әхлагы һәм гадәтләре: Ислам әдәбе буенча кулланма. – Казан: Иман, 1994. – 120 б.

24. Ивин А.А. Искусство правильно мыслить. / А.А. Ивин. – М., 1990.

25. Идегәй. (Татар халык дастаны). – Казан: Татар. кит. нәшр., 1988.

26. Илле ике вәгазь / төз. Н.Сөләймани. – Казан: Иман, 2001. – 252 б.

27. Ислам гакыйдәсе (Иман нигезләре) / төз. К.Вәлиулла. – Казан: “Мөхәммәдия” мәдр., 2002. – 191 б.

28. Ислам гореф-гадәтләре / төз. Я.Исхаков. – Казан: Матбугат йорты, 1999. – 128 б.

29. Ислам дине нигезләре / төз. Ф.Яхин. – Казан: Раннур, 1997. – 288 б.

30. Исхакый Г. Ислам әхлагы. – Казан, 2002. – 269 б.

31. Исхакый Г. Динсез яшәп булмый. – Казан: Иман, 2000. – 320 б.

32. Исхакый Р. Җан азыгы: Шигъри вәгазьләр. – Казан: “Кыйбла” кит. нәшр., 1998. – 304 б.

33. Карнеги Д. Как вырабатывать уверенность в себе и влиять на людей, выступая публично / Д.Карнеги. – М., 1989.

34. Квятковский А.А. Поэтический словарь. / А.А. Квятковский. – М.: Сов. энциклопедия, 1966. – 376 с.

35. Козырев Г.И. Введение в конфликтологию: Учеб. пособие / Г.И. Козырев. – М.: Гуманит. изд. центр ВЛАДОС, 1999. – 176 с.

36. Коръән аятьләренең татарча мәгънәләре. (Төрле галимнәрнең тәрҗемәләре һәм шәрехләреннән файдаланып

матбугатка әзерләүче Р.Батулла). – Казан: Идел-Пресс, 2011. – 624 б.

37. Коръән сүрәләре / төз. Җ.Мөбарәк. – Казан: Раннур, 2000. – 208 б.

38. Кохтев Н.Н. Основы ораторской речи / Н.Н. Кохтев. – М., 1992. Мицич П. Как проводить деловые беседы. / П.Мицич. – М., 1987.

39. Курбатов В.И. Конфликтология / В.И. Курбатов. – Ростов н/Д: Феникс, 2005. – 445 с.

40. Курбатов Х.Р. Сүз сәнгате: Татар теленең лингвистик стилистикасы һәм поэтикасы / Х.Р. Курбатов. – Казан: Мәгариф, 2002. – 199 б.

41. Курбатов Х.Р. Татар теленең синтаксис һәм стилистика мәсьәләләре. – Казан: Татгосиздат, 1956. – 176 б.

42. Львов М.Р. Риторика. Культура речи. / М.Р. Львов. – М.: Изд. центр «Академия», 2002. – 272 с.

43. Мәхмүтов М. Коръән сүзе татар телендә // Казан утлары. – 2000. – № 5. – 143-154 б.; № 6. – 147-160 б.

44. Мөбарәк Җ. Хәтер дәфтәре. – Казан: Дом печати, 2002. – 287 б.

45. Низамов И.М. Риторика // Югары уку йортлары өчен дәреслек / И.М. Низамов. – Казан: Казан дәүләт университеты, 2000. – 178 б.

46. Низамов И.М. Уем тел очында // Сөйләм һәм массакүләм аралашу. Беренче кисәк. Татар сөйләменең нигезләре / И.М. Низамов. – Казан: Тат. кит. нәшр., 1995. – 287 б.

47. Ножин Е.А. Основы советского ораторского искусства / Е.А. Ножин. – М.: Знание, 1981.

48. Нуриев Г.-Р.С., Хәйруллина А.Х. Сәхнә теле. / Г.-Р.С. Нуриев., А.Х. Хәйруллина – Казан: Отечество, 2004. – 364 б.

49. Павлова Л.Г. Спор, дискуссия, полемика / Л.Г. Павлова.– М., 1991.

50. Пәйгамбәрләр тарихы / төз. Ф.Яхин. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1992. – 144 б.

51. Риторика (под ред. Н.А. Ипполитовой). – М.: Проспект, 2009. – 448 с.

52. Сафиуллина Р.Р. Арабская книга в духовной культуре татарского народа / Р.Р. Сафиуллина. – Казань: Алма-Лит, 2003. – 212 с.

53. Сафиуллина Ф.С., Зәкиев М.З. Хәзерге татар әдәби теле: Югары һәм урта уку йортлары өчен дәреслек. – Тулыл. 2 нче басма. – Казан: Мәгариф, 2002. – 407 б.

54. Сопер П. Основы искусства речи // П.Сопер (пер. с англ.) – 3 испр. изд. – М.: Изд-во агенства «Яхтсмен», 1995. – 416 с.

55. Стернин И.А. Общение в современном обществе / И.А. Стернин. – Воронеж., 1991.

56. Татар грамматикасы. – 3 томда: 1 т. – Мәскәү: Инсан, Казан: Фикер, 1998. – 512 б.; 2 т. – Мәскәү: Инсан, Казан: Фикер, 2002. – 448 б.; 3 т. – Мәскәү: Инсан, Казан: Фикер, 1999. – 512 б.

57. Татар календаре / төз. Ш.Зәбиров, Ф.Хуҗахмәт. – Казан: Татар газ.-журн. нәшр., 1996.

58. Татар мөселман календаре / төз. Ш.Зәбиров, Ф.Хуҗахмәт. – Казан: Идел-Пресс, 2008-2010.

59. Татар халкы тарихы һәм мәдәнияте (Борынгы заман һәм урта гасырлар), Татар телендә төп гомуми белем бирү мәктәбенең 5 нче сыйныфы өчен уку әсбабы. – Казан: Мәгариф, 2010. – 199 б.

60. Татар халык иҗаты. Мәкальләр һәм әйтемнәр / төз. Х.Ш. Мәхмүтов. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1987. – 592 б.

61. Тимергалин А. Әстәгъфирулламы? Юк, сөбханалла // Мирас. – 2002. – № 1. – 58-80 б.

62. Тумашева Д.Г. Татарский глагол: Учебное пособие. – Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1986. – 189 с.

63. Ушакова Н.В., Козлов Н.И., Егидес А.П. Основы психологии общения / Н.В. Ушакова, Н.И. Козлов, А.П. Егидес. – М., 1990.

64. Фәхретдин Ризаэтдин. Нәсыйхәт: Әхлак гыйлеменнән / төз. Ә.Хәйри. – Казан: Мәгариф, 2005. – 184 б.

65. Хаков В.Х. Стилистика һәм сүз сәнгате. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1979. – 158 б.

66. Хаков В.Х. Тел – тарих көзгесе (Татар әдәби теленең үсеш тарихыннан). – Казан: Татар. кит. нәшр., 2003. – 295 б.

67. Хәйруллина А.Х. Дөрес сөйләргә өйрәнегез / А.Х. Хәйруллина. – Казан: Казан нәшр., 1992. – 96 б.

68. Шарафутдинов З.Т., Ханбиков Я.И. История педагогики Татарстана. – Казан, 1998. – 306 с.

69. Юнина Е.А., Сагач Г.М. Общая риторика / Е.А. Юнина, Г.М. Сагач. – Пермь, 1992.

70. Юсупов Р.А. Икетеллелек һәм сөйләм культурасы. / Р.А. Юсупов. – Казан: Тат. кит. нәшр., 1987. – 214 б.

**Сүзлекләр:**

1. Әхмәтьянов Р. Татар теленең кыскача тарихи-этимологик сүзлеге. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2001. – 272 б.
2. Гарәпчә-татарча-русча алынмалар сүзлеге / төз. М.И. Мәхмүтов, К.З. Хәмзин, Г.Ш. Сәйфуллин. – 2 томда. – Казан: Иман, 1993. – 853 б.
3. Ислам. Белешмә-сүзлек / төз. З.Шәфигый. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1993. – 191 б.
4. Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. – 3 томда. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1977, 1979, 1981.
5. Татар теленең орфографик сүзлеге / төз. А.Х. Нуриева, Ф.С. Фасеев, М.И. Мәхмүтов. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1983. – 280 б.
6. Татарча-төрекчә сүзлек / төз. Ф.Ганиев, Р.Әхмәтьянов, Х.Ачыкгөз. – Мәскәү: Инсан, 1997. – 496 б.
7. Сафиуллина Р.Р. Мөселман терминологиясе сүзлеге. Словарь мусульманской терминологии / Р.Р. Сафиуллина. – Казань: Алма-Лит, 2006. – 124 с.
8. Сафиуллина Ф.С. Татарча-русча фразеологик сүзлек. – Казан: Мәгариф, 2001. – 235 б.
9. Сәлимов Х.Х. Татар теленең орфоэпик сүзлеге / Х.Х. Сәлимов. – Чаллы: Камаз, 1995. – 124 б.

## Шартлы кыскартылмалар

ГТРАС – Гарәпчә-татарча-русча алынмалар сүзлеге / төз. М.И.Мәхмүтов, К.З.Хәмзин, Г.Ш.Сәйфуллин. – 2 т. – Казан: Иман, 1993. – 853 б.

ТТАС – Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. – 3 т. – Казан: Татар.кит.нәшр., 1977, 1979, 1981.

ТК – Татар календаре.

ТМК. – Татар мөселман календаре.

ДК – Дини календарь.

# СҮЗЛЕК

**Абсолют** – 1) галәмнең мәңгелек, үзгәрмәс, беренчел нигезе – рух, идея; 2) чикләнмәгән.

**Абстракт** – конкрет булмаган, гомуми.

**Автоматик** (рәвештә) – кешенең турыдан-туры катнашыннан башка, эчке җайланмалар ярдәмендә (эшли торган).

**Адвокат** – судта гаепләнүчене яклый торган хокук белгече (юрист); яклаучы, арага керүче.

**Адекват** – тәңгәл, тиңдәш, бер төрле үк, туры килгән.

**Аксиома** – дөреслеген исбат итеп торуның кирәге булмаган хакыйкать.

**Акт** – чыгыш, хәрәкәт, кыланыш.

**Актуаль** – хәзерге чор, шушы мизгел өчен бик мөһим, әһәмиятле, заман таләпләренә җавап бирә торган.

**Алгоритм** – алдан билгеләнеп куелган шартларны үтәп, исәп-хисап һ.б. мәсьәләләрне ничек һәм нинди эзлеклектә чишү юлларын аңлаткан (тасвирлаган) аңлатма.

**Анализ** – предметны яки күренешне аерым өлешләргә, кисәкләргә таркатып өйрәнү алымы.

**Антик** – борынгы грек һәм рим тарихына, культурасына бәйле.

**Аргумент** – исбатлауның нигезендә яткан мәгънәле фикер.

**Аспект** – караш.

**Атмосфера** – күч. чолганыш, шартлар.

**Бәхәс** – сүзләр ярышы.

**Гипотеза** – нинди дә булса күренешне аңлату өчен китерелгән, ләкин әле дөреслеге тәҗрибә нигезендә исбатланмаган, фәндә булуы мөмкин дип кенә табылган фараз.

**График** – төрле процессларның сан бәйләнешләрен кәкре сызыклар ярдәмендә күрсәтә торган сызым; 2) күләме һәм үтәлү вакыты анык күрсәтелгән эш планы.

**Дебат** – бәхәсләшкән сорау буенча фикерләр алышу.

**Дедуктив** – дедукциягә нигезләнгән; гомуми фикердән хосусыйга күчеп фикерләү һәм исбатлау ысулы; гомуми фикердән, логик юл белән исбатлап, хосусый нәтиҗә чыгару.

**Демагогия** – максатка ирешү өчен ялган вәгъдәләр бирү, юмалау, фактларны бозып аңлату һ.б.ш. белән җәмәгатьчелек ышанычын, яклавын казану алымы һәм чаралары.

**Деструкия** – җимерү, нәрсәнең булса да кабул ителгән төзелешен бозу.

**Диаграмма** – төрле зурлыкларның үзара чыгыштырмасын күрсәтмәле итеп, кисемтәләр яки геометрик фигуралар ярдәмендә сурәтли торган сызым.

**Диалекталь** – берәр җирле сөйләштә кулланыла торган диалектка хас булган (сүзләр, авазлар һ.б.ш. турында).

**Диалектика** – табигатьнең, җәмгыятьнең һәм фикерләүнең хәрәкәт, үсеш барышы (процессы).

**Диалог** – ике кешенең кара-каршы сөйләшүе.

**Дискуссия** – иҗтимагый бәхәс, төрле каршылыклы фикерләрне ачыклау.

**Документ** – берәр фактны раслый яки берәр нәрсәгә хокук бирә торган һ.б.ш. эш кәгазе.

**Доминант** – доминанта сыйфатындагы; төп.

**Жанр** – нинди дә булса әдәби яки сәнгать әсәрләренең үзенә генә хас сюжеты һәм стилистик билгеләре белән аерылып торган төре.

**Идеал** – җәмгыять яки аерым шәхеснең алга куйган, шуңа омтылган иң югары ноктасы.

**Идеаль** – хыялда гына яши торган; абстракт; 2) камил үрнәк булырлык, бик яхшы.

**Идеология** – билгеле бер җәмгыять, сыйныф яки сәяси партия мәнфәгатьләрен гәүдәләндерә торган сәяси, фәлсәфи карашлар, төшенчәләр җыелмасы, аларның иҗтимагый аңы, дөньяга карашы һәм фикерләр системасы.

**Иллокуция** – сөйләүченең яшертен яки ачыктан-ачык белдергән максатының тәэсир көче.

**Имидж** – хисле-тойгылы тәэсиргә исәпләнеп, таныту максатыннан махсус оештырылган, йөз, күренеш, предмет рәвеше.

**Имплицит** – ихтималланган, булырга мөмкин хәлләрдән аңлашылган мәгънә.

**Импульс** – нерв күзәнәкләре эшчәнлеге ярдәмендә нинди дә булса эшкә этәрә торган эчке теләк, омтылыш.

**Интеллигентлык** – укымышлылык, культуралылык, тәрбиялелек.

**Инверсия** – берәр сүзнең мәгънәсенә басым ясау өчен яки бөтен фразага билгеле бер стилистик төсмер бирү өчен җөмләдә сүзләрнең гадәти тәртибен үзгәртү.

**Индуктив** – индукциягә нигезләнгән; аерым, очраклы фактлар һәм хәлләргә нигезләп, гомуми нәтиҗәләргә чыгару алымы.

**Инстинкт** – 1) тере организмның, эчке яки тышкы мохиттәге үзгәрешкә карап, кирәкле, яшәү өчен әһәмиятле эш-хәрәкәтне аңсыз рәвештә башкаруга тумыштан килгән сәләт; 2) аңсыз рәвештә, берәр нәрсәгә омтылыш, хис; 3) табигый сизү, эчке сизү.

**Интервал** – ике әйбер арасындагы ераклык; ике эш арасындагы вакыт; ике тавышның калынлык-нечкәлегендәге аерма.

**Интеграция** – 1) алмаш зурлык; 2) берәр нәрсәнең өлешләрен бер бөтенгә җыю.

**Интерпретация** – нәрсәнең дә булса мәгънәсен аңлатып бирү

**Интроверт** – шәхес холкының үзенең эчке рухи дөньясына, кичерешләренә юнәлгәнлеге (үз эченә бикләнгәнлек).

**Истерия** – 1) юк бар нәрсәдән үзен-үзе белештермәслек рәвештә кычкырып елау, көлү яки бик нык әсәрләнү белән үзенчәлекле нерв авыруы; 2) күч: Берәр өлкәдә ярсулы, кызу эшчәнлек, берәр нәрсәгә шашынулы омтылыш.

**Квалификация** – кешенең теге яки бу эшкә, хезмәткә ярарлылык, хәзерлелек дәрәҗәсе; һөнәр, белгечлек.

**Код** – элемтә, ЭВМ системасында, автоматик җайланмаларда мәгълүмат эшкәртү, саклау, тапшыру өчен кулланыла торган шартлы билгеләрнең (саннар, хәрефләр) яки сигналларның (электр, яктылык) билгеле бер тәртиптәге җыелмасы.

**Коллизия** – 1) капма-каршы карашларның, көчләрнең, мәнфәгатьләрнең бәрелеше; 2) матур әдәбиятта тормыш конфликтларын һәм көрәшне сурәтләү, күрсәтү.

**Коммуникатив** – фикерләрне тапшыру, фикерне белдерү.

**Компетентлык** – нинди дә булса өлкә, мәсьәләдә яхшы хәбәрдарлык, тирән белемлелек. Билгеле бер мәсьәләне эшләүдә тиешле вәкаләткә, хокукка ия булу.

**Компиляция** – чыганакларны мөстәкыйль эшкәртмичә, башка авторлардан күчереп алып нинди дә хезмәт, әсәр язу; 2) шундый юл белән төзелгән хезмәт, күчермә.

**Композиция** – әдәбият һәм сәнгать әсәрләренең яки аларның кисәкләренең тема, сюжет буенча төзелеше, төп кисәкләренең урнаштырылу тәртибе.

**Компонент** – нәрсәнең дә булса кисәге, өлеше.

**Конвенция** – дәүләтләр арасында нинди дә булса мәсьәлә буенча төзелгән килешү.

**Конкуренция** – ярыш.

**Консенсус** – кешеләрнең үзара килешүе.

**Конспект –** нәрсәнең дә булса кыскача язма эчтәлеге.

**Конструкция** – 1) берәр корылма, машина төзелеше, аның аерым кисәкләренең урнашуы. 2) грамматик бәйләнеш ягыннан җөмләдә сүзләрнең үзара урнашуы, төзелеш тәртибе.

**Контекст** – текстның мәгънә ягыннан бер бөтен булган һәм үзенә кергән сүзнең яки тулы бер фразаның мәгънәсен ачып бирә торган өлеше.

**Конфликт** – капма-каршы як, фикер, көчләрнең бәрелеше; низаг, кискен бәхәс.

**Конфронтация** – каршы тору.

**Концептуаль**– төрле мәсьәләләргә, чынбарлыкта була торган хәл һәм күренешләргә караш.

**Корпорация** – тар сословие яки профессия һ.б. мәнфәгатьләрдән чыгып берләшкән кешеләр төркеме.

**Корректлы** – әдәпле, дөрес булган,төзәтмә кертелгән.

**Лидер** – берәр иҗтимагый сәяси оешманың һ.б.ш. җитәкчесе, юлбашчысы; 2) нинди дә булса ярышта беренче булып баручы кеше яки команда.

**Логика** – 1) фикерләүнең кануннары һәм рәвешләре турында фән; 2) табигать, җәмгыять, фикерләү күренешләренә хас эчке канунчылык; 3) берәр нәрсә турында караш.

**Модель** – 1) нинди дә булса әйбернең үрнәк өчен эшләнгән нөсхәсе; 2) берәр нәрсәнең кечерәйтеп ясалган үрнәге яки схемасы; 3) конструкциянең маркасы, тибы; 4) эретеп кою эшендә кулланыла торган калып, өлге.

**Либераль** – 1) либерализм яклы булган;

2) килешүчән, юл куючан.

**Материаль** – 1) материягә бәйләнешле; матди; аң-фикерләүдән тыш яши торган; физик матдә; 2) милеккә, эш хакына, табышка, яшәү шартларына мөнәсәбәтле.

**Менталь** (менталитет) – акыл сәләте, билгеле бер фикерләү ысулы, акыл эшчәнлеге һәм рухи җайланмалар җыелмасы.

**Нейтраль** – 1) көрәш, бәхәс һ.б.ш. булган бер якка да катнашмаучы, бер якны да якламаучы, битараф; 2) организмга файда да, зарар да итми торган (дару, төрле матдәләр, һ.б. турында).

**Норма** – 1) нәрсәнең дә булса гадәттәге, гомуми кабул ителгән, мәҗбүри булган тәртибе, торышы; 2) берәр нәрсәнең булырга тиешле үлчәме, күләме.

**Норматив** – берәр төрле эш башкару өчен билгеләнгән нормалар күрсәткече.

**Объективлык** – аңнан бәйсез, объектның үзенә хас.

**Оппонент** – бәхәстә, диспутта, диссертацияләр яклаганда кемнең дә булса фикерләренә, дәлилләренә каршы чыгып сөйләүче яки аның фикерләрен, дәлилләрен яклаучы (рәсми оппонент турында).

**Оптимистик** – тирә-юньгә күтәренке, көр күңелле мөнәсәбәт; тормышка, киләчәккә өмет, ышаныч белән карау, һәрнәрсәнең яхшы, уңай ягын күрергә тырышу халәте.

**Орфоэпия** – әдәби дөрес әйтелешне билгели торган кагыйдәләр системасы.

**Парадигма** – сүзләрнең төрләнү үрнәген күрсәткән формалар системасы.

**Парадокс** – гомум кабул ителгән һәм дөрес дип саналган фикерләргә, күзаллауларга кискен каршы булган, (кайвакыт беренче караш) кеше ышанмаслык булып торган фикер, хөкем яки күренеш.

**Партнер** – аралашып, билгеле бер мөнәсәбәтләргә кереп йөргән як.

**Патриот** – ватанпәрвәр – үзенең туган җирен, халкын, илен, ватанын сөюче, шулар өчен һәртөрле корбаннарга да әзер булган кеше.

**Пауза** – эштә, сөйләүдә һ.б. кыска гына тукталыш, туктап тору; 2) Сәхнә әсәрләре куелышында, шулай ук шигырь, доклад һ.б.ны сөйләгәндә билгеле бер эффект тудыру өчен ясала торган кыска тукталыш, тыныш.

**Пафос** – рух күтәренкелеге.

**Перлокуция** (тәэсире) – хәбәрнең тыңлаучыга йогынтысы, тәэсир көче.

**Плюрализм** – фикерләр күплеге.
**Позитив** – уңай факторларга нигезләнгән.
**Позиция** – карашлар.
**Полемика** – аралашу предметы турында бәхәсләшү.
**Полемист** – оста бәхәсләшүче кеше
**Прагматика** – 1) эш, гамәл; 2) төрле тормыш хәлләрен чишүдә файдалы гамәл, гомуми алым; 3) тел белемендә тел билгеләренең сөйләмдәге вазифаларын тикшерү өлкәсе.
**Практика** – кешеләрнең җәмгыять яшәеше өчен кирәкле шартларны тудыруга юнәлдерелгән барлык эшчәнлеге; 2) белемнәрне, күнегүләрне эштә куллану; 3) эш, тәҗрибә.
**Предикат** – фикер йөртүнең предметы турындагы хөкем, мәгънәле хәбәр.
**Принцип** – 1) берәр теория, тәгълимат, фән һ.б.ш ның төп, нигез кагыйдәсе, тезисы; 2) берәр нәрсә турында төп фикер, төп караш, эчке ышаныч.
**Проблема –** хәл ителергә тиешле теоретик яки гамәли мәсьәлә.
**Программа** – киләчәк эшләрнең, эшчәнлекнең планы; уку йортында укытыла торган фәннең кыскача эчтәлеге һәм методологик күрсәтмәләр бирелгән аңлатма.
**Просодика** – сөйләмдә (авазның) тавышның мәгънә аеру әһәмиятенә ия югарылык, көч, дәвамлылык чаралары җыелмасы.
**Профессиональ**(лек) – берәр нәрсәнең һөнәри сыйфаты, билгеле бер хәзерлек, белем таләп итә торган осталык.
**Публика** – тамашачы, тыңлаучылар; 2) җыелган халык, кешеләр.
**Публицистика** – -хәзерге көн өчен әһәмиятле темаларга багышланган иҗтимагый-сәяси әдәбият, әдәби жанр.
**Рациональ** – урынлы, нигезле.
**Реклама** – файдаланучыларны, кулланучыларны, сатып алучыларны, тамашачыларны һ.б. тарту, аларның игътибарын җәлеп итү максатыннан үткәрелгән чара.
**Реплика** – каршы әйтелгән сүз.
**Реплика** – әңгәмәгә катнашучыларның сөйләүче сүзенә каршы төшеп яки җавап итеп сүз әйтү, сүз кыстыру.
**Реформа** – нәрсәне дә булса үзгәртү. Үзгәртеп кору.
**Ритм –** нинди дә булса элементларның (тавыш, сөйләм һ.б.) билгеле бер эзлеклелек, ешлык һ.б. белән чиратлашуы.
**Ритуал** – йолалар җыелмасы.
**Роль** – 1) сәхнәдә, кинофильмда артист гәүдәләндергән драматик образ; 2) ниди дә булса эш, шөгыль; вазифа; 3) кемнең яки нәрсәнең дә булса әһәмият, эшкә яки вакыйгага катнашу яисә йогынты ясау дәрәҗәсе, керткән өлеше, хезмәте, тоткан урыны.
**Символ –** берәр абстракт төшенчәне яки идеяне белдергән шартлы билге.
**Символик** – символ булып тора торган, шуның вазифасын үти торган.

**Синтагма – сөйләм такты** – бер яки берничә сүздән төзелеп, интонация һәм мәгънә ягыннан бербөтен тәшкил иткән синтаксик берәмлек.

**Синтез** – кушу, берләштерү.

**Система** – чынбарлык нәрсәләрнең үзара бәйләнеш һәм бәйлелек челтәрендәге эзлекле тәртип; 2) бөтендәге өлешләр бердәмлелегенең гәүдәләнеше һәм чагылышы булган төзелеш (структура); 3) аерым билге яки билгеләр нигезендә берләштерелә торган нәрсәләр җыелмасы.

**Ситуация** – төрле шарт, мөнәсәбәтләр нәтиҗәсендә туган хәл.

**Софизм** – формаль яктан дөрес, ләкин асылда ялгыш фикер, ялгыштыруга, бутауга исәп тотып төзелгән сөйләм.

**Софистика** – 1) софистлар тарафыннан тудырылган борынгы Грециядәге фәлсәфи агым; 2) софизмга нигезләнгән фикер йөртү, исбатлау, шулай ук, ялгышуга китерә торган телдән әйтелгән гамәлләр.

**Стереотип** – үзгәртелмәгән, төгәл кабатланган; тапталган, еш кулланыла торган, үтемле.

**Статус** – җәмгыятьтә токкан урын.

**Статистика** – иҗтимагый һәм башка күренешләрнең микъдари исәбе, саннар белән күрсәтелгән исәп-хисап мәгълүматлары.

**Структура** – берәр нәрсәнең эчке төзелеше, өлеше – кисәкләрнең үзара мөнәсәбәтеннән гыйбарәт рәвеше.

**Субординация** – хезмәт дисциплинасы кагыйдәләренә нигезләнгән кечеләрнең өлкәннәргә буйсыну системасы.

**Субъектив** – кеше аңында яши торган, шәхескә мөнәсәбәтле.

**Субъективлык** – субъектив булу хәле, күренеше, шәхескә хас сыйфатлар.

**Схема** – берәр нәрсәнең төзелешен гадиләштереп күрсәткән сызым, аңлатма, тасвирлама.

**Таблица** – билгеле бер тема буенча үзара нисбәтләштерелеп, баганалар рәвешендә бирелгән мәгълүматлар җыелмасы.

**Тезис** – автор, оратор исбатларга яки кире кагарга теләгән төп фикер.

**Тема** – сөйләм, инша, бәхәс, әсәрнең һ.б эчтәлек юнәлеше, тасвирлау яки бәя итү объекты.

**Тенденция** – 1) омтылыш, үсеш юнәлеше, берәр нәрсәгә тартымлык; 2) зур иҗтимагый теләк; 3) сәнгать әсәрендә үтә анык ният юнәлеше.

**Термин** – фән, техника һәм сәнгать өлкәсендә, иҗтимагый-сәяси әдәбиятта анык бер төшенчәне белдерә торган махсус атама, сүз яки сүзтезмә.

**Террор** – сәяси дошманны каты эзәрлекләү, юк итү күренеше.

**Технология** – җитештерүнең билгеле бер тармагында эшкәртү алымнары, ысуллары җыелмасы, шуларның фәнни тасвирламасы.

**Типик** – билгеле бер предмет, шәхес, күренеш тибының характер үзенчәлекләрен үзенә алган; 2) гади, гадәттәге, еш очрый торган; билгеле бер заман, шартлар яки берәр шәхес өчен характерлы, шуңа хас булган.

**Толерантлык** – чит фикерләргә һәм карашларга түземлелек.

**Тоталитар** – гомуми, һәркемгә, һәрнәрсәгә кагылган, бөтен нәрсәне эченә алган.

**Традиция** –буыннан-буынга күчә торган гореф-гадәт, үз-үзеңне тотыш кагыйдәсе, караш, зәвык үзенчәлеге һ.б.ш.

**Универсаль** – күпкырлы.

**Унисон** – бергәлек, яраклашу.

**Факт** – 1) булып үткән эш-хәл, вакыйга, күренеш; 2) мисал, очрак; 3) нинди дә булса нәтиҗәгә килергә, йомгак ясарга яки берәр нинди фикерне ачыкларга ярдәм итәрдәй нәрсә; дәлил; 4) чынбарлык, реаль нәрсә.

**Фестиваль** – музыка, театр, кино һ.б.ш. сәнгать өлкәләрендәге уңышларны күрсәтү максаты белән, вакыт-вакыт үткәрелә торган җәмәгать бәйрәме.

**Цитата** – нәрсәне дә булса дәлиләү, нигезләү өчен берәр төрле текстан үзгәртмичә китерелгән өзек, өземтә.

**Шрифт** – нинди дә булса текстны җыю өчен кирәк булган билгеле бер зурлыктагы һәм формадагы хәреф, билгеләрнең җыелмасы.

**Штамп** – күчерелмә мәгънәдә: нинди дә булса эштә сукырларча иярелә торган әзер өлге.

**Эксперт** – дәгъвалы яки кыен мәсәләне чишү өчен чакырылган махсус белгеч.

**Экспертиза** – нинди дә булса эш яки мәсьәләнең билгеле бер нәтиҗә чыгару, дөрес бәя бирү өчен каралуы, тикшерелүе.

**Экстраверт** – шәхес холкының тышкы дөньяга юнәлтелгәнлеге. Экстравертларга аралашучанлык, башлап йөрүчәнлек, сизгерлек, иҗтимагый шартларга җайлаша белүчәнлек хас.

**Эластик** – 1) сузылмалы; 2) күчерелмә мәгънәдә: салмак, йомшак; сыгылмалы, кискен түгел.

**Элита** – җәмгыятьнең иң яхшы, сайланган өлеше

**Эксплицит** – сүзләрдән аңлашылган туры мәгънә.

**Эмпирик** – тәҗрибәгә нигезләнгән.

**Эпизодик**– очраклы, әллә-нигә бер.

**Эристика** – бәхәсләшү сәнгате.

**Этик** – этика кагыйдәләренә, таләпләренә туры килә торган.

**Этикет** – аерым җәмгыять, иҗтимагый катлау яки профессия членнары арасында кабул ителгән әхлак, үз-үзеңне тоту кагыйдәләре.

**Этос** – күренеш характеры.

# КУШЫМТАЛАР

*1 нче кушымта*

Вәгазь – үгетләп, өндәп, димләп сөйләгән сүз дигәнне аңлата. Җомга вәгазе догматик *(хөтбә)* һәм кануни *(вәгазь)* өлештән тора. Кануни вәгазь үзе ике кисәктән тора: нәсыйхәтле һәм рәсми өлештән.

**Татарстан Республикасы мөселманнары Diния нәзарәте имам-хатыйбларының**
**җомга вәгазьләрен укуы турында**
**НИЗАМНАМӘ**

**1. Гомуми кагыйдәләр.**

1.1. Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте имам-хатыйбларының җомга вәгазьләрен укуы турындагы бу Низамнамә Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәтенең *мәхәлләләрендә* үткәрелә торган вәгазьләрнең нәтиҗәлелеген арттыру һәм Татарстан мөселманнарын дини-әхлакый тәрбияләү барышын көчәйтү максатыннан эшләнгән.

1.2. Бу Низамнамә җомга дини хезмәте күрсәтү кысаларында һәм вәгазь укучы шәхес Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте вәкиле – имам буларак чыгыш ясаган башка очракларда да, Татарстан Республикасы мөселманнарына мөрәҗәгать итү буларак карала.

1.3. Вәгазьләрне Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте мәчетләрендә Мәхәллә Җыелышы карары, бу мәчет урнашкан районның имам-мөхтәсибе тәкъдимнәре нигезендә Мөфти тарафыннан расланган имам-хатыйблар; яки, мөселман уку йортларын тәмамлаучылар исемлегеннән Мөфти тарафыннан зарурлыгы булган очракта тәгаенләнгән икенче имам; шул ук вакытта, имам-хатыйб булмаган очракта, аның карары белән имам-хатыйб вазифаларын башкарып торырга вакытлыча тәгаенләнеп торылган мөәзин укый.

2. **Вәгазьнең төзелеше.**

2.1. Җомга вәгазе ике өлештән: догматик *(хөтбә)* һәм кануни вәгазьләрдән оеша.

2.2. Кануни вәгазь үгет-нәсыйхәттән һәм рәсми өлештән тора.

**3. Догматик вәгазь.**

3.1. Аз санда булса да зекер әйтеп үткәрелгән догматик вәгазь, җомга намазын үтәүнең шарты булып тора.

3.2. Догматик вәгазьләр ике өлешле. Беренче өлештә гадәти зекер әйтүләр һәм Мөхәммәд пәйгамбәргә (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!), аның гаиләдәшләренә, тәкъва хәлифәләргә, аның сәхабәләренә сәламнәр юллана, *тәшәһһүд,* мөселманнарга үгет-нәсыйхәтләр, киңәш-күрсәтмәләр бирелә, Коръәннән аятьләр, аның өзекләре китерелә. Икенче өлештә, Аллаһны олылауның башка төрләре белән бергә, имам мөселманнар өчен дога укый. Хөтбәнең бу ике өлеше имамның озак булмаган утырып алуы белән икегә бүленә.

3.3. Хөтбә җомга намазы вакыты җитү белән (догаларның Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте тарафыннан билгеләнгән тәртибе буенча) укыла.

3.4. Догматик вәгазьләрнең тәкъдим ителә торган текст үрнәкләре Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәтенең Голамәләр шурасы белән билгеләнә һәм Татарстан Республикасы Мөфтие тарафыннан раслана.

3.5. Догматик вәгазь гарәп телендә башкарыла.

3.6. Догматик вәгазьнең дәвамлылыгы өч минуттан да артмаска тиеш.

**4. Кануни вәгазь.**

4.1. Кануни вәгазь җомга намазы вакыты җиткәнче (догаларның Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте тарафыннан билгеләнгән тәртибе буенча) укыла.

4.2. Кануни вәгазьдә үтәлеш буенча эзлеклелек булырга, ягъни җомга намазы вакыты җиткәч укылырга мөмкин.

4.3. Кануни вәгазьнең үгет-нәсыйхәт өлешендә, имам-хатыйб, мәхәлләнең игътибарын дин тотучыларның рухи тормышын тәшкил иткән һәрнәрсәгә юнәлтә. Изге Коръәнгә һәм Сөннәткә, пәйгамбәрләр, Мөхәммәд пәйгамбәр (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!), аның сәхабәләре, тәкъва мөселманнар тормышыннан булган мисалларга нигезләнеп, мөселман дине рухи-әхлакый нәсыйхәтен, фикерләрен ирештерә, дини-әхлакый киңәшләр юллый.

4.4. Кануни вәгазьнең рәсми өлешендә, имам, Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте кабул иткән рәсми мәгълүматны (Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте Съезды, Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте Пленумы, Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте Президиумы, Татарстан Республикасы Мөфтие, Татарстан Республикасы мөселманнарының баш казые, Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәтенең Казыйлар шурасы, Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәтенең Голамәләр шурасы карарларын) мөселманнарга җиткерә. Шул ук вакытта, оештыру эшләрендә зарур булган, башка, җирле төбәк дәрәҗәсендә әһәмиятле (шул исәптән, Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәтенең төбәк казыяте, район мөхтәсибәте карарлары да) һәм мәхәллә өчен әһәмиятле (шул исәптән Мәхәллә Җыелышы һәм Мәхәллә Советы карарларын да) мәгълүмат та кануни вәгазь вакытында мөселманнар игътибарына җиткерелә.

4.4. Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте

мәхәлләләре игътибарына тәкъдим ителә торган рәсми мәгълүматның эчтәлеген Татарстан Республикасы Мөфтие билгели. Ә бу мәгълүматның мөселманнарга җиткерелүен контрольгә алуны һәр районның имам-мөхтәсибе башкара.

4.5. Вәгазьнең үгет-нәсыйхәт өлеше Изге Коръән, Пәйгамбәребез Мөхәммәднең (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) Сөннәте, имам Әбу Хәнифәнең дини-хокукый юнәлешендәге хезмәтләренә, Коръәнгә һәм Пәйгамбәребез (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) Сөннәтенә туры китереп тормыш алып барган факиһлар һәм галимнәрнең *иҗтиһадында* чагылган шәригать кануннарына туры китереп укыла.

4.6. Ислам авторитетлары дип аңлатылырга тиешле булмаган шәхесләр исемлеге һәм, шул ук вакытта, мираслары һәм шәхси үрнәкләре өлге итеп тәкъдим ителергә тиешле галимнәр исемлеге дә, Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәтенең Голамәләр шурасы белән билгеләнә һәм Татарстан Республикасы Мөфтие тарафыннан раслана.

4.7. Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте имам-хатыйблары укый торган үгет-нәсыйхәт вәгазе татар телендә сөйләнә. Аерым бер очракларда, максатка ярашлы рәвештә, җомга вәгазьләрен русча уку рөхсәт ителә. Вәгазьләрне рус телендә укыр өчен Татарстан Республикасы Мөфтиенең махсус рөхсәте кирәк.

4.8. Кануни вәгазьнең дәвамлылыгы, әгәр дә ул намаз вакыты җиткәнгә кадәр укыла икән – 40 минуттан, әгәр дә ул җомга намазы вакыты җиткәннән соң укыла икән – 20 минуттан артмаска тиеш.

## 5. Җомга намазының тәкъдим ителә торган үтәлеше.

*1 төр:*

5.1. Имам җомга намазы вакыты җиткәнгә кадәр мөселманнарга кануни

вәгазьнең үгет-нәсыйхәт өлешен укып мөрәҗәгать итә.

5.2. Мөәзин җомга намазына чакырып, беренче азан әйтә.

5.3. *Факультатив рәвештә:* кануни вәгазьне тәмам итү, Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәтенең рәсми мәгълүматын тыңлаучыларга җиткерү.

5.4. Имам һәм мәхәллә дүрт рәкәгать сөннәт намаз укыйлар.

5.5. Мөәзин, икенче тапкыр җомга намазына чакырып, икенче азан әйтә.

5.6. Имам мөнбәргә күтәрелә.

5.7. Имам догматик вәгазьнең беренче өлешен укый.

5.8. Имам мөнбәр баскычына утырып ала (ике вәгазь арасында утырып алу).

5.9. Имам догматик вәгазьнең икенче өлешен укый.

5.10. Имам җомга намазының фарыз өлешен уку өчен мөнбәрдән төшә.

5.11. Мөәзин җомга намазының *фарыз* өлешенә чакырып *камәт* әйтә.

5.12. Мәхәллә мөселманнары имам җитәкчелегендә җомга намазының фарыз өлешен укыйлар.

*2 төре:*

5.13. *Факультатив рәвештә:* Имам җомга намазы вакыты җиткәнгә кадәр мөселманнарга лекция укый.

5.14. Имам, җомга намазына чакырып, беренче азан әйтә.

5.15. Имам белән мәхәллә мөсеманнары дүрт рәкәгать сөннәт намаз укыйлар.

5.16. Имам мөселманнарны сәламли һәм мөнбәргә күтәрелә.

5.17. Мөәзин, мөселманнарны җомга намазына икенче тапкыр чакырып, икенче азан әйтә.

5.18. Имам догматик вәгазьнең беренче өлешен һәм кануни вәгазьнең үгет-нәсыйхәт өлешен укый.

5.19. Имам мөнбәр баскычына утырып ала (ике вәгазь арасында утырып алу).

5.20. Имам кануни вәгазьнең рәсми өлешен һәм догматик вәгазьнең икенче өлешен укый.

5.21. Имам җомга намазының фарыз өлешен уку өчен мөнбәрдән төшә.

5.22. Мөәзин җомга намазының *фарыз* өлешенә чакырып *камәт* әйтә.

5.23. Мәхәллә мөселманнары имам җитәкчелегендә җомга намазының фарыз өлешен укыйлар.

*3 төр:*

5.24. *Факультатив рәвештә:* Имам җомга намазы вакыты җиткәнгә кадәр мөселманнарга лекция укый.

5.25. Имам, җомга намазына чакырып, беренче азан әйтә.

5.26. Имам белән мәхәллә мөсеманнары дүрт рәкәгать сөннәт намаз укыйлар.

5.27. Имам мөселманнарны сәламли һәм мөнбәргә күтәрелә.

5.28. Имам кануни вәгазьне – аның үгет-нәсыйхәт һәм рәсми өлешләрен укый.

5.29. Мөәзин, мөселманнарны җомга намазына икенче тапкыр чакырып, икенче азан әйтә.

5.30. Имам догматик вәгазьнең беренче өлешен укый.

5.31. Имам мөнбәр баскычына утырып ала (ике вәгазь арасында утырып алу).

5.32. Имам догматик вәгазьнең икенче өлешен укый.

5.33. Имам җомга намазының фарыз өлешен уку өчен мөнбәрдән төшә.

5.34. Мөәзин җомга намазының *фарыз* өлешенә чакырып *камәт* әйтә.

5.35. Мәхәллә мөселманнары имам җитәкчелегендә җомга намазының фарыз өлешен укыйлар.

**6. Типик вәгазьләр.**

6.1. Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәтенең Голамәләр шурасы Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте имам-хатыйблары өчен типик вәгазьләр эшләп бирә.

6.2. Типик вәгазьләр, куллану өчен әзер булган вәгазь үрнәкләре дә, имам-хатыйблар вәгазь текстларын мөстәкыйль рәвештә үзләре әзерләр өчен беренчел материаллар рәвешендә дә булырга мөмкин.

6.3. Типик вәгазьләр Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәтенең Голамәләр шурасында тикшерелгәннән соң, Татарстан Республикасы Мөфтие тарафыннан расланалар һәм район имам-мөхтәсибләре тарафыннан имам-хатыйбларга җиткереләләр.

6.4. Татарстан Республикасы Мөфтие типик вәгазьләргә “Хуплана” яки “Тәкъдим ителә” грифлары куя.

**7. Низамнамә таләпләрен бозган өчен җаваплылык.**

7.1. Бу Низамнамәнең таләпләрен бозган имам-хатыйбларның эшчәнлегенә кагылган мәсьәләләрне, беренче баскыч сыйфатында ул эшләгән районның мөхтәсибәт җыелышы, икенче баскыч сыйфатында баш казый тикшерә.

7.2. Бу Низамнамәнең таләпләрен бозган имам-мөхтәсибләрнең эшчәнлегенә кагылышлы мәсьәләләрне беренче инстанция сыйфатында баш казый, икенче инстанция сыйфатында Татарстан Республикасы Мөфтие тикшерә;

7.3. Татарстан Республикасы Мөфтие, Президиум, Пленум, Мәхәллә җыелышы әгъзалары тәкъдимнәрен исәпкә алып, бу Низамнамә таләпләрен бозган дини вазифалар башкаручы кешеләрне эшләреннән алу һәм күчерү турында фәрманнар кабул итә.

*2 нче кушымта*

***Җомга вәгазе***

**Ачуланма**

*Әгүүзү билләәһи минәш-шәйтаанир-раҗиим. Бисмилләәһир рахмәәнир-рахиим. Әлхәмдүлилләәһи раббил гааләмиин вәссаләәтү вәссәләәмү галәә расүүлиһил кәрим үә галәә әәлиһи үә әсхабиһи әҗмәгыйн.*

Бөтен галәмнәрнең Раббысы, тәрбиячесе булган, безгә яшәү мәгънәсен аңлатучы Коръәнне бүләк иткән Аллаһы Сөбханә вә Тәгаләгә барча хәмед-сәнә, шөкераналарыбыз булса иде. Безнең өчен иң күркәм үрнәк булган нурлы Пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа галәйһиссәләм хәзрәтләренә, аның хөрмәтле әһленә, сәхабәләренә, күңел түрләребездән чыккан сәламнәребез, салаватларыбыз һәм һәртөрле изге догаларыбыз булса иде.

Газиз дин кардәшләрем, әссәләәмү галәйкүм үә рахмәтүллаһи үә бәракәтүһ! Бүгенге вәгазебез тискәре сыйфат – ачу халәте турында булачак.

Пәйгамбәребез галәйһиссәләмнең иң якын сәхабәләрнең берсе булган Әбү Һөрәйрә (Аллаһ аннан разый булсын) риваять иткәнчә, бер кеше Пәйгамбәр галәйһиссәләмнән: “Миңа киңәш бирче”, – дип сораган. Аллаһның расүле галәйһиссәләм: *“Ачуланма!”* – дигән. Шуннан соң теге кеше үзенең үтенечен берничә тапкыр кабатлаган, ләкин Пәйгамбәребез галәйһиссәләм һаман: *“Ачуланма!”* – дип җавап кайтарган (Бохари).

Әлеге кеше Әбү Дәрдә булган дип риваять ителә. Ул әйтте: “Бервакыт мин: “Әй, Аллаһның илчесе, миңа җәннәткә керергә ярдәм итәчәк эшне күрсәтсәнә”, – дидем. Ул: *“Ачуланма, һәм җәннәтле булырсың”,* – дип җавап бирде (Имам Табарани).

Һәр көнне кем белән булса да аралашабыз, сөйләшәбез, кайвакыт кемдер үзенең сүзләре яисә гамәлләре белән ачуыбызны чыгарырга мөмкин. Шундый вакытларда хак мөселман хәдистә әйтелгәнчә, ачуын йотарга, ачу утын сүндерергә тырышырга тиеш, чөнки ачу кешене башка гөнаһлы

гамәлләргә этәргә мөмкин. Кеше ачуланып үзенә генә түгел, башкаларга да зыян китерә.

Галимнәребез ачудан котылу өчен берничә юл тәкъдим итәләр:

1) Шайтан вәсвәсәсеннән Аллаһы Тәгаләгә сыгыну.

Бер көнне берәү Пәйгамбәребез галәйһиссәләм янында ачуланган вакытта Аллаһның расүле галәйһиссәләм үзенең сәхабәләренә әйткән: “Мин шундый сүзләрне беләм, әгәр аларны теге кеше әйтсә, ачу китәчәк: *Әгүүзү билләәһи минәш-шәйтаанир-ражҗииим.* Имам Маварди (Аллаһның рәхмәтендә булсын) үзенең “Әдәб әд-дөнья вә әд-дин” дигән китабында әйткән: “Ачу вакытында Аллаһны искә алырга кирәк. Шул вакытта кеше Аллаһтан курка башлар һәм ачуын эчтә калдыра алыр. Бөек Аллаһ изге Коръәндә болай дип әйтә:

وَاذْكُر رَّبَّكَ إِذَا نَسِيتَ

*“Аллаһны оныткан вакытта, Аны искә алыгыз”* (“Кәһаф” сүрәсе, 24 аять) .

2) Дәшмичә тору.

Ачуыбыз килгәндә, үзебезгә һәм башкаларга зыян китермәс өчен, бернәрсә дә әйтмәскә тырышырга кирәк. Сөекле Пәйгамбәребез галәйһиссәләм бу турыда әйткән: *“Әгәр берәрегез ачуланса, эндәшмәсен”,* – дигән (Әхмәд бин Хәнбәл, Тирмизи).

3) Гәүдә торышын үзгәртү.

Пәйгамбәребез: *“Берәрегез басып торганда ачуланса, утырсын; ачуы басылмаса, ятсын”* – дип әйткән (Әхмәд бин Хәнбәл, Әбү Давыд).

4) Тәһарәт алу.

Аллаһның расүле Мөхәммәд галәйһиссәләм: *“Дөреслектә, ачу – шайтаннан. Ә шайтан уттан яралтылган. Берәрегезнең ачуы чыкса, тәһарәт алсын”,* – дип эткән (Әхмәд бин Хәнбәл, Әбү Давыд).

5) Ачуланган вакытта үз ачуын йота алган кеше зур әҗер вә савапларга ирешә. Шуны һәрвакыт истә тоту.

Аллаһ Раббыбыз хак мөселманнарны мактап, Коръәндә болай дип әйтә:

الَّذِينَ يُنفِقُونَ فِي السَّرَّاء وَالضَّرَّاء وَالْكَاظِمِينَ الْغَيْظَ وَالْعَافِينَ عَنِ النَّاسِ وَاللّهُ يُحِبُّ الْمُحْسِنِينَ

*“Ул мөэминнәр бай чакларында да, ярлы чакларында да Аллаһ күрсәткән урыннарга сәдака бирәләр, ачулары килгәндә ачуны йоталар, гаепле кешеләр гафу сораганда гафу итәләр. Яхшылык кылучы әнә шундый мөэминнәрне Аллаһ сөядер”* (Гыймран сүрәсе, 134 аять).

6) Хак көч – физик көч түгел, ә рухи көч.

Аллаһның расүле галәйһиссәләм әйткән: *“Сугышта үз дошманнарын җиңгән кеше чын батыр булмас, ә ачу килгәндә ачуын йота алган кеше чын батыр булыр”,* – дигән (Бохари).

7) Аллаһның расүле Мөхәммәд галәйһиссәләмнең күркәм әхлагын һәрвакыт истә тоту.

Искә төшерик әле, мөхтәрәм җәмәгать! Пәйгамбәребез галәйһиссәләм, үзенә пәйгамбәрлек иңгәннән соң, ун ел Мәккә шәһәрендә кешеләрне иманга чакырды, ләкин иманга килүчеләрнең саны гаять дәрәҗәдә аз иде. Аны рәнҗеттеләр, төрле авыр сүзләр әйттеләр. Шулар өстәвенә, пәйгамбәрлекнең 10нчы елында, Пәйгамбәребез галәйһиссәләмне тәрбияләп үстергән, аңа таяныч булган агасы Әбү Талиб үлеп китте. Аңа терәк, таяныч булган хатыны Хәдичә (Аллаһ аннан разый булсын) вафат булды, шуңа күрә пәйгамбәрлекнең унынчы елын – кайгы елы дип атадылар. Шуннан соң да Пәйгамбәребез галәйһиссәләмгә бик күп авырлыклар күрергә туры килде. Аллаһның расүле галәйһиссәләм Мәккә шәһәрендәге кешеләрне иманга өнди-өнди гаҗиз булгач, кешеләрне дингә чакырыр өчен Зәед бин Харис (Алла аннан разый булса иде) исемле сәхабәсе белән Мәккәдәнерактарак булган Таиф шәһәренә барды. Анда да аны бик начар каршыладылар, ташлар атып, куып җибәрделәр. Пәйгамбәребез галәйһиссәләмнең аяклары ярылып, канап бетте. Шәһәрдән чыккач, Пәйгамбәребез галәйһиссәләм болай дип дога кылды: “Йә, Раббым, мин үземнең көчсезлегемнән, гаҗизлегемнән Сиңа сыенам. Йә Раббым, миңа золымлык кылган кешеләрнең зарарыннан сиңа

сыенам. Йә, Раббым, миңа дөрес юлларны күрсәт. Әллә мин өндәгән дин дөрес түгелме? Әллә минем берәр гаебем бармы?" – дип Аллаһы Тәгаләдән сорады. Аллаһ Пәйгамбәребез галәйһиссәләмнең шушы догасын ишеткәч, Җәбраил фәрештәгә ияртеп, тау фәрештәсен җибәрде. Тау фәрештәсе болай дип әйтте: Йә, Мөхәммәд, мин – тау фәрештәсе. Аллаһы Тәгалә синең янына җибәрде. Әгәр теләсәң, Таиф халкын тау астында калдырам, һәлак итәм, – диде. Пәйгамбәребез галәйһиссәләм моңа ризалык бирмәде: "Алар иманга килерләр әле, алар өметсез түгел, һәлак итмик", – дип әйтте. Бу – безгә зур үрнәк. Сөекле Пәйгамбәребез галәйһиссәләм шундый авыр чакта сабыр булып калды, ачуын йотты.

8) Ачуның зыянын истә тоту.

Әгәр ачуланган вакытта Аллаһ күреп һәм ишетеп торганын истә тотсак, үзебезне ничек тотар идек? Яки яныбызда сөекле Пәйгамбәребез галәйһиссәләм басып торса, нәрсә эшләр идек? Ачу – кешеләр сыйфаты түгел, ә хайваннар сыйфаты.

Бер көнне Гайсә галәйһиссәләм яһүдиләр яныннан үткәндә, үзенә карата әйтелгән начар сүзләр ишетте. Ул аларга изге сүз белән җавап бирде. Гайсә галәйһиссәләм янында булган кешеләр гаҗәпләнеп сорадылар: "Ничек инде син үзеңә начар сүзләр әйткән кешеләргә изге сүзләр белән җавап бирдең?" – диделәр. Гайсә галәйһиссәләм болай диде: "Һәр кеше үзендә булган нәрсәне сарыф итә".

Мөхтәрәм мөселманнар! Бер риваять сөйләп үтәм.

Начар холыклы бер егеткә этисе бер капчык кадак бирә һәм:

- Әй, улым, ачуың килеп, яки кем белән булса да ачуланышканда бакча диварына бер кадак кагып куй, - дип әйтә.

Улы беренче көнне үк утыз җиде кадак кага, әмма көннән-көн кадаклаулар күпкә кими бара, ягъни егет әкренләп ачу хисләрен тыярга өйрәнә, чөнки ул кадаклауга караганда ачу хисләрен тыеп калуның җиңелрәк икәнен аңлый башлый. Шулай итеп, бу егет ачуын тыярга өйрәнә һәм

кадаклаудан бөтенләй арына. Әтисе янына барып, шушы яңалыкны хәбәр итә. Атасы аңа:

- Әй, улым, хәзер инде, киресенчә, ачуың килгәндә барып, каккан кадакларыңны берәмләп кире суырып ал, - дип әйтә. Күпмедер вакыт үткәч, егет әтисенә:

- Син кушканнарны эшләдем. Диварда бер кадак та калмады, барысын да суырып алдым, - дип әйтә. Атасы аны дивар янына алып барып:

- Улым, син, әлбәттә, сүземне үтәдең, ләкин диварда күпме тишек калганын күрәсеңме? Нәрсә генә эшләтсәң дә, беренче хәләтендәге кебек яңа булмаячак инде. Әгәр син сабыр итә алмыйча, берәрсе белән ачуланышып, аңа авыр сүзләр әйтәсең икән, бу гамәл аның йөрәгенә шул кадаклар кебек тәэсир итәчәк. Соңыннан күпме генә гафу үтенсәң дә, (кадакларны кире суырып алган кебек) әйткән сүзләрең өчен гафу үтенсәң дә, барыбер күңелендә ялары калачак. Авыр сүз белән берәрсенең күңелен яралау кайвакыт кул белән яра ясауга караганда да катырак, шуңа күрә, әй, улым, якыннарың, туганнарың, дусларың һәм, гомумән, кешеләр белән аралашкан вакытыңда, авыр сүз әйтер алдыннан бик нык итеп уйла син. Кадак кагу белән күрсәткән мисалны беркайчан да онытма, улым, – дип әйтә.

Пәйгамбәребез үзенең бер мәшһүр хәдисендә әйткән: *“Кем Аллаһы Тәгаләгә һәм Ахирәт көненә иман китергән булса, кунагын хөрмәт итсен. Кем Аллаһы Тәгаләгә һәм Ахирәт көненә иман китергән булса, күршесенә игелек итсен. Кем Аллаһы Тәгаләгә һәм Ахирәт көненә иман китергән булса, хәерле сүз сөйләсен, яисә дәшмичә торсын”,* – дигән (Бохари, Мөслим).

Аллаһы Раббыбыз барчабызга бары тик файдалы, кирәкле сүзләр сөйләргә, ачу килгәндә ачуны йотарга һәм сабыр булырга насыйп итсә иде.

*Җомга хөтбәсе*

## Беренче хөтбә

بِسْــمِ اللهِ الرَّحْمَنِ الرَّحِيمِ

اَلْحَمْدُ لله اَلْحَمْدُ لله اَلْحَمْدُ لله الَّذِي هَدَينَا لِهَذَا وَ مَا كُنَّا لِنَهْتَدِيَ لَوْلاَ أنْ هَدَينَا الله وَ مَا تَوْفِيقِي وَاعْتِصَامِي إلاَّ بِالله فَسُبْحَانَ الَّذِي قَالَ فِي كِتَابِهِ الْكَرِيمْ **وَ مَا تَشَاؤُنَ إلاَّ أنْ يَشَاءَ الله** نَشْهَدُ أنْ لاَ إلَهَ إلاَّ الله وَحْدَهُ لاَ شَرِيكَ لَهُ شَهَادَةً مُنْجِيَةً مِنْ عَذَابِ الله وَ نَشْهَدُ أنَّ سَيِّدَنَا مُحَمَّدًا عَبْدُهُ وَ رَسُولُهْ دَاعِينَا إلَي الله صَلَّ اللهُ تَعَالَي عَلَيْهِ وَ عَلَي اَوْلاَدِهِ وَ اَزْوَاجِهِ وَ عَلَي خُلَفَائِهِ الرَّاشِدِينَ الْمُرْشِدِينَ الْمَهْدِيِّينَ مِنْ بَعْدِهِ وَوُزَرَائِهِ الْكَامِلِينَ فِي عَهْدِهْ خُصُوصًا مِنْهُمْ عَلَي الْاَئِمَّةِ بِالْحَقِّ اُمَرَاءِ الْمُؤْمِنِينَ أبِي بَكْرٍ وَ عُمَرَ وَ عُثْمَانَ وَ عَلِيٍّ وَ عَلَي بَقِيَّةِ الصَّحَابَةِ وَ التَّابِعِينَ لَهُمْ بِاِحْسَانٍ اِلَي يَوْمِ الدِّينْ رِضْوَانُ اللهِ تَعَالَي عَلَيْهِمْ اَجْمَعِينْ

أمَّا بَعْدُ فَيَا عِبَادَاللهْ إتَّقُوا اللهَ وَ اَطِيعُوهْ إنَّ اللهَ مَعَ الَّذِينَ اتَّقَوْا وَالَّذِينَ هُمْ مُحْسِنُونْ قَالَ الله عَزَّ وَ جَلَّ فِي كِتَابِهِ الْكَرِيمْ أسْتَعِيذُ بِاللهْ.......... وَ قَالَ النَّبِيُّ صَلَّي اللهُ عَلَيْهِ وَ سَلَّمْ......

Имам-хатыйб вәгазь темасына багышланган аять һәм хәдис укый

ألاَ إنَّ أحْسَنَ الْكَلاَمِ وَ اَبْلَغَ النِّظَامْ كَلاَمُ اللهِ الْمَلِكِ الْعَزِيزِ الْعَلاَّمْ كَمَا قَالَ اللهُ تَبَارَكَ وَ تَعَالَي فِي الْكَلاَمْ وَ اِذَا قُرِئَ الْقُرْاَنُ فَاسْتَمِعُوا لَهُ وَ اَنْصِتُوا لَعَلَّكُمْ تُرْحَمُونْ أسْتَعِيذُ بِالله: **اِنَ الدِّينَ عِنْدَ اَللهِ الْاِسلاَمُ**

(Имам-хатыйб мөнбәргә утырып эчтән генә дога кыла)

Мәсәлән, түбәндәге дога укырга мөмкин:

بَرَكَ اللهُ لَنَا وَ لَكُمْ وَ لِسَاءِرِ الْمُؤْمِنِينَ وَ الْمُؤْمِنَاتْ وَالْمُسْلِمِينَ وَ الْمُسْلِمَاتْ اَلْاَحْيَاءِ مِنْهُمْ وَ الْاَمْوَتْ اِنَّكَ سَمِيعٌ قَرِيبٌ مُجِيبُ الدَّعَوَاتْ بِرَحْمَتِكَ يَا اَرْحَمَ الرَّاحِمِينْ وَ سَلاَمٌ عَلَي الْمُرْسَلِينْ وَالْحَمْدُ للهِ رَبِّ الْعَالَمِينْ

Утырып дога кылганнан соң имам-хатыйб басып икенче хөтбә укырга тиеш.

## |Икенче хөтбә

أَلْحَمدُ لِلّٰهِ حَمْدَ الْكَامِلِينَ وَ الصَّلٰوةُ وَ السَّلاَمُ عَلَي سَيِّدِ الْاَوَّلِينَ وَ الْاٰخِرِينَ مُحَمَّدٍ وَ اٰلِهِ وَ صَحِبِهِ اَجْمَعِينْ تَعْظِيمًا لِنَبِيِّهِ وَ تَكْرِيمًا لِفَخَامَةِ شَانِ شَرَفِ صَفِيِّهِ فَقَالَ عَزَّ وَ جَلَّ مِنْ قَاءِلٍ مُخْبِرًا وَ اٰمِرًا **إِنَّ اللَّهَ وَمَلَائِكَتَهُ يُصَلُّونَ عَلَى النَّبِيِّ يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا صَلُّوا عَلَيْهِ وَسَلِّمُوا تَسْلِيماً**

اَللَّهُمَّ صَلِّ ... اَللَّهُمَّ بَارِكْ ...

اَللَّهُمَّ وَارْضَ عَنِ الْخُلَفَاءِ الْاَرْبَعَةِ ذَوِي الْقَدْرِ الْجَلِيِّ وَ الشَّرَفِ الْعَلِيِّ سَيِّدِنَا اَبِي بَكْرٍ وَ عُمَرَ وَ عُثْمَانَ وَ عَلِيٍّ رَضِيَ اللهُ عَنْهُمْ وَ عَنِ السِتَّةِ الْبَاقِيةِ مِنَ الْعَشَرَةِ الْمُبَشَّرَةِ وَ عَنِ الْعَمَّيْنِ الْمُكَرَّمَيْنِ عِنْدَاللهْ اَلْمُحْتَرَمَيْنِ عِنْدَ النَّاسْ سَيِّدِنَا الْحَمْزَةَ وَالْعَبَّاسْ وَ عَنِ السِّبْطَيْنِ الْجَلِيلَيْنِ السَّعِيدَيْنِ الشَّهِيدَيْنِ سَيِّدِنَاالْحَسَنِ وَ سَيِّدِنَا الْحُسَيْنِ وَ عَنْ سَائِرِ الْمُؤْمِنِينَ وَ الْمُؤْمِنَاتْ وَالْمُسْلِمِينَ وَ الْمُسْلِمَاتْ اَلْاَحْيَاءِ مِنْهُمْ وَ الْاَمْوَاتْ اِنَّكَ سَمِيعٌ قَرِيبٌ مُجِيبُ الدَّعَوَاتْ بِرَحْمَتِكَ يَا اَرْحَمَ الرَّاحِمِنْ

اَللَّهُمَّ انْصُرْ مَنْ نَصَرَ الدِّينْ وَاخْذُلْ مَنْ خَذَلَ الْمُسْلِمِينْ

اَللَّهُمَّ انْصُرْ جُيُوشَ الْمُسْلِمِينْ وَ عَسَاكِرَ الْمُوَحِّدِينْ وَاكْتُبِ الصِّحَّةَ وَ السَّلاَمَةَ عَلَيْنَا وَ عَلَي الْحُجَّاجِ وَ الْغُزَاةِ وَ الْمُسَافِرِينَ وَ الْمُقِيمِينَ وَ الْحَاضِرِينَ وَ الْغَائِبِينَ فِي بَرِّكَ وَبَحْرِكَ هَوَائِكَ مِنْ اُمَّةِ مُحَمَّدٍ عَلَيْهِمْ اَجْمَعِينْ وَ السَّلاَمٌ عَلَي الْمُرْسَلِينْ وَ الْحَمْدُ لِلّٰهِ رَبِّ الْعَالَمِينْ أَسْتَعِيذُ بِاللهِ :

اِنَّ اللهَ يَاْمُرُ بِالْعَدْلِ وَالْاِحْسَانِ وَ اِيتَاءِ ذِي الْقُرْبَي وَ يَنْهَا عَنِ الْفَحْشَاءِ وَ الْمُنْكَرِ وَ الْبَغْيِ يَعِظُكُمْ لَعَلَّكُمْ تَذَكَّرُونْ وَلَذِكْرُاللهِ اَكْبَرْ وَاللهُ يَعْلَمُ مَا تَصْنَعُونْ

*3 нче кушымта*

### *Корбан гаете вәгазе*

*Әгүүзү билләәһи минәш-шәйтаанир-раҗиием. Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиием. Әлхәмдүлилләәһил ләзи һәдәнә лил-иймән вәссаләәтү вәссәләәмү галәә расүүлиһи Мүхәммәдин сәййидил әнәми үә гәләә әәлиһи үә әсхабиһи әҗмәгиин.*

Безнең күңелләребезне иман, Ислам нуры белән нурландырган Аллаһы Тәбәракә вә Тәгаләгә чиксез хәмед һәм шөкраналарыбыз булса иде. Бөтен мәхлукатның хәерлесе булган, безгә бу дөньяда һәм ахирәттә бәхетле булырга өйрәткән сөекле Пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу

галәйһи вәссәлам хәзрәтләренә, аның хөрмәтле гаиләсенә, барлык сәхабәләренә сәламнәребез һәм салаватларыбыз булса иде.

Шәһәребезнең төрле почмакларыннан, ерак һәм якын җирләрдән килеп, шушы изге Корбан бәйрәме көнендә Раббыбыз Аллаһы Тәгаләнең әмерен үтәр өчен мәчетебезгә җыелган мөхтәрәм дин кардәшләрем сезгә динебезнең күркәм сәләмен җиткерәм: әссәләәмү галәйкүм үә рахмәтүллаһи үә бәракәәтүһ!

Хөрмәтле мөселманнар! Елга бер мәртәбә була торган бөек бәйрәмебез – Корбан гаете барчаларыбызга мөбарәк һәм хәерле булсын! Аллаһы Сөбханә вә Тәгалә ил-көннәребезгә, җаннарыбызга тынычлык, тәннәребезгә исәнлек-саулык, күңелләребезгә тәүфикъ-һидаять биреп, һәркайсыбызга хәерле һәм бәрәкәтле тормышлар насыйп итсен. Мөкаддәс Корбан бәйрәме көннәрендә ихлас күңелдән изге гамәл-гыйбадәтләр кылып, корбаннарыбызны чалып Аллаһы Тәгаләнең иксез-чиксез рәхмәтлренә барчабызга да ирешергә насыйп булсын!

Аллаһы Раббыбыз мәчетебезгә Корбан гаете вәгазен тыңларга һәм Гает намазын укырга дип килгән кардәшләребездән һәм төрле сәбәпләр аркасында Гает намазына килә алмаганнарыбыздан, һәркайсыбыздан догага мохтаҗ булган барлык әрхавларыбызның гөнаһларын, хата-кимчелекләрен гафу итеп, рухларын шат кылса иде.

Мөхтәрәм җәмәгать! Аллаһы Тәбәракә вә Тәгаләнең барлыгына һәм берлегенә ышанып, Аның кушканнарын үтәп, тыйган гамәләреннән тыелып яшәү – кешенең төп вазифасы булып тора. Аллаһы Сөбханә вә Тәгалә кешене бу дөньяга нәкъ менә шуның өчен җибәрде дә. Һәрбер мөселман үзенең Раббысына омтылырга, Аны искә алырга, һәрбер гамәлне Аның ризалыгы өчен кылырга тиеш, чөнки ул бары тик Аллаһы Тәгаләнең рәхмәте аркасында яши. Кайвакыт кеше үз Раббысын онытып, хаталар, гөнаһлы гамәлләр кыла, үзен һәлакәт чокырына ташлый, кальбен каралта. Шушы гөнаһлардан, хата-кимчелекләрдән пакьлану, Аллаһы Тәгаләгә якынаю юлларның берсе – хаҗ гыйбадәте. Бөтен Ислам галимнәренең уртак фикере буенча хаҗ гыйбадәте

һәрбер хәлле мөселман өчен фарыз (тиешле) гамәл булып тора. Аллаһы Тәгалә Коръән Кәримдә болай дип әйтә:

وَلِلّهِ عَلَى النَّاسِ حِجُّ الْبَيْتِ مَنِ اسْتَطَاعَ إِلَيْهِ سَبِيلاً

*“Мөмкинлекләре булган кешеләрнең Аллаһы Тәгалә каршындагы бурычлары – Аның йортына хаҗ кылу”* (“Гыймран” сүрәсе, 97нче аять).

Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәлам үзенең бер хәдисендә әйткән: *“Әгәр берәү хаҗ кылып, бозыклык кылмаса, өенә анасы тудырган көндәге кебек гөнаһсыз булып кайтыр”,* – дигән (Бохари, Мөслим, Насаи).

Бүген, ягъни зөлхиҗҗә аеның 10нчы көнендә хаҗиларыбыз хаҗ гыйбадәтенең төп гамәлләрен тәмамлап, ихлас күңелләре белән Кәгъбәтуллага юнәлеп тәлбия, ягъни *«Ләббәйкәллаһүммә ләббәйк. Ләббәйкә ләә шәриикә ләкә, ләббәйк! Иннәл-хәмдә вән-нигъмәтә ләкә вәл-мүлк, ләә шәриикә ләк!»* (“Йә Аллаһ, менә мин Синең каршыңда! Менә мин синең каршыңда! Менә мин Синең каршыңда! Сиңа иптәш булырлык бернинди дә зат юк! Барча мактау Сиңа гына, барлык нигъмәт һәм хөкем Синең кулыңда гына! Сиңа иптәш булырлык бернинди дә зат юк!”) - дип әйтәләр.

Газиз дин кардәшләрем! Төрле илләрдә яшәүче ничәшәр йөз миллион мөселманнар кебек, без дә бүген изге Корбан гаетенә шатланып, тәһарәт-гoселләр алып, пакь, матур киемнәр киеп, хушбуйлар сөртеп, тәкбирләр әйтеп, Аллаһ йортына, ягъни мәчеткә җыелдык.

Корбан сүзе нәрсәне аңлата соң? Корбан гарәпчәдән “якынаю”, “якын булу” дип тәрҗемә ителә. Без бу мөбарәк бәйрәмдә Гает намазларын укып, Аллаһ ризалыгы өчен корбаннар чалып, игелекле гамәлләр кылып, Аллаһның рәхмәтенә якынаябыз, шуңа күрә бу олуг бәйрәмебезне шатланып каршы алабыз.

Корбан гаете барлык мөселманнарны берләштерә, якынайта, аларның күңелләре сөю, хөрмәт, бер-береңә миһербанлык һәм шәфкать хисләре белән тула. Бу мөбарәк көнне нәфрәт һәм ачулар юкка чыга, дошманлык

һәм үпкә хисләре бетә.

Хөрмәтле мөселманнар! Аллаһның рәхмәтенә якынайта торган изге Корбан бәйрәме тирән мәгънәгә ия. Гарәпчә бу бәйрәм “”Гыйд әл-әдха” дип атала. “Әдха” сүзе корбан чалу дигәнне аңлата. Мәгълүм булганча, корбан чалу йоласы безгә Ибраһим галәйһиссәләм белән Исмәгыйль галәйһиссәләмнән калган. Без корбан чалганда шуны аңларга тиеш: Аллаһы Тәгаләгә корбанның ите дә, каны да кирәк түгел, Аңа безнең тәкъвалыгыбыз гына ирешә. Бу хакта Аллаһы Раббыбыз Коръәндә үзе әйтә:

**لَن يَنَالَ اللَّهَ لُحُومُهَا وَلَا دِمَاؤُهَا وَلَكِن يَنَالُهُ التَّقْوَى مِنكُمْ كَذَلِكَ سَخَّرَهَا لَكُمْ لِتُكَبِّرُوا اللَّهَ عَلَى مَا هَدَاكُمْ وَبَشِّرِ الْمُحْسِنِينَ**

*“Аларның (корбанга чалынган хайваннарның) ни ите, ни каны Аллаһка түгел, Аңа фәкать сезнең тәкъвалыгыгыз гына ирешә”* (“Хаҗ” сүрәсе, 37нче аять).

Тәкъва булган, Аллаһны чын күңелдән сөйгән кеше корбанны Аллаһы Тәгалә ризалыгы өчен чалып, гаиләсен, килгән кунакларын һәм күршеләрен, фәкыйрьләрне һәм мескеннәрне хөрмәт итә, аларның күңелләрен күтәрә. Шулай итеп, ул Аллаһның ризалыгына ирештерә торган гамәлләр кыла. Коръәни Кәримдә әйтелгән:

**يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُواْ اتَّقُواْ اللّهَ وَابْتَغُواْ إِلَيهِ الْوَسِيلَةَ وَجَاهِدُواْ فِي سَبِيلِهِ لَعَلَّكُمْ تُفْلِحُونَ**

*“Әй иман китергән кешеләр, гөнаһ эшләп, Аллаһ каршысында җавап бирүдән куркыгыз. Аңа якынлашырга юллар эзләгез, Аның юлында Җиһад кылыгыз (тырышыгыз): бәхеткә ирешерсез”* (“Маидә” сүрәсе, 35нче аять).

Мөхтәрәм дин кардәшләрем! Әгәр без Аллаһ газабыннан котылырга һәм Аның рәхмәтенә ирешергә, бәхетле булырга телибез икән, алдагы аятьтә әйтелгәнчә, Ислам юлында тырышырга, ягъни Корбан бәйрәме көннәрендә генә түгел, ә һәр көнне гөнаһлардан сакланып, Аллаһка шөкрана кылып, күбрәк игелекле гамәлләр эшләп яшәргә тиешбез.

Аллаһы Тәгалә «Бәкарә» сүрәсенең 29-30нчы аятьләрендә болай дип әйткән:

هُوَ الَّذِي خَلَقَ لَكُم مَّا فِي الأَرْضِ جَمِيعاً ثُمَّ اسْتَوَى إِلَى السَّمَاء فَسَوَّاهُنَّ سَبْعَ سَمَاوَاتٍ وَهُوَ بِكُلِّ شَيْءٍ عَلِيمٌ
وَإِذْ قَالَ رَبُّكَ لِلْمَلاَئِكَةِ إِنِّي جَاعِلٌ فِي الأَرْضِ خَلِيفَةً قَالُواْ أَتَجْعَلُ فِيهَا مَن يُفْسِدُ فِيهَا وَيَسْفِكُ الدِّمَاء وَنَحْنُ نُسَبِّحُ بِحَمْدِكَ وَنُقَدِّسُ لَكَ قَالَ إِنِّي أَعْلَمُ مَا لاَ تَعْلَمُونَ

*“Җир йөзендә ни булса, Ул барысын да сезнең өчен яралтты. Соңрак күкне төзергә теләде һәм аны җиде кат итеп корды. Ул – барысын да белүче. (Ий Мөхәммәд) исеңдә тот, Раббың фәрештәләргә әйтте: “Мин Җир йөзенә (Адәмне) хәлифә (башлык, хуҗа) итеп яралтачакмын”, – диде. Фәрештәләр әйтте: “Без Сине мактап, тәсбих әйтеп, Аллаһы Тәгалә кимчелекләрдән азат, дип, Сине зурлап торганда, Җир өстендә азгынлык кылачак һәм кан коячак бәндәңнеме хәлифә итеп куячаксың?” – диделәр. (Аллаһ аларга) әйтте: “Сез белмәгәннәрне һәрхәлдә мин беләмен”, – диде.*

Шул рәвешле, Аллаһы Раббыбыз Адәм балаларын күркәм сурәттә яралтып, акыл, зиһен биреп, барлык мәхлуклардан өстен кылган. Аллаһы Тәгалә җир өстендә һәм астында булган байлыкларны, судагы хисапсыз күп балыкларны, бөтен җан ияләрен безгә буйсынучы, итагать итүче итеп яралткан. Безгә, Адәм балаларына бернинди мәхлукка бирелмәгән хәлифә дәрәҗәсе бирелгән. Инде Аллаһ Раббыбыз безне шундый олуг нигъмәтләр белән бүләкләгәннән соң, безгә зур гына вазифалар, бурычлар йөкләгән. Коръән Кәримдә “Тәхрим” сүрәсенең 6нчы аятендә адәмнәр өстендәге олуг вазифаларның кайберләре искә алына. Шул вазифаларны үтәмәүчеләр каты газапка дучар булачаклары турында белдерелә:

يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا قُوا أَنفُسَكُمْ وَأَهْلِيكُمْ نَارًا وَقُودُهَا النَّاسُ وَالْحِجَارَةُ

*Әй, иманлы бәндәләр, үзегезне, гаиләгезне уттан саклагыз. Ул утның*

*утыны кешелек вазифаларын, кешелек бурычын үтәмәгән адәмнәр булыр.*

Шулай итеп, Аллаһы Раббыбыз бу аять белән безгә белдерәдер ки, үзебезне һәм гаиләбезне дөнья, ахирәт бәхетсезлегенә сәбәп булган начар эшләрдән тыеп, җәһәннәм газабыннан сакларга куша. Өстебездә булган зур бурычларыбыз хакында Расүл әкрам галәйһиссәләм үзенең бер хәдисендә болай дип әйткән: *"Әй, бәндә, синең өстеңдә Раббыңның хакы, нәфесең һәм әгъзаларыңның хакы бар һәм гаиләңнең хакы бар, һәрбер хак иясенә хакларын бир, вазифаңны үтә",* – дигән.

Беренче вазифа – Аллаһы Тәбәракә вә Тәгалә каршында булган вазифа, ягъни дөньяны, бөтен галәмнәрне юктан бар кылган Аллаһны тану, биргән барлык нигъмәтләренә шөкрана кылып, һәрвакыт һәр җирдә Аллаһ хозурына барып, хисап бирәчәгебезне истә тоту.

Икенче вазифа – кешенең үзе хакындагы вазифа, ягъни Аллаһ биргән тән сәламәтлеген саклау. Авыру булса – дәвалану. Күп кенә тән авырулары дөрес тукланмаудан килә. Бүгенге көндә без чамадан тыш күп ашыйбыз һәм эчәбез, ашказаннарыбызга ял бирмибез. Пәйгамбәребез галәйһиссәләм ашказанын өчкә бүләргә кушкан: бер өлеше ризык өчен, бер өлеше – су, бер өлеше һава өчен *(Тирмизи)*. Аллаһы Раббыбыз бу хакта Үзенең китабында да әйткән:

كُلُواْ وَاشْرَبُواْ وَلاَ تُسْرِفُواْ إِنَّهُ لاَ يُحِبُّ الْمُسْرِفِينَ

*"Ашагыз, эчегез, ләкин исраф кылмагыз. Аллаһ исрафчыларны сөйми"* («Әгъраф" сүрәсе, 31нче аять).

Күп ашау кунак сыйлаганда һәм сәхәр вакытында гына дөрес санала. Без һәрвакыт дөрес туклануга игътибар итәргә тиеш, чөнки 50 процент авырулар ризыктагы матдәләр аша килә. Мәсәлән, шәригатьчә бугазланмаган хайваннарның итләрендә зарарлы матдәләр күп була. Ризыкны яхшы ният һәм фикер белән әзерләү, шулай ук мөһим булып тора. Сырхау килгәнче сәламәтлегебезнең кадерен белик.

Аллаһның расүле галәйһиссәләм үзенең бер хәдисендә: *Пакьлек*

*(чисталык) – иманның яртысы”*, – дигән (Мөслим, Тирмизи). Шуңа күрә суны еш кулланырга, һәрвакыт тәһарәтле килеш йөрергә тырышырга кирәк. Су – яшәү чыганагы: суны никадәр күбрәк кулласак, шулкадәр сәламәтлегебез артачак. Ашаганчы һәм ашаганнан соң бер чеметем тоз куллану – авыруның профилактикасы булып тора. Пәйгамбәребез галәйһиссәләм тәннең сәламәтлеген саклау өчен, корсакка ятып йокламаска, уң якка ятарга киңәш иткән.

Адәм баласының үзе хакындагы икенче бурычы – акылны гыйлем белән баету. Пәйгамбәребез галәйһиссәләм әйткән: *“Белем алу – һәрбер мөселман өчен фарыз (тиешле)”*, – дигән (Ибн Мәҗә).

Мөселман кеше, дөньяви гыйлемме, дин гыйлемеме – икесен дә тигез күреп, өйрәнергә бурычлы, чөнки дөньяви гыйлем белән дини гыйлем, үзара бәйләнгән рәвештә, бер-берсен тулыландыра.

Адәм баласының үзе хакында өченче бурычы – күңелен, җанын тәрбияләп, начар сыйфатлардан арындырып, күркәм сыйфатлар белән бизәп, бөтен кешеләр белән дус, тату, тыныч торырга һәм игелекле гамәлләр кылырга тырышу. Расүл әкрам галәйһиссәләм әйткән: *«Аллаһы Тәгалә сезне тышкы кыяфәтегез һәм матди быйлылыгыз буенча бәяләмәс. Ул сезнең күңелләрегезгә (калебләрегезгә) һәм сез кылган гамәлләрегезгә карый»,* – дигән (Табарани).

Икенче хәдис-шәрифтә болай дип әйтелгән:

“*Белегез, кеше тәнендә бер ит кисәге бар, әгәр ул сәламәт булса, бөтен тән сәламәт булыр, әгәр ул авыру булса, бөтен тән авыру булыр. Белегез ки, ул ит кисәге – калебтер”* (Бохари, Мөслим).

Бу хәдисләрдән күренгәнчә, динебез калебкә зур әһәмият биреп, аңа игътибарлы булырга боера. Һәр мөселман үз калебенә хуҗа булырга тиеш. Калебләребезне сафландыру – һәрбер мөселманның изге бурычы. Калебләрне өч төргә бүләргә мөмкин.

Беренчесе, иман белән нурланган калебләр. Алар – Аллаһка һәм Аның расүле Мөхәммәд галәйһиссәләмгә бәйләнгән, Ислам шәригатенә буйсынган

бәхетле калебләр.

Икенчесе, ширек һәм көферлек белән каралган калебләр. Алар – яшәү мәгънәсен аңламаган, бары тик матди, дөньяви ләззәтләргә бирелгән бәхетсез калебләр.

Өченчесе, гөнаһ белән пычранган калебләр. Аларга ия булган кешеләр беренче карашка иман нигезләрен кабул иткән булып күренсәләр дә, намаз, ураза кебек гыйбадәтләрне вакытында үтәмиләр яисә бөтенләй башкармыйлар. Шундый калебләр исерткеч эчемлекләр куллану, отыш уеннар уйнау, риба, ялган кебек гөнаһларга баткан.

Иң гүзәл калебләр – иман, Ислам нуры белән нурланган, күркәм гамәлләр белән бизәлгән һәм һәртөрле гөнаһтан сакланган сөенечле калебләр. Аларга ия булучылар ике дөньяда да бәхеткә ирешәчәкләр. Шуңа күрә мөселман һәрвакыт һәм һәр урында калебне каралта торган гамәлләрдән ерак торырга тырыша. Киресенчә булса, ул үзен олы куркынычка илтә. Сөекле Пәйгамбәребез галәйһиссәләм әйткән: *“Мөэмин бер гөнаһ эшләгән вакытта аның калебендә бер кара тап барлыкка килә. Әгәр ул тәүбә итеп, бу гөнаһтан ваз кичсә, аның калебе пакьлана. Әгәр ул тәүбә итмәсә һәм гөнаһлы гамәлне кылуны дәвам итсә, аның калебендә кара таплар саны арта һәм калебе каралана”,* – дигән (Ибн Мәҗә).

Түбәндәге аятьләрне истән чыгармыйк:

قَدْ أَفْلَحَ مَن زَكَّاهَا
وَقَدْ خَابَ مَن دَسَّاهَا

*Җанын пакь тоткан кеше морадына (сәгадәткә) ирешәчәк. Вөҗданын кер каплаган кеше, әлбәттә, хәтәр зыян күрәчәк* (“Шәмес” сүрәсе, 9-10 аятьләр).

أَلاَ بِذِكْرِ اللّهِ تَطْمَئِنُّ الْقُلُوبُ

*«Мәгълүмдер ки, Аллаһ турында уйлаганда, Аны зекер иткәндә күңелләр рәхәт тынычлыкка ирешә»* (“Рәгыд” сүрәсе, 28нче аять).

**يَوْمَ لَا يَنفَعُ مَالٌ وَلَا بَنُونَ  إِلَّا مَنْ أَتَى اللَّهَ بِقَلْبٍ سَلِيمٍ**

*“Ул Көнне мал да, угыллар да файда китермәс. Әмма Аллаһка саф күңел белән инанганнар бәхетле булыр”* (“Шөгарә” сүрәсе, 88-89нчы аятьләр).

Мөхтәрәм мөселманнар! Шуны һәрвакыт истә тотыйк, изге гамәлләребез Аллаһ тарафыннан кабул булсын өчен калебләребез иманнан башка ихласлык белән дә бизәкләнгән булырга тиеш. Күп санлы изге гамәлләрне ихлассызлык белән үтәүгә караганда, аз санлы гамәлләрне ихласлык белән кылу күпкә яхшырак. Бу турыда бөек ислам шагыйре, фикер иясе Җәләлетдин Руми (Аллаһның рәхмәтендә булса иде) әсәреннән бер кыйсса сөйләп үтәсем килә.

Кешеләр үзләренең җитәкчеләренә аларның зур территорияләр белән идарә итә белүләре өчен генә түгел, ә халыкка эчкерсез мөнәсәбәтләре, күркәмлекләре өчен илтифат иткән заманда, еш кына Багдадка (башкала) бүләк яки яхшы сүз белән җитәкчегә үзләренең хөрмәтләрен һәм рәхмәтләрен тапшырырга бара торган булганнар. Бервакыт бер фәкыйрь дә үзеннән бүләк тапшырырга уйлаган, ләкин озак уйланулар һәм эзләнүләр нәтиҗәсендә үзендә бернинди кыйммәтле нәрсә дә тапмаган. Инде өметен өзеп, ул үзенең бердәнбер байлыгы – кырые кителгән, ләкин әле кулланып була торган иске чүлмәкне искә төшергән. Ул аңа үзенең коесыннан су тутырган һәм юлга чыккан.

Багдад юлында берәү очрап, фәкыйрьдән кая һәм ни өчен юл тотуы турында сораган. Җавапны ишеткәч, сораучы: “Тыңла әле, хакимдә күпме телисең, шулкадәр су бар, хәтта синең коеңдагы су да анықы!” – дигән. Фәкыйрь аптырап калган, ләкин элекке ниятен саклап: “Мин гади кеше, кыйммәтле бүләгем булмаса да, җаным аңа мәхәббәт белән тулы, һәм мин аңа бу суны булса да бүләк итү теләге белән янам”, – дип җавап биргән.

Ул юлын дәвам иткән һәм исән-имин килеш солтан сараена килеп җиткән, үзенең бүләген тапшырган, аны хөрмәт һәм кунакчыллык белән каршы алганнар. Өйгә кайтырга җыена башлагач, солтан да аның бүләгенә каршы бүләк бирергә теләгән: “Синең бүләгеңнең тышкы яктан нинди булуы мөһим түгел, – дип әйткән хаким, – аның чүлмәген алтын белән тутырыгыз!” – дигән.

Адәм балаларының өченче вазифасы – гаиләсе, ата-анасы, туган-тумачалары хакындагы вазифасы. Гаилә турында шуны әйтергә кирәк, бөек динебез аның һәрбер әгзасына күп кенә вазифалар йөкләгән. Гаиләнең һәр әгзасы үз вазифаларын төгәл үтәсә, шул вакытта гаилә нык булачак, шуңа күрә шул вазифаларны белү генә җитми, аларны җиренә җиткереп үтәргә дә кирәк. Ул вазифалар түбәндәгеләр:

– гаилә башлыгы буларак, ир кеше бәхетен һәм сөенечен үз гаиләсендә генә эзләргә, башка гаилә әгзаларыннан җитдирәк һәм төплерәк булырга, үз гаиләсен кирәк нәрсәләр белән тәэмин итәргә һәм ислам буенча яшәргә бөтен шартлар тудырырга тиеш.

– хатын кыз иң беренче чиратта иренә карата булган вазифаларны үтәргә тырышырга, аны үз мәхәббәте, йомшаклыгы, игътибарлыгы белән бүләкләргә һәм, әлбәттә, гаиләнең намусын һәм шәрәфен сакларга тиеш.

– ир һәм хатын якты чырайлы, тәмле телле, бер-берсен аңлап, хөрмәт итеп яшәргә, гаилә серләрен тышка чыгармаска, ниндидер аңлашылмаучанлык, каршылык килеп чыкса, бер-берсенә юл куярга, кирелек күрсәтмәскә тиеш.

– ата-ана үз балалары өчен күркәм үрнәк булырга, аларның матди һәм рухи ихтыяҗларын кәнәгатьләндерергә тиеш. Алар һәрбер балага гадел булырга, аларны начар дуслардан, хәрам гамәлләрдән сакларга, яхшы белем һәм тәрбия бирергә, киләчәктә үзләренә күркәм холыклы тормыш иптәшләрен табарга ярдәм итәргә тиеш.

– балалар, үз чиратында, әти-әниләрен хөрмәт итәргә, тел белән дә,

гамәлләре белән дә рәнҗетмәскә һәм үлемнәреннән соң дә онытмыйча, алар өчен дога кылып торырга тиешләр.

Алда әйтелгән кагыйдәләр буенча яшәгән гаилә, инша Аллаһ, нык, сәламәт һәм бәхетле булачак.

Туган-кардәшләребез – безнең өчен ата-аналарыбыздан соң иң якын кешеләр, шуның өчен алар белән һәрвакыт әдәпле һәм мәрхәмәтле булырга тырышыйк. Алар хакында сөекле Пәйгамбәребез галәйһиссәләм әйткән: *“Ризыгы киң һәм гомеренең озын булуын теләгән кеше туганнары белән элемтәне өзмәсен”,* – дигән (Бохари, Мөслим).

Газиз дин кардәшләрем! Вәгазем ахырында сезне бер риваять белән таныштырып үтәсем килә.

Бөек галим Җүнәйд Багдадига (Аллаһы Тәгалә аны Үзенең рәхмәтеннән аермаса иде) 7 яшь булганда, абыйсы Сарий Сакати аны үзе белән хаҗ гыйбадәтен кылырга алып барган. Хәрам мәчете (“Изге мәчет” дигән сүз) эчендә, ягъни Кәгъбәтулла янында төрле мәсьәләләр буенча сөйләшүләр барган, шуларның берсе шөкрана кылу турында булган. Анда катнашкан һәр шәех бу турыда үз белем-тәҗрибәләре белән уртаклашкан. Сарий Сакати Җүнәйдкә борылып, аңа шөкрана турында үз фикерен белдертергә кушкан. Бераз уйлагач, 7 яшьлек Җүнәйд түбәндәге гаҗәеп матур җавап биргән: “Шөкрана кылу – ул Аллаһы Тәгалә каршында гөнаһлы булмау, Аның нигъмәтләрен файдаланып, шулар белән гөнаһ кылмау”, – дигән.

Мөхтәрәм җәмәгать! Бу җаваптан күренгәнчә, Аллаһка шөкрана кылу, Аңа рәхмәт әйтү – ул намаз уку,  ураза тоту, Коръән уку кебек гыйбадәтләр белән генә чикләнми. Без Аллаһы Раббыбыз биргән әгъзаларыбыз белән дә гөнаһ эшләмәскә тиеш. Күзебезне хәрам булган нәрсәләрдән, телебезне – гайбәттән, ялганнан, яла ягудан, буш сүзләрдән саклыйк. Телләребез белән күбрәк Аллаһны искә алыйк, файдалы, дөрес сүзләр сөйлик. Карыныбызны хәрам ризыклардан, кулларыбызны хәрам гамәлләрдән, аякларыбызны Аллаһның ачуын китерә торган җирләргә

барудан саклыйк. Хәдис-шәрифтә болай диелгән: *“Файдасыз эшләрдән качу – яхшы мөселманның билгесе”* (Тирмизи).

Аллаһы Тәгалә барчабызга да ихлас шөкрана кылучылардан булырга, күңелләребездә булган барлык изге ниятләребезгә, максатларыбызга ирешергә, чалыначак корбаннарыбызның бәрәкәтен күрергә, бу дөньяда һәм ахирәт томышында да бәхетле булырга насыйп итсә иде.

*4 нче кушымта*

**Ураза гаете вәгазе**

*Әгүүзү билләәһи минәш-шәйтаанир-раҗиим. Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Әлхәмдүлилләәһи раббил гааләмиин вәссаләәтү вәссәләәмү галәә расүүлинә Мүхәммәдин саллаллаһу галәйһи вассәләм үә гәләә әәлиһи үә әсхабиһи әҗмәгиин.*

Җир-күкләрне яралтып, яңгырлар яудырып, шуның белән безгә барлык җимешләрен дә ризык итеп тәкъдим кылган, безне төрле нигъмәтләре белән бүләкләгән Аллаһы Сөбханә вә Тәгаләгә хәмед һәм сәнәләр, барча мактауларыбыз, олуглауларыбыз булса иде. Аллаһы Тәбәракә вә Тәгаләнең Хәбибе һәм Хак илчесе, бөтен галәмнәргә рәхмәт буларак җибәрелгән сөекле Пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа галәйһиссәләм хәзрәтләренә, аның хөрмәтле әһленә, сәхабәләренә, барчабызның сәламнәре, салаватлары һәм һәртөрле изге догалары булса иде.

Тәннәребезне арулап, пакь киемнәр киеп, Аллаһы Тәгаләнең рәхмәтенә һәм ризалыгына ирешер өчен Гаед фитыр намазына җыелган мөхтәрәм дин кардәшләрем! Сезне динебезнең күркәм сәламе белән сәламлим: әссәләәмү галәйкүм үә рахмәтүллаһи үә бәракәәтүһ!

Хөрмәтле мөселманнар! Һәркайсыгызны мөкаддәс көн, бөек бәйрәм, Гаед фитыр көне белән ихлас күңелдән тәбрик итәм. Гаед фитыр, ураза бәйрәмебез барчаларыбызга мөбарәк булып, алдагы елларыбызда да ил-

көннәребез, җан-тәннәребез тыныч һәм сәламәт булган хәлдә дини һәм дөньяви бәйрәм көннәрен шатлык белән күрергә насыйп булсын. Аллаһы Раббыбыз изге Рамазан аенда тоткан уразаларыбызны, укыган намазларыбызны, кылган изге гамәл-гыйбадәтләребезне кабул итеп, барыбызны да җәһәннәм газабыннан коткарып, Үзенең җәннәтләре белән бүләкләсә иде.

Ураза бәйрәме – бик шатлыклы, сөенечле көн. Ни өчен Ураза Гаете сөенечле көн соң? Дөреслектә, Гает көнендә бер Аллаһы Тәгаләгә генә шөкер кылабыз, изге Рамазан аенда тоткан уразаларыбызга, укыган намазларыбызга, кылган изгелекләребезгә шатланабыз һәм кабул булуына өметләнәбез. Аллаһы Тәгалә Коръән Кәримдә болай дип әйтә:

**وَلِتُكْمِلُواْ الْعِدَّةَ وَلِتُكَبِّرُواْ اللّهَ عَلَى مَا هَدَاكُمْ وَلَعَلَّكُمْ تَشْكُرُونَ**

*“Санаулы (ураза) көннәрен тәмам итеп, сезгә тугры юл күрсәткәне өчен, Аллаһны олылагыз, шөкер итегез”* (“Бәкара” сүрәсе, 185 аять).

Әлхәмдүлилләһ, ай буенча ураза тоттык, тәравих намазларын үтәдек, шуның белән бергә дуслык һәм шатлык мәҗлесләре – ифтарда катнашып, авыз ачтык, хәләл ризыклардан авыз иттек. Ул мәҗлесләребездә һәр көн Коръән Кәрим аятьләрен тыңлап, тәэсирле вәгазьләр ишетеп күңелләребезне тынычландырдык, иманнарыбызны ныгыттык.

Гает бәйрәменең әһәмияте турында тагын бер тукталып үтәсем килә. Рамазан гаете – Ислам динендә булган 3 бәйрәмнең берсе. Беренче бәйрәм – Ураза бәйрәме, икенчесе – Корбан бәйрәме, өченчесе исә - атна саен килә торган җомга көне.

Бәйрәм – шатлык, сөенеч мәгънәсе белән килә. Тагын сорау туа: без бу мөбәрәк бәйрәмебезне шатлык һәм сөенеч белән үткәрәбезме соң? Без ул бәйрәмнәрне чын бәйрәм итеп уздырабызмы икән?

Яңа елда, туган көннәрдә балаларга, туганнарга, дусларга бүләкләр биреп, тәбрикләп, ялтыравыклы уенчыклар элеп, чыршылар куеп, шатлансак

та, Ислам бәйрәмнәрендә намазлар укып, бернәрсә булмаган кебек өйләргә таралышу дөрес булмас.

Борынгылар әйткәннәр: *“Берәр өммәтнең чын барлыгын күрергә, белергә теләсәгез аларның бәйрәмнәрендәге хәлләрен карагыз!”* – дигәннәр.

Пәйгамбәребез галәйһиссәләм үзенең хәдисендә болай ди: *“Бер-берегезгә бүләкләр бирешегез, бер-берегезне сөярсез”*, – ди. Бүләк бирешү өчен изге ураза гаете көне иң яхшы форсат түгелмени? Бәйрәм көннәрендә, бигрәк тә балаларыбызны шатландырырга тырышырга тиешбез, чөнки шул бәйрәмнәр яшүсмерләрнең күңелләрендә күркәм тәэсир калдырачак, алар динебезне сөеп, яратып, хөрмәт итеп үсәчәкләр һәм шушы бәйрәмнәрдә булган матур мизгелләр алар күңелендә мәңгегә калачак.

Мөхтәрәм дин кардәшләрем, ватандашларым! Сез бүген Раббыбыз Аллаһны танып, Аллаһы Тәгаләгә гыйбадәт кылу, вәгазь, нәсыйхәт ишетү өчен үз теләкләрегез белән Бәйтуллаһка, ягъни мәчеткә җыелдыгыз. Мәчеттә сөйләнгән вәгазьләр таш диварларга (стеналарга) карата түгел, бәлки ихлас белән тыңларга теләүче сез кардәшләр өчен. Сөекле Пәйгамбәребез галәйһиссәләм әткән: *“Дин – ул нәсыйхәт”,* – дигән, ягъни Ислам дине – ул бер-береңне яхшылыкка өндәп, начарлыктан тыеп, бер-береңә вәгазь, нәсыйхәт кылу.

Газиз туганнар! Мөбарәк Рамазан ае безгә ризыкның, суның кадерен белергә, начар гадәтләрдән арынып, нәфесләребезне тыеп, изгелекләр кылырга өйрәтте, сабырлык, миһербанлылык, шәфкатьлелек сыйфатларын тәрбияләде.

Әгәр үзебезне мөселман дип саныйбыз икән, Рамазан аенда башланган игелекле гамәлләребезне, Аллаһы Раббыбызга шөкер итүләребезне изге ай тәмамлангач та дәвам итсәк иде, гөнаһлы гамәлләрдән, яман гадәтләрдән саклансак иде, җәмәгать!

Яшь чагында кеше дөньядагы булган байлыклар артыннан куып, *намаз укырга вакытым юк*, ди, ә картлык көнендә исә *хәтерем дә начар,*

*буыннарым да авырта*, дигән акланулар табарга тырыша. Адәм баласының гомере кыска бит, күп эшләрне башкарып бетереп тә булмый...

Мөхтәрәм дин кардәшләрем! Бу дөньяда вакытлыча яшәп барыбыз да сыналабыз, үлем җитү белән киләсе дөньяга күчәбез. Ни кызганыч, адәм баласы күп вакытта үз Раббысын онытып, Аллаһка шөкрана кылуны кичектерә, дөнья һәм ахирәт бәхетеннән үзен мәхрүм итә.

Аллаһы Тәгалә Коръән Кәримдә болай дип әйтә:

**وَإِذْ تَأَذَّنَ رَبُّكُمْ لَئِن شَكَرْتُمْ لأَزِيدَنَّكُمْ وَلَئِن كَفَرْتُمْ إِنَّ عَذَابِي لَشَدِيدٌ**

*"Исегездәме, Раббыгыз сезгә: шөкер итсәгез, әлбәттә, сезгә (нигъмәтләремне) арттырачакмын, әгәр дә көферлек кылсагыз, һичшиксез, бирәчәк җәзам бик тә хәтәрдер"* ("Ибраһим" сүрәсе, 7нче аять).

Димәк, нигъмәтләребез күп булсын, үзебез дөньяда һәм Ахирәттә бәхетле булыйк дисәк, иң элек барына да канәгать булырга һәм шөкерана кылырга кирәк. Бу игелекле гамәлләребезгә Аллаһы Тәгалә мохтаҗ түгел. Иң әүвәл үзебез өчен, камиллегебез өчен шөкерана кылырга тиешбез.

Шөкерана кылуның иң беренче билгесе – бөтен галәмнәрнең хуҗасы Аллаһны тану, Аңа иман китерү. Барлык галәмнәрнең раббысын танымау – иң зур көферлек. Аллаһны танымаучы кеше бу дөньяда Аның нигъмәтләрен башкалар белән тигез файдалана алса да, Аллаһның Ахирәттә әзерләнгән барча нигъмәтләреннән мәхрүм кала. Ул бәндәгә җәһәннәм газабыннан башка берни дә юк һәм аның хәлен беркем дә, бу дөньяда тупланган бернинди байлыгы да үзгәртә алмый. Андый кеше Аллаһның бу дөньядагы бер өлеш байлыгына алданып, туксан тугыз өлешеннән мәхрүм кала.

Шөкерана кылуның икенче билгесе – Аллаһ кушканнарны үтәп, тыйганнарыннан тыелып яшәү. Аллаһны танып та, Ул кушканча яшәмәгән кеше, көферлеккә төшмәсә дә, зур гөнаһлы була. Бу бәндә Аллаһның олы нигъмәте булган җәннәтенә җәһәннәм газабы аркылы гына ирешә ала.

Аллаһны танып, Аның кушканнарын үтәп, тыйганнарыннан тыелып яшәүчеләрнең калебләре чиста, йөзләрендә иман нуры балкып тора. Алар үз

тормышларыннан канәгать була беләләр, шул сәбәпле, Аллаһы Тәгалә аларның күңелләренә тынычлык бирә. Андый кешеләр мөлаем йөзле, күркәм сүзле булалар һәм беркайчан да зарланмыйлар. Алар турында Аллаһ Раббыбыз Коръән Кәримдә (“Фуссыйләт” сүрәсе, 30-32 нче аятьләр):

إِنَّ الَّذِينَ قَالُوا رَبُّنَا اللَّهُ ثُمَّ اسْتَقَامُوا تَتَنَزَّلُ عَلَيْهِمُ الْمَلَائِكَةُ أَلَّا تَخَافُوا وَلَا تَحْزَنُوا وَأَبْشِرُوا بِالْجَنَّةِ الَّتِي كُنتُمْ تُوعَدُونَ نَحْنُ أَوْلِيَاؤُكُمْ فِي الْحَيَاةِ الدُّنْيَا وَفِي الْآخِرَةِ وَلَكُمْ فِيهَا مَا تَشْتَهِي أَنفُسُكُمْ وَلَكُمْ فِيهَا مَا تَدَّعُونَ نُزُلًا مِّنْ غَفُورٍ رَّحِيمٍ

*“Дөреслектә, иман китергән кешеләр: безнең тәрбиячебез – Аллаһ, диярләр, соңыннан тормышта Аллаһ кушканнарын үтәп, тыйганнарыннан тыелып яшәрләр, үлгән вакытларында аларга рәхмәт фәрештәләре иңәр, сез хак мөэминнәр, үлемнән вә ахирәттән курыкмагыз һәм дөньяда калган якыннарыгыз өчен дә көенмәгез, бәлки үзегезгә вәгъдә ителгән җәннәт белән шатланыгыз, диярләр. Сезнең белән дөньяда һәм ахирәттә дусларбыз, сезне адашып һәлак булуыгыздан саклარбыз, үзегезгә хәзерләнгән җәннәттә күңелләрегез ни теләсә, шулар булыр, ягъни анда ни сорасагыз, шул бирелер. Бөтен гөнаһларыгыз ярлыканган хәлдә, Аллаһның җәннәтләренә керерсез”, – диярләр.*

Мөхтәрәм җәмәгать! Уйлап карыйк әле, Аллаһы Тәгалә безгә Коръәндә нинди эшләрне кылырга һәм нәрсәләрдән тыелырга куша соң? Коръән Кәрим аятьләренең берсенә күз салыйк:

وَقَضَى رَبُّكَ أَلاَّ تَعْبُدُواْ إِلاَّ إِيَّاهُ

*Раббың бары тик Үзенә генә гыйбадәт кылырга кушты* (“Исра” сүрәсе, 23 аять).

Бу аятьтә әйтелгәнчә, мөселман булуның төп шарты – Аллаһның барлыгына һәм берлегенә ышанып, Аңа гыйбадәт кылу. Әгәр адәм баласы чын күңеленнән Аллаһка һәм Кыямәт көненә (үлгәннән соң терелүгә һәм

Аллаһ каршында хисап бирәчәгенә) ышанса, ул һәрвакыт яхшы булырга, кешеләр күргәндә дә, күрмәгәндә дә аларны рәнҗетүдән, малларын урлаудан, барлык начарлыклардан сакланырга тырышачак. “Чын мөселман нинди була?” - дигән сорауга сөекле Пәйгамбәребез галәйһиссәләм: *“Чын мөселман шундый була: башка кешеләр аның кулыннан да, теленнән дә, каннары, маллары хакында да имин булырлар”,* – дигән.

Хәдистән күренгәнчә, иманлы адәм һичбер вакытта да, һичкемгә дә теле яки кулы белән зарар китермәс һәм һичкемнең малына яисә канына зыян кылмас.

Аятьнең дәвамы:

**وَبِالْوَالِدَيْنِ إِحْسَانًا إِمَّا يَبْلُغَنَّ عِندَكَ الْكِبَرَ أَحَدُهُمَا أَوْ كِلاَهُمَا فَلاَ تَقُل لَّهُمَآ أُفٍّ وَلاَ تَنْهَرْهُمَا وَقُل لَّهُمَا قَوْلاً كَرِيمًا**

*Ата-анагызга да игелекле булуыгызны катгый рәвештә боерды. Аларның берсе яки икесе дә сезнең янда картайса, аларга: уф (туйдым сездән), – димәгез; аларны битәрләмәгез; икесенә дә яхшы мөгамәләдә булыгыз.*

Газиз мөселманнар! Кадерле ата-аналарыбыз безнең дөньяга килүебезгә сәбәпче булганнар. Безне үстергәндә төрле авырлыкларга түзеп, күркәм тәрбия биргәннәр. Ата-аналарыбызның тырышлыкларын истә тотып, аларга карата һәрдаим игелекле, миһербанлы булырга тиешбез.

Аллаһның расүле галәйһиссәләм үзенең бер хәдисендә әйткән: *“Ата-аналарыгызның ризалыгына ирешмичә, Аллаһның ризалыгына ирешә алмассыз”,* – дигән.

Исән булсалар, ата-аналарыбызның хәлләрен белеп, ризалыгын, бәхиллеген алыйк. Әгәр үлгән булсалар, аларның каберләренә барып, кулларыбызны күтәреп: “Йә Раббым, ата-анамның гөнаһларын ярлыкап, аларга рәхмәтеңне ирештерсәң иде”, – дип догалар кылыйк. Аллаһ Раббыбыз “Исра” сүрәсенең 24нче аятендә болай ди:

وَاخْفِضْ لَهُمَا جَنَاحَ الذُّلِّ مِنَ الرَّحْمَةِ وَقُل رَّبِّ ارْحَمْهُمَا كَمَا رَبَّيَانِي صَغِيرًا

*“Миһербан һәм түбәнчелек белән алар алдында (күңел) канатларыңны җәй дә әйт: “Раббым, сабый чагымнан алып, алар мине ничек сөеп үстергән булса, Син дә аларга шулай мәрхәмәтле бул, - дип дога кыл”.*

Без әти-әниләребезгә карата күркәм мөнәсәбәттә булсак, балаларыбыз да безне хөрмәтләр. Расүл әкрам галәйһиссәләм әйткән: *“Ата-аналарыгызга игелек итегез, сезгә дә балаларыгыз игелек итәр”,* – дигән.

Хөрмәтле дин кардәшләрем! Һәрберебезнең дә янәшәбездә күршеләребез бар. Туганнарыбызга караганда да ешрак аларга мөрәҗәгать итәбез. Күршеләр белән тыныч-тату тору, аларга яхшылык, игелек кылу – мөселманнарның изге вазифасы. Пәйгамбәребез галәйһиссәләмнең мәшһүр бер хәдисен искә төшерәсем килә: *“Кем Аллаһы Тәгаләгә һәм Ахирәт көненә иман китергән булса, кунагын хөрмәт итсен. Кем Аллаһы Тәгаләгә һәм Ахирәт көненә иман китергән булса, күршесенә игелек итсен. Кем Аллаһы Тәгаләгә һәм Ахирәт көненә иман китергән булса, аңа хәерле сүз сөйләсен, яисә дәшмичә торсын”,* – дигән.

Динебезне бизәүче гадәтләребезнең берсе – пакьлык. Хөрмәтле Пәйгамбәребез галәйһиссәләм әйткән: *“Ислам пакьлык өстендә төзелгән, шуңа күрә пакьланыгыз”,* – дигән.

Әй мөселманнар! Бөтен эшләрегездә дә пакь булыгыз. Тәннәрегез, киемнәрегез пакь булган кебек ишегалларыгыз, урамнарыгыз, ашый-эчә торган савыт-сабаларыгыз һәркайсы пакь булсын. Пакьлек – сәламәтлекнең башы.

Мөхтәрәм җәмәгать! Тәне, киемнәре пакь булган кебек чын мөселманның күңеле дә пакь булырга тиеш. Кешеләрнең иң хәерлесе булырга тырышырга кирәк. Халкыбызның: “Таш атканга да аш ат”, – дигән сүзләрен беркайчан да истән чыгармыйк.

Газиз туганнар! Тормышыбыз гаять катлаулы, кайвакыт төрле яман күренешләргә дә тап булабыз. Болар барысы да мөселманнар җәмгыятен бизәми, әлбәттә. Мәсәлән, соңгы елларда, бигрәк тә яшьләр арасында үлүчеләр саны арта баруын, сәламәтлекнең начарлануы турында күп ишетәбез. Моның сәбәбе – аларның арасында тәмәке тарту, эчкечелек, наркотикларның киң таралуы. Кайвакыт кеше үз кәефен күтәрү, күңелен тынычландыру өчен хәмер һәм төрле наркотиклар куллана, ләкин моның киресе килеп чыга. Хәзерге вакытта медицина фәне хәмерне "дәвалану" өчен куллану сәламәтлек өчен зарарлы булуын күрсәтә. Хәмер арыганлыкны бетерми, көч тә өстәми, киресенчә, кеше организмы эшчәнлегенең сыйфатын киметә. Бу турыда сөекле Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәләм хәзрәтләре үзенең бер мөбарәк хәдисендә болай дип әйткән: *"Исертә торган нәрсәләрдән ерак булыгыз! Шик юктыр ки, ул – һәрбер явызлыкның ачкычы"*, – дигән (Суюти "Җәмиг әс-сәгыйрь").

Аллаһы Тәбәракә вә Тәгалә хәмернең зыяны турында болай дигән:

**يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُواْ إِنَّمَا الْخَمْرُ وَالْمَيْسِرُ وَالأَنصَابُ وَالأَزْلاَمُ رِجْسٌ مِّنْ عَمَلِ الشَّيْطَانِ فَاجْتَنِبُوهُ لَعَلَّكُمْ تُفْلِحُونَ  إِنَّمَا يُرِيدُ الشَّيْطَانُ أَن يُوقِعَ بَيْنَكُمُ الْعَدَاوَةَ وَالْبَغْضَاء فِي الْخَمْرِ وَالْمَيْسِرِ وَيَصُدَّكُمْ عَن ذِكْرِ اللّهِ وَعَنِ الصَّلاَةِ فَهَلْ أَنتُم مُّنتَهُونَ**

*«Әй, иман китергән кешеләр! Хәмер (исертә торган һәрбер нәрсә), азгын уеннар, сыннарга гыйбадәт кылу, фал ачтыру, ырымланган уклар белән шобага салу – шайтан гамәлләредер, шакшылыктыр, мондыйлардан ерак торыгыз: бәхеткә ирешерсез. Исерткеч һәм азгын уеннар белән шайтан арагызда үч орлыкларын, дошманлык чәчә; Аллаһны искә төшерүдән вә намаздан биздерергә тели. Сез бу эшләрдән ваз кичә алырсызмы икән?»* ("Маидә" сүрәсе, 90-91нче аятьләр).

Динебез һәртөрле наркотиклар куллануны катгый тыя, чөнки аларны кулланып кеше акылын һәм эшләргә сәләтен югалта. Кайберәүләр фикеренчә, наркотиклар аз гына кәеф өчен куллану зыян китермәс, дип

уйлылар, ләкин бу ялгыш фикер. Аллаһның расүле галәйһиссәләм әйткән: *“Зур микъдарда исертә торган нәрсәләр, аз микъдарда да куллану тыелган”* (Әбү Давыд, Тирмизи, Насаи).

Наркотиклар даими кулланган кеше үзенә, гаиләсенә генә түгел, тирә-юньдәгеләргә дә зур зыян сала. Организмын агулап, туган-тумачаларын кайгы-хәсрәткә сала, үзенең гомерен дә чикли.

Икенче бер аятьтә Аллаһы Раббыбыз болай ди:

وَلاَ تَقْتُلُواْ أَنفُسَكُمْ إِنَّ اللّهَ كَانَ بِكُمْ رَحِيمًا

*Үз-үзегезне үтермәгез. Шик юк ки, Аллаһ сезгә мәрхәмәтле* (“Ниса” сүрәсе, 29нчы аять).

Мөхтәрәм мөселманнар! Әгәр туган-тумачаларыбыз, дусларыбыз, күрше-күләннәребез арасында шундый бәлагә юлыкканнарны күрсәгез, булдыра алганча, аларга ярдәм итәргә тырышыгыз, чөнки, шәригатебез кушканча, мөселманнар үзара тату, ярдәмләшеп яшәргә тиешләр. Аллаһы Раббыбыз әйткән:

وَتَعَاوَنُواْ عَلَى الْبرِّ وَالتَّقْوَى وَلاَ تَعَاوَنُواْ عَلَى الإِثْمِ وَالْعُدْوَانِ وَاتَّقُواْ اللّهَ إِنَّ اللّهَ شَدِيدُ الْعِقَابِ

*«Игелек итүдә, яман эш кылудан саклануда бер-берегезгә ярдәмләшегез. Гөнаһ кылуда, дошманлык эшләрендә ярдәмләшмәгез. Гөнаһлы булып, Аллаһ каршысында җавап бирүдән куркыгыз. Аллаһның җәзасы бик тә хәтәр булыр»* (“Маидә” сүрәсе, 2нче аять).

Газиз дин кардәшләрем! Вәгаземне тәмамлап шуны әйтәм: Җәнабел Хак барчаларыбызга да тәүфикъ, һидаять бирсә иде. Дөнья һәм ахирәт бәхетсезлегенә сәбәп булган шушы начар гадәтләрдән ерак булып, аек булып, Аллаһның кушканнарын үтәп, тыйганнарыннан тыелып яшәргә, камил иман белән дөньядан үтәргә насыйп булса иде.

## *Ураза гаете хөтбәсе*

## Беренче хөтбә

بِسْـمِ اللهِ الرَّحْمَنِ الرَّحِيمِ

اللهُ أَكْبَرُ اللهُ أَكْبَرُ لاَ إِلَهَ إِلاَّ اللهُ اللهُ أَكْبَرُ اللهُ أَكْبَرُ وَ لِلَّهِ الْحَمْدُ ❀ سُبْحَانَ مَنْ نَوَرَ قُلُوبَ الْعَارفِينَ بِنُورِ الْمَعْرِفَةِ وَ الْإِيمَانِ وَ شَرَحَ صُدُورَ الصَّادِقِينَ بِشَرْحِ الْهِدَايَةِ وَ الْعِرْفَانِ وَ أَكْرَمَ عِبَادَهُ الْمُؤْمِنِينَ بِصِيَامِ شَهْرِ رَمَضَانَ ❀ اللهُ أَكْبَرُ اللهُ أَكْبَرُ لاَ إِلَهَ إِلاَّ اللهُ اللهُ أَكْبَرُ اللهُ أَكْبَرُ وَ لِلَّهِ الْحَمْدُ ❀ سُبْحَانَ مَنْ فَتَحَ عَلَى الصَّائِمِينَ أَبْوَابَ الرَّحْمَةِ وَ الْغُفْرَانِ وَ غَلَّقَ عَلَى الصَّائِمِينَ أَبْوَابَ النِّيرَانِ فِي شَهْرِ رَمَضَانَ ❀ وَعَدَ لِلصَّائِمِينَ دُخُولَ بَابٍ مِنْ أَبْوَابَ الْجِنَانِ كَمَا أَخْبَرَنَا نَبِيُّنَا نَبِيُّ آخِرِ الزَّمَانِ: إِنَ لِلْجَنَّةِ بَابًا يُقَالُ لَهُ الرَّيَّانُ لاَ يَدْخُلُهُ إِلاَّ الصَّائِمُونَ فِي شَهْرِ رَمَضَانَ ، شَهْرُ رَمَضَانَ الَّذِي أُنْزِلَ فِيهِ الْقُرْآنُ هُدًى لِلنَّاسِ وَبَيِّنَاتٍ مِّنَ الْهُدَىٰ وَالْفُرْقَانِ ❀ اللهُ أَكْبَرُ اللهُ أَكْبَرُ لاَ إِلَهَ إِلاَّ اللهُ اللهُ أَكْبَرُ اللهُ أَكْبَرُ وَ لِلَّهِ الْحَمْدُ ❀ وَ أَشْهَدُ أَنْ لاَ إِلَهَ إِلاَّ اللهُ وَحْدَهُ لاَ شَرِيكَ لَهُ ذُوالْعَفْوِ وَ الْغُفْرَانِ وَ أَشْهَدُ أَنَّ مُحَمَّدًا عَبْدُهُ وَ رَسُولُهُ صَلَّى اللهُ تَعَالَى عَلَيْهِ وَ عَلَى آلِهِ وَ أَصْحَابِهِ صَلاَةً مُوصِلَةً إِلَى دَارِ الْجِنَانِ ❀ أَيُّهَا النَّاسُ، أُوصِيكُمْ عِبَادَ اللهِ وَ نَفْسِي أَوَّلاً بِتَقْوَى اللهِ ❀ أَعُوذُ بِاللهِ مِنَ الشَّيْطَانِ الرَّجِيمِ، بِسْمِ اللهِ الرَّحْمَنِ الرَّحِيمِ ❀ إِنَّ اللَّـهَ مَعَ الَّذِينَ اتَّقَوا وَّالَّذِينَ هُم مُّحْسِنُونَ ❀ بَارَكَ اللهُ لَنَا وَ لَكُمْ فِي الْقُرآنِ الْعَظِيمِ وَ نَفَعَنَا وَ إِيَّاكُمْ بِالْآيَاتِ وَ الذِّكْرِ الْحَكِيمِ إِنَّهُ هُوَ الْغَفُورُ الرَّحِيمُ الْجَوَّادُ الْكَرِيمُ الْعَلِيُّ الْعَظِيمُ السَّمِيعُ الدُّعَاءِ

## Икенче хөтбә

إِنَّ الْحَمْدَ لِلَّهِ نَحْمَدُهُ وَ نَسْتَعِينُهُ وَ نَسْتَغْفِرُهُ وَ نُؤْمِنُ بِهِ وَ نَتَوَكَّلُ عَلَيْهِ وَ نَعُوذُ بِاللهِ مِنْ شُرُورِ أَنْفُسِنَا وَ مِنْ سَيِّئَاتِ أَعْمَالِنَا مَنْ يَهْدِهِ اللهُ فَلاَ مُضِلَّ لَهُ وَ مَنْ يُضْلِلْهُ فَلاَ هَادِيَ لَهُ وَ أَشْهَدُ أَنْ لاَ إِلَهَ إِلاَّ اللهُ وَحْدَهُ لاَ شَرِيكَ لَهُ وَ أَشْهَدُ أَنَّ مُحَمَّدًا عَبْدُهُ وَ رَسُولُهُ ❀ اَللَّهُمَّ صَلِّ وَ سَلِّمْ عَلَى جَمِيعِ الْأَنْبِيَاءِ وَ الْمُرْسَلِينَ وَ عَلَى مَلاَئِكَتِكَ الْمُقَرَّبِينَ وَ عَلَى عِبَادِكَ الصَّالِحِينَ وَ عَلَى أَهْلِ طَاعَتِكَ أَجْمَعِينَ مِنْ أَهْلِ السَّمَاوَاتِ وَ الْأَرَضِينَ ❀ اَللَّهُمَّ اغْفِرْ لِلْمُؤْمِنِينَ وَ الْمُؤْمِنَاتِ وَ الْمُسْلِمِينَ وَ الْمُسْلِمَاتِ اَلْأَحْيَاءِ مِنْهُمْ وَ الْأَمْوَاتِ وَ ارْحَمْنَا مَعَهُمْ وَ احْشُرْنَا مَعَهُمْ بِرَحْمَتِكَ يَا أَرْحَمَ الرَاحِمِينَ ❀

## Ураза гаетенең беренче хөтбәсе

Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахим.

Аллаһу әкбәрү, Аллаһу әкбәр, ләә иләәһә илләллаһү үәллааһү әкбәр, Аллаһу әкбәр, үә лилләәһил-хәмде. Сүбхәәнә мән нәүүәра кулүүбәл-

гаарифиинә би нуурил-мәгърифәти үәл-иимәән, үә шәрахә судүүрас-садикыйинә би шәрхил-һидәәйәти үәл-гыйрфәән, үә әкрамә гыйбәәдәһүл-мүэминиинә би сыйәәми шәһри рамәдаан. Аллаһу әкбәрү, Аллаһу әкбәр, ләә иләәһә илләллаһү үәллааһү әкбәр, Аллаһу әкбәр, үә лилләәһил-хәмде. Сүбхәәнә мән фәтәхә галәс-сааимиинә әбүәәбәр-рахмәти үәл-гуфраан, үәгадә лис-сааимиинә дүхуулә бәәбин мин әбүәәбил-җинәәни кәмәә әхъбәранәә нәбиййүнәә нәбиййү әәхыйриз-зәмәән: иннә лил-җәннәти бәәбәй-йүкаалү ләһүр-раййәән. Ләә йәдхулү-һүү илләс-саимүүнә фии шәһри рамәдаан. Шәһрү рамәдаанәлләзии үңзилә фииһил-курүәәнү һүдәл-линнәәси үә бәййинәәтим-минәл-һүдәә үәл-фүркаан, Аллаһу әкбәрү, Аллаһу әкбәр, ләә иләәһә илләллаһү үәллааһү әкбәр, Аллаһу әкбәр, үә лилләәһил-хәмде. Үә әшһәдү әлләә иләәһә илләллаһү үәхдәһүү ләә шәриикә ләһүү зүл-гафьүи үәл-гуфраан, үә әшһәдү әннә Мүһәммәдән габдүһүү үә расүүлүһүү. Салләллааһү Тәгаалә галәйһи үә галәә әәлиһи үә әсхәәбиһии саләәтәм-мүүсыйләтән иләә дәәрил-җинәән.

Әййүһәннәәс, үүсыйикүм гыйбәәдәллааһи үә нәфсии әүүәләм-битәкъүәллааһ. Әгуузу билләәһи минә шәйтаанир-раҗиим, бисмилләәһир-рахмәәнир-рахим. Иннәллааһә мәгаллләзиинәт-тәкау үәлләзиинә һүм мүхсинүүн. Бәәракәллааһү ләнәә үә ләкүм фил-куръәәнил-газыйим, үә нәфәганәә үә иййәәкүм бил-әәйәәти үәззикрил-хәкиим, иннәһүү һүәл-гафуурур-рахиимүл-җәүәәдүл-кәриимүл-галиййүл-газыйимү сәмиигуд-дүгәә.

## Ураза гаетенең икенче хөтбәсе

Иннәл-хәмдә лилләәһи нәхмәдүһүү үә нәстәгыйинүһүү үә нәстәгъфируһүү үә нуъминү биһии үә нәтәүәккәлү галәйһи үә нәгуузү билләәһи миң шүруури әңфүсинәә үә миң сәййиәәти әгъмәәлинәә мәййәһдииһилләәһү фәләә мүдыйллә ләһүү үә мәй-йүдълилһү фәләә һәәдиә ләһ. Үә әшһәдү әлләә иләәһә илләллаһү үәхдәһүү ләә шәриикә ләһ, үә әшһәдү әннә Мүхәммәдән габдүһүү үә расүүлүһ. Аллаһүммә салли үә сәллим галәә

җәмигыйль-әнбийәәи үәл-мүрсәлиин, үә галәә мәләәикәтикәл-мүкаррабиин. Үә галәә гыйбәәдикәс-саалихыйин, үә галәә әһли таагатикә әҗмәгыйин, мин әһлис-сәмәүәәти үәл-ардыйин. Аллаһүммә гъфир лилмүэминиинә үәл-мүэминәәт, үәл-мүслимиинә, үәл-мүслимәәт, әл-әхъйәәи минһүм үәл-әмьүәәт, үәрхәмнәә мәгаһүм. Үәхшүрнәә мәгаһүм бирахмәтикә йәә әрхәмәр-раахимиин.

*5 нче кушымта*

**Никах вәгазе**

*Әгүүзү билләәһи минәш-шәйтаанир-раҗиим. Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Әлхәмдүлилләәһи раббил гааләмиин вәссаләәтү вәссәләәмү галәә расүүлинә Мүхәммәдиү үә галәә әәлиһи үә әсхабиһи әҗмәгыйн.*

Безне ир һәм хатын итеп яралткан, арабызга бәхет чыганагы булган ихлас мәхәббәт урнаштырган Аллаһы Тәбарәкә вә Тәгаләгә иксез-чиксез мактауларыбыз һәм олуглауларыбыз булса иде. Һәркайсыбыз өчен иң күркәм үрнәк булган, безне дөрес һәм матур яшәргә өйрәткән сөекле Пәгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу гәләйһиссәлләм хәзрәтләренә, аның хөрмәтле әһленә һәм барлык сәхабәләренә сәламнәребез, салаватларыбыз һәм һәртөрле изге догаларыбыз булса иде.

Изге никах мәҗлесенә җыелган мөхтәрәм дин кардәшләрем, сезне динебезнең күркәм сәләме белән сәләмлим: әссәләәмү галәйкүм үә рахмәтүллаһи үә бәракәәтүһ!

Хөрмәтле дин кардәшләрем ! Аллаһ – бер. Аллаһ беркемгә һәм бернәрсәгә дә мохтаҗ түгел, киресенчә, без барыбыз да Аңа мохтаҗ. Аллаһы Тәгалә чиксез көч һәм куәткә ия. Ул бар нәрсәне булдыра ала. Аллаһы Сөбхәнә вә Тәгалә барлык мәхлукларын күп төрле ихтыяҗларга ия итеп яралткан. Мәхлуклар бер-берсенә мохтаҗ һәм мәңгелек Аллаһның ярдәменә

дә мохтаҗ. Бу яктан караганда кеше иң беренче урында тора, чөнки аның ихтыяҗлары һәм теләкләре башка мәхлукларга караганда күп тапкыр артыграк. Алай гына да түгел, кешенең ихтыяҗлары һәм теләкләре үсеп һәм артып тора, чөнки кеше матди һәм рухи комфортта (уңайлыкта) яшәргә тели. Авырлыклар, фәкыйрьлек, бәхетсезлек, бәла-казалар – кеше өчен авыр йөккә әйләнә. Шундый вакытларда ул үзенә ярдәм, дуслык кулын, аны аңлый торган йөрәкне эзли башлый.

Аллаһы Тәгалә бар нәрсәне дә парлы итеп яралткан. Мөселманнарның Изге китабы Коръән-Кәримдә бу хакта болай дип әйтелгән:

سُبْحَانَ الَّذِي خَلَقَ الْأَزْوَاجَ كُلَّهَا مِمَّا تُنبِتُ الْأَرْضُ وَمِنْ أَنفُسِهِمْ وَمِمَّا لَا يَعْلَمُونَ

*“Җир үстереп биргән нигъмәтләрне дә, кешеләрне дә һәм тагын аларга мәгълүм булмаган әллә никадәр нәрсәләрне парлы-парлы итеп төзүче Аллаһка чиксез мактаулар!”* (“Йәсин” сүрәсе, 36нчы аять).

Төн көн белән, ай кояш белән, җир күк белән, җан тән белән бер-берсен тулыландырган, камилләштергән кебек ир белән хатын да бер-берсен камилләштерәләр, бер-берсен тынычландыралар, бәхетле итәләр.

Сөекле Пәйгамбәребез галәйһиссәлам хәзрәтләре әйткән: *“Бай булса да, ире булмаган хатын һәм шулай ук, бай булса да, хатыны булмаган ир – мескеннәрдер”,* – дигән. Шушы хәдистән аңлашылганча, гаиләле кеше генә чын байлыкка, рухи тынычлыкка ия була ала.

Ислам динендә гаиләгә, аның бәхетле булуына зур әһәмият бирелә. Аллаһы Раббыбыз Үзенең Изге китабындагы “Рум” сүрәсенең 21нче аятендә болай дип әйтә:

وَ مِنْ آيَاتِهِ أَنْ خَلَقَ لَكُم مِّنْ أَنفُسِكُمْ أَزْوَاجًا لِّتَسْكُنُوا إِلَيْهَا وَجَعَلَ بَيْنَكُم مَّوَدَّةً وَرَحْمَةً إِنَّ فِي ذَٰلِكَ لَآيَاتٍ لِّقَوْمٍ يَتَفَكَّرُونَ

*“Аллаһның могҗизаларыннан: Ул сезгә, алар аша тынычлык табар өчен үзегездән хатыннарыгызны бар кылды һәм сезнең арагызда үзара мәхәббәт һәм мәрхәмәтлелекне булдырды”* .

Мөхтәрәм җәмәгать! Бу аятьтә әйтелгәнчә, Аллаһы Раббыбыз безгә үзенең зур бүләгеннән биргән – ул мәхәббәт хисе. Шуның аркасында гаилә барлыкка килә һәм үсә. Әгәр гаилә Аллаһ кануннары буенча яшәсә, анда Аллаһның бәрәкәте һәм рәхмәте артачак, илаһи мәхәббәт чагылачак.

Бер хәдис-шәрифтә әйтелгән: *“Дин буенча, Аллаһ ризалыгы өчен өйләнгән кеше диннең яртысын үтәгән булыр. Икенче яртысы өчен Аллаһның ярдәменә таянсын”.*

Гаилә саф һәм нык булсын өчен никах укылырга тиеш. Нәрсә соң ул никаһ? Никаһ – ул ике затның әүвәл Аллаһка, аннары әти-әниләренә, шәһидләргә һәм бер-берсенә вәгъдә бирүләре, ягъни бер-беребезне яратып, хөрмәт итеп, Раббыбыз кушканча, әти-әниләребезне онытмыйча гомер буе яшәячәкбез, дип вәгъдә бирүләре. Никах кешегә гөнаһсыз тормыш алып барырга мөмкинлек бирә. Ул – нәсел калдыру өчен иң яхшы чара. Никахта җаваплылык тойгысы һәм балаларны тәрбияләү кирәклеге кешене хезмәт итәргә һәм үз бурычын үтәргә этәрә. Никаһ гаилә тормышын җайга сала һәм бәхетле, бар яктан камил булган җәмгыятьне тудыра.

Аллаһы Раббыбыз Изге Коръәндә болай дип боера:

**وَأنكِحُوا الْأَيَامَى مِنكُمْ وَالصَّالِحِينَ مِنْ عِبَادِكُمْ وَإِمَائِكُمْ إِن يَكُونُوا فُقَرَاء يُغْنِهِمُ اللَّهُ مِن فَضْلِهِ وَاللَّهُ وَاسِعٌ عَلِيمٌ**

*“Үзләрегездән ирсез хатыннарны һәм хатынсыз ирләрне, никах хакларын үтәргә яраклы булган яхшы колларыгызны һәм җарияләрегезне өйләндерегез, кияүгә бирегез. Фәкыйрь булганнарны Аллаһ үз нигъмәтләре белән баетыр, шиксез, Аллаһ – киңлек иясе һәм белеп эш кылучы”* (“Нур” сүрәсе, 32нче аять). Аллаһы Тәгалә бу аятьтә гаиләле кешегә Үзенең рәхмәтен һәм бәрәкәтен ирештерәчәге турында әйтә.

Пәйгамбәребез галәйһиссәләм әйткән: *“Өйләнегез, балалар тудырыгыз, чөнки мин Кыямәт көнендә өммәтемнең күплеге белән башка өммәтләр каршында мактаначакмын”*, – дигән (Ибн Мәҗә).

(Әминә) һәм (Габдулла) бүген сезнең иң бәхетле, истәлекле көнегез. Сез үз гаиләгезне төзисез. Бүгеннән башлап тормыш юлыгызны янәшә үтәрсез, шатлык-куанычларыгызны һәм кыенлыкларыгызны бергә кичерерсез. Гаиләгез озын гомерле, бәхетле булсын өчен түбәндәге бурычларны үтәргә кирәк:

Иң беренчедән – бүгеннән башлап әти-әнинең хакы тулысы белән сезнең өстегезгә төшә, ике якныкы да. Әти-әниләребез төрле авырлыкларга да карамыйча, сабыр гына безне үстерделәр, тәрбияләделәр, тамакларыбыз тук булсын, өсләребездә җылы киемнәр булсын дип, авыр һәм мәшакатьле хезмәтләр башкардылар. Хәзер дә безгә хезмәт итүне дәвам итәләр. Алар Аллаһы Тәгаләгә ялварып дога кылалар. Без дә аларның бу изгелекләрен һәм хезмәтләрен камил рәвештә кайтарырга, көчебездән килгәнчә, һәрвакыт аларга чын күңелдән хезмәт итәргә һәм хөрмәт итәргә тиешбез. Шуны онытмаска кирәк: тормыштагы бәхетебез, уңышларыбыз әти-әниләребезнең изге догасы һәм ризалыгы белән бәйләнгән. Сөекле Пәйгамбәребез галәйһиссәләм: *“Ата-аналарын риза кылучы балалардан Аллаһы Тәгалә дә риза булыр”,* – дигән (Бохари).

Берәү Пәйгамбәребез галәйһиссәләмнән сорады: “Гамәлләрнең кайсысы яхшырак?” – диде. Аллаһның расүле галәйһиссәләм үз җавабында: *“Вакытында укылган намаз,аннан соң әти-әнигә изгелек кылу, аннары Аллаһы Тәгалә юлында тырышу”,* – диде (Бохари, Мөслим).

(Әминә) һәм (Габдулла), әти-әниләрегезгә карата күркәм мөнәсәбәттә булсагыз, балаларыгыз да сезне хөрмәтләр. Расүл әкрам галәйһиссәләм әйткән: *“Ата-аналарыгызга игелек итегез, сезгә дә балаларыгыз игелек итәр”,* – дигән.

Аллаһы Тәгалә барчабызга әти-әниләребезнең ризалыгын алып, Аллаһның ризалыгына ирешергә насыйп итсә иде.

Икенчедән, Пәйгамбәребез галәйһиссәләм әйткән: *“Сезнең һәрберегез көтүче һәм үз көтүегез өчен җаваплы...”* – дигән (Бохари, Мөслим). Гаиләнең матди ягы ирләр өстенә йөкләнелгән, тотарга акча кирәкме, йорт-

җир начармы, азык-төлек кирәкме – моның өчен, иң беренче, Аллаһ каршында, кешеләр алдында да ир кеше җавап тота. Гаилә башлыгы буларак ир кеше башка гаилә әгзаларыннан җитдирәк һәм төплерәк булырга һәм ислам буенча яшәргә бөтен шартлар тудырырга тиеш. Гаиләнең иң четерекле, иң авыр өлеше хатын-кыз өстенә йөкләнгән. Бу – бала тәрбиясе. Шуны истә тотарга кирәк. Әгәр әни кеше хәрам ризыклар белән тукланса, хәрам эчемлекләр эчсә, дуңгыз итләре ашаса, баланың тәне дә ярамаган ризыктан җыела. Туганда ул хәрамга хирыс бала булып туа. Шуңа күрә өйләнешкәч, никахлашкач, ир кеше гаиләне хәләл ризык белән тәэмин итәргә тиеш. Хатын-кыз, хәләл ризыклар ашап, баласын дөньяга китерергә әзерләнергә тиеш. Балаларның ниндилеге Аллаһы Тәгалә каршында, кешеләр алдында да иң беренче әни кешедән тора. Шуңа күрә Пәйгамбәребез галәйһиссәләм: *“Җәннәт – әниләрнең аяк астында”,* – дигән.

Әни генә түгел, әти дә үз балалары өчен күркәм үрнәк булырга тиеш, аларның матди һәм рухи ихтыяҗларын канәгатьләндерергә тиешләр. Алар һәрбер балага гадел булырга, аларны начар дуслардан, хәрам гамәлләрдән сакларга, яхшы белем һәм тәрбия бирергә, киләчәктә күркәм холыклы тормыш иптәшләрен табарга ярдәм итәргә тиешләр.

(Габдулла), (Әминә), галимнәребез әйткәнчә, нык һәм сәламәт гаилә дүрт нәрсәгә нигезләнгән: мәхәббәт, хөрмәт, сабырлык һәм ышану. Бер тарихи вакыйга белән таныштырасым килә. Әбү Хәнифә (Аллаһ аны үз рәхмәтеннән аермаса иде) янына бер хатын килә дә:

– Әй хәзрәт, ике ел элек ирем белән миңа никах укыгаң идең. Хәзер инде аер безне. Мин аның белән бергә яшәргә теләмим, - ди.

– Аерылырга теләвеңнең сәбәбе нидә? - дип сорый хәзрәт.

- Барлык хатыннарның ирләре өйләренә вакытында кайталар, ә минеке һаман соңга кала. Шул сәбәпле көндә диярлек өйдә тавыш чыга.

Әбү Хәнифә гаҗәпкә калып:

- Аерылырга теләвеңнең сәбәбе, өйгә соңга калып кайтуда гынамы? - дип сорый.

- Әйе, мондый кимчелеккә ия булган ир белән яшәргә теләмим. Башкалар кебек вакытында кайтсын, - дип җавап бирә хатын.

- Аеруын аерырмын, әмма бер шартым бар: өеңә кайт, зур, тәмле күмәч пешереп, миңа алып кил. Аны пешергән вакытта бернәрсә дә өеңнән алма: тозын да, суын да, онын да, йомыркасын да, сөтен дә тирә-күрше хатыннардан сорап ал. Сәбәбен дә аларга аңлат, - дип әйтә Әбү Хәнифә. Бу хатын өенә кайтып китә. Күрше хатынына кереп:

- Әй, Мәрьям, бер савыт су биреп тор әле, - ди. Күршесе:

- Суыгыз беттеме әллә? Сезнең ишегалдыгызда кое бар иде түгелме соң? - дип сорап куя.

Суыбыз барын бар. Иремнән зарланып, хәзрәт янына: “Аер мине иремнән”, дип барган идем, - дип әйтүгә, күршесе Мәрьям:

Әй, син минем иремне белсәң иде! - дип, озак кына вакыт иреннән зарлана башлый. Шуннан соң хатын күршесе Асия янына тоз сорап керә.

Нәрсә тозың беттеме әллә? Бер кашык тоз сорап кергәнсең, - ди күршесе.  – Тозыбыз барын бар, әмма иремнән зарланып, хәзрәт янына: “Аер мине иремнән”, дип барган идем, - дип әйтүгә, күршесе Асия:

Әй, син минем иремне белсәң иде! - дип, озак кына вакыт иреннән зарлана. Шулай итеп, бу хатын кайсы гына хатын янына әйбер сорап керсә дә, барысының да ирләреннән зарлануын ишетә. Күмәчне бик зур, тәмле итеп пешерә. Хәзрәт янына алып барып, бу күмәчне, аның кулына тоттыра.

Әй хәзрәт, рәхмәт сиңа, күмәчне гаиләң белән тәмле итеп аша, әмма мине иремнән аера күрмә.

Нәрсә булды, кызым? - дип хәзрәт хатыннан сорый.

Минем ирем бөтенесенең ирләреннән дә әйбәтрәк икән, - дип җавап кайтара ул.

(Әминә) һәм (Габдулла). Бу тарихи хәлдән гаилә тормышында сабырлык никадәр кирәкле сыйфат икәнлеге күренеп тора, ягъни гаилә мәңге булсын өчен ир белән хатын бер-берсенең кимчелеген эзләмәскә, күзәтмәскә, күрмәскә тырышырга тиеш. Кайсы вакытта күрсәң дә, күрмәгән кебек хис

итәргә яйсә йомшак, матур тел белән шул кимчелекләрне төзәтү юлларын күрсәтергә кирәк. Ир белән хатын – дуслыкның иң югары дәрәҗәләренә күтәрелгән кешеләр. Әгәр ике дус бер-берсенең кимчелекләрен күзәтеп, бер-берсенә төрттереп әйтә торган булсалар, араларындагы дуслык бик тиз сүнәр. Шулай ук хатын белән ир бер-берсеннән камиллек (идеал) көтәргә тиеш түгелләр. Әлеге төшенчә күп вакытта уйлап табылган хыялый бер әйбер генә булып кала. “Минем ирем, минем хатыным идеал булырга тиеш”, - дигән фикердә булган кеше, иң беренче чиратта, үзен бәхетсез итә. Бернинди кимчелексез, камил кешеләр дөньяга әле тумады һәм туачагына һич өмет юк. Аллаһның расүле галәйһиссәлам әйткән: *“Һәрбер кеше – хаталы. Һәм иң хәерле, мактаулы хаталанучылар – хаталарын танып, аңлап төзәтергә теләүчеләр”,* - дигән (Суюти “Җәмиг әс-сәгыйрь”).

(Габдулла), түбәндәге Пәйгамбәребез галәйһиссәламнең ике хәдисен истә тот:

*“Мөэминнәр арасыннан иң камил иманлылары – күркәм холыклы булганнары, ә арагыздан иң хәерле булганнарыгыз – үз хатынына карата күркәм мөгамәләдә, яхшы мөнәсәбәттә булганыгыздыр”*(Тирмизи).

*“Хатын-кыз асылда кәкре кабыргадан яратылган, әгәр син аны төзәтергә дип тырышсаң – сындырырсың, шуңа күрә аңа карата йомшак бул, аның белән тереклек кылырсың”* (Бохари, Мөслим).

(Әминә), син дә Расүл әкрам галәйһиссәламнең мәшһүр хәдисен истән чыгарма:

*“Әгәр бер хатын биш вакыт намазын калдырмыйча укыса һәм Рамазан аенда ураза тотса, үзенең пакьлеген саклап, иренә хыянәт итмәсә һәм иренә итагатьле булса, ул хатын җәннәтнең үзе теләгән ишегеннән керер”* (Әхмәд бин Хәнбәл, Муснад).

Мөхтәрәм җәмәгать! Аллаһы Раббыбыз безгә бәхетле, саф, матур тормыш итәргә боера. Гаилә кешегә бу мөмкинлекләрне бирә. Бәхетле гаилә – Җирдә җәннәтнең чагылышы булып тора. Атабыз Адәм галәйһиссәләм белән анабыз Һаваның (Аллаһы Тәгалә аннан разый булса

иде) гаилә тормышы җәннәттә башланып китә. Бу, беренче гаилә, Ислам кануннарына нигезләнгән була. Әгәр гаиләләребездә җәннәт тынычлыгын, атмосферасын булдырырга теләсәк, Адәм галәйһиссәләм белән анабыз Һава (Аллаһы Тәгалә аннан разый булса иде) кебек яшәргә, ягъни Аллаһны яратып һәм Аның кушканнарын үтәп гомер итәргә тиешбез.

Аллаһы Раббыбыз барчабызга бәхетле гаиләләр насыйп итсә иде!

## Никах хөтбәсе

اَلْحَمْدُ لِلهِ الْعَلِيِّ الْقَدِيرِ

جَلَّ أَنْ يَبْلُغَهُ الْبَيَانُ وَ التَّفْسِيرُ

لَيْسَ كَمِثْلِهِ شَيْءٌ فِي الْأَرْضِ وَ لاَ فِي السَّمَاءِ وَ هُوَ السَّمِيعُ الْبَصِيرُ. نَحْمَدُهُ وَ نَسْتَعِينُهُ وَ نَسْتَغْفِرُهُ وَ نُؤْمِنُ بِهِ وَ نَتَوَكَّلُ عَلَيْهِ وَ أَشْهَدُ أَنْ لاَ إِلَهَ إِلاَّ اللهُ وَحْدَهُ لاَ شَرِيكَ لَهُ وَ أَشْهَدُ أَنَّ مُحَمَّدًا عَبْدُهُ وَ رَسُولُهُ أَرْسَلَهُ بِالْحَقِّ بَشِيرًا وَ نَذِيرًا بَيْنَ يَدَي السَّاعَةِ ، وَ مَنْ يُطِعِ اللَّهَ وَ رَسُولَهُ فَقَدْ رَشَدَ وَ مَنْ يَعْصِهِمَا فَإِنَّهُ لاَ يَضُرُّ إِلاَّ نَفْسَهُ وَ لاَ يَضُرُّ اللَّهَ شَيْئًا.

أَعُوذ بِاللهِ مِنَ الشَّيْطَانِ الرَّجِيمِ

بِسْمِ اللهِ الرَّحْمَنِ الرَّحِيمِ

يَا أَيُّهَا النَّاسُ اتَّقُوا رَبَّكُمُ الَّذِي خَلَقَكُمْ مِنْ نَفْسٍ وَاحِدَةٍ وَ خَلَقَ مِنْهَا زَوْجَهَا وَ بَثَّ مِنْهُمَا رِجَالاً كَثِيرًا وَ نِسَاءً وَ اتَّقُوا اللهَ الَّذِي تَسَاءَلُونَ بِهِ وَ الْأَرْحَامَ إِنَّ اللهَ كَانَ عَلَيْكُمْ رَقِيبًا

يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا اتَّقُوا اللهَ حَقَّ تُقَاتِهِ وَ لاَ تَمُوتُنَّ إِلاَّ وَ أَنْتُمْ مُسْلِمُونَ

يَا أَيُّهَا الَّذِينَ أمَنُوا اتَّقُوا اللَّهَ وَ قُولُوا قَوْلاً سَدِيدًا يُصْلِحْ لَكُمْ أَعْمَالَكُمْ وَ يَغْفِرْ لَكُمْ ذُنُوبَكُمْ وَ مَنْ يُطِعِ اللهَ وَ رَسُولَهُ فَقَدْ فَازَ فَوْزًا عَظِيمًا

أَمَّا بَعْدُ : فَإِنَّ اللهَ تَبَارَكَ وَ تَعَالى حَرَّمَ السِّفَاحَ وَ أَحَلَّ النِّكَاحَ بِكَلِمَةِ : وَ أُحِلَّ لَكُمْ مَا وَرَاءَ ذَلِكُمْ أَنْ تَبْتَغُوا بِأَمْوَالِكُمْ ؛ فَانْكِحُوا مَا طَابَ لَكُمْ مِنَ النِّسَاءِمَثْنَى وَ ثُلَاثَ وَ رُبَاعَ . وَ بِمَا اسْتَفَاضَ مِنْ سُنَنِ نَبِيِّهِ وَ شَاعَ مِنْ اتِّفَاقِ أُمَّتِهِ وَ انْعَقَدَ عَلَيْهِ الْإِجْمَاعُ فَوَصَلَ الْحَقُّ مَحَقَّهُ وَ اسْتَقَرَّ مَقَرَّهُ وَ أَقْبَلَ عَلَيْهِ كُلُّ مَنْ سَمِعَ وَأَطَاعَ ثُمَّ أَنَّ ( فُلَان بن فلان ) قَدْ خَطَبَ ( فلانة بنت فلان ) وَ بَذَلَ مِنَ الصدَاقِ مَا نَاسَبَهُ أَثْبَتَ اللهُ دُرَّةَ الْمَوَدَّةِ فِي صُدُورِهِمَا وَ أَنْبَتَ حَبَّةَ الْمَحَبَّةِ فِي قُلُوبِهِمَا وَ جَعَلَ التَّوْفِيقَ رَفِيقَهُمَا وَ الصِّرَاطَ الْمُسْتَقِيمَ طَرِيقَهُمَا وَ لِيَكُنْ لَهَا مَدَارًا يَدُومُ بِهَا قَرَارًا كَمَا بَدَأَ عَرَضًا وَ يُصْبِحُ وَ هوَ لَهَا كَالْبَيَانِ يَشُدُّ بَعْضُهُ بَعْضًا. اَلْحَمْدُ لِلهِ الَّذِي لَمْ يَتَّخِذْ وَلَدًا وَ لَمْ يَكُنْ لَهُ شَرِيكٌ فِي الْمُلْكِ وَ لَمْ يَكُنْ لَهُ وَلِيٌّ مِنَ الذُّلِّ وَ كَبِّرْهُ تَكْبِيرًا .

## Никах догасы

Никах хөтбәсен укыганнан соң түбәндәге дога укырга мөмкин.

بِسْمِ اللهِ الرَّحْمَنِ الرَحِيمِ

اَللَّهُمَّ أَلِّفْ بَينَهُمَا كَمَا أَلَّفْتَ بَيْنَ آدَمَ وَ حَوَّا وَ كَمَا أَلَّفْتَ يُوسُفَ وَ زُلَيْخَا وَ كَمَا أَلَّفْتَ بَيْنَ عَلِيٍّ وَ فَاطِمَةَ وَ كَمَا أَلَّفْتَ بَيْنَ مُحَمَّدٍ وَ خَدِيجَةَ

اَللَّهُمَّ اغْفِرْ لَنَا جَمِيعًا وَارْحَمْنَا جَمِيعًا وَ نَجِّنَا مِنَ النَّارِ جَمِيعًا وَ صَلِّ اللهُ عَلَى خَيْرِ خَلْقِهِ مُحَمَّدٍ و آلِهِ أَجْمَعِينَ

رَبَّنَا آتِنَا فِي الدُّنْيَا حَسَنَةً وَ فِي الْآخِرَةِ حَسَنَةً وَ قِنَا عَذَابَ النَّارِ

*6 нчы кушымта*

## Коръән укылганнан соң дога кылу үрнәге

Әлхәмдүлилләәһи раббил гааләмииин вәссаләәтү вәссәләәмү галәә расүүлиһил кәрим үә галәә әәлиһи үә әсхабиһи әҗмәгыйн.

Йә, Рәхмәтле Раббым, укылган Коръән аятьләребезнең хата-кимчелекләрен гафу итеп, Үзеңнең киң рәхмәтең белән кабул кылсаң иде.

Укылган, тыңланган Коръән аятьләреннән, әйтелгән зекер-тәсбихларыбыздан хасил булган әҗер вә савапларны фани дөньядан мәңгелек ахирәткә күчкән иң камил кеше, барлык пәйгамбәрләрнең солтаны булган, безгә бәхетле булырга өйрәткән сөекле расүлең Мөхәммәд галәйһиссәләмнең рухына, атабыз Адәм галәйһиссәләм һәм анабыз Һавадан алып бүгенге көнгә кадәр килгән бөтен пәйгамбәрләрнең, әүлияләрнең, галимнәрнең рухларына ирештерсәң иде. Шулай ук безнең догаларыбызга мохтаҗ булган газиз әти-әниләребезнең, әби-бабаларыбызның, дәү әти-дәү әниләребезнең, кыз һәм ир туганнарыбызның, шул исәптән (фәлән улы фәләннән догага мохтаҗ булган аерым әрвахларның исемнәрен әйтергә мөмкин) барча мөэмин-мөселман кабер әһелләребезнең, мәрхүм-мәрхүмәләребезнең рухларына ирештереп,

аларның гөнаһларын, хата-кимчелекләрен гафу итеп, рухларын шатландырсаң иде.

Йә, Кодрәтле Раббым, аларның каберләрен нурландырып, хисапларын җиңеләйтсәң иде. Аларга Синең сөекле бәндәләреңнән, җәннәт әһелләреннән булырга насыйп итсәң иде.

Йә, Рәхим-шәфкатьле Раббым, укылган намазларыбыз, әйтелгән зекер-тәсбихларыбыз, кылган игелекле гамәлләребез хөрмәтенә, белеп һәм белмичә кылган гөнаһларыбызны, хата-кимчелекләребезне, ялгышларыбызны Үзеңнең киң рәхмәтең белән гафу итсәң иде.

Йә, Раббым, һәрбарчабызга исәнлек-саулык, хәерле һәм бәракәтле гомерләр насыйп итсәң иде. Сиңа гына гыйбадәт кылабыз һәм Синнән генә ярдәм сорыйбыз. Синең кушканнарыңны ихлас күңелдән үтәп, тыйган гамәлләреңнән тыелып, иксез-чиксез рәхмәтеңә һәм ризалыгыңа ирешергә, ике дөньяда да бәхетле бәндәләреңнән булырга насыйп итсәң иде.

Һәркайсыбызны хәвеф-хәтәрләрдән, сугышлардан, ачлык хәсрәтеннән, сихерләрдән, табигать гарасатларыннан Үзең сакласаң иде.

Йә, Рәхмәтле Раббым, балаларыбызга, оныкларыбызга күркәм тәрбия биреп, алар өчен сөенеп, шатланып яшәргә, аларның игелеген, миһербанлыгын күрергә насыйп итсәң иде.

Йә Раббым, һәркайсыбызга бу дөньядан тулы иман, кальби сәлим белән китәргә, соңгы сулышларыбызда да: “Ләә иләәһә илләә ллааһу Мөхәммәдүррасүлүллаһ”, - дип әйтергә насыйп итсәң иде. Кыямәт көнендә сөекле Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәләмнең шәфәгатенә ирешеп, җәннәтләреңә керергә, Синең дидарыңны күрергә насыйп итсәң иде.

Вәссаләәтү вәссәләәмү галәә расүүлилләһ үә галәә әәлиһи үә әсхабиһи әҗмәгыйн.

*7 нче кушымта*

## Сөйләм техникасыннан практикум

### Сулыш күнегүләре

***Хәрәкәттә – бәрәкәт!***

***Гәүдә торышлары***

**Беренче торыш** (1 нче рәсем). Кулларны янга сузып, тигез урында матрац яки палас җәеп, туп-туры итеп аркага ятабыз. Баш астына кечкенә генә мендәр куярга мөмкин.

**Искәрмә:**

- Әлеге торыш күкрәк читлегенең аскы өлеше һәм эч мускуллары ныгып җитмәгән укучылар өчен кулай.



1 нче рәсем

**Икенче торыш** (2 нче рәсем, 2а, 2ә рәсемнәр). 60-70 см тирәсе озынлыктагы таяк тотып, кулларны төшереп, туп-туры итеп басабыз. Иснәгәндә, иркен хәрәкәт белән кулларны баш өстенә күтәрәбез һәм, берничә секундка һаваны тоткарлап, шул торышта басып торабыз. Һаваны чыгарганда таякны муен турысына төшерәбез.



2 нче рәсем




2 а рәсем



2 ә рәсем

**Өченче торыш** (3 нче рәсем). Кулларны аркада, бил турысында тоташтырып туп-туры итеп басабыз. Акрын гына иснибез. Шул торышта һава чыгып беткәнче торабыз. Бу торышта күкрәк һәм эч мускуллары бертигез дәрәҗәдә хәрәкәтләнә.



3 нче рәсем

**Дүртенче торыш** (4 нче рәсем). Кулларны аркада, бил турысында тоташтырабыз, иснибез һәм һаваны тоткарлыйбыз. Шуннан соң иркен һәм җиңел хәрәкәт белән кулларны алга чыгарып, учларын күкрәк читлегенең өске өлешенә куйганда һаваны чыгарабыз.



4 нче рәсем

**Бишенче торыш** (5 нче рәсем). Туры басып торабыз. Кулларны аркада, бил турысында тоташтырабыз – иснибез, диафрагма турысына өскә күчергәндә (5а рәсем) һаваны чыгара башлыйбыз. Урта бармакларның очлары бер-берсенә тиеп торырлык булсын. Бу торышны күнегү тәмамланганчы саклыйбыз.



5 нче рәсем



5а рәсем

## I комплекс

## Һава алмашуны күнектерү

### *1 нче күнегү*

### *“Чәчәк кибетендә”*

Борын аша эчнең аскы өлеше хәрәкәтләнерлек итеп күп күләмдә һава алабыз. Һаваны чыгарганнан соң берничә секунд тирәсе тын торгач, иркен итеп тиз генә борын аша иснибез. Бөтен тән, эчнең аскы өлешенә кадәр киңәя, үпкәләр чиста һава белән тула. Берничә секунд һаваны тоткарлап торабыз һәм «а» авазын әйткәндәге кебек, авызны зур ачып, җылы һава чыгарабыз.

**Искәрмәләр**:

- Бу күнегүне беренче өч торышта берничә тапкыр кабатларга мөмкин.
- Әгәр дә икенче һәм өченче торышта укучы баш әйләнүен сизсә, башта беренче торышта күнектерү белән чикләнергә.

Һаваны чыгарганнан соң һәрвакыт паузаны сакларга.

Күкрәк читлегенең һәм эчнең аскы өлешенең берүк вакытта киңәюен игътибар итәргә. Моңа ирешү өчен, үзегезне чәчәк иснибез дип хис итәргә кирәк.

1. Һава үпкәләрдән иркен чыга.
2. Һава агымының көче һава чыкканда кими.
3. Һава алмашу тавышсыз башкарыла.
4. Һава алганда шау, сызгыру ишетелсә, сулыш юллары мускулатурасының киеренкелегенә ишарә.
5. Һава чыккан вакытта шау ишетелсә, тамак мускулларына көч килә.

*2 нче күнегү*

***«Һаваны өлешләп чыгару»***

Ул да нәкъ беренче күнегү кебек башлана. Һаваны чыгарып бетерәбез, бераз пауза тотабыз (борын аша тиз генә иснибез), сулышны тоткарлап торабыз. Иреннәр арасын нәзек кенә калдырып (алга таба юка иреннәр аша дип әйтербез). Һаваның бер өлешен «пф» дип чыгарабыз. Калган һаваны тагын тоткарлап торабыз, тагын бер өлешен чыгарабыз.

«Пф» авазлар җыелмасын кабатлый – кабатлый, һаваны ахырына кадәр чыгарып бетерәбез. Һава тоткарланганда иреннәр ябык.

Искәрмәләр:

- Әгәр дә баш әйләнү булмаса, бу күнегүне беренче өч торышта да эшләргә мөмкин, баш әйләнсә беренче торыш белән генә чикләнергә кирәк.
- Бу күнегү үпкәләрне чистарта. Әгәр укучы арыган, дулкынланган яисә аңа бик эссе һәм шуңардан ул бик хәлсезләнгән икән, тынычлану өчен, бу күнегүне берничә тапкыр эшләргә киңәш ителә.

*3 нче күнегү*

***«Көпшә»***

Һаваны юка иреннәр аша эчкә алабыз. Һава көпшә аркылы су эчкән кебек иркен уза. Һаваны тоткарлап торабыз; авызны зур ачып, тавышсыз гына җылы һава чыгарабыз; тиз генә иснәп, «пф-пф» авазлар җыелмасы белән өлешләп чыгарабыз.

**Искәрмәләр:**

- Әлеге күнегүне беренче өч торышта да үтәргә мөмкин.
- Бу күнегүне бары тик ирен кырыйлары аша гына сулап та эшләргә була.
- Әлеге күнегүне борын аша иснәп тә эшләргә ярый. Бу очракта ике бармак белән борын тишекләрен җиңелчә генә кысарга кирәк.

### *4 нче күнегү*

### *«Һава тоткарлау»*

Борын аша тиз генә иснибез, шуннан соң эчнең аскы өлешен ныгытып, һаваны озак тоткарлап торабыз. Әмма көчәнергә кирәкми. Һава тоткарланганда авыз ябык. Тамакка киеренкелек тудырмыйча, шауламыйча гына, авызны зур ачып, җылы һава чыгарабыз.

**Искәрмәләр:**

- Һава тоткарлауны төрләндерү өчен, авызны зур ачып торырга да мөмкин.
- Баш әйләнмәсә, бу күнегүне беренче өч торышта да эшләргә була.
- Бу күнегү вакытында һаваны тоткарлау секундларының арта баруын күзәтү кызыклы. Эчнең аскы мускулатурасы көчен арттыру өчен бу күнегү бик файдалы.
- Башта һаваны 5-10 секундтан да артык тоткарларга тырышмаска, тавыш ярыларына көч китермәскә кирәк.

### *5нче күнегү*

### *«Мин кем!»*

Туп-туры басабыз  һәм юка иреннәр аша һава алабыз. Учларыбыз белән башта акрын гына, бераздан катырак итеп, күкрәк читлегенең өске өлешен каккалыйбыз. Һаваны көчәнеп тоткарлап торган очракта, авызны зур итеп ачып һаваны чыгарып бетерергә һәм шуннан соң яңадан тиз генә иснәп, һаваны өлешләп чыгарырга кирәк.

**Искәрмәләр:**

- Бу күнегүне бары тик баскан килеш кенә эшлибез. Сулыш аппараты камилләшә, ныгый барган саен, бу күнегүне ешрак эшләргә мөмкин.
- Күкрәкне бөтен көчкә түгел, ә бармак очлары белән генә каккаларга. Кызлар күкрәкнең бары тик өске өлешен генә каккаларга тиеш.
- Һаваны чыгара башлагач, каккалауны туктатырга кирәк.

***6 нчы күнегү***

***«Мунча чабыну»***

Кулларны янга төшереп басабыз, борын аша тиз генә иснибез һәм һаваны чыгармыйча гына алга таба иеләбез; арканы кул чугы белән каккалый башлыйбыз.

**Искәрмәләр:**

- Укучы һаваны тоткарлап тора алмавын сизүгә үк, каккалауны туктатырга, тураерга һәм калган һаваны авызны зур ачып тавышсыз гына (җылы һава) чыгарып бетерергә кирәк. Моңардан соң шул мизгелдә тиз генә борын аша иснибез, һаваны «пф-пф» дип, өлешләп чыгарабыз.
- Бу күнегүне бары тик аягүрә баскан килеш кенә эшләргә мөмкин.

***7 нче күнегү*** (6, 7е рәсемнәр)

***«Туп кысу» яки кабыргара мускулларны ныгыту күнегүе***



6 нчы рәсем





7 нче рәсем

Туп-туры басабыз, кулларны мөмкин кадәр өскәрәк күтәреп, күкрәк читлеген «туп» дип күзаллап, ике яктан тотабыз.

Борын аша тиз генә иснибез шуннан соң һаваны берничә секунд тоткарлап торабыз һәм куллар белән җиңелчә генә күкрәк читлеген ян-яктан кыскалап, һаваның бер өлешен чыгарабыз. Шуннан соң кулларны яңадан төшерәбез, бу вакытта һаваны тоткарлыйбыз. Инде яңадан күкрәк читлеген ян-яктан кыскалап, «пф-пф» дип, тагын һаваның бер өлешен чыгарабыз.

Һава бөтенләй чыгып беткәч, кулларны төшерәбез һәм яңадан тиз генә иснәп, һаваны өлешләп чыгарабыз.

**Искәрмәләр:**

- Бу күнегүне бары тик басып торган хәлдә генә эшләргә кирәк.
- Башта күнегүне аеруча саклык белән эшләргә киңәш ителә.
- Нәкъ менә әлеге күнегү ярдәмендә сеңерләрнең, кабыргара мускулларның сыгылмалылыгын һәм буыннарның хәрәкәтчәнлеген үстерергә була. Ә алар, үз чиратында, күкрәк читлегенең күләмен арттыру өчен әһәмиятле.

***8 нче күнегү*** (8, 9 нчы рәсемнәр)

***«Шар кысу» яки күкрәк читлеген киңәйтү күнегүе***



8 нче рәсем



9 нчы рәсем

Туры басабыз, борын аша иснәгәндә кулларны алга сузган килеш өскә күтәрәбез, уң аяк белән алга атлыйбыз.

Шул торышта һаваны берничә секундка тоткарлап торабыз, һаваны авыз аша «пф» авазлар җыелмасы белән чыгарабыз, шул вакыт уң аякны кире күчерәбез һәм кулларны йодрыклап, сукмыйча гына күкрәккә кысабыз (гәүдәне «шар» дип күзаллыйбыз).

**Искәрмәләр:**

- Һаваны аз гына көч белән, ашыкмыйча чыгарабыз. Шул ук аяктан бу күнегүне тагын бер кат кабатлыйбыз. Күнегүне тиз темпта үтибез.
- Күнегүне ике темпта да сул аяк белән эшлибез.
- Күнегүне уң һәм сул аяктан (һәр аякка 2 тапкыр) 6 тапкыр чиратлаштырып кабатлыйбыз.

## II комплекс

## Сулыш юлларын ныгыту

### *1 нче күнегү*

### *“Үпкәләрне акрынлап кысу” күнегүе*

Тураеп басабыз, куллар аркада, тотышканнар. Борын аша (авыз ачык) күп күләмдә һава алабыз һәм аны берничә секундка тоткарлап торабыз. Кулларны иркен һәм җиңел генә хәрәкәт белән күкрәкнең өске өлешенә куябыз (6 нчы рәсем). «Ф» авазына охшаш аваз белән һаваны чыгара башлыйбыз. Аскы иреннәр өске тешләргә бик якын. Күкрәк читлегенең өске өлеше хәрәкәтләнми. Һаваны чыгарып бетергәннән соң, тиз генә иснәп, һаваны тоткарлый-тоткарлый (иреннәрне йомып-йомып), җылы һава белән “пф-пф” авазлар җыелмасын яңгыратабыз. Калган һаваны 2-3 өлешкә бүлеп чыгарабыз.

**Искәрмәләр:**

- Башта аз күләмдә генә һава иснәргә кирәк. Һаваны чыгарган вакытта күкрәк читлегенең өске өлеше генә түгел, ә аскы өлеше дә тыныч халәттә калырга тиеш. Бары тик шуннан соң гына күнегүне тулысынча кабатлап эшләргә мөмкин.
- Муен мускулатурасының иркенлеге өчен, башны уңга һәм сул якка боргалап торырга.

***2 нче күнегү***

***«Һава алмашуны тикшерү» күнегүе***

3 нче торышта (3 нче рәсем) басып торган килеш юка иреннәр аша иснибез.

Сулышны берничә секунд тоткарлап торганнан соң, 4 нче торышны алабыз (4 нче рәсем) һәм һаваны “ф” авазы белән чыгарабыз.

**Искәрмәләр:**

- Бу күнегү салкын һаваны көч белән этеп чыгаруга (каты атака) исәпләнгәнгә күрә, баштарак аны беррәттән ике тапкырдан да артыграк кабатламаска киңәш ителә.
- Һәрбер күнегүдән соң һаваны өлешләп бүлеп чыгарырга кирәк.
- Беренче очракларда һаваны күп күләмдә иснәмәскә яисә һаваны салмак чыгармаска тырышырга кирәк, чөнки әлеге күнегү сулыш юлларының киеренкелегенә китерә.
- Иснәгән чакта диафрагма һәм кабыргара мускулатураның эшчәнлегенә игътибар итәргә.

### *3 нче күнегү*

### *Тавыш ярыларының ныклыгын күнектерү*

### *I төре*

Һаваны борын аша күп күләмдә иснибез, берничә секундка тоткарлап торабыз һәм иреннәрне елмайгандагы торышка китерәбез. Һава агымын тавышсыз, дәвамлы, иркен генә “э” авазын сузуны күз алдына китереп чыгарабыз (һава уртача температурада).

Һаваны чыгарып бетергәннән соң, тиз генә иснәп, өлешләп чыгарабыз Бу күнегүне бары тик 4 нче торышта гына эшләргә кирәк (6 нчы рәсем).

**Искәрмә:**

- Күнегүне эшләгәндә сөйләм аппараты мускулларының иркенлеген тикшереп торабыз.

### *II төре*

Борын аша күп күләмдә һава иснибез; берничә секундка тоткарлыйбыз; иреннәрне елмайгандагы кебек җәеп, һаваны “с” авазы белән акрын гына чыгарабыз. Шуннан соң яңадан иснәп, һаваны өлешләп, бүлгәләп чыгарабыз. Бу күнегүне бары тик 4 нче торышта гына эшләргә мөмкин (4 нче рәсем).

**Искәрмәләр:**

- Һава чыгару артык озакка да сузылмаска һәм диафрагма да эчкә тартылмаска тиеш.
- Һаваны мөмкин кадәр дәвамлырак чыгарырга кирәк. Һава чыккан вакытта күкрәк читлегенең өске өлеше хәрәкәтләнми, күкрәк һәм муен мускуллары да иркен була.

### *4 нче күнегү*

### *«Диафрагма һәм кабыргара мускулларны ныгыту»*

Өченче торышны алабыз (3 нче рәсем), борын белән күләмле итеп иснибез, берничә секундка сулышны тоткарлыйбыз, бу вакытта 5 нче торышны алабыз (5 нче рәсем), һаваны юка иреннәр аша “ссс” авазларын яңгыраткандагы кебек тавышсыз, дәвамлы чыгарабыз.

Сулышны чыгарып бетергәннән соң тиз генә иснәп, һаваны өлешләп чыгарабыз.

**Искәрмә:**

- Муен мускулларының иркенлегенә игътибар итәбез. Диафрагма өстән аска таба бераз хәрәкәтләнеп ала.

### *5 нче күнегү*

### *«Һаваны өлешләп чыгаруны камилләштерү»*

Әлеге күнегү сөйләм, җыр вакытында өзек-өзек сулыш чыгаруны, кайбер тартык авазларны әйтүне күнектерү өчен әһәмиятле.

Һава чыгаруны иреннәрне кысып (ябып) туктатабыз. Һаваны аз күләмдә өлешләп чыгарабыз (10-12 тапкыр). Дәвамлылыгын тигез итеп кабатлыйбыз.

Бү күнегүне бишенче торышта эшләргә кирәк.

### *6 нчы күнегү*

### *Һаваны кинәт һәм еш-еш чыгаруны һәм диафрагманың дәвамлы җыелуын күнектерү*

Күнегүне өченче торышта эшли башлыйбыз, һава иснибез, берничә секундка тоткарлап торабыз һәм бишенче торышны алабыз (5 нче рәсем).

Шуннан соң юка иреннәрдән һаваның бер өлешен “ссс” авазлары җыелмасын әйткәндәге кебек тавышсыз чыгарабыз. Шул рәвешчә һаваны 3 секунд чыгарабыз да иреннәрне ябып, “пф-пф” авазлары белән өлешләп

чыгарабыз. Алга таба һаваны тагын “ссс” белән чыгарабыз һәм 3 секундтан соң тагын өлешләп чыгаруга күчәбез.Күнегүне бөтен һава чыгып беткәнче, шул рәвешчә кабатлап торабыз.

### *7 нче күнегү*
### *«Авазның көчен күнектерү»*
### *I төре*

Өченче торышны (3 нче рәсем) алабыз, иснибез, сулышны тоткарлыйбыз һәм дүртенче торышка күчәбез (4 нче рәсем).

Иреннәрне елмайгандагы кебек җәеп, һаваны кискен этеп (каты атакада), “э” авазын әйткән кебек чыгарабыз. Һава чыгып беткәннән соң, тиз генә иснәп, зуррак өлешләр белән, көчлерәк этеп чыгарабыз.

**Искәрмә:**

- Бу күнегүне үтәгәндә муен мускулатурасы, тамакта, бигрәк тә,телдә киеренкелек булдырмаска тырышабыз.

### *II төре*

Өченче торышта һава иснибез, һаваны берничә секундка тоткарлап, 4 нче торышны алабыз. Һаваны кискен этеп, «с» белән, аннан пышылдап “э” авазы белән чыгарабыз. Һаваны чыгара башлаганда күкрәк читлегенең өске өлеше хәрәкәтсез, диафрагма иркен.

1-2 секундтан соң 5 нче торышны алабыз (5 нче рәсем). Бу вакытта киеренкелек күкрәк читлегенең өске өлешеннән эчнең аскы өлешенә күчә (эчебез эчкә “бата”). Әлеге күнегүне тәмамлаганнан соң тиз генә иснәп, һаваны өлешләп чыгарабыз.

### *8 нче күнегү*

### *Тавышның көчәюен һәм акрынаюын күнектерү*

Бу күнегүнең асылы – һаваны чыгарганда салкын һавадан җылы һавага күчү, ягъни каты атакадан йомшак атакага күчү. Иснибез, һаваны тоткарлыйбыз, җылы һава чыгарганнан соң күнегүне туктатмыйча гына 5 нче торышны алабыз (5 нче рәсем). Иснибез һәм һаваны “э” авазы белән көчле, кискен (салкын һава) этеп чыгарабыз; аннан соң җылы һава белән “э” авазын пышылдап яңгыратабыз. Һаваны чыгарып бетергәннән соң, тиз генә иснәп, тоткарлый-тоткарлый (иреннәрне йомып), “пф-пф” авазлар җыелмасы белән (җылы һава) чыгарабыз. Калган һаваны 2-3 өлешкә бүлеп чыгарабыз.

## III комплекс

### *Һава алмашуны тизләтү күнегүләре*

### *1 нче күнегү*

### *Борын аша тиз иснәүне күнектерү*

Авыз ябык, тиз генә борын аша иснибез һәм һаваны авыз яисә борын аша чыгарабыз. Күнегүне берничә тапкыр беренче өч торышта кабатлыйбыз.

**Искәрмә:**

- Борын яфракларын киңәйтеп шауламый гына иснибез.

### *2 нче күнегү*

### *Ачык авыз белән борын аша тиз иснәүне күнектерү*

Борын аша мөмкин кадәр тиз иснибез. Күнегүне эшләгән чакта авыз ачык кала, әмма аның аша һава алмашмаска тырышабыз. Бу күнегүне беренче һәм икенче торышта күп тапкыр эшләргә мөмкин.

**Искәрмәләр:**

- Иснәгән чакта бөтен сулыш мускулатурасы хәрәкәтләнерлек итеп иснәргә кирәк.

- Әгәр укучыга авыз ачык халәттә борын аша иснәү кыен икән, баштарак күнегүне үзгәртергә дә мөмкин: алгы өске тешләрне аскы тешләр өстенә куябыз; телне аңкауга терибез, иреннәрне ачабыз һәм борын аша иснибез, шуннан соң телне аңкаудан алмыйча гына тешләрне ачабыз. Аннан соң телне дә төшерергә була.

***3 нче күнегү***

***Иснәү тизлеген көнектерү***

Беренче төре – һаваны йомшак атакада авыздан чыгару

Кулларны күкрәккә куеп туры басабыз; авыз ярымачык, борын аша тиз генә иснибез, шулвакыт кулларны тиз генә аркага куеп бер-берсе белән тоташтырабыз; һава чыгып беткәнче шул – өченче торышта калабыз. Шуннан соң тиз генә борын аша иснибез; юкарган иреннәр аша “пф-пф” авазлары белән һаваны чыгарабыз; яңадан иснибез һәм кулларны алга чыгарып, күкрәккә куйганда (5 нче торышта) һаваны чыгарабыз. Бу күнегүне рәттән 3 тапкыр эшлибез.

Икенче төре – һаваны йомшак атакада борыннан чыгару

Куллар ян-якта, туры итеп басабыз, авыз ярымачык; кулларны, чуклары тоташырлык итеп баш өстенә “ыргытканда” тиз генә борын аша иснибез. Һаваны шул торышта тоткарлыйбыз. Кулларны иркен генә аска төшергәндә, һаваны борын аша чыгарабыз. Бу күнегүне 3 тапкыр кабатлыйбыз.

## IV комплекс

### *Баш, җилкә хәрәкәтләре*

Баш белән хәрәкәтләр ясау муен һәм җилкә мускулларының ныгуы өчен файдалы.

Бу хәрәкәтләр баш әйләнгәндә, шулай ук гәүдәне төз тоту өчен дә әйбәт. Муен умырткасының хәрәкәтчәнлеге дә бермә-бер арта.

***1 нче күнегү*** (10 нчы,10а рәсемнәр)

***Башны алга һәм артка бөгү***



10 нчы рәсем



10а рәсем

Туры басып, көчәнмичә сулыш алабыз. Соңыннан башны артка җибәрәбез (32 нче рәсем), йөз өскә төбәлгән, шушы хәлдә озак тормыйча, башны акрын гына күтәрәбез, һәм артык көч куймыйча, ияк күкрәк читлегенә тигәнче аны алга иябез. Һаваны баш игәндә акрын гына чыгарабыз. Бу күнегүне өчәр тапкыр кабатлыйбыз.

**Искәрмә:**

- Күнегүне эшләгәндә, гәүдә һәм җилкәләр хәрәкәтсез.

***2 нче күнегү*** (11 нче рәсем)

***Башны уңга һәм сулга таба бөгү***



11 нче рәсем

Туры баскан килеш көчәнмичә генә борын аша иснибез һәм башны уң якка янтайтканда сулышны чыгарабыз. Икенче тапкыр һава иснәгәнче шул торышта калабыз, башны турайтып һава иснибез һәм аны чыгара-чыгара башны сул якка янтайтабыз.

Күнегүне 3 тапкыр кабатлаганнан соң тиз генә борын аша иснәп, һаваны өлешләп чыгарабыз.

**Искәрмә:**

- Күнегүне эшләгәндә баш алга да, артка да бөгелми, җилкәләр хәрәкәтләнми.

***3 нче күнегү*** (12 нче рәсем)

***Башны бору***



12 нче рәсем

Туры итеп басабыз, иркен һәм көчәнмичә генә иснибез. Иснәгән вакытта башны туры тотып уң якка борабыз. Күз карашы уң як җилкә аша төшкән була. Сулышны чыгарабыз һәм бышны элекке торышына кайтарабыз. Яңадан иснибез һәм башны нәкъ шул рәвешчә сул якка таба борабыз. 3 тапкыр эшләгәннән соң тиз генә борын аша иснәп, һаваны өлешләп чыгарабыз.

**Искәрмә:**

- Күнегүне эшләгән вакытта муенның бөгелмәвенә, җилкәләрнең хәрәкәтсез калуына игътибар итәргә кирәк.

***4 нче күнегү*** (13 нче,13а,ә рәсемнәр)

***Баш белән әйләнмәле хәрәкәт ясау***

Туры басабыз, иркен генә иснәгәндә башны сул якка янтайтабыз, шуннан соң артка, уңга һәм алга таба башның өске өлеше мөмкин кадәр зуррак түгәрәк ясарлык итеп әйләндерәбез, һаваны чыгарабыз. Кире якка

таба эшлибез һәм шул ук кагыйдәне истә тотабыз: йөз өскә күтәрелгәндә – иснибез,әйләндергәндә, аска төшкәндә – сулышны чыгарабыз.





13 нче рәсем  13а рәсем  13б рәсем

Күнегүне һәр якка да 5 әр тапкыр эшлибез һәм борын аша тиз генә иснәп, һаваны өлешләп чыгарабыз (“а”, “э”, “ф”, “пф”, “ссс”, “пф-пф”, “бп-бп” һ. б. авазлар җыелмасы белән).

***5 нче күнегү***

***“Юан муен” күнегүе***

Туры басабыз, иркен генә иснәгәндә башны артка кучерәбез, баш алга килгәндә һаваны “ф” авазы белән дәвамлы этеп чыгарабыз.

**Искәрмәләр:**

- Бу күнегүне 5 тапкыр эшләгәннән соң борын аша тиз генә иснәп һаваны өлешләп чыгарабыз.
- Бу хәрәкәт вакытында күкрәк сөяге (очкылык сөяге) бераз күтәрелгән кебек була. Тик җилкәләр хәрәкәтсез кала, иякне сузмыйбыз.

*6 нчы күнегү*

***Җилкәләр белән әйләнмәле хәрәкәт ясау***

Кулларны төшереп, туры басабыз. Шул халәттә җилкәләр белән әйләнмәле хәрәкәт ясыйбыз, башта 5 тапкыр алдан артка таба, аннары 5 тапкыр кире юнәлештә.

Җилкәләр өскә күтәрелгәндә иснибез һәм җилкәләр аска төшкән чакта гына һаваны чыгарабыз (ачык авыздан, борын аша).

***7 нче күнегү*** (14 нче, 15 нче рәсемнәр)

***Җилкәләр белән алга һәм артка таба хәрәкәтләр***




14 нче рәсем




15 нче рәсем

Кулларны билгә куябыз. Ике җилкәне дә бер тигез алга этеп, һаваны чыгарабыз. Иснәгәндә акрын, ләкин көч белән аларны артка “ташлыйбыз”. Җилкәләр белән бергә терсәкләр дә хәрәкәт итә, ә баш һәм гәүдә үзенең торышын үзгәртми.

Артка таба хәрәкәт – күнегүнең иң мөһим өлеше. Ул җилкәнең арткы мускуллары ярдәмендә башкарыла һәм аларны ныгыта.

**Искәрмә:**

- Бу күнегүдә җилкәләрне артка ташлауны энергияле генә түгел, бәлки кискенрәк ташлау белән дә төрлеләндерергә мөмкин.

***V комплекс***

***Куллар хәрәкәте***

Кулларны хәрәкәтләндергәндә күкрәк читлеге зурая, һава күләме арта. Бу күнегүләрне башкарганда гәүдәнең өске өлеше артка салынмавына һәм эчнең алга чыгып тормавына игътибар итәбез. Шул ук вакытта умыртка баганасы, гәүдә тыныч халәттә булырга тиеш.

***1 нче күнегү*** (16 нчы рәсем)

***Кулларны чиратлап өскә күтәрү***

***I төре – салмак темпта***




16 нчы рәсем

Куллар ян-якта, туры басып торабыз, бер кулны бик җиңел генә өскә күтәргәндә, ашыкмыйча иркен генә иснибез. Һаваны тоткарлап торабыз, кулны акрынлап аска төшергәндә һаваны чыгарабыз. Икенче кул белән дә шулай ук эшлибез.

Күнегүне 3 тапкыр эшләгәннән соң, тиз генә иснәп, һаваны өлешләп чыгарабыз.

Әлеге күнегү белән без үпкәләрнең әле берсенең, әле икенчесенең эшчәнлеген көчәйтәбез. Әгәр дә үпкәләрнең берсе көчсезрәк икән, күнегүләрне шул як кул белән күбрәк ясарга туры килә.

***II төре – тизләтелгән темпта***

**Искәрмә:**

- Муен һәм җилкә мускулларында булырга мөмкин киеренкелекне киметергә тырышабыз. Куллар иркен, җиңел хәрәкәтләнә.

***2 нче күнегү*** (17 нче, 17а рәсемнәр)

***Ике кулны да күтәрү***



17 нче рәсем



17а рәсем

Куллар ян-якта, туры басып торабыз, ике кулны да өскә күтәргәндә иркенләп иснибез. Һаваны һәм кулларны шул рәвешчә берникадәр тоткарлап торабыз. Кулларны аска төшергәндә һаваны акрынлап “ссс” авазлар җыелмасы белән чыгарабыз. Бу күнегүне 5 тапкыр кабатлаганнан соң, борын аша тиз генә иснәп, һаваны өлешләп чыгарабыз.

*3 нче күнегү*

***Кулларны болгау***

Бу күнегү алдагы күнегүне кабатлый. Кулларны өскә күтәргәндә иснәп, иркен генә аска төшергәндә һаваны да чыгарып, артка таба болгап куябыз.

Яңадан иснәп, шул ук вакытта кискен генә кулларны өскә күтәрәбез, һаваны чыгара-чыгара яңадан аска төшерәбез. Кулларның хәрәкәте җиңел һәм иркен булырга тиеш.

Әлеге күнегү һава күләмен арттыра, һава алмашуны иркенәйтә, чыккан һава агымын, үпкәләрнең өске өлеше эшчәнлеген активлаштыра.

***4 нче күнегү*** (18 нче, 18а рәсемнәр)

***Кулларны ян-яктан күтәрү***





18 нче рәсем





18а рәсем

Кулларны төшереп, туры басабыз, иснәгәндә иркен генә кулларны яннан өскә күтәрәбез. Бераздан һаваны чыгара-чыгара кулларны төшерәбез.

Төшкән вакытта кул чуклары бераз киеренке халәттә.

Күнегүне 5 тапкыр кабатлаганнан соң, борын аша тиз генә иснибез. Һаваны өлешләп чыгарабыз.

**Искәрмә:**

- Әлеге күнегүдә арка һәм җилкә мускуллары катнаша. Нәтиҗәдә күкрәк читлеге киңәя, кабыргара мускуллар ныгый.

***5 нче күнегү***

***«Очып барган кош»***

Кулларны төшереп, туры басабыз. Иркен генә иснәгәндә кулларны кош канатларын җилпегән сыман яннан өскә күтәрәбез. Кулны күтәргән саен иснибез, төшергән чакта һаваның бер өлеше үзеннән-үзе чыга.

Куллар баш өстендә очрашкач, берничә секунд тоткарланып торабыз һәм “ф” белән салкын һава чыгарганда кулларны аска төшерәбез. 3 тапкыр эшләгәннән соң тиз генә иснәп, һаваны өлешләп чыгарабыз.

**Искәрмә:**

- Әлеге күнегү күкрәк читлеген киңәйтә, сөйләм аппараты мускулатурасын тагы да сыгылмалы итә. Күнегү үтәлгәндә хәрәкәтләр иркен һәм җиңел булсын, үзебезне “очып барган кош” итеп хис итәбез.

***6 нчы күнегү*** (19 нчы, 19а рәсемнәр)

***Кулларны җәю***



19 нчы рәсем



19а рәсем

Куллар төшкән, туры басып торабыз. Эчнең аскы өлешен алга этеп иснәгәндә кулларны алга сузабыз, горизонталь торышка җиткәч, туктамыйча, ян-якка җәябез. Бераз тоткарланабыз, һаваны чыгарганда хәрәкәтләрне кирегә эшлибез.

**Искәрмә:**

- Кулларны җәйгәндә арка мускуллары, бергә китергәндә күкрәк мускуллары хәрәкәтләнә. Күнегү күкрәк читлеген зурайтырга, диафрагманы нығытырга ярдәм итә.
- 

*__7 нче күнегү__* (20 нче, 20а, 20ә рәсемнәр)

***Кулларны әйләндерү***



20 нче рәсем



20а рәсем



20ә рәсем

Куллар янда, тураеп басабыз. Кулларны күтәргәндә иркен итеп иснибез. Шуннан соң, куллар белән алдан артка таба зур түгәрәк ясаганда, “ф” белән чыгарабыз. 5-6 тапкыр кабатлаганнан соң кулларны төшерәбез һәм тиз генә иснәп, һаваны “пфф” авазлар җыелмасы белән салмак кына өлешләп чыгарабыз. Икенче тапкыр иснәгәндә шул ук хәрәкәтләрне кирегә таба

эшлибез. Тиз генә иснәп, һаваны “пф-пф” авазлар җыелмасы белән тиз-тиз 6-8 кисәккә бүлеп чыгарабыз.

**Искәрмәләр:**

- Кулларны өскә күтәрү иснәү белән бергә, төшерү – һаваны чыгару белән бервакытта башкарыла.
- Әгәр җилкәләрнең берсе авыртса, бары тик бер кул белән генә эшләргә дә мөмкин.
- Хәрәкәт вакытында умыртка баганасы тыныч халәттә, кул мускуллары киеренке түгел.

***8 нче күнегү*** (21 нче рәсем)

***«Кулны ташлау»***



24 нче рәсем

Кулларны, терсәктән бөгеп, туры басабыз; алга бер адым атлап, кинәт кенә кулларны алга “ташлаганда” иркен генә иснибез. Бер аяк алда кала, билдән бераз алга иелгәндә һаваны чыгарабыз, кулларны яңадан җыябыз. Күнегүне 5 тапкыр эшләгәннән соң тиз генә иснәп, һаваны өлешләп чыгарабыз. Аякларны алмаштырып, күнегүне 5 тапкыр эшлибез.

***9 нчы күнегү*** (22 нче, 22а рәсемнәр)

***Кулларны сузу***

Кулларны аркага куеп туры басабыз. Һава иснәгәндә кулларны сузып турайтабыз. Шул халәттә 2-3 секунд һаваны тотып торабыз. Кулларны элекке халәтенә кайтарып, һаваны чыгарабыз. Шул рәвешчә күнегүне 5 тапкыр кабатлагач, тиз генә иснәп, һаваны өлешләп чыгарабыз.



22 нче рәсем



22а рәсем

**Искәрмә:**

- Күнегүне эшләгәндә умыртка баганасы туры булсын.

***10 нче күнегү*** (23 нче, 23а рәсемнәр)

***Бармаклар белән түгәрәк хәрәкәтләр***



23 нче рәсем



23а рәсем

Кулларны җилкә тигезлегендә күтәреп, туры басабыз. Бармаклар я сузылган, я йодрыкланган. Һава иснәгәндә учларны өскә каратабыз. Һаваны “с” авазы белән өлешләп чыгарганда, кул beләзеген бөгеп, түгәрәк ясап 8 тапкыр боргалыйбыз.

### *11 нче күнегү* (24 нче рәсем)

### *Бармакларны бөгү*



24 нче рәсем

Әлеге күнегүне баскан, утырган килеш тә эшләргә була. Бармак очлары идәнгә карап торырлык итеп бөгелгән халәттә кулларны алга сузып иснибез, бармакларны йодрыклыйбыз. Һаваны чыгарган чакта төрле авазлар җыелмасы белән бармакларны турайтабыз һәм ян-якка җәябез. Шуннан соң кул чукларын тулысынча иркенәйтеп селкибез. Күнегүне 6 тапкыр эшләгәч, тиз генә иснәп һаваны өлешләп чыгарабыз.

**Искәрмә:**

- Әлеге күнегүне кулларны салындырган халәттә дә эшләргә мөмкин.

### *VI комплекс*

### *Аяк хәрәкәтләре*

***1 нче күнегү*** (25 нче, 25а рәсемнәр)

***Аякны күтәреп бөгү***

 

25 нче рәсем                25а рәсем

Кулларны билгә куеп, туры басабыз. Иснәгәндә, бер аякны тездән бөгеп күтәрәбез. Аякның тездән түбән өлеше иркен асылынып тора. Һаваны чыгарганда аякны кискен генә алга сузабыз. Кабат иснәгәндә аякны яңадан бөгәбез, һаваны чыгарганда тагын турайтабыз.

Күнегүне 6 тапкыр кабатлаганнан соң, аякны төшерәбез, ягъни ике аякка да басабыз һәм тиз генә иснәп, һаваны өлешләп чыгарабыз. Шуннан соң бу күнегүне икенче аяктан эшлибез һәм шулай ук, тиз генә иснәп, һаваны өлешләп чыгарабыз.

**Искәрмә:**

- Әлеге күнегүдә һәм алдагы күнегүләрдә дә умыртка баганасының турылыгына игътибар итәргә кирәк.

***2 нче күнегү*** (26 нчы, 26а, 26ә) рәсемнәр)

***«Велосипедта йөрү» яки аяк белән түгәрәк хәрәкәтләр ясау***

Кулларны билгә куеп туры басабыз. Ашыкмыйча иснәгәндә аякны тездән бөгеп өскә күтәрәбез һәм велосипедта йөргән кебек итеп, 8 түгәрәк хәрәкәт ясыйбыз.




26 нчы рәсем




26а рәсем




26ә рәсем

Күнегүне 5 тапкыр кабатлаганнан соң, тиз генә иснибез, һаваны өлешләп чыгарабыз. Шуннан соң әлеге күнегүне икенче аяктан эшлибез. Тиз генә иснибез, һаваны өлешләп чыгарабыз.

**Искәрмәләр:**

- Түгәрәк хәрәкәтләр сәгать йөреше уңаена да, кирегә дә, горизонталь һәм вертикаль яссылыкта үтәлә.
- Аяк мускулатурысында киеренкелек юк.
- Күнегүне ашыкмыйча эшләргә.

***3 нче күнегү***

***«Әйләндерү»***

Кулларны билгә куеп туры басабыз, иркен итеп иснәгәндә бер аяк белән алдан артка таба әйләнмәле хәрәкәт ясыйбыз, һаваны чыгарганда әйләнмәнең калган өлешен ясап бетерәбез.

Күнегүне 5 тапкыр кабатлаганнан соң, тик торганда тиз генә иснәп, һаваны өлешләп чыгарабыз. Шуннан соң әлеге күнегүне икенче аяк белән эшлибез һәм шулай ук тиз генә иснәп, һаваны өлешләп чыгарабыз.

**Искәрмәләр:**

- Әйләнмә ясаган аяк иркен хәрәкәтләнә. Ә икенче аяк туп-туры. Гәүдәнең өске өлеше тыныч, җилкәләр бер югарылыкта.
- Бу күнегү эчнең аскы өлешендәге аркылы һәм кыек мускул җепселләрен, эчке органнарның эшчәнлеген яхшырта.

***4 нче күнегү*** (27 нче, 27а, 27ә рәсемнәр)

***Аякны алга һәм артка «атындыру»***

Аяк идәнгә тимәсен өчен кубларга (спорт урындыгы) менеп, тураеп басабыз. Бер кул билдә, икенчесе белән стенага (урындык аркасына) тотынабыз. Иснәгәндә аякны артка ташлыйбыз, һаваны чыгарганда – алга.

Әлеге күнегүне 5 тапкыр кабатлаганнан соң тиз генә иснәп, һаваны өлешләп чыгарабыз. Шуннан соң аякларны алмаштырабыз.




27 нче рәсем




27а рәсем




27ә рәсем

**Искәрмә:**

- Күнегүне эшләгән чакта гәүдәнең өске өлеше селкенми; аяк иркен һәм салмак хәрәкәтләнә. Аяк очы аска таба юнәлгән.

***5 нче күнегү*** (28 нче, 28а рәсемнәр)

***Аякларны янга "атындыру"***




28 нче рәсем




28а рәсем

Кулның берсен билгә куеп, икенчесе белән стенага (урындык аркасына) тотынып туры басабыз. Аяк янга киткәндә – иснибез, җыелганда – һаваны чыгарабыз.

**Искәрмәләр:**

- 4 нче һәм 5 нче күнегүләрне аяк очларына гына басып та эшләргә мөмкин.
- Әгәр тотынмыйча гына эшли алуыгызга ышансагыз, икенче кулны да билгә куярга була.

***6 нчы күнегү*** (29 нчы рәсем)

***Тезләрне бөгү***



29 нчы рәсем

Үкчәләр бергә, бармак очлары икесе-ике якта, куллар билдә. Иснәгәндә аяк очларына күтәреләбез һәм, һаваны тоткарлап, 2-3 секунд шул ук хәлдә торабыз. Һаваны чыгарганда аяк очларында калган килеш бераз чүгәбез. Яңадан иснәгәндә, аяк очларында калган халәттә тезләрне турайтабыз һәм янә 2-3 секундка шул торышта калабыз. Һаваны чыгарганда тагын чүгәбез.

Күнегүне 5 тапкыр эшләгәннән соң, аякларга ныклап басабыз һәм тиз генә иснәп, һаваны өлешләп чыгарабыз.

***7 нче күнегү*** (30 нчы рәсем)

***Чүгәләү***

Әлеге күнегү алдагы 6 нчы күнегү кебек, тик иснәгәндә мөмкин кадәр түбәнрәк чүгәләргә кирәк; гәүдәнең өске өлеше алга иелмәгән, арка туры.

Үкчәләр бергә, мөмкин кадәр өскәрәк күтәрелгән.




30 нчы рәсем

***8 нче күнегү*** (31 нче, 31а рәсемнәр)

***Тезләрне чиратлаштырып бөгү***




31 нче рәсем




31а рәсем

Кулларны билгә куеп туры басабыз. Иснәгәндә уң аяк белән алга атлыйбыз, шуннан соң, гәүдәнең авырлыгын, тездән бөгеп, сул аякка күчереп, һаваны чыгарабыз. Алдагы аяк (уң аяк) тулысынча туры килеш кала. Яңадан иснәгәндә сул тезне турайтабыз һәм, һаваны чыгарганда уң тезне бөгеп алга иеләбез. Инде гәүдәнең авырлыгы уң аякка күчә. Гәүдәнең өске өлеше һәм арттагы аяк бер турыда. Үкчәләр күтәрелми. Күнегүне һәр аяктан өчәр тапкыр эшләгәннән соң, тураеп басабыз һәм тиз генә иснәп, һаваны өлешләп чыгарабыз.

***9 нчы күнегү*** (32 нче рәсем)

***Аяк бармакларында күтәрелү***

***I төре***



32 нче рәсем

Кулларны билгә куеп, туры басабыз. Иснибез. Иснәгәндә, аяк очларында күтәреләбез. Шул торышта эчтән салмак кына бишкә яки алтыга кадәр санап, һаваны тоткарлап торабыз да, чыгарганда яңадан табаннарга басабыз.

Әлеге күнегүне 5 тапкыр кабатлаганнан соң, тиз генә иснәп, һаваны өлешләп чыгарабыз.

**Искәрмә:**

- Күнегүне эшләгәндә гәүдәнең өске өлеше хәрәкәтләнми.

***II төре*** (33 нче рәсем)

***Кулларны өскә күтәреп, аяк бармакларында күтәрелү***



33 нче рәсем

Иснәп, аяк бармакларында күтәрелгәндә, куллар да ян-яктан өскә күтәрелә. Кулларны төшереп табанга басканда дәвамлы итеп салкын һава чыгарабыз. Борын аша тиз генә иснәп, һаваны тиз-тиз өлешләп чыгарабыз.

Күнегүне 5 тапкыр эшләгәч, чыгаруга күчәбез.

**Искәрмә:**

- Үткән күнегүләрдән аермалы буларак, бу күнегүдә бөтен сөйләм аппараты катнаша. Күнегү һава агымының көчен һәм күләмен арттыра, муен арты, җилкә мускулларын үстерә, кабыргара мускулларның хәрәкәтчәнлеген үстерә. Шулай ук аяк һәм арка мускулларын ныгыта; умыртка баганасын турайтуга да ярдәм итә.

***10 нчы күнегү*** (34 нче, 34а рәсемнәр)

***Аякны тубыктан бору***



34 нче рәсем



34а рәсем

Әлеге күнегүне аякны  аяк өстенә куеп, идәндә (урындыкта) утырган килеш тә, аякны тездән бөгеп күтәреп, баскан килеш тә эшләргә була. Иснәгәндә аяк бармакларын аска, һаваны чыгарганда эчтән сигезгә кадәр санап, үзебезгә таба тартабыз.

Күнегүне 5 кат кабатлаганнан соң тиз генә иснәп һаваны өлешләп чыгарабыз. Алга таба икенче аякны күтәреп, 5 тапкыр кабатлаганнан соң, тагын тиз генә иснәп, һаваны дәвамлы итеп өлешләп чыгарабыз (5-6 өлеш).

***11 нче күнегү*** (35 нче рәсем)

***Бер урында йөгерү***

Куллар билдә, тураеп басабыз, җилкәләрне бераз артка ташлыйбыз. Баскан урыныбызда йөгерә башлыйбыз, 1-2 адымда иснибез, алдагы 8 адымда һаваны чыгарабыз, 1 яки 2 адымда пауза ясыйбыз. Һәр аяктан 25-30 адым ясаганнан соң туктыйбыз һәм тиз генә иснәп, һаваны ваграк өлешләргә бүлеп, “пф-пф” авазлар җыелмасы белән чыгарабыз.



35 нче рәсем

***VII комплекс***

***Бөтен гәүдә хәрәкәтләре***

***1 нче күнегү*** (36 нчы рәсем)

***Гәүдәне бору***



36 нчы рәсем

Кулларны төшереп, туры басабыз. Иснәгәндә кулларны күтәрәбез һәм кулларны янга “ыргытып”, гәүдәнең өске өлеше белән сулга борылабыз. Һаваны чыгарганда элеккеге торышка кайтабыз. Күнегүне 3 тапкыр кабатлаганнан соң тиз генә иснәп, һаваны өлешләп чыгарабыз.

**Искәрмә:**

- Хәрәкәт вакытында аяклар урыныннан кузгалмый.
- Әлеге күнегү эчнең аскы һәм бот мускулларының ныгуына, кан әйләнешенең яхшыруына ярдәм итә.

***2 нче күнегү*** (37 нче, 37а рәсемнәр)

***Алга һәм артка таба бөгелү***



37 нче рәсем



37а рәсем

Кулларны билгә куеп, туры басабыз. Шул торышта иснәп алабыз. Шуннан соң акрын гына иелгәндә һава чыга. Кабат иснәгәнче шул халәттә торабыз, турайганда иснибез дә, туктамыйча, артка таба бөгеләбез. Гәүдәнең өске өлеше белән кабат алга иелгәндә һаваны чыгарабыз. Күнегүне 3 тапкыр кабатлагач, тиз генә иснәп һаваны өлешләп чыгарабыз.

***3 нче күнегү*** (38 нче, 38а рәсемнәр)

***Ян- якка иелү***



38 нче рәсем



38а рәсем

Кулларны билгә куеп, туры басабыз. Шул торышта иркен генә иснибез. Һаваны чыгарганда уңга таба иеләбез. Турайганда иснибез, һаваны чыгарганда сулга таба иеләбез. Күнегүне һәр якка өчәр тапкыр кабатлаганнан соң, тиз генә иснәп, һаваны өлешләп чыгарабыз.

**Искәрмә:**

- Кулларны чиратлап баш өстеннән күтәрү белән катлауландырырга да мөмкин (38а рәсем).
- Иелгән чакта аяклар күтәрелми, баш туры, җилкәләр дә селкенми.

***4 нче күнегү*** (39 нчы, 39а, 39ә рәсемнәр)

***Гәүдәне бору***

Кулларны билгә куеп, туры басабыз, иелеп иснибез. Иснәгәндә, гәүдәнең өске өлешен уңга, аннары түгәрәк буенча артка бора башлыйбыз. Һаваны чыгарганда сулга һәм алга хәрәкәтләнәбез, тураеп басабыз. Күнегүне 3 тапкыр кабатлаганнан соң, тиз генә иснәп, һаваны төрле

авазлар җыелмасы белән өлешләп чыгарабыз. Шуннан соң әлеге күнегүне сул якка таба эшлибез.


39 нчы рәсем


39а рәсем


39ә рәсем

**Искәрмә:**

- Күнегүне эшләгән чакта аяк, җилкә һәм баш боргаланмый.
- Бу күнегү барлык эчке органнарның да эшчәнлеген яхшырта.

***5 нче күнегү*** (40 нчы рәсем)


40 нчы рәсем

Әгәр дә кемнең дә булса уң як үпкәсе вазифасын начар үтәсә, түбәндәге күнегү киңәш ителә.

Арка туры, урындык каршына басабыз, сул кул белән урындык аркасына тотынабыз, ә уңы белән борынның сул яфрагын кысабыз, башны уңга бөгәбез, акрын гына иснибез. Һаваны ике борын тишегеннән дә чыгарабыз, баш турая. Әлеге күнегүне 3 тапкыр кабатлагач, тураеп басабыз һәм тиз генә иснәп һаваны өлешләп чыгарабыз. Әгәр дә сул як үпкәнең көче юк икән, бу очракта, урындыкка уң кул белән тотынып, башны сул якка бөгәбез, борынның уң яфрагын кысабыз.

***6 нче күнегү*** (41 нче рәсем)

Уң як үпкә яки үпкәнең өске өлеше көчсез булган очракта сул якка авышыбрак ятабыз. Сул кул алга сузылган, ә уңы борынның сул як яфрагын кыса. Шул халәттә иснибез, һаваны борынның ике тишегеннән дә чыгарабыз һәм борынның сул яфрагын кысып, тагын иснибез. Күнегүне 3 тапкыр кабатлагач, тиз генә иснәп һаваны өлешләп чыгарабыз.



41 нче рәсем

***7 нче күнегү*** (42 нче, 42а рәсемнәр)



42 нче рәсем



42а рәсем

Кулларны төшереп, туры басабыз. Иснәгәндә ике кулны да өскә, бер якка “ыргытабыз”, һаваны чыгарганда иеләбез, кулларны дуга буенча төшерәбез, тураябыз да яңадан иснәгәндә, кулларны икенче якка “ыргытабыз”.

**Искәрмә:**

- Әлеге күнегү кул мускулларын, күкрәк читлеген ныгыта.

***8 нче күнегү (***43 нче, 43а рәсемнәр***)***



43 нче рәсем



43а рәсем

Ниндидер авырлык (ком тутырылган туп, 1 кг гантель) тоткан кулларны аска төшереп, туры басабыз. Иснәгәндә, уң (сул) аяктан алга атлыйбыз, иркен һәм җиңел генә итеп, ике кулны да өскә күтәрәбез, өстә тукталмыйча гына уң (сул) якка “ыргытабыз”. Күнегүне 5 тапкыр кабатлагач, тиз генә иснәп, һаваны өлешләп чыгарабыз. Гәүдәнең өске өлеше үзеннән-үзе куллар артыннан иярә. Әлеге күнегүне үтәгәндә гәүдәнең бөтен мускуллары да ныгый.

**Искәрмә:**

- Һаваны чыгарганда, куллар аска төшә, тураеп басабыз.

**Тавыш күнегүләре**

**“Яңгыраучан гәүдә” тавыш күнегүләре комплексы**

**Сузык авазларның яңгырау баганасы**

Сузык авазларны төрле хәрәкәттә яңгыратабыз (бишкә кадәр санап). Һәр күнегүдә кушуч иреннәрнең дәвамы, аваз көчәйткеч рупор вазифасын үти. Умыртка баганасының турылыгын махсус тикшереп торабыз.

1. У-у-у… – тезләнеп алга иеләбез. Умыртка баганасы туры, койрык сөяге – копчик – югары нокта (1нче, 1а рәсемнәр).



1нче рәсем



1а рәсем

2.Ы-ы-ы… – гәүдәне идәнгә паральлель урнаштырабыз (2нче, 2а рәсемнәр).





2 нче рәсем 2а рәсем

3.Ый-ый-ый… – башны тезләргә салабыз. Умыртка баганасының турылыгы сакланмый (3 нче, 3а рәсемнәр).





3 нче рәсем 3а рәсем

4.О-о-о… – тезләнеп утырган килеш гәүдәне артка янтайтабыз (4нче рәсем). (Соңыннан, киң әйтелешле “О” авазына гәүдәне алга күчерәбез, чайкалабыз (4 нче рәсем, 4а, 4ә рәсемнәр)).







4 нче рәсем 4а рәсем 4ә рәсем

5.А-а-а… – Тезләнгән килеш гәүдәне турайтабыз (5нче, 5а рәсемнәр).



5нче рәсем



5а рәсем

6.Ү-ү-ү… – Аякка басабыз, гәүдәне нык кына (якынча 60º) алга иябез (6нчы, 6а рәсемнәр).



6 нчы рәсем



6а рәсем

7. Ө-ө-ө… – Басып торган килеш, гәүдәне җиңелчә (якынча 15º) алга иябез (7нче, 7а рәсемнәр).



7 нче рәсем



7а рәсем

8.Ә-ә-ә… – Басып торган хәлдә, гәүдәне җиңелчә (якынча 15º) артка янтайтабыз (8нче, 8а рәсемнәр).





8нче рәсем 8а рәсем

9.Э-э-э… – Тезләрне бөгеп, гәүдәне нык кына (якынча45º) артка янтайтабыз (9нчы рәсем).(Киң әйтелешле,алынма сүзләрдәге "Э" авазын гәүдәне якынча 15º янтайтып (9а рәсем))





9нчы рәсем 9а рәсем

10.И-и-и…– Туп-туры басып торабыз. Аяклар җилкә киңлегендә (10нчы, 10а рәсемнәр).



10нчы рәсем



10а рәсем

## Сузык авазларның  яңгырау тирәлеге

### Яңгырау кыры

| | |
|---|---|
| 1. Яңгырау кыры – баш һәм аның тирәлеге.<br><br> | 2. Яңгырау кыры – баш, ярты гәүдә тирәлеге.<br><br> |

| | |
|---|---|
| 3. Яңгырау кыры – күкрәк читлеге, тирәлеге.<br><br>ы – ы – ө – ә | 4. Яңгырау кыры – җилкә кыршавы, муен тирәлеге.<br><br>ө – ә – э – э |
| 5. Яңгырау кыры – күкрәкнең аскы өлеше, тирәлеге.<br><br>а – о –о | 6. Бөтен гәүдә, аның тирәлеге гүли.<br><br>у – о – о – а<br>о – о – ө – ә – ү<br>э – э – и – ы – ый |

## Яңгырау кырларын тоташтыру

Төрле авазларның дерелдәү тирәлеген истә тотып, авазларны чиратлаштырып яңгыратабыз. Гәүдәнең теге яки бу өлкәсендә дерелдәүне арттырып, тавыш көчен үстерергә мөмкин:

1. у-о; о-у. 2. у-ый; ый-у. 3. у-а; а-у.

4. у-ө; ө-у. 5. у-и; и-у. 6. а-и; и-а.

Тавышны бер регистрдан икенчесенә күчерү:

1. и – э – ә – ө; 2. и – э – э – ә; 3. у – о – а;

4. у – о – о – ы – ый; 5. у – о – а; 6. у – о – о – ы – ый – а.

## Яңгырау тирәлеген “күчерү”

1. “у” авазы “и” тирәлегендә;

2. “о” авазы “ә” тирәлегендә;

3. “у” авазы “ү” тирәлегендә;

4. “у” авазы “ө” тирәлегендә;

5. “а” авазы “и” тирәлегендә;

6. “о” авазы “и” тирәлегендә.

### Тартык авазларның яңгырау баганасы




### Тартык авазларның яңгыравын күнектерү

1. Тартык авазларның яңгырау баганасы аваз оешудагы табигатенә – тирбәнү-дерелдәү ешлыгына якынайтып төзелде. Татар әдәби телендә тартык авазларның калынлык-нечкәлек дәрәҗәсе иҗектәге сузык авазга бәйле. Тартык авазларны башта сузык авазлар баганасы хәрәкәтләре белән яңгыратабыз:

| | | | |
|---|---|---|---|
| 1) гъу | 7) жо | 13) мА | 19) пе |
| 2) къу | 8) шо | 14) гү | 20) һә |
| 3) ху | 9) зый | 15) кү | 21) вә |
| 4) wу | 10) сый | 16) дө | 22) фә |
| 5) җы | 11) ра | 17) тө | 23) ңи |
| 6) чы | 12) ла | 18) бе | 24) ни |

2. Һәрбер тартык авазны сузык авазлар баганасы хәрәкәте тәртибендә яңгыратабыз: 1) гъу; 2) къу; 3) ху; 4) wу; 5) җу; 6) чу; 7) жу; 8) шу; 9) зу;

10) су; 11) ру; 12) лу; 13) му; 14) гу; 15) ку; 16) ду; 17) ту; 18) бу; 19) пу; 20) һу; 21) ву; 23) ңу; 24) ну. Яки 1) гъө; 2) къө; 3) хө; 4) wө; 5) җө; 6) чө; 7) жө; 8) шө; 9) зө; 10) сө; 11) рө; 12) лө; 13) мө; 14) гө; 15) кө; 16) дө; 17) тө; 18) бө: 19) пө; 20) һө; 21) вө; 22) фө; 23) ңө;

24) нө. Яки 1) гъи; 2) къи; 3) хи; 4) wи; 5) җи; 6) чи; 7) жи; 8) ши; 9) зи; 10) си) 11) ри; 12) ли; 13) ми; 14) ги; 15) ки; 16) ди; 17) ти; 18) би; 19) пи; 20) һи; 21) ви; 22) фи; 23) ңи; 24) ни. Һәм башка сузык авазлар белән дә.

3. Гәүдәнең тартык авазлар баганасына туры килгән өлешен куллар белән каккалап, бер үк сузык авазлы дүрт иҗектән торган җыелма яңгыратабыз: 1) нунунуну; 2) ңуңуңуңу; 3) фуфуфуфу; 4) вувувуву; 5) һуһуһуһу; 6) пупупупу; 7) бубубубу; 8) тутутуту; 9) дудудуду; 10) кукукуку; 11) гугугугу; 12) мумумуму; 13) лулулулу; 14) рурурурy; 15) сусусусу; 16) зузузузу; 17) шушушушу; 18)жужужужу; 19) чучучучу; 20) җуҗуҗуҗу; 21) wуwуwуwу; 22) хухухуху; 23) къукъукъукъу; 24) гъугъугъугъу һ.б. сузык авазлар белән дә.

4. Гәүдәнең тартык авазлар баганасына туры килгән өлешен куллар белән каккалап, парлы тартык авазларны бер үк сузык авазлы ике иҗектән торган җыелма белән яңгыратабыз: 1) гъукъу; 2) хуһу; 3) җучу; 4) жушу; 5) зусу; 6) гуку; 7) дуту; 8) бупу; 9) вуфу. Яки өстән аска таба: 1) вифи; 2) һихи; 3) бипи; 4) дити; 5) гики; 6) зиси; 7) жиши; 8) җичи; 9) гъикъи. Һәм башка сузык авазлар белән дә.

5. Гәүдәнең тартык авазлар баганасына туры килгән өлешен куллар белән каккалап, парлы сузык авазлар катнашлыгында төзелгән ике иҗекле җыелма яңгыратабыз: 1) гъугъү; 2) къукъү; 3) хухү; 4) wуwү; 5) җуҗү; 6) чучү; 7) жужү; 8) шушү; 9) зузү; 10) сусү; 11) рурү; 12) лулү; 13) мумү; 14) гугү; 15) кукү; 16) дудү; 17) тутү; 18) бубү; 19) пупү; 20) һуһү; 21) вувү; 22) фуфү; 23) ңуңү; 24) нунү. Һәм башка сузык авазлар белән дә.

6. Фразаларны сузык авазлар баганасы хәрәкәтләрен үтәп; җырлап, сөйләп яңгыратабыз:

Туган тугайдан туйган юк.

Тырышлык – зурлык, тырышмый торсаң – хурлык.

Озын, озын, озын юл, озыннан озын – озак юл.

Абагага бага-бага башым бәрдем баганага.

Үсмәгәнне үчти-үчти дип үстермиләр.

Хәрәкәттә – бәрәкәт. Әйләнә, әйләнә дә бәйләнә.

Эшенә күрә әҗере.

Исем кешене бизәми, кеше исемне бизи.

**“Сөембикә манарасы” тавыш күнегүләре миниатюрасы**

1. “Сузык авазларның яңгырау баганасы” хәрәкәтләрен үтәп, “й” һәм сузык авазларны дәвамлы (8гә кадәр санап) яңгыратабыз.

1) Уй-уй-уй-уй…

2) Ый-ый-ый-ый…

3) Ой-ой-ой-ой…

4) Ай-ай-ай-ай…

5) Үй-үй-үй-үй…

6) Өй-өй-өй-өй…

7) Эй-эй-эй-эй…

8) Әй-әй-әй-әй…

9) Ий-ий-ий-ий.

2.Хәрәкәттә фразалап:

1) Уwулу йуун мунуруңлу;

2) Ыwылы йыын мынырыңлы;

3) Оwоло йоон монороңло;

4) Аwала йаан манараңла;

5) Үwүлү йүүн мүнүрүңлү;

6) Өwөлө йөөн мөнөрөңлө;

7) Эwэлэ йээн мэнэрэңлэ;

8) Әwәлә йәән мәнәрәңлә;

9) Иwили йиин минириңли.

3. Хәрәкәттә, җәенке фразалар яңгыратабыз.

1) Уй – wуй увулу сунуң йуун мунуруңлу уй – wуй;

2) Ый –wый ывылы сының йыын мынырыңлы ый – wый;

3) Ой – wой оволо соноң йоон монороңло ой – wой;

4) Ай – wай авала санаң йаан манараңла ай – wай;

5) Үй – wүй үвүлү сүнүң йүүн мүнүрүңлң үй – wүй;

6) Өй – wөй өвөлө сөнөң йөөн мөнөрөңлө өй – wөй;

7) Эй – wэй эвэлэ сэнэң йээн мэнэрэңлэ эй – wэй;

8) Әй – wәй әвәлә сәнәң йәән мәнәрәңлә әй – wәй;

9) Ий – wий ивили синиң йиин миниириңли ий – wий.

4. Һәр сузык авазга билгеләнгән хәрәкәт, төгәлләнгән текстка аерым мөнәсәбәт белән, сөйләп:

1) Уф – фу, уй – wуй! Сөембикә манарасының авышуы зур шул, уф – фу, уй – wуй (борчылып)

2) Ай – һай?! Сөембикә манарасы аварсы икәнни? Ай – һай! (риторик сорау, кире кагу)

3) Эй – һэй! Сөембикә манарасы! Дәверләрдән – дәверләргә күчәрсеңме җыр-моң булып?! (риторик эндәш)

4) Буыннардан-буыннарга барлык татар күңелендә мәңгелек һәйкәл-ядкәр син, и, Сөембикә манарасы! (риторик өндәү)

5. Һәр фразада тавыш тоны күтәрелә бара

I укучы: Сөембикә манарасы – алтын айлы манара!

II укучы: Сөембикә манарасы – ун буынлы манара!

III укучы: Сөембикә манарасы – туксан баскыч манара!

IV укучы: Сөембикә манарасы – нык нигезле манара!

V укучы: Сөембикә манарасы – шундый нурлы манара!

VI укучы: Сөембикә манарасы – безнең мөнбар манара!

VII укучы: Сөембикә манарасы – нинди нәфис манара!

VIII укучы: Сөембикә манарасы – мин яраткан манара!

6. Хәрәкәттә ритмик-мелодик рәсем күнектерәбез. Җырлап, сөйләп: “Нинди биек манара! Нинди бөек манзара!” (Татар халык көе “Биек тауның башларында...”)

**Мелодик диапазонны үстерү күнегүләре**

**Мәгънәви басым урынын һәм мелодик интервалларны күнектерү**

1. «Тапкырлау таблицасы» I вариант

1) 1х1, 1х2…; егетләр – гәүдәне кулларда күтәрәләр, кызлар – гәүдәне кулларда тездән генә күтәрәләр; нокта беренче баганада – “до” беренче октава – “си” кече октава.

2) 2х1, 2х2...; эчкә ятып, билдән күкрәкне күтәрәбез; нокта икенче баганада – “до” беренче октава – “си” кече октава.

3) 3х1, 3х2...; “көймә” ясап атынабыз; нокта өченче баганада – “до” беренче октава – “си” кече октава.

4) 4х1, 4х2...; аркада ятып велосипедта йөрибез; сорау; III баганада ярты тонга күтәрелү – “до-до-до#”.

5) 5х1, 5х2...; ятып ян-якка әйләнәбез; гаҗәпләнеп сорау; III баганада бер тонга күтәрелү – “до-до-ре”.

6) 6х1, 6х2...; “кайчы” күнегүен ясыйбыз; өндәү I баганада; 1,5 тонга күтәрелү – “до-до-ре#”.

7) 7х1, 7х2...; ятып; аякларны тездән бөгәбез; турайтып төшерәбез; өндәү II баганада; 1,5 тонга күтәрелү – “до-до-ре#”.

8) 8х1, 8х2...; яткан килеш тезләрне бөгеп, ян-якка борылабыз; өндәү III баганада; 1,5 тонга күтәрелү – “до-до-ре#”.

9) 9х1, 9х2...; ятып; аякларны кинәт күтәрәбез; иснибез; төшергәндә – тапкырлау; соклану; III баганада 2 тонга күтәрелү – “до-до-ми”.

10) 10х1, 10х2...; аркага ятабыз, I баганада янга әйләнәбез; II баганада тезне бөгеп аякларны эчкә терибез; пауза -аякларны сузабыз; III баганада кире аркага ятабыз; өндәү-чакыру; кварта – “до-до-фа”.

11) 10х1, 10х2...; аркага ятып, тулысынча әйләнәбез; арпеджио: 10х1 була 10: ”до-ми-соль-до”; “до-соль-ми-до”.

12) 10х1, 10х2…; тулысынча әйләнеп чыгабыз; академик гамма буенча күтәрелү-төшү; чиратлаштырып: “до-ре-ми-фа-соль-ля-си-до”: әгәр 10 ны тапкырласак бергә нәтиҗәдә килеп чыга 10; “до-си-ля-соль-фа-ми-ре-до”: әгәр 10 ны тапкырласак икегә нәтиҗәдә килеп чыга 20 һәм шулай дәвам итәбез.

2. «Тапкырлау таблицасы» II вариант

1) 1х1, 1х2...; һәр баганада тезне чүгеп; III баганада чүгәләгән килеш калабыз; нокта беренче баганада – “си” кече октава.

2) 2х1, 2х2...; һәр баганада тезне чүгеп; III баганада баскан килеш калабыз; нокта икенче баганада – “до-си” кече октава.

3) 3х1, 3х2...; һәр баганада сикереп; III баганада чүгәләгән килеш калабыз; нокта өченче баганада – “до-до-си” кече октава.

4) 4х1, 4х2...; һәр баганада сикереп; III баганада баскан килеш калабыз; сорау; III баганада ярты тонга күтәрелү -“до-до-до#”.

5) 5х1, 5х2...; һәр баганада сикереп; нәтиҗәне әйткәндә аякны алга ыргытып; гаҗәпләнеп сорау; III баганада 1 тонга күтәрелү – “до-до-ре”.

6) 6х1, 6х2...; һәр баганада як-якка сикереп; өндәү I баганада; 1,5 тонга күтәрелү – “до-ре#-до-до”.

7) 7х1, 7х2…; һәр баганада биеп; нәтиҗәне әйткәндә аякны артка борылып ыргытып; өндәү II баганада; 1,5 тонга күтәрелү – “до-ре#-ре#”.

8) 8х1, 8х2...; һәр баганада биеп; нәтиҗәне әйткәндә аякны алга чөеп; өндәү III баганада; 1,5 тонга күтәрелү – ”до-до-ре#”.

9) 9х1, 9х2...; һәр баганада сикереп; нәтиҗәне әйткәндә сикереп куллар белән тубыкларга бәрәбез; соклану; III баганада 2 тонга күтәрелү – “до-до-ми”.

10) 10х1, 10х2...; һәр баганада сикереп, нәтиҗәне аякка баскач әйтәбез; өндәү-чакыру; кварта – “до-до-фа”.

11) 11x1, 11x2...; һәр баганада сикереп; нәтиҗәне кулларны аяк очларына бәргәндә әйтәбез; арпеджио өскә: 11x1 була 11: “до-ми-соль-до”.

12) 12x1, 12x2...; һәр баганада сикереп; кулларны аяк очларына бәреп; нәтиҗәне аста әйтәбез; арпеджио аска: 12x1 була 12: “до-соль-ми-до”.

13) 13x1, 13x2...; басып торабыз; академик гамма буенча күтәрелү-төшү; чиратлаштырып: “до (беренче октава)-ре-ми-фа-соль-ля-си-до (икенче октава)”: әгәр 13 не тапкырласак бергә нәтиҗәдә килеп чыга 13; “до (икенче октава)-си-ля-соль-фа-ми-ре-до (беренче октава)”: әгәр 13 не тапкырласак икегә нәтиҗәдә килеп чыга 26 һәм шулай дәвам итәбез.

3. Мелодик диапазонны төрле озынлыктагы юллы шигъри әсәрләр белән күнектерү.

С. Рәмиев

ә) Уку

  Безне адәм иткән уку,
Адәмне алга илткән уку, (2 юлда да малайлар гына, ля# кече октава)
Илтеп күккә җиткән уку,
Уку, уку, уку. (2 юлда да си кече октава, кызлар кушыла)
  Юлымызны хак иткән уку,
Йөземезне ак иткән уку,
Үземезне баг иткән уку,
Уку, уку, уку. (4 юлда да до I октава)
  Раст, чын кеше эше уку,
Баг вә рәхәт җимеше уку,
Ачкан рәхәт ишеген уку,
Уку, уку, уку. (4 юлда да ре)
  Гакылга нур биргән уку,
Мөкатдәс уй биргән уку,
Су юкта су биргән уку,
Уку, уку, уку. (4 юлда да ми)

Дәүләт, бәхет биргән уку,
Мөлек, тәхет биргән уку,
Безгә кирәк илла уку,
Уку, уку, уку. (4 юлда да фа)
Урысча да уку, уку,
Кытайча да уку, уку,
Кемчә генә дә уку, уку,
Уку, уку, уку. (4 юлда да соль)
Ирләргә дә фарыз уку,
Кызларга да фарыз уку, (2 юлда да ля)
Фарыз эшнең барысы уку,
Уку, уку, уку. (2 юлда да кызлар гына си)

1. Озын юллы шигъри текст белән өч регистрда да иркен яңгырауны күнектерү (җырлап һәм сөйләп):

Г.Тукай

**Шүрәле** (өзек)
Нәкъ Казан артында бардыр бер авыл – Кырлай диләр;
Җырлаганда көй өчен «тавыклары җырлай» диләр.
Гәрчә анда тугъмасам да, мин бераз торган идем,
Җирне әз-мәз тырмалап, чәчкән идем, урган идем.
(4 юлда да малайлар гына, “ля#” кече октава)
Ул авылның, – һич онытмыйм, – һәр ягы урман иде,
Ул болын, яшел үләннәр хәтфәдән юрган иде.
Зурмы? дисәң, зур түгелдер, бу авыл бик кечкенә,
Халкының эчкән суы бик кечкенә – инеш кенә.
(4 юлда да, “си” кече октава, кызлар кушыла)
Анда бик салкын вә бик эссе түгел, урта һава,
Җил дә вактында исеп, яңгыр да вактында ява.

Урманында кып-кызыл кура җиләк тә җир җиләк;
Күз ачып йомганчы, һичшиксез, җыярсың бер чиләк.
(4 юлда да, “до” I октава)
Бик хозур! рәт-рәт тора, гаскәр кеби, чыршы, нарат;
Төпләрендә ятканым бар, хәл җыеп, күккә карап.
Юкә, каеннар төбендә кузгалаклар, гөмбәләр
Берлә бергә үсә аллы-гөлле гөлләр, гонҗәләр.
(4 юлда да, “ре”)
Ак, кызыл, ал, сап-сары, зәңгәр, яшелдән чәчкәләр;
Һәр тарафка тәмле исләр чәчкәли бу чәчкәләр.
Үпкәлиләр чәчкәләрне төрле төсле күбәләкләр килеп,
киткән булып, тагын да шунда чүгәләп.
(4 юлда да, “ми”)
Бервакыт чук-чук итеп, сайрый ходайның кошлары;
Китә җаннарны кисеп, ярып садаи хушлары.
(2 юлда да, “фа”)
Монда бульварлар, клуб һәм танцевальня, цирк та шул;
Монда оркестр, театрлар да шул, концерт та шул.
(2 юлда да, “соль”)
Зур бу урман: читләре күренмидер, диңгез кеби,
Бинипһая, бихисаптыр, гаскәри Чыңгыз кеби.
(2 юлда да, “ля”)
Кылт итеп искә төшәдер намнары, дәүләтләре
Карт бабайларның, моны күрсәң, бөтен саулэтләре.
(2 юлда да, кызлар гына “си”)
Ачыла алдыңда тарихтан театр пәрдәсе:
Аһ! дисең, без ник болай соң? без дә хакның бәндәсе.
(2 юлда да, “до” II октава)

2. Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» текстыннан өзек белән тавыш күнегүләре.

Кол Гали "Кыйссаи Йосыф".

Хатимә.

Йосыф сәүче кыйссасын мин сөйләп бирдем, – "соль" – кече октава *(егетләр генә)*

Гарәпчә, фарсыдагыча бәян иттем, – "соль #"

Уку-тыңлау өчен булсын ансат, дидем,- – "ля"

Укыганнар хәер-дога кылсын имди. – "ля #" *(кызлар кушыла)*

Бу кыйссаны укыр гакълы булган кеше, – "си"

Тыңлаучының күңле эрер, агар яше, – "до" – беренче октава

Юкка чыгар гөнаһларының һәммәсе,- – "до #"

Рәхман аңа рәхим-шәфкать кылыр имди. -"ре"

Укыганнар, тыңлаганнар дога кылыр, -"соль" *(кызлар гына)*

Бу зәгыйфь кол дога тели, Халикъ белер,- – "соль #"

Дога белән гөнаһлылар ярлыканыр, -"ля"

Ярлыкауга ул лаеклы булыр имди. -"ля #"

Гәүһәр – таш ул, ләкин һәр таш гәүһәр булмас, -"си" *(укучыларның мөмкинчелегенә карап)*

Тикмә кеше гәүһәр кадрен аңлый алмас, -"до" – икенче октава

Бу нәзымның кадерен һич ахмак белмәс,- -"си" – беренче октава

Гакыллылар тыңлар, аңлар, белер имди. -"ля #"

Исме Гали моны язган зәгыйфь колның, -"ля"

Егерме дүрт иҗек белән төзде юлын, -" соль #" *(егетләр кушыла)*

Ярлыка, йа Рәхман, мин гөнаһлы колың, -"соль"

Рәхмәтеңнән өлеш өмет итәм имди. -"фа #"

Ходавәндә, бар хаҗәтем сиңа мәгълүм, -"фа"

Мин зарлының мөнаҗәте сиңа мәгълүм, -“ми”

Мин колыңны рәхмәтеңнән кылма мәхрүм,- -“ре #”

Соң сулышта иман бүләк кыл син имди. -“ре”

Мәүлям биргән уңыш, ярдәм аркасында, -“до #”

Изге, бөек рәҗәп ае утызында, -“до”

Тарих елның алты йөз дә тугызында -“си” – кече октава

Бу зәгыйфь кол бу китапны төзде имди. -“ля #”

Ярдәм, уңыш, фәһем, куәт Хактан алдым, -“ ля” *(егетләр генә)*

Илһам бүләк иткәненә шөкер кылдым, -“соль #”

Галим кеше бу нәзымны сөйләп бирсә, – “ре #”

Гакыллылар колак салып тыңлап торса, -“ми”

Шул икәү мин гөнаһлыга дога кылса, -“фа”

Бу доганы тәңре кабул кылыр имди. -“фа #”

Бу вакытта китабымны тәмамладым, -“соль” *(укучыларның мөмкинегенә карап)*

Сезгә, безгә ул файдалы булсын имди. -“соль” *(укучыларның мөмкинлегенә карап)*

-Хроматик гамма буенча, юллап, җырлап тавышны күтәрү – төшерү.

Хроматик гамма буенча, юллап, сөйләп, тавышны күтәрү – төшерү.

Хроматик гамма буенча, юллап, бер югарылыкта җырлап – сөйләп тавышны күтәрү – төшерү.

Хроматик гамма буенча юллап җыр белән сөйләмне чиратлаштырып тавышны күтәрү – төшерү.

Хроматик гамма буенча, сүзләп, сөйләп, тавышны күтәрү – төшерү.

6. Ш.Галиевның «Көпчәкләр ни сөйлиләр» шигырен академик гамма буенча юллап (сүзләп) күтәрелеп-төшеп күнектерегез.

Биек тауга менеп бара бер атлы, *(малайлар гына: соль – кече октава)*

Көпчәкләр сөйрәлә бер-бер артлы, *(ля)*

Көпчәкләр әйләнә шыгыр-шыгыр: *(до – беренче октава)*

Ай ла, *(си – до)*

ай ла... (ре – ми)

Тап син дегет, майла... *(ми – фа)*

Җайла, егет, *(фа)*

җайла. (фа – соль)

Майла... (соль – ля)

Маайлаа... (кызлар: си – до – икенче октава)

Биек (до – икенче октава)

таудан *(си)*

төшеп *(ля)*

бара *(соль)*

шул *(фа)*

атлы, *(ми)*

Көпчәкләр *(ре)*

чабалар (до – беренче октава)

бер-бер (си – кече октава)

артлы: (ля – кече октава)

- Май – *(си)*

ла – *(ля)*

ма – *(соль)*

саң *(фа)*

май – *(ми)*

ла – *(ре)*

ма, *(до)*

Җай – *(соль)*

ла – *(фа)*

ма – *(ми)*

саң *(ре)*

җай – *(до)*

ла – (си – кече октава)

ма!!! *(ля – кече октава)*

7. Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» текстыннан өзекләрне хәрәкәттә, төрле мелодик һәм ритмик рәсемдә күнектерү (татар халык көйләренә салып җырлыйбыз).

8. Тавыш куәте белән игътибарны яулау күнегүе. Әлеге күнегүдә мәгълүматкача өсти-өсти фразаларны ялгап, эзлекле яңгырату, тәкъдим ителгән нияттән чыгып, соңгы мәгълүматча тавышның куәтен үстерә бару, зур тексттагы соңгы авазны анык көчле яңгырату – перспективага омтылу максатлары куела. Алдагы фразаны шул ук тонда, шул ук ритм белән күршедә торган укучы эләктереп янәшәсендәге укучыга тапшырырга тиеш. Мәсәлән, «Ана куянның ала атасын…» тизәйткечендәге вакыйгаларны сөйлибез. Максатлар: мәгълүматны аңлата барабыз, шарт куя-куя, нәтиҗәсен сөйләп хыялланабыз, инкарь итәбез, гади генә хәбәргә күчеп (зар-интизар килмичә), йомгаклап куябыз. Тавышыбызны салмак темптан, түбән тоннан башлап, тонны күтәрә, ритмы һәм тизлеген, көчен куәтләндерә барып, соңыннан акрынлап киметәбез. Тик соңгы фраза анык яңгырый. Әлеге күнегүне күләмле шигъри текст белән дәвам итәбез:

“Идегәй” дастаныннан өзек

- Идегәй би, дустым, ай!

(югары регистрда, тагын урта регистрда кабатлыйбыз)

Ханың – ияң чакырадыр,

Борылып Идел кичсәнә!

(алдагы 2 юл югары регистрда)

Кайтсана, Идегәй, кайтсана!

Каерылып атың башын тартсана!

(алдагы 2 юл урта регистрда)

Кайтып өең тапсана!

Иңсәсе биек Бүз Урдага

Иңкәеп сәлам бирсәнә!

(алдагы 3 юл түбән регистрда)

Туктамыштай ханияң

Сиңа үпкә кыладыр,

Үпкә булган сүзеңне

Үз аузыңнан әйтсәнә!

Кил, Идегәй, дусым, әй,

Безнең белән кайтсана!

Кайтсана, Идегәй, кайтсана!

Каерылып атың башын тартсана!

(8 юл буе тавыш тонын күтәрәбез)

Алганың Ал Гомәр ханның кызы иде,

Айтулының үзе иде;

Сагыныр да, саргаер,

Утырып калып картаер,

Салкын төшмәй барсана,

Кайтсана, Идегәй, кайтсана,

Ил дигәнең белсәнә!

(алдагы юлларда тавыш тоны түбәнәя бара)

## Тыныш билгеләренә бәйле рәвештә аһәң төзелмәләрен күнектерү схемалары

Текстта аһәң мәгънәсен ачыклауда тыныш билгеләренә аерата игътибарлы булу сорала.

Шартлы билгеләр: ↗ – тавыш тоны күтәрелү; ↘ – тавыш тоны төшү; | – пауза; — – мәгънәви әһәмиятле өлеш (мәгънәви басымлы сүз яки сүзтезмә); --- – тавыш тонының вариантлыгы; (?) , (!) – фразаның төрле тыныш билгеләренә тәмамлану ихтималы.

урта тон



<u>и</u> – ы – э – ә – а – о – ө – у – ү.

урта тон 

и – ы – э – | <u>ә</u> – а – о – ө – у – ү.

урта тон 

и – ы – э – ә – а – о – ө – у – | <u>ү.</u>

Төгәлләнгән хәбәрле (нокталы) төзелмәләрдә әһәмиятле сүзнең сүз басымлы иҗегендә тавыш түбәнәюе ярты тонга тигезләнә. Әһәмиятле сүз төгәлләнгән фикерле интонема, бигрәк тә, абзац ахырына туры килгәндә, тавыш төшү тулы тонга якынлаша, артып та китүе мөмкин.

урта тон 

<u>и</u> – ы – э – ә – а – о – ө – у – ү ?

урта тон 

и – ы – э – ә – | <u>а</u> – о – ө – у – ү ?

урта тон 

и – ы – э – ә – а – о – ө – у – | <u>ү</u> ?

Сорау аһәңле төзелмәләрдә әһәмиятле сүзнең сүз басымлы иҗегендә тон күтәрелүе якынча тулы тонга тигез.

урта тон 

<u>и</u> – ы – э – ә – а – о – ө – у – ү !

урта тон 

и – ы – э – ә – | <u>а</u> – о – ө – у – ү !

урта тон 

и – ы – э – ә – а – о – ө – | <u>у</u> – ү !

Өндәү аһәңле төзелмәләрдә әһәмиятле сүзнең сүз басымлы иҗегендә тавыш якынча бер ярым тонга күтәрелә.

Сорау һәм өндәү аһәңле төзелмәләрнең әһәмиятле өлеше фраза ахрында килгән очракта бу сүзгә яки сүзтезмәгә омтылыш тизләтелгән темпта уза.

урта тон 

и ы э – | ә а о ө у ү . (?), (!).

Бер төшенчәне икенчесе белән тәңгәлләштерүле, аңлатмалы, ачыклаулы интонемалар сызык (тире) билгесе белән бирелгәндә, тавыш тоны никадәр күтәрелсә, шул ук югарылык дәрәҗәсендә төшә дә.

урта тон 

и ы э ә : | а о ө у ү . (!)

Ике нокталы төзелмәләрдә тавыш тоны күтәрелү һәм төшү дәрәҗәсе тон югарылыгы ягыннан төрлечә булырга мөмкин, тик ике ноктадагы пауза сызык паузасыннан дәвамлырак.

урта тон 

и , | ы э ә , | а о , | ө , | у , | ү;

Өтер, нокталы өтер, күп очракта, санау аһәңле (тавыш күтәрелү-төшү бер дәрәҗәдә), шулай ук, интонацион баскыч (интонацион градация – тавыш тоны яңа әһәмиятле сүздә гел күтәрелә яки төшә бара) белән белдерелергә мөмкин. Һәр әһәмиятле сүз яки сүзтезмәдә тавыш тоны күтәрелеп кала.

урта тон 

и – ы – э – ә – | а – о – ө – у – ү . . .

Күпнокталы төзелмәләрдә пауза төрле дәвамлылыкта. Тавыш, тәмамланмаган интонемадагы кебек, якынча ярты тонга күтәрелгән килеш, «асылынып» кала.




Җәяләр эчендә сүзләр, сүзтезмәләр пауза һәм урта тоннан түбәнрәк тавыш белән яңгырыйлар. Җәяләр эчендә җөмләләр туры килгәндә, бераз тавыш күтәрелү була. Тик бу күтәрелү җәя алдындагы тоннан югарырак (тавыш тоны күтәрелгән вакытта – түбәнрәк) була алмый.




Куштырнаклы төзелмә паузалар, тавышның югары яки түбән яңгыравы, әдипнең «тел төбен», мөнәсәбәтен ачыклый торган тавыш төсмере белән яңгырый.

Тыныш билгеләренең яңгырауда төп вазифаларын белү һәм күнектерү мәгълуматны үзләштерүне тизләтә, сөйләм кануннарына төшенүне күпкә җиңеләйтә, аһәң камиллегенә алып килә.

## Дикция күнегүләре

### Сузык авазларны күнектерү

I вариант

Сузык авазларны өчәр мәртәбә кычкырып, акрын, шыпырт, бөтенләй тавышсыз кабатлыйбыз:

*1) А — о — у — ы — ый.*

*2) Ә—ө—ү—э—и.*

*3) А—ә, о—ө, у—ү, ы—э, ый—и.*

*4) А — а, а — о, а — о — у, а — о — у — ы, а — о — у — ы — ый.*

*5) Ә—ә, ә—ө, ә—ө—ү, ә—ө—ү—э, ә—ө—ү—э—и.*

*6) А—а, о—а, у—а, ы—а, ый—а.*

*7) Ә—а, ө—а, ү—а, э—а, и—а.*

*8) А—а, а—о, а—у, а—ы, а—ый.*

*9) А—ә, а—ө, а—ү, а—э, а—и.*

*10) А—а—а, а—о—а, а—у—а, а—ы—а, а—ый—а.*

*11) А—ә—а, а—ө—а, а—ү—а, а—э—а, а—и—а.*

II вариант

Сузык авазлар рәтен иренләштерү закончалыгы буенча тезәбез:

1) *Ый—ы—а— о—у.*
2) *И —э—ә—ө—ү.*
3) *Ый—и, ы—э, а—ә, о—ө, у—ү.*
4) *Ый—ый, ый—ы, ый—ы—а, ый—ы—а—о, ый—ы—а— о—у.*
5) *И —и, и —э, и —э—ә, и—э—ә—ө, и —э—ә—ө—ү.*
6) *Ый—а, ы—а, а—а, о—а, у—а.*
7) *И —а, э—а, ә—а, ө—а, ү—а.*
8) *А—ый, а—ы, а—а, а—о, а—у.*
9) *А —и, а—э, а—ә, а—ө, а—ү.*
10) *А—ый—а, а—ы—а, а—а—а, а—о—а, а— у—а.*
11) *А—и—а, а—э—а, а—ә—а, а—ө—а, а—ү —а.*

III вариант

Сузык авазлар рәтен иренләштерү закончалыгына каршы килеп тезәбез:

1) *У—о—а—ы—ый.*
2) *Ү—ө—ә—э—и.*
3) *У—ү, о—ө, а—ә, ы—э, ый—и.*
4) *У —у, у—о, у—о—а, у—о—а—ы, у—о—а—ы—ый.*

*5) Ү—ү, ү—ө, ү—ө—ә, ү—ө—ә—э, ү—ө—ә—э—и.*

*6) У—а, о—а, а—а, ы—а, ый—а.*

*7) Ү—а, ө—а, ә—а, э—а, и—а.*

*8) А—у, а—о, а—а, а—ы, а—ый.*

*9) А—ү, а—ө, а—ә, а—э, а—и.*

*10) А—у—а, а—о—а, а—а—а, а—ы—а, а—ый—а.*

*11) А—ү—а, а—ө—а, а—ә—а, а—э—а, а—и—а.*

**Тартык авазларга күнегүләр**

***Б, П*** **шартлаулы тартык авазларга күнегүләр**

1) Ба-бо-бу-бы-бый;

2) Бә-бө-бү-бе-би;

3) Аб-об-уб-ыб-ыйб;

4) Әб-өб-үб-эб-иб;

5) Ба-ба-баб; бо-бо-боб; бу-бу-буб; бы-бы-быб; бый-бый-быйб;

6) Бә-бә-бәб; бө-бө-бөб; бү-бү-бүб; бе-бе-беб; би-би-биб;

7) Па-по-пу-пы-пый;

8) Пә-пө-пү-пе-пи;

9) Пап-поп-пуп-пып-пыйп

10) Пәп-пөп-пүп-пеп-пип;

11) Ба-па-пап-баб; бо-по-поп-боб; бу-пу-пуп-буб; бы-пы-пып-быб; бый-пый-пыйп-быйб;

12) Бә-пә-пәп-бәб; бө-пө-пөп-бөб; бү-пү-пүп-бүб; бе-пе-пеп-беб; би-пи-пип-биб.

***Г, К* шартлаулы тартык авазларга күнегүләр**

1) Гый-гы-га-го-гу;

2) Ги-ге-гә-гө-гү;

3) Кый-кы-ка-ко-ку;

4) Ки-ке-кә-кө-кү;

5) Гыйккый-гыккы-гакка-гокко-гукку;

6) Гикки-гекке-гәккә-гөккә-гүккү;

7) Кыйггый-кыггы-кагга-когго-куггу;

8) Кигги-кегге-кәггә-көггә-күггә;

9) Гыйкыйкый-гыкыкы-гакака-гококо-гукуку;

10) Гикики-гекеке-гәкәкә-гөкөкө-гүкүкү;

11) Кыйгыйгый-кыгыгы-кагага-когого-кугугу;

12) Кигиги-кегеге-кәгәгә-көгөгө-күгүгү;

13) Кыйгыйгыйкыйк-кыгыгыкык-кагагакак-когогокок-кугугукук;

14) Кигигикик-кегегекек-кәгәгәкәк-көгөгөкөк-күгүгүкүк.

***Гъ, Къ* шартлаулы тартык авазларга күнегүләр**

1) Гъу-гъо-гъа-гъы-гъый;

2) Гъү-гъө-гъә-гъе-гъи;

3) Къу-къо-къа-къы-къый;

4) Къү-къө-къә-къе-къи;

5) Гъукъукъу-гъокъокъо-гъакъакъа-гъыкъыкъы-гъыйкъыйкъый;

6) Гъүкъүкъү-гъөкъөкъө-гъәкъәкъә-гъекъекъе-гъикъикъи;

7) Къугъугъу-къогъогъо-къагъаъга-къыгъыгъы-къыйгъыйгъый;

8) Къүгъүгъү-къөгъөгъө-къәгъәгъә-къегъегъе-къигъигъи;

9) Гъукъукъугъ-гъокъокъогъ-гъакъакъагъ-гъыкъыкъыгъ-гъыйкъыйкъыйгъ;

10) Гъүкъүкъүгъ-гъөкъөкъөгъ-гъәкъәкъәгъ-гъекъекъегъ-гъикъикъигъ;

11)Къугъугъукъ-къогъогъокъ-къагъагъакъ-къыгъыгъыкъ-къыйгъыйгъыйкъ;

12) Къүгъүгъүкъ-къөгъөгъөкъ-къәгъәгъәкъ-къегъегъекъ-къигъигъикъ;

13) Угъ-огъ-агъ-ыгъ-ыйгъ;

14) Үгь-өгь-әгь-эгъ-игъ;

15) Укъ-окъ-акъ-ыкъ-ыйкъ;

16) Үкъ-өкъ-әкъ-экъ-икъ;

17) Угъукъ-огъокъ-агъакъ-ыгъыкъ-ыйгъыйкъ;

18) Үгъүкъ-өгъөкъ-әгъәкъ-эгъэкъ-игъикъ.

***Д, Т* шартлаулы тартык авазларга күнегүләр**

1) Ду-да-до-ды-дый;

2) Дү-дә-дө-де-ди;

3) Ту-та-то-ты-тый;

4) Тү-тә-тө-те-ти;

5) Ут-ат-от-ыт-ыйт;

6) Үт-әт-өт-эт-ит;

7) Дутту-датта-дотто-дытты-дыйттый;

8) Дүттү-дәттә-дөттө-детте-дитти;

9) Тудду-тадда-тоддо-тыдды-тыйддый;

10) Түддү-тәддә-төддө-тедде-тидди;

11) Дутуту-датата-дотото-дытыты-дыйтыйтый;

12) Дүтүтү-дәтәтә-дөтөтө-детете-дитити;

13) Дутутутду-датататда-дотототдо-дытытытды-дыйтыйтытдый;

14) Дүтүтүтдү-дәтәтәтдә-дөтөтөтдө-детететде-дитититди.

**Шартлаулы тартык авазларга катлаулы дикция күнегүләре**

**1)**Быйпыйвыйфыйwыйф-быпывыфыwыф-бапавафаwаф-боповофоwоф-бупувуфуwуф;

**2)**Бипивифиwиф-бепевефеwеф-бәпәвәфәwәф-бөпөвөфөwөф-бүпүвүфүwүф;

**3)**Тыйдыйкыйгыйвыйфыйкыйл-тыдыкыгывыфыкыл-тадакагавафакал-тодокоговофокол-тудукугувуфукул;

**4)**Тидикигивификил-тедекегевефекел-тәдәкәгәвәфәкәл-төдөкөгөвөфөкөл-түдүкүгүвүфүкүл;

**5)**Кыйккыйкыйгый-кыккыкыгы-каккакага-коккокого-куккукугу;

**6)**Киккикиги-кеккекеге-кәккәкәгә-көккөкөгө-күккүкүгү;

**7)**Гъбдый-гъбды-гъбда-гъбдо-гъбду;

**8)**Гъбди-гъбде-гъбдә-гъбдө-гъбдү;

**9)**Къптый-къпты-къпта-къпто-къпту;

**10)**Къпти-къпте-къптә-къптө-къптү;

***Л, Р, М, Н, Ң, W*** **сонор тартык авазларга күнегүләр**

1) Ла-ло-лу-лы-лый;

2) Лә-лө-лү-ле-ли;

3) Лал-лол-лул-лыл-лыйл;

4) Ләл-лөл-лүл-лел-лил;

5) Лала-лоло-лулу-лылы-лыйлый;

6) Ләлә-лөлө-лүлү-леле-лили;

7) Ал-ол-ул-ыл-ыйл;

8) Әл-өл-үл-эл-ил;

9) Урр-орр-арр-ырр-ыйрр;

10) Үрр-өрр-әрр-эрр-ирр;

11) Ру-ор-ар-ыр-ыйр;

12) Рү-рө-рә-ры-рый;

13) Рур-рор-рар-рыр-рыйр;

14) Рүр-рөр-рәр-рер-рир;

15) Рурур-ророр-рарар-рырыр-рыйрыйр;

16) Рүрүр-рөрөр-рәрәр-ререр-ририр;

17) Тру-тро-тра-тры-трый;

18) Трү-трө-трә-тре-три;

19) Трудру-тродро-традра-трыдры-трыйдрый;

20) Трүдрү-трөдрө-трәдрә-тредре-тридри;

21)Трурурурурур-троророророр-трарарарарар-трырырырырыр-трыйрыйрыйрыйрыйр;

22)Трүрүрүрүрүр-трөрөрөрөрөр-трәрәрәрәрәр-треререререр-трирриририр;

23) Ма-мо-му-мы-мый;

24) Мә-мө-мү-ме-ми;

25) Ам-ом-ум-ым-ыйм;

26) Әм-өм-үм-эм-им;

27) Мала-моло-мулу-мылы-мыйлый;

28) Мәлә-мөлө-мүлү-меле-мили;

29) Лмамла-лмомло-лмумлу-лмымлы-лмыймлый;

30) Лмәмлә-лмөмлө-лмүмлү-лмемле-лмимли;

31) Млалма-млолмо-млулму-млылмы-млыйлмый;

32) Мләлмә-млөлмө-млүлмү-млелме-млилми;

33) Мам-мом-мум-мым-мыйм;

34) Мәм-мөм-мүм-мем-мим;

35) Ну-но-на-ны-ный;

36) Нү-нө-нә-не-ни;

37) Ун-он-ан-ын-ыйн;

38) Үн-өн-ән-эн-ин;

39) Унну-онно-анна-ынны-ыйнный;

40) Үннү-өннү-әннә-энне-инни;

41) Мнумну-мномно-мнамна-мнымны-мныймный;

42) Мнүмнү-мнөмнө-мнәмнә-мнемне-мнимни;

43) Нунунунну-нонононно-нанананна-нынынынны-ныйныйныйнный;

44) Нүнүнүнну-нөнөнөннө-нәнәнәннә-нененение-нинининни;

45) Аң-оң-уң-ың-ыйң;

46) Әң-өң-үң-эң-иң;

47) Аңна-оңно-уңну-ыңны-ыйңный;

48) Әңнә-өңнө-үңнү-эңне-иңни;

49) Мнаңма-мноңмо-мнуңму-мныңмы-мныйңмый;

50) Мнәңмә-мнөңмө-мнүңмү-мнеңме-мниңми;

51) Wу-wo-wa-wы-wый;

52) Wү-wө-wә-we-wи;

53) Wул-wол-wал-wыл-wыйл;

54) Wүл-wөл-wәл-wел-wил;

55) Wуң-wоң-wаң-wың-wыйң;

56) Wүң-wөң-wәң-wең-wиң;

57) Wуффу-wоффо-wаффа-wыффы-wыйффый;

58) Wүффү-wөффө-wәффә-wеффе-wиффи.

**Л, Р сонорларына өстәмә күнегүләр**

Л

**1)**Трлу-трло-трла-трлы-трлый;

**2)**Трлү-трлө-трлә-трле-трли;

**3)**Трлул-трлол-трлал-трлыл-трлыйл;

**4)**Трлүл-трлөл-трләл-трлел-трлил;

**5)**Луллу-лолло-лалла-лыллы-лыйллый;

**6)**Лүллү-лөллө-ләллә-лелле-лилли;

**Р**

1)РРР

2)Ыйр-ыр-ар-ор-ур;

3)Ир-эр-әр-өр-үр;

4)Рый-ры-ра-ро-ру;

5)Ри-ре-рә-рө-рү;

6)Рыйрыйр-рырыр-рарар-ророр-руруp;

7)Ририр-ререр-рәрәр-рөрөр-рүрүр;

8)Трыйдрый-трыдры-традра-тродро-трудру;

9)Тридри-тредре-трәдрә-трөдрө-трүдрү;

10)Трыйрыйрыйрыйрыйр-трырырырырыр-трарарарарар-троророророр-трурурурурур;

11)Триририририр-треререререр-трәрәрәрәрәр-трөрөрөрөрөр-трүрүрүрүрүр;

## С-З, Ш-Ж, Ч-Ж, В-Ф, Х, Һ шаулы-өрелмәле тартык авазларга дикция күнегүләре

**С-З**

**1)**Зый-зы-за-зо-зу;

**2)**Зи-зе-зә-зө-зү;

**3)**Сый-сы-са-со-су;

**4)**Си-се-сә-сө-сү;

**5)**Сыйзый-сызы-саза-созо-сузу;

**6)**Сизи-сезе-сәзә-сөзө-сүзү;

**7)**Сыйсыйз-сысыз-сасаз-сосоз-сусуз;

**8)**Сисиз-сесез-сәсәз-сөсөз-сүсүз;

**9)**Ыйз-ыз-аз-оз-уз;

**10)**Из-эз-әз-өз-үз;

**11)**Ыйс-ыс-ас-ос-ус;

**12)**Ис-эс-әс-өс-үс;

**13)**Ыйскый-ыскы-аска-оско-уску;

**14)**Иски-эске-әскә-өскө-үскү;

**15)**Ыйзгый-ызгы-азга-озго-узгу;

**16)**Изги-эзге-әзгә-өзгө-үзгү;

**17)**Ыйзгыйскый-ызгыскы-азгаска-озгоско-узгуску;

**18)**Изгиски-эзгеске-әзгәскә-өзгөскө-үзгүскү;

**Ш-Ж**

**1)**Шу-шо-ша-шы-шый;

**2)**Шү-шө-шә-ше-ши;

**3)**Уш-ош-аш-ыш-ыйш;

**4)**Үш-өш-әш-еш-иш;

**5)**Уж-ож-аж-ыж-ыйж;

**6)**Үж-өж-әж-эж-иж;

**7)**Жушушуш-жошошош-жашашаш-жышышыш-жыйшыйшыйш;

**8)**Жүшүшүш-жөшөшөш-жәшәшәш-жешешеш-жишишиш;

**Ч-Җ**

**1)**Чый-чы-ча-чо-чу;

**2)**Чи-че-чә-чө-чү;

**3)**Җый-җы-җа-җо-җу;

**4)**Җи-җе-җә-җө-җү;

**5)**Ыйҗыйч-ыҗыч-аҗач-оҗоч-уҗуч;

**6)**Иҗич-эҗеч-әҗәч-өҗөч-үҗүч;

**7)**Шыйч-шыч-шач-шоч-шуч;

**8)**Шич-шеч-шәч-шөч-шүч;

**9)**Җыйз-җыз-җаз-җоз-җуз;

**10)**Җиз-җез-җәз-җөз-җүз;

**11)**Чыйҗый-чыҗы-чаҗа-чоҗо-чуҗу;

**12)**Чиҗи-чеҗе-чәҗә-чөҗө-чөҗө;

**Х**

**1)**Ха-хо-ху-хы-хый;

**2)**Хә-хө-хү-хе-хи;

**3)**Ахх-охх-ухх-ыхх-ыйхх;

**4)**Әхх-өхх-үхх-эхх-ихх;

**5)**Хакмат-хокмот-хукмут-хыкмыт-хыйкмыйт;

**6)**Хәкмәт-хөкмөт-хүкмүт-хекмет-хикмит;

**7)**Ахма-охмо-ухму-ыхмы-ыйхмый;

**8)**Әхмә-өхмө-үхмү-эхме-ихми;

**9)**Ахахаха-охохохо-ухухуху-ыхыхыхы-ыйхыйхыйхый;

**10)**Әхәхәхә-өхөхөхө-үхүхүхү-эхехехе-ихихихи;

**Һ**

**1)**Ыйһ-ыһ-аһ-оһ-уһ;

**2)**Иһ-эһ-әһ-өһ-үһ;

**3)**Һыйһыйһый-һыһыһы-һаһаһа-һоһоһо-һуһуһу;

**4)**Һиһиһи-һеһеһе-һәһәһә-һөһөһө-һүһүһү;

**В-Ф**

**1)**Фув-фов-фав-фыв-фыйв;

**2)**Фүв-фөв-фәв-фев-фив;

**3)**Уффув-оффов-аффав-ыффыв-ыйффыйв;

**4)**Үффүв-өффөв-әффәв-эффев-иффив;

**5)**Уф-фу-фув-ву; оф-фо-фов-во; аф-фа-фав-ва; ыф-фы-фыв-вы; ыйф-фый-фыйв-вый;

**6)**Үф-фү-фүв-вү; өф-фө-фөв-вө; әф-фә-фәв-вә; эф-фе-фев-ве; иф-фи-фив-ви;

## Текст тикшерүдә мәгънәви басым кануннары һәм кагыйдәләре

Һәркемгә сөйләм эшчәнлеге белән бәйле мәгънәви-грамматик канун һәм кагыйдәләрне белү зарур. “Риторика” курсын үзләштерү дәвамында студентлар текст белән күп эш башкаралар. Әлеге канун-кагыйдәләр текстның мәгънәсенә төшенүдә, фикер-карашны үтемле яңгыратуда нәтиҗәле эшчәнлекне тәэмин итәләр.

*1. Яңалык кануны.*

Аралашу барышында, кагыйдә буларак, ниндидер яңалык бәян ителә. Яңалык элек булган хәл белән тыгыз бәйләнештә була. Яңа төшенчә һәрвакыт мәгънәви басымлы.

Яңа шәхес, күренеш, урын атамасын, һичшиксез, басым белән аерымлыйбыз.

*2. Актуальләштерү кануны.*

Текстта элекке хәлнең, вакыйганың дәвамы – моңарчы хәбәр ителмәгән ягы – яңалык булып, актуальләшеп кабул ителә. Юлара мәгънә һәм яңа хәбәргә мөнәсәбәт, бәя белдерү төшенчәне актуальләштерү нигезенә салына. Кайбер очракларда текстта яңа төшенчәләр, исемнәр, атамалар бер-бер артлы киләләр, ә икенче бер текстта, кечкенә генә кисәктә бер үк төшенчә берничә тапкыр кабатлана. Икенче тапкыр һәм аннан соң да кабатланганда, элекке яңалык төшенчәсен басымлау, ә яңа исем, яки яңа фикерне басымсыз укып үтү ялгыш булыр иде.

Мәгънәви басым, әйтеп узганыбызча, контексттан аңлашылган әһәмиятле сүздә була. Шулай ук чыгыш ясаучы махсус игътибар юнәлтергә теләгән сүздә дә булырга мөмкин.

*3. Раслау кануны.*

Раслауларның гади очрагы – “әйе”, “дөрес”, “чыннан да” һ. б. модаль сүзләр белән белдерелә. Чыгыш ясаучы кемнеңдер фикерен яклаганда, ризалашканда, әңгәмәдәшенә ышаныч белдергәндә, нидер вәгъдә иткәндә, вакыйга-күренешне уңайяктан бәяләгәндә; башка чыгыш ясаучыларның фикерен яклап чыкканда яки алар белән компромисска барганда, килеп туган

ситуациядә кайбер шартларны үтәгәндә һ. б. очракларда “әйе” сүзен кулланып, сөйләмен әһәмиятлерәк яңгырата.

Көчле тәэсир көченә ия раслаулар, шулай ук риторик сорау яки риторик өндәү рәвешендәге раслаулар, гадәттә, мәгънәви басымга ия.

*4. Инкарь кануны.*

Сөйләмдә инкарь күп төрле формаларда белдерелергә (иң гадие: “юк”, “түгел” модаль сүзләре “-мый/-ми” юклык кисәкчәләре белән) мөмкин. Чыгыш ясаучы башка чыгыш ясаучылар белән ризалашмаганда, аларга ышанмаганда, шик белдергәндә; үзара фикер уртаклыгы булмаганда, диалогны алга таба дәвам итәсе килмәгәндә һ. б. очракларда “юк” сүзен куллана.

*5. Капма-каршы кую кануны.*

Каршы куелган төшенчәләр, вакыйгалар мәгънәви басымга ия булалар.

*6. Шарт һәм нәтиҗә, кире хәл һәм нәтиҗә кануны.*

- Шарт һәм нәтиҗә бәйләнәшендә, нәтиҗә басымлы. Фразаның шарт өлешендә тавыш күтәрелеп кала, нәтиҗә өлешендә тавыш төшүе була.
- Кире хәл һәм нәтиҗә бәйләнәшендә, нәтиҗә басымлы. Фразаның кире хәл өлешендә тавыш күтәрелеп кала, нәтиҗә өлешендә тавыш төшүе була.

*7. Чагыштырулар кагыйдәсе.*

Сөйләм дәвамында фикер сүзләрдән төшенчәгә, аннан нәтиҗәгә үсә. Хәбәр барышында төшенчә расланырга, кире кагылырга, башка төшенчәләр белән чагыштырылырга мөмкин. Гади һәм катлаулы чагыштырулар була.

- Гади чагыштыру булганда чагыша торган сүз көчле басымлы, чагыштырылучы сүз басым алмый.
- Катлаулы чагыштыруда чагыша һәм чагыштырыла торган сүзләр басымлы булалар. басым дәрәҗәсе дә бер үк була.

*8. Сыйфатлар кагыйдәсе.*

Сыйфатлар предметның, күренешнең бер гомум мәгънәсен яки төрле-төрле билгеләрен белдерәләр.

- Бер гомуми мәгънәдәге сыйфатлар мәгънәви басымны үзләренә алмыйлар.
- Шәхес, күренешне, предметны төрле-төрле яктан бәяләгән сыйфатлар мәгънәви басымга ия булалар.

*9. Рәвешләр кагыйдәсе.*

Эшнең, вакыйганың ничек, ни рәвешле үтүе сөйләмнең мәгънәсен ачыклап килә.

*10. Алмашлыклар кагыйдәсе.*

Күрсәтү, билгеләү, сорау, билгесезлек, юклык алмашлыкларының күбесе мәгънәви басым ала.

*11. Иялек килеш кагыйдәсе.*

Аерым фразада яки җөмләдә бер-берсе белән нык бәйләнгән ике исем янәшә килгәндә, гадәттә, иялек килешендәгесе мәгънәви басымлы, чөнки ул үзе аныклаган сүз белән иялек мөнәсәбәтендә.

*12. Көчәйткеч кисәкчәләр кагыйдәсе.*

Көчәйткеч, аныклагыч кисәкчәләр, мәгънәви басымның юлына киртә булып, күп очракта, аны үзләренә күчерәләр.

*13. Инверсия кагыйдәсе.*

Сөйләмдә көчле сәнгати чара, шулай ук, текст сүзләрен сөйләм тактларына туплауда өстәмә чара да буларак, инверсия – сүзләрнең кире тәртибе кулланыла. Инверсияле сүзтезмәләр үзенчәлеклерәк яңгырыйлар, тыңлаучының игътибарын һәрвакыт үзләренә тарталар. Алар “гадәти тәртиптәгегә караганда тагын да саллырак, тагын да тасвирлырак яңгырый, ...аерым пауза, интонация белән аерымланып бирелә”.

*14. Кабатлана торган сүзләр кагыйдәсе.*

- Сөйләмдә бер үк сүз кабатланганда, тел төбендә ниндидер теләк, өндәү, күтәренке рух булса, кабатланган сүзнең соңгысы көчлерәк басымлы була.
- Аралашуда тел төбендә сагыш, үкенеч, төшенкелек чагылса, кабатланган сүзнең беренчесе көчле басымлы була.

*15. Ныклы сүзтезмәләр кагыйдәсе.*

Фразеологик әйтемнәр, мәкальләр, канатлы сүзләр бер билгеләнгән мәгънәләре буенча әйтеләләр.

*16. Сүзтезмә атамалар кагыйдәсе.*

Сүзтезмә атамаларның соңгы сүзе көчлерәк басымлы була.

## Эчтәлек

**Кереш сүз ........................................................................ 3**
**I. Аралашу эчтәлеге ........................................................... 5**
Аралашуда катнашучылар ............................................ 6
Сөйләм мөнәсәбәтләренең төзелеше ............................ 7
Хәзерге сөйләм төзелеше үзенчәлекләре ...................... 9
Максатлы аралашуны оештыру .................................... 10
Көнкүреш сөйләменең максаты .................................... 12
Халык белән аралашуның максаты .............................. 13
Аралашу нәтиҗәләрен тикшерү, үзгәртү мәсьәләсе .... 14
Үзләштерелгән белемнәрне мөстәкыйль тикшерү өчен сораулар һәм биремнәр ................................................ 16
**II. Риторика. Дини риторика: тарихи күзәтү ......................... 17**
Риторика төшенчәсе ...................................................... 17
Риторик эшчәнлекнең төп кагыйдәләре ....................... 18
Риторика һәм хөтбә-вәгазьчелек бәйләнешләре .......... 19
Борынгы Грециядә риторика фәне ................................ 23
Софистлар .................................................................... 25
Риторика үсешендә Сократ һәм Платонның эшчәнлеге ................................................................... 27
Аристотельнең аралашу тәгълиматы ............................ 28
Борынгы Римда ораторлык сәнгате ............................... 29
Ораторика һәм гомилетика ............................................ 31
Россиядә аралашу гадәте һәм риторика ........................ 31
Татар халкында хөтбә-вәгазьләр тарихыннан ............... 34
Мөхәммәд галәйһиссәлам хәдисләре ............................ 58
Үзләштерелгән белемнәрне мөстәкыйль тикшерү өчен сораулар һәм биремнәр .......................... 65
**III. Чыгыш ясаучының шәхесе, образы .................................. 67**
Аралашучы образы һәм мәдәният ................................. 67
Сөйләм кырын оештыру өлешләре: этос, пафос һәм логос ........................................................... 68
Тыңлаучыларны чыгыш ясаучы карашларына җәлеп итү ........................................................................ 71
Аралашуның нигезе буларак оратор фикере, карашлары ........................................................ 73
Чыгышның кыскача чагылышы ..................................... 75
Танып белүне оештыруда оратор карашларының әһәмияте ................................................... 76
Оратор карашының шәхси-гамәли өлешләре ................ 78

Оештыруның гражданлык тибында оратор карашына кушылу ........................................................ 79
Оратор образы .......................................................................... 80
Ораторның чыгышка әзерлеге ....................................... 82
Оялчанлыкны җиңү мәсьәләсе һәм аралашуның нәтиҗәлеген арттыру ..................................................... 84
Аралашу мөмкинлекләре сыйфатында шәхес холык-фигылен (темпераментын) файдалану ............... 87
Ныклы холык-фигыль мөмкинлекләре .......................... 88
Үтә шәхсән психологик эчтәлекле мөмкинлекләр ............................................................... 89
Психологик җайланмаларның аралашуда әһәмияте ........................................................................... 91
Чыгыш текстын язуда акыл эшчәнлегенең әһәмияте ........................................................................... 93
Чыгыш оештыруда акыл эшчәнлегенә бәйле мөмкинлекләр ...................................................... 95
Ораторның үз йөзен булдыруда акыл мөмкинлекләре ................................................................ 96
Аралашу рәвешен оештыру мөмкинлекләре ................................................................ 97
Аудиториянең оратор шәхесенә, образына мөнәсәбәте ....................................................................... 99
Сөйләмнең күзгә ташланып торган элементлары ................................................................... 100
Чыгыш манерасы .......................................................... 101
Чыгыш ясауның иң отышлы манерасы .......................... 102
Ораторның аудиториядә урнашуы һәм хәрәкәтләнүе ...................................................................... 103
Караш ........................................................................... 103
Поза .............................................................................. 104
Ораторның ым-ишарәләре ............................................ 105
Ораторның аудиторияне тоемлавы ............................... 105
Ораторның тавышы һәм интонациясе .......................... 106
Үзләштерелгән белемнәрне мөстәкыйль тикшерү өчен сораулар һәм биремнәр ................................................... 108
**IV. Аралашу даирәсен оештыруның алым-чаралары .......... 111**
Аралашу оештыруда технологияләрнең әһәмияте ........ 111
Чыгыш темасын сайлау ................................................. 112
Сөйләм эчтәлеген төзүнең билгеле алымнары .............. 113
Сөйләм ниятен тәгаенләү ............................................... 115

Сөйләм оештыруда уйлап табуның әһәмияте ............... 116
Сөйләмдә дәлилләрнең урнашуы яки композиция ........ 118
Чыгыш текстын әзерләү, алдан кабатлау ....................... 121
Вәгазь тексты язу ......................................................... 123
Вәгазьне алдан кабатлау ................................................ 125
Нотык сөйләү ................................................................ 127
Дәлилләү, дәлилләү төрләре, алымнары ........................ 129
Дәлилләү төрләре .......................................................... 130
Дәлилләү алымнары ....................................................... 131
Индуктив һәм дедуктив дәлилләү ................................. 132
Кире кагулы һәм булышлык итә торган дәлилләр ......... 132
Дәлилләрнең эчтәлегенә бер караш .............................. 133
Коръәни-Кәримдәге риторик дәлилләр .......................... 135
Дәлилләрне нәтиҗәле куллануның кагыйдәләре һәм алымнары ......................................................................... 141
Үзләштерелгән белемнәрне мөстәкыйль тикшерү өчен сораулар һәм биремнәр ................................................. 145
**V. Сөйләм төрләре һәм аралашу рәвеше ................................ 149**
Нотык (монолог) сөйләме, төрләре ................................ 149
Нотык сөйләме төрләре .................................................. 150
Өндәмә (мәйдан) нотыклары .......................................... 152
Аралашуда хисси халәткә ирешү алымнары: хуплау, кече күңеллелек, ташлама ясау (хәтер саклау) ............. 153
Котлау сүзе ...................................................................... 157
Тәкъдим итү чыгышы ..................................................... 158
Хөкем чыгышлары .......................................................... 159
Нотык сөйләм алымнарына төшенү ............................... 160
Мәгълүматның кабул ителүе буенча тыңлаучылар төре ......................................................................................... 161
Нотыкны бәяләү мәсьәләсе ............................................ 162
Ораторның үз нотыгын тикшерүе .................................. 163
Нотыклы аралашуда сораулар ........................................ 164
Сорау төрләре ................................................................. 166
Аудитория сорауларына җавап ...................................... 167
Кара-каршы сөйләшү яки әңгәмә кору .......................... 167
Әңгәмә оешу нигезләре .................................................. 168
Әңгәмә оештыру кануннары һәм алымнары ................. 170
Әңгәмә-бәхәс (эристика) ................................................ 170
Бәхәскә диалектик караш ............................................... 171
Аралашуның софистик нигезе ....................................... 172
Әңгәмәнең тәэсирчәнлеген оештыру ысуллары ........... 173

Әңгәмәле аралашуга караш ............................................ 174
Дискуссия һәм полемика ................................................ 175
Фикер каршылыгын хәл итү ысулы буларак сөйләшүләр оештыру .................................................... 176
Сөйләшүләрнең төрләре һәм вазифалары .................... 177
Сөйләшүләр алып бару стратегияләре ......................... 178
Сөйләшүләрнең “отыш-югалту” төре ........................... 179
Сөйләшүләрдә “сатулашу” ............................................ 180
Кызыксыну даирәсен исәпкә алып үткәрелгән сөйләшүләр .................................................................. 180
Сөйләшүләрне оештыру баскычлары .......................... 181
Сөйләшүләрне алып баруга хәзерләнү ......................... 181
Сөйләшүләрне алып бару .............................................. 182
Килешүгә ирешү. Консенсус алымы ............................ 184
Консенсус алымы ........................................................... 185
Сөйләшүләрнең нәтиҗәлеген тикшерү, ирешелгән килешүне үтәү .............................................................. 185
Сөйләшүләрдә арадашлык итү модельләре .................. 186
Үзләштерелгән биремнәрне мөстәкыйль тикшерү өчен сораулар һәм биремнәр .................................................. 188
**VI. Сөйләм культурасы һәм аралашу стиле .......................... 202**
Сөйләм культурасы ....................................................... 202
Әдәби яңгыраш нормалары .......................................... 203
Лексика һәм морфология нормалары ........................... 204
Синтаксис һәм стиль таләпләре .................................... 206
Халык алдындагы чыгышта стиль чараларының әһәмияте ......................................................................... 207
Сүз төркемнәренең стиль мөмкинлекләре .................... 208
Коръән аятьләренең татарча мәгънәләре теленә лингвистик күзәтү ....................................................... 213
Аятьләрнең туры һәм күчерелмә мәгънәләре ................ 213
Коръәндә лексик чагылдыру чаралары ......................... 218
Вәгазьләрнең лексик составы ....................................... 230
Көнкүреш сөйләм стиле ................................................ 265
Уку-укыту сөйләменең үзенчәлекләре ......................... 266
Уку-укыту эшчәнлегендә укытучының аралашу манерасы (стиле) ......................................................... 268
Укыту барышында – аудитория .................................... 269
Рәсми-эшлекле аралашу стиле ...................................... 270
Рәсми-сәяси аралашу стиле .......................................... 271
Өндәмә сөйләме стиле .................................................. 272

Үзләштерелгән белемнәрне мөстәкыйль тикшерү өчен сораулар һәм биремнәр .................................................. 274
**Әдәбият исемлеге ........................................................................ 276**
Шартлы кыскартылмалар ........................................................ 280
**Сүзлек ........................................................................................ 281**
**Кушымталар ............................................................................. 288**
**1 нче кушымта. Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте имам-хатыйбларының җомга вәгазьләрен укуы турында Низамнамә ........................................................ 288**
**2 нче кушымта. Җомга вәгазе .................................................. 295**
**3 нче кушымта. Корбан гаете вәгазе ........................................ 301**
**4 нче кушымта. Ураза гаете вәгазе .......................................... 312**
**5 нче кушымта. Никах вәгазе ................................................... 323**
**6 нчы кушымта. Коръән укылганнан соң дога кылу үрнәге .......................................................................................... 331**
**7 нче кушымта. Сөйләм техникасыннан практикум ............................................................................... 333**
**Эчтәлек ....................................................................................... 413**

**Ф.Ш. Нуриева, Г.С. Нуриев, Ф.Г. Миңнуллин**

# Дини риторика

Басарга кул куелды 14.12.2012

Офсет кәгазе. Ризографта басылды.

Формат 60х84 1/16. Гарнитура «Таймс».

Шартлы басма табагы 24,3. Шартлы нәшр. табагы 18,3.

Тираж 85. Заказ 42/1.

**Казан университеты нәшрияты**

420008 Казан, Проф. Нужин ур., 1/37

Тел. (843) 233-73-59, 233-73-28

**ISBN 978-5-00019-057-9**

9 785000 190579 >